ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

9.2005





2005 елның 12 августында Казанда
бөек композитор Салих Сәйдәшевка һәйкәл ачылды.
*С. Исхаков фотосы.*

# Казан утлары
# Qazan utları

2005

# 9

(995)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Галимҗан Гыйльманов, Марат Закир, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир— 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары— 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—43-56-12.
Шигърият һәм публицистика бүлеге— 92-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге — 92-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Рим ИДИЯТУЛЛИН. Хәтәр хәбәр китерә җилләр. Шигырьләр. .......... 5
Вахит ИМАМОВ. Казан дастаны. Тарихи роман. .......... 11
Фирая ЗЫЯТДИНОВА. Иң зур сөю. Шигырьләр. .......... 52
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Безгә язган һаман сагынырга... Шигырьләр. .......... 54

**ТУФАН МИҢНУЛЛИНГА 70 ЯШЬ**

Туфан МИҢНУЛЛИН. Тәэзиләкәй. Драматик хикәя. .......... 58
Туфан МИҢНУЛЛИН. Робагыйлар. .......... 70
“Таяныч ул—халык...” (шагыйрь Равил ФӘЙЗУЛЛИНның драматург Туфан МИҢНУЛЛИН белән әңгәмәсе). .......... 76

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Марсель ЗАРИПОВ. “Татнефть”нең бензин чишмәсе. .......... 89

Татарстан язучыларының XV корылтае материаллары. .......... 105

Бер сорауга — бер җавап. .......... 153

**ДИСКУССИЯ: “БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ”**

Ләйлә ДӘҮЛӘТШИНА. Киләчәккә күз төбәп. .......... 154

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Зиннур МАНСУРОВ. Чичәннәр кайтавазын кемнәр көчәйтә. .......... 159

**ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ**

Казбек ГЫЙЗЗӘТОВ. Халык тормышын язды. .......... 165

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. .......... 174

**ГАРИФ АХУНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Әлфинур НӘҖИПОВА. Хәзинә тапкан әдип. .......... 176

“Татар энциклопедиясе” битләреннән. .......... 183
“Казан утлары” архивыннан. .......... 186
Берлекнең яңа әгъзалары. .......... 188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. .......... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": исторический роман В. ИМАМОВА "Дастан о Казани" (продолжение); стихи Р. ИДИЯТУЛЛИНА, Ф. ЗИЯТДИНОВОЙ, Г. БАЙРАМОВОЙ.
"К 70-летию Т. Миннуллина": драма Т. МИННУЛЛИНА "Танзиля"; рубаи Т. МИННУЛЛИНА; беседа поэта Р. ФАЙЗУЛЛИНА с драматургом Т. МИННУЛЛИНЫМ.
"Публицистика": М. ЗАРИПОВ. "Бензинная кладезь "Татнефти".
Дискуссия "Герой нашего времени": статья Л. ДАВЛЕТШИНОЙ "Герои, влюбленные в мечту".
Материалы XV съезда Союза писателей РТ.
"Литературная критика": статья З. МАНСУРОВА посвящена творчеству поэта Г. Мурата.
"К 110-летию Т. Гиззата": статья К. ГИЗЗАТОВА "Писал о жизни народа".
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
"К 80-летию Г. Ахунова": статья А. НАЗИПОВОЙ о творчестве писателя.
Страницы из "Татарской энциклопедии".
Новые члены Союза писателей.
Из архива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: "Бабье лето"—работа художника Р. ГУМЕРОВА; писатель Захид Махмуди.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

"Prose and poetry": Historical novel by V. IMAMOV "Dastan about Kazan" (continuation); Verses by R. IDIATULLINA, F. ZIYATDINOVA, G. BAIRAMOVA.
"To 70th anniversary of T. MINNULLIN": drama by T. MINNULLIN "Tanzila"; rubai by T. MINNULLIN; discussion of poet R. FAIZULLIN with playwright T.MINNULLIN.
"Publicism": M. ZARIPOV. "Petrol well of "Tatneft".
Materials of the XVth assambley of union of writers.
Discussion "Hero of our time": article by L. Davletshina "Heroes enamoured in dream".
"Literary criticism": article by Z. MANSUROV devoted to creativity of poet G. Murat.
"To 110th anniversary of T.Gizzat": article by K. Gizzatov "Wrote about people's life".
"Science" A. TIMERGALIN. "Dictionary of nation". "To 80th anniversary of G. AHUNOV": article by A. NAZIPOVA about creativity of writer.
Pages from "Tatar encyclopedia". New members of Union of writers.
From archive of magazine.
Diary of a social-cultural life.
On our covers: "Indian summer", work of artist R. Gumerov; writer Zahid Mahmudi.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 22.08.2005 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А–630. Тираж 7011.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.



**Рим Идиятуллин**

# ХӘТӘР ХӘБӘР КИТЕРӘ ҖИЛЛӘР...

## Татарлыгын тарсынган туганга

“Бу заманда Тукайсыз да
Яшәп була”, дисәгез,—
Әткәң-әнкәң каберенә
Ялган яшьләр түкмәгез!

Көне өчен денен саткан
Хаинне акласагыз,—
Катыйль балтасын сагайткан
Җәлилне ятламагыз!

Күшеккән талны кочаклап,
Җылы тын өрмәсәгез,—
Туфанның ачы әрнешле
Йөрәген бәйләмәгез!

Кем илаһи моң каршында
Яшь түгүдән тарсына,—
Сарылмасын ул Сәйдәшнең
Шәрыкле сагышына!

Әгәр Илһам аһәңенең
Бәһасен белмәсәгез,—
Җанга пәрәвез үрәчәк
Моңсыз киләчәгегез.

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940) – *Уфада яшәүче татар шагыйре; “Хәерле иртә”, “Хәерле көн” исемле татар һәм башкорт телләрендә дөнья күргән китаплар авторы.*

Гавамның хәсрәт күлендә
Колачлап йөзмәсәгез,—
Алтын тулы авыз белән
"Халкым" дип сөйләмәгез!

..."Татарлыкның хакын хаклап
Яшәде", димәсәгез,—
Берүк, каберем туфрагына
Тамчы яшь тә түкмәгез!..

## Бергәләшеп китәләр дә...

Уралтаудан Кафтауларга—
"Күз күгәрер" аралар;
Бергә-бергә китәләр дә
Берәм-сәрәм кайталар,—
Әгәр исән калсалар...

Көньяклардан көн дә хәтәр
Хәбәр китерә җилләр:
Анда адәмнәр ашаучы
Аждаһалар бар, диләр.—
Кафтауда булмас ниләр!

Әйтәләр: кыя битендә
Ут бөркер чәчкә үсә;
Ят куллар кагылды исә,
Яшәр гомерен кисә,—
Сабагын кыеп өзсә...

Сабыйлар ич: уйга кертми
Янасыларын утта;
Исәне кайта—сөйрәлеп,
Көйгәннәре—табутта,—
Булмый йөзен танып та...

Хәсрәт яшьләрен әгәр дә
Агым суга койсалар,
Валлаһи да, ярларына
Сыймас иде дәрьялар,—
Түзә! Түзә Аналар!..

Итек белән изделәр шул
Ата-баба йоласын!—
Бала җирләгән Анасын,
Инде...
Ана җирли баласын,—
Сынган бәгъре парәсен...

Бергәләп киткән егетләр
Берәмләп кайта тора.
...Уты сүнгән өйдә кайгы
Керфек какмый утыра;
Ана укый бәддога...

## Маймыл елының соңгы көнендәге хәтәр хәбәрләргә күңел авазы

### 1

*"Көньяк-Көнчыгыш Азиядә җир тетрәүдән купкан дәһшәтле диңгез дулкыннары җәннәт илләрендә күңел ачучы йөзләрчә мең кешене һәлак итте".*

("Вакыт" программасы)

Назланганда иркә дулкын кочагында
Бар дөньяның фахише дә фахишәсе,
"Саф тәнемне пычратмагыз!" дип, шашыплар
Елагандыр гүзәл диңгез алиһәсе;

И Илаһым, атма каргыш! Адәмеңә
"Син маймылдан яралмаган!" дип төшендер;
Бу гарасат—гөнаһ җыйган без мәхлукны
Җәлләп, Җиргә тамган бөртек күз яшеңдер...

...Кичерегез:
Әрвахларга булмас үпкәм, юк ачуым,—
Аһ, беләмен
Якыннарны югалтуның җан ачысын...

2

*"Урыс диңгез сәяхәтчеләре Азия
кыйтгасын Сахалиннан аерган
бугазны беренче тапкыр кичкәндә,
шундагы кечкенә утрауларда өер-өер
кыргый этләр күреп, бугазга һәм
утрауларга "татар" исемен
такканнар".*
(Россия радиосының "Сорау—җавап"
тапшыруыннан)

Күкне терәр манаралар күреп,
Карагруһ заттан берәүсе
Әләк сызган Әби патшага:
"Җиргә чүксен, җиткерегез әмер!—
Чиркәүләрне каплый шәүләсе".

"Чыккан кояш батмас державаның
Мин бердәнбер, әйе, хуҗасы!
Күкләр исә—тәңре биләмәсе,
Ә Хак белән ара бозасы
Килми",—дигән патшабикәсе.

Аһ, падишаһ! Тууларың хактыр
Мәгърифәтле немка анадан;
Яу чабудан туймас урысны да
"Тудырмадың" нигә яңадан?!—
Күкләр белән коргач әшнәлек...

Ниләр юктыр Ходай әвәләгән
Балчык катыш адәм канында?!
"Татар" ул кырмавык булып килгән
Кыйтгаларны дер селкетеп җилгән
Маңгыт атларының ялында.

Могҗизалар җирдә, һи, бихисап:
Бәлкем, татар эттән яралган?—
Үзе ялый ачы ярасын...
Эт нәселен гомер сүккән "брат"
Мәңге адәм булмас маймылдан
Яралгандыр, бәлкем?!.

3

*"Гыйракның көньяк чүлләрендә
бозлы кар яуган".*
("Маяк" радиосы хәбәре)

Ком чүлендә боз кар ява, бу ни хәл?
Әллә күктә кузгалганмы ихтилал?

Җәт бу хәбәр Бушка барып ирешкән,
Эчләренә боз йөгереп, бөрешкән;

Буш, башына киң итәкле эшләпә
Элеп алып, юлга чыккан кичләтә;

Иярләп ул ракетасын, еракка—
Очкан дәрья артындагы Гыйракка;

“Әстәгъ, әстәгъ!” Ком өсләре шау шикәр...
Белми кемгә белдерергә әр-битәр;

Шом уятып, инде күз дә бәйләнә;
Бәй, сул кулда колга шәүлә шәйләнә.

Тар мәгарә мөешендә Бен Ладен
Башлап кына тора ястү намазын;

Күзен чәнчеп, тегеләй карый, болай,
И чамалый: “Техастан килгән ковбой!”

Игезәк чүл бүреседәй икәве
Карашалар бер-берсенә текәлеп;

Тиз ара Буш, дошманын сакалыннан
Тотып, әйтә: “Кимертәм шакалыңнан!

Кем ул чүлдә боз яудыра рөхсәтсез?!
Ярам башың!—минем куәт исәпсез;

Бер океан, җиде диңгез сикереп,
Юккамы без сезгә “ирек китердек”?!

Туктат тиз үк, яудырма боз бүлше!—ди,—
Әтү монда янкиларым өши”,—ди.

Бүлдереп Бен, ләгънәтле сүзен ата:
“Әйт, илне кем тәмуг утына тота?!

Аһ, син мөртәт, аһ, син тәмуг кисәве!
Иманлыга иман кертмәк исәбе;

Төшсен каһәр! Корт илен син тузгыттың,—
Кыямәт көн күр ачысын газапның!

Бирән кебек эчәсең дә җир сутын,
Әҗер итеп, бисмилласыз “Буш боты”н

Таратасың хәләл дип бар тарафка;
Хак, әйләндең дөньябасар каракка.

Ишәккә иш күсәк тоткан Штатың!
Качып йөреп, тузды соңгы ыштаным;

Пычагыма нәҗес каткан “ирегe”ң!
Кит, тыкшынма! Шиңдерермен кикригең!

Боз яудыру—Аллаһының боерыгы,
Шартлап катсын баскынчының коерыгы!

Тфү, иблис! Бүлдерден намазымны;
Дога кылам: корт чаксын авызыңны!"

Бу хурлыкка ковбой Жора түзмәде,—
Чепелт күзен көпшә итеп төзәде:

"Тәсбихеңнең тарт та соңгы төймәсен,
Укый башла әҗәлеңнең сүрәсен!..

Мин—җентелмән*, җентелмәннең сүз кыска:
Тиз әзер бул үлемечле орышка!

Ә әрнешеп ятмас өчен ярадан
Атышабыз унбиш ярдлы** арадан".

Бу тәкъдимне бик гадел гамәл күреп,
Аткардылар шартын шартка китереп;

Күр, әзерләр бер-берен ботарларга,
Ботарлагач, чәйнәп тормый йотарга;

Жора тоткан "Томогавк"***, гайрәтле,—
Тугыз башлы туксан дию куәтле;

Бен кулында, гыйбрәт ич, карале,—
Тутык совет "калашнигы" нибары!

Сукыр күрер—тигез түгел көч, әлбәт;
Ташбаш Буш та алды моны тиз шәйләп.

Бен әфьюнын торган арада чәйнәп,
Орды аңа таштан катырак таләп:

"Очкан җаның Кук штаты катына,
Җиткер фәрман баш нәчәлник Раббыңа:

Бөекмен дип, бик ашынып китмәсен,
Кайнар чүлгә салкын бозын түкмәсен!

Ул—ахирәт дигәненә баш түрә,
Ә фание—минем хөкемгә керә".

Дәһридән менә шундый яманны
Ишеткәчтен зәңгәр Кук тә каралды;

Автоматын илбасарга каратып,
Әйтте Ладен шулчак сүзен шартлатып:

"Син—Гитлерның тәмуттан качкан улы!—
Бел, мин—Аллаһның мөэмин бер колы;

* Джентельмен сүзеннән. Р.И.
** Ярд—озынлыкны үлчәү берәмлеге (инглиз).
*** "Томогавк"—ракетаның бер төре.

Җир әйләнә башласа да кирегә
Кол бирәлми әмер Бөек Тәңрегә.

Хәер, ник дәһригә иман талкырга!—
Бас, шашлык ясыйм синнән мин шакалга!

Ашмас җаның Күккә, ансын көтмә дә,
Җирдә явар ләгънәт сиңа бар телдә;

Хак мөселман олактырган кяфергә
Бозлы кар да бик яраган кәфенгә."

Атты күккә Ладен "Аллаһ әкбәр"ен,
Буш "әп итте" дүрт ботаклы тәресен;

Кояш черем иткән чакта баешта
Ташландылар галәм тетрәр алышка...

Шаһит булмый калмый язык һәр囚 эштә,—
Шундук Өскә хәбәр өргән фәрештә;

"Бар Ул, бер Ул" инсанына бик нечкә:
Ялт чакырткан яраннарын киңәшкә;

Ниләр булган? —Аңар безнең уй җитми,
Мәгәр хөкем кылынгандыр, Һай, җитди!

Жора ракетасын төзәп ятканда,
Бен "калашник" тәтесенә басканда,

Гаярь атлап сөзәк Гарәфә таудан*,
Җиткән төшеп Хозыр-Ильяс шулзаман;

Укыган да нидер, кырып тамагын,
Бәргән ташка капылт тылсым таягын...

Ни могҗиза! —Әйләнгән Бен сыртланга,
Ә Жора Буш—дүрт сыйраклы маймылга...

Шуннан бирле, сөенечем әйтәем,
Дөнья имин яшәгән, ди, әйкәем!..

*2004–2005*

---

* Гарәфә тау—Мәккәдәге изге тау исеме.

Вахит Имамов

# КАЗАН ДАСТАНЫ

ТАРИХИ РОМАН

36

Ибраһим әмир белән Даян сәрдәр житәкләгән болгарларның меңе дошман иравылларыннан кача-поса Идел яры буйлап шуышып төште. Шымчы жайдаклар баскыннар хәрәкәтен күз уңыннан бер дә ычкындырмый, арадашчылар әледән-әле кайтып жавап тота иде.

—Святослав Жигуле тауга таба төбәп бара. Алайларын унга-сулга жибәреп чирүне тараттырмый.

—Баскыннарның икенче яртысы буш дала буйлап сузылган. Аларда тәртип, уяулык чалымнары бөтенләй юк.

Алда Жигүле тау түбәләре тәгаенләнә башлагач, сагаерлык хәбәр кайтып житте.

—Даладагы гаскәр Жигүле тауга таба борылды. Мөгаен, Святослав белән кушылырга исәп тоталардыр.

Чыннан да, Жидеколак дигән сәер атамалы елга тамагында дошман чирүләренең ян-як алайлары бер-берсенә килеп тоташтылар. Меңбашлары, боярлар, мөнадиләр* ике нөгәр арасында чабып йөрде. Көтүче чыбыркысы сыман сузылган баскыннар гаскәре берзаманны корбан эзләп тапкан буар елан шикелле жыерылды. Алайларның һәммәсе дә хәзер арткы аякларына басып дошман өстенә сикерергә әзер торган жанвар хәленә килде. Идел буйлап озата төшкән болгарлар да ук очырырга жыенган тәтәдәй киерелделәр.

—Бортаслар жиренә килеп життек. Бәнжә каласы кул сузымында гына. Боларның берәр нинди этлек эшләве бар. Барча йөзләргә дә фәрман житкерегез. Һәрбер яугир орышка әзер торсын,—дип, тәүге әмерләрен озатты Даян сәрдәр.

*Мөнади — ханнарның фәрманнарын житкерүче кеше, глашатай.

*Дәвамы. Башы 8 санда.*

Шулай да, калкулыклар артында, тирән ерымнар эчендә барган болгар җайдаклары әле һаман эленке-салынкырак, пошмас кыяфәттә атлавын дәвам итте. Аеруча сәрдәрнең улы Насыйр үзен иркен тота иде. Шул һич тә көтелмәгән риваять бәян итте.

—Ошбу Җидеколак әлләни зур елга булмаса да, хәзәр даласыннан Иделгә ком ташый. Шул сәбәпле, Җидеколак тамагыннан бераз гына астарак кичү хасыйл булган. Аны Идел аша иң сай кичү, диләр. Ә сай булгач, билгеле ки, аймыклар да, кыпчак, бәҗәнәкләр дә, иң әүвәле, шуннан файдалана. Урысларның вятич кабиләләреннән, алан-чәчәннәреннән талап алган барча малны, коллар кәрваннарын менә шушы кичү аша куып чыгаралар. Идел буйлап төшкән сәүдәгәрләрне дә шушы урында тозак корып сагалыйлар икән. Шул нисбәттән ошбу төшне Җидеколак дип атаганнар да инде. Моны җиде колаклы, җиде күзле булып кичү дә артык гамәл түгел...

Насыйр Болгардагы болгану-мәхшәрдән качып, хәзәрләрдә шымчылыкта йөреп кайткан кеше. Аны Манас каханны үтереп тәхеткә Йосыф сикереп менгән чакта Әтилдәге сарай эченә үк үтеп кергән, диләр. Бардыр, бардыр. Насыйр утлар-сулар кичкән, елгыр сәйях, аңа ышаналар.

Насыйрның сәер бәяны болай гына да тәмамланмаган икән, егет янә күпләрне сагайтырлык сүз башлады.

—Узган ел урысларның Савилий атлы бер бояры харап булды монда. Юк, үлүен үлмәде ул, мәгәр, барыбер дә, үзенең сантыйлыгы аркасында тоткынлыкка төште. Әтил каласында каханнар алышыну, андагы башбаштаклык хакында ишеткән дә, тегеләрнең уяусызлыгына өметләнеп, таларга, баерга дип ашкынып килеп җиткән. Кияү каласындагы кенәзләрен дә кисәтеп тормаган ул. Башка боярларны да үз артыннан чакырып маташмаган. Имеш, берүзе генә искәрмәстән килеп төшә дә хәзәрләрне чалып ташлаган мал урынына рәхәтләнеп туный. Меңнән артык угрыны үз артыннан иярткән дә килгән. Асылда да, болар Әтил каласына терәлеп торган Төрекмәннәр бистәсен тоташ талаганнар. Ул нигъмәтләрен-малларын моннан ике фәрсах арасындагы Чуерташлы мәгарә эченә дә кертеп тутырганнар. Шул вакытта койрыкларын җыеп сыпыртсалар, ак сакаллы карт булырлар иде дә бит. Юк шул, нәфселәре янә Әтил ягына борган. Ә хәзәрләрнең яңа каханы Йосыф бу юлы инде менә шушы Җидеколак ярына тозак корып куйган. Урыс угрылары шуңа эләккәннәр. Каханга ялланган төрекмән җайдаклары урысларны тоташ турап чыккан. Исән калганнарын Әтилдәге коллар базарында мин дә күреп кайттым. Башлыклары Савилий утыз яшьләр чамасындагы бер пәһлеван иде. Андагы үгез шикелле таза буй-сын дисеңме, ул беләкләр дисеңме! Йодрыклары—чукмар! Иллә мәгәр аның дүрт йөзбашын базар уртасына куелган Салкын-таш өстендә кылыч белән телгәли башлагач, Савилийның күкрәккә җиткән сакалы күз ачып йомганчы ап-ак булды. Ә аның үзенең гомерен кыймадылар. Йосыф кахан әмере буенча, җәлладлар аның ике күзен төртеп тиштеләр дә, каладан читкә чыгарып җибәрделәр. Кайда йөридер ул хәзер, исәндерме-юкмы, беркем белми. Аны әлегә чаклы хәзәр даласында һичкемнең күргәне, очратканы юк. Ошбу Святослав та Йосыф өстенә барып, Савилий бояр өчен үч алуны максат итми микән?

Бер Даян сәрдәр генә көттереп телгә килде.

—Сукыраеп далада йөрүләрдән Ходай тәгалә үзе саклый күрсен!

Әмир Ибраһим янәшәсендәге меңбашлары белән яраннарның барчасы да Насыйр хикәяте белән сихерләнгән сыман әлләни кадәрле ара дәшми барды. Ибраһим үзе Даян сәрдәр белән аеры калгач кына, ниһаять, авыз ачты.

—Улың Насыйр сөйләгәннәрдән сабак алдыңмы соң? Безгә һәрбер чит

мәмләкәт, чит-ят кала эченә шымчыларны озатып тору кирәк. Әгәр дошманнарыбыз арасында күз-колаклар булдырмыйбыз икән, безне дә, әнә шулай, Савилийныкы сыман кара язмыш көтә. Бу Святослав кенәз чатыры артына да икеме-өчме шымчы тагарга онытма син...

Жидеколак елгасының бер як яры куна тактасыдай шома, тигез, икенчесен эреле-ваклы чокырлар, ерымнар ергалаган. Святослав шул ерымнар ягында төн кунарга ният итте бугай, зур гына чокыр тирәли туктап, арбалардан ике катлы ыстан кора башладылар. Чокыр эчендә дүртме-бишме чатыр үсеп чыкты, дистәләгән учак тергезделәр. Уйнашчы хатын өстенә сыланган сөяркә ир сыман, хәтфә дала буйлап зәңгәр төтен сузылды. Яңа суелган ит исе, шулпа исе борын яфракларын ярып үтте.

—Болай булгач, Святослав таң атканчы беркая да китми. Ялга тукталабыз,—дип күрсәтмәләр бирде Даян сәрдәр.

Болгарлар да яр астына яшереп кенә учак кабыздылар. Кайнар аштан соң барча ирләр киез киләмнәр өстенә сузылышты.

Төн уртасында барчасы да хәвефкә баткан мөнадинең оран авазыннан сикереп торды.

—Урыслар юк! Святослав безне алдап качкан!

Ибраһим әмир белән Даян сәрдәр, аның артыннан ук иравыл йөз ирләре урыс ыстаны торырга тиешле чокырга томырылды. Килсәләр, чокыр эчендә дистәләгән учак кына янып ята, сыпылып-тишелеп беткән чабаталар ауный, тик бер җан иясе дә юк. Ибраһимның борыны салынып төште.

—Артыннан күзәтеп баруыбызны сизгән бит бу. Йә арада бер сатлык бар. Шуңа бездән арынуны кирәк тапкан. Мәгәр кайсы якка киткән? Безгә каршы этлек эшләмәсме?

Баш ватып торырга, гоманларга ирек бирмәделәр. Ак күбеккә баткан чапкын килеп житте.

—Святослав Бәнҗә каласына бәреп керде! Святослав бортасларны талый!

—Әх, бәдбәхет! Әх, мәкерле төлке! Урыс белән якыная калсаң, сугыш балтаң билдә булсын икән,—дип сытып сүгенде дә, әмир Ибраһим шундук яу атының касыгына типте.

—Бар йөзне дә һөҗүмгә әзерләгез! Даян сәрдәр, Мөхәммәт хан янына чапкын җибәр! Баскын кенәзнең талап капкан һәр калҗасын костырырга кирәк...

Ни галәмәт, Святослав кирмән тирәли дә, кала диварлары өстенә дә каравыл бастырмаган. Ул үзен бөтенләй йә хуҗа, йә үч-җәзага тарымас сәргаскәр дип санагандыр инде. Берзаманны диварлар эчендә, Бәнҗә урамнары башында болгарларның берьюлы йөзәр-йөзәр җайдагы үсеп чыккач, урыс кенәзенең күзләре мангаена менде.

—Сак божрасы оештырыгыз, сак божрасы!—дип ярсый-ярсый кычкырып караса да, йорт-келәтләр талап йөргән юлбасар җайдакларны җыеп китерердәй яубашы табылмады. Ул арада инде тоткынлыкка төшкән Бәнҗә ирләре дә һушка килгән иде. Кемнәрдер ярымисерек урыс сугышчылары кулыннан кылыч-сөңгеләрен талап алды, кемнәрдер койма-читәннәрне җимереп коралланды. Ә аннары инде бортаслар белән болгарлар бергәләп баскыннарны изә башладылар. Святослав үзенең кул астына эләккән меңбашларны, боярларны типкәли-типкәли искә китерергә мәҗбүр булды.

—Казан төсле сак божрасы оештырыгыз, дим бит мин сезгә, җыен имгәк! Каланы таларга киткән бар гаскәрне җыеп китерегез!

Озакламый мәйдан уртасында сукса үгезне егардай пәһлеваннар сафы пәйда булды. Боларның кыяфәте үк дәһшәт бөрки иде. Саксызрак якынайган болгарларга биш-алтысының ат тоягы сыман йодрыгы да эләккәч, әрдәнә, такта, тәртә белән генә коралланган бортаслар карчыга күргән чебеш өере

сыман читкә сибелделәр. Пәһлеваннар арасында аеруча Галич егете Ермил барысын да балчык чүлмәк урынына сытып килә иде. Көтмәгәндә мәйданга алып килә торган бер тыкрык башыннан йомран шикелле сызгырган ук атылып чыкты. Икенче мизгелдә, муенына килеп кадалган ук сабына ябышып, Ермил җиргә ауды.

—Наз уйнаган чакта айгыр белән үгезгә дә, эт белән мәчегә дә аяк чалучы юк. Сиңа сабак булсын!—дип кычкырган урыс авазы ишетелде, хуҗасын гына чамалый алмадылар.

Мәйдан уртасына эт көтүе сыман куып китерелгән чабаталы урыслар кереп тулды. Мизгел эчендә болгар яугирләрен тыкрыкларга кысып чыгардылар. Ләкин үзен хуҗа итеп, тыныч хәлдә тоючы табылмады. Төнге караңгылыкта күзгә күренмәгән сарай, келәт, өй түбәләреннән мәйданда исәңгерәп торган баскыннар өстенә меңәрләгән ук яңгыры очты, дистәләгән урыс ирләре күкрәкләренә, муеннарына, эчләренә тотынып җир өстенә ауды.

—Кала читенә, далага чигенегез!—дип үкерде берзаманны түземлеген җуйган Святослав кенәз.—Калага ут төртәбез!

Болгар белән бортас ирләре күпме генә уяулык күрсәтмәсен, кисәү күтәреп йөгерешкән баскын сугышчыларны ут очыртып чупли алмадылар. Күз ачып йомган арада каланың дистәләгән почмагында янгын купты. Хыянәтче очкыннар түбәдән түбәгә сикерде, бар урамга зәһәр төтен тулды. Дәһшәтле җил тавышын, елау-сыктауларны яубашларның әмере күмеп китте.

—Каланы коткара алмыйбыз, диварлар артына йөгерегез!

—Далага чыгыгыз, далага!

Урыс җайдаклары каланы иң беренче булып ташлап чыккан иде. Яланда аптырашып, кайгырып тормадылар. Боярларның әмере янгырауга, баскын җайдаклары тигезле-тигезсез сафларга тезелде дә, төнге караңгылыкта, мунча ташына салган боз шикелле эреп, шундук гаип булды.

Дулый-дулый, дөрли-дөрли янган Бәнҗә каршындагы яланнарда бортаслылар төркем-төркем тезелешеп калды. Аларны сызланмыйча, сыкранмыйча күзәтү дә мөмкин түгел иде. Һәркайсының яңагында кайнар яшь эзләре, әрнү, сагыш. Бик күбесе юньле киемен дә элэктереп чыга алмаган. Кайсы яланаяк, кайсы ярымшәрә. Байлыгын коткарырга ымсынган кешеләрнең дә зиһеннәре ычкынгандыр инде. Кулларына тотып чыккан әйберләр арасында җыен шырдый-бырдый: ашъяулыклар, урындык, таба, мендәр.

Таң атуга, Мөхәммәт хан гаскәре килеп җитте. Бәнҗә өстенә күз йөгертеп чыккач аңлатмалар бирү артык иде. Мөхәммәт хан ачулы карашы белән Бәнҗә хакиме булып исәпләнгән бәкне эзләп тапты. Уртларын шыгырдатып, терелэй йотардай булып бер генә сүз катты.

—Йә, артабан да Болгар мәмләкәтеннән аеры буласызмы?

Бәнҗә бәге сарык лапасына бүре кертеп гөнаһланган ялкау эт шикелле шуышып килде дә, ханның итегенә борын төртә-төртә, еламсырап-сыкрап тәкърарлады.

—Юк, бортасларның моннан ары болгарлардан аеры буласы юк. Без мәңгегә бергә!

Хан озак көттермичә болгар ирләренә әмер бирде.

—Бүген үк Бәнҗәне өр-яңадан төзергә керешегез! Иллә мәгәр кылыч-садакларыгыз билегездә булсын!

## 37

Иосиф кахан сараенда бүген тагын бәйрәм. Аланнар, ләкеләр көндез каханга олау-олау ясак алып килде, искеләре урынына унбер-унике яшьлек малайларны аманатлар итеп китереп тезде.

Хезмәтчеләр мунчаларда шундук утлар кабыздылар, харәмханәдәге кыз-тәкәләр аманат малайларны ләгәннәрдә юды, табиб булып йөргән фарсы ирләре һәркайсының тәненә зәйтүн, сырганак майлары сөртеп чыкты. Әллә нинди сихерчеләр кереп, почмак саен канәфер, яран, нәркис, бөтнек, гөләп ботакларын яндыра-көйдерә хуш ис тараттылар. Пешекчеләр хөрмә, әфлисун, йөзем китереп тезде. Сорнайчылар, кубызчылар ян-як бүлмәләргә жыелып утырдылар. Хужаларның һәр минутта килеп кереп уйнаш коруы бар, якты дөнья белән хушлашасың килмәсә, һәр тарафта әзер тору кирәк.

Ә хәзергә Иосиф кахан әле сарай уртасында күңел ача. Ләке, алан кенәзләре белән бер мәжлестә утыру, билгеле ки, кахан өчен дан-дәрәжә түгел. Ләкин ул кыргый таулардагы кенәзләрнең кайтыр юлда әзери, чәчән авыллары янында үтәсе бар. Күрсәтелгән сый-хөрмәтне бәян итми калмаслар, Иосиф кахан даны кыргый тауларга да китә бирсен.

Өстәлләр сый-нигъмәтләр белән сыгылып тора, әмма ләке, алан кенәзләренең күзләре гел зал түренә көйләнгән мәйданчыкта. Анда анадан тума чишенгән япь-яшь кызлар елан сыман боргаланып бии. Каханның кулында сәйлән чылбыр. Иосиф бер очыннан күтәреп шул чылбырны өстәл өсте буйлап уйнаклата, ә кызлар, сихерләнгән сыман, сәйләннәр хәрәкәтенә ияреп янтаялар. Кахандагы чылбыр уңъякка бөгелеп дугалана икән, шәрә сылулар да йомшак мендәрләрен шул якка күпертеп бөгеләләр, сулга икән, сулга. Иосиф сәйләннәрне өстәл өстенә ташласа, чибәркәйләр идән буйлап тәгәрәп боргалана. Сылуларны мондый көйле уенга күнектерү өчен бик аз вакыт китмәгәндер инде, ә шулай да, күзәтеп утырган чакта кызык, рәхәт.

Мәйданчыкта кызлар бер-бер артлы алышынып тора. Иосиф мактанмыйча түзми.

—Әнә, сул яктагы каракай—бортас кызы. Теге, ерак почмактагы бөдрә чәчле сылу—аймыклардан. Аның янәшәсендәге кара чутыр—тажик канизәге. Ә менә монысы, ак чәчлесе—вятичлардан бүләк.

Тауныкыларга аеруча ап-ак карда юган житен сыман чәчле кыз ошады. Ул башкаларга караганда озынчарак буйлы, ботлары да озын, тыгыз; күкрәкләре чәйнек шикелле кабарып, сөзеп тора. Житмәсә, кыз кымшанган саен шул күкрәкләр су өстендәге калкавычлар шикелле сикереп уйнаклыйлар.

Иосиф тау кенәзләрендәге ач карашны тоеп алды бугай, ияге белән ым кагып вятич кызын үз янына дәште. Кызый гаурәт жирен каплап йөгереп килгәч, кахан алан кенәзенә борылып хихылдады.

—Вятич сылуы ни дә, алан сылуы ни, жан жирләре бер үк. Ышанмасаң, әнә, тотып кара.

Алан кенәзе болай да ымсынуын көч-хәл белән тыеп утыра иде. Каханнан рөхсәт булгач, сылуның ике кулын да читкә этәреп куйды. Кытай әлифбасын күргән сыман исе китеп дәште.

—Әт-тәч, бу төше дә сары!

Кахан үзе дә, өстәл артына тезелешкән вәзир-яраннар да сарай түшәмен күтәрердәй итеп дәррәү кешнәделәр. Алан кенәзе исә тыелып кала алмады, кызыйның жәннәтен әүвәл бармаклары белән кармалады, аннан борының тыкты. Хәзәр хужалары янә өстәл тøя-тøя кешнәвен дәвам итте.

Нәкъ шул мизгелдә залга яралы бер чапкын атылып килеп керде. Ярты йөзе, муены канга баткан, жилән-күлмәкләре умырылып беткән. Йөгерә-йөгерә сулышы капкан бугай, сүзләрен дә юньләп әйтә алмый.

—Кахан, дошман! Калага... Идел яклап... дошман бәреп керде. Әллә... урыслар гаскәре инде ул, әллә Мөхәммәт хан?.. Берни аерып булмый... Ләкин яралансалар, урысча сүгенәләр.

—Кайсы калага?—дип үкереп урыныннан сикереп купты Иосиф кахан.—Кайсы калага бәреп керделәр, дим?

Чапкын канлы иреннәрен ялап янә тәкърарлады.

—Әтилгә... пайтәхеткә... бәреп керделәр, кахан. Сугыш хәзер урамнарда бара. Дошман гаскәре... кул сузымында гына.

Иосиф кахан сый тулы өстәлләрне әйләндереп атты, колакларны сытардай куәтле, әче тавышы яңгырады.

—Каравылбашлар белән сәргаскәрләр кайда? Дошман пайтәхеткә бәреп кергәнче нәрсә караганнар? Мин аларның муеннарын чаптырам, дарга астырам, суям!

Агарынып калган вәзирләрнең берсе өшәнеп кенә иреннәрен ачты.

—Теге, Киев кенәзе Святослав бер ай чамасы элек "Синең өскә барам", дигән кисәтү җибәргән иде, хәтереңдәме, кахан? Әллә шул Святослав-ташбаш килеп житте микән?

—Каханга каршы корал күтәрергә аның башына тай типкәнме әллә?

—Бәлки, болгарлар, бортаслар белән бергә кушылгандыр, кемнәр белсен инде?..

Залга, ниһаять, каравылбаш үзе килеп керде. Бу да яраланган, муенында сынган ук сабы тырпаеп тора. Куәте дә беткән икән инде, тавышы гырылдап-гыжлап чыга.

—Кахан... дошман... Киевтан... Святослав...

Иреннәрен йомуга ук каравылбаш таш идән өстенә бау кисәге төсле авып төште. Моны инде дар-балталар белән өркетү артык иде. Иосиф ишек төбендә торган сакчыларга төбәлеп әмер бирде.

—Миңа калкан-кылычларны китерегез! Әтилне саклауны үз кулыма алам!..

Сарайдан чыксалар, пайтәхет өстендә Идел яклап әллә ничә урында янгын дөрли. Урамнарда сугыш. Кычкыру һәм сүгенү авазлары кахан кирмәненә якынаеп килә, димәк, вәзирләр, сәрдәрләр көмеш тәңкәләр хакына яллаган таҗик, аймык, кыпчак җайдаклары баскыннарга каршы тора алмаганнар.

—Аргамакны китерегез миңа, айгыр китерегез!—дип үкерде Иосиф кахан, бер өер бүре улавын күмәрдәй иләмсез тавыш белән.—Каравыл һәм жансакчылар алае, минем арттан!

Кирмән диварларының тышында ук Святослав белән йөзгә-йөз килделәр. Кахан әләмнәрен шәйләп алгач баскын кенәз аеры батырайды.

—Тантана итәсе көннәрең бетте, кахан. Мин синең кирмәнең урынында көл калдырып китәм. Саклардай-яклардай куәтең бар икән, минем белән шәхси алышка чык!

Иосиф иреннәрен мәсхәрәле бөреп җавап тотты.

—Колчура белән орышып, кахан дәрәҗәсен мыскыл итеп булмас! Синең ише сукбай, юлбасарга минем жансакчы да артык. Батыр булсаң, әнә, ат караучы Жәкәү белән орыш!

—Әх, куркак жан! Әх, печтерелгән тәкә!—дип, гарьләнүдән ярсып, Святослав кылычын болгый-болгый кахан тарафына томырылган иде, күмергә буялган шикелле чем-кара бер гарәп тәртә сыман озын сөңге белән тәкәббер кенәзне ияреннән чәнчелдереп атты.

Дөя сыман озын буйлы гарәп инде аты белән бастырып килә иде, әле ярый, Святослав кенәзне яраннары тояк астыннан йолкып өлгерделәр. Кенәзнең нинди мөшкел хәлгә калуын күреп калдылар, ахры, берничә минуттан кирмән алды урыс җайдаклары белән шыгрым тулды. Кайсы көянтә буйлы кылычын болгап якыная, кайсы ыргак башлы, юан сөңге сузган. Тәкъдир—явыз, аның белән шаяру-алышуда отышның булганы юк.

—Ахмак таждар гына каланы саклап үлә,—дип пышылдады Иосиф кахан үзен тирәләп алган вәзирләргә.—Акылы бар хаким алайларын коткара, халкын яклый. Святослав көл итәм, дип өркеткән кирмән урынына мин янадан бишне төзеп куям. Ә гаскәремне кырдыртсам, яклаучысыз сукбай хәленә калам.

Иосиф артка тезелешкән жансакчылар алаена борылып әмер бирде.

—Шәһәр буйлап мөнадиләр жибәрегез, каланы ташлап чыгабыз. Тәбегә эләккән күсе хәленә калгач Святославның минем алга шуышып киләчәген сез соныннанрак күзәтерсез әле...

Кахан сарае да кулларына төшкәч, урыс баскыннары атна-ун көн буе туй иттеләр. Берәүләре харәмханә эченнән чыкмый рәхәтләнде, икенчеләре хәмер-шәраб күленә чумып йөзде, уяураклар урамнан урамга күчеп йортлар таладылар. Ләкин пайтәхет дигәннәре яртылаш янып беткән, өстәвенә, инде монда яшәгән болгар-тажиклар да күз төшәрдәй ихаталарны айкап үткән иде. Баскын сугышчылар арыш капчыкларына күлмәк-чалтәр, таба-соскы сыман иске-москы гына жыеп кайтты.

Берзаманны айныдылар болар. Күпчелек сугышчылар йөзбашлары, меңбашлары аша Святославтан туган якка кайтуны таләп итте. Ерак юлларда йөреп үзе дә арыган кенәз, ниһаять, бер таңда ияргә менәргә әмер бирде. Чабата олтырагы сыман сузылып кирмән-кала читенә чыкканнар гына иде, баскыннарны төрле яклап Иосиф кахан чиргүе чолгап алды. Иосиф тауларда йә күлләрдә яшерен тоткан хәзинә хисабына яллагандыр инде, гаскәрендә баштан-аяк коралланган бәжәнәк алайлары, алан жайдаклары.

—Артка, кире диварлар эченә!—дип, Святослав ярсый-ярсый кычкырып караган иде дә, урыс гаскәренә чигенергә ирек бирмәделәр.

Иосиф алайлары баскын гаскәрне, сазлык эченә баткан фил өстенә ябырылган карга өере төсле, төрле яктан килеп чукыдылар. Святослав арбалардан түгәрәк ыстан да корып карады, вакыт-вакыт үзе башлап һөжүмгә дә күчте, файда-отыш дигәннәре барыбер күренмәде. Бәжәнәк һәм алан жайдаклары кыйгач ташкын булып килә-килә урыс гаскәренен яртысын кырып салды, ыстан канга батты. Ахырда, инде аптыраганнан гына, яна төрле әмер бирде кенәз.

—Әйдә, менә монда чөй шикелле булып тезелегез! Очка үзем басам. Минем арттан калмый ташланырсыз.

Һавадагы аккошлар чылбыры шикелле очланып сугышуны тау жайдакларының күргәне юк иде. Әүвәл алар урыс баскыннарының нинди мөгез чыгарганын да аңлый алмый аптырашып тордылар. Ә аланнар һәм бәжәнәкләр искә килгән чакта Святослав гаскәре, янгын купкан амбардагы күселәр сыман, чолганыштан чыгып качкан иде...

Яһүди Иосиф кахан шул көнне үк кичен сараена вәзирләрен, яубашларын, базарлар тотучы, кәрваннар йөртүче байчураны, үзенә тез чүккән барча күрше бәкләрен жыеп сабак бирде.

—Урыслар безнең өскә килгәнче башта болгарларны юк итәргә маташканнар икән. Болгарларны тезгә чүктерсәләр, билгеле ки, байлыкларын талау белән генә канәгатьләнмичә, аларның ин чибәр, булдыклы кызларын хатынлыкка алып китәрләр дә үзләренә гаярь уллар таптырырлар иде. Ә ир-егетләре исә, колчура рәвешендә, урыс гаскәре сафында урыс тәхетенә хезмәт итәр иде. Болгар билен сугып сындырсалар, аһ, көчәясе, көрәясе булган урысларның! Ярый әле, дуга итеп бөгә алмаганнар. Шуңа күрә сезгә нәзер һәм аманәт. Моннан ары болгарларны саклагыз, аларга тимәгез сез. Болгарлар—урыслар белән яһүдиләр арасындагы калкан. Урыс болгарны тез астына салса, аннан безнең чират.

## 38

Мөхәммәт хан йортын кырау сукты ахры. Болгар каласыннан Бәнҗәгә тагын күнелсез хәбәр килеп җитте.

—Әмир Тимер-Мөэмин үз чирүен алып Растуф өстенә барган. Ана Җукәтау белән Кашандагы башкисәр олаучылар да ияргәннәр. Тимер-Мөэмин Сура елгасын кичкәч кырыкка якын урыс авылын яндырып, талап үткән. Хәзер Растуф кенәзе Касьян безнең мәмләкәткә җавап явы әзерләп ята икән. Тимер-Мөэмин үзе әле дә әйләнеп кайтмаган, хәзер аны чирмеш олысларын талап йөри, диләр.

—Болгар иле турында кайгыртучы яңа хуҗа, яңа каһарман табылган, әх, имгәк җан!—дип сүгенде Мөхәммәт хан, чын күңелдән сызып.—Әле Йосыф кахан белән Святослав кенәз талавыннан котылган юк, ә бу инде өстәмә дошман эзләп, ил өстенә яңа кайгы-михнәт чакырып ята.

Башкаларны кисәтми-нитмичә Мөхәммәт хан үзенең юл киемнәрен барлап чыкты, кулына кылыч, камчы, көмеш очлым тотты. Чатыр ишегенә карап алгач кына, әмир Ибраһимның иңенә йөзен төртеп, әрни-әрни дәште.

—Үземнең өй эчендә тәртип салалган юк, ә мин, ахмак, илне гөл итмәкче булып хыялланып йөрим... Кайтмый булмый. Илне янә дошман явын каршылау өчен әзерләргә кирәк. Туган улкаемның гөнаһысын атасы булса да юа алмас микән?..

Ишек чаршавын ача башлагач, кире борылып, күңелендәге соңгы серен әйтте.

—Сине гомер буе үз янымда гына тотар идем дә бит, ни үкенеч, син монда да кирәк...

Кала-авыллар арасын чабып узган саен Мөхәммәт ханны язгы кар сулары, ерганаклар кебек төрле яктан агып килгән яңадан-яңа хәбәрләр каршылады.

—Растуф кенәзе Касьян Чаллы каласын тоташ яндырып чыккан. Хәзер ул кала урынын Корым-Чаллы, диеп атаганнар икән.

—Чирмешләр Тимер-Мөэмин гаскәрен тозак куеп саклап торганнар да, Ямансаз дигән баткаклыкка кертеп батырганнар. Болгар җайдакларының нәкъ яртысы шул сазлыкка чумып юкка чыккан...

Болгар үзәгендә үз кесәсендәге шикелле иркенләп актарынган Касьян кенәз гаскәрен Мөхәммәт хан Илбуга каласы янында эзләп тапты. Шүрләп-икеләнеп тә тормады ул, Болгар белән Кашаннан җыеп чыга алган барча хәзинәсен бөркәвечле арбаларга шыплап тутырды да, дошман ыстанына үзе барып керде.

—Дуамал улымның гөнаһысын юар өчен үзем килдем, кенәз. Теләсәң ас мине, теләсәң кис. Ләкин Болгар буйлап яу йөрүне туктат.

Инде бөкресе чыга башлаган, ак сакаллы Касьян Мөхәммәт ханга текәлде дә катты. Ул, мөгаен, хан кадәрле ханның үз каршына ялынып килүен күрүгә караганда "Идел кирегә ага башлаган", дигән сүзләргә тизрәк ышаныр иде. Күрәсең, нәкъ шул нисбәттәндер, ул Мөхәммәт ханга ярты сүз җавап та кайтара алмый торды.

—Безне әле генә Киев кенәзе Святослав шәрә калдырып китте,—дип, җае чыккач дәвам итте Мөхәммәт хан.—Бәнҗә көл эчендә. Хәзәр каханы Йосыф ел да килеп талый. Яңа яулар күтәрергә көч-куәт юк... Малаемның ахмаклыгы өчен мине кичер. Үз кызымны сиңамы, малаеңамы биреп туганлашыр идем, анысы да юк. Зөлфиям хәзәр каханының харәм сараенда... Ә зиннәткә-малга кызыгасың икән, арбаларым, әнә. Шуннан ары сынык алтын, сынык көмеш тә юк. Өстемдәге киемнәрне салдырып алсаң гына...

Касьян күңеле саңгырау түгел икән. Чынлап еласаң, сукыр күздән дә

яшь чыга, дигәндәй, Мөхәммәт хан ачыктан-ачык сөйләве белән Ростов кенәзен аркасына салды. Ул төнне әче бал, мәҗлес, бетмәс-төкәнмәс вәгъдәләр белән үткәреп җибәрделәр. Икенче көнне үк Касьян кенәз үз биләмәсенә кайтып китте. Әле һаман тынычлык таба алмаган Мөхәммәт хан чирмешләр ягына чапкыннар юллап караган иде, Тимер-Мөэминнең шартын җиткерделәр.

—Гаебемне беләм, тәхетне өмет итмим. Атай миңа Тубылгытауны бирсә, эт баласы сыман шуышып кире кайтам. Бирми икән, бар чирүне алып, хәзәр каханы янына ялчы булып китәм...

Икеләнү-газап эчендә бер ай вакыт узды. "Акыл—күәс чиләге төбендәге әче камыр да, бер чеметем тоз да түгел шул ул, аны күршеләргә кереп кенә әҗәткә алып булмый",—дип әрни-тилмерә сызланды хан. Ә аннары инде, янып көлгә кала язгач, әрсез улы янына яңа чапкын куды.

—Кайтсын, ачуланмыйм, Тубылгытауны бирәм.

## 39

Атна буе барган сырхау-газаплардан соң Мөхәммәт хан үзенең ятагында төнге күл өстендәге үрдәкләр шикелле шым да итми йоклап ята иде, тиз-тиз атлап кергән каравылбаш тавышына сискәнеп баш калкытты.

—Әтил каласыннан сәүдәгәрләр кәрваны килеп төште. Алар синең кызың Зөлфияне монда алып кайткан.

—Кызымны? Зөлфияне?—дип Мөхәммәт хан, сызлануларын онытып, шундук сикереп торды.

Хан үз өстенә әле җиләнен кияргә дә өлгермәгән иде, тын бүлмәгә сулышы капкан Зөлфия йөгереп керде.

—Әти, әткәем!

Мөхәммәт ике адым алга атлады да, тәмугъ газаплары кичеп кайткан кызын көзге яфрак шикелле калтыранган кочагына кысты.

—Балакаем минем, балакаем!

Бер-берсенең кочагыннан аерыла алмыйча байтак тын тордылар. Зөлфиянең тәне песи тырнагыннан котылган кош баласы сыман сулкылдады, ханның яңагыннан кайнар күз яшьләре акты. Ата кешенең иреннәре, торып-торып, һаман бер үк сүзне пышылдыйлар иде.

—Теге чакта яклап кала алмадым, кичер мине, балам. Кичер, балам.

Ниһаять, Зөлфия үзенең йөзен әтисенең күкрәгеннән алды. Мөхәммәт үз күзләренә үзе ышанмады. Егерме яшен яңа тутырып узган Зөлфиянең ирен читләренә, күз тирәләренә җыерчыклар яткан. Чигәләрендә, маңгай өсләрендә дистәләгән чал чәч ялтырый. Күзләре сүнеп баручы учакныкыдай нурсыз, салкын, төссез. "И-и, балакай! Сират күперләрен кичеп кайткансың икән бит син!"

Зөлфиянең киемнәре дә үзгә. Балтырларын кереш белән буган киң балаклы, буйлы-буйлы ыштан. Иярга атланырга җайлап куйган төсле алгы итәкләрен бил тиңентен кискән җилән-халат. Беләкләрендә, муенында сары гәрәбәдән тезгән сәйлән-муенсалар. Чәчен ат койрыгы сыман ясап артка салындырган. Колак яфракларында бизәксез-нисез тәлинкә чаклы алка. Бармак очларында махсус үстерелгән мул тырнаклар. Гаҗәп, Зөлфия хәзер сөрмә-иннекләрне дә мул куллана икән. Аның ике кашын-керфекләрен чигәләренә чаклы сузган сөрмәләре болгар кызын бөтенләй чит-ят кавем баласына әйләндереп куйган.

Аш бүлмәсенә чыга башлагач, кызының атлап йөрешен күреп, ата кеше янә хәйран калды. Зөлфия аягына кысан башмак кигән сыман вак-вак

итеп атлый, корсагы алга чыккан. Атлаган саен йөзе җимерелә, сызлануын сиздермәскә теләп иреннәрен тешли. "Әллә берәр төрле чире бар микән дә, кахан моны шул сәбәпле азат итте микән?"—дип шөбһәләнеп уйларга мәҗбүр булды ата.

Табын янына утыргач, Зөлфия Әтилдә булып узган хәлләрне ике-өч сүз белән генә бәян итте.

—Урыслар бәреп кергәч кахан каладан чыгып качты. Мине Әтилдәге болгарлар коткардылар. Рәхим байга ияреп монда кайттым. Дала буйлап кына, кача-поса...

Мөхәммәт хан кызының сәламәтлеге турында кабат-кабат сорап караса да, Зөлфия һичбер төрле җавап кайтармады. Аның каравы, мунчадан соң имче карчык кереп тишкән серләр хан бәгырен тимер ыргак сыман телеп үтте.

—Харәмханәдә бахырның бар әгъзасын эштән чыгарганнар...

Икенче таңда әтисе янына килеп керүгә үк Зөлфия тик бер сорауны гына бәгыреннән сыта-сыта дәште.

—Бәнҗәдәге Булат атлы батыр күптән өйләнгәндер инде, әйеме, әткәй?

Мөхәммәт хан, кызының өметсез карашын тотып алгач, утка пешкән карак хәленә калды. Ул йөзен аска яшерде, кызының күзләренә күтәрелеп кабат бага алмады. Җавабы да иләк аша үткәргән шикелле өзек-өзек чыкты.

—Булат батыр... юк инде ул, балакаем. Сине коткарам дип... кахан чирүе артыннан барып... әрәм булды...

Кичен Болгардагы җәмигъ мәчете манарасыннан кәүсәр чишмә челтерәве кебек саф тавышлы бәхетсез бер кызның җыруы ишетелде.

Вак инешләр кушылып, гөрләп ага
Дәрьяларга, олы Итилгә.
Газиз башың, әй, хур була икән
Япа-ялгыз калсаң чит илдә...

Иртән манара янындагы чирәмлектә Зөлфиянең җансыз гәүдәсенә тап булдылар.

## 40

Киевка кайтып кергәч Святослав үзен беренче мәртәбә чын хуҗа шикелле иркен тотты. Әнисе Ольга сырхаулап түшәк өстенә ауган, уллары Ярополк белән Олег читтә. Владимир Киев боярлары билгеләгән сынауларны үтеп, исән-сау көенчә кабат әйләнеп кайткан. Күргән михнәтләре турында кыска гына сөйли.

—Күпчелек вакытны мәгарәләр эчендә үткәрергә туры килде. Кулга нинди җан иясе килеп капса, шуны ризык иттем. Бака, күсе, әрлән, кыр кәҗәсе, тиен—берсе-бер калмады. Ике мәртәбә үлемнән чак котылдым. Берсендә ач аю килеп ябышты, икенчесендә бүреләр көтүен турап качтым. Иллә мәгәр кыргый җанварлар янәшәсендә көн күрүе хәвефсезрәк икән...

Сорап тору артык: Владимир үзенең әле һаман эт типкесендә йөрүе белән риза түгел. Сынау үтсән кенәз итәбез, дип вәгъдә бирсәләр дә, боярлар Владимирны тәхет-биләмәләр тирәсенә якын җибәрмиләр. Святославның хатыны Евпраксиянең теле элеккечә, һаман игәү сыман.

—Уйнаштан туган малаең турында сүз кузгатып авыз пычратмәле! Үз өеңдәге ике улың үсеп килә, менә шуларга зур-зур биләмәләр өләшергә вакыт...

Сөйкемләме, сөйкемсезме, хатын—ул күләгә кебек. Аны чөйгә элеп куеп кына чыгып качып булмый. Святослав та дәшми-тынмый гына җай эзләде.

Балтыйк буендагы Новгород каласы әле булса кенәзсез-хакимсез көенчә яшәп ята икән. Святослав боярлар белән дә, кенәзбикәләр белән дә киңәшеп маташмады, Владимирга ерактагы шул каланы бирде.

—Бар, тәхетләренә утыр, идарә ит. Әбиен элегрәк аларга башлык итеп Ярополк белән Олегны җибәреп караган иде дә, новгородныкылар кире куды. Алар баш июне яратмый, алар вәкарь. Ләкин мин синен ялгызыңны гына җибәрмим, наиб итеп сиңа үз аганны, Добрыняны бирәм. Монда аны дошманнарның суеп ташлавы бар, Новгородка куллары җитмәячәк. Ерак калада, ичмаса, баш сакларсыз. Бергәләп тотынсагыз, Новгородны кулга алуыгыз да мөмкин. Ятып калганчы, атып кал, ди. Әйдә, тәвәккәлләгез...

Владимир белән Добрыня чыгып киткәннән соң ай артыннан айлар уза торды, Киевка бер төрле дә яман хәбәр кайтып ирешмәде. "Һе, кайнана сыман пырдымсыз Новгород халкына да ачкыч яратырдай кияү табыла икән",—дип үз-үзен юатты Святослав кенәз. Аннары утлы кисәү шикелле хатирәләр хәтер казанын кыздыра башлады. "Мине Әтилдә алан белән бәҗәнәк җайдаклары гына мыскыл итте. Сораннарның өсләренә үч алырга барам!"

Җәй башында каладан-калага катгый фәрман очты.

—Яңа яу сәфәренә кузгалабыз. Кала кенәзләре бирәр меңлек дружина белән шундук килеп җитсен!

Киевка егерме биш меңгә якын сугышчы кереп тулгач хыянәт ачыкланды. Кырпу-ат* таулары итәгендә утырган Аксайгак каласыннан Богдан атлы кенәз бер йөз кешелек тә чирү җибәрмәгән.

—Алга, әүвәл Аксайгак өстенә!—дип җикерде котырынган хаким.— Кирмән урынында кара казык кына утыртып калдырабыз!

Талау сәфәренә чыккан алайларга олау-биштәрләрне кайсы төбәк байлыгы белән тутыруның аермасы гел юк. Аксайгак каласына ач бүреләр көтүе сыман барып ябырылдылар да, сарык тиресе урынына әзгәләп ташладылар. Шәһәрдәге халыкның урак өстенә дип хәстәрләп куйган һәм кимичә, күз карасы кебек саклап тоткан чабаталарына тикле талап чыкты алар. Святослав шуннан ары гына төп гаскәрне бәҗәнәкләр өстенә алып китте. Көрпәле кенәзнең гадәти кисәтүе инде Киевтан ук чыгып очкан иде.

—Әзер торыгыз, сезнең өскә барам!..

Бәҗәнәкләр хакиме Коркыт хан баскыннар ташкының Тын белән Сал елгалары кушылган үзәнлеккә килеп каршылады. Ул Святославны бәҗәнәкләр җиренә бөтенләй аяк бастырмаска ниятләгән иде. Ләкин урысларның егерме биш мең кешелек коточкыч гаскәр туплап чыгу мөмкинлеген күз чалымына да китереп карамаган. Шулай да, Коркыт хан— дала аугире ул. Тау мәгарәләре, үзәнлекләр-ерымнар эченә качып көткән дошман тозаклары аның өчен кыргый яңалык түгел. Сабый чактан башлап кырыкмаса-кырык төрле дошман белән яуга кергәне бар, Аллага шөкер, башы исән әле. Бу юлы да бозлы яңгыр астында калган тавык көтүе кебек калтырап төшмәде, кыю, төгәл әмерләре яңгырап ишетелде.

—Камай, Әҗми! Гаскәрне икегә бүлегез!—дип кычкырды ул үзенең яубашларына.—Бер төмәнне Тын дәрья артына алып чыгып, кәстәнә урманы эченә яшерегез. Икенче төмән белән үзем монда калам.

Тозак төмән күздән югалуга, Коркыт хан калган җайдакларын ике елга яры буйлап чылбыр сыман итеп тезеп куйды. Чылбыр сыек, ике-өч кенә саф. Дошман чөй ясап, яисә йодрыктай тупланып килсә, майга калалган

*Кырпу-ат – Карпат.

хәнҗәр шикелле үтәли тишеп чыга. Коркытка шул гына кирәк, аннары ул ике канат белән ике тәртә сыман китереп сылаячак.

Коркыт хан җансакчылар алае, яраннары белән Тын елга ярындагы калкулык өстенә менеп басты. Үзе алда. Кыяфәт сокланырлык. Канга буяп чыккан төсле кызгылт аргамагы уйнаклап, биеп тора. Йөгән, ияр, өзәнге-дирбияләр—һәммәсе дә алтын тәңкә белән бизәкләнгән. Садагы, хәнҗәр кыны, җиләне дә алтын җепләр кушып нәкышьләнгән. Ә муенына озын челтәр яткан биек очлымы, кылычы, күн бияләй куньчлары гап-гади, саф корычтан. Коркытны ерактан меңбашы яки җансакчылар түрәсе дип кенә кабул итәр идең, аның очлым түбәсендә тәвис йоннары белән бизәлгән нәфис башак җилферди. Аның ише билге башка бер генә җайдакта да юк.

Коркыт ханның йөзе чүл гарәбенеке төсле кара янган. Хан, хаким, меңәрләгән җаннар хуҗасы, дип кыйланып-эреләнеп, сарай эчендәге тәхеттә генә утырмый бу, димәк. Янаклары җилдә яргаланган. Чал йөгерә башлаган мыек чылгыйлары ике яклап ияккә асылынган. Борын өстенә бөтәрләнеп килгән куе кашлар астында ике күзе күмердәй янып тора. Карашында икеләнү-шикләнү дигән коткыларның эзе дә төсмерләнми.

—Ана бүре, кыргый ана бүре,—дип бәяләде Святослав, тау башында балбал сыман басып торучы Коркытны күрүгә үк.

Аннары инде карарын да әйтте.

—Иң беренче булып әнә шул бүрене үтерәбез. Э-э-әй, Аксайгак гыйсьяннары! Гөнаһыгызны юарга сезгә форсат чыкты. Миңа Коркыт бүрене тотып китерегез!

Бояр тиуннары, җансакчылар Аксайгак каласыннан җыеп китерелгән алты-җиде йөз ирне сөңге, кылыч очлары белән төртә-төртә калкулыкка таба куалады. Сарайларга, келәтләргә качкан җирләреннән йолкып чыгарылган кешеләр бит, мескеннәрнең кыяфәт шәптән түгел. Кайсы өстенә итәге челтәрләнгән иске бишмәт, аягына тишек чабата кигән, кайсы яланаяк, бер генә кат киндер күлмәктән. Чиру дип аталган бу көтүнең яртысы сөлге белән кылыч эләктереп өлгергән, калганнарының кулында чалгы кисәкләре, сәнәк, күсәк. Тормыштан инде әллә кайчан ук гайрәт чиккәннәр, ахрысы, сугымга озатылган сарык көтүе урынына тота-каба торып йөгерделәр. Барган шәпкә җан ачысы белән кычкыралар.

—Илем өчен түгел, балаларым өчен!

—Шушы көнгә калдырган җансуярга ләгънәт!

—Ләгънәт, лә-ә-әгъ-нә-ә-әт!

Бичаралар хан менеп баскан тау битенә дә җитә алмадылар. Бәҗәнәк мәргәннәре аларны ат өстендә утырган килеш кенә сәрпи ук очыртып кырып салды. Болытлар шикелле акрын-ипләп кенә аккан Тын елга ярында берничә минуттан соң фәкать ыңгырашу-сызлану авазлары гына ишетелә иде.

Святослав бернинди бәла-каза күрмәгән кешедәй, дәртле тавыш белән кычкырып фәрман бирде.

—Чернигов белән Оскол меннәре, алга! Аксайгак хәерчеләренең хурлыкларын юып кайтарыгыз!

Святослав Коркыт хан чигенмәс, үҗәтлегенә барыр, дуамалланыр дип өмет иткән иде, бәҗәнәкләр хакиме калкулыкны вәкарь ир очсыз фахишәсен ни рәвешле көндәшенә калдырса, шундый ук җиңеллек белән ташлады да китте.

—Куркак җан! Боламык, чүпрә!—дип Святослав ярсый-ярсый җикеренгән булды, Коркыт хан төкерәм мин сиңа, дип котырта диярсең, әйләнеп тә карамады.

Святослав тәмам туарылды, үзен-үзе белештерми шашты.

—Яуга, яуга! Болар дала бүресе түгел, хужа ыргыткан сөяк хакына ялланган эт көтүе. Боларга таулар арасына качып сарыклар гына көтеп йөрисе бар. Алга, алга! Бу куркак этләр өерен турап бетерегез!

Урыс алайлары бәҗәнәкләр өстенә яна агач куышы тапкан умарта күче сыман ябырылды. Бернинди хәйлә белми болар, тозакны абайламый. Арыш көлтәләрен чабагачлар белән кыйнарга чыккан игенчеләр кебек, кусәк-кылычларын болгый-болгый, болар мүкләк сыер төсле алга-артка карамыйча, чабаталарын сөйрәп атлауны гына беләләр. Нәтиҗәдә Коркыт ханның тозагына килеп эләктеләр. Анын Тын белән Сал елгалары буйлап тезелгән ике чылбыры хәвеф сизгән кош канатларыдай капылт җыелды да урыс чирүен ике яклап кабат китереп кысты. Үзәнлек тар, чолганышта калган урыс сугышчылары мичкәгә тутырылган маймыч шикелле кайнаша, чигенергә-качарга бер ара юк. Бәҗәнәкләр очырган һәрбер ук диярлек чираттагы корбанын эзләп таба. Үзәнлек өстендә кычкырыш, мәхшәр, тәшвиш.

—Ни пычагыма дип кенәз безне бәҗәнәкләр өстенә алып килде? Боларның һәркайсы ат өстендә, ә без ничек качыйк?

—Көбә кулмәкләр юк, тимер калканнар юк, ничек сугышасы?

—Үлем үзәненә килеп каптык, үлем үзәненә!..

Шулай да, сан - сан инде ул. Егерме биш мең ир-ат булып килгән гаскәр берзаманны бәҗәнәкләрне елгалар ярына илтеп кысрыклады. Урыс ирләренең тегермән канатлары сыман бертуктаусыз әйләнеп торган кылыч-чукмарлары меңәрләгән бәҗәнәк җайдакларын иярләреннән суырып алды, сытты, чәрдәкләде. "Дуамал орышта бу урман-саз карачкыларына каршы торып булмый икән",—дип нәтиҗә ясады Коркыт хан да, дошман өстен чыга башлаган бер минутта. Шундук әмер бирде.

—Артка, артка, елга аръягына!

Бәҗәнәк җайдаклары куна тактасыннан җил себереп төшергән кибәктәй капылт юкка чыкты. Урыс алайлары алачык мичендәге тимер сыман кызган иде инде, калканнары-кылычлары белән суга сикерделәр. Арттан Святослав шашып куалады.

—Алга, алга! Бәҗәнәкләрне кырып бетерәбез!

Коркыт хан тозактагы төмәнен тезеп караса да файдасы күренмәде. Тау түбәсеннән ычкынган таш өерен хәтерләтеп килгән урыс алайлары яңа төмәннең алгы сафларын да сытып-җимереп узды. Дошмандагы мондый чая дуамаллык дала яугирләренең өнен алды бугай, әле бер, әле икенче баштагы җайдаклар йөзәрләп-йөзәрләп кача башладылар. Коркыт ахырда җансакчыларына тешләрен кысып ысылдарга мәҗбүр булды.

—Оран салыгыз. Бердәм чигенәбез.

## 41

Святослав бәҗәнәкләрне пайтәхетләренә чаклы тын да алдырмый куды. Кенәз инде боларны ояларына кереп бикләнерләр, дип өмет иткән иде, Коркыт хан Тын елга ярында утырган Саркел каласын урап кына үтте. Күзләрен акайтып төбәлгән меңбашларга Коркыт көнбагыш ярган шикелле ансат бәян итте.

—Диварлар эченә, тозакка барып кермим. Илсез калсам-калам, әмма чирүсез калмыйм.

Меңбашлар арасында пышылдашу, ризасызлык тугач, янә кушып китте.

—Әнә, Йосыф кахан да әүвәл Әтил каласын ташлап чыккан иде. Соңыннан үзе шушы урман карачкысын кибәргә элгән бозау тиресе урынына умырды, өзгәләде. Шулай түгелмени?

Ниһаять, ризалаштылар. Бәҗәнәкләр гаскәре Маймыч елгасын* кичеп Көбә үзән ягына чигенде. Святослав Саркел диварларын җимереп керде. Керүен-керде, әмма ике-өч урамны айкап чыгуга ук акайды да катты. Моның исеме генә пайтәхет икән ләса! Кая карама, саман шакмаклардан төзелгән йорт. Тәрәзәләренә карындык тарттырып куелган, түбә урынына камыш. Ихатадагы агач сәкеләр, катлы-катлы челтәрләр өстендә эремчек кибеп ята, сарай артларында кавын-карбыз үсә, йөзем бакчасы бар. Боларны иярләр өстенә төяп буламыни? Төясәң дә, ни пычагыма кирәк? Байлыклары, алтыннары кайда?

Кала уртасына житәрәк кенә таштан салынган йортлар тезелеп китте. Коркыт хан сарае, әнә, нәкъ уртада, калкулыкта икән. Тирә-юне бакча, вак-вак күлләр, җиде-сигез манара кукраеп утыра. Кенәздән дә алдарак Чернигов сугышчылары килеп житешкәннәр. Алар инде, әнә, сарай артындагы келәтләрдән сыртларына салып савыт-саба, ефәк-парча төргәкләре, тимердән ясалган кылыч-калкан ташый.

Сарайга узгач, затлырак күренгән беренче бүлмәдә үк алты-жиде иргә тап булдылар. Көмеш җепләр белән нәкышьләнгән жиләннәренә, йомшак күн итекләренә карап, боларның хан даирәсендәге түрә яки туган-тумача икәнлеген чамалау кыен түгел. Аныграк сорашып торырга ара да бирмәделәр.

—Ханның казна сакчылары, битекчеләр, мулла-имам болар,—дип пышылдады Святославның колак төбендә инде баскыннар ягына авышкан бер сатлык җан.

Святослав әүвәл түрәләргә ияк кагып дәште.

—Хан казнасы кайда?

Түрәләрнең уклау йоткан сыман сүзсез торуын күргәч, жансакчыларының берсенә ым ташлады. Кылыч ялтырап алды, бер түрәнең башы идәнгә тәгәрәп төште. Святослав янә мәгарә салкынлыгы белән соравын кабатлады.

—Ханның хәзинәсе кая яшерелгән?

Бәҗәнәк ирләре эндәшмәде, тик алар да берәм-берәм башсыз калып ауды.

—Табарбыз, сездән башка да бик тиз ачыкларбыз,—дип, кансыз, канәгать рәвештә сөйләнде баскын кенәз.—Хуҗасын сатмый торган этләрсез халыкның булганы юк әле.

Святослав жил-жил атлап сарай түренә томырылды, яраннары чак-чак житештеләр. Хан залының ишекләрен тибеп ачуга, һәммәсе дә таш балбал шикелле катып калды.

Залның нәкъ урта бер жирендә хәнжәрдәй казык тешләрен ыржайткан ике каплан йөри, болар теләсә кемне ботарларга әзер. Аларны чакырылмаган кунаклар өстенә сикерүдән муеннарына тагылган нечкә чылбырлар гына тотып тора төсле. Чылбырларның очы тәхет ягына сузылып юкка чыккан.

Зал түрендә, өстенә ефәк-парчалардан махсус чатыр корып куелган калкулыкта ап-ак яулыкларга төренгән ике хатын утыра. Артларында берсеннән-берсе сабыйрак өч кыз, ике малай. Хатыннарның берсе яшь, төскә-биткә чибәр. Икенчесенең яулык читләреннән чалара башлаган чәчләре күпереп чыккан. Күзләре көл сипкәндәй төссезләнсә дә, карашы горур, тәкәббер, вәкарь. Үзе башлап, шунсы сүз башлады.

—Гөнаһсыз кешеләрне газаплама. Хан хәзинәсенең кайда икәнлеген барыбер белә алмассың.

—Син кем, Коркытның хатынымы?—дип сорады кенәз, моны ачыклауның отышы булмаса да.

Өлкән хатын ияген калкыта төште.

*Маймыч елгасы—бүгенге Маныч елгасы, Дон кушылдыгы.

—Коркыт ханнын әнисе булырмын мин. Телем-телем итеп турасаң да, мин улымны сатмыйм.—Ана кеше якыннарына таба баш иэде.—Хәер, киленем дә, оныкларым да сатмый. Өркетергә маташып азапланма. Без, сезнең кебек, урман кыргыйлары нәселеннән түгел!

Ярсудан үзен-үзе белештермичә Святослав ике генә адым алга атлаган иде, капланнар коточкыч ырылдап аның тарафына сикерделәр. Корыч чылбырлар гына кенәзне үлем тырнагыннан саклап калды. Святослав капылт артка томырылды, бөтен тәне энә кадагандай куырылды, мизгел эчендә шабыр тиргә батты. Артына әйләнеп күз ташлаган иде, тәхетне тирәләп баскан балаларның, аналарның карашында һаман хафалану, нәфрәт, үч очратты. Түземлеге бетте. Бусагадан атлап чыгышлый, меңбашлары тарафына жилкә аша гына әмер атты.

—Ишек-тәрәзәләрне томалап ут төртегез. Бөтен елан бергә янып бетсен!..

 Яртылаш янып көлгә әверелгән калага кайтып кергәч, Коркыт хан кара нигез өстенә тезләнеп ләгънәт орды.

—Хатынны алыштырып, балаларны янадан табып була. Газиз аналарны алыштырып булмый. Әнкәм өчен гафу итәсем юк. Үч алмыйча үлмим. Барыбер башына житәм. Каргыйм ул кыргыйны. Аллаһтан ялварып каргыйм. Бәддога ул чабаталы урман кыргыена! Нәләт ана, ләгънәт!

## 42

Святослав Киевка әйләнеп кайтса, газиз Малушасы жир йөзеннән киткән. Ни булгандыр ана, бер атна эчендә саргаеп кипте, диләр. Ат караучы Йомыкый Герасим гына гайре сәер, аеры сүзләр сөйли.

—Евпраксия бер ай буе аучылардан бүреләрнең үт куыгын ташыттырды мина. Сукыр Маланья йортында камырга шуны кушып икмәк пешерделәр...

Бер ел чамасы да вакыт үтмәгәндер, кенәзбикә Ольга, гел тәгамьнән калып, түшәк өстенә ауды. Көннән-көн күзгә күренеп кибә, су да капмый, тәүлек буена сызланып-аунап чыга. Святослав аның янында көн дә елый-елый газаплана, үзе һаман кирә. Үз-үзен, күңелен, хисләрен аңлый алмый. Югыйсә, шушы ана ана Тәнре ярәштергән Малуша белән кавышырга ирек бирмәде, Владимирны туган оныгы итеп танымады, Святославның үзенә гел-гел аяк чалды. Ә хәзер, менә, жир йөзендә шушы анадан да газизрәк бер бәндә юк. Әби-бабаларның "кан тарту" дип сөйләгәннәре шушымы соң әллә?

Улы кергән саен кенәзбикә Ольга, иреннәрен чак-чак кыймылдатып, һаман бер үк сүзләр тәкърарлады.

—Яуга йөреп кенә илне ныгытып булмый. Сабый бала сыман өлкән туганга тартыл. Безгә абый кеше—Кайсаркала. Юнаннарга елышырга кирәк. Жиһанда гадел дин тик аларда гына. Христиан динен өйрән. Шул юл гына безне үсешкә алып чыгар...

Бер таңда кенәзбикәнең гәүдәсе Святославны тынсыз-хәрәкәтсез көе каршылады. Карт ананы Үзи елгасы ярына чыгарып жирләделәр. Әле үзе исән чакта ук Ольга кабере өстендә учак ягып бию ләрне тыеп аманат әйткән иде. Христиан горефләре буенча тырыштыргач, хушлашу корырак, күңелсез килеп чыкты. Святославка кабер янында япа-ялгыз калу да тәэсир итте бугай, беренче мәртәбә Саркел каласын, Коркыт ханның ут эчендә калган гаиләсен искә төшерде ул.

—Алар мине каргагандыр инде,—дип үкенеч күленә чумарга мәжбүр булды.—Аеруча Коркытның карт анасы нәләт укый-укый каргагандыр. Ана каргышы төшми калмый, диләр. Менә, жимешен бүген жыям. Киевта минем өчен газиз бер кеше юк. Кире кайтмыйм, аңа аяк тартмый...

Святослав шул көнне үк Киевны ташлады да Переяславец дигән кирмәнгә күчеп китте. Новгород каласына да кенәз хәбәре белән канатланган чапкын очкан иде.

—Киевны Владимирга бирәм. Улым монда кайтсын.

Новгородта яшүсмер улы янында зирәк акыллы Добрыня агасы да булганлыгын искә алмаган иде, тәртәгә тибә торган чыгымчы ат шикелле тискәре җавап кайтты.

—Тәхеткә якын йөргәннәр башын югалта ул. Безгә иске Новгород каласы да ярап тора.

—Алайса, пайтәхеткә Ярополк кайтсын,—дип кулын өметсез генә селтәп, ул Вышегород каласына яңа чапкын куды.

Үзе айлар буе базга чумган шикелле дәшми-тынмый яшәде-яшәде дә, чукышмыйча тора алмаган юньсез әтәч сыман, Святослав яз көне тагын халыкны яу сәфәренә җыеп чыгып китте.

—Бу юлы Дунайдагы болгарларны тез астына бөгеп салабыз. Алардагы Петр кенәз хәзер кайсар дигән дәрәҗәне йөртә, шуны үзебезгә тартып алабыз,—ди.

Тота-каба яңа пайтәхет төзү белән мәшгуль болгарлар, билгеле ки, көтелмәгән дошман явын кайтарырга әзер тормаганнар. Борын төпләрендә каек-баркас белән килгән алтмыш меңлек гаскәр пәйда булгач, юньлерәтле каршылык күрсәтә алмадылар. Картаеп барган кайсар үзе яу кырына чыгып та карамады. Акча хакына ялланган угыз белән мадьяр яубашлары каланы ташлап качты. Әле тернәкләнеп кенә килгән пайтәхетне җимерттермәс өчен Петр кайсар Святослав ыстанына каек-каек алтын озатырга мәҗбүр булды.

Кан коюсыз, ансат җиңүдән соң Святослав чик-чаманы җуйды.

—Безгә каршы торырдай каханат юк. Әйдә, Кайсаркаланы барып җимерәбез,—дип, ул бөтенләй акылыннан шашты.

Дунай ярында бик тиз генә баеп алган меңбашлар, боярлар, баһадирлар—һәммәсе дә сүз куешкан сыман бердәм булып аны якладылар. Каек-баркаслар, кораблар көньякка юл алды. Ләкин капкан саен калҗа гына булып тормый икән. Диңгездә купкан давыл урыс каекларын йомычка урынына әйләндереп атты. Меңәрләгән-меңәрләгән сугышчылар туймас кенәзгә ләгнәт укый-укый су төбенә китте. Исән калганнары Камчы елгасы* тамагындагы, Варна буендагы яр өстенә чыгып егылдылар. Святослав һаман акылына килмәде, коры сөяккә калган илдәшләрен һаман алга куды.

Юнаннарга ялланган алан белән угыз шымчылары инде әллә кайчан ук Кайсаркаланы кисәтеп куйган иде. Юнаннар кайсары Цимисхий үзе нииндидер кыргый урыс кенәзе хакына ияр өстенә менеп тә вакланмады. Аның гаскәрен баскыннарга каршы Склир белән Патрикий атлы сәргаскәрләр җитәкләп алып килде. Святослав, әтәчләнеп, юнан пәһлеваннарына каршы орышка үзенең ике баһадирын чыгарып караган иде дә, ач-ялангач ирләр тамчы да елгырлык күрсәтә алмыйча әрәм булды. Аннары урысларны Дунай тамагына чаклы ут уйнатып кире кудылар. Ахырда баскыннар сафында ун мең чамасы гына сугышчы торып калды. Алары да аксак-туксак, йә яралы иде. Святослав, май урлап тотылган мәче сыман башын түбән иеп, юнан сәргаскәрләре каршына үзе китте.

—Болгарлар моңа чаклы сезгә ясак түли иде, элеккечә калсын, мин аларга тимим. Кайсаркала Киев өчен һәрчак абый иде, шулай булачак та. Гаскәремне бүгеннән үк кире кайтарып җибәрәм, ә үзем сезнең кайсарыгыз каршына бүләк төяп барам.

*Камчы елгасы — Дунай янәшәсендә, Кара диңгезгә коя. Бүген дә шул исемне йөртә.

Болгарлардан таланган барча алтыннарны юнан корабларына күчереп төяделәр. Баш сәргаскәр Склир алданрак киткән иде, ул урыс кенәзен Адрианополь ярына килеп кайсар Цимисхий белән бергә каршы алды. Святославны гап-гади бер көймәгә күчереп утырттылар, үзе ишкәк иште. Ике хакимне күз алдыннан кичерү үзе үк гыйбрәт иде.

Кайсар сөткә чумдырып коендырган шикелле ап-ак аргамак өстенә менеп алган. Өстендә шакмак тәнкәләрдән тезелгән алтын көбә, башында таҗ. Кулына ин очына саф алтыннан ике башлы сәмруг кош ясап куелган кайсар чукмары тоткан. Өзәнгеләр, атның авызлыгы, кайсар кигән бияләй куныччлары, итек типкеләре—бары да саф алтыннан. Кояш нурларыннан аларның һәммәсе дә күзне камаштыра, кайсарга текәлеп карап булмый, ул күктән җир өстенә төшкән зур алиһә кебек. Янында алтын-көмеш җепләр белән чигелгән җиләннәргә, чикмәннәргә төренгән руханилар, вәзирләр, сәргаскәрләр. Артта ап-ак парчалардан, ефәкләрдән корган олы чатыр. Яр өсте, гомумән, әкият, җәннәт, сер, могҗиза сыман. Ана аяк басу өчен дә йә әүлия, йә пәйгамбәр булырга кирәк төсле.

Ә аста, сагызлары кубып төшкән балыкчы көймәсендә, ишкәкләрдән кулларын аера алмыйча урыс хакиме утыра. Өстендә тезгә төшеп житкән киндер күлмәк, балаклары капчык сыман киң киндер ыштан. Бозау тиресен аннан-моннан иләп теккән итекләр авыз ачкан. Бер колакта тимерче чүкеп ясаган алтын алка... Кенәз өстендә шуннан гайре бер байлык юк. Баш түбәсендә бер уч итеп калдырылган чәч тотамы җилдә уйный. Мыек чылгыйлары ияген үтеп, муенына хәтле салынып төшкән. Куллары сөялгә батып, яргаланып беткән. Куе кашлары астыннан төбәлгән утлы карашында кимсенү, көнчелек һәм нәфрәт.*

Үзенең нинди отышлы кыяфәттә торуын чамалый, билгеле. Иң беренче булып, кайсар телгә килде.

—Ә мин синең әниеңне, кенәзбикә Ольганы әйбәт белә идем. Әгәр христиан динен алданрак, унбиш-егерме ел элек үк кабул иткән булса, бәлки, мин ана өйләнеп тә куяр идем әле. Чибәр иде, каһәр!..

Кайсар Цимисхий башын артка ташлап, ихахайлап көлде. Святослав уртларын шыгырдатып кыскан көенчә, көч-хәл белән түзде.

—Менә шул мәрхүмә әниеңә рәхмәт укы, кенәз. Аны белмәгән булсам, мин сине үземнең каршыма кол урынына, богауланган көе китертәчәк идем...

Кенәз шуннан соңгы сүзләрне ишетмәде. Чатыр эченә кереп, ишек төбендәге өстәл артында утырулар да, урыс сугышчыларының кайсар каршына капчык-капчык алтын ташуы да төштәге шикелле генә үтеп китте. Святослав өчен иң мөһиме инде ачыкланган иде. Бу җиһанда җиңелмә, адәм мәсхәрәсенә калма, тезгә чүкмә икән. Тәкъдир усал, кансыз, явыз. Тезгә чүккән кешенең башына төкерәләр, ул хуҗа кимереп ташлаган сөяк-санакны ишек төбендә көтеп утыручы мескен эт баласы хәленә кала икән. Сабак алып китәргә кирәк моннан, онытылмаслык сабак!

## 43

Гаскәреннән аерылып калган, чит-ят илдә йөргән Святослав бу көннәрдә туган җиренең нинди ут эчендә янганын бөтенләй дә белми, шуның белән берникадәр бәхетле иде әле. Ә Кияү каласында янә кан-яшь, кайгы-хәсрәт, мәхшәр.

Урыс гаскәре Кайсаркала ягына төшеп китүгә үк, Киевның имән

*Әлеге күренеш рус рәссамы К. Лебедев рәсеме буенча тасвирланды.

диварларын ашлык көлтәләре урынына җимерә-сыта, Коркыт бәреп керде. Урамнарда кырылудан качып котылган сигез мен ир кенәз сараена кереп бикләнделәр.

—Кенәзегез Ярополк чыгып бирелсен, ул чагында башкаларга тимим!— дип боерды ияр өстендә тау кыясыдай горур утыручы Коркыт хаким.

Кәрниз тәрәзләре ярыгыннан көнләшердәй җавап кайтардылар.

—Кенәз качты, күптән Переяславецтагы канизәкләре куенында рәхәтләнә инде.

—Ул чагында сәрдәр тезен чүксен.

Авызларына су капкандай, бертөрле дә җавап бирмәделәр. Коркыт һаман көтте. Берзаманны сарай артындагы келәтләр ягыннан кулына йөгән тоткан, йолкыш кына кыяфәтле ир-ат килеп чыкты. Башында эт талаган сыман йолкынып беткән бүрек, өстендә кырыкмаса-кырык ямау салган бишмәт, аякларында ыштыр да урамыйча гына эләктереп чыккан тишек чабаталар. Берьюлы йөз сукыр чебен кереп тулган шикелле күзләрен челт-челт йома, юкә бау белән буган ыштаннарын әледән-әле күтәргәләп куя. Килешкилбәте үк акылы зәгыйфь мескеннеке сыман. Өстәвенә, як-ягына каранып, тилемсә тавыш белән кычкыргалап куя.

—Росток, Росток! Кая йөрисен, имгәк?

Бермәлдә, батырланып, хәтта бәҗәнәк җайдакларына да бәйләнә башлады бу.

—Минем Ростокны күрмәдегезме, оланнар? Бер аягы аксак.

Үзенә таба караш ташлаучы да табылмагач, йолкыш ир-ат кала диварлары ягына атлап китте. Коркыт ханның түзем мичкәләре коргаксый башлаган иде, кәрниз тәрәзәләренә төбәлеп янә аваз салды.

—Сәрдәрне чыгарыгыз каршыма. Сәрдәрегез минем колым булырга ризалашса, калагызга тимим.

—Сәрдәр яраланган. Шуны чүпрәк белән бәйлисе бар. Аннары чыгарабыз,—дип суздылар-суздылар да, ахыр чиктә каһкаһәле җавап ыргыттылар.

—Ат юллаучы булып кыйланып, сәрдәр Претич, әнә, борын төбегездән чыгып ычкынды бит. Әй, син, ахмак Коркыт!

Егермеләп җайдак ук шикелле атылып мәйданнан чыгып очты, бәҗәнәкләр хәрәкәтсез калды. Вәт, ачыгавыз! Вәт, юеш борынлы малай! Көтүче хезмәтен балачактан бирле яттан белүче дала кешесе саналып йөргән була һәм шуны кара эшне татып та карамаган түрә-бояр алдый! Адәм мәсхәрәсе, хурлык, оят!

—Сарайга ут төртегез!—дип үзен-үзе белештерми фәрман бирде Коркыт.—Кансыз урыс минем әнкәйне шулай әрәм итте. Боларны да шул рәвешчә юкка чыгарабыз!

Киев урамнарын ялкын чолгауга ук бәҗәнәкләр көньякка юл алды. Канлы үч сугышы әле һаман тәмамланырга исәпләми иде...

Святославны Үзи елгасы тамагында, бусагалар артына ышыкланып каршы алды ул. Кенәзнең җансакчылар алае саранча көтүе талаган иген басуы шикелле сирәгәеп калган, алары да хәлсез, ач-ялангач. Сәрдәр булып ияреп йөргән Свенельд картка, Киевтан качкан Претичка ышанмалы түгел. Шулай да, Коркыт ханның буар елан сыман сузылган җайдаклар чылбырын күргәч Святослав качмады, чигенмәде, иң беренче булып яуга томырылды. Бу орышның соңгысы икәнен дә, үч явының фәкать җан кыю белән генә тәмам буласын да анлый, тоя иде. Ук шикелле төбәлеп, ул туп-туры Коркыт каршына барды, курыкмыйча шарт-таләбен куйды.

—Кылычтан орышабыз!

Кайчандыр берүзе ун ир-атны турап сала торган Святослав хәзер инде

кибеп беткән корык сурәтенә охшап калган иде. Гомер буе ауга йөреп, кылыч болгап үскән дала яугиренә каршы тора алмады. Бер-ике мәртәбә капландай сикерүгә үк Коркыт хан урыс кенәзенен муенын кыеп атты. Аннары кичәге дошманынын башын бөтенләй кисеп алды да, аны бәҗәнәкләр арасында иң маһир кул остасы саналып йөргән жайдак итәгенә ыргытты.

—Монннан касә яса. Дошманнар каршында киләчәктә юри шуннан эчәм.

Яудан биш-алты иярчене белән бергә карт төлке Свенельд бояр гына качып котыла алды.*

44

Киев каласына үги бала сыман гел михнәт-хәсрәт чигеп, елапсыктап яшәргә язган, ахры. Олуг кенәз үлеме турында хәбәр кайтуга биш-алты ай вакыт та үтмәгәндер, урыс илендә коточкыч яна чир канат ярды.

Святослав хәл итеп киткәнчә, Ярополк инде ничә еллар буе Киевта утыра, Олег Коростеньда, Владимир Новгородта яшәп ята иде. Кайсы угылынын бөек кенәз булып калачагы хакында әтиләре әманәт әйтмәгәч, әлбәттә инде, туганнар бер-берсенә баш бирергә һич тә атлыкмады. Әкияттәге аккош, кысла һәм чуртан шикелле, йөк арбасын һәркем үз көенә тартуны кулай күрде. Калалар арасында чапкын йөртү, хәбәр алышу гадәтләре бетте. Мөгаен, мондый башбаштаклык әле тагын еллар буе дәвам итәр иде, көтелмәгән бәла бар дөньяны әйләндереп атты.

Ярополк беркөнне яраннарын жыеп ауга чыгып китте. Нияте—Үзи ярыннан ерак булмаган бер урманда кеш, селәүсен, төлкеләрне сугып алу иде. Төшке аштан кичкә чаклы ияр өстеннән бер дә төшми байтак юырттылар. Кенәзнең йөзе корыган агач ботакларына сыдырылып бетте, бер чокырда абынып аты ауды. Ярополк инде ачуыннан, гайрәт кайтудан шартлар дәрәҗәгә житкән иде. Шулчагында тирән ерым эченнән бишалты жайдаклы гына төркем килеп чыкты. Башлыклары—атаклы Свенельд боярнын Лют исемле әрсез, ташбаш улы. Монын хакында әле элегрәк тә "байчуралар ишек төбендә ыштырларын суткән, кәвешләрен каккалаган арада тәрәзәдән кереп, яшьрәк хатыннарын да, кызларын да кызыл әтәч сыман таптап чыга", дип гайбәт сатып көлдерәләр иде. Менә, хәзер инде Лют карак мәче кебек Ярополк кенәзнең биләмәләренә дә килеп кергән. Ятим бәрән эзләп тапкан ач бүре шикелле Ярополк мона ябырылды.

—Кызылъяр ягындагы барча урман гомер-гомергә минем атай биләмәсе булды. Син ничек чит утарга аяк басарга жөрьәт иттен, уйнаштан туган нәрсә?

Лютнын сынар колагы да селкенмәде.

—Кем чит утарда йөри дә, кем уйнаштан тумаган чын хужадыр әле? Синең әбиенне яшь чагында гел минем атай куенында яткан, диләр. Без синен белән икәү агай-эне булып чыкмагаек.

Лют корсагына шап-шоп суга-суга, ихахайлап көлде. Монын әрсез кыланышын, пычрак гайбәтләрен дистәләгән ир-ат ишетеп-күреп торды. Кайнар көе бозлы суга китереп тыккан пыяла савыт сыман, Ярополкнын түзем касәсе кисәкләргә шартлап ярылгандай булды. Үз-үзен белештермичә ул садагына ябышты, икенче мизгелдә бояр улын бугазына кадалган ук ияреннән йолкып, әйләндереп атты...

Улынын үлеме турында хәбәр алуга ук, Свенельд бояр Коростеньга очты.

*972 елда булган вакыйгалар.

Әүвәл древлян аксакалларын күреп котыртты ул, ә аннары күз яшенә батып Олег янына керде.

—Абыең акылдан шашкан, Ярополк чирле. Киев боярлары аны сөйми. Алар атаң урынына тәхеттә сине күрү турында хыяллана. Тәхет даулап килсән, бар дружина синең якка чыга. Абыеңны үт куыгы сыман кисеп ташлау өчен иң-иң кулай вакыт.

Свенельд ишек катында әзер торган аксакалларга ым ташлады. Тегеләр дә телләрен-телгә йоктырмыйча котыртуны белде.

—Игорь бабаң килеп тураганнан бирле древляннар Киев өчен чит-ят. Без һаман шул Киев сорыкортларына ясак-салым түләп интегәбез. Без сиңа ияләштек, син күптән үзебезнеке. Абыеңны тәхеттән алып атсаң, без, древляннар да, сиңа кушылыр идек...

Ниһаять, Олег сынды. Древляннар умарта күчедәй шашып яуга кузгалдылар. Бер илдә дә сатлык яисә шымчы бәндәләрнең бетеп торганы юк. Бер тәлинкә кайнар аш хакына Киевка да соран чапкын очты. Энекәшенең хыянәте турында хәбәр алуга, Ярополк барча дружинасы белән каршы чыкты. Бертуган абзый белән энекәш тиешле кешеләр Обруч дигән кала янында, кырда очраштылар. Олег яуга йөреп чыныккан, орыш күреп үскән сәрдәр түгел. Ярополк үзенең жайдакларын бәҗәнәкләр алымы белән ташкын итеп яуга ташлауга ук, Олег әмерфәлән биреп тормыйча да кала ягына качты. Аңа йөзәрләгән, меңәрләгән ирләр иярде. Барча качкын җайдак шәһәр капкасы каршындагы күперчеккә сарык көтүе сыман килеп тыгылды. Арттан килгән ташкын әүвәл Олегны йомычка урынына күпердән алып атты, аннары яшь кенәз өстенә йөзәрләгән ат гәүдәсе очты...

—И-и-их! Син бит миңа бертуган энекәш идең. Абыеңа ник кул күтәрдең?—дип әллә юри, әллә чынлап өзгәләнде күпер читенә килеп тезләнгән Ярополк.—Синең җаныңны кыючы дигән хурлыклы дан күтәреп ничек яшим инде? Әгәр, синең өчен үч алырга атлыгып, минем өскә Владимир килсә?..

Юкка гына калтыранды кенәз. Бер мәртәбә бүре авызыннан качып котылган бәрән гомер буе һәр куактан куркып яши, диләр. Кече яшьтән бирле читкә тибелеп үскән Владимир да Обручтагы фаҗига хакында ишетүгә, дингез кичеп, варягларга качты. Сөяк-санак көткән эт шикелле айлар буе ишек-капка төбен саклап караса да, король янына барыбер кертмәделәр. Җавап яңакка суккан шикелле усал, кансыз иде.

—Син колчура Малуша баласы. Король ялчы-колчураларны тыңлап вакыт әрәм итми...

Владимир, тәвәккәлләп, алпар көбәләренә төренде дә варяглар сафында норман гаскәрләренә каршы яуга китте. Заманында, әле яшүсмер көе, ач аю белән алышка чыккан кеше булуы хәтерендә яңаргандыр инде. Бер орыш вакытында норман баһадирын ияреннән сугып очырды ул. Варяглар да тиешенчә бәяләде, ахры, король чатырына якын җибәрделәр.

—Бер мең алпар бирәм,—дип "мәрхәмәт" күрсәтте баш аксөяк.—Аннары сезнең үз илегездә Рогволод атлы энекәшем Полоцк каласына хуҗа. Ачкыч таба белсәң, ул да сиңа сугышчылар бирер. Новгород каласын кайтарып алгач, миңа бүләк һәм канизәкләр юлларга онытмассың...

Ярополк Новгородка яңа хаким утыртып куйган, ә тегесе каланы гына түгел, якындагы чуд белән кривич кабиләләренең утарларын да талап чыккан икән. Кичәге кенәзнең корыч көбәле алпарлар гаскәре белән кайтуын күрүгә үк барысы да Владимир әләме астына килеп кушылдылар. Ишек төбенә эт шикелле сөйрәп китерелгән хаким колагына Владимир, бармак яный-яный, бер үк сүзләрне тезде.

—Ярополкка житкер. Мине илгә үги иткән өчен аны гафу кылмыйм. Үч алмыйча торып туктыйсым юк. Яуга әзерләнсен...

Король юлламасын тотып кайткан сукбай Владимирны Рогволод атлы варяг кенәзе хәтәр жылы кабул иткән иде. Нияте бүтән икән.

—Ярополк миңа бертуктаусыз яучы юллап тора. Рогнеда атлы кызымның кулын сорый. Вакытында кайттың. Туйда икегезне бер өстәл артына утыртып дуслаштырмый булмас. Ярополк—кияү, син кода тиешле кеше. Икегез дә миңа бүләк-санак белән ярдәм иткәләрсез...

Болай да гомер буе ин ачы давылда иксез-чиксез диңгез уртасында калган ялгыз көймә сыман бәргәләнгән, жәфа чиккән Владимир хәзер инде Рогволодның өстәлләрен әйләндереп ташлардай булып кызып чыккан иде, жиләк-жимеш, шәраб күтәренеп залга кенәз кызы Рогнеда килеп керде. Кәүсәр чишмә суында коендырган шикелле алсу тәннәр, махсус акшарлаган сыман ап-ак толым, төбен күреп булмас зәмзәм коесыдай чиста-зәңгәр күзләр, камыштай зифа буй-сын, пешеп житкән дәү алмалар кебек төртеп торучы ике дәртле күкрәк.

Рогнеда жиләк-жимешләрне куйгач кәс-кәс басып залдан чыгуга ук, Владимир ис-акылын жуйган кеше төсле Рогволодның кулларына барып ябышты да шашып-шашып ялварырга кереште.

—Кызыңны миңа бир, мине киявең ит, мәрхәмәтле кенәз? Новгородның бар байлыгын сиңа китереп бирәм.

Варяг кенәзе Рогволод сукбай Владимирны юлда табылган эт баласын тибеп очырган кебек итеп кенә үзеннән читкә этте.

—Фу-у! Пычратмале минем керсез тәнне! Ни сөйлисең, йолкыш? Нинди кияү итү, кыз бирү ди тагын? Минем колчура Малуша баласына өләшә торган кадерсез кызларым юк. Үзеңә тиңнәрне, әнә, йә лапаска, йә базарга чыгып эзлә!..

Битенә лач итеп төкерелгән Владимир бу юлы инде тыелып кала алмады. Ул зал диварларына эленгән зиннәтле кылычлар арасыннан берсен эләктерде дә варяг кенәзен күз ачып йомган арада икеләйгә ярды. Рогволодның залга атылып килеп кергән ике малае да урыс кенәзенең шашкын кылычыннан котыла алмадылар. Алар да утын әрдәнәсе сыман ярылып ике якка ауды.

Куркынып-өшәнеп залга йөгереп кергән Рогнеданы кочагына сосып, Владимир бер генә сүз әйтте.

—Миңа кияүгә чыкмыйсың икән, сине дә суячакмын!

Ис-акылын жуйган варяг кызы урыс кенәзенә каршы тора алмады. Владимир шушында ук шаулатып туй уздырды.

...Новгород, Полоцк, чуд, кривич, варяг сугышчыларыннан, тагын әллә нинди ялчы сукбайлардан хасил бетмәс-төкәнмәс яу ташкынын күргәч, Ярополк Киев диварлары артына кереп бикләнергә мәжбүр булды. Владимир да үз гаскәренең көченә ышанып житми иде, ике як та ай буена житди һөжүм ясарга тәвәккәлләмичә тик торуны отышлырак күрде. Ул арада тәхет язмышын хәл итү астыртын, мәкерле эш йөртә белүчеләр һәм сатлык-хыянәтчеләр кулына күчте. Шулар тау битенә чокып ясалган куыш эчендә ятучы Владимир каршына Киевның Блуд атлы боярын тотып китерделәр. Владимир өстәлгә бер чүлмәк алтын тәңкә чыгарып куйды, фахишәдәй юха елан тавышы белән ысылдый-ысылдый вәгъдәләрен тезде.

—Киевны алырга ярдәм итсәң, син миңа икенче атам төсле гомер буе якын булачаксың. Тәхеткә утыруга, беренче бояр итәм!

—Син гаскәреңне жый да юри генә чигенеп тор, кенәз,—дип, хыянәтче бояр шундук жавап сүзен әйтте.—Ярополкны синең каршыңа мин үзем китертермен...

Ә ачлы-туклы гаскәр белән камалышта яткан Ярополк өчен сатлык жаннын икенче мәкере дә әзер иде.

—Боярлар сиңа каршы түнтәреш әзерлиләр. Алар сине, арканнарга чорнап, теге уйнаштан туган сукбай кулына илтеп тапшырмакчы. Сиңа жансакчыларыңны алып, каланы калдырып тору хәерлерәк булыр. Теге сукбай каладан чигенүгә кире әйләнеп керерсең. Ул арада хыянәтче боярларның исемен ачыкларбыз.

Каладан чыгуга, җансакчылар башлыгы кенәз Ярополк каршына килеп, үзен явыз ир-ат көчләүдән сакларга җыенган гөнаһсыз кыз шикелле ялынып караган иде.

—Әйдә, угызлар йә бәҗәнәкләр янына барыйк та шуларны акчага яллап карыйк, кенәз? Өстәмә гаскәр күрсә, Владимир да кире әйләнеп кайтмас.

Тынламады Ярополк кенәз. Мие шулпаланган карт шикелле һаман сүзсез-нисез Тын елга ягына чигенүен белде. Аннары инде мәкерле Блуд юллаган чапкын куып житте.

—Владимир качты. Түнтәреш әзерләгән боярларны зинданнарга яптык. Кенәз кире кайтсын.

Киев диварларына житеп килгән чакта Ярополк белән аның яраннарын Владимирның тозак алайлары турап атты. Ярополкның көмәнле булып калган хатыны Ангелина да тәскә-биткә күзләрне камаштырырдай чибәр иде. Владимир әлеге юнан сылуыннан да баш тартмады, хатынлыкка алды.*

## 45

Гомер көчек түгел, аны бауга-чылбырга утыртып кына тотып торып булмый. Мөхәммәт хан да биреште, олыгайды инде. Ә күк капусы тәбәнәкләнгән кешенең күңеле астан көчле агымсу ашаган язгы боз шикелле көпшәкләнә, юкара ул. Мөхәммәт хан да кыртлы тавык урынына әледән-әле балаларын үз янына чакыра торган булып китте. Җае чыккан саен әле оныклары туу хөрмәтенә, әле яңа мәчет манарасы бастыру унаеннан корбан чалу мәжлесе яисә ат чабышы, мәргәннәр бәйгесе үткәреп күңел ачты. Тәртә арасына керә белми торган, чыгымчы Тимер-Мөэмин дә инде күптән хан сарае эргәсендә иде. Көннәрдән-беркөнне мәжлес вакытында юктан гына тавыш чыгарды ул.

—Идел яклап ушкуйлар өере бәреп кергән, чирмеш олысларын тоташ талаганнар,—дип чапкын кереп хәбәр салган иде, Тимер-Мөэмин шуны эт шикелле каптырды да алды.

—Ме-е-нә-ә-ә, ме-е-нә-ә! Растуфка җавап явы белән барган өчен мине эттән алып эткә салган идегезме? Имеш, Мөэмин туймас тамак та, Мөэмин Болгар иле өстенә яңа яу чакыра. Әнә, кыстатып тормады ул шәрә урыс, сәбәпсез-нисез көенчә тагын басып керде. Карак бүре сымак бер сарыкны сыртка салачак та, җәза-кыйнау күрми чыгып качачак ул. Күтәрергә куәте житмәгән ачудан әле башка малны буып китмәсә ярый тагын. Чирмеш олыслары өчен кан костырырга кирәк алардан! Өсләренә җыелып барырга да Болгар юлын мәңгелеккә онытырлык итеп дөмбәсләргә кирәк! Ә без теләсә кайсы бозау килеп талый-талый имгән чагында да ирек куя торган сыер сымак юаш, ә без ачыгавыз!

Табын янына җыелып утырганнар арасыннан җавап итеп бер Ибраһим гына аваз салды.

—Әйе, без ачыгавыз, без җебегән, абзый кеше, анысын дөрес әйттең. Иллә мәгәр тәхетне вә илне чит-ят дошман өстенә яу йөреп яки талау юлы

---

*976 елда булган вакыйгалар.

илә ныгытмыйлар. Харәм урланган мал бер көнлек кенә калжа ул, каптын-йоттын—бетте. Илне, әнә, суярга әзерләгән мал урынына күреп, үз ризыгын, үз куәтен илә күрәйтергә, симертергә кирәк. Андый малны, гадәттә, басуга чыгарып түгел, аран эченә бикләп симертәләр. Ә безнең Болгар иле—өстенә ыштан кию гадәтен дә оныткан тол хатыннарга охшап калды хәзер. Кем иренми, кил дә эссенне бас—каршы торучы юк. Без дә шулай. Чикләребез Сура, Ука елгаларына, Нократ башына тикле барып житә, вәләкин ул якларда бер генә ныгытылган бистә, йә кирмән юк. Күршеләрне караклыкта гаепләү, бүрәнә аша бүре куып артларыннан йодрык болгап калу, ай-яй, жинел ысул. Ә йортыбызга юньле-рәтле ишек илә йозак куя белмәгән өчен үзебез гаепле ләбаса, фәкать бер үзебез!

—Әй, алай комы коелып, бөкресе чыгып беткән карт-корылар сымак көпә-көндез ишек-тәрәзә бикләп көн күрергә жыенасың икән, бар соң, урыс белән янәшә утыр да яшә!—дип Тимер-Мөэмин шәрран ярып тузынырга тотынды.

Мөхәммәт хан улларының янә әрепләшеп-якалашып таралуыннан куркып калган иде. Сүзләрен кабадан йон тартып жегерләгән шикелле сайлап суза-суза гына ул да үзенең карарын ирештерде.

—И-и-иплән кирәк, оланнар, и-и-иплән кирәк. Тимер-Мөэмин угылым да, Ибраһим да хаклы. Дошман килеп кыйнаганда кул кушырып утыру да ару түгел, илне-йортны йозакка бикләп кую да бик мәслихәт. Әйдәгез, болай итик. Берәр әмир илә берәр сәрдәр Ука, Сура буена барып әйләнсен дә урыс белән ике арада кирмән-киртә төзердәй урын сайлап кайтсын. Мөэмин улым, турысын әйтим, сина ышанып житмим. Ушкуйлардан үч алырга кыжрап, синең уч төпләрең би-и-ик кычытып тора. Бер йөз жайдак биреп юлласаң да, синең күршедәге урыс утарларын талап чыгуың бар. Шуңа, әйдәгез, Ибраһимны юллыйк. Ул бура бурый-бурый шомарган балта сабы сымак иплe кеше, нужа шулпасын да күп чөмергән. Яна кирмән урынын хаталанмый, каударланмый гына тәгаенләп, Ходай кушса, бәлки, әле нигезләп тә кайтыр...

Әмир Ибраһим, бер мең жайдак, балта осталары, ташчылар һәм пешекчеләр алып, икенче таңда ук юлга чыгып китте. Сәйяхчыларны Чулман тамагына чаклы иярен озаттылар. Хатын-кызлар, бала-чага яшереп кенә балавыз да сыкты. Болгарлылар арасында Тимер-Мөэмин генә учларын угалап, авыз ерып калды. Юкка булмаган бу.

Тоз яларга килгән сыер шикелле, ул шул көнне үк Мөхәммәт хан янында бөтерелеп йөри башлады. Жыры гел бер.

—Ничә айлар бүе ауга чыкканың юк. Бәкләр, морзалар сине картайган, дип уйлар. Бала-чытырман үзәнендә кыр кәжәләре белән жәйрән мыжгып тора. Әйдә, шунда киттек.

Тамчы тама-тама ташны тишә, диләр, Мөхәммәт хан да сынды. Ерак олыслардагы морзаларны, кала олугбәкләрен кузгатып тормыйча, курсыбайдагы мәргәннәрне, сарай тирәсендәге түрәләрне генә алып, Чирмешән буендагы үзәнлеккә килеп урнаштылар. Чатырларны корганнан соң беренче казан янына жыелгач ук Тимер-Мөэмин янәшәсендә күләгәдәй тагылып йөргән карачкыны күреп һәммәсе дә дәррәү сискәнде. Дөрес, кемнәрнендер аны элегрәк тә ерактан гына чамалап-шәйләп калганы бар, әмма йөзгә-йөз килеп очрашканы юк иде әле.

Тимер-Мөэмин аны Ростовка ясаган талау сәфәреннән табып-иярген кайтты. Кыяфәте тәһарәтенне алырдай иләмсез һәм котсыз. Аның каршында йозьяшәр имәннәр дә чүгеп куя бугай, бүе дөядәй озын. Бүреген салса, башы кабак кебек олы, өстәвенә чебеннәр таеп егылардай пәләш. Ике кулы тезенә житкән. Гел бөгелеп йөри. Ә инде йөзе-кыяфәте! Төшенә

керүләрдән Ходай тәгалә үзе саклый күрсен! Ике бармак калынлыгы таптар маңгай. Карчыгадан йолкып алынгандай кәкре борын. Шуның өстенә бөтәрләнеп килгән куе кашлар. Ике төймә кебек елтырап торучы бәпбәләкәй күзләр. Табак хәтле чырай, соскы шикелле салынып төшкән ияк. Тарак-сабынның йөзен дә күрмәгән куе, җирән сакал. Аңкавына сыймыйча, ирен читләренә бияләй шикелле бүселеп төшкән теленнән селәгәй агып тора. Каешланып каткан күлмәк-бишмәтеннән үләксә исе аңкый. Албасты дисәң дә албасты бу, башка берни түгел! Тимер-Мөэмин ник ияртгән аны, ни сәбәпле монда алып килгән?..

Икенче көнне ике төркемгә бүленеп, дулкын сыман як-якка таралдылар. Тимер-Мөэмин арт ягына борыч сөрткән шикелле гел әтисе янында бөтерелде, Ростов карачкысы җиргә убылгандай юкка чыкты. Тимер-Мөэмин Мөхәммәт ханны ятьмәгә әләктергән җәен урынына гел куе таллыклар, баланлык, әрәмәлек ягына сөйри иде.

—Җәйрәннәр шәрә ялан буйлап утлап йөрергә сыер көтүе түгел. Мондый миең кайнап чыгарлык чилләдә акыллы мал күләгәдә качып ята бит ул. Күбәләк куа чыккан малай-шалай кебек булма, атай. Әйдә, әрәмәлек эченә керәбез, әйдә инде, әйдә!

Мөхәммәт хан әнә шул рәвешчә кармакка килеп капты. Куак төбенә качып көткән Ростов карачкысы аны чытырман эченә барып керүгә үк ияреннән сарык бәрәне урынына йолкып алды да, тезләре өстенә аркылы ташлап, умыртка сөяген нәкъ урталай сындырып-өзеп атты. Ә бер-ике минуттан соң үзәнлекне инде Тимер-Мөэминнең тилереп үкергән, тантаналы тавышы каплап киткән иде.

—Мөхәммәт хан вафат, атай вафат! Ул канат астында йөрткән Ибраһим Болгарда юк. Атай урынына мин хан булып калам!..

Ибраһим әмирне фаҗигале хәбәр Елантау өстендәге ыстанда куып җитте. Әле бернинди карарга да килмичә, тирә-юньнең гүзәл табигатен күреп кенә ял-табынга тукталганнар иде. Искитмәле урын!

Янда шома тасма булып сузылган Идел җәйрәп ята. Аңа төбе аермачык күренеп торган, чиста зәңгәр сулы кечерәк бер елга килеп кушылган. Исемен белүче юк. Елантау астында шул елга яклап дистәләгән чишмә челтерәп ага. Тауның мәгъриб һәм шималь ягына эреле-ваклы әллә ничә күл тезелеп киткән. Якын-тирәдә генә чирмеш, мукшы, болгар авыллары яшәп ятадыр инде. Бер-ике күл суына юкә кайрылары китереп тутырганнар. Шушы күлләр янәшәсендә мәһабәт, дәү казанны хәтерләткән олы инкүлек бар. Ул казан эченә ярдәм көч булырдай вак-вак бистәләрне яшереп төзеп була. Шәрекъ ягына таба гәрәбә муенса ташлары кебек сузылган иң олы өч күл ярында кыргый кабан дуңгызлары утлап йөри. Кайбер пешекчеләрнең морзаларга ияреп бу якларга элек тә килгәне бар, әлеге зур сулыкны Олы Кабан, Урта Кабан, Кече Кабан күлләре дип атаганнар икән. Әйдә, шулай булсын. Иң мөһиме, яңа кала, яңа кирмән корып кую өчен үтә кулай төбәк. Елантау үзе армас-талмас Идел, исемсез елга, исәпсез-хисапсыз күлләр, хәтфә үзәнлекләр, тирән, киң ерымнар, чокырлар уртасында мәгъруп кыя сыман калкып тора. Моның өсте берьюлы ун бистәне сыйдырырдай иркен. Әгәр шушы биек тау читенә бүрәнә диварлар, каравыл манаралары, имән капкалар да төзеп куйсаң, бу кирмәнне бернинди дошман көче дә яулап алачак түгел! Болгар тәрәге булачак өр-яңа каланы нәкъ менә шушы биеклек өстенә торгызырга кирәк!

Ибраһим Елантау битендә әнә шул рәвешчә хыялланып-очынып тора иде, дала яктан җан-фәрманга очкан ялгыз чапкын пәйда булды. Ат кадерен белүче ир болай каударланмый, димәк, хәбәре мал кызганып торырдай арзан түгел моның.

Ияреннән сикереп төшүгә үк, чапкын, тезләренә чүгеп, башын жиргә ора-ора әйтеп салды.

—Әмир, бәла! Мөхәммәт хан вафат!

Ибраһим чигәләрен кысып ыңгырашты. Керфекләрен ачкач, иреннәре арасыннан тик бер генә сорау сытылып чыкты.

—Мөэмин үтердеме?

—Ул яллаган катил. Ауга чыккач билен сындырдылар...

Байтак ара үткәннән соң гына әмир Ибраһим ияргә сикереп менде. Нията иткән карары тайпылышсыз, катгый яңгырады.

—Яңа кала өчен бик шәп урын иде, кызганыч, аны ташлап китәргә туры килә инде. Тимер-Мөэмин безгә тыныч-имин яшәргә ирек бирмәячәк. Илне генә түгел, үзебезнең башны да саклап калу өчен ышыграк жир эзләмичә булмый. Хуш, туган ил!

## 46

Ерак-еракта, Болгар иленнән жиде дала, житмеш дәрья артында яткан Мәвәраннаһ жирендә дә канлы сугыш бара. Караханнар каханлыгы белән сәманиләр солтанлыгы ничәмә-ничә еллар буена үзара суешалар. Мондый кырылышка бер гасыр элек үк караханнар хакиме Кадыйр кахан нигез салган, диләр. Аннары яу-талашны аның улы-оныклары Басыйр хаким, Садыйк, Сөләйман дәвам иткән. Бүген карлукъылардан, чагыл, яхмә, төргәш кабиләләреннән торган чирүләрне сәманиләргә каршы Сөләйманның малае чыбыркылап куа. Аның чын исемен белүче дә юк. Кара халык арасында фәкать кушаматы белән генә искә төшерәләр—Бөкре Карун.

Сал-Сал батыр ике ел буена менә шушы яу эчендә йөри. Аны кахан жайдаклары Алатау өркәчләре артына кереп качкан кышлактан нәкъ ул бәлигъ булган көнне алып китте. Әүвәл гади нәүкәр булып йөргән иде, хәзер инде түрә. Соңгы өч ай дәвамында әмир Әбүгали курсыбаендагы йөзбаш ул. Мондый мәрхәмәткә, мондый дәрәжәгә юлыгуның сере бик зур.

Беркөн төнлә Сал-Салны тирмәдән биш йөз жайдак башлыгы булып исәпләнгән Гайсә батыр үзе уятып алып чыкты. Сал-Сал шундук пыш-пыш килеп төпченергә тырышып карады, тик Гайсә бер сүз дәшми. Кирмән елгасы дип аталган инешкә таба ияртте дә китте. Инеш буендагы тирән чокырга төшсәләр, тоташтан тимер көбәләргә төренгән йөзләп жайдак тора. Арада көмеш очлым түбәсенә затлы каурыйлар кадаган бер түрә бар. Чокыр эче сумала төтене шикелле бик караңгы булса да, Сал-Сал аны барыбер чалымлады. Бөкре Карун дип мыскылланган каханның энекәше Фаикъ әмирнең улы Әбүгали бит бу. Аның әтисе Хорасан атлы олы илгә хужа, кахан һәрчак диванына чакырып кинәшләшә торган зур аксөяк. Әбүгалинең үзенә бертөрле дә аерым биләмә-кала әләкми бугай әле. Ул хәзергә каханның канат астында вәзир сыйфатында йөрергә генә мәжбүр. Менә шул Әбүгали башлап сүз кузгатты.

—Без ният иткән олы эшне жыен әтәк-сәтәк илә ерып чыгып булмый. Әүвәл үзебезнең каравыл алайлары тозагыннан сиздермичә үтеп китәсе бар. Алар илә кан коймаска исәп. Ә аннары сәманиләр солтаны Нух-Мансур яшеренгән Бохарага үтеп кермәкчебез. Анда нинди капкын, нинди тозак көйләп куйганнардыр, алдан белеп булмый. Менә шуңа күрә без ошбу махсус нөгәргә бер йөз меңнән артык нәүкәр арасыннан иң-иң елгырларны, иң-иң көчлеләрне генә сайлап жыйдык...

Сал-Сал өчен монысы зур яңалык түгел. Ул үзләренең төмәнендә бер ел дәвамында иң гайрәтле батыр исәпләнә. Аны бил алышында да, мәргәннәр

ярышында да һичбер нәүкәр һаман җинә алмый. Сал-Сал әле барча гаскәр бәйгесенә дә чәчрәп чыгар иде, аның кахан-әмирләр күзенә күренердәй юньле аргамагы, көмешләнгән ияре, көбәсе, очлымы юк...

—Үзебезнең тозак чылбыры аша үткән чагында да, сәманиләр ятьмәсенә килеп эләксәк тә, һичбер кемне көтеп торыш булмый,—дип кансыз тавыш белән кисәтергә онытмады әмир Әбүгали.—Яраланып авучылар табыланитә калса, андыйларны ташлап китәчәкбез.

“Безнең баш бәясе, ай-һай, кыйбат икән!”—дип эчтән генә янып сыздылар. Йөзләрендә ул-бу чагылмады. Һәркем аңлый иде: Әбүгали аларны бик тә тар кешеләр даирәсенә тартып кертте, бәлки, әле кахан колагына да барып ирешмәгән яшерен сер ачты, моны тишкән шалпавызга исән котылу юк...

Караханнар чиген саклаучы тозак чылбырын, басу-кырдан үз ихаталарына кайтып баручы казлар көтүедәй тезелеп, бик сак кына үтеп китмәкчеләр иде дә, исән-имин котыла алмадылар. Каравыл алайлары боларны сәманиләр ягына качып китүче сатлык җаннар дип кабул иткәннәрдер инде, куа чыгып, өермәдәй ук янгыры очыра башладылар. Егермедән артык җайдак җиргә егылып калды. Гайсә батырның беләге генә яраланган иде, Әбүгали аны үзе барыбер икегә телеп атты.

—Минем аягыма гер кирәк түгел...

Ә инде Бохара диварлары каршына барып җиткәч, Сал-Сал шайтан биетүне күргән төсле авыз ачты да катты. Монда әмир Әбүгалине көтеп торганнар лабаса! Ул бер манара каршына басып күренүгә үк, асылмалы күперне төшерделәр дә ян капкадан эчкә уздырдылар. Карахан җайдаклары исәпсез-сансыз сәмән йортлардан, йөзәрләгән пулат-алачыктан, эрелеваклы манаралардан хасил кала урамнарын да тоткарлыксыз үтте. Шәһәрне икегә бүлеп аккан Чәрсу инеше ярында, Солтан Нух-Мансур үзе яшеренгән мәһабәт таш кирмән капкалары каршында гына усал тукtаттылар.

—Әмиргә үзе белән ун җансакчы алып керергә генә рөхсәт, башкалар монда кала.

Әбүгали юлда вакытта сынап-бәяләп өлгергән, ахрысы, ул үзе белән Сал-Салны да алды. Нух-Мансурның ерак бабасы Исмәгыйл Сәмани үзе төзеп калдырган кирмән эченә кергәч, егет яңа дөньяга килеп эләккән шикелле гел шаккатып барды. Шушы таш диварлар эчендә дә дүртмебишме сарай, кайсы түгәрәк итеп, кайсы сигезпочмаклап ясалган биек манаралар, шифалы янгырдан соң үзара ярышып үскән гөмбәләр шикелле ак пулатлар. Аларның диварлары гына түгел, баскычлары, түбәләре, хәтта ихаталары да төрле-төрле төстәге ташлар, пыяла шакмаклары белән бизәкләнгән. Зур мәйданның һәрбер почмагында зәйтүн, кугән, элмә, хөрмә, әфлисун агачлары чәчәк атып утыра. Уртада агымнары төрле биеклеккә сикереп уйнаклаган фонтан. Аның тирәсендә гөләп, ләлә, канәфер, яран, нәркис түтәлләре тезелешеп киткән. Шулар арасында аллы-гөлле тәвис кошлары кукраеп һәм кәс-кәс басып йөри. Йә, Ходаем! Җәннәт дигәннәре менә кайда икән!

Сал-Сал әллә солтан хәтле солтанның үзен күрергә насыйп булыр микән, дип хыялланган иде, күктәге йолдызлар колчуралар учына килеп төшми шул ул. Әбүгали каршына шушы кала хуҗасы, әмир Хәләф чыкты. Сихри фонтан янындагы бер почмакка барып утырдылар. Чыш-пыш килеп сөйләшкән сүзләре Сал-Сал колагына усак яфраклары лепердәве сыман чак-чак кына ишетелеп торды.

—Килешенгән вәгъдәләребез шул көенчә кала. Уртанчы кызым Зәйтүнәне сиңа хатынлыкка бирәм.

—Бәрәч, бәрәч! Солтан миңа үзенең төпчек сенелесе Саимәне бирү турында авыз ачкан иде.

—Саимә ни, Зәйтүнә ни, барыбер түгелмени? Мин—Мансурның энекәше, Зәйтүнә тәнендә дә солтан каны ага. Ә Саимәне башкача телгә алма, аны газнәвиләр шаһы Маликка вәлидә хатын итеп биреп җибәрдек без.

—Барыбер, гадел түгел.

—Аның караявы, туену өчен солтан сина Сәмәркәндне дә бирә.

—Ә анысы хакына мин нишләргә тиеш?

—Солтан сина теге чакта ук киная салган иде. Бөкре Карунны котыртып яуга чыгару шарт. Безнең чиру аны Карт Җинги дәрьясы янында тозак корып көтеп торачак...

Сал-Сал үз колакларына үзе ышанмыйча тораташ шикелле катып калган иде, янга баскан нәүкәр касыгына төртте. Сөйләшү тәмамланган, Әбүгали ат таптаган табак шикелле сытык чырай белән кирмән капкасына таба атлап бара икән.

Кабат караханнар ягына кәлтә елан сыман шуышып, исән-сау чыктылар. Кайтуга, Әбүгали Сал-Салны үзенең шәхси тән сакчыларыннан хасил курсыбаена чакырттырып алды. Иртәгә Сал-Сал инде иң гаярь бер йөз җайдак башлыгы булып яна яуга чыга...

Чыннан да сәманиләр Бөкре Карун гаскәрен Карт Җинги елгасы ярында, биек тау өркәчләре артына качып каршылады. Елга буендагы үзәнлеккә бер төмән чамасы гына җайдакларын тезеп калдырганнар. Бөкре Карун кичә генә ияр күргән селәгәй малай түгел, тик нигәдер ул ярты гаскәрен шул җәйрән баласы төсле кеп-кечкенә дошман төмәне өстенә ташлаттырды. Тау түбәсеннән ычкынган таш туфаны сыман тузгып очкан карахан ташкыны мескен төмәнне бәрән көтүе урынына сытып-изеп узды. Шулчагында гына тау өркәчләре ышыгыннан Нух-Мансур белән Хәләф әмир нөгәрләре калкып чыкты. Үзәнлектә тантана итә башлап сукырайган караханнар өстенә канатларын җәйгән бөркет төсле ике яктан төшеп ябырылдылар. Яу чоңгыл шикелле үз эченә тартты, Бөкре Карун сак чируген дә калдырмыйча кырылыш-орыш үзәгенә куды. Үзәнлектә коточкыч суешу, мәхшәр купты.

Сал-Сал батыр үзе Бөкре Карун белән әмир Әбүгали чатырлары корылган калкулыкны ышыклап баскан иде. Берзаманны үзләренә таба үзәнлек читеннәнрәк, шыпан-шыпан гына якыная башлаган нөгәрне шәйләделәр. Сал-Сал җайдаклар уртасында баш түбәсенә көмеш очлым элгән Хәләфне таныды да агарынып калды. Әле кайчан гына шушы кеше әмир Әбүгалидән кияү ясамакчы, өстәвенә Сәмәркәндне бүләк итмәкче иде бит. Хәзер шушы ук бәндә бер төркем елан ияртеп Әбүгалине буып ташлар өчен якыная. Ничек шулай икейөзле була ала кеше, нинди хәл бу?

Артта Бөкре Карунның ачыргаланып кычкырган фәрманы яңгырап ишетелде.

—Әнә теге шайтан таягын, әмир Хәләфне тотып китерегез мина! Исән көе тотып китерегез! Мин үзем аның йөрәген суырып алам!

Сал-Сал үз-үзен белештермичә алга томырылды. Анын яшендәй уйнаклаган кылычы астында җиде-сигез сәмани авып калды. Кыр казлары сыман чөй ясап тезелешкән башка караханнар да дошман нөгәрен ерып килә иде. Сәманиләр әмирләрен саклый алмадылар. Сал-Сал батыр аны бер мизгелдә ияреннән йолкып күтәрде дә, тезләре өстенә аркылы ташлап, кахан чатыры тарафына очты.

Җирдә шыңшый-шыңшый аунаган Хәләф янына, иң беренче булып, Әбүгали килеп җиткән иде. Ул кылычын кыныннан кабаланып тартып чыгарса да, Бөкре Карун җан кыярга ирек калдырмады.

—Тукта, ашыкма син, әмир! Ансат үлем илә котылмасын. Бу имгәкне

мыскал-мыскал телеп, ярасына тоз сибә-сибә газапларга кирәк. Солтан атын алып кәпрәйгән Нухка сабак булсын.

Әбүгали сазга кереп баткач ябышырга салам тапкан сыман Сал-Сал ягына борылып ысылдады.

—Хәзер үк телен кис ошбу хәсис җанның! Хәзер үк кис! Аннан күзен чокы! Турап, өзгәләп бетер! Бу хәсисне син эләктереп кайттың. Кахан сиңа каршы килә алмый.

Менә шул минутта үзенең күңелендә нинди ут уйнавын Сал-Сал бер тамчы да аңламыйча калды. Әүвәл хәтерендә Бохара урамнары, солтан кирмәнендә кәс-кәс басып йөргән вәкарь тәвисләр яшен шикелле сикергәләп узды, ә аннары ияреннән икегә теләнеп ауган Гайсә батырның газап тулы карашын очраткандай көйде. "Түрәлек хакына мине сатасыңмыни, әй, егеткәй?!"—дип эндәшкән әрнүле авазы ишетелгәндәй булды.

—Юк, юк!—дип ярсый-котырына кычкырып җибәрде Сал-Сал.—Мин бит катил түгел! Мин үземне сатмыйм!

Янда Әбүгали зәһәр елан сыман янә ысылдады.

—Җир йөзендә яшәтмим мин сине! Нәселеңне корытам! Таптыйм, изәм, сытам!

—Бик хуп, сатлык әмир,—дип кенә Әбүгалинең битенә ташлады да Сал-Сал батыр шундук ияр өстенә сикереп менде.—Җилне куып тотардай этләр таба алсаң, әйдә, эзләп кара.

Берничә мизгелдән соң Сал-Салның дөя шикелле дәү, мәһабәт аргамагы буш дала ягына таба томырылып-шашып чаба иде. Ботак-чатаклы имән күсәк тоткан батырны куа чыгучы ташбаш табылмады.

## 47

Сал-Сал инде ярты ел буе Алатау мәгарәләре эченә качып яши. Монда иптәшләр күп. Богау чылбырларын өзеп, зиндан ишекләрен җимереп коллык михнәтеннән котылган азатлар бар. Йортын-ихатасын соңгы мендәренә, иләк-табасына тикле талап чыккан кахан салымчыларын кыйнап йә үтереп качкан ярлылар дистәләгән. Кәрваннарда ерак араларга йөргән чакта йоклап хуҗасының малын урлаттырган кушчылар, шул ук кәрваннарны үрмәкүч шикелле сагалап талаганда йә атамансыз, йә үзләре кул-аяксыз калган юлбасарлар хәтсез. Әле тагын кахан гаскәренә алынудан качкан салам-сыйрак, үзенә кайда да җылы оя коралмаган сукбай, үзенең үтә дә акыллы, тик бердәнбер дип санаган буп-буш фәлсәфәсен тыңлатырга үшән колак табалмыйча аптырап йөргән суфый-дәрвиш, дала уртасында тырпаеп утырган йомрытау шикелле шыр-ятим калган малай-шалай, йорт-лапасы янган хәерчеләр, кыяфәтләренә күз ташларга да куркыныч гарип-горабәләр. Чын ир итеп исәпләрдәй качаклар өч йөз чигенә җитеп килә бугай, ә ярты-йорты әтрәк-әләмнәре санап бетергесез.

Сал-Сал менә шулар арасында башлык булып йөри. Үзе моны сорап та алмады, дәгъва-киная да белдермәде, тик яннарына килеп кушылганнан бирле барча качак аңа буйсынып яши. Шул печән кибәнедәй зур гәүдәсе, имәндәй таза беләкләре, чүлмәк чаклы дәү-дәү йодрыклары—һәммәсе дә аны башкалардан аерадыр инде.

Качаклар күбесенчә ау-балыкка йөреп тамак туйдыралар. Бер аягын атлаганда икенчесен әткә ашатырдай итеп, карт-корылар төсле ярымйоклап барган кәрваннарны талау-чишендерү дә болар өчен чит-ят шөгыль түгел. Атаманнары Сал-Сал кайчакларда шашынып китеп, хәтта, әмир, бәк, кахан

көтүләрен дә талап кайта. Ләкин үзе моннан ләззәт тапмый, ахры, аннары атна-ун көн буена сөмсерен коеп, авызына су капкандай йөри.

Менә бүген ул учак янында күмерләрне болгаткалап утырды-утырды да бөтенләй дә көтелмәгән яңалык ачып салды.

—Моннан кул сузымында гына, ике көнлек арада, минем әткәй белән әнкәй яшәп ята. Дөрес, әти булган кеше үземнеке түгел, үги атай. Ләкин унике-унөч ел чамасы нәкъ шул кеше мине үзенең куенына сыендырды, ашатты, киендерде. Ә мин, игелексез, инде ике ел буена шуларның хәлләрен дә белмим.

—Соң, әйдә, әйдә, хәзер үк җыенып та китик,—дип берничә елгыр җайдак урыннарыннан сикереп купкан иде, Сал-Сал шып туктатты.

—Ата-ана йорты көтү җыеп кайта торган базар түгел. Аннары... аннары мине анда кахан яисә Әбүгали этләренең көтеп торуы бар. Үзем генә кайтам, миңа иярмәгез...

Алатау ерымнары эченә поскан кышлакка Сал-Сал, югыйсә, кичке карангылык ингән чакта гына килеп кергән иде, чыра янып сүнәрдәй ара узуга, авылның икенче очыннан җайдак чыгып очты.

Сал-Сал өйгә ингәч Сания белән Исәнбай икесе дә улларының кочагына килеп сыендылар. Яңакларында шатлыклы күз яшьләре. Сәке читенә, урындыкларга тезелеп утыргач та, сокланулы караш белән Сал-Салны күзәтәләр. Сокланмаслык түгел. Баш түбәсе түшәмгә тигән буй-сын. Тәнендә үгезләрне сугып егардай гайрәт, тазалык бар. Яуга чыгып киткән чакта иреннәре өстендә мамык сыман йомшак төкләр генә иде, хәзер куе кара мыек. Менә шунысы тәэсир итте бугай, Исәнбай әкә хәтер казанына чумып алды.

—И-и, мин Болгардан алып кайткан чакта менә мондый мендәр шикелле бәләкәй генә сабый бала идең, инде, менә, түшәм җимерердәй батырга әйләнгәнсең. Күз генә тимәсен, и-и, гомерләр!

Болгар атамасын телгә алгач Саниянең карашында да әүвәл очкын уйнап куйды, әмма икенче мизгелдә үк йөзен болыт каплап киткән сыман булды.

—Болгарлар дөньяда моннан унбиш ел чамасы элек үзләре коллыкка сатып җибәргән Сал-Сал атлы сабый барлыгын онытканнардыр инде. Аллага шөкер, исән калдык әле. Аллага шөкер, Исәнбай табылды.

Әлеге күңелсез хатирәләр белән Сал-Сал бала чактан бирле танышып үскән, шуңа күрә еракта калган, инде онытылган Болгарны искә алуларын бер дә сөйми иде. Ә менә бүген, саташкан ай сыман, бөтенләй икенче яктан килеп ачылды ул.

—Минем Болгарны барып күрәсем килә,—дип Исәнбай әкәнең йөзенә текәлеп сөйли башлады Сал-Сал.—Берүк ачуланма. Син миңа чып-чын икенче ата булдың, игелекләр кылдың. Мин сиңа рәхмәтләр укып гомер буе дога кылачакмын. Иллә мәгәр ошбу җир йөзендә минем үз атам да булган. Мин аны хәтерләмим. Ә менә болгарлар үзләре кайчандыр җиһанда Байдар атлы баһадир яшәгәнен, аның шулар иле, шулар азатлыгы өчен җан биргәнен искә алалар микән? Шуны беләсем, ачыклыйсым килә. Мине атам каны үз янына тарта.

Сал-Сал инде әнисе тарафына борылып үз карарын әйтте.

—Мин Болгарга китәргә булдым, әнкәй.

Сания күз яшьләренә буылып, сыгылып төште. Берничә сүзе генә аермачык булып ишетелде.

—Китмисең, китмисең син, үз иленә кайтасың, газиз балам. Үзеңне кабат монда көтеп җиткерүләр насыйп булмас инде...

Сал-Сал урамга атлап чыккан иде, күрше койма-капка артына яшеренеп торган алты-җиде ир килеп ябырылды. Сал-Сал шуларның бер-икесен генә

чоеп атарга өлгерде, калганнарын тау-таш арасына поскан качаклар уктан чүкеделәр. Тегеләр качкан урыннарыннан аягурә күтәрелгәч кенә танып алды батыр. Үзе белән бергә мәгарәдә яткан, яуга йөргән иптәшләре икән.

—Мине кахан яисә Әбүгали яллаган этләрнең сагалап торуы бар, дип үзең кисәттен бит,—ди-ди көлешәләр хәзер.

Тау битенә менгәч, үзе уйнап үскән кышлак өстенә әйләнеп, усал итеп сүгенеп куйды Сал-Сал.

—Сатлык җаннары юкка чыксын өчен моның бер башына очкын элеп китү дә артык булмас иде. Юк шул, бармый, кулым күтәрелми. Бу бит—мин ятимне сыендырган авыл.

48

Дала яклап очкан яңа чапкын күренде. Бүген таннан башлап бишенчесе инде. Манарадагы күперчекләр өстенә менеп баскан тоткавыллар өчен бу яңалык түгел. Янкалага ялгызак көенчә дә агылалар, олаулап-олаулап та. Кайсысы Болгарның үзеннән үк төбәп килә, кайсылары аеры-аеры көе Бәнҗә, Кашан, Ашлы каласыннан. Хәтта, арбасына соңгы сыер-сарыкларын тагып юлга чыккан арлар, чирмешләр, мукшылар да очраштырып тора. Идел яры буйлап менсәләр дә эзләп табалар Янкаланы, Ука ярына барып төртелсәләр дә барыбер адашмыйлар. Болгар илендә рәнҗетелгән һәркем шушы кирмән диварлары артына кереп сыенып оя эзли, һәрбер сәйях шушында мәрхәмәтле ышык-түбә таба. Ә кирмән капкалары каршына килеп егылган юлчыларның зар-хәсрәте бер үк.

—Тимер-Мөэмин яңа салым салды. Хәзер инде базарга чыккан өчен генә түгел, ана кергәнче үткән кала капкалары, авыл күперләре өчен дә бугаздан буып талый.

—Болай да авызыбызны ачсак үпкә күренеп тора. Ә Тимер-Мөэмин түбәгә чыгарылган һәрбер мич морҗасы, лапас артына өйгән һәрбер кибән өчен дә салым талап ыштансыз калдырмакчы...

Менә шушы кайгы-афәтләрдән котылмакчы булып, кара халык Янкалага агылып кына тора. Иделгә Ука елгасы килеп кушылган төштә бер ел гына элек калыкты ул. Ләкин даны инде еракларга китте. Әлегә юньле-рәтле исеме дә юк үзенен.Ерактагы бер төбәккә килеп тәүге бура бурау бәхетенә ирешкән төзүчеләр һаваланып үзенчә сукалыйлар.

—Саескан тавы башына менеп беренче казыкны кагучы кеше әмир Ибраһиммы? Шулай булгач, Ибраһим кирмәне бу, бетте-китте!

—Һе, алайга китсә, Чулман буендагы Шайтан каласына беренче казыкны кагучы кеше дә шул Ибраһим. Хәзер инде ул кереп чыккан барча кирмәнне дә аның исеме белән атыйкмыни?

Ибраһим әмир үзе бернигә дәгъваламый. Тәүге юлдашларын тынычлыкка чакырып, ипле генә дәшә.

—Хикмәт исемдә түгел, тора-бара меңгә төрләнер ул. Иң мөһиме, бу—урысларның борын төбенә китереп салган беренче зур кала. Шулай икән, әйдә, әлегә ул "Яна кала" аты белән йөрсен.

Менә биш-алты ай буе мондагы халык аны, үзенчә жинеләйтеп, "Янкала" дип сөйли. Үпкәләүче кеше һич сизелми. Монда, гомумән, борын салындырып йөрүне бер дә өнәмиләр. Урыны ул түгел. Әле Идел, әле Ука елгасының аръягында урыс юлбасарлары, әрсез ушкуйларның яна нөгәрләре пәйда булып тора. Янкалада һәрчак уяу, сак йөрергә, бердәм, дус яшәргә кирәк. Шушы кануннарны сакламасаң, мүкләк бәрән кебек көтүдән аерылып калуың бар...

Яна чапкынны манара астындагы асылмалы капка каршына килеп житүгә

үк жинел таныдылар.

—Даян вәзирнен малае Хәзәр Насыйр бит бу. Нишләп сакчыларсыз гына йөри икән?

Соткавылларнын теле гел искечә. Тимер-Мөэминнең Даянны түрәлектән алып атканына әллә кайчан инде, болар аны һаман "вәзир" диләр. Насыйрнын да Йосыф кахан сараена шымчылыкка барып кайтуына ничәмә-ничә еллар үтеп киткән, әле булса "Хәзәр" дигән кушаматы калды. Монда иркенлек, хөррият, башбаштаклык. Хәтта, Тимер-Мөэминне дә "хан" дип олылап телгә алучы юк...

Әмир сараен әйләндереп алган биек ихата эченә Насыйрны тоткарлыксыз-нисез үткәрделәр. Ихата уртасында күлмәкләрен салып аткан көенчә бүрәнә бурап маташучы Ибраһимны күргәч, юлчы кунак күрше мунчасына адашып кергән шикелле аптырап ук калды.

—Бәрәкалла! Син үзен монда сугымчы да, пешекче дә, табынга кунаклар чакыргач алларына чыгып биюче дә мени?

—Әйе, нәкъ шулай, туганкай,—дип, Ибраһим башын артка ташлап, рәхәтләнеп көлде.—Үзем менә шушылай итеп үрнәк күрсәтмәсәм, башкаларны ничек бушка эшләтәсен? Аннары эшсез яткан тимер тутыга бит ул. Мин үземә нинди шөгыль табыйм?

—Әйтерсен лә, син эшсезлектән коргаксып интегәсен. Ярты ханлыкны авызына караттын ла инде.

Шул рәвешчә, хужа кешенен салпы ягына салам кыстырып алгач, ниһаять, Насыйр житди сүзгә күчте.

—Хан котыра, әткәйне богаулап зинданга ташлаттырды. Яна салым салгач тимерчеләр бистәсе, бердәм кубып, хан кирмәнендәге капкаларны жимереп аткан иде, аларны, янәсе, минем әткәй котырткан булып чыкты. Мин Болгардан төнлә генә качтым. Юлда жан өшеткеч хәбәр куып житте. Хан йөздән артык тимерченен кулларын чаптырган, ди.

—Ә-ә-әй, бәдбәхет! Әх, канэчкеч көзән!—дип ачынып бүлдерде әмир. Насыйр дәвам итте.

—Хан әле яз көне үк менбашларын, морзаларны далаларга юллап, кыпчакларны, угыз-бәжәнәкләрне яллый башлаган иде. Берме, икеме төмән туплап алгач, синен өскә жибәрмәсә ярый. Хәтта хәзәр каханыннан да курыкмый ул, ә синен исеменне ишетүдән дер калтырап тора. Чөнки хаксыз изелгән барча халык синен янына кача, шушы Янкалала терәк эзли. Син тәхеткә лаек төп дәгъвачы гына түгел. Син гади халык ышанычы, ил калканы. Менә ни сәбәпле ханга куркыныч син...

Насыйр килгәннән соң бер атна чамасы гына вакыт үткән иде, дала өстенә кара тузан болыты күтәреп якынайган атлы гаскәр күренде. "Тимер-Мөэмин юллаган катилләр йә жәзачылар чирүеме әллә?"—дип хорафатка бирелә башладылар. Дивар өстендәге агач басмалар ирләр белән тулды. Сумала, су, вак таш тутырылган казаннар астына ут яктылар. Көбә-очлымнарга төренеп алган Ибраһим әмир үзе манарага менде.

Юк, болар Тимер-Мөэмингә ялланган умырткасыз колчуралар түгел. Хан үзенен башбирмәс энекәшен һәм ул төзегән кирмәнне жир йөзеннән себереп ташлау өчен бер төмән жайдак та кызганып тормас иде. Ә болар сан ягыннан бер меңгә дә тулмый. Өстәвенә, алар, әнә, ничек иркен атлап, туарылып килә. Әйтерсен лә, яу сәфәре кануннарын бөтенләй оныткаңнар. Әйтерсен лә, боларны учларында биетеп тота торган бер сәрдәр юк. Барча жайдак көтүчесез калган мал шикелле озын чылбыр ясап таралышкан. Жәяләре аркада, сөңгеләре өзәнгегә асып куйган килеш. Кайберләре хәтта йөгән тотып та азапланмый бугай, байтак атлар пошкыра-пошкыра башын болгап бара. Ин койрыкка дөяләр ияртеннәр, аларны куучы кушчылар да

сирәк. Валлаһи, ник туганына үкенеп йөри торган җыен пошмас әтрәк-әләм, йолкышлар өере ләбаса бу!

Жайдаклар кирмән дивары алдына сузылган биек үр каршына житкәч, Ибраһим аларны янә кат-кат күздән кичереп чыкты. Чүл гарәбенекедәй чутыр тәннәр, сирәк сакал, чылгыйлары озын булып асылынган мыек, сөякләре ике якка төрткән киң яңаклар, тап-тар, кысык күзләр. Күбесенең өсләрендә мамыктан сырган бишмәт, яисә җиңнәре балактай киң чапан, башларында өчпочмаклы киез эшләпәләр, яисә бөдрәләнеп торган йоннары да кыркылмаган сарык тиресеннән тегелгән, түмгәк шикелле түм-түгәрәк бүрек. Юк, болар Ибраһимга электән үк таныш бәҗәнәкләр дә, кыпчаклар, аймыклар, угызлар да түгел. Алайса, каян гына килеп чыккан жайдаклар бу? Алар кемнәр?

Сафлар арасыннан кибәндәй зур гәүдәле бер пәһлеван аерылып чыкты. Бу башкаларына бөтенләй охшамаган. Буе тегеләргә караганда бер карышка биек, яңаклары озынча, йөзе япь-яшь, ә үзен, ай-һай, иркен, горур тота.

—Кала бәгегез бардыр, сөйләшергә чыксын!

Дивар өстендә күк күкрәгән сыман шаркылдап җавап кайтардылар. Аратирә мәсхәрәләп кычкырган сүзләр дә ишетелеп торды.

—Мүкәләп чыксынмы соң ул, әллә башын игән көе аягурә күренсә дә гафу итәсеңме?

—Монда бәк-морзалар түгел, әмир хуҗа! Белеп сөйләш, йолкыш!

—Эт талаган мондый ыбыр-чыбырларны кайдан эзләп таптың?..

Ошбу тавыш-гарасаттан дөя чаклы аргамагы гына пошкырынып куйды, ә жайдакның кылы да селкенмәде. Саңгырау кеше төсле, тавышын күтәребрәк, янә кычкырды ул.

—Мин бит сезгә кала бәгегез монда чыксын, дидем. Әгәр курка икән, мин чирүне бер чакрымга читкә җибәреп торам.

Япь-яшь пәһлеван артына борылып ике-өч фәрман да ыргытып өлгермәде, жайдаклар җәйрән шикелле сикергәләп шундук диварлардан читкә ыргылдылар. Менә шул вакытта хәйран калды әмир. Сәер, гаҗәп! Бу йолкышлар, мондый әтрәк-әләм юлбарыс көтүе сыман жыерылып, әсәренеп, дәһшәт кузгатып та чаба белә икән!

Ибраһим үр артына яшь пәһлеван шикелле үк япа-ялгыз чыкты. Ике-өч адым ара калдырып туктагач, кәләш күргән кебек сәерсенеп бакты. Гайрәт ташып торган мәһабәт сын, йөзендәге һәрбер бөртек, һәр күзәнәк саен таныш чалым. Каян, ничек хәтерли ул аларны? Кем соң бу егеткәй, йә, Ходаем, кем?

Түзмичә сорады ул.

—Син кем буласың, батыр? Кай яклардан килдең? Нинди чирү бу синең кул астында?

—Бик ерактан килдек без, әмир, бик ерактан,—дип башлап китте батыр, ә Ибраһимны янә эчтән корт талады.

“Сөйләме гел безнеңчә. Бернинди алышта, бәйгедә очраткан юк. Кем соң бу егеткәй, кем бу?”

Колагына батыр сүзләре ишетелеп торды.

—Кызылком сахралары артыннан, Алатау буйларыннан ук кузгалдык без. Минем кул астында карлукълар, мангытлар бар. Юлда кыпчаклар, угызлар өстәлде. Болгар жиренә кергәч, хәтта әле бортаслар, суарлар да килеп кушылдылар. Барысы да хан-каханнар йә әмир-бәкләр талавыннан качып китүчеләр. Мин берсен дә кире кумадым. Кем коткару сорап яисә терәк-куыш эзләп килә, барысын да канат астыма жыйдым. Минем чирүне җәберләнгән, изелгәннәр көтүе, дип атасаң да була, гадәләт вә хөрриятkә сусаган ихтилалчылар, дисәң дә хата түгел.

Ибраһим төрттереп сорау бирүдән тартынмады.

—Бортас, суар җирләре аша үтеп киткәнсең. Нишләп Тимер-Мөэмин ханга барып ялланмадың?

Егет ачу-ярсуыннан кайнар казанга чумдырган кысла сыман кызарынып чыкты.

—Этнең ялваруы Ходай тәгаләгә барып ишетелсә күктән ит явар иде, дип әйткән бер аксакал. Синең колаклар да шулай саңгырау икән. Әле генә әйтеп тордым ласа. Минем җайдакларым—элек тә хан-әмирләр тарафыннан таланган вә җәберләнгән ирләр. Ни йөз белән мин аларны тагын бүре авызына илтеп тыгыйм?

—Алайга китсә, мин дә әмир инде.

—Әмир әмирен, анысын яхшы беләм. Иллә мәгәр син абзыең тарафыннан читкә тибелгән, үзеңә тиешле тәхеттән коры калган әмир. Ә җәберләнеп бергә жыелган аксак-туксак, яраланган бүре көтүе белән бер ул. Андый бүреләрнең көче, игътибары дошманнарга каршы юнәлтелгән була. Ахыр чиктә, алар бер-берсен тиктомалдан тотып ашамыйлар.

Ибраһим көлемсерәп куйды, янә сорау бирде.

—Ә дошманны җиңгәч кая барырлар соң ул бүреләр?

—И-и-и, Ибраһим әмир!—дип башын чайкый-чайкый сузды батыр.—Җиңүчеләр ияр-тәхет дигәненә менеп алгач, янә җәберләнгән, кимсетелгән, таланган як табыла, хасил була бит ул. Җир йөзендә кимсетелгән, изелгән халыкларның мәңге бетәсе юк.

—Һе! һе-һе! Әрекмән шикелле бер катлы гына түгел икәнсең син, батыр. Син беркатлы түгел,—дип кабатлап торды-торды да, Ибраһим әмир бер бармагын егет йөзенә ук шикелле төбәп, капылт сорап куйды.

—Исемеңне син кем диден әле?

Егет әмир хәйләсен шәйләп өлгермәде, тиз-тиз җавап бирде.

—Сал-Сал.

—Сал-Сал, Сал-Сал,—дип кабатлады янә аптыраган әмир.—Минем бу исемне әллә кайчан ук ишеткәнем бар иде бит инде. Кайда ишеткәнне генә хәтерләмим. Этиең кем синең?

Искә-анга килгән Сал-Сал батырның йөзе калкан сыман кырысланып калды. Җавабы да боз шикелле салкын, җансыз чыкты.

—Анысы мөһим түгел. Бездә ил өчен игелек кылган кешеләрнең исемен-шәҗәрәсен ятлаучы юк. Без—черегән капчык бавы шикелле кыска хәтерле кавем.

Берникадәр аптырашып торганнан соң әмир телгә килде.

—Бөтен мәмләкәтләр буйлап туплаган ул мескеннәр чирүе белән ни кылырга җыенасың инде?

Сал-Сал батырның йөзе элеккечә кырыс, житди иде. Усалланып дәште.

—Мыскыл итмә, әмир. Ир-егетләрнең асылы яуда йә орышта сынала. Син дә сынап кара.

—Кайда, ничек итеп?

—Менә шушында, кырда. Син ике, йә өч йөз яугиреңне чыгар. Ә мин бер йөз генә җайдак чакырып алам. Минекеләр җиңеләләр икән, бөтенесен иярткәм дә кире борылып китәм. Ләкин ук очырып, кылыч белән турап, чынлап сугышу юк. Юньле җайдак үзен болай да раслый ала, кан коюсыз гына орышсыннар.

Ибраһим байтак вакыт буе баш чүмечен кашырга мәҗбүр булды, аннан гына кулын селтәп үз карарын әйтте.

—Әйдә, орышсыннар. Ичмаса, каладагыларга бер тамаша булыр.

Ике якка да катгый фәрман китте. Кирмән эчендәге һөнәрчеләр, хатын-кыз, бала-чага—һәммәсе дә дивар өстенә тулды. Ибраһим белән Сал-Сал

гына тегендә-монда кучеп маташмады, алар яндагы калкулыкка, үргә менеп басты...

Сал-Сал болай дуамалланыр, әтәчләнер-кукраер дип уйламагандыр инде, Ибраһим әмир үз ягыннан, чыннан да, өч йөз ирне чыгарырга әмер биргән иде. Тегеләр ике-өч катлы чылбырдан хасил тыгыз бөҗра булып тезелделәр. Һәрбер яугир сөңге урынына тоткан тәртәләрен алга төбәп баскан, бөҗра дошман күргәч энәләрен кабарткан усал керпе сыман. Ирләрдәге килешкилбәт җитди, арада берәү дә уйнарга исәпләми, һәркайсы кыргый даладан килгән җайдакларга сабак укытмакчы. Ләкин болардагы көрпәлек-һавалану, масаю-тәкәбберлек озакка бармады шул.

Менә, Идел ярындагы үзәнлектән йодрык-төен булып йомарланган "дошман" калкып чыкты. Шикләнерлек түгел, җайдакларның саны бер йөздән дә артып китми иде. Алар үткен сөңге шикелле тезелешеп алга томырылуга ук дивар өстендәгеләрнең һәммәсе "аһ" итте. Сөңгенең нәкъ очына, башак өлешенә икешәр өркәчле, зур-зур дөяләрне бастырып куйган болар. Җайдаклары өркәчләр арасына кереп поскан, ә дөяләр сыртыннан бастырык кадәрле энәләр сузылып килә. Аргамаклар иярләгән ирләр чүл бүресе, фил, юлбарыс авазлары чыгарып бертуктаусыз улый, кайберләре хәтта ат сыртына менеп баскан көе аягурә оча. Берзаманны җайдаклар яшен суккан сыман капылт юкка чыкты. Аларның ияр астына чумып юыртуын бик аз кеше генә абайлап-шәйләп калды.

Бөҗра ясап тезелгән урыс сугышчылары дала явы, дөя, җайдаклар чаялыгы күреп үскән нөгәр түгел. "Дошман" йөзендәге очлы башак кыл икегә ярып керүгә үк дистәләгән ирләр янга тәгәрәп калды, бөҗра кулдан ычкынган керәч тәлинкә шикелле яргаланып бетте, "керпе энәләре" юкка чыкты. Ияр астыннан күтәрелгән дала җайдаклары урыс ирләрен кыл арканнар атып чүпли башлагач, янкаланыкылар инде карчыгадан качкан тавык чебиләре кебек читкә сибелеште. Бернечә минуттан соң урыс ирләренең күпчелеге балчык урлар артына кереп поскан, калганнары яу кырында арканнарга уралып ята иде. Дивар өстендәгеләр ачыну-рәнҗүле бәя җиткерделәр.

—И-и, җыен җебегән, куркак! Шушы йолкышларга да каршы тора алмадыгыз. Тимер-Мөэмин түмәннәре килсә, сездән нинди җиңү өмет итеп булсын?..

Үз гаскәренең йомшаклыгын күреп пошаманга төшкән Ибраһим да "дошман" йөзе белән соклануын яшерми сорап куйды.

—Боларны мондый орыш алымнарына ничек өйрәттең син?

—Һе, һе-һе!—дип көлемсерәп җавап бирде Сал-Сал, нәкъ баягы Ибраһим әмир сыман.—Без ярты ел буе дистәләгән вилаять, олыс, ханлык тозакларын үтә-үтә килдек. Авызына су керсә, аю булып аю да йөзәргә өйрәнә ул. Без дә юлда туктап ыстан корган саен күнекмәләр ясадык, өйрәндек инде менә.

Ибраһим әүвәл, сыный-сыный, батырның йөзенә озак текәлеп торды, аннары кайнар итеп кочагына кысты.

—Мин чын, ышанычлы сәрдәр эзләп табалмыйча күпме иза чиктем. Әйдә, сәрдәрем бул, Сал-Сал!

## 49

Таҗларын ача башлаган чәчәк бөреседәй гүзәл Айзирәкне Ибраһим әмирнең сараена кергәч очратты ул. Гөлләргә су сибеп йөргән чибәр кызыкайны шәйләде дә гүя телсез калды. Уйнак колын сыман нәфис, сылу буй-сын. Әле хөрмә кебек кенә төрткән нәни күкрәкләр өстенә сузылган ике йомшак толым. Карлыгач канатыдай кыйгач кара

кашлар. Шомырт сыман янып торган күзләр. Әле тапланырга өлгермәгән язгы агач яфраклары кебек эчкерсез, җылы караш. Танны көткән чәчәк таҗы шикелле мөлаем, сусыл, назлы иренкәйләр.

—Әмин сине беләм, Сал-Сал батыр,—дип үзе эндәште ул.—Хәзер бөтен халык сине генә сөйли. Янкаланы таң калдырдың бугай.

Сал-Сал тыенкы гына көлемсерәп куйды, әмма җавап кайтарырга сүз тапмады. Айзирәк ризык алып кайткан әнисен каршылаучы кош баласы кебек чыркылдавын белде.

—Каладагылар сине генә уйлап баш ваталар хәзер. Җиде дала аръягыннан монда кайтып җәфаланмас иде, ул безнеңчә сөйләшә, ул болгарлы, диләр. Ә асылда кем син, "Сал-Сал" чын атыңмы?—беркем белми. Син миңа да сереңне чишмәссең инде?

Ниһаять, батыр да аваз бирде. Ләкин әллә табышмак, әллә тозак корды.

—Ник чишмәскә? Чишәм! Мәгәр монда түгел.

—Ә кайда соң?—дип уенга кушылды сылу.

—Дивар аръягында, дала кочагында. Җиде-сигез генә төн кунсам да, инде күреп кайттым. Ука буендагы Каенлы тау астында Ана сөте дигән чишмә тибеп ята.

—Беләм, беләм, анда булганым бар,—дип Айзирәк ботактан-ботакка очкан тутый кош шикелле канат кага-кага чыркылдады.

—Белсәң, кояш баткач менә шул чишмә буена кил. Шунда серләшербез.—Егет "син шикләнмә" дигән кебек янә өстәп куйды.—Курыкма, сиңа кагылмыйм мин. Башкаларга урлап качарга да ирек бирмим.

Энҗе сәйлән тавышлары чыгарып, Айзирәк янә көлде.

—Һе, синдәй аю да урлатып тормас инде. Тик... әти генә...

Сал-Сал хафага төште.

—Әллә чыгармыймы?

—Элегрәк ул бер сүз дә әйтми иде. Хәзер генә, менә...—Айзирәк олы гөнаһ кылган кеше төсле үзенең күкрәкләренә күз ташлады.—Тоткавыллар башлыгына әйтеп куйган. Имеш, аның рөхсәтеннән башка бер адым да читкә атламаска.

Сал-Сал батыр өстеннән тау төшкәндәй җиңел сулап куйды.

—Ана гына калса, хәл итәрбез. Сине капкаларда туктатучы булмас...

Айзирәк тулган ай калыккач кына килеп җитте. Сал-Сал инде әллә кайчаннан бирле читлектәге арыслан шикелле йөренгәләп, утлар йота-йота көтеп тора иде. Җиңел юырткан чаптар күренүгә үк, иңнәренә канат үскән сыман, ана каршы очты. Сылукайны иярennән алып, сабый чагыннан бирле бергә үскән сөеклеседәй назлап, күкрәгенә кочты. Талымлы һәм кайнар иреннәре берсен-берсе эзләп кушылганчы, һавада гомергә сыңар тапкыр гына кабатлана торган тылсымлы сүзләр асылынып калды.

—Мин бу көнне ничә еллар буе тилмереп көтеп йөрдем. Күктәге меңәрләгән йолдызларны көнләштереп, ниһаять, мин бит сине, сине эзләп таптым. Алай да туган җиремә әйләнеп кайтканмын мин.

—Мин дә сине көттем, Сал-Сал абый. Далаларга, яланнарга чыгып эзли-эзли син батырны көттем...

Җиһан әле генә бәби тапкан бәхетле һәм назлы ана сыман тынып, җиңеләеп калган. Күк йөзе бәллүр чишмә төбедәй чалт-аяз. Анда качышлы уйнарга чыккан сабыйлар, яшьтәшләр шикелле йөзәрләгән йолдызлар, адашлар үзара күз кысыша. Үзенә яр таба алмыйча саргайган сазаган кызныкы кебек салкын, боек йөзле ай кыршауга утыртылган кебек тәгәрәвен белә. Ара-тирә генә җилбәзәк хатын шикелле анда-монда сибелгән вак болытлар йөзеп үткәлиләр. Үзен онытгырмас өчен генә, бишектәге сабый бала сыман уфылдап, саташкан җил сызгырып-исеп уза. Кайсыдыр

почмакта, өенә кайтмый калган әрсез ир шикелле, кәккүк-ябалаклар аваз биреп куя. Мәңге-мәңге йокламаска сүз биргән тынгысыз инеш-чишмәләрнең тонык челтерәве килеп ишетелгәли. Табигатьнең камил, бөтен, истирәхәт кичереп яткан чагы!..

Таган кебек атынган-очынган күңелен көч-хәл белән тыеп Сал-Сал сорап куйды.

—Сиңа ничә яшь соң әле, бәгырькәем?

—Унөч тула инде... озакламый.

Сал-Сал үзеннән бигрәк сылукайны тынычландыру өчен өстәп әйтте.

—Ярәшергә була икән инде.

Айзирәк язгы ажаган, җәйге салават күпере сыман уйнаклаган күңелен тыеп кала алмады.

—Ошыйммы мин сиңа, Сал-Сал абый? Егетләрнең күзе төшәрлекме, матурмы мин? Яшермә, дөресен әйт миңа, дөресен әйт!—дип, ис-акылын җуеп шашынды ул.

—Матур, матур, искитәрлек сылу,—диде Сал-Сал, кабаланып, Айзирәкнең талым-уенына каршы тора алмыйча.

Яль-яшь кызыкайның мич ташыдай кызган шашыну-сырпалану чүпрәсе басылмады. Утардан чыгып качкан колын кебек уйнаклап, ул яндагы биек таш өстенә сикереп менде. Берничә мизгелдән соң тирә-якка Айзирәкнең хаситәсе, эчке күлмәкләре, гаурәт япмалары очып төште. Ирештереп-үчекләп эндәшкән назлы тавышы чишмә челтерәвен күмеп китте.

—Мин йокысы туеп уянган кошмын бүген. Мин яңа гына туган җилнең үзе хәзер. Теләсә кая очып китә алам. Мин ирекле, мине тыючы юк. Менә, кара, менә, кара миңа, Сал-Сал абый. Синең өчен генә чишендем мин. Сине гашыйк итәрлек матурлыгым бармы минем, бармы?

Сал-Сал Айзирәккә текәлде дә, әйтерсең лә, утлы күмер йотты. Чибәркәйнең буе-сыны яшь каендай зифа. Биле ике учка сыеп бетәр төсле. Нәни алма шикелле төрткән имиләре түм-түгәрәк, тыгыз. Шул алмаларның нәкъ урта бер җиренә килеп кунган чия төшләре—алсу, ләззәтле, ымсындыргыч, газиз. Иң ярсу, иң мәһабәт газәлләргә дә биргесез төз аяклары нәфис, дәртле. Ә шул аяклар кисешендәге сихри капка, әйтерсең лә оҗмах, җир җәннәте! Дөньяда шушындый да камил затлар, гүзәллек һәм тылсым була икән, йә, Ходаем!..

Сал-Сал инде дә түзә алмыйча күзләрен чытырдатып йомган гына иде, Айзирәк таш өстеннән сикереп төште дә уйнак җил шикелле килеп сарылды аңа. Тел очында һаман сәйләп чылтыравы.

—Тотып кара инде мине, Сал-Сал абый. Сиңа ошыйсым килә бит, менә, тотып кара.

Җәннәт бакчасына кереп адашкач, Сал-Сал зәмзәм суы йоткандай бөтенләй онытылды...

Янкала диварларына якыная башлагач кына шәйләп алды Сал-Сал. Дивар күләгәләренә ышыкланып, ялгыз җайдак басып тора анда. Билендә кылычы, инендә җәясе бар. Бик теләсә, әллә кайчан ук очына утырта алыр иде. Димәк, нык теләми. Сал-Сал батыр кирәк әле аңа. Айзирәкнең керсез-гөнаһсыз данына караганда җайдак өчен сәрдәр кадерлерәк.

## 50

Сал-Сал далада яңа нөгәр белән көнегүләр үткәреп азаплана иде, төш җиткәндә Ибраһим аны үзенең сараена чакырттыры. Кайтып керсә, дөя йоныннан суккан ап-ак киез, аллы-гөлле хәтфә келәмнәр өстенә корылган әмир табыны янына алты-җиде ир-ат тезелешкән.

Йөзләре талчыккан, киемнәре керле. Сорашып торасы юк, ерак юл газаплары кичкән сәйяхчылар болар. Сал-Сал өчен һәммәсе дә чит-ят, шуны истә тотып, әмир таныштырды.

—Болгардан тагын яна кунаклар килеп төште, сәрдәр. Барысы да ил терәге булырдай күренекле ирләр. Менә монысы—Кашан каласының олугбәге Шуран. Янәшәдә—Тәмте олысына хужа тиеш Балтач. Болары—Сабакуллән, Нур-Сувардан, Ашлы каласыннан илче итеп озатылган морзабайчуралар. Һәммәсе дә гозер белән килгән. Алар минем Болгар тәхетенә кайтуымны сорый. Мона без әзерме? Син бит сәрдәр кеше. Тынлап, үлчәп кара.

Карабаш кызлар көмеш тәпсиләргә тезеп кымыз, әче бал, хөрмә-йөзем, кунакларга таянып утыру өчен вак мендәрләр кертте. Табынга токмачлы аш, булар бөркеп торган ит калҗалары өелгән көмеш табаклар чыгарып куйган чакта илче булып килгән ирләрнен төп зарлары-максатлары ачыкланып беткән иде инде.

—Тимер-Мөэмин соңгы вакытларда аеруча чирмеш, ар, мукшы олысларын талый. Әлеге олысларда ислам динен кабул итәргә теләмәгән бәгъзе авылларга икеләтә-өчләтә салым җиткерелде. Мукшы ирләре Сура елгасын кичеп, Растуф кенәзе ышыгына кача башладылар.

—Тимер-Мөэмин җәзасыннан исән-имин котылган тимерчеләр, пайтәхетне ташлап, башка калаларга чыгып качты. Болгарда бүген көбәләргә генә түгел, хәнҗәр-кылычларга тикле олы кытлык. Әмир Ибраһим кайтса, пайтәхетне яклардай көч табылмый.

—Пайтәхеттән гайре барча калаларда имам-хатыйблар, бәк-морзалар, һөнәр осталары, сәүдәгәрләр Ибраһим әмир яклы. Кара гавам дә Ибраһим кайтса гына җинел сулый башларга өметләнә...

Шушы хәбәрләрне барлап чыкканнан соң һәркем өчен байтак тараф ачыкланды сыман. Тик шулай да Ибраһим әмир үз фикерен белдерергә ашыкмады әле. Әүвәл ул Сал-Салга төбәлеп сорау бирде.

—Һәммә сүзне энәсеннән җебенә тикле тынлап утырдың. Ни әйтерсең, сәрдәр?

—Бер зур кимчелек бар,—дип егет сәер сүзләр белән авыз ачкач, ашауларын ташлап, барчасы да ана текәлделәр. Сал-Сал бала йоннарын да селкетми дәвам итте.

—Сезнең арада, менә, олугбәкләр бар, морзалар, сәүдәгәрләр бар, хәрби сыбайлар юк. Әгәр Болгардагы барча гаскәр Тимер-Мөэминне яклап чыга икән, пайтәхетнең имән диварларын да, ханның таш кирмәнен дә безләге көч белән генә яулап булмаячак. Гади халыкның урамнар буенча коры кулын болгап, бугазын ярып йөрүеннән безгә файда килми.

—Ә син ни пычагыма сәрдәр булып йөрисен?.. Гади халык та көч!—дип кунакларның бер-икесе ризасызлык күрсәтә башлаган иде, хужа кеше кул күтәреп кенә тиз туктатты.

—Шартың, киңәшең нинди? Син кунакларга шуларын да җиткер.

—Хан чирүендәге меңбашларны, йөзбашларны, бигрәк тә курсыбайдагы түрәләрне үзебезнең якка аударырга кирәк. Кайбер сыбайлар белән башта ук сүз куешу да артык булмас иде.

Сал-Сал шул рәвешчә Болгардагы хәрби түрәләрне Янкалага китереп күрештерү хакында киная ташлап алгач, Ибраһим әмир дә йөзен ачып салды.

—Әзерлексез-нисез көе кайтып үз илемдә кан коясым килми. Башка калалар мине колач җәеп каршыларга әзер, анысын күреп торам. Иллә мәгәр, менә, сезнең арагызда пайтәхетнең үзеннән бер генә вәкил дә юк. Аеруча яна сәет булып алган Әшрәф хәзрәт безне яклый микән, мин аны

да белмим. Сал-Сал сәрдәр хаклы. Болгар диварлары эргәсенә кайта-нитә калсак, капка ачып безне каршыларга әзер торучы сыбайлар да күренмиләр әле. Борча белән кандаланы гына ут капкандай ашыга-кабалана куалар ул. Артка ут капмаган, без ашыкмыйк...

Кунакларның кайсыберләре, йөзләрен чытып, табынны ташлап китте. Үпкә-зарлары, рәнҗүләре яңгырап ишетелде.

—Йөз фәрсах юл үттек, бер ай буе килдек, ә ул безне битебезгә төкереп озатмакчы. И-и-и, игелексез бүкән!

Олугбәк Шуран гына тузынмады, ләкин үзенең шарт-кинәшен барыбер ирештерде.

—Син бездән генә таләп итеп ятма. Тәхеткә әзергә-бәзер кайтып керергә кем дә оста. Әнә, Сура аръягында бәҗәнәк, угыз, кыпчак көтүләре утлап йөри. Хуҗалары ерак түгел, димәк. Шулар аша бәҗәнәк, угыз ханнары белән солых төзесәң йә аларның алайларын ялласаң да була. Ачуым килмәгәе, шуларның кызларын дүртенче-бишенче хатының итеп ал, мәгәр ханнарын үз ягына аудар. Сиңа бот күтәреп яту аеры килешеп бетмәс...

Сәйяхларны төн кунарга озаткач, Ибраһим әмир Сал-Салны читкә чакырып дәште.

—Син, чыннан да, Болгардагы сыбайлар монда килер, дип өмет итәсеңме? Әллә... әллә төнлә Ана сөте чишмәсен сакларга сәбәпме бу?

—Чишмәнең катнашы юк,—дип көлемсерәп җавап кайтарырга мәҗбүр булды Сал-Сал.—Ә сыбайларга килсәк, алар белән сүз беркетү хәер. Болгар диварлары каршына барып җинелсәк, йә син үзең, йә Тимер-Мөэмин мине дарга асасыз бит. Аннан соң ул чишмәләр миңа нигә кирәк?

Ибраһим канәгать көлә-көлә сараена таба китеп барды...

Болгар иленнән яңа олы кәрван ярты елдан соң гына килеп җитте. Ләкин бу юлы аны инде йөзәрләгән җайдак озатып йөри, илчеләр төркеме сәет Әшрәфнең үзеннән, курсыбайдагы ике йөзбаштан, Болгардагы кәрвансарай түрәләреннән хасил иде. Кочаклашып күрешкәннән соң барысы исеменнән сәет Әшрәф кенә гозер сүзен әйтте.

—Түземлек мичкәләребез коргаксыды. Болгар сине көтә. Иленә кайтырга вакыт, Ибраһим... хан...

Өч көн үтүгә юлга кузгалдылар. Яугирләр, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, Кызылком сәхрәләре артыннан монда килеп юлыккан дала җайдаклары, әллә каян гына хасил булган җыен сукбай, иң азакта туктаусыз мөгрәп йә бәэлдәп ияргән мал көтүе—барча җан иясе кала капкаларыннан озын дәрья булып сузыла-сузыла чыкты. Дивар-манаралар өстендә санаулы гына сугышчылар, үзләре каккан тәүге казыкларын ташлап китәргә кызганган ташчылар белән балта осталары, хатын-кыз, бала-чага, карт-корылар гына күз яшьләрен сөртә-сөртә тезелешеп калды. Манара очлары күздән югала башлагач кына, Ибраһим кулын болгый-болгый саубуллашты.

—Хуш, бәхил бул, газиз Янкала!*

## 51

Сал-Сал “әй, юл үтү ул яу йөрү түгел, мәшәкате булмас”, дип бик һаваланып-кәпрәеп кенә сәфәр чыккан иде, ай-һай... Язгы ташкындай җәелгән кәрванның бер очыннан икенчесенә чаба-чаба, егет тузанга, тиргә батып бетте. Табын янына утырып, тын да алганы юк. Кәрван колын, бозау, бәрән китергән мал көтүе сыман тукталыш саен тулылана, ишәя, үсә бара. Әүвәл Ибраһим яллаган ике мең бәҗәнәк җайдагы

*1221 елдан соң ул рус халкы нигезләгән Нижний Новгород дип атала башлаячак. Мәгълүм ки, тарихны һәрчак җиңүчеләр яза.

килеп кушылган иде, хәзер көн-таң атса арлар, чирмешләр өстәлеп кенә тора. Әлбәттә инде, әмир шат, канәгать, әмма барча күрсәтмәләр, гаепләү-әрепләүләр Сал-Сал башына имән чикләвеге кебек явып кына тора.

—Чирмешләр кичә ач калганнар. Аларга тирмә кормагансын, казан асмагансын.

—Бәҗәнәк ирләрен иң койрыкка калдырмыйча булмас. Алар беркөн төнлә ар кызларын көчләп чыккан икән.

—Ашлы каласына житәргә ара күп калмады, иравыл йөзләрен көчәйтергә кирәк...

Сал-Сал, кылны кырыкка ярырдай булып, әрле-бирле чаба. Айзирәк утырган бөркәвечле арба янына тукталып, сөйгәненә җылы сүз кушарга, тал бөреседәй йомшак кулларын сыйпап бушанырга бер ара юк. Өстәвенә, табигать тә ук-җәясен нәкъ ана каршы корып куйган сыман.

Жиһанга җәй сулышы якынлашып килә, ә язнын чигенергә исәбе юк шикелле, мәхлук кәҗә төсле һаман киреләнә. Әмма анын буыннары камырланган, сыегайган инде. Күк йөзе хәзер ятим бала кебек еларга гына тора. Әле адашып килеп чыккан бер болыт пыскак янгыры белән үкчәгә тибеп ала, әле сыргак буран юлчыларнын янакларын көнче хатын сыман чәбәкли. Чокыр-ерымнарда, уйсулыкта кымшанмыйча яткан кар катламы ярлы кеше юрганы кебек һаман сәрпәләнә, һаман ертыла бара. Калдык кар астыннан килеп чыккан барча агач-куак, койма-читән күкрәк тутырып сулыш алган сыман бер карышка үсеп, биегәеп куя. Якын-тирәдәге елга-инешләрдә боз катламнарынын сырхау карт-коры шикелле уфылдап йә сукранып ыңгырашкан авазы ишетелгәли.

Аяк асты сагыз кебек баткак. Олы кәрван гармун күреге шикелле әле сузыла, әле жыерыла. Баш астына бет-борчалы ястык салганнармыни, Ибраһимнын бөтенләй йокысы качты. Ул Сал-Сал янына әйләнә дә килә, әйләнә дә килә. Жайлап-майлап сөйләшүне белми, теле әрем суыдай әче.

—Итәк-чабуларны жыярга иде бит, Сал-Сал сәрдәр. Һәр көн—жан бәһасе. Болай урык-сурык килеп барсак, сарык көтүе төсле таралып бетү дә ерак йөрмәс. Аннан кил дә чүке...

Аеруча тау төшүләр жыкны, сүлне ала. Арбаларнын барча тәгәрмәчләрен әле тау очында ук бәйләп куйган булалар, ә түбәнгә таба төшә башладынмы, алар боз өстенә куып кертксн сыер сыман тайгаклый да йә якындагы бер ерым эченә мәтәлә, йә алдагы олау өстенә барып менә. Һәр олауны мен газаплар белән янә юлга сөйрәп чыгаралар, вакыт әрәм була.

Әле ярый, арада жор телле шаяннар, борын салындыра белмәс тапкырлар бар. Ямантау дигән сәер кушаматлы гажәп текә үр өстенә житкәч, юл йөреп шомарган карт сәүдәгәр гыйбрәтле бер хикәят бәян итте.

—Әнә, күрәсезме, тау астында элек бер авыл бар иде,—дип, түбән таба бармак төртә-төртә башлап жибәрде ул.

Тау башына жыелышкан ирләр аста янган бүрәнәләр, күмер өемнәре күреп шаккаттылар. Карт сәүдәгәр янә дәвам итте.

—Жыелыштык та, без яндырдык аны. Түзәр әмәлебез бетте чөнки. Ни хәл итик? Ничә генә олау мал төяп килмик, бөртегенә хәтле талап шәрә калдыралар. Ничек итеп, дисезме? Болар оста! Шушы тау башында ел әйләнәсенә ике-өч ирләре каравылда тора. Мал төягән олау чылбыры килеп чыкты исә, юхалана-юхалана ярдәмгә ташланалар. Берсе алдан ук әзерләп куйган бастырыкларны тартып чыгара да үрәчәләр арасына китереп тыга. Калганнары тәгәрмәчләргә аркан урашалар, йә өркүдән янга сикермәсен өчен ат күзенә каеш тырыс көйләп куя болар. Янып-көеп йөгерешкән мондый булышчыларны күреп, син, әлбәттә, сөенәсен инде...

Карт сәүдәгәр юлчыларны авызына каратып тоткан арада тау башына

дистәләгән яңа олаулар килеп туктады, күпләре кузладан төшеп сүгенә башладылар. Ләкин салмак хикәят тавышын ишетеп алуга, колак сагайтып, һәммәсе дә тынды.

—...Боларның ыргак яисә кармак сымак эләктереп ала торган хәйләләре шунда, бөтен эшне бетергәч дилбегәне олаучының үз кулына тоттырып куя теге соран йөзләр. Аннары атыңның сыртына чыбыркы белән ике-өч тапкыр сыдырып алалар да, әйдә, әллү-ү-үр аска! Күз бәбәкләре акайган атыңны тыюлап, түбән таба атлый-сикерә йөгерәсең инде. Дилбегәләрең кулда, күзең атта. Бөтен кайгың—атың гына әрәм була күрмәсен дә, атың өркеп читкә сикермәсен. Ир канаты—ат канаты, ансыз калсаң, беттең...

—Йә-йә, ә аннары, ә аннары,—дип, бер-берсенең өстенә өелешеп, юлчылар карт сәүдәгәрне тыкырдатырга ук тотындылар. Ә тегесе үз жаена тезде.

—...Ә теге эт жаннар ул арада арткы яклап синең олау өстенә сикереп менә. Арба төбендә ни бар, ни табалар, барысын да читкә очыралар. Хәтта бау аламасы да, иске, тишек кәвешең дә калмый. Үр астына төшеп егылгач арбаңа әйләнеп карасаң, бозау ялагандай тап-такыр, салам төге дә юк. Син, бичара, жан ачысы белән ыргылып, тау өстенә йөгерергә мәжбүр. Иллә мәгәр, фи-и-ю-уйт, анда төшеп калган малкайларыңнан да жилләр искән...

—Бәреп үтерәсе калган ул караклар көтүен, ботарлыйсы калган!—дип ярсуын чыгарып түгәргә ашыкты тынлап торган ирләр.

Карт сәүдәгәр нәкъ үзенчә итеп, ашыкмый очлап куйды.

—...Бәреп үтерергә... тоттырмый шул алар. Бар байлыкны җыеп алалар да җен алгандай шундук юк булалар. Шуңа күрә без бүтәнчә хәл кылдык. Елан оясы корысын, юкка чыксын дип, менә шушы авылларын төрле яктан ут төртеп көлгә калдырдык без. Лягънәт төшкән бу урынны башка юлчылар да онытмасын өчен, әнә, без әле тау башына ике янган казык та утыртып, көйләп куйдык.

Тау очында, чыннан да, күмерләнгән ике казык күргәч, юлчылар үз олаулары янына ашыктылар. Әйтерсең лә, һәркем әлеге урындагы яман данның үз чабуына ябышуыннан чиркана, шүрли иде...

Бара-бара, мондый гыйбрәтле, сәер риваятьләрнең тагын берсен Сал-Салга әле сөйгәне Айзирәк авызыннан да ишетергә, тынларга туры килде.

Кәрван Идел яры буйлап төшә-төшә Ашлы каласына житеп килә иде инде. Көн чалт-аяз. Олаулар чылбырындагы ат пошкырулар, арба шыгырдаулар, жайдакларның умарта күче сыман гөжелдәп сөйләшкән авазлары—барысы да Сал-Сал өчен йокы мендәредәй таныш иде. Мондый хәвефсез минутларның кадерен белеп калырга ашыгып, ул кача-поса гына Айзирәк янына килеп житте. Ә тегесе, иркәләнергә-көйләтергә жай табылгач, шундук иреннәрен бүлтәйтеп каршылады.

—Аякка кырмыска көтүе төштемени, кымшана да алмыйм. Дала буйлап уратып та кайтмыйсың бит, ичмаса.

—Беткән баш беткән. Әйдә соң, алайса,—диде дә, Сал-Сал Айзирәкне үзенең ияренә утыртып, читкә алып китте.

Исеме дә билгесез инеш ярында чалма рәвешендәге түм-түгәрәк, биек йомрытау янына житкәч, Айзирәк сагышлы, боек тавыш белән эндәшеп туктатты аны.

—Әйдә, иярдән төшик тә тизләник без бу тау каршына. Башны иеп аңа сәлам бирик. "Бәхетсез яр тавы", дип олылыйлар аны кайберәүләр. Икенчеләр "Ялгыз балдак", диләр. Икесе дә урынлы, икесе дә дөрес... Әнә, күрәсеңме, тауның билен саргылт ком ураган. Сөйгән ярлар бер-берсенең бармакларына кидерергә өлгермәгән алтын балдак бит ул. Кавыша

алмаган бәхетсезләр балдагы. Андый бәла-казалардан аралый күр безне, йә, Ходаем!

Сал-Сал тирә-якта җәйрәп яткан тип-тигез дала уртасында олы печән кибәне шикелле калкып торган япа-ялгыз тауга текәлде дә әсәренеп, житдиләнеп калды. Йомрытауның нәкъ урта бер төшен һәрьяктан да янгыр, жил ашаган. Яшел үләннәрсез калган буынтыкта гәрәбәдәй сап-сары төстәге ком катламы ачылып тора. Тау—биленә алтын кушак йә булмаса алтын бөжра киеп баскан кебек. Ялгыз тауны алтын балдак кигән ялгыз, бәхетсез яр белән чагыштыру, и-и, бу чаклы да туры килер, дөрес булыр икән!..

Айзирәк элеккечә монсу тавыш белән тезеп китте.

—Менә шушы инеш буендагы бер авылда Гөлйөзем атлы бик тә сылу бер кыз яшәгән, ди. Бик күп егетләр гашыйк булган аңа. Күрше авыллардан килеп тә кабат-кабат кулын сораганнар. Ә ул беркемне дә үзенә якын жибәрмәгән, бер яучыны да кабул итмәгән, ди. Чөнки боларның авылында Зиннәт атлы егет булган икән. Алар сабый чактан ук бергә уйнап үскәннәр, тора-бара бер-берсенә үлеп-үлеп гашыйк булганнар. Берзаманны болар инде өйләнешергә вәгъдәләр беркетеп, үзара балдаклар да алмашып өлгергәннәр. Ләкин Гөлйөзем болай итеп кисәткән ди үз егетен. "Гади балдак кына түгел, йөрәк ачкычым бу. Сансызлама, югалтасы булма. Әгәр бүтән егет күтәреп килә икән, улчагында йөрәгемне аңа ачачакмын". Зиннәт моңа игътибар итеп тә маташмаган, балдакны шундук атсыз бармагына киеп куйган. Шулай да, башка егетләр көнләшеп сорашканда Зиннәт балдак хуҗасының исемен әйтми икән. Тик барыбер белгәннәр, аңлаганнар инде. Шуннан болар әлеге балдакны кулга төшерергә дип мәкерле уй корганнар...

Сал-Сал батыр җәя кереше кебек киерелде. Хәзер ул инде тын алырга да куркып тынлый иде.

—...Теге көндәш егетләр бәхетеннән жиде кат болытлар өстендә йөзгән Зиннәтне үзләре белән ауга чакырганнар. Урманга баргач егетне аю чокырына сугып төшергәннәр. "Күрше аланнарда, күрше урманнарда синең туганнарың, балаларың бардыр, алар янына ашык. Мине дә авылда сөйгән ярым көтә. Мин кайтмасам, ул нык сагыныр, елар. Ашама, тимә миңа, жибәр, аюкаем?"—дип күз яшьләре белән ялварган, ди Зиннәт. Аю ашамаган. Ләкин егет чокыр өстенә менгәч, көнче юлдашлары суеп үтергәннәр. Балдагын бармагыннан салдырып алганнар да Гөлйөзем янына кайтып кергән болар. "Син: кем балдакны кире алып килә, мин шуңа гына кияүгә чыгачакмын",—дип вәгъдә биргән идең, йә, сүзеңне үтә, беребезне сайла, дип өстенә басып талымлыйлар икән. Гөлйөзем боларның сүзенә, әлбәттә, ышанмаган. Шулвакытны боларның авылына аю килеп кергән. Ул Зиннәтне биленә салып алып кайткан икән. Егетне Гөлйөзем каршына төшереп калдырган да кире борылып киткән. Җинаятьләре фаш булгач, җәза алудан куркып, катил жаннар авылдан чыгып качкан. Ә Гөлйөзем Зиннәтне күтәргән дә менә шушы урынга китереп жиргә индергән, ди. Өстенә бәләкәй генә тауҗык өеп куйган. Шуның очына хуҗасыз калган балдакны кидергән. Ә үзе кияүгә чыкмаган, көн-таң атса, шушы кабер янына килеп, кан-яшь түгә икән. Гөлйөземнең ачы яшьләренә чыланып үсеп чыккан тау бу. "Бәхетсез яр" тавы, "Алтын балдак" тавы...

Сал-Сал әлеге ялгыз тау янынннан газиз әнекәшен жирләп калдыргандай коч-хәл белән генә атлап китте. Ә Айзирәк авызыннан мондый бәхетсез ярлар хакындагы хикәятләрне тагын-тагын ишетәсе калган икән әле.

*Ахыры киләсе санда.*



## Фирая Зыятдинова

# ИҢ ЗУР СӨЮ

### Шундый дөнья...

Бик гади ул Тормыш фәлсәфәсе:
Нәрсә бирсәң, шуны аласың.
Ут бирәсең килеп кешеләргә,
Яналасың икән—янасың...

Яналмыйсың икән—үзең кара:
Мәҗбүр итми беркем янарга.
Ә кем белә, тиештер син, бәлки,
Ташкын елга булып агарга.

Бар чүп-чарны тиештер син, бәлки,
Үзең белән алып китәргә.
Тирә-юньгә Яшәү бирер өчен
Ком чүлләрен бакча итәргә...

Дөнья—төрле, кешеләр дә төрле:
Кемгә язган мәңге янарга,
Ә кемгәдер—ут сүндерер ташкын—
Ярсу елга булып агарга...

### Иң зур җиңү

Мәшәкатьле дөнья ваклыклары
Баштан ашып китә.
Үзе белән сөйрәп төшмәк була
Әллә кая—төпкә...

Бар көчеңә кайчак тырмашасың,
Өскә чыкмак булып.
Көчең бетсә, шундый ачу килә,
Күңел китә тулып...

Иң зур сөю—вак-төяге белән
Җирне сөюдер ул...
Күңелеңне—үз-үзеңне җиңү—
Иң зур җиңүдер ул.

Фирая ЗЫЯТДИНОВА – *шагыйрә; "Матур буласым килә", "Язгы ярсу", "Ташу" h.б. китаплар, популяр җырлар авторы. Казанда яши.*

***

Су болгану гаҗәпмени,—
Заманалар болгансын да...
Үз-үзеңне табу кыен
Мондый мәхшәр арасында.

Дөрләп янган тәмут бу җир:
Янасын да, каласын да
Белми Кеше, бәргәләнә
Меңләгән ут арасында...

## Хәтер

Уйлар үзе яхшылыкта,
Тик ялгышлар булып тора.
Хәтер—хәтәр: оныттырмый,
Кәефне гел кырып тора.

Ялгышларны саный-саный,
Яңаларын кылып торам.
Хәтер—шул ук: оныттырмый,
Кәефне гел кырып тора:

"Акыллы бул икенче!"—дип,
Колакны гел борып тора...

## Соңгы яфрак

Яшим диеп күпме тартышса да
Соңгы яфрагы да өзелеп төште:
Сары җилләр сарылып, юаткандай,
Каен кызын иңнәреннән кочты...

Җил-давылда әгәр аумый калса,
Җан иңәр ул каен йөрәгенә;
Өмет тулы җырлы язлар килер,
Яшел җилләр сарылыр иңнәренә.

Бар да кайтыр, бар да кабатланыр—
Шулай булачагын беләм ич мин.
Ник соң сагыш бәргәләнә җанда—
Өзелеп төшкән соңгы яфрак төсле?!

***

Көн белән төн чиратлашып тора,
Яхшы-яман белән дөнья тулган:
Яхшысын да, яманын да татып,
Берәм-берәм кешеләр дөнья куйган.

Мәхәббәт һәм нәфрәт ялкыннары...—
Кеше йөрәгенә бар да сыйган.
Җир йөзендә бары бер нәрсәгә—
Ялгызлыкка күнегеп булмый сыман.

***Редакциядән:***
*Сентябрь—шагыйрәнең (ул 1945 елда туган) юбилей ае. Каләмдәшебезне ихлас күңелдән котлыйбыз, аңа сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары теләп калабыз.*



# Гөлзадә Бәйрәмова

## БЕЗГӘ ЯЗГАН ҺАМАН САГЫНЫРГА...

### Һәйкәл салам

**Мин рәссам түгел,**
**Ә шулай да**
**Килә минем сурәт уясым.**
**Балачакның гүзәл мизгеленә**
**Күңелемдә һәйкәл куясым.**
**Күзге муллык. Ашлык тараткандыз**
**Көшел-көшел, чирәм өстенә.**
**Чүп-чарыннан аны аралыйбыз,**
**Мондый эшләр безгә төс кенә.**
**Яны белән әни җилгә баскан**
**Ашлык тулы чиләк кулында,**
**Шатлык нуры балкый йөзләрендә,**
**Уйлый булыр безнең турыда...**
**Мич каршында әни бөтерелә**
**Табагачын тотып кулына.**
**Кайсы кала, кайсы китә бүген,**
**Өлгертергә кирәк, юлына...**
**Кичке якта кулына орчык алып**
**Утырыр ул каба янына.**
**Ул эрләгән җепләр озынлыгы**
**Җитәр иде,**
**Галәмнәрне урап алырга!**
**...Күз алдымда тора моңсу йөзе—**
**Озатканда капка төбендә.**
**Мин рәссам түгел,**
**Шулай да Аңа**
**Һәйкәл салам күңелем түрендә.**

### Бер дуска

**Шомландырып күңелләрне**
**"Их, дөньясы!"—димә әле.**
**Туар көннәр бүгенгедән**
**Мең мәртәбә булыр ямьле.**

---

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА — *журналист; шигырьләре һәм мәкаләләре вакытлы матбугатта даими басылып килә. Казанда яши.*

Ябылсалар синең алда,
Ишекләрнең—ач башкасын.
Бәхет бит ул шундый серле
Әйтми кайдан башланасын.

Уфтанма син, юкка-барга
Күңелендә ялкын барда.
Хак Тәгалә безне аклар,
Сөю хаккын хаклаганга.

## Уйлану

Җырлар язмам сиңа бүтән,
Күңелем белән синнән китәм.
Сурәтең дә акрын-акрын
Тоныклана бара икән.

Күзәтмәмен хәтта читтән:
Капкаларны ябып китәм.
Бәхет диган аланлыкка
Илтер юллар аерым икән.

Очрашудан мәгънә чыкмас,
Сүз башласак—сүзләр үтмәс.
Хисләр сүнгән, кабынырга
Хәзер инде көчебез җитмәс,
Йөрәкләр дә ярсып типмәс.

Еллар үткәч очрый калсаң
Узарсың син танымыйча:
"Улмы соң бу? Әллә түгел,
Бөкерәйгән бер карчык ич,
Эндәшмәсәң яхшы түгел."

Мин уйлармын: "Исән микән,
Ничек көннәр кичә икән?
Гомерләре әле һаман,
Бәхет эзләп үтә микән?"

Картлык безне көтә алда,
Һәм ялгызлык каршы ала,
Гомер кичкән парларны да,
Аерым-аерым гүргә сала.

## Гаҗәпләнмә...

Көнләшәсең бер дә юкка,
Күңелем бит чуар түгел.
Синең белән узган еллар
Хиссез узган еллар түгел.

Ишетәсең килә булыр
Элеккечә назлы сүзләр.
Мин аларны җилгә түгел,
Хәзер инде җырга тезәм.

Гаҗәпләнмә моңсулансам,
Һич шикләнмә уйга батсам.
Сәбәбе дә гади кебек,
Яшәешнең үзе кебек,
Сабантуйлар көтми күңел,
Белмим никтер кызык түгел.

## Ялвару

"Үлмә!"—дип инәлеп ялвардым,
Бирәсем килмәде әҗәлгә.
Бәгырьдән өзелгән аваздан
Бар дөнья, әйтерсең, әйләнә.

Әйләнә өзелгән өметләр
Соң кабат төбәлгән күзләрдә.
Сөюнең бар көче шундадыр,
Әйтелми калынган сүзләрдә.

Инәлеп ялварган аваздан
Тетрәнде агачлар-кыялар.
Яшәргә ашкынган чагында
Азмы соң яшерен хыяллар!

"Үлмә!"—дип ялварып сорадым,—
Бәхетем—син, диеп уйладым.

***

—Исеңдәме?
—Исемдә...
Бар сөйләшү—тоташ истәлектән,
Очрашулар булган бер чакта.
Чыбык-чабык өстәп утыргандай,
Пыскып янган, сүнгән учакка.

***

*"Хатын-кызның җиде шәме булыр,*
*берсе янмаса—берсе янар."*

Халыктан

Җиде ятны ярлар иттек,
Җиде ятны үз иттек.
Җиде ятка җаннар аттык,
Җиде ятны яраттык.

Җиде төн урталарында,
Җиде шәм утларында
Башларыңны салма икән,
Җиде ят кочагына.

Җиде йолдыз—җидегән йолдыз
Җиде күк катларында,
Җиде ятлар юлдаш булса
Җиде юл чатларында,
Җиде яктан җилләр исәр
Җиде ят тарафына.

***

*Хатын-кыз мәхәббәт турында*
*гына яза диючеләргә.*

Сәясәтне, әйдә, ирләр язсын,
Алар сүзе күпкә акыллы.
Акыл белән хис янәшә түгел,
Безнең йөрәк хисле-ялкынлы.

Сәясәтне, әйдә, ирләр язсын,
Алар китә сугыш кырына.
Безгә язган һаман сагынырга,
Һәм янарга сагыш утында.

Сәясәтне, әйдә, ирләр язсын,
Без җырларбыз сөю турында.
...Илләр гаме—ирләр гаме булсын,
Ил тоткасы—ирләр кулында.

## Теләк

Сыенасым килә сиңа,
Җаныңа, тәнеңә, күңелеңә.
Яши алмам кебек идем синсез,
Әллә инде онытыласың,
Әллә инде күнегелә.
Тик шулай да,
Вакыт-вакыт
Сыенасым килә,
Азга гына.
Ярдәм эзләп тилмергәндә—
Терәгем итеп.
Хәлсез чакта таянырга—
Тирәгем итеп.
Ялгызлыктан моңсулансам—
Йөрәгем итеп.
Җылы эзләп тартылганда—
Учагым итеп.
Иркәләнер, назлар булган
Кочагым итеп,
Сыенасым килә сиңа,
Бик азга, азга гына.

*Туфан Миңнуллинга 70 яшь*



# Туфан Миңнуллин

# ТӘНЗИЛӘКӘЙ

МОНОСПЕКТАКЛЬ ӨЧЕН ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМАТИК ХИКӘЯ

**Катнашучы**:
Газинур—хикәяне сөйләүче.

## I кисәк

### 1. Исәнме, Тәнзиләкәй!

Бер бүлмәле фатир. Стеналарда Тәнзиләнең төрле яшьләрдәге портретлары. Бер портрет хәтта түшәмгә дә беркетелгән. Бүлмә уртасындагы мольбертта Тәнзиләнең язылып бетмәгән портреты. Караватта Газинур йоклап ята. Тәрәзәдән төшкән кояш нуры аны уята. Газинур торып тәрәзәгә бара. Кояш белән исәнләшә. Тиз генә урын-жирен жыештыра да, бер-ике гимнастика хәрәкәтләре ясап ала. Бүлмә буйлап йөреп, портретлар белән исәнләшә.

Газинур. Хәерле иртә, Тәнзиләкәй... Кәефләрең ничек, Тәнзиләкәй? *(Исәнләшеп йөргәндә кайбер "Тәнзилә"не үбеп тә ала.)* Исәнме-саумы, Тәнзиләкәй? Афәрин, барыгыз да исән-сау. Ачуланмагыз инде, Тәнзиләкәйләр, озаграк йокланган. Бүген ял көне, эшкә барасы юк. Бүген көне буе мин сезнең янда булачакмын. Бүген бит әле сезнең туган көнегез дә. Әнә кояш та ничек сәламли сезне *(түшәмгә карап)*. Нәрсә, мин синең белән исәнләшергә оныттыммы? *(Идәнгә чалкан ятып)*. Исәнме, Тәнзиләкәй. *(Торып)*. Ә хәзер, Тәнзиләкәйләр, миңа юынып алырга рөхсәт итегез. Сез ул арада иртәнге серенада тыңлый торыгыз. *(Магнитофонны кабыза, анда Газинур жырлый.)*

Тәнзиләкәй, тор инде,
Йокың туйгандыр инде,
Сандугачлар чык суларын
Эчә торгандыр инде.
Тәнзиләкәй, тор инде,
Йокың туйгандыр инде,
Матур кызлар чәй суына
Бара торгандыр инде.
Тәнзиләкәй, тор инде,
Газинурың син торганны
Көтеп торадыр инде.

*(Газинур юынып һәм бәйрәмчә киенеп чыга).* Йә, ничек, Тәнзиләкәйләрем, серенада ошадымы? Мин аны кичә генә, сезнең бүгенге туган көнегезгә атап яздым. Ишеткәнсездер, үзем жырладым. Мин инде, Тәнзиләкәй, синең кебек

итеп жырлый алмыйм. Син матур итеп жырлар идең. Син бит жырчылар арасында йолдыз булып кабынырга тиеш идең. Кабына алмадың шул. *(Мольберттагы портрет янына килеп).* Ә син нигә болай монайдың? Килешми. Бүген бит бәйрәм. Бүген бер көндә ике бәйрәм. Синең туган көнең һәм юбилей. Әйе, әйе, юбилей. Бүген бит мин синең ике йөзенче портретыңны ясап бетерәм. Туган көнең белән котлыйм, Тәнзиләкәй. Әлегә шулай дип кенә әйтәм. Ә бәйрәмен бүген кич бәйрәм итәрбез. Жырлар жырларбыз, гармун уйнарбыз, теләсәң биербез дә. Йә, йә, монайма. Ирең янында, балаларың янында. Менә бит мин бер ялгызым гына, алай да монаймыйм. Гафу ит, Тәнзиләкәй, ялгыз дип әйтеп ялгыштым. Нишләп ялгыз булыйм мин, әйеме, Син бит минем янымда. Менә әйт син, кемнең ике йөз Тәнзиләсе бар. Юбилей бүген. Ике йөзенче Тәнзилә монаерга тиеш түгел. *(Кулына буяулар белән пумаласын алып).* Йәле, елмаеп жибәр әле, дөнья яктырсын. Яктылык ул, Тәнзиләкәй, кояш яктысыннан гына тормый. Күңеле якты кешегә караңгы төн дә якты булып күренә. Хәтерлисеңме, без синең белән караңгы төндә икәү генә урманга барган идек. Шүрәле күрергә дип барган идек. Син үзең бит миңа бәйләндең, Шүрәлене күрсәт дидең. Шүрәле көндез күренми дигәч, төнлә алып бар дидең. Бардык, Шүрәле күренмәде. Тавышы гына ишетелде. Син курккып миңа сыендың. Курыкма, бу Шүрәле тавышы түгел, ябалак кына ыңгыраша дидем. Төн иде, дөм караңгы иде. Шул караңгыда мин синең күзләреңнән төсең күрдем. Дөм караңгыда урман сукмагында без адашмадык. Ә менә көпәкөндез адаштык. Йә, йә, моңайма. Менә шулай. Елмаю сиңа бик тә килешә. *(Мольберттан портретны алып).* Тәк, кайда булачак инде синең урының? Ике йөзенче булгач, түрдә торырга тиешсеңдер инде. *(Портретны элеп куя).* Менә шунда тор син миңа карап, ә мин сиңа карап торыйм. Кайдан да син миңа күренергә тиеш. *(Читкә китеп карый, идәнгә утырып, ятып карый).* Юк, Тәнзиләкәй, бүген син минем янәшәмдә бул инде. *(Портретны алып, сәхнә алдына алып килә).* Менә шушында синең урының. Ә мин синең янәшәңә утырам. Тәрәзәдән дөньяга карап утырыйк. Әнә шулай, елмаеп карап утыр. Тәрәзәдә сине күргәннәр нинди бәхетле хатын дип уйласыннар. Янында пары утыра дип миңа карасыннар. Мин дә аларга елмаермын. Күрәсеңме, Тәнзиләкәй, әнә сиңа охшаган бер кыз үтеп бара. Унжиде яшеңдә син нәкъ шундый идең. Хәзер бераз олыгайдың инде. Мин дә олыгайдым. Кырык яшь шактый инде ул, әйеме. Юк, юк, син элекке кебек үк чибәр. Тик менә чәчләреңә бәс куна башлаган. Чигә чәчләре ник алдан агара икән ул, Тәнзиләкәй? Әллә кешенең гомере шуннан башлана микән. Шулайдыр, әйеме? Кан тамырлары да шуннан үтә бит. Юк, син картаям дип хафаланма, берничә бөртек кенә алар. Ныклабрак карамасаң, күренмиләр дә әле алар. Мин аларны буяп та куя алам, әлбәттә. Ләкин, гафу ит, Тәнзиләкәй, мин бит художник, рәссам бит мин. Алдашырга ярамый миңа. Мин инде болай да алдашам. Юк, бүтәннәрне алдамыйм мин, үземне алдыйм. Сине оныттым дип үземне алдыйм. Онытa алмыйм бит мин сине, җанкисәккәем... Карале, Тәнзиләкәй, кемнәр үтеп бара. Әнә ич, култыклашканнар. Икесе дә авызларын ерганнар. Сәлам сезгә, ерык авызлар, киләчәктә дә көлеп яшәргә язсын. Ә сез нәрсәгә чыраегызны сыттыгыз? Нәрсә житми сезгә? Ә кемгә житә бу дөньяда? Кемнең әле миңа житте дип әйткәне бар? Исәнлегегезгә шөкер итегез. Менә безгә карагыз. Әллә безнең барысы да ал да гөлме? Икебез дә елмаябыз бит. Нәрсә, мин, Тәнзилә мине ташлап кияүгә чыкты дип, елап утырыйммы? Үзем ясатып бетермәгән иргә туры килдем дип, Тәнзилә жыласынмы? Менә утырабыз бит әле, елмаешып утырабыз, әйеме, Тәнзиләкәй. Әй син, нәрсә авызыңны ачып тәрәзәләр санап барасың? Монда утыра Тәнзилә апаң. Туган көнең котлы булсын, Тәнзилә апа, диген. Син аны ачуланма инде, Тәнзиләкәй, яшь бит әле. Безнең яшькә житкәч барысын да аңлар. Рөхсәтме, мин синең алдыңа ятып торыйм. Бүген мин сине тагын төштә күрдем. Менә шулай алдыңа ятканмын да күктәге йолдызларны санаймын икән. Шунда бер тавыш ишеттем. Син, Газинур, әллә кайдагы йолдызларны санама, яныңдагы йолдызга кара дип әйтә икән. Кем тавышы дип эзләп тапсам, айдагы Зөһрә кыз миңа эндәшә икән. Ул, син миңа карама, Тәнзиләгә кара, дия икән. Сиңа күтәрелеп карасам, син юк икән, Тәнзиләкәй. Нигә юрыйк икән бу төшне, Тәнзиләкәй? Әллә мин сине икенче тапкыр, мәңгелек-

кә югалтачакмын микән? Син төшләргә ышанма, ярыймы, Тәнзилә. Ташлап китә күрмә мине. Мин монысын күтәрә алмаячакмын. *(Торып утырып).* Сүз бирәсенме, Тәнзилә? Әйт инде бирәр сүз. Йә, нигә елмаеп китеп бардың. Елмайма, үтенеп сорыйм. *(Портретны борып куя).* Мин бит болай да эшли алам. Менә хәзер карап тор почмакка. *(Тәрәзәдән карап).* Ә сез нәрсә елмаясыз? Өзелеп сөйгән кешен ташлап китсен әле, елмаерсыз микән. Нәрсә безнең тәрәзә каршына килеп үбешәсез, әллә сезгә бүтән урын беткәнме? Китегез! Китегез диләр сезгә. Их, Тәнзиләкәй... Нигә син минем төшемә шулай булып кердең? Күпме мине сынарга була. Ю-у-ук, онытыр дип өметләнмә. *(Бүлмә буйлап йөренеп портретларга эндәшә)* Онытыр дип өметләнмә! *(Гармунын алып тартып-тартып уйный).* Онытыр дип өметләнмә!

Чуалган бер серле йомгак булып
Язмышыма кереп уралдың;
Язмышыма кереп уралдың да
Томаннарда эреп югалдың.

Үзәннәрдән эзләмәс дип,
Үзәннәрне буйлама,
Онытыр дип өметләнмә,
Онытыр дип уйлама.

Кыр казлары белән китеп бардың,
Кыр казлары белән кайтмадың.
Инде көтәм тәүге сөюемнең
Кайтавазлар булып кайтканын.

Эзләсә дә табалмас дип
Качыш-качыш уйнама;
Онытыр дип өметләнмә,
Онытыр дип уйлама.

Мин оныттым, оныт диеп
Җилдән хәбәр юллама,
Онытыр дип өметләнмә,
Онытыр дип уйлама.

Хәтерлисенме, Тәнзиләкәй? *(Тәнзилә портреты каршына барып).* Нәрсә, әллә миңа үпкәләденме? Ачуланма, Тәнзиләкәй. Әллә нишләдем әле мин. Кинәттән генә кызып китәм. Төш кенә бит ул. Югалтаммы соң мин сине! Бер кызык нәрсә сөйлим әле үзенә. Минем күргәзмәм булды бит әле. Синең бер портретыңны куйдым. Күргәзмәгә килүчеләр синең яныңнан китмиләр. Кемең бу дип, миннән сорыйлар. Язылган бит, мин әйтәм. Ә портрет астына "Неизвестная женщина" дип язылган. Ялганлыйсың, диләр. Бу ханым синең бик тә, бик тә известная диләр. Әйтмәдем. Әйткәч сөйлисе була. Менә шулай—неизвестная женщина син, Тәнзиләкәй. Ә бит дөресен генә әйткәндә, мин алдашмадым. Хатын-кыз бит һәрвакытта да неизвестная. Билгесез зат. Без бит синең белән үзебезне үзебез белә башлаганнан бирле бергә үстек. Унтугыз яшькә хәтле гел бергә булдык. Беләмме соң мин сине? Белмим ләбаса. Ярата дип йөрдем, ярата дип үзең дә әйтә идең, яратмагансың. Әйттең бит яратам дип. *(Стенада эленеп торган бер портрет янына килә).* Менә, ул шаһит. Сора аңардан, ул синең яшьлегең, унсигез яшьлек чагың. Кил әле янына, сора, яратам дип әйттеңме диген. *(Тәнзиләнең идәндәге портретын яшь чактагысы янына элеп куя).* Сора. Мине армиягә озатканда сине генә яратам дип ничә тапкыр кабатладың. Иртәгә китәм дигән көннең төнендә дә әйттең. Яратам дип хатлар яздың. *(Тумбочка тартмасыннан кәгазьләр күтәреп килә).* Менә, күр, бу синең хатларың. Кара, бер дәфтәр битендә бары бер генә сүз—яратам. Йөз тапкыр язылган. Менә монысын укы. Җыр да җыр, җыр да җыр. Барысы да мәхәббәт турында. Кулыңнан тотып яздырмадым бит. Юк, син уйлама, мин сиңа үпкәләп, ачу саклап әйтмим бу сүзләрне. "Неизвестная женщина" дип дөресен язганымны гына әйтәм. Мактадылар сине. Бирәү сатып алырга да сораган иде. Сүгеп ташладым үзен. Аптырап карап тора. Гафу үтендем. Онытылып киткәнмен. Үзең уйлап кара, ничек инде мин сине сатыйм ди. Ул бит җаныңны сату белән бер. Бу фатирда, Тәнзиләкәй, бөтен нәрсә дә сатыла. Тәнзиләкәйләр һәм гармун гына сатылмый. Беләсенме, Тәнзиләкәй, минем турыда әллә нинди гайбәтләр сөйлиләр. Мин бит фатирыма бирәүне дә кертмим. Дусларым белән дә остаханәдә генә очрашам. Остаханәдә синең бер портретың да юк. "Неизвестная женщина" гына анда. Чөнки аны инде күрделәр. Аңа ятлар күзе төште, шуңа күрә ул инде син түгел. "Билгесез хатын" булып калсын. Монда барысы да син. Карале, бусы да син бит *(Тәнзиләнең балачак рәсемен алып баш очына күтәрә).* Син бу, Тәнзиләкәй, син!

## 2. Сабый чак

Һай, мин ашыгам бугай, Тәнзиләкәй. Адәм баласының бала чагына хәтле сабый чагы була. Нарасый чагы. Кешенең иң бәхетле чагы. Дөньяны, үзен-үзе аңламаган чагы. Дөньяны, үз-үзен күбрәк аңлаган саен аның бәхете кими бара, кими бара. Мин инде беләсең, синең сабый чагыңны хәтерләмим, чөнки үзем дә сабый булганмын. Мин бит синнән бер генә көн алдан туганмын. Синең туган көнең бүген булса, минеке кичә иде. Икебез дә таң алдыннан туганбыз. Сабый чагыңны күрмәсәм дә синең ул чактагы портретыңны ясадым мин. Менә ул. *(Портретны яңа ясап бетергән портрет янына алып килә).* Менә, күр. Танымыйсыңмы? Мин анда юк дисеңме? Ә Син игътибар белән кара. Күрәсеңме, ап-ак томаннар эчендә синең күзләр. Күзләр дә түгелдер әле, күзләреңнең карашыдыр. Ап-ак томаннар аша дөньяга карыйсың. Ә дөнья шундый матур. Ап-ак дөнья! Әни әйтә иде миңа, кышның башында, ак томаннар агачларга бәс булып кунган көндә тудың дия иде. Күрше өйдә икенче көнне син дөньяга аваз салгансың. Ә ике шатлык рәттән туры килгән. Минем әнием без туган көннәрдә миңа атап бишек җыры чыгарган, аннары аны синең әниең дә җырлаган. Тавышы бик моңлы иде әниеңнең. Минем әниемнең дә күңеле тулы моң иде. Күңеле моңлы булган өчен әти нигәдер ачулана иде. Үзең җирдә, күңелең күктә, җиргә төш, дия иде. Юк, әнием җиргә төшә алмады. Җаны күккә ашты. Әниеңә охшагансың, дип әти мине дә ачулана. Минем өйләнми йөрүемне дә әлләниләргә юрый. Ул аңламый, Тәнзиләкәй, минем мәхәббәтемнең моңлы фаҗигасен аңлый алмый. Ул гына түгел, күпләр аңламый минем мәхәббәтемне, син дә аңламадың, шулайдыр инде, җирдә атлап йөрер өчен туган кешенең күктә кош булып очып йөрүе аңлашылмыйдыр. Мәхәббәтнең ни икәнен аңлатып булса, кешеләр бик тә бәхетсез булыр иде, тормыш, яшәү дә кызыксыз булыр иде. Аңлашылган нәрсә, ачылган сер кызыксыз була бит ул, Тәнзиләкәй. Гафу ит, Тәнзиләкәй, мин сиңа әниләребез җырлаган бишек җырын тыңлатмакчы идем. Ишетәсеңме? Әнә ул җыр безгә якынлаша. Әнә, әнә, ишетәсеңме? *("Тәнзилә" белән "Бишек җыры"н тыңлыйлар. "Бишек җырын" Газинур үзе дәвам итә. Кулында "Сабый чак" портреты).*

Ап-ак кына биләвең,
Ап-ак теләк теләдем:
Актан да ак теләгем—
Сиңа тәүге бүләгем.
Әлли-бәлли бәү генәм,
Бердән-бер берәү генәм.

Багып туймас баламдыр,
Сулап туймас һавамдыр,
Җаннарыма дәвадыр.
Балам—йөрәк пәрәмдыр.
Йокла, балам, бал гынам,
Гөлем белән ал гынам.

Кояшымдыр, аемдыр,
Ай-һаемдыр, ваемдыр,
Шатлыгымдыр, кайгымдыр—
Сулыш алган саендыр.
Тәнзиләм, Тәнзиләкәй,
Тәнзиләкәй, Тәнзиләкәй, Тәнзиләкәй.

Әйе, әти мине ачуланма, бу җирнең кешесе түгел син ди. Инде кырыкка җиттең, акыл һаман да керми ди. Нишлим соң, Тәнзиләкәй, шул бишек җырын тыңлап үскән бала җиргә төшә алмый интегәдер. Хәер, син дә аны тыңлап үстең, ләкин җирдән күтәрелә алмадың. Юк, юк, мин сине гаепләмим. Аллам сакласын. Әгәр дә бөтен кешеләрнең дә җаны күктә очып йөрсә, алар кеше дип аталмаслар иде. Алар фәрештәләр булыр иде. Җиргә җирне сөреп иген үстерүче дә, мал багучы да, сәүдә итеп акча табучы да кирәк. Синең дә ирең булган, унган кеше. Сине дә затлы машиналарда гына йөртәләр. Балаларыгыз бәхетле. Миңа чыксаң, нишләр идең. Тиләләр бит алар әкият итеп сөйләгәндә генә кызыклар: яшәгән ди, булган ди…

Яшәгән ди, булган ди бер тиле малай
Йөргән ди күккә карап шалай да валай.
Күктән йолдыз чүпләп куйган да ди өеп,
Аннан уйнаган ди шуларны күккә чөеп…
Ай нурыннан баскыч ясап күккә менгән ди,
Ак томаннарга уралган җирне күргән ди.
Кояшка да үрелгән ул—кулы пешкән ди,
Кулы пешкән малай җиргә егылып төшкән ди.

Шулай, Тәнзиләкәй. Ә син беләсең-

ме, үз телелегеңне аңлаудан да авыррак нәрсә юктыр. Теле икәнлегеңне дә беләсең, акыллы булырга да тырышасың, ләкин... Син миңе гафу ит инде, миңа акыл кермәстер ахры, кырыкка хәтле кермәгән акыл, кырыктан соң чыга башлый ди. Шуны бел, Тәнзиләкәй, синең сабый чагың, ак томаннар эчендәге күз карашың миндә генә бар. Бары тик миндә генә, берәүдә дә юк. Балачагыңның хатирәләре дә миндә генә. Син аларны оныттың инде. Бүгенге белән генә яшәгән кеше киләчәкне дә күз алдына китерми, үткәннәрне дә оныта. Телисеңме, балачагыңны исеңә төшерәм. Юк, син тыңла, тыңла. Миңә, танмйсыңмы үзеңне. Бу син: минем хәтеремә мәңгегә уелып калган синең сурәтең. Юк, ялгыштым, сурәт түгел. Мин сурәт ясамыйм. Сурәт ул җансыз була. Мин сине җансыз итеп күрергә теләмим. Әнә бит син нинди! Хәтерлисеңме? Бу синең бала чагың.

## 3. Балачак

Син онытканасыңдыр да инде, мин оныта алмыйм. Хәтерлимсең, икәүләшеп авылдан чыгып киткән идек. Безгә әле сигез генә яшьләр булгандыр. Әрәмәлеккә сандугач күрергә бардык. Сайраулары бигрәк матур, үзе нинди икән дидек. Син шунда адаштың. Әллә мин адаштым микән? Мин сине эзләдем. Озак эзләдем. Жылый-жылый эзләдем. *(Тәнзиләне эзли).* Тәнзиләү! Тәнзиләү-ү! Син кайда-у?! Тәнзиләү-ү! *(Утырып жылый, үзе бертуктаусыз Тәнзилә дип кабатлый. Торып портретлар арасыннан эзли һәм, ниһаять, табып ала. Сигез яшьлек "Тәнзилә" аңа елмаеп карап тора).* Тәнзилә! Кая киттең соң син? Сине эзләп мин үлә яздым. Әйе, мин жыладым, ә син көлдең генә. Курка белми идең шул син. Юк, мин дә адашып югалудан курыкмадым. Сине югалтудан курыктым. Син инде бик нык үзгәрдең, Тәнзилә. Челтерәтеп көлүең генә үзгәрмәде. Бүтән мин сине янымнан җибәрмәдем. Кулга кул тотышып сандугач оясын бергә эзләдек. Бер оя таптык, тик аның сандугачы юк иде. Сандугачның оясына кайтканын көтеп озак утырдык. Сандугач күренмәгәч, мин үзем сандугач булып сайрадым. *(Сандугач булып сайрый).* Аннан син миңа кушылдың. Икәүләп сайрадык. Сандугачның анасы сайрамый, атасы гына сайрый диләр. Без ул чакта аны белми идек шул әле. Сайрап туйгач, кайтырга чыктык. Шунда синең аяк табаныңа шырпы кадалды. Яланаяклы кызый һәм яланаяклы малай идек без. Тырнак белән ала алмагач мин аны тешем белән суырып алдым. Күпләр хатын-кызга мәхәббәт аңлатканда аяк астында туфрак булыр идем диләр. Ә мин синең табаныңны ялаган кеше, Тәнзилә. Әрәмәлектә йөреп каралып беткән табаныңны ялаган кеше. Син аларны онытканасыңдыр инде. Ул чакта кытыклама дип көлгән идең. Әйе, әйе, авырта димәдең, кытыклама дидең. Без анда үбешкән тә әле. Син әйттең, үбешәбез дип. Ничек үбешергә дә өйрәттең. Апаңның Хәлим абый белән үбешкәнен карап торгансың. Бу безнең беренче үбешүебез иде. Мин аның тәмен татымадым, син дә татымагансыңдыр, шуңа күрә ул көнне бүтән үбешмәгәнбездер. Шунда әле без кузгалак дип ниндидер агулы үлән ашаганбыз. Икебез дә агуланып авырып яттык. Син алдан терелдең. Минем янга кердең дә "Син үләсеңмени?" дип сорадың. Үлемнең ни нәрсә икәнен белми идек әле без. Безнең бергә йөргәнне күргән әниләр синә килен дип, миңа кияү дип дәшәләр иде. Бу сүзләр безгә ошый иде. Килен белән кияүнең ир белән хатын икәнлеген аңлаганбыздыр инде, без икәү янәшә ятып та карадык. Кызык булган иде, әйеме? Миңа бит очында, борының өстендә сипкелләр бар. Мин аларны саный идем. Бүтәннәрнең сипкелләре әллә нинди ямьсез була, синекеләр матур иде. Болындагы чәчәкләр кебек иде алар. Хәтерлисеңме, бер көнне син апаңның ирен буявы белән көзгесен алып чыккан идең. Без синең белән чияләр арасына качтык та синең иреннәреңне буядык. Шул иреннәрең белән син минем янагымнан да, маңгаемнан да, иренемнән дә үптең. Кызык булган иде. Көлештек. *(Балачак көлүе белән тәгәри-тәгәри көлә).* Көзгегә карадык та көлештек, карадык та көлештек. Безнең көлешкәнне апаң ишетте. Икебезне дә тотып алды. Сине кыйнамакчы иде, мин кыйнаттырмадым. Кулын тешләдем. Син боларны онытырга тиеш түгел идең, Тәнзилә. Онытырга тиеш түгел идең, мин бит онытмадым. Безнең очрашулар-

нын һәр мизгеле минем хәтеремдә. Мин инде аларның барысын да сина сөйләп тормыйм. Нигә елмаясың, Тәнзилә? Тегесен сөйлә, дисеңме? Ачуланмыйсыңмы? Әйе, күл буенда булды ул хәл. Авылдан еракта ул күл. Хәзер инде аны камышлар баскан. Нигә анда бардык икән? Мажаралар эзләргә ярата идек шул. Курка да белми идек. Шул күл читендә чупырдаштык. Синең күлмәгең белән балык сөзеп карадык. Аннары балчыктан курчаклар ясадык. Шунда сина балчыктан апаңныкы кебек күкрәкләр ясадык. Син аларны кубып төшмәсен дип ике кулың белән учлап тотып апаң сыман йөреп күрсәттең. Мин тәгәри-тәгәри көлдем. Трусикларыбыз астында нәрсәләр барын да карадык әле без. Ничек оялмадык икән. Без табигатьнең үзе кебек кыргыйлар һәм табигатьнең үзе кебек сафлар идек шул. Шул эшебез өчен үсә төшкәч оялыштык. Беркайчан да син миңа ирләр күзе төшәрлек жиренә кагылдырмадың. Хәер, мин үзем дә кагылмадым. Бабайларыбыздан безгә күчкән язылмаган законнарны икебез дә белгәнбездер, күрәсең. Балачак самимилеге балачакта гына калырга тиешлеген аңлаганбыздыр. Кайчакларда сина ачуым чыкканда нигә соң мин сине саф килеш икенче берәүгә жибәрдем дип тә үкенеп куйгалыйм. Ләкин андый пычрак уйдан бик тиз арынам. Сине—буйга житкән кыз чагыңны шәрә итеп язмакчы да булдым. Ясадым да ертып ташладым. Синнән оялдым, үземнән оялдым. Беренче класска кергәндә мәктәпкә дә икәү бардык бит синең белән, икәү бер партага утырдык. Кайда әле, кайда, карыйк әле, син ул чакта нинди булдың икән? *(Тәнзиләнең мәктәп формасында төшкән рәсемен эзләп таба).* Күрәсеңме, син ул чакта нинди идең. Синнән дә чибәр беркем юк иде дөньяда. Синең янәшәңдә утыруыма мин куана идем, хәтта горурлана да идем. Кайчакларда сина сокланып карап утыруымны күреп укытучы апа кисәтү дә ясый иде. Таһир, тактага кара дия иде. Әйе, Таһир дигән кушамат такты миңа. Әмма ни өчендер сина Зөһрә дип дәшмәде. Аннары мине күчереп утырттты. Әти белән әнигә дә әйткән укытучы бу турыда. Әни укытучыны ачуланган. Нәрсә, сина балаларның бер-берсен кыйнавы күбрәк ошыймыни, яратып караганнар ярамыймыни дигән. Безне аеруларын мин бик авыр кичердем, синең әлләни исең китмәде бугай. Мәктәптән кайтканда да мине көтми башладың. Әллә син кинәт үсеп киттең, әллә мин сабый чагымнан китә алмадым. Мин көнләдем сине, Тәнзилә. Бергә синең белән янәшә утырган кыздан көнләдем. Аны бер-ике тапкыр кыйнадым да әле. Бер гаепсезгә кыйнадым. Сина да үпкәм зур иде. Ләкин, менмең рәхмәтләр сина, син әллә сизеп, әллә үзең дә белмичә мине чыгырымнан чыгарырлык нәрсәләр эшләмәдең. Мин синең өчен һаман да "кияү" идем. Их Тәнзилә, бәгырь кисәккәем, ярата идем шул сине. Син туган көнеңдә үк миңа бәхет итеп яратылган зат идең.

Миңа парга яратылган яр идең син,
Үзең юкта минем өчен бар идең син.
Язда—ташкын, жәйләрдә—гөл, ә кышларын
Ап-ак булып яна яуган кар идең син.
Минем өчен генә туган көн идең син,
Күктән ингән илаһи бер өн идең син.
Сызылган таң, иртәнге чык, кичке шәфәкъ,
Сергә чумган тулган айлы төн идең син.
Миңа атап чыгарылган жыр идең син
Сазымдагы көй көйләгән кыл идең син
Былбылга—тал, тургайга—күк, Аккошка—күл,
Колыннарга болын белән кыр идең син.

## 4. Үсмер чак

Таһир һәм Зөһрә булып яшьлегебез таңын каршыладык, Тәнзиләкәй. Нигә мине Таһир дип атады икән укытучы апабыз. Үземне Таһир дип уйлап, нигә сине Зөһрә дип атадым икән? Таһир белән Зөһрә кавыша алмаганнар бит. Нигә без шуны белмәдек икән? Нигә алар язмышын кабатларга алындык икән? Нигә син Таһир белән Зөһрә жырын яратып жырладың икән?

Таһир—батыр, Зөһрә—матур,
Алар да каушалмаган.

Син матур идең дә, мин батыр була алмадым шул, Тәнзиләкәй. Сабан туе

мәйданына чыгып көчемне күрсәтә алмадым. Беләгемдәге көч белән яшьтәшләрем арасында дан тотмадым. Минем куллар сугышыр өчен яратылмагандыр, күрәсең. Сиңа беләге көчләләр күбрәк ошый иде шул. Хәтереңдәме, тугызынчы класста укыганда язгы ташу ташыганда мин сине ташу аша күтәреп чыкканда егылдым. Хәтерлисең син аны. *(Портретлар арасыннан Тәнзиләнең мәктәп формасында ясалган портретын алып).* Менә шул көндәге рәсемең бу. Күрәсеңме, син монда нинди. Мыскыллы күз карашыңны мәңге онытасым юк. Мескен дидең дә, ул көнне шундый мыскыллы караш ташлап өегезгә йөгердең, шул көннедер бәлки беренче тапкыр безнең мәхәббәтебезгә кара тап кунгандыр. Бәлки, син аны үзең дә сизмәгәнсеңдер. Мине мыскыл итәргә дә теләмәгәнсеңдер. Мескен дигән сүз үзеннән-үзе тугандыр. Ә миңа бик тә, бик тә авыр булган иде ул көнне. Бер айга якын чирләп яттым. Салкын суда салкын тидергән диделәр. Ул гына булмагандыр, Тәнзилә. Синең сүзең һәм карашың йөрәгемә кадалгандыр да урын өстенә салгандыр. Син дә бит коендың ташу суында, ләкин чирләмәдең. Мин бәлки урын өстеннән шул ятудан тормаган да булыр идем, син хәлемне белергә кереп йөргәч терелдем. Рәхмәт сиңа ул көннәр өчен. Мин тиле, мескен дигәнең өчен, гафу үтенер дип тә көткән идем, син ләкин аны әйткәнеңне дә онытkан булгансыңдыр, искә төшермәдең. Ничек итеп егылганыбызны сөйләп көлдең генә. Матур итеп көлдең. Әйтерсең лә мин юри генә, кызык ясар өчен генә егылганмын. Хәтерлисеңме, Тәнзиләкәй, мәктәптәге чыгарылыш кичәсен. Син шашып биедең. Мин бүген уйлавымча, ул кич синең мәктәп белән түгел, яшьлегең белән хушлашу кичәсе булгандыр. Биегәндә син мине күрмәдең. Ә вальсны икәү әйләндек. Ул вальста яшьлегебез белән хушлашу иде бугай. Син миннән күзеңне алмадың. Ләкин күзләреңдә мәхәббәт чаткысы юк иде шикелле. Хуш, Газинур, безнең юллар аерым булыр ахрысы дигән сүзләр иде карашыңда. Кичәдән соң да без төнне бергә үткәрдек. Планнар кордык. Мин күптәнге хыялымны сөйләдем. Рәссам булырга хыяллана идем. Син, белмим әле, мин бит бишлегә укымадым, институтка керә алмам, ләкин авылда калмыйм дидең. Жае табылыр әле дидең. Мәхәббәт турында да сүз булды, билгеле. Мин антлар иттем. Син дә иттең. Ләкин син минем антыма да, үзеңнең антыңа да ышанмый идең шикелле. Күңелеңдә әйтеп бирә алмаган шик ята иде. Хәзер әйтәсең дә онытырсың әле дигән сүзләрне еш кабатладың. Укыганда рәсем укытучыбыз, син, Газинур, зур рәссам булачаксың, сиңа укырга кирәк дия иде. Аның сүзләрен ул кичтә син дә кабатладың. Зур кеше булырсың да мине күрмәссең дә әле дидең. Мин янә антлар иттем. Минем мәхәббәтем ихлас һәм мәңгелек булса да синеке яшьлек мавыгуы гына булгандыр, күрәсең. Ә шулай да татлы булган иде ул кичебез. Туктаусыз үбештек. Гөнаh кылу дәрәҗәсенә җитеп якынайдык. Син аңа миннән дә якынрак булдың бугай. Миңа минем мескенлегем комачаулады шикелле. Юк, мескенлек булмагандыр ул, мин сине үзем дә сизмәстән сакларга теләгәнмендер. Күңелем саф иде шул, Тәнзиләкәй. Кайвакытларда сиңа үпкәләгәндә шул сафлыгымны битәрлим, саф килеш сине ятлар кочагына салганым өчен үкенгәлим дә. Әмма бу ямьсез уйлардан тиз арынам. Әгәр дә мин үземнең һәм синең сафлыгына тап төшергән булсам, сине егерме өч ел буе ярата алыр идеммени. Әлбәттә, әгәр минем бу сүзләремне бүгенге яшьләрнең кайберләре ишетсә, миннән кычкырып көләчәкләр. *(Тәрәзә янына килеп).* Әйе, көләчәкләр. Көлсеннәр. Заманасы сафлыктан көлә торган заман. Шәрә заман. Бүгенге заманга ияреп мин дә үземнән көлгәлим. Ләкин, нишләтәсең, шундый инде мин, Тәнзиләкәй. Мин үз гомеремдә шәрә хатын-кыз рәсемен язмадым. Дөньяда шәрә хатын-кыз рәсемен ясап дан казанучы рәссамнар күп. Атаклылары да җитәрлек. Алар хатын-кыз дип аталган гүзәллекнең серен аның шәрә гәүдәсеннән дә эзләгәннәр. Миндә исә чишенгән хатын-кызны күрү хайвани хис кенә уята. Минем кеше булып каласым килә. Хәер, мин бәлки ялгышамдыр, кеше дә бит хайваннар кебек үк табигать баласы. Фәрештәләр затыннан түгел. Кешенең бит әле җир өстенә үзеннән соң нәсел калдырасы да бар. Фәрештәләр ул бәхеттән мәхрүмнәр. Менә мин кем инде бүген, йә? Фәрештә дияр идем, канатларым юк, кеше дияр идем, нәселем юк. Ләкин мин үкенмим, Тәнзиләкәй. Чөнки син бар. Син минем мәхәббәтем дә

һәм... нәфрәтем дә. Әйе, нәфрәтем дә. Бу сүзне ишетү сиңа, бәлки, сәер тоеладыр. Чөнки мин аны беренче тапкыр әйтәм. Син әле аны ишетерсең. Ә хәзер ямьле көннең ямен җибәрәсем килми. Чөнки бүген синең бәйрәмең. Туган көнең. Ул көнне бары тик мәхәббәт турында гына сөйләячәкбез. Туган көненне бөтен шәһәр белән бәйрәм итәчәкбез. *(Тәнзиләнең соңгы портретын махсус постаментка куя).*

## 5. Туган көн

Күрәсеңме, Тәнзиләкәй, әнә берәүләрнең кулында чәчәк бәйләме. Алар синең туган көнеңә баралар. Әнә берәүләр елмая, туган көнең хөрмәтенә елмаялар алар. Әнә күгәрченнәр парлы-парлы йөренә, алар да белә туган көненне. Әнә тантаналы көй яңгырый, ишетәсеңме? *(Кулларын дирижер кебек сузып).* Маэстро! Янгырат музыканы. Бөтен галәм ишетсен. Бүген Тәнзиләнең туган көне. Күктәге триллион йолдызлар гамәлләге хәрәкәтләреннән бер мизгелгә туктап торсыннар. Бүген Тәнзиләнең туган көне. Маэстро! Оркестрындагы бөтен скрипкалар, альтлар, виолончель, контрабаслар, флейталар, трубалар, тромбоннар уйнасын. Литавралар чыңгылдасын. Барабанчы, син дә йоклама. Яле, бәр әле. Йоклаганнар уянсын. *(Оркестр тантаналы музыка уйный. Газинур аны Тәнзилә портреты алдына тезләнеп тыңлый. Музыка тына.)* Йә, ничек, Тәнзиләкәй. Охшаганмы туган көн бәйрәмең? Ә нигә синең күзләрең моңсу? Әллә җылыйсың инде. Җылама, Тәнзиләкәй. Нигә сиңа җыларга? Бәхетең тулы. Шатлыктан җыласаң ярый, кайгыдан җыларга язмасын. Мин сиңа бүләк тә әзерләдем. Гафу ит инде, чәчәк бәйләме бүләк итәм. Синең чәчәкләргә әлләни исең китми иде билгеле. Болынга чыккач минем чәчәк җыйганымны көлеп карап тора идең. Мин сиңа барыбер чәчәк бүләк итәм. *(Зур чәчәк бәйләме күтәреп "Тәнзилә" алдына сибә).* Ә хәзер... Хәзер нишлибез, Тәнзиләкәй? Хәзер биибез. Мәктәптә әйләнгән вальсыбызны дәвам итәбез. Маэстро! Вальс! Тик зинһар салмак кына... *(Тәнзиләнең портретын алып вальс әйләнә. Җырлый).*

Бир кулыңны кулларыма,
Ал кулымны кулларыңа,
Ил сөенсен, мин куаныйм
Бу дөньяга туганыңа,
Яннарымда булганыңа.

Сал кулыңны иңнәремә,
Кулым куйыйм билләреңә,
Без әйләник, җир әйләнсен
Безнең бию көйләренә,
Синең туган көннәреңдә.

Карадым да күзләреңә,
Нур балкыды йөзләремдә,
Гөл чәчелсен син әйләнеп,
Биеп үткән эзләреңдә,
Язларын да, көзләрен дә.

*("Тәнзилә"не үз урынына куеп).* Ничкә билләргә вальс әйләнү бигрәк килешә шул. Тал кебек бөгелә дип синең турыда җыр чыгарганнар инде ул, Тәнзиләкәй. Хәтерлимсең:

Талы, талы,
Талы бөгелеп тора.
Сагындым, күрәсем килеп,
Үзәк өзелеп тора.

Син бәхетлеме бүген, Тәнзиләкәй? Әйе, шулай шул—син бәхетлеме, дип мин синнән еш сорыйм. Бәхетле итеп күрәсем килә сине. Елмай инде, Тәнзиләкәй. Телисеңме, мин сиңе елмайта торган җыр җырлыйм. Җүләрләр җыры. Әйе, әйе, җүләрләр җыры. Акыллылар җүләр җыр җырламый бит ул, Тәнзилә. Җүләрләр җырын җүләрләр генә җырлый, акыллылар елмаеп тыңлый гына. Без җырлаганнан көлеп, давай, дип куәтләп кенә торалар.

Сандугачым сайрый, сайрый,
Сайрый, сайрый башлады:
Сайрый, сайрый, сайрый, сайрый,
Сайрады да ташлады.

Гафу итә күр, Тәнзиләкәй, җүләрләр җыры булмады бугай бу. Җүләрләр турында булды шикелле. Ә хәзер инде өстәл янына рәхим ит, Тәнзиләкәй. Менә монда түр башына утырып бак. Күрәсеңдер, өстәлемдә ризык юк. Ләкин син бар дип уйла. Дөньядагы бөтен тәм-томнар да алдына куелган дип сана. Дөнья бит ул ничек кабул итсән, шундый. Кемнәрдер уйлыйлардыр—Газинур үзе белән үзе сөйләшә диләрдер. Аны тыңларлык Тәнзилә юк бит янында, диләрдер. Портрет бит ул

сурәт кенә, ишетми дә, сөйләшми дә дип ялгышалардыр. Ә минем өчен син бар, син янымда. Мин хәтта синең учларыңның җылысын тоям. Мин хәтта синең тавышыңны ишетәм. Җырыңны тыңлыйм. Синең яратып җырлый торган җырың. *(Тәнзиләнең җыры ишетелә).*

Таһир белән Зөһрәне
Агызганнар суларга:
Йөреп-йөреп каушалмасак,
Без дә ошарбыз шуларга.
Таһир—батыр, Зөһрә—матур,
Алар да кавыша алмаган.

Кем өйрәтте сиңа бу җырны, Тәнзиләкәй? Син бит аны бәләкәй чагында ук җырлый идең. Балалар җыры түгел бит ул. Үсеп буйга җиткәндә дә җырлый идең. Яшьләр җыры түгел ләбаса ул. Күңеленә кем салды бу җырны? Ничек син аны ничә еллар буе ташламыйча җырладың? Кавыша алмауның фаҗигасен аңлар яшьтә түгел идек ул чакта. Бүген, бәлки, инде син бу җырны җырламыйсыңдыр. Бүген аны мин җырлыйм.

Сөеп-сөеп каушалмасак,
Без дә охшарбыз шуларга.

*(Берничә тапкыр "Без дә охшарбыз шуларга" дип кабатлый).* Их! Тукта, нигә әле мин моңаям, Тәнзиләкәй. Бүген бәйрәм ләбаса. Маэстро! Бүген бәйрәм! Ә бәйрәмдә биилэр. *(Оркестр дәртле бию көен уйный. Газинур бии башлый. Стенадагы Тәнзиләнең туй күлмәге кигән портретын күреп туктап кала).* Ашыкма, Маэстро! Биергә иртәрәк бугай. Тәнзиләнең туенда биисе бар.

*Пәрдә*

# II кисәк

## 6. Туй

*(Тәнзиләнең туй күлмәге кигән портретына озак кына карап торганнан соң Газинур аны кулына алып мольбертка куя).* Гафу ит, Тәнзиләкәй, туеңда була алмагач туй күлмәгеңнең нинди икәнен күрмәдем. Әгәр дә синең туеңда кияү егете үзем булсам, нәкъ менә шундый күлмәкле кәләш янында утырган булыр идем. Кем белә, бәлки син шундый күлмәк кигән булгансыңдыр. Килешә сиңа туй күлмәге. Котлы булсын туегыз, Тәнзиләкәй. Соңга калып котлаганга ачуланма. Туең көнне котлый алмадым. Уйлаган идем. Булачак ирең янында мескен булып күренәсем килмәде. Икенче тапкыр синнән шул сүзне ишетәсем килмәде. Мин чыннан да мескен бер бәндә кисәге идем ул көнне. Җыладым. Үземне кызганып җыладым. Ничәмә еллар буе янәшәңдә йөреп яратуымның тирәнлеген аңлата алмаганмын. Юк, мин сине гаепләмим, үпкәләмим дә. Син мине ташлап бүтәнгә кияүгә чыгуыңны аңлата алдың, мин, юк, мин сине берәүгә дә бирмим, дип әйтә алмадым. Соңгы тапкыр очрашуыбызны хәтерлисеңдер. *(Портретлар арасыннан берсен алып мольберттагы Тәнзиләгә күрсәтә).* Менә шундый идең син. Тулай торактагы бүлмәгә ишекне шакып килеп кердең. Үзем генә идем булмәдә. Кердең дә ишек яңагына сөялдең. Менә күр, йөзең ап-ак иде. Каршына атылып килдем. Ни булды, Тәнзиләкәй, дидем.

—Ни булды, Тәнзиләкәй?

(Тәнзилә тавышы). Исәнме, Газинур.

—Исәнме, исәнме. Әйдә, түрдән уз, утыр.

—Юк. Мин әйтергә генә килдем. Мин... Мин... кияүгә чыгам, Газинур.

—Ничек?

—Мин кияүгә чыгам. Әйтергә килдем. Ачуланма.

—Ә мин?

—Мин бүтәнгә чыгам. Ул читтән кайтты. Мине сорады. Мин чыгам. Мена язган хатларыңны китердем.

—Тәнзилә.

—Ачуланма. Без барыбер бергә була алмыйбыз. Син киттең. Мин калдым. Авылда каласым килми минем. Син мине кайтып алмаячаксың. Мин шунда тирес арасында калачакмын.

—Ни сөйлисең син, Тәнзилә?

—Шулай инде.

—Мин яратам бит сине, Тәнзилә.

—Яратасыңдыр. Мин дә яратамдыр... Әни дә әйтә, бергә булмаячаксыз, ди. Син укыйсың да укыйсың... Хуш.

Әйтергә килдем. Хатларыңны китердем. Хуш.

Син чыгып киттең, Тәнзилә. Артыннан чыгып кулларыңнан кысып тотып, китмә, мин сине беркемгә дә бирмим дип әйтә алмадым. Мин көтмәгән идем... Мин әзер түгел идем. Исемне җыйганда син юк идең инде. Пристаньга йөгердем. Пароход кузгалып китте. Мин кайтканда авылда туй иде инде. Өегез янына бардым. Керә алмадым. Керергә иде миңа. Сине алып чыгарга иде. Мескен идем шул мин. Җыладым. Әти мине сүкте, әни юатты. Сез икенче көнне китеп баргансыз. Син аптырыйсыңдыр инде, нигә боларны сөйли дип уйлыйсыңдыр. Юк, сиңа сөйләмим мин аны, үземә сөйлим. Онытa алмыйм бит, Тәнзиләкәй, нишлим. Онытырга кирәк икәнен дә беләм. Яратышып та кавыша алмаганнар без генә түгелдер. Барысы да минем кебек өзгәләнмидер. Рөхсәт ит, Тәнзиләкәй, соңга калып булса да туебызны уздырыйк. Кил, утырыйк янәшә. Менә шулай. Күрәсеңме, син туй күлмәгеңдә булсаң, минем өстә дә бит кияү егетенең костюмы. Без пар килгән бит, Тәнзиләкәй. Әйдә әле, икәү бергә көзге каршына барып басыйк әле. Күрәсеңме, ниндиләр без. Мин инде бераз картайган, син әле яшь. Әйдә, өстәл янына, анда безне кемдер котлый. Рәхмәт әйтик, Тәнзиләкәй. Барысы да безгә тигез тормыш телиләр. Мин исерткеч эчемлекләр эчмим, Тәнзиләкәй. Ләкин өстәлгә куйдым инде. Нишләтәсең, хәзерге туйлар ансыз булмый шикелле. Әллә соң туебыз хөрмәтенә авыз итеп куйыйммы? *(Бокалга шәраб салып эчә).* Ачуланма, Тәнзиләкәй. Анда туй җыры җырларга җыеналар ахрысы. Юк, үзебезнең туебызга туй җырын үзем яздым.

Ярларсыз елга булмыйдыр,
Парсыз туйлар булмыйдыр.
Парына яр табылмаса,
Гомер тулы булмыйдыр.

Туйларыгыз котлы булсын,
Бәхетегез чуклы булсын.
Туй күлмәге бер буладыр,
Еш кисәң, кер кунадыр.

Ярсыз калган ялгызларны
Бәхет урап узадыр.
Туйларыгыз ямьле булсын,
Тормышыгыз тәмле булсын.

Кул чабуыгызны үтенәм, кадерле кунаклар! Безнең туебызга килеп безнең шатлыгыбызны уртаклашкан өчен икебез исеменнән рәхмәт әйтергә рөхсәт итегез. Сезгә дә шундый бәхетле көннәр күрергә насыйп әйләсен. Сез бәхетнең ни икәнен беләсезме, кадерле кунаклар? Бәхетнең ни икәнен белер өчен бәхетсез булып карарга кирәк. Гел бәхетле кеше бәхетле була белми. Ач кешегә каткан ипи дә тәмле. Юк, сез шаулашмагыз, тыңлагыз. Моны сезгә мин әйтәм. Бүгенге көндә, хәзерге мизгелдә иң бәхетле кеше әйтә бу сүзләрне. Әнә карагыз сез минем кәләшемнең йөзенә. Бәхетлеме? Бәхетле. Чөнки аның да яратмаган ире бар һәм аны яраткан мин бар. Елмай, Тәнзиләкәй. Сине бәхетле дип уйласыннар. Мин бәхетлеләр өчен тост тәкъдим итәм. Гафу итегез, кадерле кунаклар, бәхетсезләр өчен тост тәкъдим итәм. *(Бокалга шәраб салып).* Гафу ит, Тәнзиләкәй, үзем тост тәкъдим иткәч, эчеп куймыйча булмый. *("Тәнзилә" янәшәсенә утырып).* Син дә берәр сүз әйтергә телисеңме? Оялма, монда барысы да үз кешеләр. Монда барысы да диярлек синең белән минем ишеләр. Яртысы—синең кебек акыллы, яртысы—минем сыман тиле. *(Урыныннан торып).* Хөрмәтле кунаклар! Минем кәләшем—Тәнзилә сүз әйтергә тели. Игътибар белән тыңлавыгызны үтенәм. Ул үзе ояла. Татар кызлары бераз гына ояла беләләр әле. Тәнзилә үз сүзләрен минем тел белән әйтергә тели. Кадерле кунаклар! Мин Газинурны бик яратам. Без бергә уйнап үстек. Тормышның бер мизгелендә мин ялгыштым. Ярату дигән бөек хисне көнкүрешнең җайлы, унай яшәешенә алыштырдым. Бүген мин ялгышымны төзәтү бәхетенә ирештем. Бәхетсез кешене бәхетле итү дөньяда иң-иң зур савaплы гамәлдер. Газинур сезгә бәхет турында фәлсәфә сатты. Ләкин бәхетсезлекнең ни икәнен әйтмәде. Бәхетсезлек—ул ялгызлык. Төрмәләрдә дә иң зур җәза—төрмә тәртибен бозган тоткынны бер ялгызын карцер дигән җиргә ябып куюю. Мин Газинурны шул җәзадан коткардым. Туебыз бүген булса да мин һәрвакыт аның янында, аның җанында булдым. Көтә белгән Газинур өчен тост тәкъдим итәм. *("Тәнзилә"не үбеп алып).* Рәхмәт, Тәнзиләкәй. Синең тостка салып куймыйча булмый инде, Тәнзиләкәй. Ә хәзер, хөрмәтле әфәнделәр, Тәнзиләкәй сезгә үзенең бүгенге туенда

жырларга җыенган җырын җырлый.

Таһир белән Зөһрәне,
Таһир белән Зөһрәне
Агызганнар суларга.
Сөеп-сөеп каушалмасак,
Сөеп-сөеп каушалмасак,
Без дә охшарбыз шуларга.

Ачуланма, Тәнзиләкәй. Синең җырың хөрмәтенә берне тотып куям инде. *(Салып эчә).* Ә хәзер, әфәнделәр, концертыбызның чираттагы номеры—күмәк бию. Маэстро! Бию көе!

Бие, бие, Гәйнулла,
Биегән кеше бай була.
Биегән кеше бай булганчы
Карт алаша тай була.

*(Шашып-шашып бии. Арып егыла. Ятып үкси-үкси җылый. Оркестр тынып кала. Бераз тын яткачтын әкрен генә торып).* "Тәнзилә", син монда нишләп утырасың әле? Нигә кәнтәйләнеп утырасың? Өйдә ирең көтмимени? Син бер ахмакның яратам дигәненә алданып туй кулмәге киденме? Бәлки ул сине яратмыйдыр. Бәлки синнән үч алыр өчен генә туй ясаган булып янәшәңдә утырадыр. Әйе, әйе, яратмый ул сине. Ул сине күптән инде онытты. Сагынмый да ул сине. Ул үзенең яшьлеген генә сагына. Аңлыйсыңмы, аңгыра баш, ул эгоист, ул үзен генә ярата, синең аңа кирәгең юк. Бар, кайт өеңә, кәнтәй, бар. *(Портретны урындыктан алып, ишеккә юнәлә).* Юк, юк, китәргә ашыкма әле син. Әнә урамга кара. Күрсеннәр сине, үтеп-китеп йөрүчеләр чын йөзеңне күрсеннәр. Әй, сез, узгынчылар, күрегез—бу Тәнзилә нинди кыз иде. Хәзер бизнесмен хатыны. Мина килгән. Туй ясыйбыз ди. Туй күлмәге киеп килгән. *(Стенадагы "Тәнзиләләр"-гә портретны күрсәтеп чыга.)* Менә ул сезнең мактаулы Тәнзиләгез. Менә күрегез. Юк, яратмыйм мин аны. Берегезне дә яратмыйм. Мәхәббәтем минем нәфрәткә әйләнде. Әйе, әйе, нәфрәт, ләгънәт төшсен сиңа, хыянәтче кәнтәй. *(Портретны атып бәрә. Өстәл янына утырып бокалга тутырып шәраб сала. Эчәм дигәндә туктап кала. Борылып идәндә яткан "Тәнзилә"гә карый. Бокалны өстәлгә куеп портрет янына килә. Тәнзиләнең йөзләрен учы белән сыпыра).* Гафу ит, бәгырькәем. *(Портретны йөзен стенага каратып сөяп куя. Кулына гармунын алып).* Кил әле, дускай. Гафу ит, туйның ямен җибәрдем. Сине дә онытып җибәргәнмен. Син бит минем телем белән әйтә алмаган, әйтергә ярамаган серләремне дә беләсең. Йәле, көйлә әле мина минем җан авазымны. *(Уйнап ала).* Әйе, шулай. Әлбәттә, шулай. Син һәрвакыттагыча хаклы. Нәрсә? Юк, җырламыйм әле бу юлы. "Музыкальная пауза". Син уйна, әйдә, уйна. Кирәкми, уйнама яшьлек көен. Кинәт кенә картаеп киттем әле мин. Менә бүген яшьлек белән очраштым да, картаеп киттем, үткәннәргә еш сәяхәт итәргә ярамыйдыр ул. Үткәннәр белән генә яшәсән, киләчәккә юлны табуы читендер. Талантлы художник диләр иде. Авыл кызының мин язган портретын күрделәр дә искиткеч диделәр. Һәм мин гомер буе шуны кабатладым. Ике йөз портрет. Ике йөз илле, өч йөз булыр. Шуннан ни? Кемгә кирәк алар? Уйна, дускай. Уйна минем сагыш көен. Татарның сагышлы көен. Татарның язмышы да минем мәхәббәтем кебек сагыштан гына тора. Үткәне сагышлы, киләчәге билгесез. Уйна "Тәфтиләү"ен, уйна "Гөлҗаман"ын, "Уел"ын уйна. *(Тәрәзә янына килеп).* Ә сез тыңлагыз, узгынчылар. Кая киттегез соң әле сез! Нинди кавем булды соң бу? Көндез тәрәзә каршына килеп үбешәләр. Төнен берсе дә юк. Урамга чыгарга куркалардыр төннәрен. Ә без курыкмый идек авылда. Төн уртасында урманга чыгып китә идек. Хәзерлисеңме, Тәнзиләкәй. Юк, кирәкми, хәтерләмә. Оныт... Мин дә онытам. *(Тәнзиләнең стенага сөяп куйган портретын мольбертка куя. Мольбертны өстәл янына алып килә).* Онытам, Тәнзилә. Онытам, Тәнзиләкәй. Син әле минем нишләргә җыенганымны белмисең. Әгәр дә син минем нишләргә җыенганымны белсән, йөгереп килеп җитәр идең дә аякларыма тезләнеп җылый-җылый "алай эшләмә" дип ялыныр идең. Мин хушлашам синең белән, Тәнзилә. Хушлашам, Тәнзиләкәем.

## 7. Хушлашу

Ничек дисеңме? Бик тә мәкерле минем уем, Тәнзиләкәй. Мин бүгеннән яна тормыш, янача яши башлыйм. Фатирга евроремонт ясатам. Анда синең портрет-

ләрын булмаячак. Нишләтәмме? Бөтенесен жыям, унар-унар итеп бәйлим, машина яллап машинага төим, авылга алып кайтам да яндырам. Барысы да уйланган. Тик кайсы жирдә яндырырга гына белмим әле. Авыл уртасында ут ягу ярамас. Югыйсә, авылда сезнең өй дә безнең өй дә юк инде. Анда кычыткан белән әрекмәннәр генә үсә. Сезнең өй уртасында яндырсам, дөресрәк булыр иде булуын. Әрәмәлеккә барып син адашкан жирдә, синең аягыңнан тешләрем белән шырпыны суырып алган жирдә яндырсам да ярый. Бәлки урман читендәдер, бәлки мине мескен дип атаган урындадыр. Яндырачагым хак, Тәнзиләкәй. Уйланган, карар кылынган. Мин айнырга телим, Тәнзиләкәй. Мин инде болай да айнып-айнып алгалыйм. Кайвакытларда пычак алып тураклап чыгарга да уйлыйм. Кулым бармый. Пычак белән уйнау рәхимсезлек бит ул, вәхшилек. Ә утта яндыру? Ул да рәхимсезлектер. Ләкин анда вәхшилекнең эзе калмый. Көл тарала да оча да бетә ул. Төтене күккә күтәрелә учакның. Ә күктә янган мәхәббәтнең төтене болыт булып адашып йөри. Кил, менә бирегә утыр. Мин бу иске фатирның иске диварларыннан берәм-берәм синең рәсемнәреңне алам. Карап утыр, берсе дә калмасын. Ә юк, башта зур эшкә тотынганчы, бераз янәшә утырып торыйк. *("Тәнзилә"не янына утырта).* Маэстро! Матәм маршын уйна. Тап шундый марш—кайгылы да булмасын, тантаналы да булсын. Тукта, Маэстро! Бер минутлык тынлык. *(Урыныннан торып).* Кайсыннан башлыйбыз, Тәнзиләкәй? Кешенең гомере туган көннән башлана. Димәк, ак томаннар эчендә карап торган Тәнзилә беренче булып хәтердән югалырга тиеш. *(Сабый чак картинасын алып).* Хуш, дөньяга бәхетле булырга дип туган нарасыйның күз карашы. Хушыгыз, ак томаннар.

Ак томаннар, ак томан...
Ак томаннарга уралып,
Син карап торган сыман.

Хуш! *(Картинаны стенага сөяп куя да Тәнзиләнең бала чагы портретын ала).* Хуш, яланаяклы кызый. Син минем балачак бәхетемнең һәм киләчәк бәхетсезлегемнең шаһиты. Әрәмәлектә адашкач табылган идең, гомер сукмагында югалгач табылмадың.

И гөнаһсыз балачак:
Балачак хатирәләре
Яра булып калачак.

*(Балачак портретын куеп, туй күлмәге кигән Тәнзилә портретын ала).* Минем, Тәнзиләкәй, дөньяга сорауларым бик күп. Бихисап күп нәрсәләрне мин аңламыйм. Һәм жавапларын эзләмим дә. Тормыштагы бөтен сорауларга да жавап табылса, яшәве тагын да кызыксызрак булыр иде. Син искә төшкән саен бер сорау мине газаплый—туеңда утырганда мине бер генә тапкыр булса да исеңә төшердең микән? Менә шушы сорауга жавап табасым килеп яшәдем. Бәхетемә каршы—соравыма жавап табылмаган килеш синең белән хушлашам. Хуш, жавапсыз соравым.

Туй күлмәге ник ак була икән?
Болыннарда уйнаклаган колын,
тайлар
Үсә-үсә ник ат була икән?

*(Стеналардагы портретларны жыя).* Хушыгыз, Тәнзиләкәйләр. Мәхәббәтем утында яндыра алмадым, нәфрәтем утында яндырыйм. Һай, юк, кичерегез, бәгырькәйләрем, нәфрәтем юк, юк сезгә. Кем белә, кавыша алмавыбыз, бәлки, бәхеткә булгандыр. Бәлки, тормышның вак-төяк мәшәкатьләренә, ыгы-зыгыларына күмелеп мәхәббәтем нәфрәткә әйләнгән булыр иде. Бүген мин мәхәббәтемне саф килеш саклап хушлашам. Буш хыялларымны яндырам да... *(Бушап калган стеналарга карап).* Шәрә диварлар. Ә мин шәрәлекне яратмыйм бит. Шәрәлектә сер юк. Синең урыныңны ни алыр икән, Тәнзиләкәй? Мин дөрес әйтәм—кем алыр икән димим, ни алыр икән дим. Анда кеше сурәтләре булмаячак. Мин синнән башкаларның портретын яза алмам инде. Кемне генә сурәтләргә алынсам да аннан син карап торырсың. Бәлки әле мин бергә йөргән әрәмәлек, су буйларын, урман юлларын язармын. Табигать бездән гүзәлрәк. Алыштырса, сине табигать кенә алыштыра алыр инде. Тәнзиләкәйләр, сезне кәфенгә төрер вакыт житте. Ап-ак бүзгә төреп алып кайтам сезне. Туй күлмәге белән кәфен дә бер тостә бит. Ак бүзне махсус сатып алдым. *(Өсталгә ак материя жәя. Портретларны берәм-берәм шул материя өс-*

*тенә куя. "Сабый чак" картинасын кулына алгач, туктап кала. Картинага карап тора*). Карама миңа алай итеп. Карама. Мин гаепле түгел. Гаебем юк минем сезнең алда. Әйе, мин рәхимсез, әйе, мин миһербансыз. Әйе, мин яндырам. Ә син үзең нинди? Нигә син мине җылатасың? (*Картинаны үз урынына элә-элә.)* Әйе, мин рәхимсез, әйе, мин явыз. Ләкин син дә бит... Карама миңа елмаеп. Карама. *(Картина каршына тезләнеп).* Карама! Карама.

*Пәрдә*

*2001-2004*

---

# РОБАГЫЙЛАР

*Мин кулына каләм алып шигырь язган һәр яшь жилкенчәк кебек заманында дәфтәрләр тутырып шигырь яздым. Аннан соң акыл кера башлагач шагыйрь түгеллегемне аңлап, үземне шуңа ышандырдым. Ләкин шигырь чыгару чире вакыт-вакыт гел бимазалап торды һәм кешегә күрсәтми генә робагый дип аталган дүртьюллыклар язып тордым. Шактый җыелгач, кызык өчен берәүгә укыган идем, боларны бастырырга кирәк, диде. Ташка басылып калсын әле, дип ризалаштым. Ни хикмәттер, Равил Фәйзуллин кебек таләпчән шагыйрь дә аларның кайберләрен ошатты һәм журналында аларга урын бирде. Кемнеңдер зәвыгына мин язганнар туры килмәсә, претензиясе "Казан утлары"на булсын.*

**Туфан Миңнуллин**

*

**Язлар җитте, кар астына куз йөгерде,**
**Урам буйлап дәрте ташкан кыз йөгерде.**
**Кыз артыннан мәңге гашыйк, мәңге иләс,**
**Күзлек кигән ике кысык күз йөгерде.**

*

**Кайдан алдың кашларыңның кыйгачлыгын,**
**Кемнәр бирде күзләреңнең көләчлеген?**
**Ходай димсең? Рәхмәт аңа! Ләкин нигә,**
**Нигә миңа биргән Мәҗнүн иләслеген?**

*

**Карлар ява, дип язалар сокланып,**
**Һәм йөриләр зур шагыйрьгә чутланып.**
**Кар ява ул. Кая ява — шуны күр:**
**Кыз бүркенә ява ул кар мутланып.**

*

**Алсу, дымсу иреннәрең бөрелгән,**
**Назлы, татлы сүзләр тама телеңнән...**
**Бүтәннәрнең барысын да онытып,**
**Сине генә мактап язам бүгеннән.**

*

Күлмәгеңнең изүләре уелган,
Шул урынга бер миң ясап куелган.
Беләм: гонаһ миңа анда багарга,
Ләкин мин дә коелмаган чуеннан.

*

Йәле, үлчик: билең болай, түшең шулай,
Бу жиреңнең формасы да камил бугай...
Сөбханалла! Бөтенгаләм конкурсында
Җиңәр өчен яраткан ич сине Ходай.

*

Ах, Карак кыз! Бакчама син нигә кердең?
Агачларым арасында нишләп йөрдең?
Алдалама! Күзләреңдә шомыртларым,
Иренеңдә чияләрем төсен күрдем.

*

Бу гүзәлгә күз тимәсен, диде микән?
Бит уртаңа кояш сипкел сибеп киткән.
Саныйк әле ничәү икән: берәү, икән...
Сөбханалла! Сипкелләрең татлы икән.

*

Ут уйнатып күзләреңнең карасында,
Җилдерәсең гүзәллекнең арбасында.
И, Асылзат! Кысылып җан тәслим кылыйм
Пешеп җиткән ике алмаң арасында?

*

Сөю, сөелү серләрен кемнәр белә?..
Гашыйк булса, берәү җылый, берсе көлә.
Шунсы мәгълүм: һәр гашыйкның күңеленнән
Бу җиһанга илаһи бер нур бөркелә.

*

Үтте инде гашыйк булып тилергән чак,
Карачкыга кызлар диеп үрелгән чак...
Син ышанма, үтте диеп юри язам —
Өйдәгегә тәкъва булып күренгән чак.

*

Ах, Сылузат! Сине күреп китте һушым —
Булыйм, дидем, яннарыңда ишең-кушың.
Һаваларда очып йөргән лачын идем,
Хәзер синең читлегеңдә — тутый кошың.

*

Минме синең утларыңда көймәгәнме?
Сине күзләп эзләреңнән йөрмәгәнме?
Ә бөркөнне мине чиксез бәхет басты —
Егылдым да кочакладым күләгәңне.

*

Бәхет күктән төшми диләр, төште бит —
Җаннарыма канат булып үсте бит.
Очып китеп барып кундым кояшка —
Ах, Җанашым, йөрәккәем пеште бит.

*

Сизәсеңдер, карыйм сиңа сөзеп-сөзеп,
Гашыйк күңлем күлләреңдә йөри йөзеп.
Күзләремдә шайтан, күңлем фәрештә күк —
Сиңа кайсы күбрәк ошый? Әйтче өзеп.

*

Үтте язым, җәем, җитте инде көзләр...
Бу сүзләрне шуның өчен язам, кызлар:
Туфан абый, зинһар өчен картайма, дип,
Берегезнең, бәлки, бераз күңле сызлар.

*

Уңга-сулга тайпылулар үтә, ахры,
Миңа дигән кайнар кочак бетә, ахры,
Кайнар кочак ияләрен сүгә-сүгә,
Кайнар мичне мактар көннәр җитә, ахры.

*

Җанда хисләр бәрелешеп дөбердәшә:
Чык яныма, соңлама, дип кемдер дәшә.
Тәрәз ачсам, коелырга өлгермәгән
Усак яфраклары гына лебердәшә.

*

Чишмә ага, бака сайрый, йолдыз яна...
Шундый төндә яратам, дип әйттем аңа.
Яратканың исбатла, дип көлгән иде,
Мин оялдым, мин кызардым — вәт дивана.

*

Бер фәкыйрьгә кинәт бик зур байлык иңгән —
Мескенебез бер елаган һәм бер көлгән.
Менә мин дә нәкъ шул хәлдә, Җанкисәгем,
Нишләргә дә белми торам синең белән.

*

Кит каршымнан, кит, бинамаз, ымсындырма,
Үткән-киткән яшьлегемне юксындырма...
Шулай дидем. Һәм яшьлегем әллә кайдан
Аваз салды: ычкындырма, ычкындырма!

*

Уйлыйсыңдыр: Туфан абый миңа гашыйк,
Мин, гүзәлне, күргәч кала каушап-шашып...
Юк, Җанкисәк, ялгышасың, сиңа түгел,
Сине яраткан Ходайга иям башым.

*

Ни диярләр Рамазанда әз-мәз шашсак?
Күзне йомып, гөнаһлардан бераз качсак?
Сәхәр чагын әйтмим инде — артык иртә,
Ничек булыр, пәп итешеп, авыз ачсак?

*

Үлчи торгач кемнең күбрәк түзгәнен,
Ваттык, ахры, мәхәббәтнең бизмәнен —
Хәзер менә ике якта икебез
Тикшерәбез кемнең кемнән бизгәнен.

*

Чирләремне син санама әле, доктор.
Бу дөньяда бер дә чирсез кеше юктыр.
Үзең доктор, үзең сылу, үзең чибәр —
Яннарымда бераз гына утырып тор.

*

Үтте кызлар: "Исәнмесез, бабай", — диеп,
Артларыннан карап калдым, башым иеп.
Шунда кинәт, арандагы яшь айгырдай,
Егет чагым кешнәп куйды, башын чөеп.

*

Сандугачны кем өйрәткән җыр җырларга?
Чәчәкләрне кемнәр сипкән болыннарга?
Зинһар өчен, ат буласын белгертмәгез
Болыннарда уйнаклаган колыннарга.

*

Яңа яуган кар өстендә эзләр кала,
Аерылганда әйтелгән сүзләр кала.
Бар да үтә, бар да кала... Иң авыры —
Мөлдерәмә өмет тулы күзләр кала.

*

Яратмадың, һәрчак мыскыл иттең мине,
Яратмадың рухымны һәм җисемемне.
Тик шулай да, яратты, дип язып куйдым
Хатирәләр китабына исемеңне.

*

Карама син миңа алай, карама.
Кагылмачы төзәлмәслек ярама.
Талпынсам да, кочагыңа кералмыйм —
Синең яшьлек, минем картлык арада.

*

Карт түгел мин һәм картаймам мәңгегә.
Ышандырып нәрсә әйтим дәлилгә? —
Галиябану әби булмый һичкайчан,
Бабай диеп эндәшмиләр Хәлилгә.

*

Бик күптәннән — әби патша заманында
Үпкән идем сине урман аланында.
Шул урынга быел барсам — бер чикерткә
Нидер көйли кипкән үлән сабагында.

*

Актарынам хатирәләр капчыгында —
Нидер шәйлим ватык көзге ярчыгында:
Йа, Ходаем! Унҗидедә үпкән кызым
Сәлам әйтә алтмыш яшьлек карчыгыма.

*

Гаҗәпләнмә күктән йолдыз чүпләвемә,
Йолдызларны алларыңа сипкәнемә.
Нишләтәсең, уйнак күңел өмет итә
Картлыгымны яшьлек белән сипләвеңә.

*

Томаланды күзләр — нуры сүнеп бара.
Ераклаша бара якын гына ара...
Тау башында кем ул? Нинди чибәр зат ул?
Нигә соң ул мине күрми, Йөзекара.

*

Курыкмыймын картлык миңа кизәнгәнгә,
Була аның сырхавына түзәргә дә.
Картаюның иң яман бер ягы шунда —
Яратам дип әйтү оят гүзәлләргә.

*

Карале син, күр син теге Сылузатны —
Түш киереп атлаулары ничек татлы...
Хуш, картлыгым! Мин ияреп киттем аңа,
Без бит әле ни әйтсәң дә Туфан атлы.

*

Гыйшык кадрен яшьлек белми, картлык белә —
Чөнки дә ул сөю тәмен татып белә.
Шулай булгач, нигә икән бу кыз-ыркын
Малайларны бабайлардан артык күрә?

*

Кызык ясап көләр өчен тузган баштан,
Яратам, дип әйткән идем кызган баштан...
Мәхәббәтемнең тарихын яза алмыйм.
Шул әлеге тузан башлы кыздан башка.

*

Печән өсте җиткән икән — сизмәгәнмен,
Печән исен сизгәч кенә өзгәләндем:
Печәнлектә уздырган төн искә төште —
Мин, күрәсең, синнән һаман бизмәгәнмен.

*

Яши-яши, киттем инде картаеп та,
Ара-тирә мәс тә булдым һәм аек та...
Шуны белдем: әдәбият дәрьясында
Бүре, кәҗә һәм кәбестә бер каекта.

*

Төшемдә мин таш гасырга кайтып килдем,
Кыргыйларга шигырьләрем укып йөрдем,
Шигыреңне ташка уеп яз, диделәр.
Шагыйрьлекнең ни икәнен шунда белдем.

*

Нигә кирәк яшәдем дип үкерү,
Җиңдем диеп дөньяны ду китерү?
Ә чынында безнең гомер нәрсә ул? —
Ярыктан чыгып чокырга сикерү.

*

Ишегеңне ача идек дер калтырап, —
Телең белән ташлый идең безне турап.
Бүген нишләп кулың сузып елмаясың?
Безнең янга төштең мәллә? Нихәл, бырат?

*

Бөтен нәрсә сатылган бу заманда
Безнең яшәү туры килә тамангa.
Фәхишәнең товарына күз багып,
Әхлак диеп кем лыгырдый һаман да.

*

Хатынга — ир, ә ирләргә хатын кирәк,
Бу дөньяга һәрчак тиле акын кирәк.
Тиле язган робагыйны аңлар өчен
Мәҗнүнлек һәм әз-мәз генә акыл кирәк.

# "ТАЯНЫЧ УЛ—ХАЛЫК..."

ШАГЫЙРЬ РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИННЫҢ
ДРАМАТУРГ ТУФАН МИҢНУЛЛИН БЕЛӘН ӘҢГӘМӘСЕ.

**Равил Фәйзуллин:** *Туфан Абдуллович! Бу әңгәмә барышында мин Сиңа "Сез" һәм "ага" сүзләре белән мөрәҗәгать итмәкчемен. Ихтирамым да зур, беркадәр яшь аермалары да бар...*

**Туфан Миңнуллин:** Алай итмик әле, Равил! Төрки-татар дөньясында үзара якыннар һәрвакыт Син дип сөйләшә. Без бит замандашлар, әдәбиятка да бер вакыттарак килдек, кочаклашып йөрмәсәк тә, бергә дустанә гомер кичердек, иҗат иттек, балалар үстердек, иң мөһиме—фикердәш була алдык. Шуңа күрә бу әңгәмә инде акыл утырткан ике өлкән әдип сөйләшүе булсын.

**Р.Ф.:** *Килешәм. Син безнең журналыбыз кунагы бүген, шуңа күрә сүз, нигездә, Синең иҗат һәм аңа бәйләнешле мәсьәләләр тирәсендә булыр, хуҗа сыйфатында сорауларны мин бирәм булып чыга инде.*

*Моннан нәкъ ун ел элек (алмалы ел иде ул! Быел да шуңа охшап тора) Синең туган ягың Кама Тамагында, туган авылың Олы Мәрәтхуҗада татар әдәбияты-сәнгатенең кабатланмас бер бәйрәме булган иде. Яшь-яшь Туфанга нибары 60 яшь. Татарстанның гаҗәп матур урыны—Идел белән Каманың тоташкан урынында, биек ярда (ялгышмасам, исеме Айгыртау) татар рухын биеккә күтәргән Дуслар Учагы дөрләгән иде. Көн матур, чакырылган кунаклар берсеннән-берсе күркәм, бәйрәм хуҗасы—бөек... Матур сүзләр, мәңгелеккә омтылыш... Шул вакыйгадан соң ун ел гомер үткән дә киткән. Ул бәйрәм Синең үзеңә дә охшагандыр дип уйлыйм. Мөгаен, гомерем булса, ун елдан соң фәләннәрне эшләрмен, дип уйлап хыяллангансыңдыр, дөньяда фәлән унай үзгәрешләр булыр дип фараз кылгансыңдыр... Йә, Туфан ага, егерме беренче гасырның бишенче елында кәефләр ничек? Үзеңнән, дөньядан канәгатьме?*



**Т.М.:** Минем яшьтә кәеф иң беренче чиратта саулык-сәламәтлек белән бәйләнә. Ул яктан Ходайның биргәненә шөкер әлегә, кем әйтмешли, әкрен генә йөгереп йөрибез. Аннан инде безнең кәеф иҗат белән нык бәйләнгән. Анда да, иншалла, тик торган юк. Өйдә дә иминлек. Димәк, үземнән канәгать, зарланырга хакым юк.

Дөньядан канәгать дип әйтә алмыйм. Мин һәм Син теләгәнчә әйләнми дөнья тәгәрмәче. Иң авыр кичерелгәне—туксанынчы еллар башында Рәсәйдә шәйләнгән демократиянең бетүгә таба баруы. Бигрәк тә күсәкнең юан башы безнең тарафларга төшә. Ничәмә-ничә гасыр хыялланган дәүләтчелеккә ирешү юлында җилкенеп алган идек, Суверенитет турында Декларация кабул иттек, Төп законыбыз—Конституциядә безне өметләндергән маддәләр пәйда булды. Бүген алар юкка чыкты. Үзен татар дип санаган кайсы кешенең йөрәге әрнемәс бу хәлгә. Шуңа каршы тора алмау чарасызлыгы җанны каезлый. "Нишләргә?" дигән сорауны үземә еш бирәм,

тик жавабын таба алмыйм. Сүз шәхсән үзем турында гына бармый. Минем күнелемнән татарның үз дәүләте булырга тиеш дигәнне беркем дә тартып ала алмый. Мине яратмаган илне мин Ватаным дип әйтә алмыйм. Ничек һәр татарның күнеленә шул хисне сендерергә? Нишләргә?

**Р.Ф.:** *Язучы эшчәнлегенен ахыр нәтиҗәсе—китап. Хезмәтләре театр, спектакльләр белән бәйле булган драматургларнын китапка карата фикерләре, шагыйрьләр яки прозаикларныкыннан бәлки беркадәр үзгәдер. Ни генә булмасын, китап—барыбер китап инде ул! Берничә ел элек Синен 10 томлык әсәрләрен басылып чыкты. Сирәк була торган куанычлы хәл. Сонгы дәвердә безнен заман язучыларыннан бары Т. Әйдинен генә мондый санда томлыклары чыга алды. Үткән заман классик әдипләрнен дә күптомлы сайланма әсәрләре әзерләнә дип беләм. Әйе, язу—бер хикмәт, китап итеп чыгару—үзе бер тарих, ә менә укучы күнеленә барып ирешү... Менә шул сонгысы—китапнын кешеләргә барып ирешүе яки ирешмәве турында Синен фикерне беләсе килә. Хәтерендәдер, әле май аенда гына булып үткән язучылар съездында да байтак сүз булды бу хакта. Китап—безнен тарихыбыз, данлы үткәнебез. Китап—безнен киләчәгебезме?*

**Т.М.:** Бүгенге көндә чын һәм хәтта чын ук булмаган язучыга да китап чыгару зур проблема түгелдер. Республика житәкчеләре ярдәмнәреннән ташламыйлар. Бүген төп мәсьәлә—чыннан да китапның укучыга барып житүе һәм укылуыдыр. Монда проблема баштан ашкан. Китап укучылар азайды. Бу татарда гына түгел, күпсанлы урыста да шулай. Аларның китап, журнал тиражлары бик түбән. Күрәсең, мондый хәл заман шаукымыдыр. Бүген кешенең йөрәге һәм башыннан алда корсагы йөри. Корсак кайгысы белән генә яшәүченең, билгеле инде, рухы ярлы була. Рухы ярлы кешегә китап кирәкми. Ләкин бу вакытлы фажигадер. Кешеләребез күнеленә азык житмәвен тоеп, эзләнерләр һәм китапка килеп юлыгырлар дип өметләнәм.

**Р.Ф.:** *Театрсыз милләтне күз алдына китерү кыен. Дөньяда без анлаган классик мәгънәдә театрлары булмаган, әмма яшәгән һәм яшәячәк милләтләр дә бардыр, бәлки. Безнең шартларда театр—халыкның милләт булып яшәвенең бер билгесе. Әйтик, халыкны рухи берләштерүдә, телебезне саклауда театрнын роле бик зур. Шуннан чыгып, беләсе килә: театрларыбызнын бүгенге хәлләре ничек? Әйтик, тагын 15-20 елдан аларны ничек күз алдына китерәсен?*

**Т.М.:** Дөньяда театры булмаган милләт юк. Театрнын формалары төрле-төрле. Без ияләшкән, рәсмиләштерелгән театрнын формасы бердәнбер түгелдер. Татарда рәсми исем алган театрга хәтле күнел ачулар булмаганмы? Туйлар театр түгелмени? Кич утырулар да театр. Ин зур театрыбыз—Сабан туе. Анда милләтне милләт итеп саклый торган компонентлар тулып ята. Тел осталарының ярышлары да даими булып торган. Әйтик, казакъ, кыргыз халкында айтыс дип аталган бәйгеләр бүген дә үткәрелә. Татарларда да булган ул, әле без Мәскәүдә укып йөргәндә Измаил паркы дип аталган жирдә Нижгар, Тамбов, Пенза төбәкләреннән чыккан татарларның яшьләре кара-каршы такмак әйтешәләр иде. Шулай итеп телләрен саклыйлар һәм чарлыйлар иде. Егет белән кызның кара-каршы басып такмак әйтешүе—менә дигән театр. Профессиональ театрыбызга килгәндә, ул, әлбәттә, яшәячәк. Нинди булуы мине әллә ни борчымый. Татарча сөйләшүче, татарча фикерләүче, татар жанлы театрыбыз гына булсын.

**Р.Ф.:** *Хәтердә: 80 нче еллар уртасында "Әлдермештән Әлмәндәр"не Бөтенсоюз телевидениесеннән күрсәттеләр. Без, бер төркем язучылар, Пицунда ижат йортында идек. Жыелышып утырдык телевизор каршына. Бүтән милләт язучылары да байтак жыелды. Карыйбыз: экранда үзебезнен яраткан артистлар, үзебезнен тел, жанга якын мохит... Күз яшьләрен китерер дәрәжәдә горурлык! Күнел бәйрәме! Менә шундый матур сәгатьләр бүләк иттен Син безгә ул чакта! Хуш, болары—үткән заман. Татар драматургларынын, шул исәптән Синен әсәрләрен, бүтән илләр, халыклар сәхнәләрендә куеламы хәзер?*

**Т.М:** Әгәр без СССРдан аерылып чыккан союздаш республикаларны мөстәкыйль ил дип кабул иткәнбез икән, аларда минем пьесалар куелгалап тора. Бигрәк тә

Казакъстанда, Үзбәкстанда. Россиядәге башка милли театрларның репертуарында мин язганнар бар. Бигрәк тә Төньяк Кавказ республикаларында мин популяр. Урыс театрларында—юк. Хәтта Казаныбыздагы урыс телле театрларда да мине драматургка санамыйлар. Хәер, мине генә түгел, гомумән татар драматургиясен алар санга сукмыйлар. Күрәсең, безнең дәрәҗәгә "төшәселәре" килми. Урыс әйтмешли, черт с ними. Миңа үзебезнең театрлар да бик житкән, алар бер дә урыснықыннан *(урыснықы микән әле бүгенге урыс театрлары)* ким түгелләр.

**Р.Ф.:** *Соңгы елларда Камал театры инициативасы белән "Яңа татар пьесасы" дигән конкурс-ярышлар (нишләптер конкурсларны соңгы вакытта "бәйге" дип яза башладылар. "Бәйге" сүзе, минемчә, ул күбрәк ат чабышларына карый) оештыралар. Әлбәттә, жинүчеләр билгеләнә. Бу конкурсларга Синең карашың? Һәм өстәп: татар драматургиясенең киләчәге кемнәр кулында?*



*Әмирхан Еники белән СССР язучылар съездында. 1986 ел.*

**Т.М.:** Конкурсмы, бәйгеме—миңа барыбер. Тегесе дә монысы да ярышу инде аның. Мондый гамәлне мин хуплыйм, ярышырга яратам. Элеккеге ярышларда катнаша идем, соңгысында катнашмадым. Чөнки конкурсның шартлары канәгатьләндермәде. Анда урыс телендә язылачак драма әсәрләре дә кабул ителә, диелгән иде. Татар телендә язылмаган пьеса татарныкы була алмый дип саныйм. Чөнки тел—әдәбиятның төп үзәге, сырт сөяге. Татар телендә яза белмәгән язучы татарларны да мин татар язучысы дип атамыйм. Гафу итсеннәр. Татар язучылары буласылары килсә, татарның теленнән жирәнмәсеннәр, объектив сәбәпләр эзләп акланмасыннар. Ана телсез милли әдәбият—ул яһүдләр теориясе. Алар безне кыйбласызлыкка өндәп, үзләре Израильгә карыйлар. Без башка халык, ни кызганыч, безнең Израилебез юк, без үзебезне үз телебез белән сакларга мәжбүр ителгән. Әлегә, дип тә өстәп куйыйм. Драматургиябезнең киләчәге кемнәр кулында дигәндә, татарча камил язучы татарлар кулында булыр дип өметләнәм.

**Р.Ф.:** *Фараз итеп, әгәр Камал театры, байтак дистә еллар аның төп хуҗасы М. Сәлимҗанов дөньяда булмаса, бүгенге Туфан Миңнуллин шушындый зур була алыр иде микән?*

**Т.М.:** Мин Марсельне татарның бөек режиссеры дип саныйм һәм аның белән бергә иҗат итү бәхете тигәнгә язмышыма рәхмәтле. Әмма Марсель булмаса, мин дә булмас идем дип әйтергә телем әйләнми. Мин үземне мөстәкыйль фикер йөртүче шәхес дип исәплим. Кемнеңдер итәгенә ябышып дәрәҗәгә ирешү минем өчен ят нәрсә. Мин драматург буларак режиссерлар Сабир Өметбаев, Равил Тумашев, Гали Хөсәеновларга рәхмәтемне әйтеп торам. Сабир абый Өметбаев, мәсәлән, Минзәлә театрында беренче пьесамны куйды. Әсәр буларак шактый ук йомшак булса да, куйды. "Үзең язганны үзең сәхнәдән кара, үз ялгышларыңны күрсәң, драматург булачаксың, күрә белмәсәң, театрга пьеса күтәреп килмә", диде. Аны ничек онытасың...

Әлбәттә, Марсельнең миңа тәэсире зур булды. Ул чын укымышлы, эрудицияле шәхес иде. Ләкин ул да минем язганнарга мохтаж иде. Төп мәсьәләләрдә фикерләр берлеге безне якынайтты, берләштерде. Һәр драматургның бәхете—аны аңлаган режиссерның язмышына туры килүе. Бүген мин Камал театрының баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәев белән уртак тел табарга тырышам, Түбән Кама театры режиссеры Рөстәм Галиев белән дә борчагыбыз пешә.

**Р.Ф.:** *Син бөтен табигатен-холкын белән—карьера өчен яратылган кеше түгел. Гөбедән чыккан тавыш белән турыдан ярып сөйләшү, ачымы-төчеме, хакыйкатьне ярып салу... Син дипломатик кануннарнын бөтен нечкәлекләрен белеп бетергән кеше дип уйламыйм (ә кем белә, бәлки, киресенчәдер...). Шулай да... Син, карьера кешеләренә хас булганча, хакимият-власть тирәсеннән беркайчан да китмәден. Язучылар оешмасы парторгы, соңрак—шул оешманың рәисе. СССР Югары Советы депутаты, Татарстан депутаты... Хәзер дә Татарстан Дәүләт Советында даими комиссия рәисе урынбасары... Малың бар, даның бар дигәндәй... Нигә Хемингуэйлар кебек табигать стихиясендә ял итеп, кирәк чакта бар вакытны фәкать иҗатка гына биреп яшәмәскә?*

**Т.М.:** Килешеп бетмим, Равил. Карьерага омтылмаган кеше шәхес була алмый. Ә мин үземне шәхес дип саныйм. Ләкин нинди карьерага омтыласың бит. Мине иҗат карьерасы һәрвакыт камчылап торды. Бүген әйтергә ярыйдыр инде, мин Туфан Миңнуллин дигән исемне алу өчен тырыштым. Кайберәүләр бит язган әйберләре астына фамилияләрен куялар да Татарстанның атказанган фәләне дип өстиләр. Шул өстәмәләрсез генә кем икәнемне белсәләр, мин максатыма ирешәм дип шатланам. Әйе, ул яктан чын карьерист мин. Ләкин мин кемнәрнен дә садакасы хисабына, "служебный карьерага" ирешергә теләмәдем. Андый карьерага ирешер өчен әлләни тырышырга кирәкми бит—кемнәргәдер ярый белергә генә кирәк. Минем дәрәҗәле исемнәрем шактый һәм алар миңа язучылык һөнәре өчен мин начальство тирәсендә буталып йөри башлаганчы ук бирелгәннәр. Хезмәтемне вакытында күреп алып бәяли белгәннәргә рәхмәт. Депутат булып сайлануларым да шуңа бәйләнгәндер дип уйлыйм.

Власть башында утыручыларга "ярый белүем"нең хикмәте нидәндер, өзеп әйтә алмыйм. Һәрхәлдә, ялагайланудан түгел. Күпләр хакимияттә утыручыларның психологиясен аңлап бетерми. Анда ялагайларны өнәп бетермиләр. Чөнки ялагайлар—ышанычсыз кешеләр. Алар жае чыкса, үз туганнарын да саталар. Өстәгеләр мөстәкыйль шәхесләрне хөрмәт итәләр. Әлбәттә, ул мөстәкыйль шәхес өстәге икенче мөстәкыйль шәхеснең урынын биләргә тырышса, ул чакта аңа каршы көрәш башлана. Жинелгәнне анда кызганмыйлар. Мин берәүнең дә урынын алырга тырышмадым, берсенең дә тәхетенә кызыкмадым, әйтәсе сүзем жанны борчыганнан әйтелә, ихластан сөйләнелә. Начальство без уйлаганча ук акылсыз түгел, нәрсәнең ни өчен әйтелгәнен бик яхшы аңлый.

Ә инде, Хемингуэйча яшәп иҗат итүгә килгәндә, мин алай да яшәп карадым. Ләкин без яшәгән ил Хемингуэйлар өчен түгел. Кешенең кадере булмаган илдә алай яшәп булмый, кычкырып ачтан үләсең. Телиме, теләмиме, кеше үзе яшәгән мохиткә яраклаша. Без никадәр генә мөстәкыйль булырга тырышсак та, имгәтелгән буын—Безгә, үзебезчә яшәргә тулы ирек бирелсә дә югалып калабыз, ирек өчен көрәшүебез үзара сукранышудан узмый.

**Р.Ф.:** *Сүз җебенең очын югалтмыйча, әңгәмә башын искә төшерик әле: син "Суверенитет турында декларация кабул иттек. Төп законыбыз—Конституциядә безне өметләндергән маддәләр пәйда булды. Бүген алар юкка чыкты", дисең. Ә кем гаепле?*

**Т.М.:** Үгезнең мөгезен эләктерәм дисең инде. Кем гаепле? Ялгышмасам, урысның бер зыялысы да заманында Россиянең мөшкел хәлгә төшкәненә "Кто виноват?" дигән сорау куйган булган. Кемнәрнедер гаеплисе дә килми. Бардыр инде, Алтын Урда империясен саклый алмаганбыздыр. *(Хәер, һәр империянең таркалырга тиешлеген тарих исбатлап тора)*, Болгар дәүләте җимерелүендә дә үз кулыбыз юк түгелдер, Казан ханлыгын да бар тәркиләр бергә җыелып яклый алмадык. Яулап алучы дәүләт, табигый хәл, үз кагыйдәләре белән эш йөртә. Шуның өчен яулап алган бит инде ул, татарга яхшы булсын дип бәреп кермәгән. Бер тарихи факт мине өметләндерә — дүрт гасыр ярым албасты астында яшәсәк тә милләт буларак югалмадык. Берничә тапкыр үзебезнең саклану иммунитеты исән икәнлекне күрсәтә алдык. Бигрәк тә соңгысы — Декларация кабул иткән көннәрдә дәррәү уянуыбыз өметне көчәйтте. Без бүген каршыбызда кем торганны күреп чигендек, кем гаепле? Әлбәттә, кайбер конкрет мәсьәләдә кемнедер гаепләп тә

буладыр. Ләкин зинһар кирәгеннән артык каты кагылып бер-беребезне рәнҗетешмик. Тарихи ситуацияне дөрес бәяләп чигенә белик. Әмма һәр даим көрәшкә әзер булырга кирәктер. Әйткәнемчә, рухыбызның сәламәтлеген сакларга өйрәник. Әмма болар гына төгәл һәм тулы җавап түгел. Кем гаепле? дигән сорау кала бирә. Бәлки аңа Син дә, бүтән дә җавап эзләр. Кем гаепле?

**Р.Ф.:** *Нигә депутатларның берәрсе житди политик акция ясамады? Әйтик, протест йөзеннән мандатыннан ваз кичмәде? Парламентның яртылабы элекке состав, ягъни 90 нчы еллардан бүгенгегә кадәр депутат булып торучылар бит. Заманында үзләре үк чыгарган законнарны үзләре үк сүттеләр. Депутатлары шундый булгач... Глобаль уйлаучы даирәләр, дөнья җиһангирләре диюем, "бу халыкны теләсә нишләтеп тә була", дип тә уйлыйлардыр, бәлки?*

**Т.М.:** Бу чын шагыйрь соравы. Сәясәтче мондый сорауны бирмәс инде. Мин дә сәясәтче түгел. Шуңа күрә җавабым да үзебезчәрәк булыр иде. Бәлки ул җавап та түгелдер, уйлану гынадыр. Син әйткәнчә, минем дә протест ясап депутат мандатыннан демонстратив рәвештә баш тарту теләге уе башыма килгәли. Соңгы елларда бу теләк көчәя төште. Ләкин шунда әтинең әнигә әйтә торган бер сүзе искә төшә. Әни нигәдер булса ризасызлык белдереп тузына башласа, әти: "Тукта, кызма әле син, Халисә" дия иде. Әни бераз сүрелгәч икенче төрлерәк уйлый иде. Ярый, Синенчә булсын, мин депутат мандатын атып бәреп, әйтәсе сүземне әйтеп сессиядән чыгып киттем ди. Шуннан ни була? Ни үзгәрә? Ни кызганыч, берни дә үзгәрми. Берәүләр мине яклап дуларлар, берәүләр кызганырлар, берәүләр ялгышты диярләр, дурак дип әйтүчеләр дә табылыр. Заманында мин Минтимер Шәрипович президентлыкка сайланганда аның яклаучысы (доверенное лицо) булдым. Шунда миңа президент Дудаев кебек булсын иде ул дип әйтүчеләр була иде. Мин аларга президент Дудаев кебек булсын өчен халкың чечен кебек булырга тиеш дип әйтә идем.

Суверенитетның беткәннән-бетә баруын күреп дулыйм да, күмерем бераз сүрелгәч, уйлыйм: "Тукта әле, дим, минем протест ясап китүемә караганда, сүземне туктаусыз трибунадан әйтеп тору отышлырак түгел микән?" дим.

**Р.Ф.:** *Син "Татар кодексы" Кануннамәсенең төп авторы. Аның тезислары ун еллар элек "Казан утлары"нда да чыкты. Соңрак, тәфсиллерәк итеп (янадан редакцияләнгән варианты диикме) "Идел" журналында басылды. Миңа калса, бик житди Кануннамә ул. Яһүдләрнекен әйткән дә юк, Төрекманбашы Ниязовның да (ул, мөгаен, коллектив хезмәттер инде) "Рухнамә"се дә гыйбрәтле. Аның белән татар укучысы да танышса, файдага гына булыр. Әлбәттә, һәр халыкның үз карашлары, үз кануннары, үз идеаллары... "Татар кодексы"н халык аңына сеңдерү өчен нишләргә кирәк?*

**Т.М:** Төгәл генә белмим. Без өстән әйтелгәнне хакыйкать дип кабул итәргә өйрәтелгән. Милләтне саклауның эчке динамикасын үзләштермәгән. Татар теле нигә кирәк, татар теле белән кая барып була дип сөйләнүче татарга җан ирегә турында сөйләп, ни эш кырып була икән? Милли хисләре булса да, хакимият башында утыручылар гына милләтне саклый алмыйлар. Аларга таяныч кирәк. Ә таяныч ул—халык. Мин—татар дигән хис һәр татарның җанында булмаса, Мәскәүне сүгүдән ни файда? Әгәр җаныбызда татарлык була икән, Мәскәү дә, Вашингтон да пычагым да кыра алмый. Менә шуны аңлатырга тырыштык Кодекста. Аны мәктәпләрдә өйрәнеп яшь буынның җанына сеңдерә алсак иде. Ни кызганыч, мәктәптә укытучылар арасында аны аңлатырдайлары күп түгел. Татар дигән сүзне кычкырып әйтергә курыкканнар үзләре кебекләрне тәрбияли. Югыйсә татар булып татар өчен көрәшүнең ни начарлыгы бар. Мин, мәсәлән, татар дип әйткәндә бүтәннәрне түбәнсетмим, үземне генә зурлыйм.

**Р.Ф.:** *Без язучылар күп дистә еллар Язучылар оешмасына елышып яшәдек. Шунда җыелдык, утырышлар уздырдык, мактаныштык, тәнкыйтьләдек һәм тәнкыйтьләндек... Оешмасыз иҗади яшәүне күз алдына китерү кыен иде. Чөнки күбебезнең иҗади язмыш (иҗади яктан бәяләнү, китаплар чыгаруга булышлык, исем-премияләр алу, югары органнарга, сайлауларга тәкъдим итү һ. б.; шулай ук*

*көнкүреш-матди хәлләр—фатир, пенсия, путевка-юлламалар алу һ. б.) Язучылар оешмасына бәйле иде. Хәзер вазгыять бүтән. Шулай да, галәт-менталитет белән без һаман да оешмага ниндидер өмет белән карауны дәвам итәбез. Гәрчә, иҗтимагый оешма буларак, Язучылар берлегенең мөмкинлекләре чикле хәзер. Синеңчә, оешманы язучылар үзләренең туган йорты кебек күрсеннәр өчен яна сайланган җитәкчеләргә, һәм гомумән, язучылар коллективынаниләр эшләргә кирәк?*



*Сулдан уңга: Гәрәй Рәхим һәм Рабит Батулла белән. 1969 ел.*

**Т.М.:** Төрле хәлләр булды. Язучылар оешмасы коммунистлар оештырган кыса дию- чеkәр табылды. Бәлки шулайдыр. Күпләргә Язучылар берлеге кирәкмидер дә. Мина да шәхсән аның практик яктан кирәге юктыр. Ләкин без бер һөнәр кешеләре буларак очрашып сөйләшмәсәк, фикер уртаклашмасак, кирәк чакта үзебезнең катгый сүзләребезне әйтмәсәк, ни булыр? Җыр да бар бит:

Агай-эне—ак мыек,
Бер-беребезне какмыек.
Каккан-суккан чакларда да
Бер-беребезне яклыек.

Без барыбыз да аерым-аерым, "качып" эшли торган һөнәр ияләре. Озак "качып" йөргәннән соң агай-энеләрнең нишләп йөргәнен, ни уйлаганын беләсе килә. Үзен турында сөйлисе килә. Менә шундый чакта бергә җыелып аласың да рәхәтләнеп сөйләшәсең. Өнәп бетермәгән кешеләреңне дә сагынган буласың. Кеше табигатьтә көтү инстинкты белән яшәүче җан иясе. Көтү булып яшәсәк тә, көтүчеләрне ярatып бетермәүче "кәҗәләр" без. Шуна күрә безнең рәисләребез дә үзләрен чыбыркы аскан көтүче дип хис итмәсеннәр иде. Ә андый көтүчеләр булгалады арабызда. Көтүче роленә кергәч, үзләрен зур язучы дип тә уйлады кайбер бахырлар. Мин Язучылар берлеген без татарларга бигрәк тә кирәк оешма дип саныйм һәм аның җитәкчеләре безне татарлык идеясе тирәсендә берләштерергә, яшь талантларны барларга, аларга юл ачарга булышырга тиешләр дип уйлыйм.

**Р.Ф.:** *Кеше телиме-теләмиме, барыбер кемгәдер, нәрсәгәдер хезмәт итә ("Нәрсәгәдер" дигәнне ниндидер идея-максатка дип әйтүем). Ахыр чиктә, Синең иҗат та, минем һәм фәләннең иҗаты да җәмгыятьнең билгеле бер ихтыяҗларына хезмәт итә. Элек коммунистик партия әгъзалары идек... Хәзер дә төрле партияләр җитәрлек. Ялгышмасам, Син хәзер "Бердәм Россия" фиркасе әгъзасы. Депутат булып та шул партиядән үттең шикелле. Классик драматург, депутат, элеккеге коммунистның (берәр ел Язучылар оешмасының парторгы булып та тордың бит әле) бүгенге идеологик кредосы ниндән гыйбарәт?*

**Т.М.:** Идея дигән нәрсә бар. Шул сүз тамырыннан чыккандыр—идеал дигән төшенчә бар. Янә дә сәясәтчеләр ясаган идеология дә бар бит әле.

Белгәнем кадәренчә, коммунистик идеянең бер генә начарлыгы да юк. Кешеләр кайсы расадан, кайсы милләттән булуларына, тормыш баскычының кайсы басмасында басып торуларына карамастан—тигез хокуклы булырга тиешләр. Начармыни? Байлыкка шул байлыкны җитештерүчеләр хуҗа булырга, теге яки бу табигый шартлар аркасында кеше эшкә яраксыз икән, андыйлар җәмгыять тарафыннан якланырга тиешләр. Начармы? Безне бердәнбер сагайткан нәрсә—коммунистик идея дөньяны кирәгеннән артык материалләштерә—кешеләрне диннән аера. Ком-

мунистик идеянен кешеләрнең аңына үтеп керә алмавының сәбәбе бәлки шундадыр да. Ул идеал була алмады. Кешене рухыннан аерырга ярамый. Һәр идеяне дә яхшы яки начар максатта файдаланырга була. Рухы ярлы, белеме сай, күнеле саф булмаган кешеләр ин изге китабыбыз Коръән Кәримнән дә әшәкелек эзләделәр. Авыр булса да әйтергә туры килә, безнең бер өлкән язучыбыз "Коръән серләре" дигән әсәр язып изге китапны пычратты.

Коммунистик идеяне большевиклар ваклады, анардан үзләренең диктатурасын кертү идеологиясе ясадылар. Идеяне әкияткә әйләндерделәр. Без аңа ышанмый башладык. Коммунизм төзү идеясе мәзәк-анекдотлар материалына әверелде. Экономика законнарын белмәгән надан житәкчеләр хәерче СССРда егерме елдан коммунизм булачак дип игълан иттеләр. Хәер, кем белә, бәлки ул наданлыктан да булмагандыр, алданырга өйрәтелгән халыкны тагын бер тапкыр алдау өчен махсус уйланылган сәясәт булгандыр. Андый алдаулар күп күрелде шул. Шуны бүгенге сәясәтче "демократлар" бик оста файдаланып, властька менеп утырдылар. Коммунистик идеягә халыкны каршы куеп коммунистлар партиясен тараттылар. Әлбәттә, алдау ысулы белән эш йөрткән партия кайчан да булса бер таралырга тиеш иде. Ләкин мин чын күнелемнән ышанып әйтәм, коммунистик идеянең төп тәгълиматлары яшәргә тиеш. Ерткыч капитализмның акулаларына каршы үзенен дәлилле сүзен әйтеп барырлык көч яшәргә тиеш. Чөнки халыкны алдау бүген дә дәвам итә. Ләкин коммунистик идея өчен көрәшүчеләр, Дума депутатлары кебек, үзләренең шәхси мәнфәгатьләрен генә идея хисабына яклаучылар булырга тиеш түгел.

Күзәтүләрдән чыгып шундый нәтижәгә дә килдем әле мин: Рәсәй дигән дәүләттә нинди генә идея белән кайсы гына партия хакимияткә килмәсен—тулаем гомумхалык файдасына берни дә үзгәрми. Барысы да халык исеменнән властьны эләктереп алалар да халыкны онытталар. Шундый илдер инде бу, күрәсең.

**Р.Ф.:** *Син матди яктан каләм ияләре арасында иң хәлле (бай дисәң дә ярыйдыр) язучы. Газетадан укып белдем: бер елны Синең еллык керемен 1 млн. сумнан артык булган икән. Менә Син хәләл хезмәт һәм булдыклылыгың белән ирешкәнсең. Бик әйбәт. Язучы халкына да гел хәерче булырга димәгән. Акчаны Ирекка юл диләр. Асылда, ижат кешесе ирекле булырга тиеш тә. Матди бәйлелек мескенлеккә тарта. Бер шагыйребез юкка гына болай язмагандыр:*

*"Илһамлы каләме өстеннән*
*гомере буе*
*карап торды ипи кузе."*

*Син, минемчә, моннан азат. Ирек, ижат, жәмгыятьтәге урын кебек категорияләр (бәлки, төшенчә дип әйтергәдер) турында Синең кебек шәхес ни уйлый икән? (Ижат кешеләре дә төрле бит әле: музыкант, сынчы-архитектор, рәссам, артист һ.б.) Хәерче килеш олы сәнгать тудырып буламы?*

**Т.М.:** Әйе, булмый. Хәерче, теләнче шәхес була алмый, ә шәхес булмаган кеше ижат итә алмый. Әмма байлык та ижат итәргә бердәнбер гарантия түгел. Бай хәерче, бай теләнчеләр дә була—шуны да онытмыйк. Син мине бай дип атыйсын. (Шулай язып өйгә рэкетирлар жибәрмә тагын! Өебездә чын караклар кызыгырлык әйберләр юк.) Әлбәттә, мин акчасыз кеше түгел. Ләкин мин аңа табынмыйм. Кергәнен "туздыра" барам. Ничек туздырганымны оныкларым белә. Минем дә бит муеннан бурычка батып акчасыз утырган елларым бар иде. Акча миңа мирас булып калмады. Ул чакта да мин хәерче, теләнче булмадым. Иң авыр сугыш елларында, ачлыктан шешенгәндә дә әни безне теләнергә чыгармады. Анардан берәр әйбер сораганда да, "жыламый, шыншымыйча сора", дия иде. Бик тә яшәргә теләсәң, тырышасын инде ул, акчасы да табыла. Мин бит авыл баласы, бүген тапканны бүген кабып бетерүче түгел. Алдагысын да уйлыйсын. Бүген, мәсәлән, чын картлыгым турында да уйлыйм. Дөньяда мәгънәле итеп яшәргә тырыштым—шул гына.

"Ипи кузе" бөтенебезгә дә карап тора. Татарда хәерче язучы юктыр ул. Акчасы чамалылар күп, хәерчеләр юк, Аллага шөкер. Гомумән, хәерчелек, теләнчелек татарга хас сыйфат түгел. Жыламыйк.

Жан биргәнгә жүнен бирә—
Үзе яраткан Ходай,

—дип жырлыйлар безнең авылда.

**Р.Ф.:** *ПЭН-клуб эшчәнлегеннән бик азлар хәбәрдар. Халыкара бу оешма бүлегенең Татарстанда оештырылуына да ун елга якын. Оештырылган көннән башлап Син аның президенты саналасың. Бу оешма һәм аның эшчәнлеге турында укучыларыбызга беркадәр мәгълүмат бирсәң икән?*

**Т.М.:** Бу турыда, минемчә, байтак язылды инде. Гәҗит укыштырып, радио тыңлаштырып баручылар беләдер. Укымаганнарына сүз әрәм итеп сөйлисем килми, барыбер укымаячаклар. ПЭН-клуб безнең язучыларыбызның турыдан-туры чит илләр даирәсенә чыгып, татар әдәбияты, татар тарихы, татар кешесе белән бүтәннәрне таныштыручы оешма ул. Безне чит илләрдә белмиләр. Мәскәү безне чит илләр күзеннән яшереп саклады һәм саклый. ПЭН-клубның бердәнбер вазыйфасы шул. Арабызда шул оешмага каршы көрәшеп маташучы ахмаклар да булды. Нишләтәсең, анысы да татарлык.



*Шагыйрь Разил Вәлиев белән. 1998 ел.*

**Р.Ф.:** *Син Язучылар оешмасында рәислек иткән чорда "Татарстанның халык язучысы", "Татарстанның халык шагыйре" дигән исемнәр булдырылды. Югары оешмаларны шушы исем кертергә күндерден. 1986 елдан башлап 18 кешегә бирелде бу исем. Шуларның 11 е вафат, 7 се исән. Синең үзеңә дә бу исемне күптән бирергә кирәк дигән фикерләр булды. Имеш, Син үзең теләмисең икән... Хикмәт нәрсәдә? Гомумән, бу исем турында фикерең?*

**Т.М.:** Имеш, димә, Равил. Теләмәгәнемне Син үз колагың белән ишеттең. Роберт Миңнуллин "Безнең дәрәҗәгә төшәсе килми Туфан абыйның" дип төрттереп тә куйды. Анардан сенсация ясарга кирәкми. Сәбәбе бик гади—без андый исемне булдырырга йөргәндә аны бик сирәк язучыларга гына бирерләр дип уйлаган идек. Күп дигәндә өч-дүрт шагыйрь һәм язучы булыр дигән идек. Андый югары дәрәҗә өчен 18 кеше күп ул. Мин ул исемне йөрткән беркемне дә кимсетергә теләмим. Бары тик шул өч-дүрт арасына керергә үземне лаек түгел дип кенә саныйм. Әйткәнемчә, бүген миңа Туфан Миңнуллин дигән исем бик житкән. Дан өстәмәгән бүләккә кызыгырлык яшьтән узганмындыр ахрысы. Бөтен бүләкләрне, дәрәҗәле исемнәрне үзең белән алып китәргә язмасын иде.

**Р.Ф.:** *Бу әдәбиятка килгәндә, ягъни үткән гасырның 60 нчы еллар башы була инде бу, тулы бер аксакаллар төркеме бар иде. Г. Бәширов, Х. Туфан, Ш. Маннур, А. Шамов, И. Гази, С. Хәким, М. Әмир... Тагын биш-алты исем санарга була. Алар безнең өчен зур абруйлы шәхесләр иде, әйткән сүзләре дә канун кебек катгый иде. Без алардан беркадәр шүрли дә идек шикелле. Кылган гамәлләрне, язган-сызганнарны алар күзе белән дә карап бәяли идек... Аксакаллар бит! — алар ни әйтер?... Хәзер кайтып чагыштырып карыйм: аларга ул вакыт 50-60 яшь булган икән! Хәтта бүгенге бездән дә яшьрәк! Әйе, без дә шактый озын гомер кичереп киләбез, яшьләребез дә зур, ә аксакал була алдыкмы соң? Ата-бабаларыбыздан калган әхлак нормалары сакланамы хәзер? Замана бүтән булгач без үзебез дә бүтәнме, яшьләребез дә без теләгәнчә түгелме? Мин бу хакта еш уйланам. Синең фикерне дә беләсе иде!*

**Т.М.:** "Без яшь чакта сыерлар да мөгрәп кайталар иде көтүдән" дип әйткән ди колагы катыланган бер әбекәй. Дөнья шулай үзгәреп торадыр инде ул. Минем үземә дә еш кына андый уй килә. Без өлкәннәр вакландык бугай, элеккеләр саллырак фикерле булә, үзләрен мәртәбәлерәк итеп тоталар иде дип уйлыйм. Без

яшьләр тәртиплерәк, әдәплерәк идек дип тә әйтәсе килә. Уйлап-уйлап торам да элеккеләрнең дә кәефебезне җибәргән кайбер гамәлләре искә төшә. Мисаллар эзләмик, үткәннәргә селтәнүне мин егетлеккә санамыйм. Инде бүгенгегә килсәк, мин үземә аксакал дип караучы шактый яшьләрне беләм. Күп кенә язучылар Синең шигырьләрдән өзек алып үзләре язганнарга эпиграф итеп куялар. Кеше олгайгач үзенә күбрәк игътибар өмет итә. Элеккеләр әйбәтрәк иде дип фикер йөртү шуның нәтиҗәседер ул.

**Р.Ф.:** *Син көндәлек (вакытлы дип тә әйтәләр) матбугатта иң актив язышкан әдип. "Кызыл тышлы дәфтәр"дән сәхифәләр иң тиражлы, тәрбияви әһәмияте зур булган басмаларда бик еш басыла. Мин үзем аларны яратып укыйм. Халык та яратып танышып барадыр дип уйлыйм. Син аларны үз иҗатыңда нинди урын тота дип исәплисең?*

**Т.М.:** Үз иҗатына зур эш итеп караган язучының көндәлек алып бара торган дәфтәре бардыр ул. Чөнки бар күргәнне, ишеткәнне хәтердә саклап тору мөмкин түгел. Кемнәрдер көндәлеген күрсәтми, мин исә күрсәтердәйләрен матбугатка биреп барам. Мин аларны әдәби яктан эшкәртеп тә тормыйм. Тора-бара бу әдәбиятның публицистика дип аталган жанрында эшләү рәвешен алды. Аларны дөньяга чыгаручыларга рәхмәт, ошатып укучыларга рәхмәт.



*Гомәр Бәширов белән. 1988 ел.*

**Р.Ф.:** *Син кырык елдан артык "Казан утлары" журналының даими авторы. Озак еллар буе аның редколлегия әгъзасы да. Утырышларда, Синең белән аерым очрашуларда гел әйтә килəм: баш редактор буларак, ярты вакыт подписка-тираж мәсьәләләре белән шөгыльләнеп үтә. Хәзерге 6-7 мең тираж—бик күп оештыру эшләренең нәтиҗәсе. Шуна да карамастан, кимү тенденциясе дәвам итә. Шактый көч куеп чыгарган журналны күпләр укуын теләү—табигый хәл. Тираж—әдәбият язмышын күрсәткән фал. Син журналда эшләсәң, бу юнәлештә нинди гамәлләр кылыр идең? (Шуны да өстәп әйтим: туган ягың Кама Тамагында да журналны бик аз алдыралар. Чагыштырыр өчен: Сабада—300 данә, Кама Тамагында—27 данә).*

**Т.М.:** Соңгы җөмләне хакимият укый торган гәҗиткә дә яз әле. Бәлки файдасы тиеп, күбрәк язылырлар. Нишләтим инде ул язылмаганнарны. Мин, мәсәлән, татар телен һәм әдәбиятын укытучылар "Казан утлары"н укып барырга тиешләр дип саныйм. Бу аларның профессиональ мәҗбүри бурычлары. Районадагы һәр китапханә журналны алдырырга тиеш. Җыламасыннар укытучылар, "Казан утлары"н алдырырлык кына акча түләнә аларга. Аңламаган укытучыларга хакимият аңлатырга тиеш. Әгәр дә әдәбият укытучысы бүгенге әдәби процесстан хәбәрдар түгел икән, аның әдәбият укытырга хакы юк. Ә инде калган Кама Тамагы татарлары сабалылардан бераз көнләшсеннәр иде, бигүк надан түгел лә инде без.

**Р.Ф.:** *Классик Туфан Миңнуллин шәкертләр үстердеме? Булса, алар кемнәр?*

**Т.М.:** Шәкерт үстерү минем эшем түгел. Гомумән, әдәбиятта остазлыкны һәм шәкертлекне өнәмим. Һәр язучы әдәбиятка остаз сүзен кабатламыйча, үз сүзен әйтер өчен килергә тиеш. Без—өлкән буын аларга үз сүзен әйтер өчен шартлар тудырырга тиеш. Минем яратып әйтә торган бер сүзем бар: миннән яхшы язучыны

яратып бетермим *(чөнки көнләшәм)*, ә миннән начар язучыны женем сөйми. (Чөнки ул әдәбиятның әче дошманы). Мин киләчәк буынга фәлсәфи карыйм. Әгәр бездән соң татар язучылары килмәсә, безнең кирәгебез юк, без язганнарның кирәге калмаячак. Безне алыштыручы яшь буын бездән талантлырак булырга тиеш, бу—табигать законы. Һәр талантлы татар язучысы минем өчен бик тә кадерле. Талантлылар арасында үзенне кеше итеп тоясың. Сәләтсез һәм өстәвенә әрсез язучылардан Ходай сакласын.

**Р.Ф.:** *"Дус" сүзе бар. Бер ижекле генә...*
*Ә мәгънәсе—чиксез һәм тирән.*
*Әй, кыен шул асылын бу сүзнең*
*дөрес итеп аңлап бетерү!"*

*дип язган идем мин "Сәйдәш" поэмасында. "Дусларына карап үзенә бәһа бирерләр" дип тә әйткәлиләр. "Заманалар авыр, еллар ябык, дус-иш кирәк гомер итәргә!" дип жырлаган борынгыларыбыз һәм хәзер дә жырлыйбыз. Фикердәшләрең бармы, булса, дуслык мөнәсәбәтләре нинди критерийлардан чыгып корыла?*

**Т.М.:** Дуслык дигән төшенчә гомер үткән саен үзенең төсмерен үзгәртеп тора. Яшь чакта күп кешегә дус дип эндәшәсең. Шуңа күрә дусларның саны да күп була. Яши-яши кемнәрдер арбадан төшеп кала, йә син алар белән бер арбада утырып барырга теләмисең, йә сине утыртмый башлыйлар. Чөнки тормышка карашың житдиләнә барган саен, сайлана башлыйсың. Шешәдәшләр, әшнәләргә түгел, фикердәшләргә мохтажлык арта. Дуслык бит ул корбан да сорый торган нәрсә. Дустың дип санаган кешенә син һәрвакыт бурычлы. Ул бурычны дус дигәненнән түләтергә телисең икән, димәк, анда дуслык булмаган. Дус ул синең иң яшерен серләреннең дә сандыгы. Шуңа күрә, дусларым бар минем дип әйтергә күнел базмый. Якын иткән фикердәшләрем бар, Аллага шөкер. Табындашларым да аз түгел. Кешеләр арасында кешеләрчә яши беләмдер, ахрысы. Әш кешеләрен хөрмәт итәм, үзен шәхес дип санаганнарга якынаям. Кайчандыр дус булып йөреп тә, тормыш аерган замандашларымны онытмаска тырышам. Әйткәнемчә, бүген дустанә аралаша торган даирәм тарая бара. Марсель Сәлимжанов та вафат булды, Илдар Юзеев та юк инде, Шәүкәт Галиев белән дә сирәк очрашабыз, Альберт Яхинны да телефоннан гына ишетәм. Ләкин мин аларны һич онытмыйм. Гариф абый Ахуновны да сагынам. Әдәбият дөньясына кергәндә алар минем таянычым булдылар.

Бүген күбрәк үземнән яшьрәкләр белән аралашам. Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова... Алар белән миңа кызык.

Тормыш бит ул кызыклы нәрсә. Шагыйрьләр Роберт Әхмәтжанов, Мөдәррис Әгъләмов белән мин, мәсәлән, бер табын артында кочаклашып утыра алмыйм. Ләкин талантлары өчен хөрмәт итәм. Синең белән дә шулай. Алда әйтелгән шагыйрьләр белән аналогия үткәрергә теләмим. Әмма без икебез ике холыктагы кеше. Синең белән җәелеп



*Сулдан уңга: Башкортстан язучылары Әсгать Мирзаһитов, Марат Кәримов, Туфан Миңнуллин, Гариф Ахунов, Илдар Юзеев, Гөлшат Зәйнашева, Әңгам Атнабаев. 1970 ел.*

сөйләшеп утырган юк диярлек. Син һәрвакыт каядыр ашыгасың. Син безне каядыр үтеп барышлый гына күрәсең. Синең вакытың минутлап бүленгән. Җыелышларның, мәҗлесләрнең дә башында гына күренәсең дә югаласың. Син берәү белән дә якалашмыйсың, киеренке мөнәсәбәтләрне уратып үтә беләсең. Ә мин болганчык кеше. Син акыл белән яшәсәң, мин күбрәк хис белән яшим. Синең турыда төрле сүзләр дә ишеткәлим. Әмма мин сине хөрмәт итәм. Син талантлы милләттәшем. Милләт мәсьәләсендә, әдәбиятка карашта безнең фикерләр һәрвакыт диярлек тәңгәл килә. Татарның талантлы баласын холык-фигыленә игътибар итмичә хөрмәт итәргә тиеш без.

Ә инде якын итмәгәннәргә килгәндә, алар турында сөйләп торасым килми. Бар андыйлар. Ясалма кешеләрне яратмыйм. Киеренке мөнәсәбәтләрдә әдәп кагыйдәсен онытып пычракта аунарга яратучыларны җенем сөйми. Үзен дөньяның кендеге дип санаучылар да миңа юлдаш түгел. Алар еш кына мине үртәп, мине бәхәскә тартып кертергә маташалар. Андыйлар белән бәхәскә кереп вакланмыйм. Мин аларны күрмим генә. Минем өчен алар юк бәндәләр. Читтән караганда бәлки баламут кебегрәк күренәмдер, әмма корсакка төртеп сөйләшә башласалар усалланам.

**Р.Ф.:** *Менә мең елга бер туры килә торган (шөкер, ул безнең гомергә туры килде!) Казан юбилее да үтеп китте. Бу бәйрәм төрле кешедә төрле хис калдыргандыр. Әмма Казанның бу олуг юбилее тарихка гына күз төбәү түгел, киләчәк турында ныклап уйлану өчен бер җай да. Син Олы Мәрәтхуҗа улы булсаң да, Казан кешесе бит инде. Балалар белән, гомер белән шушы шәһәргә береккән. Казан—бөтендөнья татарларының карап торган мәркәзе. Киләчәк гасырларда да ул шулай булып калырмы?*

**Т.М.:** Әлбәттә, Казан безнең башкалабыз, мәркәзебез. Күзне төбәп карап торган үзәгебез. Аның тарихы да татар халкы тарихы. Дан тоткан, үзен якларга тырышкан, яклый алмаган, татарлыгын нык югалткан, тагын бер дәртләнеп селкенеп алган, янә дә сүрелә башлаган. 1000 ел дип ничә ел шаулыйбыз. Шулай кирәктер, зур юбилей бит. Әмма мин бүген ул бәйрәмне таралып, куанып бәйрәм итә алмыйм. Әллә ни булды минем белән, бәйрәмнәр кызык булмый башлады. Күбрәк уйландыра. Без үз-үзебезне юатыр өчендер инде, Болгар дәүләте, Алтын Урданың бөеклеген еш искә алабыз. Билгеле, тарихны белергә кирәк. Әмма үткәннәр белән генә яшәү бәхетсезләр шөгыле. Кызык түгел. Рәсәйне мин Ватаным дип әйтә алмыйм инде. Мине кирәксенмәгән ил миңа Ватан була алмый. Республика, җөмһүрият дип тә горурланырлык сәбәпләр кими бара. Соңгылары бигрәк күңелне төшерде. Латинга кайтуны сузып-сузып килдек тә баш казыгы куйдык. Милли югары уку йорты дип сөйләндек, ул идеяне дә үтерделәр. Үземне мин алданган кеше итеп хис итәм. Мәскәүне гаеплибез, гел Мәскәү генә дә түгелдер инде. Көрәшергә теләмәгән үзе егыла. Хәерле булсын. Казаныбыз 1000 еллык “исконный урыс шәһәре” булып калмагае. Мәскәүнең ул юбилейны зурлап бәйрәм итүе дә шуңа ишарәли шикелле. Бүтән мәсьәләләрдә безне зурларга ашыкмый бит. Ләкин мин аппатиягә бирелмәскә тырышам. Шагыйребезнең “Кисмәк өстенә каракош иттифакый кунган ул” дигән өмет белән үземнең рухи халәтемне саклыйм.

**Р.Ф.:** *Әдәбиятта, сәнгатьтә тәнкыйть дигән төшенчә бар. Төшенчә генә түгел, тәнкыйтьче дип аталып йөрүче һөнәри төркем бар. Алар үзләренчә хәрәкәттә: язалар, сөйлиләр, китаплар чыгаралар... Безнең турыда да—Синең белән минем иҗат турында диюем—байтак яздылар. Игътибарлары өчен рәхмәт, әлбәттә. Шулай да... Син үз иҗатыңда тәнкыйтьнең реаль тәэсирен, ягъни булышлыгын тойдыңмы? Гомумән, бүгенге көндә әдәби тәнкыйть Синеңчә нинди булырга тиеш?*

**Т.М.:** Кайдан килеп күрде икән татарга бу сүз? Үзенеке микән? Төп мәгънәсе нәрсәне аңлата икән: кемне дә булса салып таптаумы, әллә үтереп мактаумы? Бүген минем үземнең шәхсән тегесенә дә монысына да исем китми. Буласы—начармы, яхшымы—булган. Әдәби тәнкыйтьнең мин әйткән һәр ике формасы әдәби мохиткә яңа кереп баручыларга куркыныч. Иҗат кешесен таптап та, мактап та үтерергә мөмкин. Мисалларны Син дә, мин дә беләбез. Нинди генә булса да тәнкыйтьнең төбендә кешелеклелек ятарга тиештер. Тәнкыйтьнең оператив формасы бар. Ул

рецензияләр рәвешендә языла. Моны мин реклама дип кенә кабул итәм.

Әдәби тәнкыйтьнен чын асылы—анализдыр. Әйтик, язучыны теге яки бу әсәрне язарга нинди сәбәпләр этәргән, максатына ирешә алганмы язучы, ирешә алмаса, ни комачаулаган, бүгенге җәмгыять күзлегеннән караганда әһәмиятлеме язылган әсәр, язучы үз фикерен ни дәрәҗәдә осталык белән әйтә алган. Гомумәдәби процесста үз урыны бармы әсәрнең һәм башкалар, һәм башкалар. Мондый тәнкыйтьанализ теләсә кемне уйландыра. Син язучылык хезмәтенең ничаклы җаваплы икәнен янә бер тоясың, ягъни үз эшенә читтәнрәк карап бәя бирәсен. Бер кызыклы факт. Мин язган пьеса буенча куелган спектакльне карап утырам берзаман. *(Кайсы икәнен әйтмим.)* Шунда үзем дә сизмәстән онытылып китеп "болай язмыйлар!" дип кычкырып куйдым. Анализлы тәнкыйтьтән соң ул язучы "чыннан да болай язарга ярамый икән, төзәтергә кирәк", дип уйлансын, яки үзенең "дөрес язганына" инансын иде.

**Р.Ф.:** *Мәгълүм булганча, Татарстанда татарларның чиреге чамасы гына яши. Республикадан читтә яшәүче шул күпчелек кавем турында Син нәрсәләр уйлыйсың? Аларның күбесен милләтебез балалары санап без үз-үзебезне алдамыйбызмы? Байтагы үз телен оныткан, тарихи рухи тамырлар өзелгән... Аларны янә җыю мөмкинме? Мөмкин булса, нишләргә?*

**Т.М.:** Безнең кыска гына әңгәмәдә бу турыда нидер әйтү бик авыр. Бигрәк тә "нишләргә?" дигән сорауга җавап эзләве катлаулы мәсьәлә. Мин аңа җавап та бирә алмамдыр ахры. Татарның язмышыдыр инде ул сибелеп яшәү. Атилла бабаларыбыздан башлап Болгар, Алтын Урда дәүләтләреннән чиге дә очсыз-кырыйсыз. Алтын Урдадан ничә ханлык кына бүленеп чыккан. Бүген татар кайда гына яшәсә дә, нигездә, үз җирендә яши—килмешәк түгел. Мин инде Америка, Финляндия, Австралия ише илләрдә гомер кичерүчеләрне әйтмим. Аларны язмыш җиле сипкән. Үз илендә генә төпләнеп яшәүгә канәгать булмыйча кая да булса бару борынгы бабаларыбыздан калган инстинкттыр күрәсең. Менә шул татарны ничек татар итеп сакларга? Ничек бер идея тирәсенә тупларга? Безнең кебек үк җир шарының бөтен почмагында диярлек яшәгән яһүд халкы мона ирешә. Аңа инде югалу куркынычы янамый. Глобализация турында күбрәк алар сөйләсә дә алар бу эпидимиягә эләкмәячәк. Киресенчә, дөнья белән үзләре идарә итәргә җыеналар. Бәлки безгә алар моделен кулланыргадыр? Заманында бит "Татар үткән җирдә яһүдигә эш юк" дигәннәр. Бу сыйфатыбыз безнең әле дә күпмедер дәрәҗәдә саклана дип уйлыйм. Кайда кем булып эшләсә дә, татар югалып калмый, җаен, хәйләсен таба. Ләкин, ни кызганыч, татарлыгын яһүд кебек саклап калырга хәйләсе җитми. Бигрәк тә урыска үзен "ашата". Яһүд маржага өйләнсә дә, татарга кияүгә чыкса да яһүд туа, татардан—урыс туа. Югыйсә, эчке тотрыклылыгы ягыннан урыс татардан көчсезрәк.



*Сулдан уңга: Казакъ язучысы Сакен Жунусов, Туфан Миңнуллин, казакъ язучысы Шерхан Мөртазаев һәм Азат Абдуллин. 1986 ел.*

Без татар-башкорт мөнәсәбәтләрен куертып сөйләргә өйрәндек—татар башкортлаша дибез. Ә мин мона әллә ни борчылмыйм. Татарның мангаена башкорт дип язсаң да ул башкорт була алмый. Ә башкорт бик тиз татарлаша һәм урыслаша. Бүгенге башкортларны шул хафага сала да инде. Мин аларның хәлен аңлыйм.

Чуаш та, мари да була алмый татар. Инглиз, французга да әйләнмидер. Ә менә урыска әйләнә дә куя! Әллә соң урыс үзе дә татарга әйләндеме дип уйлап куям кайчакта. Бик тиз уртак тел табалар бит. Тел киртә булып тормый. Мин проблеманың сәяси ягына махсус кагылмадым. Чөнки Россия дигән илдә безне милләт буларак сакларга теләүче хакимият булмады һәм булмас та шикелле. Әлегә бездән "котылу" сәясәте көчәйгәннән-көчәя бара. Шушы шартларда саклану юлын табарга иде. Бу—Татарстаннан читтә яшәүче татарларга гына кагылмый, бу барыбыз өчен дә уртак проблема. Бездә "берләшик!" дигән чакыру еш әйтелә. Шул берләшүнең тормышка ашыру юлларын табарга, һәр форсаттан файдаланырга иде. Иң мөһим бурычларыбыз, бүгенге көндә иң актуале, минемчә, Мәскәүнең безне төрле этник төркемнәргә бүлеп таркатуына каршы торудыр. Әгәр дә, без—Казан татары, без—мишәр, без—себер, әчтерхан татары, без—типтәр, без—керәшен дип сөйләнсәк, тиз арада беребезнең дә калмавы бик ихтимал. Башкортлар белән бәхәсне тирәнгә җибәрмәскә иде. Экстремизмга һич ничек юл куярга ярамый. Аларның югарыда әйтелгән проблемасын безгә аңларга һәм аңлашырга кирәктер.

Бер куаныч—читтәге бик күп татарларыбыз Казанны үзләренең дә башкаласы дип саный. Шулай булгач Казанны чыннан да бөтен татарларның кыйбласы дәрәҗәсендә тотарга иде. Татарның иҗтимагый фикере мәдәнияте бары тик үзе таныган рухи башкаласында гына формалаша ала. Моны үзебез дә аңларга һәм бүтәннәргә дә аңлатып торырга тиешбез.

Бүген диннең йогынтысы көчәя бара. Мөселман татарлар да, керәшен татарлар да дингә милләт күзлегеннән дә карарга тиешләрдер. Төп динебез безнең ислам дине. Шул дин тирәсендә берләшкән хәлдә үзебезнең гарәп тә иранлы да түгеллегебезне онытмасак иде. Бүген мәчет-мәдрәсәләребезгә урыс теле кереп бара. Татар мәчетендә бөтен мөселманнарга уртак телдә—Коръән телендә булса, калган сөйләшүләр бары тик татарча гына булырга тиеш дип саныйм. Менә мәсәлән керәшен татарларының үз чиркәүләре булуы ошый. Бер керәшен апасының "ярый әле үз чиркәвебез булды, урыска әйләнеп бетә язган идек" дигәнен мин еш искә алам. Без бит интернационализмны башкаларны олылап үзебезне түбәнәйтү дип аңлый башладык.

**Р.Ф.:** *Галәттә әңгәмә ахырында бирелә торган традицион сорау: алдагы көннәргә нинди уй-планнар корып яшисен?*

**Т.М.:** Бер җыр искә төште:

Агыйдельнең аръягында
Күтәрелде томаннар.
Аерылырга түгел иде
Безнең корган планнар.

Әдәбияттан, театрдан аермасын иде Ходай. Яшьлектә язмасаң да "кызыклар" күп. Урам тулы чибәр кызлар—кайсына сүз кушсаң да килешә, мәҗлесләрдә "Алмагачы" көенә дә сиптерәсең, дусларның хисабы юк, сәламәтлек—корычтай. Картайгач... Әйтеп тормыйм инде. Бердәнбер кызык—язудыр. Хәтта әдәбият белән кызыксынып карамаганнар да картайгач яза башлыйлар. Язу бит әле ул үз-үзең белән сөйләшү дә, чөнки сине үзеннән башкалар тыңламый башлый. Кешеләр дә тыңлый алырлык әсәр язасы килә. Туктап булмастыр инде. Ул "чир" үзем белән бергә генә китәрдер. Әле менә дәртләнеп кино өчен сценарий язам. Рамил Төхфәтуллин "куябыз!" ди. Авызына бал да май. Тагынмы? Тагын да бар эшләр... Ходай гына күпсенә күрмәсен.



Марсель
Зарипов

# "ТАТНЕФТЬ"НЕҢ БЕНЗИН ЧИШМӘСЕ

Соңгы вагоны еракка китеп күмелгән поездның ишек баскычына сикереп менеп булмый, әмма тарих поездын куып узып була.

Түбән нефть промыселлары 1982 елның 30 сентябреннән башлап көн саен үз хәзинәләреннән берәр миллион тонна нефть һәм берәр миллиард куб метр табигый газ ала башлады, шулай итеп, ул төбәк илнең нефть табу өлкәсендәге алтын маягы булды. Аңа кадәр илнең төп нефть цехы Татарстан республикасы иде, ә менә нефтьне эшкәртү буенча тоткарланып калды ул. Төгәлрәк әйтсәк, артта калды. Моның сәбәпләре ни соң?

Сугыш елларында илнең нефть наркомы булган Николай Байбаков үзенең "Дело жизни" *("Гомерем эше")* дигән китабында күпләргә билгесез бер сөйләшүне исенә төшерә. Иосиф Сталин белән була ул сөйләшү һәм турыдан-туры нефть сәнәгате үсешенә, аерым алганда Татарстан төбәгендә нефтьне эшкәртү индустриясен оештыруга кагыла.

Егерменче гасыр азагында Татарстан нефть промыселлары "кара алтын" чыгару сәнәгатенең илле еллыгын билгеләп үттеләр. Республикада житмешенче елларда аякка баскан Казан "Органик синтез" заводы белән Түбән Кама нефть-химия сәнәгать үзәкләре тулы көчләренә эшлиләр иде инде. Бу мәһабәт предприятиеләр чималдан нефть-химия продуктлары эшләп чыгара, ә Татарстанда нефтьне беренчел эшкәртү мөмкинлеге юк иде. Илнең иң зур нефть төбәкләреннән берсе булган республика керосин, бензин, дизель ягулыгы, майлау кирәк-яракларын читтән ала килде. Акыл белән исәпләгәндә, чынлап та, сәер хәл бит — җир астыннан шулкадәрле нефть ташкыннарын суырт та, үзеңнең нефть продуктларың булмасын, имеш! Бу хәл белән ничек кызыксынмаска мөмкин ди соң?

Икенче бөтендөнья сугышы елларында совет промыселларында нефть чыгару ике тапкырга диярлек кимеде. Анык кына әйткәндә, унтугыз миллион тоннага гына калды. Нефть коточкыч житми башлады. Сталинның хәтере яхшы, ул әле союздаш илләр — Америка, Англия танкерларының хәрби конвойлар сагы астында немец су асты көймәләре мыжгып торган Атлантика сулары аша Мурманск белән Архангельскиның катмый торган төньяк портларына килеп йөргәннәрен дә, совет танклары Прохоровка кырларындагы каты сугышларда гитлерчыларның броняλы

Марсель ЗАРИПОВ *(1931) — публицист язучы; «Кара хәзинә», «Тәхет йөге» һ. б. китаплар авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

армадаларын нинди ягулык салынган моторлар белән каршы алганнарын да, моторларына ташкүмердән алынган ясалма ягулык салырга мәҗбүр булган немец эскадрилияләренең һавадагы өстенлекләрен юкка чыгаручы самолетларыбыз багында нинди бензин булганлыгын да яхшы хәтерли. Сугыш елларында Советлар иле үз аркадашларыннан танклар, самолетлар, хәрби корабльләр, паровозлар, трактор һәм автомобильләр, металл, шартлаткычлар, снарядлар, азык-төлек кенә алып тормый. Ул илләрдән кергән корал һәм башка сугыш кирәк-яраклары арасында 2,8 миллион тонна нефть продуктлары, шул исәптән сугышчан машиналарның моторларына салу өчен миллион тонна ярымнан артык ягулык та була. Бергәләп сугышу менә шундый ул. Берәүләр сугыш кырларында, гомерләрен дә аямыйча, канын түгә, икенчеләр исә уртак җиңү өчен "кара алтын" төялгән танкерларын җибәреп тора.

Әлбәттә, "бөек совет халкының юлбашчысы" Сталин Англия премьеры Черчилльнең сугыштан соң Америкадагы Фултон шәһәрендә, Көнбатыш илләрен советларга каршы салкын сугыш башларга чакырып, ялкынлы-мәкерле чыгыш ясаячагын алдан күреп тә бетермәгәндер, әмма гитлерчыларга каршы берләшкән аркадашларының мәкерлелеген чамалагандыр. Нефть наркомы Байбаков үзенең истәлекләрендә әле 1944 елда, фашист Германиясе белән сугыш тәмамланмаган чакта ук, Сталин белән булган тагын бер әңгәмәсе турында яза.

— Иптәш Байбаков, — ди Сталин, — ничек уйлыйсыз, союздаш илләр, сытарга мөмкинлек күрсәләр, безне сытып бетерерләрме?

— Ә ничек алар безне сытып бетерә алсын икән? — дип җавап бирә Байбаков.

— Бик гади генә. Безнең танкларыбыз, самолетларыбыз, машиналарыбыз бар. Немецлардан кулга төшергән хәрби техника да күп. Әмма, әгәр бензин, дизель ягулыгы булмаса, алар бит тимер тавы гына булып калачак. Нефть — хәрби техниканың җаны ул, бөтен икътисадның да җаны, дип тә өстәр идем.

Сталинның сугыштан соңгы стратегик күрсәтмәсе: кыска гына вакыт эчендә илдә нефть чыгаруны өч мәртәбә арттырып, сыек ягулыкның еллык табышын алтмыш миллион тоннага җиткерергә кирәк, дигәне менә шуннан килеп чыга да. Бу санны Сталин беренче тапкыр Мәскәүнең үз исемендәге районы сайлаучылары белән 1946 елның 9 февралендә очрашуда әйтә. "Без, — ди ул, — сәнәгатебездә ел саен 50 миллион тоннага кадәрле корыч, 500 миллион тонна ташкүмер, 60 миллион тонна нефть алуга ирешергә тиешбез. Бары тик шул чагында гына Ватаныбыз һәртөрле очраклы хәлләрдән сакланган булыр. Моңа, мөгаен, бер өч яңа бишьеллык кирәктер, әгәр дә артыграк та булмаса әле. Ләкин моны эшләп була, без моны эшләргә тиешбез".

Сталин әйткәнчә, "бөтен икътисадның җаны" булган кара алтын ташкыны совет илен һәртөрле көтелмәгән хәлләрдән сакларга, Көнбатышның нефтенә өметләнеп яшәүдән коткарырга тиеш иде. Әлбәттә, узган гасырның сиксәненче елларында совет промыселлары елына 640 миллион тонна нефть ала башлаганны Сталин күрсәтмәсе белән чагыштырсаң, ул әйткән 60 миллион тонна моның тик уннан бер өлеше кадәр генә. Ләкин ул заманнарда анысы да бик зур күрсәткеч иде.

Яшь нефть республикасы Татарстанның стратегик маяклары традицион: нефтьне чыгарып кына калмыйча, эшкәртергә дә кирәк. Дөрес, республикада нефть сәнәгатен үстерү турындагы Сталин кул куйган 1950 елның 28 апрелендәге директив документта әле нефть эшкәртү турында бер сүз дә әйтелми. Бөек җиңүдән соң Сталин бер үк вакытта партия Үзәк Комитетын да, совет хөкүмәтен дә җитәкли. Сталин күрсәтмәләре белән үтәп чыгылган беренче бишьеллыкларның удар төзелешләре, Идел буендагы, Курск дугасындагы җиңүләребез, Берлинның бирелүе, Татарстанда тормышка ашырылырга тиешле нефть программасы — болар һәммәсе дә иң вак нечкәлекләренә кадәр уйланылган эшләр. Ул заман өчен шактый зур булган уй-ниятләребезне тормышка ашыруны катлаулы халыкара хәлләр, күптән түгел генә гитлерчыларга каршы бергәләп көрәшкән илләрнең безгә каршы салкын сугыш башлап җибәрүләре таләп итә иде. Зур булмаган автономияле республика алдагы күп елларга илнең төп нефть цехы булып кала килде. Директив документта бу юнәлештәге эшләр тәфсилләп аңлатылган иде. Күпме төзелеш бүлекчәләре кирәк, алынган нефтьне саклый торган резервуарлар кайда булырга тиеш, бораулау системаларын кайлардан кайтартырга, нефть промыселы осталары булган тау эше

белгечләрен күпме әзерләргә, тирән скважиналар челтәрен кайсы нокталарда күтәрергә – болар һәммәсе билгеләнгән. Ә иң соңыннан, йомгаклау сүзендә, күпме нефть суырту мәслихәт булачагы әйтелгән.

Совет илен котылгысыз нефть катаклизмнарыннан саклап калырга тиешле стратегик программаның маяклары әнә шундый иде. 1950 елда Татарстан Шөгер һәм Баулы җирләреннән, Ромашкино мәйданнарының беренче нокталарыннан 640 мең тонна кара алтын суыртып алды. Әлбәттә, аз, бу ихтыяҗ артык зурдан иде шул. 1951 елга Сталин күрсәтмәсе республикада нефть алуны өч мәртәбә арттыруны таләп итә, ә алдагы елда исә аны 2 миллион 100 мең тоннага җиткерү бурычын куя иде. 1953 елда инде 3 миллион 300 мең тонна, 1955 елда 7 миллион тонна нефть алырга тиеш идек. Димәк, биш ел элек кенә ирешелгән күрсәткечләр унөч мәртәбә артачак дигән сүз бу. Әлбәттә, дөнья масштабында зур үсеш, аны безнең теләкният кенә түгел, халыкара сәяси хәл таләп итә иде.

Сугыштан соңгы беренче бишьеллыкта республикабыз нефть эшкәртүнең үз нигезен булдыру бурычын куймый иде әле, эшләп торган заводларны тәэмин итә алу да зур көч сорый иде. Ниятләгән программа бетәр-бетмәстән, Сталин Татарстан нефть промыселларына тагын да югарырак стратегик бурыч куйды: нефть алуны элекке документта күрсәтелгән унөч тапкыр арттыру урынына егерме өч тапкырга арттыру сорала иде. Димәк, республиканың җир куеныннан җиде миллион гына түгел, ә унбиш миллион тонна нефтьне кысып чыгарырга кирәк иде.

Элекке нефть программасын болай тиз һәм акылга сыймаслык итеп яңадан үзгәртү турында Казан журналисты Валентин Белокопытов белән сөйләшеп утырганда "Татнефть" берләшмәсенең беренче житәкчесе Алексей Шмарев болайрак искә ала: "Декабрь азакларында без, узып барган елның йомгаклары, киләсе ел максатлары турында сөйләшү өчен, гадәттә партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре З. И. Моратов белән очраша идек. Бу юлы Зиннәт Ибәтович Ромашкинодагы һәм башка ятмалардагы запасларның исәбе алынганмы-юкмы икәнлеге белән кызыксынды. Мин бу эшнең шушы көннәрдә төгәлләнгәнлеген әйттем. Соңгы нәтиҗәләр без элек фараз кылганнан өч мәртәбә артык иде. Зиннәт Ибәтович моңа бик шатланды, шунда ук туры элемтә аша партия Үзәк Комитетына – Маленковка шылтыратты: "Георгий Максимилианович, сез кичә Татарстанның киләчәктә нефть чыгаруны күпмегә арттыра алу мөмкинлеге белән кызыксынган идегез. "Татнефть" берләшмәсе башлыгы белән *(ул минем янымда утыра)* без сезгә шатланып белдерәбез: тәмам ачыклангач, нефть запасларыбыз элек министрлыкка күрсәткән фаразлардан өч мәртәбә артык булып чыга". Ул, телефон трубкасын кулы белән каплап: "Георгий Максимилианович без әйткән саннарны Бериягә хәбәр итә", – ди.

Яңадан Мәскәү белән сөйләшә: "Аңладым, Георгий Максимилианович. Икәү барырбыз". "Аннары күңелсез генә итеп миңа әйтә: "Иртәгә көндезге сәгать өчкә безне Берия чакыра", – ди. "Лубянкагамы?" – дип кызыксынам. "Кремльгә", – дип җавап бирә Моратов, шаяртып өстәп куя: "Әлегә..."

Күңелдә шом кузгалды. Хрущевның ябык хатында Булганинның әйткән сүзләре китерелгән: "Сталинга керергә барсаң, аннан кулга алынмыйча әйләнеп чыгарыңа ышаныч юк иде". Кремльгә Берия белән очрашуга барганда Моратов белән минем дә кәеф шундыйрак булды.

Нефть сәнәгате министры Н. К. Байбаков та чакырулы иде.

Барып керүгә, әфлисун төсендәге кызгылт-сары күн куртка кигән симез йозле, алтын күзлекле Берия шунда ук аңа ташланды: "Министр, әйт әле, Татариядәге нефть запасларың күпме синең?" Байбаков безнең элек фаразлаган санны әйтте. "Ә хәзер, Шмарев, син әйт".

КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы һәм Министрлар Кабинетында нефть эшләрен күзәтеп торучы Бериягә без алданрак кергән идек. Аңа Маленковка белдергән санны кабатлаудан башка юл калмаган иде. Мин ике санның ни өчен төрлечә булуын аңлатмакчы булдым. Берия мине кырт кисте: "Күрәсеңме, Татариядә нефть өч мәртәбә күбрәк. Син, министр, белмисең. Ә сиңа буйсынып эшләүчең белә. Син нәрсә белән шогыльләнәсең соң? Син безне саташтырып-буташтырып бетердең бит!" – диде.

Эчебезгә салкын йөгерде.

Үтергеч тынлыктан соң Берия: "СССР Министрлар Советының Татариядә нефть чыгаруны арттыру турындагы карар проектын әзерләгез. Истә тотыгыз, үсеш шактый сизелерлек булсын. Ул нефтьне кайда, ничек бушатып торуны без үзебез кайгыртырбыз, металлурглар өстәмә нефтьне сыйдырырлык бакларны ясап өлгертерләр", — диде.

Дөрес, үзгәртеп эшләнгән бу программаны республика үтәп чыга алмады — 1955 елда Татарстан промыселлары илгә 13,2 миллион тонна нефть бирде. Әмма төбәкнең һәм бөтен совет икътисадының ул чордагы бик артык зур булмаган мөмкинлекләреннән чыгып караганда, мондый үсеш тә дөнья казанышларына тиңләшерлек иде.

Ләкин иң мөһиме шул булды: нефть мәсьәләләренә кагылышлы 1952 елгы директив күрсәтмәдә беренче мәртәбә республика алдына алынган нефтьне эшкәртү бурычы да куелды. Без аны, документ буларак, русча китерәбез:

*"В целях обеспечения переработки нефти, добываемой в Татарской и Башкирской АССР, и необходимого развития в центральных и восточных районах страны базы по производству авиационных топлив, масел и автотракторного горючего, обязать Министерство нефтяной промышленности (т.Байбакова) ...расширить мощности действующих нефтеперерабатывающих заводов и построить новые заводы, в первую очередь в районах добычи нефти — Татарии и Башкирии.*

*Председатель Совета Министров Союза ССР — И. Сталин*
*Управляющий Делами Совета Министров СССР — М. Помазнев.*
*24 марта 1952 года".*

Республиканың нефть эшкәртү мөмкинлеген исәпкә алмыйча төзелгән программа Ромашкино ятмаларының запасы якынча берничә дистә миллион тонна чамасы булыр дип бәяләнгән чагында кабул ителгән иде. Җир асты байлыклары запасын дөньякүләм күрсәткечләрдә исәпләгәндә, бу саннар зур түгел иде. Әмма ике елдан соң геологлар тагын да төгәлрәк саннар китерделәр, Ромашкиноның җир асты хәзинәсе ике миллиард тоннадан да артып китә, диделәр. Мондый гаять зур байлык бөтен дөньяда да, булса, бер уннан артмыйдыр, мөгаен.

Дөрләп барган салкын сугыш заманнарында, нефтькә бик зур кытлык булган чагында, әлеге баш әйләндергеч куанычлы мәгълүматларны алгач, совет хөкүмәте нишләргә тиеш иде? Авырлыкларга да карамастан, нефтьне суыртудан тыш, аны эшкәртергә — якын һәм ерак максатлар куеп, аннан моторлар һәм мичләр өчен ягулыклар гына алмыйча, башка төрле нефть-химия эшләнмәләре дә булдырырга кирәк бит. Әгәр дә төгәенләп әйтсәк, республика алдына бик зур бурычлар куела. "Җир маеннан" күп нәрсәләр эшләп чыгару бер республика кулыннан гына килә торган эш түгел. Әле башлап ил вә дөнья сәнәгатенең традицион булган бензинын, керосинын, дизель һәм мич ягулыкларын, легроин, майлау кирәк-яракларын җитештерсәң дә ярап торыр иде. Аннары инде тагын да катлаулырак, тагын да отышлырак эшкә тотынып, чималны күкертле-водородлы яңа матдәләргә таркатырга да була. Нәрсәләргәме? Әйтик, гап-гадиләре — метан, пропан, бутан, пентанга. Алардан соң этилен, пропилен, амилен җитештерәсең. Өченче киштәгә ацетилен, амилен, кротонилен, валирелен куелса, дүртенчесендә бензол, толулол, ксилол, кумол кебекләре булыр. Баш бу алып бетәрлек ике дистәгә якын бу ярымфабрикатлардан сәнәгатьтә нефть химиясе нигезендә әллә нәрсәләр ясап була. Нәрсәләрме? Әйтик, метаннан ванна бүлмәләре өчен пәрдәләр, төрле торбалар, җилемле-ябышкак әйберләр, пластмассалар, синтетик каучук, төрле эреткечләр, суыта торган матдәләр, янгын сүндергечләр, фармацевтика товарлары, вискоза һ. б. алырга мөмкин. Этан дигәне дә юыну кирәк-яраклары, серкә кислот[illegible]ы, антифризлар, буяулар, янә дә пластмассаның аерым төрләре, төзү-бәйләү әйберләре, поливинхлорид һәм пенопласт ишеләргә чимал була. Пропан, бутан, бензол, толулол һәм ... көл турында да берике сүз әйтик тә, туктарбыз. Пропан кыстырып-тыгызландырып калдырырга бик уңайлы әйберләр өчен, эпонид сумалага, янә дә юу кирәк-яракларына, изоляция материалларына, автомобильләрнең эчен җиһазлауга тотыла. Чөнки ул янмый диярлек. Бутан — анысы нейлон, пластмассалар, янә синтетик каучук, лаклар эреткеч,

оргпыяла, шиннар һәм башкалар... Бензолдан да төрле сумалалар, фармацевтика әшләнмәләре, нейлон, төрле көймәләр, автомобильләргә запас частьләр, буяулар, агулый торган инсектицидлар ясыйлар. Толуолдан ясалма тукымалар, шартлаткыч матдәләр, янә буяу эреткечләр эшләнә. Ксилолыннан да буяулар ясау өчен сумалалар, ныклы пластмассалар, полиэфир тукымалар алалар. Махсус мичләрдә яндырылган нефть көленнән резин шиннар һәм янә дә пластмассалар ясыйлар.

Болар әле башлангычы гына. Хәзерге нефть-химия сәнәгатенең мөмкинлекләре санап бетерерлек кенә түгел. Алардан бик кирәкле металл, агач, күн, мех, тукымалар, хәзерге заманны алардан башка күз алдына да китереп булмый торган әйберләр эшләнә. Иген бөртеге белән он икмәк пешергәндә нигез генә булган шикелле, күкертле водород чималлары да башка җитештерү тармакларына бары тик нигез генә булып тора.

Сталин билгеләгән вакыт бик кыска-кырыс була. Кремль хуҗасы эленке-салынкы йөргәнне, эшне тарта-суза гына маташтырганны яратмый, фронттагы кебек тиз, төгәл һәм нәтиҗәле эшләүне таләп итә ул. Татарстанда нефть эшкәртү сәнәгатен кузгату да, скважиналарны бораулагандагы шикелле, бик тиз башланып китә. Казанга якын гына Столбище авылы янында кирәкле мәйданчыкны сайлап алалар, тиешле тикшеренүләрне үткәргәч, Грозныйдан килгән белгечләр тиешле техник документларын әзерли. Булачак нефть эшкәртү комплексына директор билгеләп, төзелешне башлап җибәрәсе генә кала. Директорлыкка партия өлкә комитетының нефть тармагы секретаре Сергей Князев атлыгып тора. Әмма Сталин бер ел дигәндә үлеп китә, аның ихтыярын санга сукмаучылар да табыла, билгеләнгән программаны тикшерү-сүтү башлана. Иң әүвәл, урын дөрес сайланганмы, дигән шик туа. Әйтерсең, аны башка җиргә күчерү бик авыр эш. Аннары Татарстанда нефть эшкәртү сәнәгатен оештыру кирәкме икән, аңа нефть чыгару төбәге булу, нефть чималын алу даны да бик җиткән, диючеләр дә күренә.

Вакыйгаларның алга таба ничек дәвам итүе кызыклы. Директив күрсәтмәләрдә аталган нефть эшкәртү заводлары Башкортстанда төзелә. Бүген аларның куәте илле биш миллион тонна нефть эшкәртергә җитәрлек, ә үзләрендәге нефть өч мәртәбә ким алына. Алар хәзер Себер ятмаларыннан табылган хәзинәне эшкәртү белән мәшгуль. Мисалга, Россиянең иң зур компанияләреннән берсе булган "Лукойл" Башкортстанга ел саен алты миллион тонна нефть җибәреп килә. Татарстан исә Сталин күрсәтмәләрен гамәлгә ашыруда соңлый, бары тик, мәйданчыгын сайлаганнан соң, проект документларын әзерләргә генә өлгерә һәм ... нефть чыгаручы төбәк кенә булып кала.

Нефть һәм нефтьне эшкәртү — юкса бер-берсе белән бик тыгыз тоташкан ике савыт шикелле генә бит. Әмма чылбырның кайсыдыр бер җире өзелгән, сыеклыклар икесе дә бер тигезлектә була алмаган, берсе икенчесеннән биегрәк булып чыккан.

Ә ул замандагы нефть белгечләре ни-нәрсә уйлаганнардыр, хәзер инде әйтүе дә кыен. Әмма дөреслек шул — республикабыз үз нефть ятмаларын кузгата башлаган беренче елларда ук нефть эшкәртү сәнәгатеннән читенгән, бары тик аны чыгару белән генә чикләнгән, эшкә җигелергә тиешле корылмаларын башка төбәкләргә озатып бетергән. Үз җирләреннән суырткан нефть өч миллиард тоннага якынлашкан Татарстан илле ел буена алга киткән башка төбәкләргә чимал озатучы булып кына кала бирә. Әлмәт — Пермь, Әлмәт — Түбән Новгород, Әлмәт — Самара, Ромашкино — Келәүле, халыкара "Дуслык" магистрале — җир асты торбаларыннан менә кайларга озатыла Татарстанның "җир мае"...

Тарихи вакыйгаларны тикшергәндә: "Шулай булган булса, болай булган булса..." дип фаразларга тиеш түгел. Тарихны күчереп язган саен тарихи вакыйгаларны чиста битләрдән генә башламыйлар. Чынлап та, аерым вакыйгалар барышында, мисал өчен, дөньядагы иң эре нефть дәүләте булган советлар иле дөнья компанияләре таянган кагыйдәләргә буйсынып эшләсә, хәл бөтенләй башкача булыр иде. "Кара алтын" ала башлаган беренче көннәреннән үк ул үз алдына нефтьне эшкәртү бурычын да куйган булса... Американың нефть магнаты Джон Рокфеллер үз эшен нәкъ шулай башлап җибәргән, аннары гына башка нефть промыселларын үз кул астына алган. Шулай эшләнгән булса, Татарстанның нефть-химия үзәкләренең берсе булган Түбән Каманың да тарихы күп алданрак башланыр иде.

1952 елгы карар тормышка ашырылса, каләм-кәгазь осталары – журналистлар да Түбән Кама турында түгел, ә нефтехимикларның Столбище дигән шәһәре турында язарлар иде.

Вакыт дигәнең – дус та, дошман да ул. Уңышлы гамәлләренең бәхетле мизгелләрен җуймаган кешеләргә – дус, ә төрле сәбәпләр аркасында булса да уңайлы мизгелләрен файдалана белмәүчеләр өчен – дошман. Бер еллык нефть табышы 60 миллион тонна булырга тиеш, дип күрсәткән директив документта Сталинның ни өчен нәкъ шушы санга тукталуы әйтелмәгән. Алтмыш миллион тонна нефть... Аның чиреге Татарстан промыселларына туры килә. Сталин, күрәсең, үзеннән соң киләчәк юлбашчыларның икътисади уй-ниятләрен чамалап бетерә алмагандыр. Алар исә, Такташча әйткәндә, "башларыннан инде коммунизм кыры күренә" дигән алдавычка ышанып, чи нефтьне чит илләргә шул килеш сата һәм шуның белән илнең финанс хәлен яхшыртмакчы була. Ә башка илләр чит илләргә аны саны һәм сыйфаты белән аерылып торган, хезмәт көче кергән товарлар итеп кенә сата. Горбачевның үзгәртеп кору реформалары чорында нефтьчеләр Сталин күрсәтмәләрен ун мәртәбәдән дә арттырып, ел саен 630-640 миллион тонна нефть ала килделәр, ә ил, нәкъ сугыштан соңгы еллардагы шикелле, һаман да нефтькә туймады. Ни өчен?

Фараз кылынган якынча җаваплар болай. Кызганыч ки, геологларның әүвәл илнең үзәгендә икътисади яктан иң отышлы булган Башкортстан, Татарстан республикалары, Самара, Пермь, Оренбург өлкәләре, аннан соң килеп Көнбатыш Себер нефть ятмаларын ачулары күп кенә җитәкчеләрнең башларын әйләндереп җибәрде. Әйләндермәслек тә түгел бит: бер Көнбатыш Себердә генә дә бетмәс-төкәнмәс шикелле тоелган ике йөздән артык зурдан да зур нефть ятмасы табылды ич! Бишьеллык арты бишьеллык үткәргән социализм иле, табылган нефть байлыкларын үзендә эшкәртмичә, чи нефтьне чит илләргә сатып, аның каймагын да ала алмый калды. 1970 елда ил чит илләргә 67 миллион тонна чи нефть һәм 29 миллион тонна нефть продуктлары озатты. Шакката хәл. Советлар иле Көнбатышка нефтьне күбрәк озаткан саен аның базар бәясе төшә барды һәм үзебезнең кесәгә суга торды. Дәүләт казнасының валюта запасын тулыландыру өчен бер тонна нефть урынына ике тонна сатарга туры килә иде. Нефть табу сәнәгатенә төшкән йөк авырайганнан авырая бара, ачылган запаслар кимегәннән кими, иң яманы – аның сыйфаты да начарая иде. Шуңа күрә чираттагы һәр тонна нефтьне чыгару күбрәк хезмәт һәм чыгымнар таләп итеп торды. Бу хәл, бу стратегик озын баскыч зур өметләр багланган "коммунизм кырларына" түгел, ә озакламый килеп туачак кыен хәлгә – кризис упкынына алып бара иде.

1966 – 1970 елларда Көнбатыш Себердәге нефть ятмаларын үзләштерү башланды. Нефть сәнәгате министрлыгы бу эшкә 9,2 триллион сум акча сарыф итте. Аннан соңгы бишьеллыкта чыгымнар ике мәртәбә диярлек күбрәк – 18 триллионнан артык булды. Алдагы бишьеллыкта ул 25,3 триллион сумга җитсә, 1981 – 1985 елларда 42 триллион сумга якынлашты. Илнең яңа җитәкчесе Михаил Горбачев үзгәртеп коруны игълан иткәч тә нефть сәнәгатендә үзгәрешләр булмады. Ил һаман да нефть чыгаруны арттыру, сатуны көчәйтү юлыннан баруын дәвам итте. Биш ел эчендә нефть эшенә 80 триллион сум чамасы акча сарыф ителсә дә, ул инде котылгысыз һәлакәттән коткарып кала алмый иде. Бик көчәнеп-көчәнеп тә нефть чыгару чирек гасырда бары тик 2,2 тапкыр гына үсте, ә чыгымнар 8,5 мәртәбә артты. Хәвефле кыңгырау гына түгел, чаң кагар вакыт җитте – нефть чыгару кими башлады, зур өметләр баглап торган Көнбатыш Себер җирләре үзгәртеп кору елларында беренче тапкыр планын ун миллион тоннага үтәп җиткерә алмады.

Партиянең генераль секретаре Михаил Горбачев, нефть эшендәге иң зур түрәләрне, үзенең киңәшчеләрен-вәзирләрен ияртеп, Себер промыселларын айкап йөрде, яңа үсеш таләп итте. Бер иш нефть генералларын – егерме өч кешене эшеннән алып ташлады, кемнәргәдер орденнар да таккан булды, әмма файдасы тимәде. Дәүләтнең чимал сатып кына яшәү сәясәте өчен җавап бирер вакыт җитте. Нефть командирлары директив күрсәтмәләрне үтәргә никадәр тырышсалар да, яңа скважиналар бораулау искеләреннән чыккан нефть күләменең кимүен каплый алмады.

Нефть сатудан кергән долларлар нефть ятмаларын үзләштерү өчен кирәкле техника һәм материаллар алуга, чит илләрдә совет нефтеннән ясалган әйберләрне кертүгә китеп бара, алар өчен чимал сатудан алган табыштан күп артык чыгымнар сорала иде.

Әлбәттә, дәүләт икътисады җәһәтеннән караганда, нефть чималын кайда эшкәртеп файда күрсәң дә барыбер: аңа Пермь өлкәсе ни дә, Татарстан җирләре ни. Ләкин үзәк хакимият күзлегеннән тыш җирле мәнфәгатьләр дә бар бит әле. Татарстанны нефть чималы биреп торучы итеп кенә калдыру икътисади яктан файдалы түгел, әхлакый яктан исә оят та иде. Урындагы җитәкчеләр, төбәкнең матди һәм әхлакый югалтулары күп, халык хуҗалыгына зур зыян килә, дип, башкаланың төрле ишекләрен кага башладылар, нефть стратегиясен яңадан карауны таләп иттеләр. Әмма поезд киткән иде шул инде...

Сталинның 1952 елгы күрсәтмәләреннән соң сигез ел үтә. Төп нефть төбәге булган Татарстан илдә нефть чыгару артымының дүрттән өч өлешен диярлек бирүзе биреп килә. Шушы тарихи чорда Түбән Кама нефть-химия заводларын проектлаштыру эшләре башлана. Татарстан совнархозы рәисе Алексей Шмарев 1960 елның 18 февралендә Россиянең Министрлар Советына, комбинатта махсус нефть эшкәртү комплексы да булсын иде, дигән мөрәҗәгать юллый. Аның тәкъдимен кире кагалар. Шул ук тәкъдимне партия съездында КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табеев та кабатлый. Ләкин ишетергә теләүче табылмый. Фикрәт Табеев СССР халык хуҗалыгы Югары Советы рәисе Д. Устиновка дәлилле хат юллый. Ул хат бер бүлмәдән икенчесенә күчеп йөри башлый. Йөри торгач, ниһаять, шундый документ барлыкка килә:

*"Татарстан АССРның Түбән Кама районында ягулык (мазут) өчен нефть эшкәртү заводы төзү турында карар кабул итәргә, нефть эшкәртү корылмаларының беренче чиратын 1971 – 1972 елларда 6,0 миллион тонна эшкәртерлек итеп гамәлгә кертергә".*

Тарих поезды алга чапканда, Татарстан озак еллар буена бары тик углеводород чималы биреп торучы гына булып, нефть перронында басып калды. Ни хәлләр итмәк кирәк?..

Ел арты ел үтә торгач, ярты гасыр узып та китте. Бу елларда республика нефтьчеләре, җиде ел дәвамында беренчелекне кулларыннан ычкындырмыйча, 100 миллион тоннадан артык нефть биреп килделәр. Илдә алына торган "кара алтын"ның күләме исә 600 миллион тоннадан артып китте. Әмма илнең нефть сәнәгате сәясәте тамчы да үзгәрмәде. Татарстан гомергә башка нефть эшкәртүче төбәкләргә чимал җитештереп торырга дучар ителде.

Дөрес, 1977 елда куәте җиде миллион тоннага исәпләнгән нефть эшкәртү заводын алай да эшләтеп җибәрделәр. Әмма ул да Түбән Камадагы этилен комплексына турыдан-туры бензин куып тору өчен генә кирәк иде. Казан белән Эстәрлетамак органик синтез заводларына да, Европада иң зур саналган Зәй ГРЭСына да, үз ТЭЦларына да өлеш чыкты—аларга ягулык мазут бирә башладылар.

1986 елда мазут җитештерүче корылмаларны зурайтырга тырышып карадылар. Ләкин ул вакытта инде республика җирләре аша Төмән газын Европага ук җибәрү өчен җир асты торбалары салынган иде. Зәй ГРЭСын һәм урындагы ТЭЦларны әнә шул зур Себер торбасына ялгадылар да куйдылар. Газ газ инде—файдалырак та, чистарак та. Түбән Кама мазуты кирәкми башлады, аны цистерналар белән илнең төрле почмакларына озатырга кирәк булып чыкты.

Мизгелләр озак тоелса да, еллар тиз үтә. Нефтьне эшкәртү мәсьәләсе дә һаман бер урында тора бирде. Юкса Россия Президенты Владимир Путин, чит илләргә чимал гына сатудан туктап, сыйфатлы эшләнмәләр чыгарырга кирәк, дип чакырса да, гамәлдә ул уй-ниятләр тормышка ашырылмый кала әле.

Нефть төбәкләренең берсе булган республикабызның нефтьне эшкәртү турындагы башлангыч уй-ниятләре дә үзәк хакимиятне кызыксындырмый. Без бары тик үз көчебезгә генә таянырга тиешбез, ә финанс мөмкинлекләребез бик чикле. Шулай да, уйга батып утырганчы эшкә тотыну мәслихәттер. Алга! Кыюларга юллар ачык!

1997 елның 25 октябрендә Президентыбыз Минтимер Шәймиев Түбән Камада

төзеләчәк нефть эшкәртү заводының нигезенә беренче ташны салды. Янә ике айдан соң "Түбән Кама нефть эшкәртү заводы" дигән мөстәкыйль акционерлар җәмгыяте оешты. Бу эшкә алынучы көрәштәшләр һәм фикердәшләр—"Татнефть", Түбән Кама "Нефтехим", "Татнефтепродукт" акционерлык җәмгыятьләре, Казан "Оргсинтез"ы, "Таиф" фирмасы, "Татнефтехиминвестхолдинг" һәм "Нефтек-Техно" компанияләре.

Ләкин 1998 елгы дефолт *(акча арзанаю)* тез астына китереп сукты. Якты өметләр ишелеп төште—компаньоннарның финанс запаслары юк иде. Нефтьне эшкәртү турындагы уй-ниятләр игълан ителеп ике ел үткәч, 1999 елның ахырына заводны төзү эшләре нибары өч процентка гына үтәлде. Нишләргә? Үзебезнең нефтьне эшкәртү сәнәгатеннән баш тартып, һаман да чималны читкә озатып утырыргамы?

Инде бу уй-ниятләр барып чыкмый икән, башка юлларын эзләргә кирәк иде. Шулай иттеләр дә. Республика җитәкчелеге "Татнефть" компаниясенә төп заказчы җаваплылыгы белән бергә төзелеп килгән заводның акцияләре контроль пакетын да тапшырды. Аны төп инвестор итте. Димәк, заводка ул хуҗа була. Табигый ки, төзелеп ятучы һәм гамәлдәге Түбән Кама нефть эшкәртү заводын "Татнефть" акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Шәфәгать Тәхәветдинев җитәкләде.

"Татнефть"нең беренче илле еллыгы нефть чыгару, шуңа бәйле рәвештә запасларны эзләү-разведка эшләре, скважиналар бораулау, алынган нефтьне җыеп саклау һәм тиешле урыннарга озату корылмалары төзү белән үтсә, икенче илле еллыгы хуҗалык стратегиясен тамырдан үзгәртү—нефть-химия проектлары, чималны мотор һәм төрле мичләргә ягулык итеп кенә тотмыйча, аңардан тагын да файдалырак табыш алу ниятенә багышланды. Махсус бүлекчә—"Татнефть-Нефтехим" компаниясе оештырылды, ул инде нефть-химия предприятиеләренең нефть промыселлары өчен эшлекле штаб та булды. "Татнефть" Украинадагы Кременчуг нефть эшкәртү заводы белән берлектә эшли башлады. Бу БДБ илләрендә күп күкертле авыр нефтьне эшкәртеп чыгаручы бердәнбер завод иде. Тула һәм Ярославль өлкәләрендә нефтьчеләребез Ефремов синтетик каучук заводы белән "Ярполимер" акционерлык җәмгыяте акцияләренең контроль пакетларын үз кулларына алдылар. Аннары Түбән Кама шин акционерлык җәмгыятенең технологик цехларын үзгәртеп коруга акча салдылар. Анда исә Россиядәге автомобиль шиннарының дүрттән бер өлеше җитештерелә. Шуннан соң техник углевод заводы акцияләренең контроль пакетына да ия булдылар. Бердәнбер кышкы нефть-майлау комплексын төзүдә төп инвестор булып та, төзү эшләренә катнашып та күп гамәлләр башкардылар. Компаниянең соңгы иң уңышлы адымы Төркиядәге "Тюрпаш" нефть эшкәртү заводларының өчесен яулап алу булды.

1999 елның ахырыннан 2002 елның ахырына кадәр, ниһаять, Түбән Кама нефть эшкәртү заводының күптән көтелгән база комплексы эшкә җибәрелде. Аңа 11 миллиард сум акча салдылар, шуның 7 миллиардын нефтьчеләр түләде. Кем акча түли, шул хуҗа: завод Түбән Кама "Нефтехим" акционерлык җәмгыяте белән технологик бәйләнештә торса да, ул "Татнефть"-"Нефтехим" бүлекчәләренә карый.

Заводны эшләтеп җибәргәннән соң бер ел үтте. Римнан нефть эшкәртү компанияләренең Бөтендөнья ассоциациясе хәбәре килде: заводка "Россиянең, БДБ илләренең 2003 елгы иң яхшы нефть эшкәртү заводы" дигән исем биргәннәр. Татарстанда үткәрелгән традицион бәйгедә заводның генераль директоры Хәмзә Баһманов "Ел директоры" булып танылды. Алдагы язда Швейцариянең Цюрих каласында Түбән Кама нефть эшкәртүчеләренә халыкара символик бүләк—"Алтын коелма" тапшырылды. Аны сәнәгатьнең иң алдынгы предприятиеләренә генә бирәләр. Шәп бит!

Кадрлар...

Мәсьәләне кадрлар хәл итә. Заводта мең ярым идарәче *(Көнбатышча әйткәндә, менеджерлар)*, инженерлар, техниклар, операторлар, электриклар, эретеп ябыштыручылар, слесарьлар һәм компьютер системалары белгечләре эшли. Аларның алтмыш бер проценты махсус урта техник һәм югары белемле. Җиде фән кандидаты бар. Белем—көч ул! Биредә һәр кеше—шәхес, үз холкы-табигате, үз язмышы белән шәхес.

Үзенчәлекле, күркәм кешеләрнең берсе—генераль директор Хәмзә Баһманов.

Дипломында "төзүче-инженер" дип язылган, ул һөнәрнең нефть эшкәртүгә бер катнашы да юк. Ә менә, күрче, "Елның иң яхшы директоры", халыкара "Алтын коелма" лауреаты!

Түбән Кама "Нефтехим" акционерлык җәмгыяте заводларының җитәкчеләре арасында нефть-химия юнәлешендәге белемгә ия булмаганнары берничә генә. Әйтик, энергетика һәм элемтә идарәсе башлыгы Василий Полуянов Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган, ә баш энергетик Александр Вдовин политехник институтта белем алган. Транспорт идарәсе башлыгы Анатолий Калинин шул ук институтта тимер юлларны файдалану белгече булырга укыган. Генераль директорның шәһәр төзелеше буенча урынбасары Рафаил Глянц Казан төзүче инженерлар институтын тәмамлаган.

Күпчелек җитәкчеләре үз белгечлекләре буенча эшлиләр. Аларның яртысыннан артыграгы — утыз өч кеше — Казан химия-технология институты дипломын йөртә. Бу институт тирән белемле инженерлар әзерләп чыгара.

Шулай да химик-технологик белемнәре булмаган җитәкчеләр дә юк түгел. Менә шул ук Хәмзә Бәһманов. Ул, төзүче инженерлар институтын тәмамлап, беренче һөнәри чыныгуны нефть төбәгенең башкаласы булган Әлмәттә алган, шунда ук райбашкарманың рәис урынбасары булып эшләгән. Холкы-табигате белән тынгы белмәс егет. Авылларны газлаштыруда катнашкан, бу эшкә бер карыш та торбалар бирелмәгән заманда була бу; аннары терлекчеләрне потлап-потлап сөт савып алырга өндәп йөрергә туры килгән — райбашкарма хезмәткәре бит! Анысы да терлекләргә азык җитмәгән заманнарда. Аннары авыл халкын юллар төзергә, кар тотарга, урман полосалары утыртырга өндәгән. Соңгы елларда "Татнефть" берләшмәсенең төзү-ремонт идарәсен җитәкләгән. Ул шул рәвешле кешеләр белән килешеп эшләргә, аларны кыен чакларда дәртләндереп җибәрергә, ягъни идарә итәргә өйрәнгән.

Республика нефтьчеләренең дә хыялы, ниһаять, тормышка аша: нефть эшкәртү заводы төзү турында карар кабул ителә. Бу эшне җитәкләргә кемне куярга икән? "Татнефть" берләшмәсенең генераль директоры Ринат Галиев Хәмзә Бәһмановны әңгәмәгә чакырып ала. Хәл-әхвәлләрен сораштырып, кан басымың уйнамыймы, дип кызыксынганнан соң аны Галиев кабинетының арткы бүлмәсенә дәшәләр. Бәһманов моның тикмәгә генә булмаганлыгын шундук аңлап ала. Генераль директор аны бик яхшы белә, чөнки Хәмзә Бәһманов райбашкармада эшләгәндә үзе партиянең шәһәр комитеты беренче секретаре иде бит, аңа иң җаваплы эшләрне тапшырып кына торды. Бераз гәпләшеп утыргач, Галиев Бәһмановка яңа эш тәкъдим итә. Түбән Кама нефть эшкәртү заводын төзеп, хутка җибәрергә кирәк икән. Бәһманов шул эшне җитәкләргә тиеш.

Юк, Хәмзә Бәһманов бу эшкә һич тә шатланып тотынмый. "Бераз уйлыйм әле, вакыт бирегез" — ди ул. "Уйла, — ди нефтьчеләр генералы. — Ләкин эштән баш тарта күрмә — анысы җиңел. Алдыңа куелган бурычны яхшылап үтәү турында уйлан. Кагыйдә бик гади, һәркемгә билгеле: шүрләсәң — алынма, алынсаң — шүрләмә. Дилбегәне кулыңа тот та — ку әйдә!"

Әлбәттә, күнегелмәгән җитди яңа эш һәрвакыт кыен: иялләшкән эшеңнән, үзең белеп бетергән, үз иткән кешеләрдән аерыл, гадәтләнгән тормышыңны яңача көйлә, һәр талы-ташы таныш җирләреңне калдырып, әле белмәгән-күрмәгән якка китеп бар... Кыен булмыймы соң! Яңа эшне тартып бара алырмынмы, дигән шик-шөбһәсе дә борчый бит әле аның.

Шулай итеп, Хәмзә Бәһмановны әле төзелмәгән заводка генераль директор итеп куйдылар. Нефть-химия эшләрен дипломлы төзүче-инженерга, директор кәнәфиеннән аерылмыйча, заводны төзү барышында өйрәнергә туры килде. Белмәү — оят түгел, белергә теләмәү — оят, ди халык.

Хезмәт колективының калган кешеләрен генераль директор Бәһманов, берләнбер җитәкче буларак, үзе берәмтекләп, күзгә-күз карашып сөйләшүләрдән соң сайлап туплады. Удар төзелешләр шигаре белән халыкны оешкан төстә җыеп алу ысулы күптән юкка чыккан иде инде. Яңа директор, үзенә кирәкле кешеләрне эзләп, илнең нефть эшкәртү заводларын иңли башлады. Ничек булса да кызыксындырып, төрле вәгъдәләр биреп, белгечләрне Түбән Камага чакырды ул. Мөмкин булганда — фатир, яхшы хезмәт хакы, тиз үсү мөмкинлеге *(берьюлы ике-өч баскычка күтәрелү!)*,

заманча иң яхшы техника, аппаратлар, приборлар — кызыкмаслыкмы соң! Илдә әле мондый да камил завод булмаган, тиз генә буласы да юктыр...

Әлбәттә, Бөтенсоюз комсомол удар төзелешенә яшьләрне күтәргән еллардагы кебек чиратлар тезелмәде, әмма көн саен берничә кеше кадрлар бүлеге ишеген кага торды, яңа коллектив әнә шулай тупланды.

Заводның баш технологы булып Уфадан күчеп килергә Шамил Әхмәтдинов ризалашты. Ул үз эшенең остасы, институтта укып чыкканнан соң чирек гасыр эчендә нефть эшкәртү тармагында гади эшче дә булган, инженер дәрәҗәсенә дә ирешкән. Беренче унбиш елын инженер, смена башлыгы, "Оргнефтехимзаводлар" трестының инженер-технологы булып эшләгән. Тагын җиде ел — каталитик крекинг комплексының бүлек башлыгы, Уфа нефть эшкәртү заводының смена җитәкчесе. Түбән Камага күчкәнче соңгы ике елын "Башнефтехим" акционерлык җәмгыятендә смена җитәкчесе, газокаталитик производствода инженер-технолог булып эшли. Әлбәттә, заводның баш технологы булу абруйлырак та, акчалырак та, хезмәт баскычыннан тагын да күтәрелү мөмкинлеге дә бар.

Уфадан килүчеләрнең янә берсе — эксплуатация буенча баш инженер урынбасары, заводның әйдәп баручы белгече Валерий Малафеев. Институттан "нефть һәм газ эшкәртүнең химик технология белгече" дигән диплом алып чыкканга кадәр ул башта нефть техникумын тәмамлый, хезмәт юлын гади оператордан алып башлый, Орск нефть эшкәртү заводында җайланмалар буенча баш кеше, Уфадагы шундый ук заводта цех башлыгы урынбасары, шунда ук баш инженер урынбасарына кадәр күтәрелә ул. Яңа заводның беренче белгечләреннән булган Валерий Малафеев — Башкортстан АССРның атказанган рационализаторы, СССР Министрлар Советының махсус бүләге һәм БАССР Югары Советының Мактау грамотасы иясе, БАССРның атказанган нефтьчесе, "Минтопэнерго"ның атказанган хезмәткәре... Бу исемнәр, бүләкләр намуслы хезмәтнең күзгә күренмәс маяклары гына түгел, алар һөнәри үсеш шаһитлары да. Кеше шәхес буларак әнә шулай аякка баса, чын ир-ат булып җитешә.

Генераль директор үзен элекке эше буенча яхшы белгән, аңа ышанган белгечләрне дә ияртеп алып килә. Хәер, бу бер дә гаҗәп түгел, ә күптән билгеле традиция. Зур төзелешләр, яңа заводларның директорлары белән берлектә, кагыйдә буларак, еш кына алар кул астында эшләгән көрәштәләре һәм фикердәшләре дә, яңа урында эшләргә ризалык биреп, хезмәт юлын яңача башларга теләп күчеп киләләр.

Әйтик, төньяктагы Вилюй гидроэлектрстанциясе төзелеше башлыгы Евгений Батенчукны министрлык КамАЗ автогигантына күчергәч, аны яратып "Батя" дип йөртүче бик күпләр аның артыннан Кама буена тартылалар. Себердән төзелеш-монтаж идарәсенең баш инженеры М. В. Уманский, план идарәсе башлыгы М. М. Михайловская, хезмәт һәм хезмәт хакы бүлеге башлыгы урынбасары М. Д. Бухалов, Социалистик Хезмәт Герое бригадир А. Б. Новолодский күчеп килә. Илнең нефть сәнәгате министры итеп Татарстан совнархозының нефть идарәсе башлыгы Валентин Шашинны билгеләгәч тә, Татарстан нефтьчеләре арасында җитәкче һәм белгеч булып җитешкән хезмәттәше артыннан ул министрлыкка Татарстанның күп кенә белгечләре күчә. Татарстан нефтьчеләре Рәфкать Мингәрәев, Виктор Мищевич, Әгъзам Вәлиханов, Шаген Донгарян, Анатолий Перов, Валерий Грайфер, Василий Сорокин, Альберт Галсустовлар министр урынбасарлары, бүлек башлыклары булып китәләр. Ул елларда үткен теллеләр, Союз министрлыгы "Татнефть"нең филиалына әверелде, дип шаярта иде.

Түбән Кама нефть эшкәртү заводына Хәмзә Баһманов белән бергә генераль директорның беренче урынбасары, предприятиенең коммерция хезмәте җитәкчесе Валерий Абрамов килә. Куйбышев политехник институтын тәмамлагач, ул бик күп урыннарда күп белгечлекләр буенча эшләгән. Төньяк Кавказда "Грознефть" берләшмәсендә бораулау эшләре идарәсенең ремонтчы слесаре, Татарстанда мастер, бүлек башлыгы, "Бөгелмәнефтемаш" берләшмәсенең комсомол комитеты секретаре була, профтехучилище директоры кәнәфиендә дә утырып ала. Аннары, кызып китеп, гасырның легендар төзелешенә — КамАЗга килә. Автозаводта ул өлкән мастердан алып инструментлар җитештерү цехының башлыгы дәрәҗәсенә кадәр үсә, аннары Кустанайдагы дизель заводының инструментлар-штамп цехы башлыгы булып ике

ел эшли. Түбән Камага килгәнче ул тагын биш ел Әлмәттәге бер берләшмә җитәкчесе була. Хәмзә Баһманов аны шуннан үзенә беренче урынбасар итеп чакыра.

Тагын бер җитди, җаваплы эшкә — генераль директорның икътисад һәм финанс эшләре буенча урынбасары вазифасына 1998 елның маенда Әлмәттән Наил Гамиров килә. Ул ике югары уку йортын — Губкин исемендәге Мәскәү нефть институтын һәм Кама политехник институтын тәмамлаган. Кырык еллык гомерендә нефть чыгару мастеры, өлкән технолог, нефть промыселы башлыгы урынбасары, шул ук вакытта Губкин институтының Әлмәт филиалында укыта; "Әлмәтнефть" идарәсенең фәнни-тикшеренү һәм промысел эшләре цехын җитәкли, өч елга якын "Татнефть" берләшмәсенең кыйммәтле кәгазьләр бүлеге башлыгы була... Шул рәвешле, ул промышленность предприятиеләрендәге хәзерге финанс хәлләрен энәсеннән җебенә кадәр өйрәнә, зур тәҗрибә туплый.

"Түбән Кама нефть эшкәртү заводы" ачык акционерлык җәмгыятенең баш бухгалтеры Мәүлет Газизов Татарстанның Яңа Чишмә районындагы Үтәш авылында туып-үскән. Уньеллык мәктәптән соң ук Казан финанс-икътисад институтына укырга керә һәм аны егерме бер яшендә тәмамлап та чыга. Аннары тынгысыз хезмәт юлы башлана — бухгалтерлыкның көндәлек эчпошыргыч кырыс эшләре, сумнар-тиеннәр санап утыру, финанс мөмкинлекләрен кысып тотарга өйрәнү, йокысыз төннәр... Ә акчаның кайчан, кайда җиткәне бар соң аның? Югары белем алып чыккач, ул әле төньяктагы Полярный шәһәрендә армия хезмәтен уза, армиядән кайткач, сигез ел буе "Таткомплектмонтаж" трестының бер бүлегендә бухгалтер, тагын өч ел технологик җитештерү комплектациясендә өлкән бухгалтер, 1983-85 елларда шул ук идарәнең баш бухгалтеры булып эшли. Түбән Камага чакыртып алганчы, ул әле Финляндиядә газ үткәрү төзелеше идарәсендә, аннары яңадан Татарстанда төзү-монтаж идарәсендә, "Чулман" төзү-сәүдә фирмасында, "Татнефтегазстрой" акционерлык җәмгыятендә дә эшли... Эшләгән урыннары төрле булса да, хезмәте бер — баш бухгалтерлык. Барлык оешмаларда, завод-фабрикаларда җитештерү эшчәнлеге һәм социаль эшчәнлекнең төп нигезе — бухгалтерия.

Материаль-техник тәэминат һәм җиһазларны туплау идарәсе башлыгының беренче урынбасары Рифгать Сәйфуллин да әүвәл нефть техникумында, аннары институтта укый. Югары белемне ул читтән торып укып ала, бер үк вакытта слесарь, токарь, инженер-конструктор, инженер-технолог, бораулау конторасының баш механигы булып эшли. Эшләп тә, укып та тормыш тәҗрибәсе туплаган белгеч һәркайда югары бәяләнә. Институт тәмамлап чыккан Рифгать Сәйфуллин прокат-ремонт цехы башлыгы, бораулау конторасы баш механигы, аннары бораулау эшләренең Азнакай идарәсе баш механигы вазифаларын башкара. Бу еллар арасында ул әле төньякта — Уренгойдагы тирән бораулау экспедициясендә җитештерү хезмәте базасының башлыгы да була, шунда ук — баш механик та әле. Тагын өч ел Кубада да эшләп кайта. Аннары тугыз ел (1990 – 1999) бораулау эшләренең Азнакай идарәсе конструкторлык бюросы башлыгы, ябык акционерлык җәмгыяте "БЭЛ"нең директоры, җаваплылыгы чикләнгән "САФТ" акционерлык җәмгыятенең әйдәүче инженеры да була. Ул төпле һөнәри гыйлемле, зур тәҗрибәле кеше. Аның салкын Төньяктан алып мәңге яшел эссе Азатлык утравы Кубага кадәр дөнья гизүе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Түбән Кама нефть эшкәртү заводына Сәйфуллин капиталь төзелеш бүлегенең әйдәүче инженеры булып килә. Бераздан үз җилкәсенә материаль-техник тәэминат һәм җиһазлар туплау идарәсе җитәкчесенең беренче урынбасары йөген күтәрә.

Заводның финанс бүлегендә баш бухгалтер — кыю һәм кырыс ханым Валентина Фәттахова утыра. Ул миллионлаган тонна "кара алтын"ны эшкәртү өчен тотыла торган күп миллионлы акча ташкыны өчен җаваплылыкны да үз өстенә алудан куркып калмаган. Байлыкны арттыру чыгымнарны арттыру хисабына булмаска тиешлеген, ә бәлки сак тотуга бәйле икәнлеген бик яхшы белә. Үз язмышының үтелгән елларын да саклап тота белгән: югары белемне читтән торып укып алган. Әле техникумга укырга кергәнче үк өлкән пионервожатый, хәреф җыючы, лаборант, Геофизика Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү институтында дүртенче разрядлы эшче, нефть эшкәртү заводында оператор ярдәмчесе булган. Шулай тормыш тәҗрибәсе туплаганнан соң, ул Ишембай нефть техникумына кереп укый. Укып чыккач, аны

"Татнефть" берләшмәсенең норматив-тикшеренү станциясенең нефть чыгару бүлегенә эшкә билгелиләр. Ул өч елдан нефть һәм нефть продуктлары сатуурнаштыру идарәсендә инженер-экономист була, аннары "Татнефть"нең планлаштыру һәм икътисади анализ бүлеге башлыгының урынбасары булып эшли. Чирек гасырлык эш стажы булган Валентина Фәттахова югары белемне дә читтән торып укып ала — Казан финанс-икътисад институтын тәмамлый.

Түбән Кама нефть эшкәртүчеләренә "Нефтехим" ярдәмгә килә. Тәҗрибәле, белемле белгечләрнең бәясен беләләр биредә. "Нефтехим"ның электр белән су кудыру җайланмасы үз технологик системасы аша елына җиде миллион тонна нефть чималын кудырып чыгара ала, аны эшкәртү заводына эшчеләре белән бергә тапшыралар. Яңа эшкә күчүчеләргә тоткарлык ясамыйлар, киресенчә, хезмәт стажлары югалмасын дип, приказ белән күчерәләр. Саубуллашканда яңа урында уңышлар теләп, нефтехимикларның һөнәри абруен сакларга, яңадан әйләнеп кайткан очракта һөнәрләрен арттырып, үсеп кайтырга теләк телиләр.

Шулай берәмтекләп җыела-җыела, мең ярым кешелек хезмәт коллективы туплана, инженерлык белеме белән һөнәри тәҗрибә бергә үрелеп бара, зур хыяллар белән тормышчан уй-ниятләр кушыла, нефть эшкәртүдән тыш бик күп һөнәрләрне үзләштергәнлектән, аякка басып килүче предприятиеләргә хас авырлыкларны җиңеп чыгардай коллектив була ул. Әле кичә генә бер-берләре белән таныш булмаган, әмма тормыш тәҗрибәләре зур, кыенлыклардан һич курыкмый торган белгечләрне бер эш, уртак бер язмыш берләштерә.

Балык — тирән суны, адәм заты яхшыдан яхшыны эзли. Һәр кешенең үзе генә белгән хыялы бар. Кемнәрдер хезмәтендә югарырак үрләргә, җаваплыраккабруйлырак урында эшләп, дан-шөһрәт казанырга тели. Ә кемнәрдер акчага, байлыкка гына кызыга. Кемнәрдер исә яңа җирләрдә яшәп карарга, үзе өчен яңа дөньялар ачарга омтыла. Кешенең нинди дә булса анык бер эшне, яшәү урынын сайлавы аның холык-табигатеннән киләдер. Джек Лондонның мавыгучан геройлары Калифорниянең Көньяктагы приискаларыннан алып Төньяк киңлекләренә кадәр эзләп, әрле-бирле сугылып йөриләр. "Җил һәм кояш туганнары" геологлар җилкәләренә рюкзаклар-палаткалар асып, җир асты байлыкларын эзлиләр, бу — һөнәри әвәслекләре. Урман кисүчеләр үзләре тырышып төзегән йорт-җирләрен ташлап, яңа, пычкы-балта тимәгән урман ешлыкларына ашкыналар. Гомерлек "дүңгәләкләр" булган төзүчеләр бер төзелештән икенчесенә күчеп йөрүдән ялыкмыйлар. Бу тынгысыз халык артыннан тормыш-көнкүреш өчен бик кирәкле пешекчеләр, чәчтарашлар, итекчеләр, тегүчеләр, табиблар һәм башкалар иярә. Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Түбән Кама нефть эшкәртү заводының төзелү һәм аякка басу тарихы башкачарак, ул тирәнрәк, нечкәрәк. Кешеләр кыргый тайга урманнарына беренче аяк басучылар булып түгел, ә ике йөз мең кешеле уңайлы шәһәрдә яшәргә дип киләләр. Нефть эшкәртүчеләр алтын таулары да эзләми, хәер, аларның хезмәт хакы, ТЭЦ эшчеләренекеннән кала, шәһәрдә иң югары санала — айга ун мең сумнан артык. Яңа эшкә тартылуда җитәкченең уңай тәэсире дә зур, кешеләр иҗтиһади эшчәнлеккә кыю чакыручы, җегәрлебулдыклы директор тирәсенә туплананалар.

Түбән Кама нефть эшкәртүчеләренең уй-ниятләре, хыяллары, безнеңчә, ике сәбәпкә кайтып кала.

Беренчесе — үз эшләренең осталары җир астыннан "кара алтын" ятмаларының эшкәртү өчен авыр булган нык күкертлеләрен дә буйсындырырга, табигатьтә начар нефть булмавын расларга омтылалар, иң начар чималдан да, эшкәрткәч, менә дигән сыйфатлы эшләнмәләр алып, дөнья базарына чыгарга теләкләре зурдан икәнлегенә инаналар. Нефть болай да кара, нигә аны, артык күкертле, төрле катнашмалары күп, эшкәртеп бетереп була торган түгел, дип, тагын да каралтып күрсәтергә?

Ашкындырып торган икенче бер сәбәп — үзләренең элгәрләре күптән җибәргән стратегик хатаны төзәтү иде. Заводның нигезе булырга тиешле комплексны төзегәндә һәм эшләтеп җибәргәндә, вакыт белән исәпләшмичә, алны-ялны белмичә эшләделәр. Башка заманда айлар буе башкарыласы эшне дә бер атнада майтара бардылар, кирәк булганда идарәчеләр дә монтажчылар эшенә тотынды,

аппаратчылар исә төзүчеләр булды. Әһәмияте ягыннан һөнәри генә түгел, әхлакый да булган мәсьәлә төрле сәбәпләр аркасында элгәре буыннар тарафыннан тормышка ашырылмый калган, дип саналды. Аны ерып чыгуны һәммәсе дә изге бурыч дип кабул итте. Көннәр, тырыш хезмәт белән тыгызланып, бер-бер артлы үтә торды. Бер ел эчендә нефть эшкәртү заводын эшләтеп тә җибәргәч, аңа һөнәри бүләк — "Алтын коелма" тапшырылды.

Чынлап та, Татарстан нефте үзенчәлекле. Җир асты ятмалары бик бай — илнең кайсы төбәгендә тагын элекке СССРның 0,3 процентын гына тәшкил иткән республикада бер кеше гомере аралыгында алган кадәр — өч миллиард тоннага якын "кара алтын" алып була?

Беренче карашка нефть бер төрле генә, катнашмаларсыз шикелле. Гамәлдә исә табигатьтә ничәмә-ничә нефть ятмалары булса, шул кадәрле үк төрледән-төрле ул байлык, аңлап та бетермәссең. Себердә Рус ятмасы дигән төбәк бар, аннан алынган чимал кышкы майлау өчен бик яхшы. Ышансаң — ышан, ышанмасаң — юк, әмма шоферлар, тракторчылар сөйли: кайбер скважиналардан алынган нефтьне турыдан-туры бензин бакларына салырга була, имеш! Саласың, моторыңны кабызасың да — әллүр! Гадәттә иң яхшы эталон нефть дип Баку тирәсендәге Сураханыдагы нефть санала. Ул гел җиңел нефтьтән генә тора, җиңел эшкәртелә дә икән.

Лампаларга "кәрәчин мае" ягып яшәгән заманнар да истә әле, ул чорда бензин бик нәзберек, җиңел шартлаучан ягулык санала иде, аны бер өч мәртәбә кудырып, катнашмаларыннан арындырганнан соң, калдыкларын йота торган махсус скважиналарга тутыра иделәр. Бәлки киләчәктә кирәге чыгар диптер инде. Аннары бензин белән эшләүче автомобильләр заманы килде. Машиналар да теләсә нинди бензинны сөйми, аларны чистартылган, югары октанлы ягулык белән генә йөртә иделәр. Үз автомобильләрен Генри Форд "атсыз арбалар" дип атаган. Бу "арбалар" тиз йөрешле, табигатьне дә аз пычрата. Киләчәктә бензин моторлы машиналарны тромобильләр алыштырачак. Ул вакытта бензин чоры бетәчәк.

Татарстан нефть ятмаларының күкертле саналган катламы — авыр нефть. Табигать-ана үз байлыкларын җир астына катлам-катлам итеп салган. Борынгы девон катламындагы нефть — күкертсез, чиста, аның өстендәрәк ятканы нык күкертле, авыр. Боларның һәркайсысын аерым чыгаралар, аерым технологик ысуллар белән эшкәртәләр. Күкерттән тыш нефтькә су, минераль тозлар, ванадий, марганец, висмут кебек сирәк очрый торган мәгъдәннәр дә катнаша. Боларның атомнары һәм молекулалары геологик чорларның миллионлаган еллары эчендә тау токымнары белән шулкадәр аралашып беткәннәр ки, аларны бер-берләреннән табигый шартларда аерып алырлык та түгел, моның өчен күп көч куярга кирәк.

Түбән Кама нефть эшкәртү заводында килер буыннарга истәлекле сүзләр язылган капсула куеп калдырдылар. Анда Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең теләк сүзләре мәгъдәннән коеп язылган: "Без җиребез астындагы теләсә нинди нефтьне эшкәртергә өйрәнергә тиешбез", — диелгән. Түбән Кама нефть эшкәртү заводы нәкъ әнә шул максаттан чыгып төзелә дә. Аның торбалары, колонналары, вакуум аппаратлары аша чимал ташкынын куып, кара җир асты коктейлен төрле состав өлешләргә аеру, кирәкле катнашмаларын алу зарур. Һәр алынганы халыкара сыйфат сертификаты таләпләренә җавап бирергә тиеш. Ә ул таләпләр бик катгый, ирекле базар кануннары кырыс: иң начар чималдан әзерләнгән эшләнмәләр дә иң югары сыйфатлы булсын.

Бик күп төрле техника һәм махсус аппаратлар да куелган максатка ирештең дигән сүз түгел әле. Житештерүне заманча техник чаралар белән тәэмин итү аңа хезмәт күрсәтүчеләргә дә зур таләпләр йөкли, аларның һөнәри тәҗрибәләре, иң катлаулы технологик система белән эшләү күнекмәләре дә булырга тиеш. Космос-галәм һәм атом заманы чорның агышын нык тизләтте, уйланып-исәпләп торырга вакыт калмады. Дан һәм танылу алырга омтылучылар йә беренчеләр булырлар һәм теләгән җимешләрен өзеп алырлар, яки аларны тагын да комарлырак һәм һәвәсрәк бәхетлеләр узып китәр. Менә шундый заманда яшибез! Тормыш автомобиль ярышы түгел, икенче кат узышка чыга алмассың, барган вагонга сикереп менеп өлгерергә кирәк.

Соңгы нәтиҗә кешеләрнең тырышлыкларына, осталык һәм үҗәтлекләренә бәйле.

Хәзерге һөнәр иясләре исемлегендә борынгылары да, иң соңгылары да бардыр. Кыйммәтле асылташларны шомартучы да оста, агачтан гаҗәеп җиһазлар ясаучы да оста, эретү мичләреннән мәгъдән коеп алучы да оста, кирәкле әгъзаларны күчереп утырта белүче хирург исә осталарның да остасы. Җир мае — нефтьне эшкәртә белеп, аннан кирәкле матдәләр ала белүчеләр дә осталар түгелмени? Нефть шул нефть хәлендә гел генә дә кулланылмый диярлек. Ә бит бер елда бөтен дөнья берничә миллиард тонна нефть чыгара. Ул иң әүвәл эшкәртелүдән соң башта ягулык-майлау әйберләре җитештерүгә китә. Шуннан соң инде әлеге чималдан, әйтик, резин шин-көпчәкләр, төрле буяулар, элпәләр, тукымалар, өй җиһазлары, автомобиль, кораблар, самолетларга кирәк-яраклар да җитештерәләр. Крекинг җайланмалары аша да шул кадәрле нефть диңгезе ага дигән сүз. Шулай булгач, хәзерге шартларда нефть эшкәртүче һөнәре иң кирәкле, иң абруйлы һөнәр булып чыга.

Түбән Кама нефть эшкәртү заводындагы кадрлар бүлеге исемлегендә кемнәр генә юк. Менеджерлар, инженер-технологлар, аппаратчылар, автокар йөртүчеләр, ремонтчылар, шоферлар вә тракторчылар... Әле тагын компьютерлар белән эшләүче операторлар, иң кирәкле тәэминатчылар вә эшләгәненңе озатып торучылар... Күпме? Әмма алар барысы да бер эш белән мәшгуль — нефтьне эшкәртеп, сатарга яраклы хәлгә китерү аларның бурычы.

Крекинг җайланмаларына чималны йөзәр-меңәр тонналап тутыралар, аны төрле матдәләргә аеруны өзлексез алып баралар, әзерләрен алгач, яңа чимал өстиләр.

Күкертле нефтьне эшкәртү цехы башлыгы урынбасары Степан Сутурин үзен "дипломсыз инженер" дип атый. Ул халыкка чирек гасыр хезмәт иткән, үз аппаратлары аша 100 миллион тоннадан артык чимал үткәргән элекке җайланманы җибәрүдә дә катнашкан. Ә хезмәт юлын Ангарскидагы зур нефть эшкәртү заводында башлаган. Һөнәре ошап, үсәргә мөмкинлек булса да, квартир мәсьәләсе бик кыен булган. Аны Түбән Камага эш белән дә, квартир белән дә тәэмин итәрбез дип чакырганнар. Яңа урынга алар алты кеше килеп төшкән, үзләрен генераль директор Николай Лемаев каршы алган, эш урынын күрсәткән, квартирларга кайчан күчәселәрен дә әйткән: "Җайланманы җибәреп өч ай үткәч тә булыр" — дигән. Сүзләрендә торганнар: җайланманы да вакытында эшләтә башлаганнар, фатирлы да булганнар. Хәзер инде менә чирек гасыр Түбән Кама кешеләре булып яшиләр. 1998 елны Мәскәүдән "Нефтек-Техно" компаниясенең генераль директоры Н. Лемаев килә. Сутуринны эшләп торган аппарат янында күргәч, җилкәсеннән кагып: "Ә-ә-ә, сибиряк! Төпләндеңмени?" — дип исәнләшә. "Төпләнмичә соң! Чирек гасыр үтеп китте бит, үзе бер гомер!" — дип җавап бирә Сутурин.

Уфадагы яңа нефть эшкәртү заводыннан өлкән оператор Риф Мөхәммәтшин дә квартир кирәк булганга күчеп килгән. Ул, зарарлы эштә эшләү сәбәпле, пенсиягә дә чыккан, әмма көче-җегәре бар, теләге дә бар — рәхәтләнеп эшләп йөри әле. Өч баласы да Түбән Камада туган. Өлкән улы Илдар сәнәгати-техник бүлектә инженер. Оныклары да үсеп килә. Барысы да ата-ана кулы астында.

Мичләр блогы операторы Александр Мигуновны язмыш кайларга гына ташламаган: Уралда Златоустка якын бер металлургия заводында дистә елдан артык корыч койган, Түбән Камага өч баласын төяп килеп төшкәндә кече кызына өч кенә яшь була. Килгән уңайга ике гаиләгә бер кухня, бер туалетлы квартирда яшәп торганнар, дүрт елдан соң өч бүлмәле зур квартирга күчкәннәр. Аерым квартирны алданрак та бирмәкче булганнар аңа, әмма иске йорттан. Күчәселәре килмәгән, яңаны көткәннәр.

Цех башлыгы Евгений Шабалин бераз яшьрәк, оператор хезмәтендә бишенче разряд алганнан соң гына нефтехимик институтның кичке бүлегенә укырга кергән, Органик синтез технологиясе белгечлегенә укыган, диплом алып чыгуга үзен җитәкче итеп күтәргәннәр. Белеме дә бар, хезмәт тәҗрибәсе дә җитәрлек, андый кешеләрне аеруча хөрмәт итәләр.

Тәҗрибәле өлкәннәр канаты астында эшче биографиясен Түбән Камада башлап җибәргән яшьләр бик күп. Әмма бирдә кешеләрне яшенә карап түгел, эшенә карап бәялиләр: тырышмы ул, осталыгы бармы, белемен арттырамы?

Мастер-технолог Алексей Турбашев Казан химия-технология институтының нефть факультетында укый, бу крәстиән егете бик тырыш була, институтны кызыл

диплом белән тәмамлый. Бер ел бишенче разрядлы оператор булып эшли. Тәҗрибә туплагач, аны мастер итеп куялар. Ике ел эчендә шәхси тормышын да көйләп җибәрә – өйләнә, "Жигули" машинасы сатып ала.

Гомуми конвейер бүлегендә эшчеләр генә булса, гидрочистарту комплексындагы операторлар йә техник, йә инженер дипломына ия. Заводның башка цехларына да белгечләрне, кагыйдә буларак, бирелән алалар. Соңгы елда гына да инженерлык вазыйфасына дүрт кешене – Олег Ермолаев, Артур Киндебаев, Марат Рәхимҗанов һәм Ирек Камаловны күчерделәр. Заводта эш артып кына тора, белгечләр тиз үсә. Комплексның водород эшләп чыгару, күкерт алу, гидрочистарту цехларында үз операторлары, машинистрлары, электриклары, слесарьлары эшли. Керосинны гидрочистарту бүлегендә Минтаһир Билалов, Илдар Саматов, Марат Хәмидуллин кебек егетләр, ә технологик бүлектә Урал Лотфуллин, Рөстәм Сираев, Ленар Шәймәрдәнов, Радик Исламовлар тырыша.

Иң җаваплы цехларның берсе – күкерт цехы. Күкерт көнкүрештә зур байлык ул. Фәндә булсын, төрле эш тармакларында булсын, ул һава кебек кирәк. Ләкин нефтьтәге күкерт бик күп бәла-казалар китерергә дә мөмкин. Ул ягулыкта калса, моторларны сафтан чыгара, газлары һавага таралса, кешеләрнең сәламәтлегенә зыян сала, табигать өчен зарарлы кислоталы яңгырлар булып ява. Нишләргә соң? Нефтьне күкерттән арындыру юлларын эзләргә кирәк. Башка юл юк.

Нефтьне эшкәртү бик катлаулы. Иң әүвәл аны тоздан һәм судан арындыралар. Элегрәк аны судан арындыру өчен махсус су җыйгычлар төзи торган булганнар. Нефть судан җиңелрәк, ул өскә күтәрелә, ә су аста кала икән. Нәтиҗәне бер-ике көн генә түгел, айлар буе көткәннәр, кадерле вакыт шулай сарыф ителгән. Бик күп нефть чистарту корылмалары ясалган. Ә хәзер Түбән Кама заводында нефтьне махсус мичләрдә 120 градуска кадәр җылыталар, төрле матдәләр өстәп, аны чиста нефтькә һәм суга аеруны тизләтәләр. Тагын әллә ничә төрле ысул кулланалар әле. Мичтәге ялкынны йә көчәйтәләр, йә киметәләр, химикатлар өстиләр, басымны һәм электр көчәнешен күзәтеп торалар. Чималны вакытында салып, әзерен вакытында алырга да кирәк. Гаять зур төгәллек, осталык таләп итә торган бу чаралар әле эшнең башы гына. Барлык технологик чараларны сөйләп тормастан, шуны гына әйтик, иң әүвәл углеводород газлары, аннары нафта яки легроин, аннары керосин, аннары җиңел дизель ягулыгы, аннары авыр дизель ягулыгы алына. Иң аста мазут утырып кала. Күрдегезме, никадәр четерекле гамәлләр! Шуңа күрә дә нефть эшкәртүчеләрнең хезмәте кырыс-авыр, бик җаваплы. Россиянең Новокуйбышевск, Пермь, Кетово, Киришидагы заводларында күкертле авыр нефтьне буйсындыра алмыйлар, ә менә Түбән Камада булдырганнар, алар – җиңүчеләр!

Заводка ел дәвамында килә торган чималның күләме искечә – җиде миллион тонна чамасы калган. Әмма аны завод конвейерларында эшкәртү сыйфаты яхшырган, мазутка кадәр алына торган өлешләрне алтмыш биш процентка күтәрергә мөмкинлек туган. Шуның нәтиҗәсендә сатуга китә торган товар, 2003 елда янә егерме биш процентка артып, табыш 250 миллион сумга җиткән. Заводның барлык төзелешләре дә тәмамлангач, чималны эшкәртү тагын да тирәнәячәк, товар җитештерү моңарчы күрелмәгән югарылыкка ирешеп, туксан сигез процентка күтәреләчәк!

Яңа заводның иң зур файдасын сумнарда-процентларда гына бәяләргә дә мөмкин түгелдер. Аның файдасы – табигатькә, тирә-юньгә зыян китермәү, фән теле белән әйткәндә, экологик чисталык. Әле бит, Татарстан нефте түбән сортлы, начар, дигән гайбәтләр дә таратып өлгергән иделәр.

Түбән Кама нефть эшкәртү заводын тирә-яктагы табигатьне саклаучы итеп тә карарга кирәктер. Чөнки анда чистартылган җәйге һәм кышкы дизель ягулыгы бары тик 0,05 процент катнашмасы белән генә җитештерелә. Бу исә һәм Россия, һәм дөнья таләпләренә туры килә дигән сүз. 2003 елда заводның һавага чыгарып ташлана торган күкерт һәм азот оксидлары егерме биш мәртәбә кимetelгән. Шул ук вакытта ел саен нефтьтән алына торган утыз мең тонна күкерт химия, төзелеш, фармацевтика, авыл хуҗалыгы тармакларында файдалануга китә.

Завод 2004 елда, чистартылган керосиннан файдаланып, реактив ягулык эшләп

чыгара башлады, анысы сыйфаты белән дөньядагы шундый башка ягулыклардан күп өстен тора.

Татарстан икътисадында нефть, газ, химия тармагын үстерү программасы биш елга тәгаенләнгән. "Татнефть"нең мактанычы – Түбән Кама нефть эшкәртү заводы исә иң төп көчләрнең берсе санала. Әлеге завод елына җиде миллион тонна нефть эшкәртеп чыгарса, аның икенче чираты сафка баскач, ул елына унсигез миллион тоннага җитәчәк. Бу эшне элекке шикелле чирек гасырга сузып түгел, ә тиз башкарырга исәплиләр. Турыдан-туры кудырылган бензин төзеләчәк этилен заводы өчен чимал булачак, аңардан елына алты йөз мең тонна этилен алыначак. Шундый бер завод "Түбән Кама Нефтехим" акционерлык җәмгыяте составында эшли дә инде, шуның янына яңа завод житештергән этиленны дә өстәсәң, республика аны елына бер миллион ике йөз мең тонна эшләп чыгарачак дигән сүз. Этилен – нефть химиясенең икмәге ул. Аңардан иң кирәкле пластмасса-полиэтилен эшләнә, җаның ни тели, шуны ясарга була.

Бу программаны тормышка ашыру өчен 1,3 миллиард доллар акча сарыф итәргә кирәк булачак.

Менә шундый байлык ул нефть! Берәүләргә аннан бензин, керосин, сумалалар кирәк булса, икенчеләргә – асфальт, гудрон, битум, өченчеләргә металлар, парафин, күкерт, төрле дарулар, дүртенчеләргә түбә ябу өчен чирәп, корым, пластмасса кирәк. Ә кемнәрдер, бәлки, кыйммәтле кара һәм кызыл уылдык алырга хыялланадыр. Алырлар да!

Тарих поезды артыннан чабарга кирәкми, вакытны үзең тизләтеп яшәү мәслихәт.

---

## КИЛӘСЕ САНДА УКЫГЫЗ

Журналыбызның алдагы санында Вахит Имамовның «Казан дастаны» романының ахыры, Рәмзия Габделхаковaның «Зинһар, югалма!», Фәрит Яхиннның «Бакыр бозау» исемле повестьлары дөнья күрәчәк.

Поэзия яратучыларны Рәсимә Гарифуллинаның «Ак сарайда серләр бар» исемле поэмасы, Халисә Мөдәррисова, Нур Әхмәдиевларның яңа шигырьләре сөендерсә, публицистика бүлегендә исә Төркиядә яшәүче Татарстан кызы Ләйсән Шаһинның «Төрек әсирләренең хатирәләре» дигән күләмле язмасы урнашачак.

Шулай ук Тәлгат Насыйровның «Октябрь революциясе һәм эзәрлекләнгән татар матбугаты» исемле мәкаләсе, Аддер Тимергалинның «Миллият сүзлеге», «Татар энциклопедиясе битләреннән» сәхифәсе, Риф Бәдринең «Ярыктагы кояш» исемле шук повесте—боларның һәммәсен дә сез «Казан утлары»ның 10 санында укый аласыз.

# *Татарстан язучыларының XV корылтае*

Майның 27 сендә Казан милли мәдәният үзәгендә Татарстан язучыларының XV корылтае булды. Аны кереш сүз белән күренекле драматург **Туфан Миңнуллин** ачып җибәрде.

Татарстан Президенты М. Шәймиев, Министрлар Советы һәм Дәүләт Советы исеменнән корылтайда катнашучыларны Премьер-министр **Рөстәм Миңнеханов** сәламләде. "Язучылар съезды—республикабыз өчен күренекле вакыйга,—диде ул.—Сезнең иҗатыгыз җәмгыятьтә барган вакыйгалардан аерылгысыз. Сез социаль тотрыклылыкны тәэмин итүдә, демократик процессларны ныгытуда, милли-мәдәният һәм телне саклап калуда алгы сафта торасыз. Күптән түгел үзенең 70 еллыгын билгеләп үткән Татарстан Язучылар берлеге республикада мәдәниятнең югары үсешен билгеләүче иҗат оешмаларыннан берсе санала".

Премьер-министр үзенең чыгышында язучыларның хәзер иҗат итү өчен чикләнмәгән ирекккә ия булуларын, әмма җаваплылыклары да артуын әйтте. "Шуңа күрә дә иҗатыгыз өчен шартлар тудыру мәдәният өлкәсендә республика дәүләт сәясәтенең өстенлекле бурычларыннан берсе булып тора,—диде ул.—Миллиятне рухи яктан савыктыру, тормыш дәрәҗәсен күтәрү, җинаятьчелек белән көрәш, социаль киеренкелекне йомшарту—җәмгыятьнең төп бурычлары. Шушы эшләрнең башында безнең язучылар торырга тиеш".



*Корылтайны Туфан Миңнуллин ачты.*

Хөкүмәт Рәисе аннары Роберт Миңнуллин, Рәфкать Кәрами, Рәдиф Сәгъди һәм Нонна Орешинага Татарстан һәм Россиянең мактаулы исемнәрен бирү турындагы таныклыкларны һәм билгеләрне тапшырды. Язучылар берлегенә исә яңа "Газель" микроавтобусының ачкычын тапшырды.

Язучылар берлеге идарәсе рәисе **Ф. Галимуллин** идарәнең ике корылтай арасындагы эшчәнлеге турында хисап тотты. Ревизия комиссиясе хисабын аның рәисе **Ф. Зыятдинов** ясады. "Әдәби фонд" эше турында фондның идарә рәисе **Г. Рәхим** сөйләде.

Аннары әдәби жанрлар буенча докладлар тыңланды. Аларны **Д. Заһидуллина** (проза), **Т. Галиуллин** (шигърият), **Д. Гыйманова** (драматургия), **Л. Газизова** (рус телендәге әдәбият), **Р. Корбан** (балалар әдәбияты), **Ә. Закирҗанов** (әдәби тәнкыйть), **К. Миңлебаев** (әдәби тәрҗемә) ясады.

Фикер алышуда Татарстан китап нәшрияты директоры Д. Шакиров, язучылар Р. Идиятуллин, В. Имамов, Р. Батулла, Р. Фәйзуллин, Н. Орешина, З. Дәүләтов, А. Хәлим, М. Хәбибуллин, В. Лаврищко, Ф. Галиев, Э. Шәрифуллина, Ф. Сафин, М. Вәли-Барҗылы, А. Хәсәнов, Г. Гыйльманов, Л. Кожевников, М. Маликова, Н. Акмал, Н. Сафина, Р. Ягъфәров, Ә. Рәшит, Л. Шагыйрьҗан катнашты.

Татарстан Язучылар берлегенең яңа рәисе итеп **Илфак Ибраһимов** (Мөхәммәт Мирза) сайланды. Берлекнең идарәсенә түбәндәге язучылар сайланды: **Р. Батулла,**

**Мансур Вәли–Барҗылы, Мөдәррис Вәлиев, Разил Вәлиев, Л. Газизова, М. Галиев, М. Гыйләҗев, З. Дәүләтов, Д. Заһидуллина, Р. Зәйдуллин, В. Имамов, К. Кәримов. Р. Корбан, С. Малышев, З. Мансуров, Р. Миңнуллин, Т. Миңнуллин, Г. Морат, Ш. Мостафин, Г. Рәхим, Д. Салихов, Ф. Сафин, Р. Фәйзуллин, З. Хөснияр.**

Биредә без (беркадәр кыскартып), корылтайда ясалган докладлар һәм кайбер чыгышларны бирәбез.

# Фоат Галимуллин

## ҮСЕШ ЮЛЫНДА

Хөрмәтле каләмдәшләр!

Бүген олы җыенибызда бергәләп хәзерге хәлебезне бәяләү, иртәгәбезне ачыклау юнәлешендә уртак бер фикергә килә алырбыз. Соңгы өч елдагы эшебез, иҗатыбыз нәтиҗәләрен күздән кичерү бүгенге урыныбызның кайда булуын, бигрәк тә нинди юнәлештә хәрәкәт итәргә тиешлегебезне ачыкларга ярдәм итәр.

Сезнең кулда Язучылар берлегенең 14 һәм 15 нче корылтайлары арасындагы эшчәнлеген яктырткан махсус китап бар. Анда барлык каләмдәшләребезнең эшчәнлеге дә шактый киң чагылдырылган.

***

Бу еллар илдә бер иҗтимагый-икътисадый формациядән икенчесенә күчүне тәэмин итүче реформаларның (үзгәртеп коруларның) аеруча кызу темпларда алып барылуы белән характерлы. Үзгәртеп коруларга дучар булмаган бер генә өлкә дә калмады. Алар хәзергә бик авырлык белән тормышка кереп бара, ник дигәндә, күпчелек үзгәртеп корулар халыкның яшәү рәвешенә, әхлакый нигезләренә дә кагыла. Аларның барысы да уңай эмоцияләр тудырмый. Информация алып килүче техник мөмкинлекләрнең чамасыз артуы, тамашачыга тәкъдим ителүче кино продукциясенең, телевидение тапшыруларының идея-эстетик юнәлеше торган саен гуманизмны, әхлак нигезләрен җимерә баруы язучы каләменә дә тәэсирсез калмый. Әнә шул фильмнар һәм тапшырулар миллионнарның зәвыгын һәм ихтыяҗын формалаштыралар. Музыкада халык бәгыреннән чыккан моңга кадер бетүгә юл тотылган кебек, әдәби әсәрләрдә дә безнең халкыбыз гомер-гомердән күнеккән матурлык, уңай образ үрнәге, яхшылыкның яманлыктан өстен чыгуы кебек затлы хасиятләр кими бара. Болар, әлбәттә, борчуга сала, иҗат кешесенең күңелен бимазалый торган тенденцияләр. Чөнки мондый юнәлеш алга таба да шулай сакланып калса, без берничә елдан, бик күп кыйммәтләребезне югалтып, бөтенләй башка, кирәкмәгән менталитетка ия буыннар үстерәчәкбез. Бу, әлбәттә, бөтен җәмгыятебез проблемасы. Ләкин ул иң әүвәл җәмгыятьнең аеруча ярала йөрәге булган язучыларның нык тартылган, киеренкеләнгән күңел кылларында сыкрану авазлары чыгара. Күпчелек каләмдәшләр әдәбиятыбызның затлылык традицияләрен үзләре өчен өлге дип саныйлар, изге кыйблаларына тугрылыклы калалар.

Быел без татар халкы башкаласының 1000 еллыгын бәйрәм итәргә әзерләнәбез. Бу һәрберебез күңелендә горурлык хисләре тудыручы вакыйга. Ике гасыр чигендә, ике меңьеллык аралыгында яшәү туры килүенә без бик тәэсирләнгән идек. Безнең замандашларга Казанның ун гасырлыгын да күрү насыйп булды. Бу уңай белән ышанып әйтә алабыз: сүз сәнгатебезнең тарихы да Казаныбызныкыннан һич тә ким түгел. Тарих фәне күп тапкырлар раславынча, шәһәр төзи белгән халыкның тарихы вакыт ягыннан күпкә тирәнгәрәк китә.

Бу бәйрәмнән соң Казанның шәһәр буларак статусы тагын да күтәрелеп калачак.

Моның күзгә бәрелеп торганы—ул метролы шәһәр булачак. Аның бер станциясе шагыйребез Г. Тукай исеме белән атала. Шәһәр хакимияте бу станцияне бизәүнең эчтәлеген тәэмин итүдә Язучылар берлеген дә җәлеп итте. Без кулдан килгән бөтен ярдәмне күрсәттек. Шәһәр белән бергә хәл итәсе тагын бер зур эш бар: хәзер, күреп торабыз, Казаныбызда зур төзелешләр, үзгәртеп корулар бара. Шул уңайдан кайбер урамнарның исемнәре дә алыштырыла. Соңгы вакытларда бер урамга Аяз Гыйләҗев исеме бирелү турында куанычлы хәбәр булды. Без Г. Исхакый, Сөембикә, Болгар, Колшәриф, Мөхәммәдьяр, А. Алиш, Гайнан Кормаш, Хәйретдин Мөҗәй, Гази Заһитов, Газинур Гафиятуллин, М. Әмир, Ф. Хөсни, И. Гази, Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, С. Хәким, Г. Ахунов һәм башка кадерле исемнәр белән аталган урамнарыбызны да күрергә теләр идек. Гомумән, әдәбият тарихыбызда тирән эз калдырган шәхесләрнең исемнәрен мәңгеләштерү буенча байтак эшләр башкарылды. Нәкъ менә бүген хисап тотучы җитәкчелек Җаекта Г. Тукайга һәйкәл кую эшен башлап йөрде. Хәзер Мәскәүдә, С.-Петербургта бөек шагыйребезгә бюстлар кую мәсьәләсе хәл ителеп килә. Әле соңгы вакытларда Чүпрәледә Зәки Нуригә, Актаныш районының Әнәк авылында Нур Баянга бюстлар ачылды. Кайбыч районының Кошман урта мәктәбе шагыйрь Әбрар Сәгыйди исеме белән аталды. Ике ел элек Минзәлә районы балалар китапханәсенә Рәшит Гәрәй исеме, шул ук районның Югары Тәкермән мәктәбенә Габделхәй Сабитов, Актаныш районы Уразай мәктәбенә Риза Ишморат, Сарман районы Чукмарлы мәктәбенә Әзһәр Габиди исемнәре бирелде. Мондый мәңгеләштерү актлары тагын да дәвам иттереләчәк.

Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков ярдәме белән Язучылар йорты урнашкан бина янындагы бакчаны тиешле таләпләргә туры китереп үзгәртү, анда күренекле классик язучыларыбызның һәйкәлләрен урнаштыру эше тормышка ашырылачак.

Тарихыбызны барлау, аңа хөрмәт белән карау—мәдәниятле халык эше. Узган ел без әдәбият тарихыбызның шактый бер кыска дәверенә, ягъни берлек булып оешуына 70 ел тулуны билгеләп үттек. 2005 елга Дәүләт Советына юлламасында Президентыбыз "Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең 70 еллыгын бәйрәм итү республикабыз тормышында мөһим вакыйга булды",— диде. Бу, чыннан да, шулай иде. Бу бәйрәмдә без үткән юлыбызга борылып карадык, талантлы язучы һәм оештыручылар булган элгәрләребезгә рәхмәт хисләребезне белдердек, бүгенге каләмдәшләребезне зурладык. Тарихыбыздан гыйбрәт алу, хәзергене ачыграк күрү безгә барыр юлыбызның юнәлешләрен дөресрәк итеп билгеләү мөмкинлеген тудырачак.

Инде хәзерге хәлебезгә якынрак килик.

Язучылар берлеге үз эшен планлы рәвештә алып барды. Эшне Татарстан язучыларының XIV корылтае резолюциясендә каралган бурычларны тормышка ашыру буенча эш программасын кабул итүдән башлап җибәрдек. Ул, нигездә, корылтайда яңгыраган тәнкыйть сүзләрен һәм тәкъдимнәрне искә алып төзелде. Менә аларның кайберләре: яшь алмаш белән эшләү буенча рәис урынбасары штатын булдыруны максат итәргә; аеруча талантлы яшьләргә индивидуаль консультант итеп остазлар билгеләргә; кабул итү коллегиясенә булган барлык гаризаларны карап бетерүне йөкләргә, ул каләмдәшләребезне союзга алу-алмау мәсьәләсен хәл итәргә; әгъзалар кабул итүгә таләпчәнлекне арттырырга, бу мәсьәләдә нинди дә төркемчелекләргә юл куймаска; сыйфат мәсьәләсе үзәктә торырга тиешлеген искәртергә, әгъзалыкка кандидатлыкны кыюрак файдаланырга; остаханәләрнең күчмә утырышларын уздыруны да гамәлгә куярга; идарәнең киңәйтелгән утырышларын уздыру гамәлен дәвам иттерергә, аларда берлек алдында торган актуаль мәсьәләләрне даими тикшереп барырга; балалар әдәбиятының торышы; язучының иҗат активлыгы, язучының иҗтимагый активлыгы; китап бастыруны һәм таратуны оештыруның актуаль мәсьәләләре.

Хисап чорында барлыгы 30 идарә утырышы һәм 6 тапкыр идарәнең киңәйтелгән утырышлары уздырылды. Бу соңгылары язучыларның гомуми җыелышлары булып әверелде һәм аның вазыйфасын үтәде. Шулай ук без ике тапкыр әдәби ел йомгаклары уздырдык. Аларда әдәби иҗатның нәтиҗәләрен барладык һәм бүгенге көннең мөһим бурычларын билгеләдек. Шуның өстенә шигърият, проза, балалар әдәбияты, тәнкыйть, тәрҗемә, рус телле язучылар һәм драматургия остаханәләренең дә ай саен

утырышлары уздырылды. Бер-ике, хәтта өч остаханәнең берләштерелгән утырышлары уздырылу да традициягә әверелде. Моның белән әйтергә теләгән фикер шул: язучыларга иҗади сөйләшүләр, бәхәсләр алып бару, бер-береңнең фикерләрен ишетү өчен мөмкинлекләр җитәрлек булды. Димәк, берлектә иҗади мохит булдырылган, төрле юнәлештә әдәбият проблемаларын тикшерү мөмкинлеге тудырылган. Ә аны ничек файдалану һәр язучының үз эше.

Биредә инде язучыларыбызның иҗтимагый һәм гражданлык активлыгы турында сүз чыга. Без, инде әйтелгәнчә, язучыларыбызның барысын да актив эшкә тартырга тырыштык. Чынлыкта бу шулай булды да. И. Юзеев, М. Хәбибуллин, Р. Миңнуллин, Р. Харис, Р. Вәлиева, Ш. Җиһангирова, Э. Шәрифуллина, Ф. Сафин, Р. Бәшәр, Н. Хисамов, Х. Миңнегулов, М. Маликова, Ә. Рәшитов, Р. Мостафин, Л. Шагыйрьҗан, Н. Әхмәдиев, Ф. Тарханова, Д. Гарифуллин, Ә. Сәләхов, Ф. Бәйрәмова, И. Гыйләҗев, И. Сирматов, Т. Галиуллин, Р. Сәгъди, В. Нуриев, С. Гәрәева һәм башкалар укучылар белән бик теләп очрашалар, алар белән мәгънәле әңгәмәләр алып баралар, әдәбиятны пропагандалауга зур өлеш кертәләр. Отчет чорында 120 ләп язучының юбилейлары уздырылды. Алар арасында гомумәдәбият күләмендә мөһим юбилейлар да булды: Г. Исхакыйга 125 ел, Г. Кутуйга 100 ел, Рәшит Әхмәтҗановка 60 ел, Ә. Баяновка 75, Н. Фәттахка 75, М. Хәбибуллинга 75, И. Юзеевка 70 яшь, Ш. Бикчуринга һәм А. Гыйләҗевка 75 ел һ. б. Укучылар массасына әдәбиятыбызның асыл сәхифәләрен җиткерүдә мондый әдәби бәйрәмнәрнең әһәмияте бик зур.

Язучының иң үткен коралы—каләм. Күпчелек каләмдәшләребез бу елларда актив иҗат иттеләр. Бу яктан Т. Миңнуллин, Р. Мостафин, Г. Мөхәммәтшин, Н. Орешина, Г. Сәгыйров, Ә. Сәләхов, Д. Салихов, А. Хәлим, Ф. Бәйрәмова, А. Әхмәдуллин, Н. Әхмәдиев, М. Әхмәтҗанов, Р. Әхмәтҗанов, Р. Батулла, Р. Бәшир, В. Имамов, Ф. Сафин, Ф. Садриев, Р. Бохараев, М. Вәлиев, Р. Вәлиева, Л. Газизова, Г. Гыйльманов, Л. Закиров, Р. Кәрәмиев, В. Корчагин, М. Маликова һәм башкаларның каләме йөгерек булды. Шул ук вакытта алар газета-журнал битләрендә, радио-телевидениедә үткен-үткен чыгышлары белән җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп иттеләр.

Оешмабыз шактый зур. Бүгенге көндә 307 әгъза исәпләнә. Әле соңгы идарә утырышында гына да 3 кешене берлеккә кабул иттек. 307 кешенең 230 ы ир-ат, 77 се хатын-кыз. 247 кеше татар телендә, 59 ы рус телендә, 1 се чуваш телендә яза. Язучыларның уртача яше—59,5. Без 3 елга 36 кешене берлеккә кабул иттек. 21 язучыбыз вафат булды. Димәк, язучыларыбызның саны 15 кә артты. Без Пермь, Ульяновск, Чиләбе өлкәләреннән, Башкортстан, Удмуртия республикаларыннан, Мәскәү шәһәреннән дә каләмдәшләребезне берлеккә алдык. Түмән өлкәсе, Казакъстаннан да кабул итәргә әзерләнгән кандидатларыбыз бар. Бу эш алга таба да дәвам иттерелергә тиеш. Чөнки әлеге язучылар үз регионнарында бик тә абруйлы шәхесләр, алар ярдәме һәм үрнәге белән бу якларда яшәүче милләттәшләребездә туган әдәбиятыбызга мәхәббәт тәрбияләнә, татар рухы яшәтелә. Әйтик, Чиләбе өлкәсендә безнең Ирек Сабиров исемле шагыйребез яши. Шушы араларда аның 55 яшенә багышлап өлкә үзәгендә зур кичә уздырылды. Ул андагы 260 мең татар өчен олы бәйрәм булып әверелде. Безнең шагыйребезне Россия Президенты “Ватан алдындагы хезмәтләре” өчен орден-медале белән бүләкләде. Менә бу язучының җәмгыятьтәге олы урыны турында сөйли торган матур факт.

Еш кына язучыларыбыз ярдәмгә дә мохтаҗ була. Берлек җитәкчелеге Татарстан Президенты каршындагы Мәдәниятkә ярдәм күрсәтү фондыннан мохтаҗ язучыларга, юбилярларга квартал саен 1000 әр сумлык матди ярдәм күрсәтте. Барлыгы 363 мәртәбә 1000 әр сум акча бирелде. Кайбер язучыларга 3, 5, 10 мең сумлык ярдәм оештырылды. Сугыш ветераннарына 9 Май уңаеннан шулай ук өстәмә ярдәм күрсәтелде. Өлкәннәр көнендә, Җиңү көнендә, 8 март, 23 февраль, Яңа ел уңаеннан ветераннар, хатын-кызлар, балалар, өлкәннәр өчен бәйрәм чаралары оештыру, чәй мәҗлесләре үткәрү, күчтәнәч-ярдәмнәр өләшү даими алып барылды. Бу эшләрдә “Әдәби фонд” та даими катнашып, ярдәм итеп килде. “Әдәби фонд”ның хисап конференциясендә без бу турыда ачык итеп әйттек. Соңгы вакытларда Язучылар берлеге белән “Әдәби фонд”ның бергәләп эшләве матур нәтиҗәләргә китерде.

Берлек ярдәме белән 25 язучы махсус хастаханәләрдә дәваланды. Иҗат йорты ачылу ике корылтай арасындагы иң зур казаныш итеп каралырга хаклы. Инде туксанга якын язучы үз Иҗат йортыбызда ял итте, дәваланды. Аларга путевка алуга 1 миллион

137 мең 593 сум акча тотылды. Ике корылтай арасында 19 язучы торак шартларын яхшыртты. 24 кеше торак шартларын яхшырту чиратында тора. Алар арасында бер генә кешенең (Хамис Яһудин) квартирасы юк (әле күптән түгел генә Башкортстаннан килде). Р. Хәлиуллина, Н. Акмал, М. Әгъләмов һәм башкаларны фатирлы итүгә без үзебез дә бик куанып яшибез.

Татарстан язучыларының Россия Федерациясендәге башка әдәбиятлар арасында чагыштырмача өстенлеге бар икән, ул барыннан да элек бездә әле китап басылу системасының шактый нәтиҗәле сакланып калуында күренә. Шушы 3 елда барлыгы 385 китап басылды...

Дәүләт нәшриятларында гына елга уртача 128 китап дөнья күргән. 2005 елдан китап өчен гонорарлар артуын да өстәсәң, шактый күңелле генә хәл килеп чыга. Моннан шул аңлашыла: һәр язучы өч ел саен бер тапкыр китап чыгара ала. Дөресе дә шулай, әгәр каләмдәшебез укучыга яңа сүз әйтелгән, эстетик кыйммәте булган әсәр яза икән, ул нәшер ителмичә калмый. Шуның өстенә шушы 3 елда "Рухият" нәшриятында 32 китап чыгуын да әйтергә кирәк. Бу "Татнефть"нең әдәбиятыбызга күрсәткән зур ярдәме. "Рухият", кагыйдә буларак, әдәби мирасыбыздан, бүгенге авторларыбыздан иң затлы, уңышлы әсәрләрне генә сайлап баса. Россия Федерациясенең кайбер төбәкләрендә елына "Рухият" чыгарган сандагы китаплар да басылмый. "Матбугат йорты", "Раннур", "Чаллы" нәшриятлары да бу вакыт эчендә байтак китапларны укучыларга тәкъдим иттеләр. Аерым алганда "Матбугат йорты" нәшрияты—22, "Раннур"—12, "Чаллы" нәшрияты 27 китап чыгарды. Китапларыбызның полиграфик эшләнеше нык яхшырды. Миңа Мәскәүдә китап күргәзмәсендә катнашырга туры килде. Казанда басылган китаплар бу яктан бер дә ким-хур булырлык түгел, киресенчә, "Идел-пресс"та басылган китаплар хәтта өстенлекле күренәләр.

Бер уңайдан "Мәгариф" нәшриятының (директоры М. Вәлиев) бер бик тә игелекле эш юнәлеше турында әйтергә кирәк: биредә яшь авторларга китап укучыларга барып җитү өчен тиешле шартлар тудыруга әһәмият бирелә. Әйтик, берлек әгъзасы булмаган Нурзилә Нотфуллина, Лилия Гыйбадуллиналарның беренче китаплары дөнья күрде. "Ялкын" журналына язучы балалар иҗатын яктыртуга да махсус китап багышланды. "Гөрләвекләр кайтавазы" китабы да шушы игелекле эшнең нәтиҗәсе булып тора.

Без бу очракта Татарстан китап нәшриятына олы рәхмәтебезне әйтергә тиеш. Д. Шакиров кебек бүгенге әдәбиятның ихтыяҗларын тирәнтен белеп, шуларны тормышка ашыру өчен янып-көеп эшләүчене тиешенчә бәяләргә кирәк. Язучылар оешмасына ихлас хәерхаһ булган икенче бер җитәкче—"Идел-пресс" нәшриятының генераль директоры И. Әхмәтҗановны да бу очракта рәхмәт хисләре белән телгә алабыз. Әдәбият язмышы күп очракта шушы җитәкчеләр кулында.

Басылган китапларның структурасы да шактый кызыклы. Ул нормаль үсештә булган әдәбиятның йөзен күрсәтүче көзге булып тора. Әйтик, классикага игътибар зур булуы күзгә ташлана. К. Насыйри, Г. Тукай, Т. Гыйззәт, А. Шамов, М. Әмир, Ә. Ерикәй, Г. Кутуй, А. Алиш, Ф. Кәрим, Ш. Маннур, Ә. Исхакларның китаплары укучыга тәкъдим ителде. Г. Исхакыйның мирасы шулай ук китап хәлендә укучыга кайтарыла бара. Г. Тукайның тууына 120, М. Җәлилнең тууына 100 ел тулу уңаеннан алдагы елда бу бөекләребезнең әсәрләрен чыгару тормышка ашырылачак.

Ниһаять, Ә. Еникинең 5 томлыгы басылып бетте. Бу алты еллыкта, Президентыбыз фатихасы буенча, моңарчы булмаган бик тә әһәмиятле эш башкарылды. Халык язучыларының һәм халык шагыйрьләренең 5 томлыкларын чыгару эше башланды. Ә. Еникидән кала, А. Гыйләҗев, Н. Фәттах, Х. Камалов, Г. Афзал, И. Юзеев, Ш. Галиев, Ф. Яруллиннарның күптомлыклары дөнья күрде инде. Быел исә М. Мәһдиевкә 75, Г. Ахуновка 80 ел тула. Шул уңай белән аларның 5 томлыкларын чыгару да тормышка ашырылыр дигән өмет бар. Бу эш әлеге олуг язучыларыбызның иҗатын бербөтен итеп күрсәтергә, аларның әсәрләрен билгеле бер системада, бөтен зурлыгында тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә.

Бу елларда басылып чыккан әсәрләрнең байтагын укучыларыбыз җылы каршылады, алар бүгенге әдәбиятыбызның йөзен күрсәтү ягыннан үзенә күрә бер казаныш буларак бәяләнделәр. Шагыйрьләрдән Р. Мингалимнең "Дәрт чүлмәге", З. Мансуровның "Җәрәхәтле йөрәк җылырак", Ә. Рәшитовның "Фидаилар", К. Булатованың "Әрнү", Р. Вәлиеваның "Кояшлы яңгыр", О. Левадныйның "О свободном падении вверх", С. Малышевның "Что-то полосатое", Э. Шәрифуллинаның



*Корылтай залының гомуми күренеше.*

"Уйлы еллар", Ф. Әһлиянең "Йөрәкнең соңгы кылы", М. Фәйзуллинаның "Тик сиңа гына", Роберт Әхмәтҗановның "Татар иртәсе", Р. Миңнуллинның "Күңелләр нечкәргәндә", Р. Шәриповның "Мәңгелек яр", Л. Шагыйрьҗанның "Божра вә Хөҗрә", Ф. Гыйззәтуллинаның "Күз нурларым", Ф. Тарханованың "Серле дөнья" китапларын шигъриятебезнең җитди казанышлары арасында карарга кирәктер.

Бу уңайдан Р. Харисның "Исемсезләр" шигъри романын аерып карарга кирәк. Эш авторның бездә шигъри роман жанрына яңа сулыш өреп җибәрүендә генә түгел, бәлки алынган теманың глобаль характерда булуында, шагыйрьнең XX гасырга тулы бер шигъри паспорт булырлык әсәр тудыруында. Әлеге роман, үткәнне бәяләүдән бигрәк, киләчәкне алдан күрүгә нигез булырлык фәлсәфи нәтиҗәләре белән кыйммәтле.

Бездә поэма жанрларының шактый үсеше күзәтелде, әлеге жанрның табигатендә, төзелешендә нык тыгызлык, фикер үткенлеге, гомумиләштерүләрнең көчле булуы тенденциясе билгеләнде. Без Ә. Рәшит, Х. Әюпов, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Харисларның бу юнәлештәге иҗатларының тагын да үсеш алуын көтәбез.

Шулай да бу елларны прозаның аеруча өстенлекле үсеш чоры дип әйтә алабыз. Әйтик, Татарстан китап нәшриятында чыккан китапларны барлаганда да бу тенденция ачык сизелә. 247 китапның 97 се шигърияткә, 112 се прозага карый. Шул ук вакытта 18 е драматургиягә, 27 се әдәбият белеменә һәм тәнкыйтькә нисбәтле. Эш шулай ук санда гына да түгел. Проза китапларының күбесе, матбугатта булмасын, радио-телевидение тапшыруларында яки тәнкыйтьчеләрнең хезмәтләрендә булмасын, киң яңгыраш тапты, аларны укучылар ала, укый, әлеге әсәрләр турында үз фикер-карашларын булдыра. Бу күпсанлы әдәби очрашуларда да расланды. Әдәбиятның күп тармаклы һәм киң колачлы жанрларында, безнең карашка, аеруча отышлы булган әсәрләр рәтендә түбәндәгеләрне әйтә алабыз: М. Хәбибуллинның "Бату хан һәм Ләйлә", "Айбиби", "Атилла", С. Шәмсинең "Низаглы йортта", Р. Вәлиевнең "Җөй", Р. Кәраминең "Өзелгән чәчәк", В. Корчагинның "Женщина в черном", Д. Вәлиевнең "Уверенность в Невидимом", Л. Ихсанованың "Кемгә сөйлим серләремне?", Н. Гыйматдинованың "Парлы ялгыз", Г. Гыйльмановның "Албастылар", М. Әмирхановның "Тәкъдир", Н. Орешинаның "Мина замедленного действия", Ф. Бәйрәмованың "Алыплар илендә", Ф. Сафинның "Саташып аткан таң", Г. Гомәрнең "Гармун телләре уникё", В. Имамовның "Тозлы яра", Р. Бәшәрнең "Ачык капка", Ф. Латыйфиның "Бәйсез этләрне атарга" һ. б.

Драматургларыбызның оригиналь әсәрләре гадәттә сәхнәдә бара. Ләкин безнең татар халкы сәхнә әсәрләрен китап хәлендә укырга да ярата. Моны онытырга ярамый. Соңгы елларда Т. Миңнуллинның 10 томлык әсәрләре дөнья күрде. Г. Каюмовның "Упкын өстендә уен", Э. Яһүдиннең "Мәхәббәткә мәдхия", Д. Салиховның "Гыйлаж тәрәзәләре", "Узып барышлый" кебек җыентыкларын да хуплап каршыладык. Соңгы елларда драма әсәрләре иҗат итү буенча конкурс оештырылып, аның нәтиҗәләре 2 томлык китапка тупланып чыкты. Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең драматургия мәсьәләләренә багышланган махсус киңәйтелгән утырышында тәкъдир ителгән бу китаплардагы әсәрләрне укыгач, мондый конкурсларны уздырудагы һәм

унай, һәм житешмәгән яклар турында уйландык. Әлеге өлкәдә аксаган урыннар күбрәк. Бу әлеге китапларга тупланган пьесаларда да ачык күренде.

Тәнкыйте, әдәбият белеме үскән әдәбият—киләчәге булган әдәбият. Соңгы елларда иҗатның бу юнәлешен җанландыруга нык игътибар ителде. Әдәбиятка Р. Шәрәфиев, Ә. Закирҗанов, Д. Заһидуллина кебек нык әзерлекле, үткен күзле, тирән фикерле тәнкыйтьчеләр килде. Шул ук вакытта өлкән буын тәнкыйтьчеләребез дә актив эшләде. Тәнкыйть өлкәсендә уңышлы хезмәтләр өчен Җ. Вәлиди исемендәге бүләк булдыру да отышлы гамәл. М. Вәлиев, Р. Сверигин, Р. Шәрәфиев, С. Хафизовлар бу бүләкнең лауреатлары булдылар. Әлеге премиянең С. Хафизовка Уфага алып барып бирелүе Башкортстан башкаласында яшәүче зыялыларыбыз өчен чын мәгънәсендә олы бәйрәм булып әверелде. Тәнкыйтьнең ныклы әдәбият белеме җилкәсенә нигезләнү мөмкинлеге булу безне яңа уңышларга өметләндерә. Ике корылтай арасында Р. Мостафинның "О времени, о жизни, о себе", А. Әхмәдуллинның "Офыклар киңәйгәндә., Ф. Урманчеевның "Лиро-эпос татар среднего Поволжья", Д. Заһидуллинаның "Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы", Х. Миңнегуловның "Г. Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты", "Гасырлар өнен тыңлап", Н. Хисамовның "Хәтер сагында", Ә. Закирҗановның "Заман белән бергә", М. Вәлиевнең "Тормыш дулкыннары" һәм башка китаплар әдәбиятыбызны, эстетика үсеше тарихын өйрәнүгә житди өлеш буларак керделәр.

Боларның барысы бергә безнең әдәбиятыбызның эзлекле хәрәкәте, үсеше турында сөйлиләр. Мондый үсеш алга таба тагын да югарырак нәтиҗәләргә китерәчәгенә шикләнмәскә мөмкин. Яшь язучылар белән ел саен уздырылып киленгән семинарлар, "Иделем акчарлагы" конкурслары шулай дияргә мөмкинлек бирә. Бүгенге көндә 30 язучыбыз төрле әдәби берләшмәләргә, түгәрәкләргә җитәкчелек итә. Г. Гыйльманов Казан университетында, М. Хәбибуллин, Р. Мостафин Баулыда, Р. Вәлиева, Д. Салихов Нурлатта, И. Юзеев, Ш. Мостафин Мамадыш районында, Ф. Садриев Мөслимдә, Р. Фәизов Арчада, Э. Шәрифуллина Казан педагогия көллиятендә, Ф. Исмәгыйлова Азнакайда, Г. Мөхәммәтшин Балтачта, Р. Низамиев Теләчедә, Р. Бәшәр Чаллыда, Ф. Абдуллин Түбән Камада, Т. Нәҗмиев Сабада эшне аеруча уңышлы алып бардылар. Яшь язучыларның иҗатларын җанландыру һәм бәяләү өчен Р. Вәлиев Түбән Камада, Р. Миннуллин Казанның 81 нче мәктәбендә, Р. Харис Казанның 4 нче гимназиясендә һәм Буа шәһәренең Луначарский исемендәге мәктәбендә үз исемнәре белән аталган премия булдырдылар. Аны ел саен бирә киләләр, әлеге уку йортларында бу бүләккә лаек булу өчен ел буе эш кайный. Актанышта ел дәвамында Нур Баян исемендәге бүләкне алу өчен бәйге алып барыла. Анда катнашучылар елдан-ел арта бара.

Без шушы елларда халык шагыйрьләре исеменә лаек булган Р. Харисны һәм Р. Миннуллинны, Г. Тукай бүләгенә лаек булган М. Хәбибуллинны, М. Юнысны, Р. Мингалимне ихлас котлыйбыз. М. Җәлил бүләгенә лаек булган "Мәгариф" китап нәшрияты директоры М. Вәлиев, "Сәләт" фонды җитәкчесе Җ. Сөләймановлар өчен сөенәбез. Ел саен бирелеп барган Г. Исхакый, Г. Державин, А. Алиш, Ф. Хөсни, Җ. Вәлиди бүләге лауреатларын да мактаулы исемнәр белән котлыйбыз. Һ. Такташ бүләгенең беренче лауреаты Р. Гаташны кинәнеп тәбрик итәбез.

Хисап бирү чорында төп эш юнәлешләренең берсе башка әдәбиятлар белән хезмәттәшлекне үстерү булды. Без чуаш, удмурт, мари, мордва, башкорт, Түбән Новгород, Кемерово, Ульяновск төбәкләрендәге коллегаларыбыз белән аеруча якын мөнәсәбәтләр урнаштыра алдык. Чуашиядә татар әдәбияты, Татарстанда чуаш әдәбияты көннәре уздырылды. Алар ике республика тормышында әһәмиятле вакыйга булып әверелде. Балтач районының Лыза авылында туып-үскән күренекле удмурт язучысы Георгий Медведевның тууына 100 ел тулуны билгеләп үтү безнең удмурт дусларыбыз тарафыннан югары бәяләнде. Мари Эльнең Бәрәңге районында, Ульяновск өлкәсенең иске Кулаткы, Барыш районнарында уздырылган татар әдәбияты көннәре шулай ук олы вакыйгалар буларак кабул ителде.

Соңгы елларда башкорт язучылары белән элемтәләрнең йомшавы безне борчый иде. Узган елдан башлап бу юнәлештә матур адымнар ясалды. Бу республиканың Язучылар берлеге идарәсе рәисе узган ел Татарстан Республикасы көненә килде, шигырь бәйрәмендә чыгыш ясады. Язучылар берлегенең 70 еллык тантаналарында да башкорт делегациясе актив катнашты. Без исә Уфада С. Юлаевның тууына 250 ел,

М. Кәримгә 85 яшь тулу уңаеннан уздырылган тантаналарда булдык. Л. Шәех һәм Л. Габидуллина Уфада яшь язучылар семинарында булып кайттылар. Берничә еллык тәнәфестән соң без ел саен яз көне Бәләбәйдә уздырылып килүче "Илһам чишмәләре" дигән фестивальгә чакыру алдык. Шагыйрь Н. Әхмәдиев анда татар шигъриятенең затлылыгын лаеклы рәвештә күрсәтә алды.

Татарстан Язучылар берлеге рәисенең Түбән Новгородта Идел буе федераль округына кергән төбәкләрнең язучылар оешмалары җитәкчеләре киңәшмәсендә катнашуы шулай ук күрше әдәбиятлар белән элемтәләрне җайга салырга ярдәм итте. Алга таба Кабарда-Балкар һәм Якутия әдәбиятлары белән элемтәләр булдыру турында сүз алып барыла.

Безнең иҗади оешманың төп канунына—Уставына 1999 елда узган корылтайда билгеле бер шартларда кайбер үзгәрешләр кертелгән иде. Без бүгенге көнгә кадәр шул тәртипләр белән яшәдек һәм яшәвебезне дәвам иттерәбез. Ләкин заманалар хәрәкәттә, мондый документлар да үзгәрмичә кала алмый.

Әйтик, берлек рәисенең һәм идарәсенең эшләү срогы 3 ел дип билгеләнде. Җитәкчелекнең бу составы шушы таләпкә буйсынып эшләде. Үзегез күреп торганча, без аннан бер адымга да тайпылмадык. Хәтта XIV корылтайны ике айга алданрак та уздырдык. Чөнки июль ае корылтай уздыру өчен төрле яклап уңайсыз булыр дип уйладык. Һәм ул дөрес тә булды. Инде XV корылтайны да, көнен көнгә туры китереп дигәндәй, нәкъ 3 ел тулгач уздырабыз.

Ләкин, тәҗрибә күрсәткәнчә, корылтайларны болай уздыру үз-үзен акламый. Ул гади олы җыелышларны хәтерләтә башлый. Корылтай уздыруның мәшәкатьләре дә күп. Чын-чынлап иҗади эшләрне оештырып, язучыларның мәнфәгатьләрен кайгыртып яшисе урынга ярты ел буена корылтайны әзерләү мәшәкатьләре белән мәшгуль булырга туры килә. Ә ул мәшәкатьләр шактый күп һәм катлаулы. Идарә әгъзалары да үзләрен психологик яктан дәвамлы эшкә көйләмиләр, бу мохиттә үзләрен вакытлы хис итәләр. Моннан эш бары тик оттыра гына. Бу тулысынча рәискә дә карый. Яңа рәис сайланган очракта ул бер ел буе эшкә өйрәнә, бер елын басылып эшли, бер елын китәсе ел дип эшли.

Сайланып эшли торган органнарның берсендә дә 3 еллык вәкаләт юк. Гадәттә ул 5 ел, кайбер очракларда 4 ел максатка ярашлы дип санала. Чөнки ул вакытта сайланган кешеләрдән эш һәм нәтиҗәләрне дә тиешенчә таләп итеп була. Димәк, безгә бу срокны 4 яки 5 ел дип үзгәртергә кирәк дип саныйм. Шул ук вакытта Чаллы, Әлмәт бүлекләре җаваплы секретарьларының һәм бүлек бюроларының эшләү срогын да берлек рәисе һәм идарәсе срогына туры китерү мөһим.

Уставта ачыклык табарга тиешле бер мөһим мәсьәлә бар, ул да булса Россия Язучылар союзы белән мөнәсәбәтләрне ачыклау. Барыбызга да билгеле булганча, безнең гамәлдәге Уставта мондый бәйләнешләр бөтенләй каралмаган. Бу да туксанынчы еллар башында мәгълүм вәзгыятьтә шулай эшләнгән иде. Әмма бүгенге шартларда тулы бер иҗат оешмасының эшчәнлек мөнәсәбәтләрен дөньядан аерып кую үзен акламый. Чөнки Татарстан Республикасының тормышы һәм иҗтимагый-сәяси, һәм икътисадый, һәм хокук ягыннан бәйләнеше меңнәрчә җепләр ярдәмендә гомумроссия белән тыгыз бәйләнгән бер вакытта без язучылар гына читтә торып кала алмыйбыздыр...

Ерак барасы түгел, үзебезнең "Әдәби фонд" та Россия "Әдәби фонд"ы белән мөнәсәбәтләрен өзмәде. Иманым камил, Г. Рәхим—бу оешманың идарә рәисе үзе расларга—әгәр Россия "Әдәби фонды" ярдәм кулын сузмаса, Татарстан "Әдәби фонды" инде күптән ябылган булыр иде. Чөнки Татарстан Мәдәният министрлыгы моннан берничә ел элек "Әдәби фонд"ның яшәү чыганакларын өзеп куйды.

Мисалга ПЭН үзәгенә берләшкән язучылар төркемен китерү дә урынлы булыр. Алар да үзләренең Мәскәүдәге коллегалары белән даими элемтәдә торалар. Бу бик табигый кабул ителә. Бу—тормышчан ихтыяҗ, аңардан беркая да китеп булмый. Әйтик, язучының эш стажын билгеләргә кирәк. Моны аның матбугатта чыккан беренче әсәреннән алып саныйлар. Бу хакта, нигездә китап палатасында саклана торган матбугат органнарына таянып, Татарстан Язучылар берлеге пенсия органнарына тиешле белешмәне бирә иде дә, шуның белән мәсьәлә хәл ителә иде. Әмма 2004 елның 1 гыйнварыннан алып безнең белешмә ярамый башлады, димәк, аны Мәскәүдән алырга кирәк. Без моңа кадәр аны Халыкара Язучылар союзлары берләшмәсеннән

ала килдек. Хәзер бу оешма таркалып бара. Аны әкренләп Россия Язучылар берлеге алыштыра...

Мәсьәләне хәл итүнең бер генә юлы бар—Россия Язучылар берлеге белән договор нигезендәге мөнәсәбәтләр урнаштыру. Бу эшне кайберәүләр иҗат союзлары турында закон кабул ителгәч эшләргә тәкъдим итәләр. Моның әлеге закон белән бернинди бәйләнеше юк...

Татарстан Язучылар берлегенең 3 еллык эшчәнлеген күздән кичергәндә шуны әйтергә була: каләмдәшләребез гаять күп һәм төрле эш башкарганнар. Төп эшебез булган иҗатта да шактый куанычлы нәтиҗәләребез бар.

Берлекнең матди ягын ныгыту буенча да байтак эш башкарылды. Без бирегә килгәндә бердән-бер машина да йөрмәслек хәлдә иде, хәзер ике җиңел машина, бер “Газель” микроавтобусы бар. Берничә компьютер, башка күп кенә техник җиһазлар булдырдык. Бинага 840 мең сумлык ремонт уздырдык. Түбәне тулысынча алыштырдык. Бинаны тышкы яктан җиренә җиткереп ремонтладык. Хәзер эчке яктан капиталь ремонт һәм реконструкция кирәк булачак. Моның өчен 30 миллион сумнан артык акча таләп ителә.

Ләкин һәрбер җанлы эштәге шикелле, алга таба үсешне тәэмин итү өчен бик күп резервлар да бар. Сез алар турында сөйләрсез, чыгышларыгызда эшлекле тәкъдимнәр бирерсез. Мин фикер алышу, Х. Туфан әйткәндәй, “гүзәл гамь”, “анабыз Әдәбият” һәм аның бүгенге һәм бигрәк тә иртәгәге бурычлары турында барыр дип ышанам. Докладчы буларак, әле минем йомгаклау өлешендә чыгыш ясыйсым бар. Димәк, кайбер мәсьәләләрне шул вакытта яктырту мөмкинлеге булачак. Резолюция проектында бурычлар ачык чагылыш тапкан һәм ул сезнең чыгышлар белән камилләшер.

**Гәрәй Рәхим**

## ЯЗУЧЫ ДА ЯРДӘМГӘ МОХТАҖ

Моннан берничә ел элек без Россия җирлегендә барлыкка килгән иҗтимагый хәйрия оешмасы “Әдәби фонд”ның 140 еллыгын билгеләп үттек. Бу оешманың төп максаты авыру, инвалид, картайган һәм ярлы язучыларга акчалата ярдәм күрсәтеп, аларга иҗат мөмкинлекләре тудыру иде.

Совет чорында язучыларыбызга “Әдәби фонд” аша матди ярдәм күрсәтү эшен тулысы белән дәүләт үз кулына алды. Урта һәм өлкән буын язучылар хәтерлидер, Кырымдагы, Грузиядәге, Балтыйк буендагы, Мәскәү янындагы атаклы курортлар һәм санаторийлар зоналарында СССР Литфондының менә дигән Иҗат йортлары эшләп килде, аларга һәр язучы юнь генә бәягә путевкалар алып, бик тә уңайлы шартларда иҗат итәргә мөмкинлек бар иде. Дөресен әйткәндә, татар әдәбиятының Ватан сугышыннан соңгы 30-40 ел эчендә дөнья күргән иң асыл әсәрләре әнә шул Иҗат йортларында язылды. Ул чакта Литфонд тарафыннан язучыларга матди ярдәм күрсәтү дә сизелерлек дәрәҗәдә иде. Язучы роман яки күләмле башка әсәр язар алдыннан Литфондка, “Иҗат чоры өчен” дип, язылачак әсәрен күрсәтеп гариза язды да, аңа шул әсәрен язу чорына шактый акча бирелде. Язучы язылачак әсәре өчен кирәкле материалларны эзләп СССРның теләсә кайсы почмагына Литфонд командировкасы белән йөри алды. Авыру язучыларны дәвалау өчен ул чакта иң сыйфатлы медицина ярдәме күрсәтүче түләүле поликлиникаларга Литфонд бушлай талон бирә иде. Шул ук вакытта Литфондның язучыларга фатир алып бирерлек, вафат булган язучыларны олы хөрмәт белән соңгы юлга озатуның бөтен чыгымнарын күтәрерлек мөмкинлеге бар иде. Татар язучыларының теләсә кайсына Мәскәүдәге СССР Литфондының атаклы Чазовлар эшләгән үзәк поликлиникасыннан, юк кына бәягә менә дигән костюм яки

пальто тегеп бирә торган промкомбинатыннан файдалана ала иде. Әлбәттә, бу кадәр хәйрия ярдәме күрсәтү өчен Литфонд тарафыннан бик күп акча тотылды. Ә бу акча каян килә иде соң? СССР хөкүмәте карары белән әдәби китаплар баса торган бөтен нәшриятлардан, әдәби әсәр нәшер итә торган бөтен журналлардан, бөтен театрлардан авторлык гонорары күләменең 2 проценты кимәлендә акча Литфондка күчерелә иде. Әмма ул авторлар гонорары исәбеннән түгел, дәүләт исәбеннән керә иде. Шулай итеп, СССРдагы бөтен халыкларның классик язучылары, әйтик, Пушкин, Толстой, Тукайның, грузин, азәрбәйҗан, Урта Азия, Балтыйк буе классикларының ул чактагы берничәшәр йөз мең, хәтта миллион данә тираж белән чыккан китапларыннан килгән керемнең 2 проценты Литфондка күчерелеп барды, ягъни инде әллә кайчан вафат булган классик язучыларның хәйрия акчасы яңа буын язучыларга иҗади шартлар тудыруга тотыла иде.

90 нчы еллардагы демократик җилләр тәэсирендә Россия Дәүләт Думасы "Иҗтимагый оешмалар турында" закон кабул итте. Ә бу закон буенча иҗтимагый оешмаларга дәүләт бюджеты бер тиен дә акча бүлеп бирергә тиеш түгел, алар үз уставлары нигезендә матди яктан үз-үзләрен тәэмин итәргә тиешләр. Билгеле булганча, Язучылар берлеге һәм Литфонд дәүләт оешмалары түгел, иҗтимагый оешмалар. Шушы закон нигезендә әлеге 2 процентның Литфондка күчерелүе туктатылды һәм Россиядәге бөтен республикалар, крайлар, өлкәләр литфондлары бер тиен акчасыз калдылар. Мәскәүдә СССР Литфондының мөлкәте зур иде. Ул мөлкәтнең бер өлешен СССРның Союздаш республикалары литфондларын берләштергән Халыкара "Әдәби фонд" алып калды, бер өлешен Россия Федерациясе язучылары Литфонды, үзбаш аерылып, үзенә алды. Россия Литфондындагы "яңа урыслар" тиз арада Литфонд мөлкәтен приватизацияләп саттылар. Шулай итеп, Мәскәү янындагы Малеевка иҗат йорты, поликлиника, Галицино Иҗат йорты язучылар карамагыннан ычкынды.

Ә менә Халыкара Литфонд бүгенгә кадәр үз милкен саклап килә. Ул Переделкино Иҗат йорты, промкомбинат һәм башка предприятиеләрдән килгән керем хисабыннан Халыкара Литфондны тәшкил иткән җирле литфондлар язучыларына күпмедер ярдәм итә. Без, әлбәттә, бөтен милекне сатып юкка чыгарган һәм язучыларга бер тиен дә ярдәм итмәгән Россия Литфондыннан аерылдык. (Безнең берлекнең әле үзләре дә таркау хәлдә гомер кичергән Россия язучылар оешмалары белән якынаюында да әлләни мәгънә күрмим мин.) Без элеккеге СССР республикалары Литфондлары хокукында Халыкара Литфондны гамәлгә куючыларның берсе булдык.

Бүгенге көндә Халыкара Литфонд ярдәме белән без һәр елны 9 майда, өлкәннәр көнендә, 8 мартта һәм Яңа ел бәйрәмендә сугыш ветераннары, өлкән әдипләр, инвалид һәм авыру язучыларга, вафат булган язучыларның өлкән яшьтәге гаилә әгъзаларына, әдипләребезнең кече яшьтәге балаларына һәм оныкларына бәйрәмнәр оештырабыз, кулдан килгәнчә бүләкләр, азык-төлек пакетлары белән ярдәм итәбез. Аеруча мохтаҗ язучыларга шәхси финанс ярдәме күрсәтәбез. Халыкара Литфонд вафат булган язучыларны соңгы юлга озату өчен өчәр мең сум акча бүлеп бирә.

Әлбәттә, болар аз, бик аз, хәтта, әйтер идем, бу хәйрия ярдәме түгел, хәерчегә хәер бирү кебек кенә. Безнең бит хәтта язучыларыбызга сатып алган бүләкләрне, азык-төлек пакетларын кибеттән төяп алып кайтырга машинабыз да юк. Шулай да без Халыкара Литфонд белән мөнәсәбәтләрне дәвам итәргә кирәк дип саныйбыз.

Язучыларның хәле бездә генә түгел, бөтен Россияда һәм элеккеге СССРны тәшкил иткән республикаларда дә әйбәт түгел. Әйтик, Россия Федерациясенең бөтен өлкәләрендә диярлек һәм күп кенә республикаларда литфондлар бөтенләй яшәүдән туктады, Язучылар союзлары да бармак белән генә санарлык. Аллага шөкер, безнең республикада әле Президентыбыз Минтимер Шәрипович һәм хөкүмәтебезнең язучыларга аеруча җылы мөнәсәбәте аркасында Язучылар Союзы да, "Әдәби фонд" та республикабызның рухи тормышына шактый тәэсир итәрлек җегәрдә яшәп килә.

Без Россия һәм элеккеге СССРны тәшкил иткән республикаларга караганда Татарстандагы сәяси һәм иҗтимагый тотрыклылыкның ышанычлырак булуына шатланабыз һәм моның белән горурланабыз да. Сүз дә юк, бу тотрыклылыкны Президентыбыз, парламентыбыз һәм хөкүмәтебезнең зирәклеге тәэмин итә. Шул ук

вакытта республикабыз халкының һәм гомумән бөтен татар халкының күңел көрлеген саклауда, халыкның рухи халәтен сәламәт тотуда иҗат кешеләренең, аерым алганда язучыларның өлеше бәяләп бетергесез зур. Бүгенге көндә халыкның рухи халәтен телевидение, радио, газета-журналлар, китаплар, кино, сәхнә, театр, гореф-гадәтләребезгә бәйләнешле бәйрәмнәр, мәгариф системасы һәм дин гамәлгә ашыра. Ә бит радио-телевидение, газета-журналлар, китап нәшриятлары, кино сәнгате, концертлар, театрлар, бәйрәмнәр һәм юбилей чараларының 70-80-90 проценты классик әдипләребезнең һәм бүгенге язучыларыбызның әсәрләре, күп вакытта аларның турыдан-туры катнашы белән тормышка ашырыла. Ә шушы титаник хезмәт өчен язучыларга матди яктан мөнәсәбәт ничек соң? Ярый әле газета-журналлар, китап нәшриятлары язучыларның басылган әсәрләре өчен чагыштырмача ярыйсы гына гонорар түлиләр. Ә радио-телевидение, республикадагы бәйрәм һәм тантаналы көннәрдә куелган йөзләрчә концертларда, юбилейларда, бәйрәмнәрдә, кичәләрдә файдаланылган әдәби әсәрләр өчен язучылар бер тиен дә акча алмыйлар. Ә бит әлеге чаралар репертуарының 90 процентына кадәрен язучыларыбыз иҗат иткән әсәрләр тәшкил итә. Шәүкәт Галиев, Роберт Әхмәтҗанов, Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, Роберт Миңнуллин, мәрхүм Гөлшат Зәйнашева һәм башка бик күп шагыйрьләребез иҗат иткән җырлар, прозаиклар, драматурглар, юмористлар әсәрләре радио һәм телевидениедән бөтен дөньяга тәүлек буе яңгырап тора. Язучыларыбызның ул әсәрләре халкыбызның күңел көрлеген саклауда, халыкның рухи халәтен сәламәт тотуда гаять зур урын тоталар. Әмма моның өчен авторлар бер тиен акча да алмыйлар—радио түләми, телевидение түләми, меңләгән концертлардан акча килми.

Яки алыйк мәгариф өлкәсен. Мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбияты дәресләренең, һәр мәктәптә көн саен диярлек оештырыла торган гомуми чараларның 80 проценттан артыгын язучылар әсәрләре тәшкил итә. Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре тулаем диярлек язучылар әсәрләреннән тора. Димәк, балаларны, яшь буынны тәрбияләүдә язучыларның өлеше бәһаләп бетергесез зур. Мәгариф өлкәсенә без республика бюджетыннан фәлән миллион акча бүлеп бирәбез. Балаларны тәрбияләүдә, дәреслекләр чыгаруда, дәресләр үткәрүдә әсәрләре һәрдаим файдаланыла торган язучыларга бу акчадан бер тиен дә тамый—аларның әсәрләре тулысынча бушка файдаланыла. Бәлки безгә язучыларыбызның әсәрләрен радио-телевидениедә һәм мәгариф системасында файдаланган өчен аларның хезмәтен бәяләү максатында әнә шул радио-телевидение, мәгариф системасына, юбилейлар һәм бәйрәмнәргә тотыла торган акчаның 1-2 процентын “Әдәби фонд” исәбенә күчереп, язучыларга матди ярдәм күрсәтү өчен файдаланырга кирәктер? Яки башка юлларын табып, язучыларыбызның югарыда әйтелгән хезмәтләренә түләүне хәл итәргә кирәктер. Минемчә, хөкүмәтебез бу эшне җайга сала алыр иде.

Халыкның рухи халәте дигәннән тагын бер җитди мәсьәләне әйтмичә китеп булмый. “Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел”,—ди шагыйрь. Борынгыдан халыклар үзләренең бөек улларын һәм кызларын җирләүгә, аларның каберләрен күз карасыдай саклауга зур игътибар биргәннәр. Византия һәм грек пантеоннары шул турыда сөйли. Күп халыклар бу традицияне бүген дә дәвам итә. Әйтик, грузиннар, әрмәннәр үзләренең бөек кешеләрен җирләү өчен махсус пантеоннар булдырды. Алар бөек кешеләрне бер урында җирлиләр һәм ул урынны дәүләт күләмендә карап, изге бер урын итеп тоталар. Мәскәүнең үзендә дә, пантеон дип аталмаса да, атаклы кешеләрне җирләү өчен махсус зиратлар бар. Дөрес, без дә күренекле сәнгать эшлеклеләрен татар зиратына урнаштырырга тырышабыз. Әмма, бүген татар зиратының шәһәр уртасында кысылып калуы сәбәпле, мөмкинлекләр бик чикле. Татар язучылары гомумән төрле җирдә чәчелеп җирләнәләр. Әйтик, Арча кырындагы зиратта Ибраһим Гази, Зәки Нури, татар зиратының төрле почмакларында күп кенә язучыларыбыз, Мәдәният һәм ял паркы янындагы туганнар каберлегендә Галиәсгар Камал белән Һади Такташ ята. Моннан унбиш-егерме еллар элек, хәзер инде үзләре дә мәрхүм өлкән татар әдипләре һәм бүгенге олпат язучыларыбыз М. Горький исемендәге Мәдәният һәм ял паркы янындагы туганнар каберлеген Татарстанның атаклы кешеләре пантеоны итәргә дигән тәкъдим белән чыкканнар иде. Аны тиешенчә төзекләндергәндә, территориясендә мөселман, христиан һәм

башка диннәр өчен аерым урыннар билгеләп куйганда, бу мәйданны Татарстанның атаклы кешеләре пантеоны итеп зурлап файдаланырга булыр иде. Урыны да яхшы, җире дә җитәрлек...

Татарстан "Әдәби фонд"ы бүген язучыларыбызның һәрберсенең матди һәм иҗади хәләтен белеп тора. Без аларның һәрберсенә шәхси ярдәм итәргә әзер. Әмма моның өчен язучыларыбызның татар халкы тормышында тоткан урыны дәрәҗәсендә дәүләт катнашы да кирәк. Без һәрвакыт республикабыз җитәкчеләренең безгә карата әйбәт мөнәсәбәтен тоеп яшәдек. Шуңа күрә, хәзер тормыш никадәр катлаулы булса да, язучыларыбызның кәефе төшенке түгел. Дәүләт органнарының әлеге әйбәт мөнәсәбәте әдипләребезгә матди ярдәм төсендә тагын да бераз артса, безнең язучыларыбызның күңеле күкнең җиденче катында булыр иде.

Амин.

Дания
Заһидуллина

# ИКЕ КОРЫЛТАЙ АРАСЫНДА ТАТАР ПРОЗАСЫ

XX гасыр ахырына татар прозасында алга таба үзгәрешләргә китерәчәк стиль тенденцияләре аермачык күзаллана башлаган иде. Лирик–эмоциональ башлангыч үсү; психологизм тирәнәю; тәнкыйди башлангыч көчәю, һәм иң әһәмиятлесе, интеллектуаль тенденция алга чыгу үзен нык сиздерде. Яшәешкә, тормышка, кешегә караган универсаль кануннарны барлап һәм укучыга тәкъдим итеп язылган әсәрләрдә, реаль чынбарлыкны тасвирлау белән чикләнмичә, гомумән яшәешне колачлаган яңа әдәби модель төзелә башлады. Шушы сыйфатлар ике корылтай арасында иҗат ителгән проза әсәрләрендә дә әйдәп бара. Милли әдәбиятыбыз төрле стильләр, тенденцияләр, алымнар синтезына нигезләнгән үзенчәлекле әсәрләрне мәйданга чыгарды. "Бүгенге дөнья әдәбияты—заман хакында сөйләүче түгел, ә замандашлар белән тормыштагы әһәмиятле мәсьәләләр турында сөйләшүче ул" (В.Новиков) дигән сүзләр татар әдәбиятындагы соңгы еллар эзләнүләренә гомуми бәя була ала.

Проза хакындагы сүзне олы жанр—романнан башлыйк. Һәр милли әдәбиятның көчен романнар язылу билгели. Бу жанрда реализм әйдәп баручы ролендә кала һәм, шәхеснең кыйммәтен ассызыклаган хәлдә, традицияләргә тугрылык саклап, иҗтимагый тормышка аерым игътибар бирелә. Әсәрләрдә чор картинасын тудыру, заман, хакимият, системаның бөтенлекле образын укучы күз алдына бастыру максаты куела. Реалистик әсәрләр ярдәмендә татар язучылары татар халкы үткәненең аерым бер дәверләре сурәтен яңадан тергезергә, шушы сурәт ярдәмендә бүгенге һәм киләчәк хакында уйландырырга омтылалар.

Реалистик әсәрләрдән, Ф.Садриевның "Бәхетсезләр бәхете" трилогиясенең икенче китабы дөнья күрде. Трилогия совет заманына колачлы тәнкыйди бәя бирү максатын куя. Автор бәясе—чыннан да, күпъяклы, күппланлы. Аның заманга хас типлар тудыру осталыгын да билгеләп үтү кирәк. Әсәр партиянең халык тормышы белән идарә итү механизмына деконструкция ясау ягыннан көчле. Икенче кисәк иҗтимагый көрәштә сындырылуга хөкем ителгән шәхеснең деградация кичерү этабын колачлый, совет идеологиясенең үзфикерле шәхесне юкка чыгаруга йөз тотуын, партия һәм талантлы шәхес мөнәсәбәтләрен күрсәтүе ягыннан игътибарга лаек.

Х.Камаловның совет чорындагы хезмәт–көнкүреш романнарын искә төшергән "Үксезләр"е—катнашучы геройлары, аларның тарихлары чиктән тыш күп булган, нигездә сөйләшүгә корылган реалистик әсәр, аерым бер тәнкыйди, әхлакый фикерләр белән баетылган булса да, традицион кабул ителә, роман жанрына яңалык алып килми.

К.Кәримовның "Сакау күке" романы—дилогиянең икенче китабы—хезмәт

кешесенең тормышта үз урынын табу, бәхетле булу өчен көрәшен тема итеп күтәрә. Су чыгаручы Фазыл тарихы итеп уйланылган романда үзгәртеп корулар, постсовет чоры картинасы тергезелә, заманга хас чирләр көлүнең күп кенә төрләре: ачы сатира, ирония, хәтта җылы юмор ярдәмендә ачыла. Реалистик әсәрдә тудырылган тормыш моделе шәхси мәнфәгатьләр һәм иҗтимагый мәнфәгать, мәхәббәт һәм хыянәт, әхлаклылык һәм әхлаксызлык, хакыйкать һәм ялган, матди һәм рухи башлангычлар дигән антиномик принципларга нигезләнгән. Авторның әхлакый позициясе әйдәп бара һәм әсәр уйланмасы шуңа таңгәл килә. Ләкин икенче пландагы геройлар тарихын җентекле тасвирлау әсәрне зурайтып җибәргән.

В.Имамовның "Тозлы яра" романы әдәбият белән тарих синтезына омтылып язылган. Уйланма һәм документаль фактларның чигендә урнашкан тормыш моделе, әдәби чынбарлык булудан бигрәк, тарихи хакыйкать кебек кабул ителә. Әмирнең яшәү һәм үлем вакыйгаларын колачлап алган ике китап сюжеты, асылда, кеше тормышы тарихы түгел, ул 1922–39 елларда совет хакимияте урнашу тарихы һәм укучыны бер хакыйкатькә алып килә: Рәсәйдә яңа тормыш төзү—иң беренче чиратта, хакимлек өчен көрәш булган. Яңа тормыш төзүдә катнашкан типлар галереясындагы иң гаярь кеше итеп сурәтләнгән Әмир совет системасы тарафыннан көчле кеше рухының чарасызлык чигенә җиткерелүенә мисал була. Әсәрнең исеме киңәйтелгән метафора кебек аңлашыла: яңа тормыш төзү—кешелек тарихындагы тозлы яра, ялгыш, хата, фаҗига; аның аерым сәхифәләре—кешеләр, гаиләләр, нәселләр, милләтләр күңелендәге тозлы яра, үкенечләр, күз яшьләре... Хөр яшәргә омтылучы кешене иҗтимагый законнарга буйсындыруның—кол итү, рухи җимерү булуы хакындагы фикер фактологик материалның һәм натуралистик сурәтләрнең байлыгы артына яшеренгән һәм публицистик материалның бай һәм көчле булуы әсәрнең әдәбилегенә, тәэсирлелегенә зыян сала.


*ТР Премьер-министр урынбасары—Мәдәният министры Зилә Вәлиева язучылар белән.*

Ф.Сафинның "Саташып аткан таң" трилогиясе ике корылтай арасында реалистик прозаның зур уңышы дип бәяләнергә лаек. Тарихи роман XX гасырның беренче чирегендә булып узган вакыйгаларга һәм илкүләм, һәм милли мәнфәгатьләр, милли тарих күзлегеннән бәя бирүе белән яңа. Үзәккә Әхмәтсафа Дәүләтъяров—татар тарихында билгеле шәхес куелган. Аның дөньяга карашы формалашу, чын күңелдән ышанып яңа тормыш төзүгә катнашуы, зур исем–дәрәҗәләргә ирешүе һәм шушы системаның канлы тегермәнендә юкка чыгарылуы бәян ителә. Автор героен, барыннан да элек, фаҗигале язмышка ия, яңа тормыш төзү идеясенең корбаны булган татар кешесе итеп сурәтли. Романнар 1920–30 елларда илдә барган үзгәрешләрне, аларның татар халкы язмышына тәэсирен фаҗига буларак бәяли, язучы экзистенциясе көчлеләрне юк иткән заманга, ялгыш юлдан киткән җәмгыятькә, корбан булган шәхесләргә һәм төп көчләрен югалткан милләткә юнәлтелә, укучыда да үкенеч ачысы тудыра.

Реалистик романны тарихи материал белән башкача кушуның бер мисалы—М.Әмирхановның "Тояк эзе" әсәре булды. Төп иҗтимагый сюжет сызыгын "болгарчылар" һәм "алтын урдачылар" теорияләре бәрелешенә, фәндә яңалык һәм официоз каршылыгына корган әсәрдә зыялы татар кешесе үзәккә куела. Ләкин бу герой иҗтимагый һәм шәхси тормышта капма–каршы кыйммәтләргә йөз тоткан шәхес булып чыккан. Натуралистик, тупас детальләр дә әсәрне бизәми.

Татар прозасында көчәйгән интеллектуаль тенденция әдәби әсәрдә язучы белдерергә теләгән фикернең тормыш законнары кебек бирелүен гамәлгә куя. Мәрхүм Р.Сибатның тетралогиядән соңгы китап буларак билгеләнгән "Инабәт" һәм "Шаһ тур" кебек романнарын да шушы агымда бәяләргә кирәк. Татар кешесенең милли сыйфатларын барларга омтылып язылган әсәрләрдә укучыга тормыш кануннарын җиткерү максаты куелган. Ялгызак шәхес, аның иҗтимагый богауларны һәм язмышны җиңү фәлсәфәсен биреп, Р.Сибат кешенең кешелекле булып, кеше булып калу фикерен ассызыклый. "Яшәештә кеше өчен кирәк биш нәрсә бар: тән саулыгы, җан–рух тынычлыгы, гаилә ныклыгы, тормыш иминлеге, йорт–җир, милләтең бөтенлеге" дип раслаучы язучы яхшылыкның да, явызлыкның да кешенең үзеннән килүен һәм башка күп кануннарны әсәр текстына урнаштыра. Дөрес, романнарның әдәби эшләнеш ягы көчле түгел, тел–интонация ягыннан язучының алдарак басылып чыккан "Ялгызак" әсәре белән чагыштырганда да күпкә оттыра. Күпсүзлелек, натуралистик детальләргә мөрәҗәгать итү, халык сөйләменә һәм көнкүрешенә якынайтырга теләп стильләштерү, берьяклы һәм әсәрдән әсәргә кабатланучы характерлар кертү эстетик яктан үзен акламый.

Традицион романнардагы иҗтимагый сызыкны фәлсәфә белән алыштыру омтылышы ясап язылган роман—З.Хөсниярның "Терсәк сугышы" кешегә һәм тормышка үзенчәлекле күз ташлавы белән кызык. Бу язучының каләме заманга хас яңа күп кенә билгеләрне беренчеләрдән булып калкыта кила. Ләкин романдагы фәлсәфи материал милли тормыш сурәте белән кушылмый, чит әдәбияттагы алымнарны файдалану күзгә бәрелә.

Интеллектуаль тенденция белән бергә, әдәбиятка постмодернистик алымнар үтеп керү, аларның әйдәп баручы рольгә омтылуы күзәтелә. Шундыйлардан, Т.Галиуллин трилогиясендәге өченче роман—"Төнге юллар"—басылып чыкты. Романнар беренче карашка маҗаралы әсәр кебек уйланылганнар, шуларга хас, җинаятьләр, үтерешләр үзәккә куела. Ләкин язучы туктаусыз үтереш, акча өчен көрәш, кан коеш, үч алу, куркыту, дустыңны сату кебек хәлләрнең җәмгыятьтә нормага әверелүен күрсәтә. Мондый җәмгыятьтә көрәшчеләр һәм геройлар әлеге явызлыкны тудыручыларга, күбәйтүчеләргә; гөнаһсызлар—корбанга әверелә. Гөнаһсызларның каны коелу, кешенең ерткыч хайваннан да түбән хәлгә төшүе постсовет чорына иң зур бәя, иң олы тәнкыйть булып яңгырый.

Разил Вәлиевнең "Мирас" романы 1980 еллар ахырында, соцреализм кануныңың ясалма күренеш булуы ачыктан–ачык белдерелгәннән соң, шуңа хас сыйфатларны файдаланып, үзенчәлекле стильләштерү юлы белән язылган, бер үк вакытта әсәрнең идея–эстетик асылы башка нәтиҗәгә—тормышның күптөрлелеге һәм күпкырлылыгы, кешеләр хакыйкатенең, каршылыклы һәм төрле булган хәлдә, бердәм тормыш–яшәеш агышын хасил итүе хакындагы фикергә алып килә. Роман төп геройның тормышта үз–үзен табу тарихын сөйли, кешенең тормышын гомуми эшкә багышлавы да, су баскан авыллар, югалып баручы милли мәдәният, менталитет, традицияләр дә—мирас икәнен искәртә. Әсәрдә: авылны югалту—тарихны югалту—акылны югалту чылбыры үстерелә. Моннан чыгу юлы һәр кешенең күңелендә җаваплылык тойгысы булуга бәйләп куела. Ләкин традицион производство романнарындагы кебек күпсүзлелек, күләм зур булу таркаулыкка китерә.

Ике корылтай арасында татар әдәбиятында постмодернистик роман иҗат ителде һәм аны драматург бирде. Т.Миңнуллинның соңгы еллар дөнья әдәбиятындагы авангард роман структурасындагы "Минһаҗ маҗаралары" милли яңгыраш белән яңа алымнарның уңышлы синтезы кебек кабул ителә. Әсәр Минһаҗ исемле авыл картының, газета–телевидение, кино–гайбәтләр тәэсирендә, XX гасырда булып узган төп сәяси вакыйгаларны шәрехләве, шуларга пародия бирү кебек уйланылган, антиутопия. 21 маҗара–бүлек, ахыр чиктә, XX гасыр буенча барган сәяси үзгәрешләрне абсурд ноктасында бәяләү булып синтезлаша. Бүлекләр эчендә Рәсәй хакимиятенә һәм татар көнитешенә кагылышлы шактый усал бәя–тәнкыйть даими игътибар үзәгенә куела. Ил узган сәяси этапларны халык теле, масса теле аша тергезеп, "Минһаҗ маҗаралары"нда Т.Миңнуллин яңа тормыш төзү, яшәешне үзгәртү, якты киләчәк, совет идарәчесе хакындагы официаль мәдәният тудырган мифны юкка чыгара. Хуҗа Насретдиннәрне дәвам итүче Минһаҗ образы аша язучы халыкның көчен дә көлә белүдә һәм яшь аралаш көлә алуда күрә, көлү—тормыш авырлыкларын

жинүнең бердәнбер юлы кебек тәкъдим ителә.

Әлбәттә, интеллектуаль тенденцияле әсәрләр белән янәшә, мажаралы әдәбият яшь укучыны мавыктырып, кызыктырып укуга тарта, тәрбияли. М.Хәбибуллинның тарихи романы "Айбиби"—шундыйлардан. Һичшиксез, укыла торган, мавыктыргыч романтик әсәрдәге мәхәббәт тарихын теләсә кайсы дәвергә күчергәндә дә, аның кыйммәте югалмас кебек тоела. Ләкин мавыктыргыч, эмоциональ–экспрессив тел белән язылган романда мәхәббәт, кеше хис–кичерешләре тарихны күмеп киткән. Тарихи материалның әкияти–уйдырмалылыгы, таркаулыгы кеше хисләренең, мөнәсәбәтләренең матурлыгы тудырган тәэсирне киметә генә.

Гасырлар чигендә детектив әсәрләр язучылар күбәйде. Шулай да бу жанрда иң оста каләм иясе булып М.Маликова кала. Бу өлкәдә уңыш булган "Өермә" романы үтерүчене эзләү белән бәйле мавыктыргыч сюжеты, талантлы һәм саф күңелле романтик геройлары белән сокландыра. Шул ук вакытта постсовет чорына хас күп кенә сыйфатлар: матди байлыкларның рухи кыйммәтләрдән дә, кеше гомереннән дә өстен куелуы, халыкның хәерчелек, җинаятьчелек, наркотиклар белән агулау шартларында яшәргә мәҗбүр ителүе, моның кемнәрнедер баету хисабына булуы һ.б. калку, язучының тәнкыйди мөнәсәбәтен күрсәтеп билгеләнә.

Күргәнебезчә, роман жанры традицияләрне нык саклый. Совет әдәбиятында күнегелгәнчә, зур күләмле, күпсанлы геройлар һәм аларның диалогы–сөйләшүләре белән тутырылган, хезмәт, производствоны турыдан–туры күрсәтүгә зур игътибар бирә торган романнарның әле мәйданнан киткәне юк. Бер үк вакытта, әдәбилекне арттыра торган яңа алымнар күбәя бара. Заманның иҗтимагый проблемаларын гомумкешелек мәсьәләләре белән тәңгәлләштерү теләге үзен нык сиздерә.

XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятында әйдәп баручы жанр булган повесть үзгәрешләргә сизгеррәк. Бигрәк тә гасыр ахырында татар повесте эзләнүләр кичерде, яңа формаларга мөрәҗәгать итеп, үзенчәлекле әсәрләр бирде.

Реализм кысаларында язылган тәэсирле повесть—М.Әмирхановның "Мөкәррәмә"се. Язучы Бөек Ватан сугышы темасы чикләрендә, повесть рамкаларында сугыш чорына, совет хөкүмәтенең кеше гомерен чүпкә дә санамаган эчке сәясәтенә, шәхес культының аяныч сәхифәләренә шактый колачлы, тирән, заманча бәя бирә. Ләкин натуралистик детальләр повестьның эстетик кыйммәтен төшерә, массачыл әдәбияттан килгән очсызлы ямаулыклар кебек тоела.

З.Зәйнуллинның шулай ук реалистик традицияләрдә язылган "Ат классы" повесте сугыштан соңгы фаҗигале атмосфераны тирән һәм гаять нечкә тергезүе ягыннан матур тәэсир калдыра. Вакыйгаларны авторның заманга бәя–мөнәсәбәте бер йодрыкка җыя һәм хәрәкәткә китерә. Язучы—характерлар тудыру һәм детальләр белән эшләү остасы. Нәкъ менә характерлар укучы игътибарын туплап, әсәрнең кызыксынып укылышын тәэмин итә.

Әдәбият һәм публицистика арасында, чиктә торган повесть—Вахит Имамовның "Япон татары". Әсәрнең иң көчле ягы—татар укучысы өчен яңа, кызыклы материалга нигезләнү. Читкә киткәннәр кабул итүендә, язучы татар милләтенең инкыйлабтан соңгы аянычлы язмышына, идеология буларак большевизмга колачлы бәя бирә. Фаҗигале хәлләр: илдә калганнарның күргәннәре, Кытайда татарларны совет солдатларының газаплаулары, гражданнар сугышының коточкыч сәхифәләре татар милләте вәкиле күзлегеннән сурәтләнә. Ләкин әдәбилектән алып китә торган үзлек—характерларның тулысынча эшләнмәве, публицистика белән мавыгу бар.

Повесть жанрында романтизм мәйдан тота, әйдәп бара. Мәсәлән, Р.Бәшәрнең "Ачык капка" исемле уңышлы китабы шушы юнәлештә язылган әсәрләрдән тора. Яңадан мәйданга чыккан, яңа романтизм яңа алымнарга, заман проблемаларына сизгер. Мисалга берсен—"Адашкан кош тавышы"н алыйк. Мәхәббәт, татар авылының гадәти көнкүрешен соклангыч сурәтләү белән янәшә, повестьта Чечня сугышына үзенчәлекле бәя урын алган. Чеченнар өчен бу сугышның—үз илен, җирен саклау булуын ассызыклап, язучы кан коешның сәяси максатларда алып барылуына игътибар итә, кулына власть эләккән хәрбиләрнең үз солдатлары гомерен дә, җирле халык мәнфәгатьләрен дә бернигә дә санамавын билгели. Яңа алымнардан, полифонизм уй агышын, аң агышын тергезергә ярдәм итә, автор төзегән ике төрле тормыш моделе кешелеклелек һәм заман чирләренә (кешелексезлек, явызлык, эчкечелек, мәкер, кеше канын коюны бернигә дә санамау) бирешү кебек тәгъләшә.

М.Кәбировның "Мәхәббәттән жырлар кала" повестенда тормыштагы, кешеләр күңелендәге матурлыкны, изге, корбанчыл мәхәббәтне романтик сурәтләү реалистик катлам белән кушыла. Тарихи вакыт 1990 елларны үз эченә ала һәм иҗтимагый бәя берничә яссылыкта бирелә: егетләрне сугышка җибәреп, аннан соң алар язмышыннан йөз чөерүче; ришвәт, тән сату, аракы сатуга кереп баткан; тормышта кешегә үз сәләтен файдаланырга, үз мөмкинлекләрен эшкә җигәргә юл бирми торган җәмгыять булуы ассызыклана. Әсәрдә экзистенциальлек көчле. Ләкин романтик башлангыч гомуми фәлсәфи фикернең оптимистик килеп чыгуына китерә. Тормыш никадәр генә авыр булмасын, ул барыбер матур, нигезендә башкаларга файдалы булу омтылышы ята, диелә.

Ә.Салахның шушы ук структурадагы "Соңгы вальс" повесте да романтик һәм реалистик сюжет сызыкларының янәшәлегенә корылган. Төп герой Газиз тормышындагы берничә көнгә сыеп беткән романтик мәхәббәт ретроспекция ярдәмендә тасвирланган, Чернобыль фаҗигасенә бәйле, кеше–җәмгыять каршылыгының үзгәреш тарихы алар. Реалистик сюжет сызыгы Чернобыль хакыйкатен укучыга җиткерү белән үк кыйммәтле. Бу сызык—җәмгыятьнең кешене алдап үлемгә китерү тарихы, ул кеше кыйммәте җуелу, алдашуның нормага әверелүе, дәүләт мәнфәгатьләренең кеше мәнфәгатьләрен исәпкә алмавы кебек өлешләрдән җыела. Экзистенциаль фәлсәфә ялгызлык төшенчәсенә бәйләнә. Шушы фонда вальс—мәхәббәт символы гына булып калмый, кешеләрнең ялгызлыктан котылу юлы дәрәҗәсенә күтәрелә.

Шунысын да искәртергә кирәк: ике корылтай арасында басылып чыккан "Каеннар юлы", "Көт син мине..." кебек әсәрләрендә Ә.Салах беренче повесте яулаган биеклекне саклап кала алмады.

Сентименталь агымда, романтик рух калку билгеләнә торган повесть—М.Вәлиевнең "Идел яры" әсәре беренче мәхәббәтне һәм туган җирне җую сагышын тергезеп язылган булса да, соңгысының фаҗига, афәт чигенә җиткерелеп тасвирлануы белән үзенчәлекле. Мәхәббәтне югалту сынавын кеше рухи яктан тәҗрибәләрәк булып уза, ә инде туган җирне югалту белән килешә алмый, дигән фикер әлеге чагыштыруның нәтиҗәсенә әверелә.

Ике корылтай арасында татар повесте постсимволизм агымында язылган әсәр бирде. М.Кәбировның "Акбабайның туган көне" повесте шартлы–метафорик формада иҗат ителгән, ләкин әсәрнең төп эчтәлеге символ ярдәмендә ачыла. Әсәрдә Акбабай универсаль символ булып килә: кеше аңында яшәүче яхшылык, игелек кебек тә; яшәештәге мәрхәмәтлелек төсендә дә; кеше күзаллавындагы Илаһи көч итеп тә; татар рухы, милли рух кебек тә; гомумән рухи башлангычның чагылышы буларак идеология мәгънәсендә дә укылышка ия. Повесть XX гасырда татар милләте өлешенә төшкән иҗтимагый үзгәрешләрне үзәккә куя, өстенлек иткән идеологиягә каршы юнәлтелгән. Совет чорында лозунгка әверелгән сүз–гыйбарәләрне актив файдалану, аллюзияләр, сәяси шарж үзенчәлекле хикәяләү хасил итә. Фәлсәфи фикернең татар рухы кешедән–кешегә, буыннан–буынга тапшырылып саклана, ул—барыннан да элек игелеклелектән гыйбарәт, бу рух бары тик дөресен сөйләгән, саф күңелле, башкалар гамен кайгыртучы кешеләрдә генә очрый дигән, бик тә мәгънәле идея тирәсенә җыелуы—шулай ук язучының уңышы, бүгенге татар әдәбиятының татар милләтенә биргән бәясе булып яңгырый.

Постмодернистик алымнарга нигезләнеп язу омтылышы повесть жанрында үзен гел сиздереп килә. Мәсәлән, А.Фәләхнең "Таш бәгырь" һәм "Татлы газап" повестьлары нәкъ шулай, беренчесе—деконструкция принцибына таянып, икенчесе—авторның үлеме концепциясен файдаланып иҗат ителгән. Ләкин әсәрләрнең әдәби–эстетик эшләнеше йомшак, яңа алымнар милли эстетика казанышы дәрәҗәсендә үзләштерелмәгәннәр.

Интеллектуаль тенденция повесть жанрында да көчле. Ф.Бәйрәмова "Алыплар илендә" повестеның үзәк герое Камилне аллегорик образ, милләтнең киләчәге итеп күзаллаган. Эчкечелек, наркомания, байлык артыннан куу, битарафлыкның кешеләр рухи дөньясын томалавы; рухи фаҗига—кеше күңелләренең "сөрелеп–яраланып" беткән булуы һәм экологик фаҗига—табигатьнең юкка чыгарылуы янәшә сурәтләнә. Автор сәбәпләрне төгәл билгели, табигатьне байлыкка табыну юк итсә, кешеләрнең рухи матурлыгын тарихны оныту, дөрес кануннар буенча яшәмәү бетерә, ди сыман;

шушы хәлдән чыгу юлын табарга тели. Камилнең дингә килү тарихы бер канунны югары күтәрә: дин генә җәмгыятьне һәм кешене рухи юкка чыгудан коткару, камилләштерү көченә ия, намазга басу—иманлы булуга тиң. Ләкин, публицистикага бирелеп, намазга басканнар арасында да төрлесе бар, басмаганнарның барысын да имансыз дип раслау дөрес булмас, диясе килеп китә.

Г.Гыйльмановның "Оча торган кешеләр" повесте автор өчен традицион кимәлдә язылган. Аның X1Y корылтайга кадәр басылып чыккан "Албастылар" романы татар әдәбияты өчен яңа сүз буларак кабул ителгән иде. Повестьта да мифологик материал әсәрне реальлек чикләреннән алып чыга, кешеләрнең очу, яшьлеге белән очрашу сәләте чынбарлык кебек тәкъдим ителә. Сәүбәннең мәхәббәтен, үз–үзен табу, асылын тану кебек бирелгән тарих яшәешкә кагылышлы күп кенә канунна рны укучыга житкерә. Кешенең мөмкинлекләре чикләнмәгән, аны танып–белү генә авыр, тормышны камилләштерү юлы—кешенең үз рухын камилләштерүдә, үз күңелен чистартуда, диюче автор мифологик материалны уңышлы файдалану, мифологик сюжет схемаларын тергезү, архетипик образлар куллану, фәлсәфи һәм әхлакый кыйммәтләрне мажаралы сюжетка төреп укучыга житкерү юлын күрсәтте.

Н.Гыйматдинова XX гасыр ахыры татар әдәбиятына магик реализм агымында иҗат ителгән күп әсәрләр бирде. Аның яңа әсәре—"Парлы ялгыз" романтик повесте рухи мәхәббәтне югары күтәрә, рухи ялгызлык фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итә.

Әхлакый мәсьәләләр белән баетылган романтик әсәрләрдән М.Маликованың "Мендем биек тауларга" повесте соңгы чор әдәбиятында киң яктыртыла торган маргинальлек мәсьәләсенә үзенчәлекле якын килә.

Традицион реалистик һәм романтик повестьлар да күпләп иҗат ителгән: Ә.Моталлаповның "Исәнме, авыл", "Нигез", Р.Вәлинең "Мәк чәчәге", Н.Хәсәновның "Ак балык", Г.Галиеваның "Өзелгән өмет" һ.б., Аларда да тәнкыйди, әхлакый, фәлсәфи материаллар кертеп җибәрү омтылышы сизелә. Ләкин яңа алымнар әсәр тукымасына зур йогынты ясамый.

Нәтиҗә ясап, гомумән повесть жанрын бер кат күздән үткәрсәк, бу өлкәдә казанышларның игътибарга лаек икәнлеге шиксез. Ләкин жанр хәзинәсендә нәкъ менә соңгы 10–20 елда барган негатив тенденция—массачыл әдәбият билгеләренең көчәюен күрсәтергә кирәк. Гадәти сюжетка, йә мәхәббәт өчпочмагына, йә ниндидер серне яки җинаятьне ачуга багышланган тарихка корылган, күнегелгән типажлар белән эш итүче, моңа кадәр әдәбият сурәтләү өчен лаек тапмаган күренешләр ярдәмендә укучыны җәлеп итәргә омтылучы повестьлар шактый языла. Әлбәттә, мондый әдәбияттан тулысынча баш тарту мөмкин түгел. Ләкин аның үз язучысы бар. Элитар, классик әсәрләр язарга таланты булган язучыдан укучы массачыл әдәбият түгел, башка сыйфаттагы продукция көтә.

Әлбәттә, кечкенә генә чыгышта барлык проза әсәрләренә бәя бирү мөмкин түгел. Ике корылтай арасында бик күп китаплар дөнья күргән. Мәсәлән, Ф.Яхин, М.Хуҗин, Р.Сәгъди, Г.Гомәр, Р.Вәли, Д.Гайнетдинова, Н.Кәримова һ.б. авторлар укучыга проза китаплары тәкъдим итә. "Казан утлары", "Мәйдан", "Сөембикә", "Идел" журналларында басылып чыккан проза әсәрләре дә шактыйга җыела. Без язылу вакыты ике корылтай арасына туры килгәннәрен игътибар үзегенә куярга тырыштык.

Гомумиләштереп әйткәндә, татар прозасы гасыр ахырында барган күп кенә тенденцияләрне дәвам иткән. Анда һичшиксез, реализм юнәлеше әйдәп бара. Реалистик әсәрләрне модернистик алымнар белән баету матур тәэсир калдыра, яңача яңгыраш бирә. Шул ук вакытта романтизмның яңа көч белән мәйданга атылуы шиксез. Ә бит рус һәм чит ил әдәбиятына күз салсак, аларда мондый күренеш күзәтелми. Бу юнәлеш татар прозасына шулай ук яңадан әйләнеп кайтып, аны милли әдәби мәйданына әверелдерде. Романтизмның, сентименталь тенденциянең төрле төсмерләр белән баеп калкып чыгуы, барыннан да бигрәк, милли әдәбиятны камилләштерү, хыялыйлыкны, эмоциональлекне арттыручы алымнарны гамәлгә кертү омтылышы белән билгеләнә. Шушы ике юнәлештән тайпылып язылган әсәрләрне татар әдәбиятында хәзергә "шартлы–метафорик әсәрләр" дигән баш астына җыеп буладыр. Алар арасында һәм модернистик, һәм постмодернистик алымнар белән баетылган әсәрләр бар. Милли әдәбият шушы юлда кызыклы үрнәкләр бирде. Бу юлны татар әдәбиятын үзгәртүче, яңартучы мөмкинлек буларак карау шарт.

Бер үк вакытта, соңгы еллар татар прозасында күзәтелә торган кайбер тискәре

күренешләрнең арта баруы хакында әйтми калу мөмкин түгел. Без бүген рус мажаралы әдәбиятының китап киштәләребезне басып алуын күрәбез. Алар зур–зур тиражлар белән нәшер ителә, кино– һәм теле–фильмнар төсендә экраннардан төшми. Ләкин рус һәм чит ил әдәбиятында мажаралы, массачыл әдәбият һәм элитар әдәбият аерып куелган. Хәтта мажаралылык элементлары белән баетылганда да, элитар әдәбият үзенең зәвыкле укучыга адреслану үзлеген саклый. Татар әдәбиятында исә массачыл әдәбиятка хас сыйфатлар белән әсәрләрне шыплап тутыру, мажаралылык янәшәсендә әхлак проблемалары күтәрү, укучыга ачыктан–ачык нәсихәт бирүне әдәбиятны элитарлык баскычына күтәрү өчен җитәрлек дип санау бар. Язучылар, күрәсең, укучыны шулар ярдәмендә үз иҗатына җәлеп итү мөмкин дип таба. Бу проза әсәрләренең гомуми сыйфаты кимүгә китерә.

Аннары, татар телендәге массачыл әдәбиятны туган телен яхшы белгән укучы укый. Бүгенге яшьләрнең күбесе, без иртәгә китап укучылар итеп күрергә теләгән буын, нигездә чит мәдәният йогынтысында тәрбияләнә. Рус телендә укучы яшь кеше, әлбәттә инде, 1960–80 еллар рус әдәбияты әсәрләрен хәтерләткән китапларны татарча укымас. Аларны татар әдәбиятына алып килү өчен һәм әдәби концепция җәһәтеннән оригиналь, һәм эстетик яктан камил, һәм фәлсәфи–интеллектуаль тирән әсәрләр кирәк. Шундый дәрәҗәдәге әсәрләр генә татар әдәбиятын дөньякүләм таныта, милли әдәбиятның уртак әдәби пространстводагы урынын билгели ала. Прозаның торышы турында уйланганда, әдәбиятның киләчәге хакында фикер йөрткәндә, иртәгә укучы кулына килеп керәчәк китапка нинди таләпләр куела икәнлекне истән чыгармасак иде. Әзләнүләр чорындагы татар прозасына XX гасыр башындагы кебек олы сикереш ясавын, сыйфат үзгәреше кичерүен теләп калам.

Тәлгат Галиуллин

## ШИГЪРИЯТ МОҢНАРЫ

Бүгенге көндә Татарстанның Язучылар берлегендә 100 ләп шагыйрь исәптә тора… "Язучыларның кыйммәте исәп белән билгеләнми, күпме бу, азмы?" дигән риторик сорауга берәү дә канәгатьләндерерлек җавап бирә алмас: "бу санга башлап һәм яшь язучылар, үзешчәннәр кермәгән бит, халык саны башка милләтләрне арттыру исәбенә кими бара, ә рифма сырлаучылар өстәлә тора", диярләр. Шагыйрьләр сафы ишәю, бер яктан, татар халкының шигъри җанлы булуы, гасырлар дәвамында моң-зарын, шатлыгын-сөенечен шигъри сүздә калдырырга омтылуы турында сөйләсә, икенчедән, шигырь белән мавыгучыларның йөздән берәрсе генә татар поэзиясе күгендә якты йолдыз булып кабынса, калганнары шигырьне аңлап, күңеленә сеңдерә торган яхшы укучы булып калачак. Китапка, язма-басма сүзгә мәхәббәт сыекланган заманда соңгысы—ягъни шигырь укучысы—шулай ук кадерле заттыр әле.

Ике корылтай арасында татар поэзиясе ничек яшәде, кайсы үзенчәлекләре белән әдәбият тарихына кереп калуга дәгъва итә ала? Шигърият үсешенә бәя биргәндә скептиклар белән битарафларның: "Шагыйрьләрегез арасында Туфан, Хәким, Афзал, Юзиев кебек олы шәхесләр бармы?" дип астыртын елмаеп куюлары мөмкин. Сүз осталары, гадәттә, Тукай әйтмешли, "үлеп күрсәтмичә" лаеклы бәяләрен алмыйлар, бөекләре дә пәйгамбәрләр рәтендә йөртелмиләр.

Иманым камил, ышанычым нык—чирек, ярты гасырдан соң ук һәр нәрсәгә шик, шөбһә белән караучылар табылыр һәм алар: "Сез шигърият үсә дип шапырынасыз, арагызда ялкынлы хисле, ярсу фикерле, үткен күзле Равил Фәйзуллин; уен халык күңеленә уйдырып, хикмәтле тел белән җиткерә алган Мөдәррис Әгъләм; галәм җисемнәрен, ак, сары, кызгылт йолдызларны уч төбендә уйнаткан Роберт Әхмәтҗанов; аек зиһенле, фәлсәфи катламлы, чагыштыру-метафоралар белән кешенең акылын

гаҗәеп бер олылык итеп күрсәтә белгән Ренат Харис; дөньяны йөгәнсез тулпардай иңләргә омтылган ярсу Зөлфәт; Көнбатыш һәм Көнчыгыш мәдәни казанышлары арасында уртак җанлы җепләр эзләүче, шашкын тойгылы романтик Рәдиф Гаташ; саф күңелле, самими Гәрәй Рәхим; сүздән тәсбих тезү сәләтенә ия Рөстәм Мингалим; Казан халкы белән Кырым татарлары арасында уртак җепләрне, тарихи якынлыкны фәнни һәм сурәт аша раслаучы Әхмәт Гадел; йөрәк ярсуын тышкы шигъри тыйнаклыгы белән бастырып килүче Харрас Әюп; милләт мәнфәгатьләрен кайгыртуда абруйлар белән исәпләшмәгән, гражданлык пафосын затлы сүзгә төрә белгән Айдар Хәлим; татар теленең сыгылмалы байлыгын ажагандай уйнаткан, үзе тудырган сурәтләргә сокланып туймаган Марсель Галиевләр юк", дип җиңүче кыяфәтендә йөренеп алыр. "Хатын-кыз шагыйрәләрегез яңгырдан соң күтәрелгән гөмбәләрдәй үсә, тик араларында Сажидә Сөләйманова, Лена Шагыйрьҗан кебек ир-егетләрне бәйгегә чакыра алырлык талантлар күренми; тормыштан туйган балавыз сыгучылар, елап-сыктап, ыңгырашып яшәүчеләргә йөз тоткан, үз бәхете өчен көрәшче тәрбияләү бурычын өстенә алмаган бәетчеләр басты", дип тә өстәр кемдер...

Әйе, шагыйрь язганча, киләчәкне уйлап, бүгенгене дөрес бәяләү өчен "еракка китеп карау" ихтыяҗы бар. Ә еллар, көннәр агымсулардай һәркайсыбызның акыл, йөрәк, җан җылысын алып үтәләр дә үтәләр... Шигъри сүзләре үлемсез булса да, шагыйрьләр мәңгелек түгел.

*Чиксезлекнең чиксез бер җирендә*
*Очрашырбыз кебек яңадан,—*

дип язуы белән Р. Мингалим хаклы.

*Шагыйрьләр пыскый алмыйлар,*
*Шагыйрьләр—яна гына!—*

дип өстәп, Р. Фәйзуллин каләмдәшләренә уйланырга урын калдыра.

*Шигырьләр сыктым мин—*
*Кып-кызыл кан икән.*
*Шигырь ул—Кояшның күзеннән өзелгән*
*Илаһи җан икән.*

(Факил Сафин. "Язмыш")

Яшәргә уйлаган, киләчәге турында кайгырткан әдәбият беренче нәүбәттә чорның уй-фикерен, моң-зарын, сөенечен чагылдырырга лаеклы алмаш, варислар турында уйларга тиеш. Иҗади ярыш бер мизгелгә дә тукталып тормый, өзлексез дәвам итә, чөнки бу процесс—поэзия үсешенең төп күрсәткече. Алмаш мәсьәләсендә татар шигъриятендә хәлләр ничегрәк тора соң?

"Шигърият—яктылык, матурлык һәм өмет кушылмасыннан гыйбарәт", диләр. Киң күңелле оптимист Сибгат ага Хәким һәр уңай очракта "яңа буын шагыйрьләре төркем-төркем килә, мин аларның аяк тавышларын ишетәм", дип кабатларга ярата иде. Ышанычы һәрдаим акланмаса да, остаз сүзен бирми, өметен җуймыйча, энҗе бөртекләрен эзләвен дәвам итте.

Нечкә хисле, рухи дөньяга игътибарлы, татар лирикасының гүзәл традицияләрен үстерү нияте белән юлга чыккан Рәмис Аймәт; М. Җәлил һәм Ф. Кәримнәр кайнарлыгын, пафосын табигать һәм эчке халәт матурлыгына төреп бирә белгән Марат Закир әле генә яшь шагыйрьләр рәтендә йөрделәр. Баксаң, аларның да үкчәләренә басып, яңа буын аваз сала икән: Луиза Янсуар, Ленар Шәех, Айдар Җамалиев, Гөлнур Корбанова, Лилия Гыйбадуллина кебек яшь каләмнәр үзләренә мәйдан даулый, игътибар сорый.

Безнең чорда шигырь язучылар арасында энҗе бөртекләрен, ягъни өмет чаткылары күренгән яшьләрне үстерү шөгылен "Казан утлары" һәм "Идел" журналлары, гәзитләребез, аеруча "Мәдәни Җомга" дәвам итә. Г. Гыйльманов Казан университетының татар факультеты каршында, заманында М. Мәһдиев ярдәмендә калкып алган "Әллүки" иҗади оешмасына җан өрде. Әдәбиятка яңа көчләр өсталеп тормаса, ул үсештән туктый. Хәзерге яшь алмаш, 20-30 еллардагы сыман, сукадан яисә станоктан чакырылмый, ә төпле әдәби әзерлек белән, чынбарлыкның катлаулы үсеш

чалымнарын күреп, "пакусны" киң алдырып килә.

Татар поэзиясенең олы тарихы булу—яшьләргә таяныч ноктасы. Аларның беришесе Тукай, икенчеләре Такташ, өченчеләре Туфан, Җәлил, С. Хәким шигъри мәктәпләре йогынтысында үсәләр. Традицияләрне дәвам итү—якынлык һәм охшашлык белән беррәттән, фикер вә хис яңачалыгын, эзләнүләр киңлеген таләп итә. Шигырь техникасы үскән дәвердә рифма табу, иҗек санын килештерү авыр түгел, ә инде кеше рухы гүзәллекләрен, татар халкының яшәеш рәвешен, кайгы-хәсрәтен, сөенечен югары профессиональ дәрәҗәдә ачу, татар поэзиясенең сыйфат дәрәҗәсенә тап төшермәү җиңел түгел.

Шигъри осталыкны, җитди проблематиканы—кояш һәм ай, күк җемелдәшеп утырган йолдызлар турында язу дип уйлау, шыплап тутыру, күләмле, эре образларны кат-кат кабатлау үзеннән-үзе яңалыкка, мифологик аңга үтеп керү яисә үтә яңачалык була алмый әле. Татар поэзиясенең алтын тоткасына кул салучылар ми төпкелләренә шул хакыйкатьне салып куярга тиешләр: аның дәрәҗәсе югары һәм дөнья шигъриятенең сыйфат кимәленнән түбән тормый.

Татар поэзиясенең тагын бер үзенчәлеген истән чыгарырга ярамый. Безнең язучылар мөстәкыйль дәүләтле, хөкүмәт дәрәҗәсендә яклаулы, димәк ки, тук тормышлы әдәбиятлар белән чагыштырганда кайтышрак матди һәм сәяси халәттә яшәсәләр дә, аларның җәмгыять тормышында, милләт язмышын кайгыртуда позицияләре әһәмиятлерәк һәм олырак.

Мөстәкыйльлеккә ирешкән мәмләкәтләргә милләтне, телне яклау, мәгърифәт, мәктәпләрдә, югары уку йортларында ана телендә уку-укыту өчен җан атып, төн йокыларын качырып яшисе, көрәшәсе юк. Әйтик, инглиз, алман, рус, болгар шагыйрьләренә—яшәү белән үлем, яхшылык белән явызлык, әдәп-әхлак мәсьәләләре, аталар һәм балалар мөнәсәбәте, мәхәббәт сагышы турында гына уйланып, яңгыравык, ямьле рифма сайлап утырасы гына кала. Ахыр чиктә, аларның диссидентлары да яклаулы.

Гасырлар дәвамында, дәүләтчелеген югалткан көннән алып, татар сүз сәнгате милләтне яшәтү өчен көрәшнең мөһим өлешен өстенә алды, сәяси көч һәм милли идеология дәрәҗәсенә күтәрелде.

*Татар рухы җирдә ятар түгел,—*
*И, милләтем итсен тантана,—*

ди Роберт Әхмәтҗан "Бакый ага Сөембикәсе" шигырендә, хыялына ирек куеп.

Дөрес, совет чорында татар поэзиясе дә Җир шары проблемалары, галәмне буйсындыру, атом-төш коралы, Себер трактындагы кварталлар турында да язды, Америкалы "рәнҗетелгән" негрларны яклап тавыш бирде. Европага аккан татар нефте өчен шатланды, әмма дөнья безнең интернациональ рухны бәяләмәде, мөстәкыйльлек алырга булышмады.

СССР империясе таркалгач, татар халкы да иркенрәк сулап куйды, шагыйрьләр ясалма биеклектән түбәнгәрәк төшеп, халкыбыз язмышына якынлашты, үз киләчәге милләт, тел яшәешенә бәйле икәнлеген аңлады. Милли рухтан, халыкны авыру дәрәҗәсенә җитеп яратудан башка чын шагыйрь була алмый. Милләтеңне ярату—милләтчелек түгел.

Талантлы шагыйрь гомумкешелекне борчыган, тетрәндергән проблемаларга милли, тарихи, шәхси мәнфәгатьләрне яктырту аша килә. Ерак галактикалар, Йолдызстан, Атлантида, таш аргамаклар белән саташып йөргән Р. Әхмәтҗан гапгади җир бәхете, мәхәббәт символы—зәңгәр көянтәләр, йөрәк кыллары турында яза башлады.

*Юк, без инде күләгәләр түгел,*
*Күчермәләр түгел—*
*Нөсхәләр!*
*Күләгәләр—юан...*
*Ә без—күңел кебек,*
*Йөрәк кылы кебек нечкәләр.*

("Күләгәләр")

Сихри тойгылы лирик шигырьгә өстенлек бирүнең нәтиҗәсе озак көттермәде.

Роберт Әхмәтҗан Тукай исемен йөрткән олы бүләккә лаек булды, 70 еллык юбилее шигърият бәйрәме гөрләп узды. Дөрес, ике корылтай арасында төрле характердагы юбилейлар бихисап булды. Тик театр залларында купшы кичәләр, үзен сорап укучылар конференцияләре уздырулар—танылу күрсәткече түгел әле.

Халык язмышын һәр гамәлдән өстен күргән шагыйрь бүләк өчен иҗат итми; поэзия аның яшәү рәвеше булганда иртәме-соңмы рәхмәте дә эзләп таба. Татар шигъриятенә кырык елга якын намус белән хезмәт итеп килгән, фикер һәм хис бердәмлегенә ирешкән шагыйрь һәм драматург Рөстәм Мингалимга Тукай исемендәге, яшьләрчә дәртле, зыялы шагыйрь Рәдиф Гаташка Такташ премиясе бирелүне җәмәгатьчелек "дөньяда дөреслек бар икән әле!" дип, канәгатьлек белән җанына үткәрде. Татарстанда иң югары бәя—республиканың халык шагыйре, язучысы исеме бирелү. Прозада бу исемне йөртүчеләрнең саны саегып китсә дә, поэзиядә, иншалла, андый затларыбыз арта тора. Балаларны ташламыйча, олыларны уйландырырлык, нәзберек лирик парчалар остасы, өлкәнебез Шәүкәт Галиев янына исемлеләр өстәлә тора: Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллин, Әхсән Баянов, Ренат Харислардан торган төркемгә күптән түгел Роберт Миңнуллин өстәлде.

Әдәбиятның төп күрсәткече, бәяләү бизмәне—туган тел, аның мөмкинлекләрен үстерү. Прозабызда рус телле татарлардан (аларның да күбрәк читтә яшәүчеләреннән) тәрҗемә аша татар әдәбияты "ясау" модага кереп бара. Иншалла, русча язучы татарлардан татар поэзиясе оештыру дәрәҗәсенә төшкәнебез юк. Телен, димәк ки, иманын сатмаган өчен татар поэзиясенең абруе дөнья күләмендә дә җитди. Язучылар корылтаенда поэзия буенча еш кына нотык тоткан мәшһүр тәнкыйтьчебез Нил Юзиевның ятратып китерә торган мисалы бар иде. Исегезгә төшерәм. Совет чорында дөнья күргән 200 томлык дөнья әдәбияты тупланмасына 17 татар шагыйре иҗатыннан үрнәкләр бирелгән. Анда бер прозаигыбыз яисә драматургыбыз иҗатыннан мисаллар китерелми. Субъектив фактор дияргә урын бар, әмма фактны инкяр итүе кыен.

Хәзерге татар поэзиясе туган халкы, кешелек дөньясы өчен, җаваплылык хисен тоеп, чордашыбызга әхлак тәрбиясен сеңдерү, аны коллык психологиясеннән арындыру рухы белән яши. Рәмзия Габделхакова "Юк ла, миләш тәлгәшләре" шигырендә чечен фаҗигасе турында шомланып яза икән, бу афәтнең бер башы үзебезнең халык җилкәсендә икәнен онытмый. Хәзер "Уртак дошман, уртак ил" төшенчәләренә караш үзгәрде, салкын боз катламнары арасында калган үз милләтең турында кайгырту ихтыяҗы алга чыкты.

*Алланың канат астында*
*Күпме урын яуладык.*
*Учакларга кырау тиде,*
*Дөрләп китә алмадык.*

(М. Галиев. "Бәгырь өзгәләнгәндә")

Шуңа якын теләкне Җәүдәт Дәрзаман үз фикерен символикага төреп тормыйча, ярып сала:

*Бишәр гасыр ээрлекли икән*
*Бер җибәргән тарихи хатаң,*
*Моң да бирми сиңа, тын да бирми*
*Мәскәү кулы тоткан милли якаң.*

("Тормыш—сәхнә".)

Халык язмышы турында уйлану, бәхәс, әңгәмә, лирик ачылу рәвешендә язылган шигырьләр Кави Латыйп, Әхсән Баянов, Марс Шабаев, Илдус Гыйләҗев, Мөдәррис Вәлиев, Нур Әхмәдиев, Әхмәт Рәшит, Шамил Маннапов, Фәрит Яхин, Госман Садә, Нияз Акмал һ. б. иҗатыннан күпләп табыла.

Хәзерге шигырьдә зиһен, интеллект көче катнаша, шигырь җисемле, бай интонацияле, күп тавышлы була бара, фикер логикасы алга чыга, фәлсәфи уйлануларга юл ачыла. Азатлык, бәйсезлек өчен көрәш дулкынында иҗатка килеп, шагыйрь буларак ачылып киткән, шигырьләрендә халкыбызның ачы язмышын йөрәкләре аша уздырып, тарихи аңны сискәндереп уятуга омтылу җәһәтеннән Р. Зәйдулла, Г. Морат, Сөләйман эзләнүләре игътибарга лаеклы.

*Олаулап татар сагышы...*
*Бәгыре челтәр-челтәр...*
*Халкыма бәхет дауларга*
*Бәлки, шул сагыш җитәр?*

—дип ("Бәхет-сагыш—бер көянтә" шигырендә) язса да, Сөләйман сагыш белән генә киләчәккә үтеп булмасны аңлый. Шагыйрьләр иҗатына уйлану киңлеге, кискен контрастлык һәм образлы гомумиләштерү рухы хас. "Сөләйман патша сүзе"ндә Г. Морат болай ди:

*Хак булса патшасы,*
*Халкы да исәер.*
*Гауғалы дәүләттә*
*Түрәләр ишәер.*

Дөрес сүз, өстәп тә, киметеп тә булмый!

Шәүкәт Гаделша остазы Булат Сөләйманов юлыннан барып, милләтебезнең үзенчәлекле кавеме яшәгән төбәк һәм аның кешеләре белән таныштыруны дәвам итә ("Синдә, Себер, Туган ягым", "Себер татарым, ни диим?" бәйләмнәре).

Баһадир шагыйребез Фәнис Яруллин кискен афористик гыйбарәләрне өнәми, шигъри рәсемнең нәзакәтлегенә, интонациянең табигыйлегенә, музыкаль яңгырашына игътибар итә. Шул җирлектә рухи матурлык белән психологик сурәт бердәмлегенә ирешә.

*Каурыйларны җыям учларыма,*
*Каурый түгел, гүя моңнар җыям.*
*Туган якларымның моңнарына*
*Никадәрле кайнар уйлар сыйган.*

Хатын-кыз шагыйрәләр иҗаты турындагы бәхәс әледән-әле, янган шырпыга эләккән күкерт кебек, кабынып тора, кайберәүләрне аларның поэзиягә күпләп килүе, ир-ат затын кысырыклавы борчый. М. Әгъләмнең бу мәсьәләгә үз карашы бар. "Шагыйрәләр күбәйгәннәр икән, әнкәм теле озын гомерле", "Инкыйраздан саклап калмак теләп, Шигырь яза бүген хатын-кыз",—ди ул "Саклап калмак теле" әсәрендә. Әйтик, Л. Шагыйрьҗан романтик һәм реалистик стиль мөмкинлекләреннән кыю файдаланып, бизәкләрнең бай һәм төрле булуын күз уңында тотып, нинди генә темага, проблемага алынмасын, халык язмышы, милләт киләчәге турында уйланулар юлына чыга. "Әдәбият корабы" шигырендә сүз сәнгатебезнең үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында гына барган кебек, әмма шагыйрә әдәбиятны халыктан, милләтне шигърияттән бер мизгелгә дә аерып карамый.

*Йөзеп бара Әдәбият-кораб,*
*Җилкәннәрен меңнәр күтәргән,*
*Шул дәүләткә ия булган халык,—*
*Хакың бармы синең батәргә?!*

Шунда ук сизгер җанлы шагыйрә милләтен уяту, үз хокукы өчен көрәшкә алып чыгу юлларын эзли.

*Син яшисең, димәк, милләт булып,*
*Җир-ананың татар баласы син,*
*Зур учакка утын салсаң гына,*
*Мәңгелеккә Җирдә каласың син.*

("Халыкара тигезлеккә сусап").

"Зур учакка утын салу"ның, "Мәңгелеккә Җирдә калуның" мәгънәсенә һәркем үз уен, хыялын салырга хаклы. Кеше җанына хас сызлану, йөрәк әрнүе, шатлыгы,

хатын-кыз гына тоя һәм сурәтли алган күңел тибрәлешләре Энже Мөэминова, Илсөяр Иксанова, Эльмира Шәрифуллина, Бикә Рәхимова (бу көннәрдә "Мәрхәмәт" исемле саллы җыентыгы чыкты), Флера Гыйззәтуллина, Салисә Гәрәева, Фирүзә Җамалетдинова, Халисә Мөдәррисова, Асия Юнысова, Фирая Зиятдинова, Нурия Измайлова, Ләйсән Кәшфиева һ. б. иҗатларында үз төсмерләре, бизәкләре белән ачыла. Нәҗибә Сафина белән Рифә Рахманның табигый моң белән сугарылган, беренчесенең халык язмышы өчен үрсәләнгән, икенчесенең шәхеснең олы мәхәббәткә, сөяргә һәм сөелергә хаккы барлыгын раслаган лирикалары татар поэзиясенең йөзенә кызыллык китерерлек түгел. Татар шагыйрәләре фикеренчә, һәр инсан—кечесе, олысы—бәхеткә лаеклы.

*Җырлыйлар да биилә[р],*
*Шигырьләр дә сөйлиләр...*
*Тик мондагы балалар*
*Көлә генә белмиләр.*

("Балалар йортында". Р. Габделхакова).

Жанрлар җәһәтеннән татар поэзиясе эзләнүдән туктамый. Дөрес, Көнбатыштан иңгән баллада, сонет, триолет, элегия кебек жанрларга игътибар кимеде, аның каравы безгә гарәп, фарсы, төрек шигъриятләре аша килгән, милли җирлектә чәчәк аткан газәл, робагый, фәрд, мәрсия кебек жанрлар тернәкләнде. Р. Гаташ газәлне үз шигъриятенең визит кәгазе дәрәҗәсенә күтәрде, фәрд үсешенә күптән түгел арабыздан киткән, милли рухлы көрәшче Әдхәт Синугыл җан өрде, Көнчыгыш шигъриятенең затлы традицияләрен Акъегет ("Хәтер авазы") һәм Мөхәммәт Мирза ("Яктыртмакчы булсаң халык күңелен") яңа җирлектә дәвам иттерәләр, үстерәләр.

А. Блок әйткәнчә, поездлар сирәк, әмма озакка туктый торган станцияне—поэма жанрын—әйләнеп үтсәк, татар поэзиясе турында кузаллавыбыз тулы булмас. Поэма 60-80 нче елларда алга сөрелгән: төгәлләнгән вакыйгалар, катлаулы характерлар тасвирланган, сюжетлы яки риторикага корылган публицистик поэмалар чорын үтеп, яңа үсеш юллары барлый. Әмма сан җәһәтеннән поэма ике корылтай арасында әллә ни өлгерлек күрсәтмәде. Әдәбиятның барометры саналган "Казан утлары"нда да алар сирәк басылды. Гасыр башы һәр чорда хәвефле, гайрәтле һәм үзенчәлекле булган. XX гасырның беренче елларында Исәнбәт, Такташ, Туфан, Кутуй, Нәҗми кебек татар поэзиясенең алтын баганалары туган. XXI гасыр башы әле үз сүзен соңрак иңдерер. Поэма жанрында сурәтлелек символикасы яңаруы, төрле фикерләү типларының, метод-стильләрнең аралашуы, диффузия күренеше күзәтелә. Бу үзгәрешләрнең беренче карлыгачы Лена Шагыйрьҗанның "Дөнья базары яхуд яңа Америка" булды. Әсәр Нью-Йорктагы сәүдә үзәген шартлату уңаеннан язылган һәм "һәр явызлык өчен түлисе була" дигән идеяне Тукай традицияләренә сыенып, үткен тел һәм сатирик гомумиләштерү алымнарына таянып җиткергән сәяси поэма үрнәге.

Хәзерге лиро-эпик жанрның бер үзенчәлеге—тарихи шәхеснең тормышын, эшчәнлеген фокуска алып, үзәк каһарман язмышын сурәтләү аша чор, халык проблемаларын калкытып кую. Бу традиция татар поэзиясендә күптәннән яши. С. Хәким, И. Юзеев, М. Әгъләмнәрнең Тукайга багышланган әсәрләрен, Р. Фәйзуллинның "Сәйдәш" поэмасын искә төшерик. Эльмира Шәрифуллинаның "Каюм коесы" шул типтагы әсәр булды. Галим һәм шагыйрь Ә. Мәхмүдов "Көзге җилләр" тарихи поэмасында бөек Тукайның соңгы фаҗигале көннәрен ачуда үз сүзен әйтә.

З. Мансуровның "Ике егълау" поэмасы сурәтләр символикасы үзгәрүгә мисал-үрнәк була ала. "Кара каршы ике бикәч егълаша" дип, автор ике төрле—шәхси мәнфәгатьләре һәм халык язмышы—яшәештә бәргәләнгән хатын-кыз образларын тәкъдир итә. Ярославна кыпчакларга яу чабып, әсирлеккә төшкән ире Игорьне сагынып сыктануын һәм йөрәге Казан халкын кызганып әрнегән Сөембикә егълауларын чагыштырып, икенчесенең рухи бәргәләнүләрен тирәнтен ачып, заманча фәлсәфи-этик нәтиҗәләр ясый автор.

"Ике мөһаҗир" поэмасында Р. Низами да, З. Мансуров үрнәгендә, драматик кичерешләрне шәхесләр язмышы аша тасвирлау юлына чыга. Төрек шагыйре Назыйм Хикмәтнең алдавыч идеяләр—большевиклар шигаре—корбаны булуын күрсәтү аша

шагыйрь татар халкының үткәнен, хәзергесен, үзеннән генә тормаган сәбәпләргә бәйле киләчәген йөрәге аша уздыра, сызлана, әрни.

XXI гасыр башы поэмасына хас сыйфатлар—эпик һәм лирик башлангычларның кушылуы, синтезы, символик сурәтләр, замана алып килгән ачкыч сүзләр балкышы Ренат Харис поэмаларында чагылышын тапты. “2002 ел шигъриятенә бер караш” исемле чыгышында Р. Зәйдулла “Соңгы елларда, мәсәлән, Ренат Харис бик үзенчәлекле поэмалар иҗат итте. Бездә, гадәти булганча, аларга тиешле бәя бирелмәде кебек”,—дигән иде. Чыннан да Р. Харис иҗатында хәзерге лиро-эпик жанрның барлык типологик төрләре: “Чехов базары”, “Һарут белән Марут” кебек сатирик поэмалардан һәм “Өч үбешү” кебек лирик төрдән алып, тарихи поэмалар “Михаил Худяков”, “Идегәй”гә хәтле чагылышын тапты. Шигъри эзләнүләренең киеренке ноктасы, һичшиксез, “Исемсезләр” романы булды. Татар әдәбиятында өченче шигъри роман пәйда булды. Инкыйлаб һәм авыл хуҗалыгын көчләп кумәкләштерү чорларына багышланган С. Батталның “Чирмешән якларында”, Ә. Давыдовның “Йокысыз төннән соң” романнарыннан аермалы буларак, Р. Харис әсәре заманыбызга якын булуы, катлаулы структурасы, чорыбызның сәяси, әдәби вакыйгалары уртасыннан атлап, вакыт белән ара хронотобын онытгырып укыла торган яңа гасыр поэзиясе казанышы. Автор романының беренче юлларыннан ук максатын, әхлакый-фәлсәфи кредосын калкытып куя:

*Герой эзлим! Герой эзлим*
*Күз бетереп, җир ертып.*
*Әйтерсең лә татарда мин*
*Байрон, Пушкин, Лермонтов!..*
*Әлбәттә, татарны эзлим,*
*Шуңа эзлим татардан—*
*Таба алсам, яза алсам,*
*Татарга да булыр дан.*

Күп геройлы шигъри романында Р. Харис үрнәк-өлге булырлык геройны тапканмы, юкмы, анысын әсәрне укыгач белерсез...

Пафоска өлеш чыгарып, авыр артиллерия турында уйлануга бирелеп, сәнгатебезнең иң хәрәкәтчән һәм гаять популяр төре—җыр жанры турында онытып барабыз түгелме? Лирик әсәрне гомерендә шигырь китабын кулына тотып карамаган туң колакларга, саңгырау җаннарга ирештерүнең сыналган юлы—аның җыр канатында эфирдан, сәхнәдән яңгыравы. Татар поэзиясе тарихы барлыкларын бу төргә багышлаган фидакарьләрне белә: Мостафа Ногман, Гөлшат Зәйнашева, Мансур Шиһапов, өлешчә Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин. Җыр классикларына житди конкурент булып Рәфис Корбан үсеп килә. Резеда Вәлиева, Шәмсия Җиһангирова, Флера Тарханова, самими, нечкә хисле яшь шагыйрә Фәүзия Солтаннарның лирик әсәрләре җырга тартылып, көйчеләребезне рухландырып тора. Уңышлы җыр текстларында авторлар рифма яраштырудан, халык иҗатында табылган чагыштырулардан (иренне—чиягә, күзне—карлыганга, битне—алмага, чәч толымын—юлга тиңләү кебек) уза алмаганнардан аермалы буларак, үзәккә кичереш хәрәкәтен, хис-фикер үсешен куеп, таушалмаган сурәтлелек эзләү юлына чыгалар.

Әмма... Ләкин... Җыр текстын язуны җиңел кәсепкә әйләндерү, теләсә кемнең бу жанрга алынып, такмакны әсәр дип тәкъдим итеп, композиторларның да арзанлы җимгә алдануы жанрның абруен төшерә. Җыр бакчабыз житди сөйләшүне таләп итә. Русларда хәзерге җыр жанры берниндн эстетик һәм мәгънәви йөкне үз өстенә алмый, диләр. Безнең дә шул көнгә калуыбыз бар.

Поэзиябезнең күләгәле яклары, үсеш авырлыклары бармы соң? Әлбәттә, фикер, яңгыраш җәһәтеннән бәяләгәндә, зур, өлкән әдәбиятларга хас булганча ару, талчыгу, тын кысылу галәмәтләре сизелә, илдәге сәяси вәзгыятьнең үзгәрүе нәтиҗәсендә пессимизм мотивлары, киләчәккә шөбһәле караш шигъри тукымаларга үтеп керә.

Киләчәк өчен борчылу, өметсезлек, яшәешнең мәгънәсезлеген икърар итү, шәхеснең ялгызлыгын үзәккә алу, тормыштан тую мотивы (“Кеше дигән җанвар кая бара”, “Арыдым ла. Уйлар хәтта черем итә Кырынаеп күңел мендәренә”—М. Галиев) Зөлфәт, М. Әгъләм иҗатларына да үтеп керә. Масштаблылык җитмәүне, тематик ярлылыкны, тормыш-көнитешне сурәтлибез дип, җирдән шуышып барган натурализм

ярларына төшүне милли үзенчәлегебез дип санарга ярамый. Рифма, ритм чатаклыкларына, сүзне дөрес кулланмауга, аллитерация, ассонанс, фоника мөмкинлекләрен эшкә җигә белмәүгә мисалларны күпләп табып булыр иде.

Тукайлардан килгән усал, үткен сатира традицияләребез, сәяси лирикабыз сәхнәдән төшеп бара. Сатираны җиңелчә шомарту, юмор алыштыра. Брежнев, Горбачев, Путин, Буш кебек әһелләрне сурәтләгәндә без ифрат кыю, өлгер, ә үзебезнең түрәләрне, хәтта район җитәкчеләрен дә ялагайлыкка күчкән мактау рухында, хәтта поэмалар багышлап сурәтлибез. Бу—татар язучысының матди яктан бәйле булуы, аңа куркаклык хисенең көчле тамыр җибәрүеннән килә торгандыр, күрәсең. Зыя Мансур, Әхмәт Исхак, Габдулла Шамуков, Зәки Нури иҗатларында шактый үскән мәсәл, бигрәк тә аның аллегорик, кыска төре бөтенләй диярлек күренми.

Хәер, кыюлык үрнәкләре дә күренеп ала. "Син яхшырак киенер өчен—халкың саттың, Кәеф-сафа корыр өчен—халкың саттың",—дип Р. Мингалим киная-эзоп теленә таянса, Р. Фәйзуллин "Башлык—тәре сурәт иконаны Ватиканнан алдырды", дип, "Шундый хәлләр" шигырендә адресны ачыклап, ачынып яза.

Соңгы елларда "шигырьне укымыйлар, шигырь китаплары шүрлекләрдә сатылмыйча, тузан җыеп ята", дигән фикер еш кабатлана. Шул сылтау белән кайбер нәшриятлар шигырь җыентыкларын кабул итмәскә дә тырыша. Шигырьләр вакытлы матбугатта яисә мәҗмуга төсендә басылып, үзе турында чаң сугып тормаса, бәлки укучысы да юкка чыгар? Бәхеткә, төп китап нәшриятлары—Татарстан китап нәшрияты, "Мәгариф" һәм "Рухият"—шигъри сүзнең җан азыгы, тел сакчысы икәнлеген аңлап, поэзиягә хәерхаклык күрсәтәләр. Татарстан нефтьчеләре ярдәмендә эшләп килгән "Рухият" ике корылтай арасында Р. Фәйзуллин, А. Хәлим, М. Галиев, Э. Шәрифуллина, Ә. Маликов, Р. Гаташ һ. б. шагыйрьләрнең сайланмаларын укучыга ирештерде. "Мәгариф" нәшрияты поэзиябезнең олы тарихы һәм бүгенгесе белән таныштыруның отышлы юлларын эзли. "Милли әдәбият китапханәсе" һәм "Хәзинә" серияләрендә иң соңгы сорда: "Сәгыйт Рәмиев, Шәехзадә Бабич" (2005, төзүчесе һәм сүз башы авторы Д. Заһидуллина), "Татар шигърияте. XX гасыр башы" (2004, төзүчесе, сүз башы авторы З. Рәмиев), "Татар шигърияте. 1980-2000 еллар" (2003, төзүчеләр Т. Галиуллин, Н. Гафиятуллина), "Муса Җәлил. Әсәрләр" (2004, төзүчеләре шулар ук). "Мәгариф" нәшриятенең янә бер үзенчәлекле мәҗмугасы турында әйтеп үтәсе килә. Ул—халык шагыйре иҗатына багышланган, житмешләп автор катнашында Равил Фәйзуллинның иҗади портретын тудырган "Заман. Иҗат. Шәхес" китабы (2002, 492 бит).

"Хәзинә" сериясендә ел башында XX йөзнең 20-30 еллар поэзиясен иңләгән "Сәлам сиңа, тормыш" (2004, фәнни редакторы, сүз башы авторы—Т. Галиуллин, гомуми кереш—Р. Гаташ) җыентыгы дөнья күрде. Зәвык белән һәм затлы бизәлештә чыгарылган бу китапларны кулга алуы рәхәт, татар поэзиясенең кодрәтле байлыгы горурлык хисе уята.

Поэзиябез кеше күңеле матурлыкларын җырлауда, яшәешебезнең төрле кыйтгаларын сурәтләүдә җитди уңышларга ирешә. Аның казанышлары белән горурланырга тулы хакыбыз бар.

Дания
Гыйманова

# СӘХНӘБЕЗДӘ НИЛӘР БАР?

Драматургия ул әдәбият кануннары белән генә яшәми, аның "сәхнә сәнгате" дигән аерым бер дөнья белән тыгыз бәйләнештә булуы язучы иҗатына бөя биргәндә үзенә күрә бер кыенлык тудыра. Сәхнәнең үз яшәеше бар һәм язучы, телиме ул, теләмиме,

аңа буйсынырга, шуны исәптә тотарга мәҗбүр. Бары тик шул очракта гына автор үзенең иҗат җимешен сәхнәдә күрүгә һәм үз тамашачысын табуга ирешә. Ә болай— пьеса, әдәби әсәр буларак язылып та, сәхнә өчен конкрет адресланмаса—күп очракта, драматургиянең "тулы хокулы" иҗат җимешедәй кабул ителми. Соңгы вакытта басылган кайбер мәкаләләрдә Фәүзия Бәйрәмова һәм Айдар Хәлимнең бик кызыклы пьесалары дөнья күреп тә, аларның театр сәхнәләренә менмәүләренә борчылу, шул уңайдан хәтта берникадәр дәрәҗәдә театр җитәкчеләрен гаепләү чагылды. Тик хикмәт шунда ки: теге яки бу пьеса, идея-тематик ягыннан нинди генә кызыклы һәм камил булмасын, әгәр дә ул театрда куелмый икән, димәк, ул үз максатына ирешә алмый, чәчмә әсәр булып кына кала бирә. Спектакльнең чын хуҗасы—режиссер—драматург иҗатын сәхнәдә образлы рәвешли алмый икән, аны сәхнәгә күтәрүдән файда юк. Чынлыкта театрга тема-проблемаларны, көн геройлары һәм характерларны язучы тәкъдим итә, тик сәхнәнең рухын тоймаган авторның ниндидер уңай нәтиҗәгә ирешә алуы икеле.

Драматургик әсәр һәм спектакль арасында зур аерма барлыгын хәзер күпләр таный. Бу бигрәк тә "фикер тарафдарлары" булып танылган Зөлфәт Хәким һәм Мансур Гыйләҗев иҗатларында аермачык чагыла. Алар тарафыннан язылган пьесалар режиссер концепциясенә ятышлы булганда гына киң яңгыраш ала алалар. Әйткәнебезчә, драматургик текст режиссерга спектакль куяр өчен чертеж-сызым гына ул. Чынлыкта исә, кирәкле җирдә басымнарын үзгәртеп, режиссер пьесаны сәхнәдә яңача "укып" чыга.

Авторлар белән театр арасындагы араны якынайта торган рецептларны аныклавы кыен, билгеле. Алар шактый күп һәм, шулай ук, үзара мөнәсәбәтләргә дә бәйләнгән. Бу җәһәттән, мисал өчен театрлар тарихына күз салсак, мондый гыйбрәтле мисалларны күрербез. Мәсәлән, Әлмәт театры прозаик-драматург Аяз Гыйләҗевның 10 пьесасын сәхнәләштергән, ә менә шул ук чорда яшәгән, иҗат иткән шагыйрь-драматург Илдар Юзеевның бередә бер әсәре дә куелмаган. Моны ничек аңларга? Икенче мисал: Мөслимдә яшәүче драматург Фоат Садриевның шул ук Әлмәт театрында 13ләп пьесасы куелган, ә менә башка, хәтта Кама аръягы театрлары да аны бик үк өнәп бетермиләр. Өченче мисал: быел Гаяз Исхакый премиясенә лаек булган драматург Данил Салиховның дистәләгән пьесалары К. Тинчурин, Әлмәт, Минзәлә, Башкортстандагы татар, башкорт театрларында рәхәтләнеп сәхнә күрә (сүз уңаеннан әйтим, быелгы сезонда гына 8 әсәре төрле театрларда куелган) һәм алар репертуар тота, ә менә Г. Камал театрының, ни сәбәптәндер, моңа кадәр әле аның бер генә әсәрен дә үз сәхнәсенә күтәргәне юк. Моны ничек аңлатырга?

Әйе, дөресен генә әйткәндә, драматургларыбызның күбесе бүген җилкәнсез көймәләрне хәтерләтә. Кая таба, ничек йөзәргә? Ходай үзе генә белә. Шунлыктанмы, бүгенге көндә драматургларыбыз "театрлар, режиссерлар безне күрсә, ишетсә, аңласа иде, алар белән элемтәгә керә алсак иде" дигән хыял белән яши. Чынлыкта, бүгенге көндә алар һәм театрлар арасындагы элеккеге тыгыз элемтәләр җуелуы үзен нык сиздерә. Хәзерге көндә мондый бәйләнешләр бәхетле очраклылык кына тәшкил итә. Заманында язучыларга һәрвакыт ярдәм итәргә, булышырга, аларга яңа идеяләр бирергә әзер торган, драматурглар өчен үзенә күрә иҗат лабораторияләре ролен үтәгән режиссерларыбыз Празат Исәнбәт, Равил Тумашев, Гали Хөсәеновтәйне табу шактый кыен. Шушы бушлыкны тутыру ниятеннән узган ел Г. Камал театры тарафыннан драмалар бәйгесе оештырылып, игелекле эш эшләнелде. 2004 елда бу бәйгедә—111, ә быелгы яшь драматурглар конкурсында 32 әсәрнең "ярышта" катнашуы үзе үк бу өлкәдә никадәр потенциаль көчләр барлыгын күз алдына китерергә мөмкинлек бирде. Андый бәйге автор белән театр арасындагы бәйләнешләрне җайга салу өчен конкрет бер адым буларак каралырга тиеш. Бәйге нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм "Җыен" фонды ярдәме белән 2004 елда "Яңа татар пьесасы" альманахы 2 томлык китап булып басылып чыкты һәм анда 14 пьесаның дөнья күрүе, 21 пьесаның кыскача эчтәлек-аннотациясе бирелүе үзе үк шул бәйләнешләрнең нигезен барлыкка китерде. Бер ел эчендә генә дә ул җыентыктагы дүрт пьеса сәхнә күрде. Болар Г. Камал театрында—З. Хәкимнең "Телсез күке" һәм "Бит"е, Р. Бохараевның "Тимер борчагы", Чаллы драма театрында—Р. Батулланың "Ана каргышы" һәм З. Хәкимнең "Бит"е. Куелуын куелдылар, ләкин алар сәхнәдә тиешле яңгыраш таба, мәдәният тормышыбызда эзле вакыйга булып кереп кала

алдылармы? Бу сорауларга гади генә җавап бирү мөмкин түгел. Калган пьесалар алга таба репертуарга кертелерме, юкмы—бусы инде театрларның үз ихтыяҗларына бәйле.

З. Хәкимнең "Телсез күке" драмасы театрның иҗат программасын чагылдырган спектакльләрнең берсенә әверелде. Ул "Яңа татар пьесасы" бәйгесендә беренче урынны яулады. Әсәр милли темага багышланып, әле артык ерак булмаган тарих битләренә күз сала һәм татар халкы рухи дөньясының эчке бер яшәү чыганагының асылына төшенергә омтылуы белән үзенә җәлеп итә. Ләкин "Телсез күке" күләме ягыннан шактый озын (китапта 162 бит), шуңа күрә аны гади сәхнә калыпларына сыйдыру бик шикле. Мөгаен, әсәрдә күтәрелгән четерекле һәм үткен "татар мәсьәләсе" театрны үзенә шулкадәр тарткан булса кирәк, режиссер Ф. Бикчәнтәев аны 3-4 мәртәбә кыскартып, бербөтен яңгырашка ия спектакль тудырырга тырышкан. Татар халкы кайда гына яшәмәсен, аның күңелендә һәрчак туган иленә бирелгәнлек, үз телен, моңын сагыну, юксыну хисе яши һәм бу сагыш тойгысы асылда халыкны бер-берсенә тарта, берләштерә. Әлеге әсәр күп илләргә сибелгән татар халкының язмышы турында борчылып, ачынып язылган һәм спектакль тамашачыны үз асылына кайтырга өнди, аның үзаңына җайлап кына сәяси бәйсезлек, мөстәкыйльлек рухы сеңдерергә тырыша.

Ә менә З. Хәкимнең икенче пьесасы "Бит"—күбрәк психологик драма жанрында язылган фәлсәфи әсәр. Тик, кызганычка каршы, сәхнәдә ул әле үзенең тиешле тирәнлегендә, фәлсәфи мәгънәсендә ачылып җитә алмады. Сюжет монда үзмаксатка әверелә. Ә инде өченче урынны яулаган әсәр—Р. Бохараевның "Тимер борчагы"—сәхнә куелышы ягыннан автор әйтергә теләгән фикердән бик ерак тора. Гомумән, бу әсәргә яшь режиссерның әлегә "теше үтеп җитмәгән". Ул балалар өчен язылган пьеса, ләкин аның адресы ачыкланмаган һәм авторның әйтергә теләгән фикере спектакльдә "нуль"гә әверелгән.


*Хатын-кыз әдибәләребез.*

Бүгенге көндә драматурглар сафында Туфан Миңнуллин,Рабит Батулла, Ризван Хәмид, Мәдинә Маликова, Фоат Садриев, Юныс Сафиуллин, Фәнис Яруллин, Мансур Гыйләҗев, Зөлфәт Хәким, Гафур Каюмов, Данил Салихов, Аманулла, Хәбир Ибраһимов, Рәдиф Сәгъди, Фәнәвил Галиев, Эсфир Яһудин, Рафис Корбан, Ркаил Зәйдулла, Равил Бохараев, Шамил Фәрхетдинов тора. Аларның һәркайсының үз йөзе, үз куәте бар.

Элегрәк безнең театрларыбыз "Тормыш геройларын—сәхнәгә!" дигән максат белән эш итте. Бүгенге чуар, социализмны капитализмга үзгәртеп кору заманында исә, тормыш принципларыбызның асты өскә килгән бер чорда, иң алгы планда кем булырга тиеш—икеләнә торган, бернигә ышанмаучан, кыйбласын җуйган, шуны эзләүче, эшнең җаена төшенергә омтылучы, "ике агач арасында адашкан" кешеме? Әллә югыйсә, бернигә карамыйча, язмыш сынавын лаеклы үтеп, тирә-юнендәге кешеләргә игелек күрсәткән, мәрхәмәтле, үзенең тормыш принципларына турылыклы булып калган чын Кешеме? Бу сорауларга җавапны бүгенге драма әсәрләребездән эзлик. Мисал өчен игътибарны Т. Миңнуллинның "Шулай булды шул..." пьесасына юнәлтик. Кем монда герой—кичә генә алдынгы колхозчы булган, хәзер заман үзгәрешләренә яраклашучы, кызының йөккә узу хурлыгын яшерергә омтылучы Нургалиме, яки машиналы булу бәрабәренә очраган бер кызга өйләнергә әзер Алмазмы? "Халыкта мәхәббәтне сатып алып булмый" диләр, ә менә бүгенге заман чире—"алдымбирдем" чире белән авырганыбызны сизми дә калып, уйламаганда гына мәхәббәткә дә һөҗүм итә башлаганбыз бит. Бу әсәрдә шушы ике образдан тыш башкалары әсәрнең төп темасыннан читтә калалар сыман. Бигрәк тә хатын-кыз рольләре—алар "туры сызыктагы" характерлар, бары тик ярдәмчел образлар гына. Әйтик, Хәлимә образы.

Аның кызы кемнәндер бала табарга җыена, "алдым-бирдем" ясап аталары аңа "ялган туй" ясый, ә анасының моңа исе дә китми. Бәлки мондый ана образы безнең заман героинясыдыр? Автор бу очракта, миңа калса, драма материалын комедия жанры кысаларына сыйдырырга тырышкан.

Заманның тагын бер герое—Ф. Галиевнең "Корт" әсәрендәге Хәйдәр образына тукталасы килә. Мәскәү белгечләре Казанда узган драматурглар семинарында бу пьесага "иң кызыклы авыл пьесасы" дип мөһер сукты һәм аның төп герое Хәйдәрне заманыбызның "уңай герое" рәтенә күтәрде. Хәйдәр турында Мәскәүнең "Страстной бульвар" журналы болай язды: "Безнең заман герое турында авторлар да, тәнкыйтьчеләр дә күп сөйлиләр, тик реаль тормышта аны таба гына алмыйлар. Герой—ул эчке һәм тышкы шартлардан, акчадан бәйсезлек хисенә ия кеше, шул ук вакытта, бу кешенең яшәү халәте югары, изге максатларга буйсынган булырга тиеш. Галиев мондый геройны авылда тапкан. Авыл халкы күзлегеннән караганда ул үзе бераз сәер кеше. Башта ул барча халык белән колхозда эшләгән, соңыннан үз хуҗалыгын булдырган. Үзенә керем эзләп түгел, ә бәлки бары тик инерция белән генә яшисе килмәгәнлектән. Авылдашларның исә Хәйдәр "хәйләсенә" төшенәселәре килә—ничек итеп ул бакчасында колорада кортларын юк итә алган, кая киткән алар? Бу образ күп тапкырлар сәхнәдә күрелгән көлкеле герой түгел, ул бары тик җир йөзендә үз-үзен хөрмәт итүче, гап-гади бер хезмәт кешесе. Монда җир кешеләренең шул җиргә булган мөнәсәбәте уртага салып карала һәм авыл халкының мәзәк холкы елмаю аша сурәтләнә." Шундый ук риясыз, саф күңелле кешеләрне Данил Салиховның "Узып барышлый" һәм "Өзелгән йөзем" драмаларында очратабыз. Бу пьесалар үзләренең моңсу аһәңе, йөрәкләрне чеметтереп ала торган хакыйкате белән җәлеп итәләр. Сюжетлары бик гади һәм тормышчан. "Узып барышлый"дагы Шәйхулла карт фронтовик дустының үлем хәлендә икәнлеге турында хәбәр ала һәм аның янына бару теләге белән юлга чыга. Ләкин аны вокзалларның берсендә, поезддан поездга күчкән чакта, документларына хәтле кычкыртып талыйлар. Әсәрдә бүгенге көн геройлары—караклар белән бергә илебез өчен башын салырга әзер торган, романтик рухлы, коммунист йөрәкле фронтовиклар. Ике буын вәкиле биредә йөзгә-йөз очраша. Ике төрле чор, ике төрле катлам вәкилләренең фаҗигасе күзаллана. Алар бик киеренке хис-тойгылар белән чарланган.

Бөек Ватан сугышы темасына багышланган "Өзелгән йөзем" драмасы Минзәлә һәм Әлмәт театрында Җиңү бәйрәме алдыннан тамашачыга күрсәтелде һәм халык тарафыннан зур дулкынлану белән кабул ителде. Әсәрдә ике парның язмышында сугыш кайтавазының тәэсире, бернигә карамастан кешеләр рухының сынмавы бәян ителә. Нинди генә очракларда да Кеше һәрвакыт—мәхәббәттә дә, дуслыкта да, өметсезлектән җанына урын таба алмаганда да—көчле булып калырга тиеш! Шул ук тема Аяз Гыйләҗевның "Яра" повесте буенча М. Гыйләҗев язган инсценировкада да ярылып ята. Аны шулай ук ике театрыбыз куйды—Г. Камал театры һәм Түбән Кама театры. Чор фаҗигасе, язмышлар драмасы монда да спектакльләрнең рухын тәшкил итте. М. Гыйләҗевның үз иҗатына килгәндә исә, аның Минзәлә театрында куелган "Яратылыш" драмасы һәм К. Тинчурин театрында куелган "Баланың баласы балдан татлы" комедиясе һәр вакыттагыча җитди уйланылган, фикере ягыннан көн кадагына суга торган әсәрләр. Гомумән, аның образлары—фикер чагылышлары ягыннан җыелма театраль маскалар кебек. Алар берникадәр схематик рәвештә сюжет-композициясе ягыннан шахмат уенын хәтерләтәләр. Характерларга бераз җанлылык та өстәлсә, күпкә отышлырак булыр иде төсле.

Инсценировкалар турында сүз чыккач, шуны да ассызыклыйк: 100 еллык театрыбыз тарихында проза әсәрләрен сәхнәләштерү сан ягыннан әллә ни күп түгел. Исәпләп карасаң, җәмгысы 10-15 ләп проза язучының әсәрләре буенча инсценировка эшләнгән һәм аларның күбесе театр тарихында эзле, зур вакыйга булып кереп калган. Ә менә соңгы өч ел эчендә, ни хикмәт, театрлар проза өлкәсенә "һөҗүм"не көчәйткән—6 әсәр сәхнәләштерелгән. Монда билгеле, Татар яшь тамашачылар театрының баш режиссеры Ринат Әюповның роле аз түгелдер, чөнки аларның 5 есен сәхнәгә ул куйган. Шулар арасында Г. Исхакыйның өч хикәясе бар. Чаллы театрында куелган "Кәләпүшче кыз", Минзәләдә куелган "Сөннәтче бабай", һәм "Остазбикә" (инсценировкалар авторы Р. Садриев) аерым бер яссылыкта каралырга тиеш. Р. Әюпов куелышындагы алда әйтелгән спектакльләр театрлар тормышында аерым бер

вакыйгага әверелде. Шулай булмаса, быел Минзәлә театрының "Сөннәтче бабай" белән "Остазбикә"се Муса Җәлил премиясенә лаек була алыр иде микән? Аннан соң Татар яшь тамашачылар театрында шул ук режиссер зур осталык белән милли классикабызның җәүһәре саналган Г. Ибраһимовның "Алмачуар" һәм Г. Әпсәләмовның "Газинур" әсәрләрен куйды.

Шундый ук тәэсир итү көченә ия дип Р. Батулланың "Сак-Сок" пьесасын да атар идем. Драматург бу очракта да халкыбызның күңел түренә тирән яшеренгән хәсрәтле милли хис-тойгыларны, уй-фикерләрне күзаллап, аларны файдаланырга тырышкан. Аның әсәрләренә Чаллы театры да мөрәҗәгать иткән, "Нурислам нигезе" пьесасын төпле социаль драма күзлегеннән чыгып, уйландырырлык дәрәҗәдә куя алган. Чаллы театры Р. Батулланың тагы бер әсәрен—"Ана каргышы" дип аталган пьесасын—куйган.

Йомгаклап шуны гына әйтәсе килә: республикабыз театрларында өч елда 40 ка якын сәхнә әсәре куелган икән, димәк, драматургларыбыз хәрәкәттә—эзләнәләр, табалар, актив рәвештә тормышыбызга йогынты ясарга тырышалар. Аларның әсәрләрендә дә киләчәк заман героеның үсентеләре бөреләнә, фәлсәфи кыйммәтләр ачыклана, милләт язмышы ачыклана.

**Рафис Корбан**

## ЗАМАНГА ЙӨЗ БЕЛӘН

Соңгы корылтайда балалар әдәбияты буенча чыгышны миңа ясарга насыйп булган иде. Анда бер генә мәсьәләгә тукталырга туры килде. Ул—балалар китабын чыгару проблемалары һәм бездә шушы эшне башкарырга тиешле балалар китабы нәшриятына мохтаҗлык. Үткән корылтай бу тәкъдимне бердәм хуплап, үзенең резолюциясенә аерым пункт итеп: "Татар балалар китабы нәшриятын ачу буенча чаралар күрергә!"—дип, зурлап язып та куйган иде.

Ләкин, ни кызганыч, идарә бу мәсьәләгә багышлап киңәйтелгән утырыш үткәрде һәм "андый нәшриятка мохтаҗлык юк" дигән карарга килде дә, шуның белән бу бурычны өстеннән төшереп куйды. Ә мәсьәлә чишелмәгән килеш калды.

Кирәк безгә балалар китабы нәшрияты! Телебезне саклап калу өчен кирәк, милләт булып сакланып калуыбыз өчен кирәк. Халкыбыз өчен кирәк! Югыйсә, тагын күп дигәндә 10 елдан, безнең язганнарыбызны укучы да булмаячак!

Идарәнең киңәйтелгән утырышында "булган нәшриятларыбызда балалар китабы бастыруга игътибарны көчәйтергә кирәк" дигән тәкъдим белән чикләнелде. Бәхәсләшмим, безнең Татарстан китап нәшрияты да, "Мәгариф" нәшрияты да балалар китабы чыгаруга зур игътибар бирә. Ике корылтай арасында Татарстан китап нәшрияты 40 тан артык, "Мәгариф" нәшрияты 30 дан артык балалар әдибенең китапларын бастырып чыгарды. Исемләп санаганда, бу исемлеккә бүген балалар өчен иҗат иткән һәр язучыны кертергә мөмкин. Кыскасы, ике корылтай арасында безнең балалар язучыларыбыз ким дигәндә берәр китап бастырып чыгару бәхетенә ирешкәннәр. Өч елга бер китап чыгару—бу бүгенге мөмкинлекләрдән чыгып караганда "бик әйбәт" дип бәяләнергә хаклы. Ләкин, хөрмәтле каләмдәшләр, хәлебез шулай әйбәт дип тынычланып калырга урын бармы? Әйдәгез, шушы ике корылтай арасында чыккан китапларга кыскача күзәтү ясап алыйк әле.

"Мәгариф" һәм Татарстан китап нәшриятларында 70 ләп авторның китабы басылган дидек. Шулардан яртысы—34 е генә—үз китапларын яңа әсәрләрдән төзеп чыгарган. Аларның 20 се—шигырь, 14 е проза жанрына карый. Шагыйрьләргә килгәндә, барысы да таныш исемнәр. Балалар шигъриятенә бер генә яңа исем дә килмәгән. Проза хакында да шуны ук әйтергә кирәк. Балалар прозасында аеруча актив

эшләгән, әсәрләренең һәм сюжет корылышы, һәм стиль, тел үзенчәлекләре белән үзенә җәлеп иткән бер авторны күрсәтеп үтәсе килә. Ул—Рәшит Бәшәр. Аның Татарстан китап нәшриятында чыккан "Ачык капка" китабы авторның балалар дөньясын, психологиясен белеп, шулай ук халкыбыз язмышы, тарихы, үткәне хакында үтемле, аңлаешлы тел белән язуы укучыны үзенә тарта. Бәшәр шигърият өлкәсендә дә эшләвен уңышлы дәвам итеп, 2003 елда "Мәгариф" нәшриятында "Кояшлы яңгыр" исемле шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарды.

Шигырьләргә килгәндә, Илгизәр Солтан атлы талантлы гына балалар шагыйребез бар иде. Кызганыч, инде "бар иде", дип, үткән заманда сөйләргә мәҗбүрбез. Татарстан китап нәшрияты чыгарган "Тәмле телле малай" китабы Илгизәрнең үзенең дә тәмле телле шигырьләр иҗат итүе хакында сөйли.

Шулай ук Гакыйль Сәгыйровның "Шатлыклы иртә" китабын уңышлы балалар китапларыннан берсе булды дип билгеләп үтәсе килә. Фирая Зыятдинова, Йолдыз, Вәсимә Хәйруллина кебек шагыйрәләребез дә нәни укучыларны әйбәт шигырь китаплары белән сөендерделәр. Яңа әсәрләр язмасалар да, Шәүкәт Галиев, Роберт Миңнуллин, Мәрзия Фәйзуллина, Энҗе Мөэминова, Ләбибә Ихсанова, Роза Хафизова, Альберт Хәсәнов кебек әдипләребез нәни укучыларына үзләренең яңа китапларын бүләк иттеләр.

Галимҗан Гыйльман, Флера Тарханова, Рафаэль Газизов, Мөҗәһит, Илдар Юзеев, Ләбиб Лерон, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Ренат Харис, Эльмира Шәрифуллина, Әхсән Баянов кебек язучыларыбызның балалар өчен язган әсәрләре исә "Мәгариф" нәшрияты тырышлыгы белән нәни укучыларына барып ирешә. Соңгы елларда балалар өчен һәм прозада, һәм шигърияттә Нәкыйп Каштановның сулышы киң ачылып китте. Ул Татарстан китап нәшриятында, "Мәгариф", "Рухият" нәшриятларында берсеннән-берсе кызыклы шигырь-хикәяләр тупланган китаплар чыгарды.

Күрәсез, хәлебез алай ук начар түгел икән әле. Язучыларыбыз эшли—яшьләр яңа әсәрләре белән ялтырый, өлкәннәр элекке багажларын барлый, үзләрен яңа буын укучысына таныта.

Ләкин күңелне борчыган нәрсәләр дә шактый. Әйтик, Фәүзия Бәйрәмованың "Алыплар илендә", Ләлә Гыймадиеваның "Чуфут кале малайлары" әсәрләрен кертмәгәндә, китапларыбызда заман рухын, заман баласы психологиясен, аның дөньяга карашын чагылдыручы әсәрләр юк дәрәҗәсендә.

Тагын бер мәсьәлә. Ул—соңгы елларда балалар әдәбиятында яңа исемнәрнең азлыгы. Яшьләр, студентлар арасында Ленар Шәех атлы егетебез балалар өчен өметле генә шигырьләр язарга сәләтле булуын күрсәтте. Аның иҗатын балалар әдәбияты остаханәсендә тикшереп, шигырьләрен Татарстан китап нәшриятына тәкъдим иттек. Ленардан кала яңа исемнәр күренми. "Ике корылтай арасында берлеккә 37 яңа әгъза кабул ителгән" дигән сүзләрне ишеттек—кызганычка каршы, аларның бишесе генә балалар өчен язган әсәрләре белән үткән. Иң яше 1960 елда туган.

Алда әйтеп үткәнемчә, балалар өчен язучыларыбыз ике корылтай арасында кимендә берәр китап бастырып чыгару бәхетенә ирешкәннәр. Әйе, китап чыгару язучы өчен бик мөһим—ул аның иҗади эшчәнлегенең үзенчә бер нәтиҗәсе, тормышының асыл мәгънәсе. Шуңа күрә без һәммәбез дә язганнарыбызны китап рәвешендә күрергә омтылабыз. Китап ул—язучының укучысына барып ирешү чарасы. Рәсәйдә дәүләт дотациясендә китап чыгаручы нәшриятлар ике республикада гына калды—Татарстанда һәм Башкортстанда. Шулай ук дәүләт ярдәмендә яшәп ятучы Язучылар берлеге дигән иҗтимагый оешмалар да берничә генә. Ләкин, хөрмәтле каләмдәшләр, без телибезме, теләмибезме, бер көн килеп, нәшриятларны да, Язучылар берлеген дә казнадан асрау тукталыр. Башка төбәкләрдә, Мәскәүдә, алар күптән инде мөстәкыйль яшәүгә мәҗбүр ителделәр. Ә безнең әле һаман да дәүләт хисабына яшәп ятуыбыз ул бары тик Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиевнең әдәбиятка, сәнгатькә, мәдәниятка хәер-хаһлы мөнәсәбәте аркасында гына! Шуңа күрә без, беренчедән, бүгенгә кадәр безгә ярдәм иткән мөхтәрәм Президентыбызга рәхмәтле булып, икенчедән, тормыш-яшәешебездә базар мөнәсәбәтләренә күчәргә әзер торырга тиешбез. Дөресен генә әйткәндә, соңгысына безнең берлек әзерлекне инде күптән башларга тиеш иде. Ә без, кызганычка каршы, әле һаман да алдыбызга ялгыш иллюзияләр корып, могҗизага ышанып, нәрсәгәдер өметләнеп ята бирәбез.

Әйтик, китап чыгару эшендә Язучылар берлеге читтә торырга тиеш түгел. Кайбер язучыларыбыз шушы дөрес фикердән чыгып, үзләренең кулъязмаларын берлек житәкчеләренә китереп тапшыралар. Ләкин, кызганычка каршы, ул кулъязмалар идарә аппараты шкафларында еллар буе тузан җыеп ятарга мәҗбүр ителә. Драматург Әмир Камалиев, мәсәлән, моннан берничә ел элек идарәгә тапшырган кулъязмасын нәшрияттан эзләтеп интеккәч, ниһаять, берлектән эзләп табып, былтыр нәшриятка китерде һәм ул китап булып басылып ята. Күренекле әдибебез, инде мәрхүм Газиз Мөхәммәтшинның җәмәгате Ләлә ханым шулай ук иренең "Саумысыз, аккошлар" исемле җыентыгын берничә ел берлектә югалып ятканнан соң, нәшриятка китереп тапшырды. Димитровград каласыннан Гакыйль Сәгыйровның ике җыентыгы менә берничә ел инде идарә шкафларында тузан җыеп ята икән. Бу хакта нәшриятка Фәнис абый Яруллин хәбәр биргәч идарәгә берничә тапкыр мөрәҗәгать итсәк тә, әле хәзергә кадәр кулъязмаларны күрә алганыбыз юк. Һәм мондый мисаллар байтак.

Берлек идарәсе һәм аппараты шулай ук язучыларның китапларын тарату буенча да нәшриятлар белән кулга-кул тотынып эшләргә тиеш дип беләм. Бу мәсьәләдә дә "кызганычка каршы" дигән сүзләрне кулланырга туры килә. Язучыларның төрле очрашулары, төрле регионнарда татар әдәбияты көннәре, юбилей кичәләре уздырылып тора. Ләкин еш кына бу чараларны үткәрү программаларын төзегәндә язучыларның китаплары игътибардан читтә кала. Өр-яңа бер мисал: 10-15 көн элек кенә бер төркем язучылар Бөек Ватан сугышында һәлак булган шагыйрь Нур Баянның тууына 100 ел тулу уңаеннан аның туган ягында—Актаныш районында—йөреп кайттылар. Татарстан китап нәшрияты шушы юбилей һәм Бөек җиңүнең 60 еллыгы уңаеннан шагыйрьнең иң яхшы шигырьләрен һәм поэмасын туплаган китабын әзерләп, бастырып чыгарды. Ләкин бу хакта Актанышта белми дә калдылар. Ә бит моның ише чараларны оештыручылар китап нәшриятларын да читтә калдырырга тиеш түгелләр иде!

Чыгышымны түгәрәкләп, хөрмәтле каләмдәшләр, шуны әйтәсем килә: бүгенге корылтай 70 еллык тарихы булган Татарстан Язучылар берлеге язмышында хәлиткеч булырга мөмкин. Шуңа күрә без бүген яңа сайланачак идарә һәм берлек аппараты алдына заманга йөз белән борылып, үзенең эшчәнлеген яңача, яңа критерийларга йөз тотып кору бурычын куярга тиешбез.

Лилия
Газизова

## РУС ЯЗУЧЫЛАРЫ ИҖАТЫ

Реализмның бәрәкәтле туфрагына нигезләнгән классик проза һәм поэзия традицияләрен уңышлы рәвештә дәвам итә барып Татарстанда яшәүче хәзерге рус язучылары соңгы 3 елда кызыклы гына әдәби әсәрләр тудырдылар. Республика нәшриятларында һәр елны 2-3 авторның китабы басылып чыкты. Ләкин, рус телендә иҗат итүче каләмдәшләребезнең саны 40 тан артуны искә алсак—бу сан, әлбәттә, зур түгел.

Иң нәтиҗәле эшләүче язучыларыбызның берсе—ул Владимир Корчагин. Соңгы елларда бу автор фәнни фантастика жанрында уңышлы иҗат итә. "Карадан киенгән ханым" романы хәзерге фәнни ачышларны гомум кабул ителгән әхлак нормалары яктылыгында карый, укучыга җитди рухи сабак бирә.

Нонна Орешина иҗат иткән "Акрын эшләүче мина" романы исә үткен психологик сюжетка корылган, аның төп геройлары—катлаулы рухи эзләнүләр белән яшәүче хәзерге яшьләр.

Майя Вәлиева сирәк кеше эшли торган анималистик проза тармагында яза, аның

"Кешеләр һәм бультерьерлар" әсәре башта "Идел" журналында, аннары аерым җыентык булып дөнья күрде һәм ул Республика Милли китапханәсе уздырган тикшерү нәтиҗәләре буенча 2004 елның иң күп укылган китабы дип табылды.

Диас Вәлиев укучыларга яңа дин, панфилософия тәкъдим итү юлында тырышлыгын киметми, аның "Күренмәгәнгә ышаныч" дигән икетомлыгы шушы юнәлештә яңа адым дип кабул ителергә тиеш. Соңгы елларда ул шулай ук "Дон Жуан портреты" дигән кызыклы җыентык та бастырып чыгарды.



*ТР Премьер-министры Рөстәм Миннеханов язучы Нонна Орешинага диплом тапшыра.*

Күренекле әдәби тәнкыйтьчебез Рафаэль Мостафинның "Заман, тормыш һәм үзем турында" дип исемләнгән китабы да истә калырдай әдәби күренеш иде дип уйлыйм. Ә менә Владимир Лаврншконың "Көз яшьләре" дигән җыентыгы проза һәм поэзия әсәрләрен бергә туплаган кызыклы басма. Бу елларда шулай ук Салават Юзеев "Мин монда калам", Алла Гарзавина "Университет профессоры—немец галиме" дигән китаплары белән сөендерделәр. Евгений Сухов үзенең криминаль-психологик романнар сериясен дәвам итте. Владимир Паркаев та яңа әсәрләр бирде. Язучы фронтовик Геннадий Паушкин, Аркадий Мельников шулай ук уңышлы иҗат белән шөгыльләнделәр.

Ольга Левадная, Елена Бурундуковская, Наилә Ахунова шигърият үрләреннән һаман күтәрелә баралар. Николай Алешковның "Петр белән Мариша малае" дигән поэзия китабы исә тәнкыйтьчеләрнең аерым игътибарына лаек дип саныйм. Шулай ук Иван Грай, Михаил Тузов, Лилия Газизова яңа китапларын бастырып чыгарды. Леонид Топчий белән Юрий Макаровның җыентыклары исә үзләре мәрхүм булгач дөнья күрде.

Балалар өчен кызыклы шигырь китаплары басылып чыкты. С. Малышев, Б. Вайнер бу өлкәдә уңышлы эшләде. Р. Миңнуллинның әсәрләре русча дөнья күрде. Шигъри әсәрләрне русчага тәрҗемә итү эшен уңышлы оештыру ягыннан шагыйрә, "Идел" журналының баш мөхәррир урынбасары Роза Кожевникованың актив эшчәнлеген аерым билгеләп үтү сорала. "Мөнәҗәтләр" китабының рус телендә басылып чыгуы да (С. Малышев тәрҗемәләре) игътибарга лаек күренеш.

Бу елларда матбугатта Р. Кожевникова, Р. Сабиров, С. Малышев, Н. Беляев, В. Трофимов, В. Лаврншко, О. Левадная, Н. Ахунова, Н. Әхмәров, И. Грай, А. Әпсәләмова, Л. Набат, В. Домрачев, Т. Пашагина, Т. Ратникова, Н. Спасова-Земляниченко, Е. Беляева-Чернышева, А. Кашина, Л. Газизова үзләренең шигъри бәйләмнәрен бастырдылар.

Казан Курчак театрында Б. Вайнер, Л. Кожевников, Н. Ахунова пьесалары нигезендә кызыклы спектакльләр дә куелды. Инде 12 ел буена балалар өчен "Зонтик" журналы басылу да иҗатка уңай тәэсир ясый. Ике ел элек "Шакмак тәгәрмәч" ("Квадратное колесо") журналы чыга башлау да әйбәт булды.

Соңгы елларда Әхәт Мушинский (2002), Лилия Газизова (2003) һәм Лев Кожевников (2004) Г. Р. Державин исемендәге премиягә лаек булдылар.

Бу чорда шулай ук киң колачлы оештыру чаралары да күрелде, берсеннән-берсе кызыклы әдәби очрашулар, кичәләр булып узды. Н. Ахунова, А. Кәримова, Т. Алдошин җитәкләгән әдәби берләшмәләр аеруча актив эшли. Яшьләр белән актив эш алып барылу аркасында матбугатта талантлы яңа исемнәр күренде. Бу чорда А. Хәсәнов, М. Тузов, И. Грай, Е. Турухан, С. Юзеев Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

Әлфәт
Закирҗанов

# ҖАНЛАНУ СИЗЕЛӘ

Әдәби иҗатның бер тармагын тәшкил иткән тәнкыйтьнең торышы, аны җанландыру мәсьәләләре соңгы елларда игътибар үзәгендә булды. Чөнки тәнкыйть әдәби барыш белән бергә атлап, хәтта аннан алда барып, әдәбияттагы табышюгалтуларны ачык күрсәтергә, билгеле бер таләп-критерийларны билгеләргә, сүз сәнгате белән китап укучы арасында арадашчы, киңәшче, ярдәмче ролен үтәргә бурычлы.

Ике корылтай арасында әдәби тәнкыйтьнең торышын ничек бәяләргә соң? Төрле газета-журналларда басылып чыккан күпсанлы мәкаләләр, китап-җыентыклар, фәнни-теоретик хезмәтләр белән танышу уңай якка үзгәреш турында сүз алып барырга мөмкинлек бирә. Тәнкыйтьнең әдәби процесс, җәмгыятьтәге мөһим үзгәрешләр, милләт язмышы, җәмәгатьчелекне борчыган проблемалар белән бәйләнеше күренә.

Хәзерге сүз сәнгатенең, шул исәптән тәнкыйтьнең торышын, үсеш-үзгәрешен билгеләүче булып "Казан утлары" журналы һәм аның янәшәсендә "Мәдәни җомга" газетасы тора. Аларның аягына басып дигәндәй "Мәйдан" журналы атлый. Беренчесендәге—"Әдәби тәнкыйть", "Китап күзәтү", "Әдәбиятыбыз тарихына", соңгысындагы "Каләм яктысы" һ.б. рубрикаларда әдәби тәнкыйтькә, гомумән, әдәбият тарихына, белемнә бәйле язмаларга системалы урын бирелә. Эчтәлек-концепцияләренә бәйле "Татарстан", "Мирас", "Идел" журналларында тәнкыйть материаллары аз урын били. "Ватаным Татарстан", "Шәһри Казан" газеталары исә нәкъ менә оператив тәнкыйть—басылып чыккан китапларга күзәтү-бәяләмәләре белән—әлеге тармакка хезмәт итә.

Тәнкыйтьне җанландыру, аның чор әдәби процессы белән бәйләнешен арттыру һәм китапны пропагандалау вазыйфасы ягыннан рецензия—китапка күзәтү ясау—өһим роль уйный. Кызганыч ки, иң оператив жанр булырга тиешле рецензия-бәяләмә рәвешендәге китап күзәтүләр һаман канәгатьләндерми. Мондый язмалар белән танышкач, аларның шактый булуы күзгә ташлана, әмма төрле матбагаларда басылып чыккан китаплар саны белән чагыштырганда гаять тә аз икәнлеге аңлашыла. Бу жанрда иң актив эшләүчеләр буларак Р.Шәрәфиев, Р.Мостафин, М.Вәли-Барҗылы, Р.Сверигин, Ә.Мәхмүдов, М.Әхмәтҗанов, Р.Фәизов, Н.Акмал, Ф.Бәширов, Ф.Зариф, В.Нуруллин язмалары игътибарга лаек. Аларда әсәрләр үткән тарих һәм бүгенгебез белән бәйләнештә карала, автор концепциясе үз тормыш тәҗрибәләре, яшәеш турында уйланулары аша ачыла, төп сыйфат-билгеләре калкытып куелып, китап укучыга тәкъдим ителә. Шулай да күпчелек рецензия-бәяләмәләрнең уртак кимчелеге – артык гомуми бәя, эчтәлек сөйләү һәм әдип иҗатының сәнгати ягы читтә калу. Китап күзәтүләр арасында әдәбиятның мөһим ике тармагы читтәрәк калып килә. Бу – драматургия һәм балалар әдәбияты. Ике корылтай арасында И.Юзеев, Т.Миннуллин, М.Маликова, А.Хәлим, Г.Каюмов, М.Гыйләҗев, Ю.Сафиуллин, Д.Салиховның пьеса җыентыклары басылып чыкса да, аларга бәяләмә-күзәтүләр булмады диярлек. Балалар әдәбияты белән дә шул ук хәл - бары берничә язма.

Хәзерге тәнкыйтьнең әдәби барыштагы урыны, беренче чиратта, әдәби-эстетик анализга нигезләнгән жанр формаларында ачыла. Бу очракта без иҗат портретларын, аналитик фикерләүнең шәхси уйланулар , әдип шәхесе белән үрелеп барган эссены, асрым әдәби төрләр янсә жанрлар торышына күзәтү-бәяләрне күздә тотабыз. Прозага бәйле Р.Сверигин, Ф.Латыйфи, Р.Рахмани, А.Хәлим, Д.Заһидуллина, Р.Зарипов, Р.Фәтхрахманов, М.Закир, Н.Гафиятуллина мәкаләләре, поэзия буенча Р.Рахмани,

Р.Зәйдулла, З.Мансуров, Р.Гаташ, С.Хафизов һ.б. язмалары, драматургияне өйрәнүче А.Әхмәдуллин, Д.Гыймранова, Г.Арсланов чыгышлары күпләрнең игътибарын җәлеп иткәндер.

Р.Рахманиның тәнкыйди язмалары хис һәм фикер бергәлегенә ирешкән әдәби әсәр кебек укыла. Аның каләме шактый сайлап, иҗатлары вакыт сынавын узган, җәмәгатьчелектә танылып та, тәнкыйть тарафыннан әлегәчә ачылып-аңлатылып бетмәгән әдипләргә төбәлә. Тәнкыйтьченең М.Юныс, Л.Шагыйрьҗан турындагы язмалары әлеге әдипләрне шәхес, художник, язучы итеп һәм берсен прозада, икенчесен поэзиядә уникаль күренеш буларак ачуы белән әһәмиятле.

Хәзерге шигърият турындагы уйлануларга бәйле Р.Гаташ, З.Мансуров язмалары шигъри көчләрне барлау, күрү, туплау рухында язылган. Шагыйрь-тәнкыйтьчеләр поэзиянең профессиональ дәрәҗәсе төшү, поэтика кануннарына игътибар кимү, телгә кагылышлы җитешсезлекләр артуын билгеләү белән чикләнәләр, конкретлык җитми. Мисал өчен, Р.Гаташ унга якын шагыйрь иҗатына күзәтү ясагач, мондый нәтиҗәгә килә: "йолдызлар бар, алар яна – күрә, сөенә белик". Аңлашыла ки, алдагы өлештә саналган кимчелекләр, "син дә йолдыз – мин дә йолдыз" ди торгач, эреп юкка да чыга.

Ә менә Р.Зәйдулланың "Куркытмагыз кошлар авазын" исемле язмасында Л.Шагыйрьҗан, Э.Шәрифуллина, З.Мансуров поэмаларын бәяләве шигъри анализның матур үрнәге булып тора. Р.Зәйдулла тәнкыйть өлкәсендә аз эшли, әмма нәрсә турында гына уйланып язса да, аңлап-белеп яза, шуңа да фикерләре ачык, мәгънәле.

Д.Заһидуллина исемен соңгы еллар әдәби тәнкыйтенең ачышы дип санар идем. Бу өлкәдә иң актив эшләүчеләрнең берсе ул—газета-журналларда гына да 10 лап мәкаләсе дөнья күрде. "Мәйдан" журналының махсус бүлегенә лаек булуы да шуның ачык мисалы. Аның төп кыйбласы - әдәби барышны язучының чынбарлыкны кабул итү һәм чагылдыру хасиятеннән чыгып, ягъни әдәби юнәлеш-агым нигезендә тикшереп бәяләү. Теоретик әзерлекле, әдәби анализда фәлсәфи карашларны да иркен файдаланучы тәнкыйтьченең Н.Гыйматдинова, Ф.Латыйфи турындагы язмалары әдипләрнең иҗат психологиясен һәм эволюциясен ачуның бер үрнәге булып тора. Башкортстанда яшәп иҗат итүче М.Кәбировның иҗат серләренә беренчеләрдән булып керүче дә ул иде. Д.Заһидуллинаның хәзерге тәнкыйть, Т.Галиуллин белән Мөдәррис Вәлиев җыентыклары турындагы язмалары да әлеге тәҗрибәле тәнкыйтьчеләрнең табышларын билгели алуы белән аерылып тора. Аерым язмаларда йә исемен атап, йә атамыйча гына: "Д.Заһидуллина теоретик терминнар яисә төрле "изм"нар белән мавыга" дигән фикерләр күренде. Бу мәсьәләдә бәхәскә кереп тормастан, шуны гына әйтәсем килә: бердән, әдәби барыштагы яңалыкларны аңлатучы термин-төшенчәләрнең үзебездә эшләнмәгәнен беләбез. Әгәр аерым әсәрләребез дөньякүләм танылу алырга хаклы дибез икән, аларны бәяләгәндә дөнья әдәбият белемендә кабул ителгән критерийларга нигезләнү мөмкин, хәтта кирәк. Икенчедән, һәм, иң мөһиме: тәнкыйтьче, безнең өчен яңа булып тоелган, ә рус әдәбиятында инде калыплашкан төшенчәләргә нигезләнеп, тикшерә торган язучының сәнгати фикерләү үзенчәлеген, әдәби-эстетик табышларын һәм югалтуларны бөтен тулылыгында ачып бирә.

Әдәбиятка үзенчәлекле караш-мөнәсәбәте белән аерылып торган авторларыбызның берсе – Р.Фәтхрахманов. "Йөрәкнең җеназасы" мәкаләсендә ул А.Хәлимнең "Татар вакыты", "Өч аяклы ат" әсәрләренә реализм кануннарыннан чыгып тирән анализ ясый һәм әлеге иҗатның төп үзенчәлекләреннән берсе итеп тормыш-чынбарлыкны мөселман идеологиясе призмасы аша яктыртуда күрә. Миңа калса, милли үзаңын җуйган кеше турында Ч.Айтматовтан алынган "маңкорт" сүзе киң кулланышка кергән кебек, Р.Фәтхрахмановның җиңел кулы белән А.Хәлим әсәренә нисбәтле бүгенге һәм киләчәк тормыш-яшәешендә буталып-адашып калганнар турында "мотаһарчылык" төшенчәсе дә әйләнешкә керер кебек. Ә менә соңгы вакытта шактый актив эшләүче Р.Зарипов мәкаләләрендә ирония белән өртелгән тәнкыйди рух өстенлек итә. Тәнкыйтьченең төп фикерләре белән килешкән хәлдә, анализ-бәяләмәдә әсәрләрнең тормышчанлыгы, ышандыру-ышандырмавы белән мавыгуы сизелә.

Язмалар арасында М.Закир, күптән түгел мәңгелек йортка күчкән галимә һәм тәнкыйтьче Мәдинә апа Җәләлиева, Н.Гафиятуллина мәкаләләре әдәби-эстетик таләпләрдән чыгып язылулары белән аерылып тора. Баштагы икесе турында

матбугатта сүз булды инде. Н.Гафиятуллина Ә.Салахның "Соңгы вальс" ын реалистик һәм романтик сюжет сызыклары үзара керешеп киткән әсәр буларак бәяләп, гаять кызыклы иҗат дөньясын ача. Тәнкыйди фикер-карашлар да мәкалә авторының таләпчән зәвыгы турында сөйли.

С.Хафизов - әдәби процессны даими күзәтеп барып, тирән эчтәлекле язмалары белән чыгыш ясаучы авторларның берсе. Алдагы елларда дөнья күргән "Туксанынчы еллар әдәбияты", "Әдәбиятта базар заманы" кебек мәкаләләрен күпләр хәтерлидер әле. Тәнкыйтьченең "Очмыйча син түзеп кара..." язмасында Башкортстандагы татар әдәбияты, аерым алганда 10 га якын шагыйрь лирикасы турындагы фикер-карашлары ачык-төгәл, дәлилле, мәгънәле. Автор тәнкыйтьләүдән дә качмый. Гомумән, "Башкортстан татарларының үз, кабатланмас рухын гәүдәләндергән әдәбият" турында матур күзаллау тудыра.

Сәхнә әдәбиятын өйрәнү, аның бүгенге торышын барлау, киләчәгенә ориентирлар билгеләү һаман да артка калып килә. Төрле спектакль премьералары, театрларның гастрольләре уңае белән язылган күзәтү төсендәге мәкаләләрдән тыш, драматургиягә кагылышлы хезмәтләр бармак белән генә санарлык икән. Арада А.Әхмәдуллин, Д.Гыйймранова, Р.Хәмид язмалары игътибарга лаек.

Драматургия тарихын системалы өйрәнүче А.Әхмәдуллин язмаларында хәзерге сәхнә әдәбиятының иҗтимагый һәм тәрбияви әһәмияте аеруча калкытып куела, шуңа да пьесаларда гаҗизлек мотивының киңәюен, кешенең кыргый инстинктларына күп мөрәҗәгать итүне, еш кына явызлык-караңгылыкның изгелек-матурлыктан өстен чыгуын сурәтләүне тәнкыйтьче кабул итми. Кешенең рухын күтәрә, җанына хөрлек, өмет бирә торган хәл-күренешләрнең, образ-геройларның күбрәк булуын тели.

Соңгы еллар тәнкыйте турында сүз алып барганда "Казан утлары" журналында 2004 елда башланып киткән һәм бүген дә бара торган "Безнең заман герое" исемле дискуссияне читләтеп үтеп булмый. Фикер алышу темасы хәзерге әдәбиятның һәр төре турында киң планда сөйләшү алып бару мөмкинлеге биреп, әдәби тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләрне барларга, аларны активлаштырырга, шуның белән бу тармакны тагын да җанландырып җибәрергә ярдәм итте. Дискуссиядә әдәби үсешнең төп тенденцияләрен, тема-проблемалар төрлелеген, аерым төр-жанрлар торышын билгеләү, заман героена хас сыйфат-билгеләрне ачыклау, сәнгати уңышларны һәм җитешсезлекләрне аерып күрсәтүгә бәйле шактый җитди, кызыклы һәм фикер төрлелегенә, каршылыкларга, яңа уйлануларга этәрә торган сөйләшү бара.

Һәр язмада нииндидер әһәмиятле мәгълүмат булуын әйтеп, бәхәсләргә киң урын калдырган мәкаләләргә тукталып үтик. Р.Фәизов "Алар безнең арада" мәкаләсендә ачык итеп соцреализм чоры әдәбиятындагы уңай геройларны сагынуы турында яза. Тәнкыйтьченең киң планда әдәби герой, прототип, индивидуальлек һәм гомумилек мәсьәләләре турында фикер йөртүе дә шактый бәхәсле. Аның Ф.Латыйфи әсәрләрендәге персонажларны соцреализм геройлары дип атавы да гаҗәпләнү уята. Р.Раковның "Укыр җаннар бетмәсен" язмасында А.Хәлимнең "Татар вакыты"нда сурәтләнгән Мотаһар, Мөдәррис, Фәрдүнә кебекләрне тудыручылар дип сугыш елларында җанын-тәнен кызганмыйча ил өчен, халык өчен дип хезмәт иткән "Намус" романындагы Нәфисә һәм башкаларны санавын аңлый да, аңлата да алмыйм.

Р.Зарипов тулаем кызыклы, тәнкыйди пафос өстенлек иткән "Пегас кашына микән?" язмасында бүгенге сүз сәнгатендә Достоевскийдагы Свидригайлов кебек геройларның күбәю сәбәбен үткәндәге әдәбиятыбыздан эзли һәм Т.Миңнуллинның "Кырларым-тугайларым", "Әлдермештән Әлмәндәр" кебек пьесаларын заман сынавын узмаган әсәрләр дип бәяли. Тәнкыйтьченең фикерләре кызыклы булса да, мин аларны кабул итә алмадым. Беренче пьесада 70-80 еллар авылы кешеләренең, икмәк дип җан атучының, шәхси мәнфәгатьләренә караганда, иҗтимагый кирәклекне алга куйган колхоз рәисенең образы тудырыла. Нәкъ шундый булулары белән алар чор рухын чагылдыра да инде. Әгәр Әлмәндәр картны автор әсәр ахырында намазлыкка бастырган булса, ул пьеса фәлсәфәсен, драматург концепциясен бозып аңлауга китерәчәк иде. Гомумән, алдагы еллардагы колхоз-производство яисә әхлакый-фәлсәфи сорауларны үз эченә алган әсәрләрне бүген инде әдәби-эстетик кыйммәте юк дип, алай җиңел генә тарихтан сызып атарга ашыкмыйк.

Дискуссия уңае белән язылган "Татарга сатма матбугат" мәкаләсендә Р.Фәтхрахманов хәзерге әдәбиятта барган эзләнүләрнең ике юнәлешен аерып чыгара.

Берсе – үткәндәге казанышларны кире кагып, яңага омтылу, вәзгыятькә аналитик бәя бирергә тырышу, икенчесе – ислам дине кануннарына нигезләнгән фикер-карашларны яклау. Әлеге бүленештә берьяклылык, ягъни дини-рухани юнәлештә язмаучыларның барысын да азгынлык һәм оятсызлыкны таратучылар итеп күрү сизелә.Ә менә Д.Заһидуллинаның теоретик һәм фактик материалларга бай "Уңай герой югалу: сәбәпләр, нәтиҗәләр" язмасы алдарак чыгыш ясаган берничә авторның "әдипләребез әшәкелек-азгынлык, ямьсезлек-караңгылык күренешләрен сурәтләү белән артык мавыгалар" дигән фикеренә җавап та булып тора.

Соңгы еллар тәнкыйтендә Р.Сверигинның лаеклы урыны бар. Галимнең "Нурзилә новеллалары...", Ф.Яруллинга 60 яшь тулу уңае белән язылган "Аны беләбезме?" язмалары сәнгати осталыкны билгеләү җәһәтеннән язылган. Дискуссия уңае белән дөнья күргән "Гасырлар чатында" мәкаләсендә хәзерге прозадагы табыш-яңалыкларны билгеләү белән бергә, конструктив, дәлилле, ышандыра торган тәнкыйть тә урын алган. Р.Сверигинның әлеге язмасы сәнгатилек мәсьәләләрен калкытып куюы, әсәрләргә эстетика таләпләреннән чыгып бәя бирүе белән үзенчәлекле.



*Корылтайда катнашучылардан бер төркем.*

"Безнең заман герое" на бәйле фикер алышуның кульминациясе булып әлегә А.Хәлимнең "Сез беләмсез кая барганны?" исемле күләмле хезмәте тора. Бу уңайдан шуны да искәртеп китик: әдәби иҗатның барлык өлкәләрендә дә уңышлы иҗат итүче язучы "Бирегез мәйдан!" эссесында Ф.Бәйрәмова әсәрләрен хәзерге татар әдәбиятының олы казанышы дип, һәм яңа герой концепциясе бирелеше ягыннан дөньякүләм яңгыраш алырга тиешле иҗат буларак тикшереп бәяләгән иде. Соңгы язмасы фикер алышуларга, еш кына бәхәсләргә юл ачты.

Әдипнең кайнар публицистика белән сугарылган җитди уйланулары аша, бүгенге яшәешебезне һәм әдәбиятыбызны педагогик, фәлсәфи, тәнкыйди, социаль анализлау нәтиҗәсендә туган хезмәтнең нигезендә милләт язмышы мәсьәләсе тора. Текстта ул сүз сәнгатенең милләт каршындагы җаваплылыгы булып тәгәлләнә. Автор милләт һәм әдәбият кебек аерылгысыз бәйләнгән төшенчәләрне бербөтен итеп карый. Язманы буеннан-буена өмет хисе сугара: без булган, бар һәм булачак, ди язучы. Әмма моның өчен һәркемнең күңелендә милли үзаң уятырга, барлык милләтпәрвәрләрнең эчке потенциалын бергә туплап, бердәм хәрәкәт итәргә кирәк. Шуларны милли идея итеп күтәргән тәнкыйтьче әдәбиятның төп бурычын милләт каһарманы тәрбияләүдә күрә һәм моның асылын, нигез-шартларын, юнәлешен җентекле аңлата.

Тирән аналитик фикерләүгә корылган хезмәттә хәзерге әдәбиятка, шул исәптән тәнкыйтькә дә хас булган, ассызыклап чыгарылган кимчелекләр белән кайсыбыз гына килешмәс икән. А.Хәлимнең мәктәп дәреслекләре, әсәрләрнең сайланыш принциплары, бәя бирү юллары турындагы уйланулары да Мәгариф һәм фән министрлыгының дәреслекләр бүлеге хезмәткәрләрендә кызыксыну уяткандыр дип уйлыйм.

Әлеге әдәби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи һәм милли-мәдәни уйланулар синтезы булган хезмәттә каршылыклы фикерләрнең күп булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Бердән, киң масштаблы булуы, яшәешнең күп якларын иңләп алуы төп сораудан читләшүгә китергән; икенчедән, А.Хәлимнең акны ак, караны кара дип әйтергә теләвен хуплаган хәлдә, урыны белән берьяклылык, субъективлык өстенлек ала. Әйтик, ул хаклы рәвештә: "Кайчан без мактамыйча җылы сүз әйтергә, хурламыйча тәнкыйть итәргә өйрәнербез икән?"—ди. Шунда ук үзенә каршы килеп, Ф.Сафинның "Саташып аткан

таң" ында нигездә җитешсезлекләрне генә күрә. Һәрхәлдә романга ясалган анализ шундый фикер калдыра. Икенче урында Т.Миңнуллинның "Илгизәр плюс Вера", "Шәҗәрә" ләре артында нинди матур кыланышлы мәкер ятканын ачарга кирәклекне искәртә. Тәнкыйтьче бик нык ялгыша: Т.Миңнуллин пьесаларында бернинди дә мәкер юк. "Илгизәр плюс Вера" ның төп идеясе нәкъ менә милли тамырлардан аерылуга китерүче катнаш никахларның еш кына бәхетсезлек, ятимлек, ялгызлык, хәтта фаҗига белән тәмамлануын ачуга кайтып кала. Г.Исхакыйның "Көз", "Ул әле өйләнмәгән иде", Ф.Әмирханның "Хәят", Ш.Камалның "Акчарлаклар", Ә.Еникинең "Әйтелмәгән васыять" кебек әсәрләргә бирелгән бәя дә, йомшак итеп әйткәндә, гаҗәпләнү уятты. Бер генә мисал белән чикләнәм. "Көз" повесте эчкечелекне, күңел ачуны якламый, әсәрнең төп идеясе рухи тамырларыннан аерылган кешенең йомшаклыгын һәм, киресенчә, милли яшәү рәвеше кешедә горурлык, өмет, көрәш сыйфатлары тәрбияли дигәнне раслауда. Мәктәп укучыларында милли үзаң тәрбияләүдә "Көз" повесте – иң уңышлы әсәрләрнең берсе.

Тагын бер мәсьәләгә тукталып үтмичә булдыра алмыйм. Бу – XX йөз башы әдәби һәм иҗтимагый фикеренә караш. Р.Зарипов "әдәбиятта катнаш никахны яклауның, дингә, динчеләргә каршы көрәшнең башында XX гасыр башы демократик язучылары торды" дигән фикерне яклый. Дөрес, ул әлеге демократларны атамый, әмма без сезнең белән аларны яхшы беләбез: Тукай, Исхакый, Әмирхан, Рәмиев, Ибраһимов һ.б. Р.Фәтхрахмановның да элегрәк язылган мәкаләләрендә С.Рәмиевне алласызлык-дәһрилек шагыйре дигәне хәтердә. А.Хәлим дә "унтугызынчы гасыр азагы – егерменче гасыр башында татар милләтенең идеологлары катастрофага тиң ялгыш җибәрделәр",- дип яза. Ф.Бәйрәмованың да шуңа якын фикерләре "Мәдәни җомга" битләрендә чагылыш тапкан иде. Без инде яңадан Тукайлар буынына кизәнә башладыкмыни? Җәмәгать, җәдитчелекне хурлау, тамгалау тарихта булды бит инде. Ашыгыч нәтиҗәләр ясамаска иде. Әдипләр иҗатында чагылган рус яшәешеннән үрнәк алу, аерым руханиларны тәнкыйтьләү, хатын-кыз иреген яклау һ.б. фикер-карашларны чор мохите, җәмгыятьтәге шартлар белән тыгыз бәйләнештә генә дөрес аңлап була. Мисал өчен, үзе дә танылган хәзрәт улы булган Ф.Әмирханны "Хәят" яисә "Фәтхулла хәзрәт" е өчен ничек инде динсезлектә гаепләргә мөмкин?

Чынлап та, дискуссия әдәби тәнкыйтькә билгеле бер җанлану алып килде. Шулай да күпсанлы мәкаләләр белән танышканнан соң бер үзенчәлек-кимчелек калкып чыга. Без әсәргә бәя биргәндә һаман да тема-проблема-идея яссылыгында калабыз. Әсәрләр төрле булган кебек, аларның сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен ачу юллары да төрле булырга тиеш.

Бүгенге татар әдәби тәнкыйтенең нигезен тәшкил иткән язмаларны өйрәнү түбәндәге нәтиҗәләргә китерә: 1) тәнкыйтебездә билгеле бер җанлану сизелә башлады. Үз стильләре, әдәбиятны аңлау һәм эчке хасиятләрен билгеләүдә кызыклы алым-билгеләре белән аерылып торучы тәнкыйтьчеләр бар дип әйтә алабыз. Шактый яңа исемнәр пәйда булу да уңай күренеш; 2) тәнкыйтьтә тәнкыйди рухның акрынлап булса да артуы күзәтелә, шул ук вакытта кат-кат искәртелгән, әйтелгән кимчелектән арына алмыйбыз - әдип иҗатына объектив һәм тулы бәя бирү, таләпчәнлек җитми. Аерым язмалар чын иҗатчы белән графоманны аерып кую кирәклеге турындагы фикерләр белән башлана да, язма авторы үзе үк уртакул әсәрне үтереп мактый башлый; 3) тәнкыйтьнең иң йомшак урыны – аналитик анализга нигезләнгән академик тәнкыйтьнең, ягъни әдәбияттагы төп тенденцияләрне, әдәби юнәлеш-агымнарны, стиль үзенчәлекләрен, әсәрләрдәге әхлакый-фәлсәфи һ.б. катламнарны эстетик планда ачып бирүнең аз булуында.

Әйтелгәннәргә нигезләнеп, тәнкыйтьне үстерү юнәлешендәге бурычларны болай билгеләп булыр иде: 1) тәнкыйть буенча эшләүче яшьләрне үстерү; моны уңай хәл итүнең юлын Язучылар берлеге белән югары уку йортларының татар факультетлары бергәләп эшләвендә күрәм; соңгы вакытта аларда тәрҗемә итү, редакцияләү һәм тәнкыйть белгечлекләре ачыла башлау моңа нигез булып тора ала; 2) тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләрнең җаваплылыгын, газета-журнал редакцияләренә тәнкыйть мәкаләләренә таләпчәнлекне арттыру; 3) тәнкыйтьнең эчтәлеге, вазыйфасы, тәнкыйтьченең иҗат лабораториясе белән танышу һ.б. җитди проблемаларга бәйле тәнкыйть секциясенең махсус утырышларын үткәрү; кайберләрен киң җәмәгатьчелеккә дискуссия өчен тәкъдим итү; 4) академик тәнкыйтьне үстерү, ягъни аның

теоретик табышлар белән кушылып, үрелеп үсүенә ирешү; аерым жанрлардагы табышюгалтулар яисә аларның үзара тәэсир итешүе, шулай ук төрле стильләрнең үзара керешеп китүе кебек күренешләр игътибар үзәгенә чыгарга тиеш.

З.Мансуров И.Нуруллин турындагы бер язмасында әлеге олы тәнкыйтьченең фикерләрен китерә: "Тәнкыйть, сәнгать буларак, каләм иясеннән илһамлану таләп итә, ә фән буларак, ул объективлык һәм төгәллек кысаларыннан чыкмаска тиеш". Әлеге фикер тәнкыйть өлкәсендә эшләүчеләрнең иҗат принцибы булсын иде дигән теләктә калам.

**Кыям Миңлебаев**

## ТӘРҖЕМӘ—СӘНГАТЬ УЛ!

XX йөзнең урталарында бездә әдәби тәрҗемә эше юлга салынды: сүзгә-сүз тәрҗемә итүгә дә, "ирекле" тәрҗемәгә дә чик куелды, эчтәлекне сөйләп чыгу урынына әсәрнең рухи байлыгын нәкъ оригиналдагыча гәүдәләндерү, автор теленә тиң дәрәҗәдә ана телендә язып чыгу таләбе куелды. Тәрҗемәгә университетта белем алган, зур укымышлы, эрудицияле яшьләр килде.

Тырыш хезмәт юлында танылган С. Әдһәмева, И. Гази, С. Фәйзуллин, А. Шамов кебек өлкәннәрдән фатиха алып, яшьләр җиң сызганып эшкә керештеләр. Көндез Татарстан китап нәшриятында, газета-журнал редакцияләрендә эшләсәләр, буш вакытларын фидакяр хезмәткә багышладылар. Җөмһүриятебездә милли мәктәпләр бере арты бере ябылган, мәдәният учаклары сүнгән, димәк ки телебезнең тамырына балта чапкан бер заманда әлеге яшьләр ана теленең булган байлыгын саклап калу, кадерен белү, аның музыкаль яңгырашына игътибарны юнәлтүдәй изге юлга бастылар. Әнә шул яшьләрнең фидакяр хезмәте нәтиҗәсендә татар укучысы ярты гасыр дәвамында саф ана телендә язылгандай иҗади тәрҗемәләрне үз телебездә уку бәхетенә ирешә. Менә алар: В. Шишковның "Хәсрәт дәрьясы" романы (ике томнан торган әлеге әсәрне шушы юллар авторы тәрҗемә итте); И. Гончаровның "Гыйбрәтле язмыш" романы (Ф. Гайнанова тәрҗемәсе); И. Тургеневның "Аучы язмалары" (В. Зыятдинов тәрҗемәсе); А. Купринның "Хикәя һәм повестьлары" (Р. Даутов тәрҗемәсе); В. Астафьевның "Патша-балык" романы (Т. Нурмөхәммәтов тәрҗемәсе); А. Дюманың "Өч мушкетер" романы (Я. Халитов тәрҗемәсе); Ә. Мохтарның "Чинар" романы (Л. Хәмидуллин тәрҗемәсе); А. Мифтахетдиновның "Кит эше" дигән китабы (Ә. Хәсәнов тәрҗемәсе); А. Чехов "Хикәяләр"е (С. Ибраһимова тәрҗемәсе); Г. Шәриированың "Гафуровлар гаиләсе" романы (М. Харисов тәрҗемәсе); Н. Думбадзеның "Мәңгелек канун" романы (Н. Вәлитова тәрҗемәсе); К. Паустовскийның "Яңгырлы иртә" җыентыгы (Ф. Зыятдинова тәрҗемәсе); Л. Толстойның "Хаҗи Морат" повесте (Л. Гыйззәтуллина тәрҗемәсе) һ. б.

Әдәби тәрҗемә мәктәбе әһелләре камиллек дәрәҗәсенә җиткереп ана телендә язып чыккан йөзләрчә китап милли әдәбиятыбызны әйтеп бетергесез баетты, ана теленә кадер-хөрмәтне арттырды, укучыларыбызның зәвыгын күтәрде. Әнә шуларны искә алып, әдәби тәрҗемә мәктәбенең рухи байлыгыбызга керткән өлешен "Алтын дәвер" дип бәяләү дөрес булыр.

90 нчы еллар башында Татарстан Фәннәр Академиясе энциклопедия чыгару максатын күтәрде. Русча бер генә томлы сүзлек әзерләнә башлагач, Академиянең Президенты, ТЭИ директоры М. Х. Хәсәнов ошбу юлларның авторын эшкә дәшә—тәрҗемә бүлеге әнә шулай оеша.

...Ә бүгенге көндә тәрҗемәгә битарафлык хөкем сөрә. Сүздә тәрҗемәгә дә, тәрҗемәчеләргә дә беркем каршы түгел, дөнья киң, тик син тәрҗемә әсәрен китап итеп чыгарырга хыялланма!

Әнә шул сәбәпле әдәби тәрҗемә осталары Фәния, Вакыйф, Яхъя кордашларымның юбилеенә бернинди игътибар да, юбилей китапларын чыгаручы да булмады…

Ике корылтай арасында остаханәбездә өметле вә каләмле яшьләрне үз һөнәребезгә өйрәтү игътибар үзәгендә булды. Аларны гадирәк шигырь вә хикәяләрдән башлатып, ашыкмыйча гына катлауландыра бардык, башкарган эшләрен уртага салып тикшердек, бергә-бергә киңәшләштек, яшьләрнең тәрҗемәләре кычкырып уку дәрәҗәсенә җиткәнче камилләштерелде.

Әле ярый, "Мәгариф" нәшрияты икетеллелекне сүздә генә түгел, бәлки эштә дә алга этәрә һәм әледән-әле үз авторларыбызның әсәрләрен оригиналы белән бергә тәрҗемәдә җөмһүриятебез укучыларына тәкъдим итә.

Бүтән нәшриятларның исә тәрҗемәдән котлары алына…

"Татмедиа" хезмәткәрләре белән киңәшләшеп, остаханәбездә перспектив план төзегән идек, ул планны корылтай карамагына да тапшырдык. Әдәби тәрҗемә өлкәсендә армый-талмый иҗат итүчеләргә—яшенә дә, картына да—игътибар кирәклеген һәммә кеше аңласын дип чаң сугабыз, бигайбә!

**Дамир Шакиров,**

**Татарстан китап нәшрияты директоры**

## КИТАП ГАМЕ—ОЛЫ ГАМЬ

"Китаплы өйдә нур булыр",—дигәннәр борынгылар. Әлегә кадәр безнең халкыбыз китаплы булды, аның күңеленнән нур китмәде. Моның өчен без бер яктан зур әдәби хәзинә туплауда армый-талмый эшләгән язучыларыбызга бурычлы булсак, икенче яктан, шушы әдәби байлыкны нәшер итеп, укучыга җиткерүгә мөмкинлек тудырган Республика җитәкчелегенә олы рәхмәтебезне әйтергә тиешбез.

…Язучыларыбызның әсәрләрен бастыруга Татарстан китап нәшрияты да зур өлеш кертә. Язучыларның ике съезды арасында узган өч ел вакыт эчендә 246 исемдәге китап дөнья күрде. Китапларның тышкы бизәлеше дә, эчтәлеге дә елдан-ел яхшыра бара. Монысы әйбәт. Ләкин мине бирегә күңелдә йөргән борчулы уйларны уртаклашасы килү теләге алып чыкты.

Иң борчыганы, әлбәттә, китап тарату мәсьәләсе. Китапны язу, бастыру белән генә эш бетми, аны укучысына җиткерергә дә кирәк. Элекке китап сәүдәсе системасының җимерелүе китап таратуны гаять дәрәҗәдә кыенлаштырды. Районнарда китап кибетләре калмады.

Базар чоры дип аталган бу чорга кергәч, китапның асыл кыйммәтен, олылыгын онытып, аңа товар дип кенә карау өстенлек ала башлады. Ләкин эш китапны сатуга килеп җиткәч, нигәдер аның товар булуы да онытыла. Икмәк, кием-салым кебек товарлар янында кибет киштәсендә китапка урын табылмый. Туфракка сеңгән яңгыр суы кебек, китап халыкка үзе сеңәргә тиеш микәнни соң?

Район җитәкчеләре ит, сөт җитештерү, иген уңышы белән бергә халыкның рухи азык белән тәэмин ителешен дә кайгыртырга тиеш иде кебек. Бигрәк тә татар авылы өстендә рухсызлык, әхлаксызлык болыты куерып, яшьләр заманның барча яман чирләрен үзләштереп ятканда. Ләкин китап районнарның күпчелегенә юл таба алмый. Мөслим, Актаныш, Сарман кебек районнар узган елда бер генә китап та алмаганнар.

Мондый шартларда Татарстан китап нәшрияты, билгеле инде, заказ үтәүче, текстны китапка әйләндерүче генә булып кала алмый. Ул китап сату эшенә дә ныклап кереп бара. Язучылар берлеге дә үз эш рәвешенә беркадәр төзәтмәләр кертергә тиештер дип уйлыйм. Әлегәчә аның китапны рекламалау, пропагандалау белән чынчынлап шөгыльләнгәне булмады. Радио-телевидение һәм вакытлы матбугатның мөмкинлекләре бик аз файдаланыла. Китап укучылар белән районнарда, башка

төбәкләрдәге очрашулар да китаптан башка гына үтә килә. Бәлки, берлекнең пропаганда бүлеге эшен үзгәртеп корырга кирәктер? Бүлекнең мөмкинлекләрен арттырып, китапны тарату белән дә шөгыльләнә алырлык итеп?

Язучылар үзләре дә кулларына автор нөсхәләре керү белән тынычланмасыннар иде. Калган нөсхәләр складта ята бирсә, бу кысыр куаныч кына була лабаса. Һәр әдип үз укучысын тәрбияләргә, аңа төрлечә юл ярырга тиештер. Мисаллары бар: Мөсәгыйт Хәбибуллин, Резеда Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова очрашулардан кайтып кермиләр, аларның китаплары да әйбәт тарала.

Аннан, укучыларның яшәешне бүтәнчәрәк күзаллый торган яңа буыны да барлыкка килде бит. Аның күңеленә дә ачкыч табасы, иҗади эзләнүләрне арттыра төшәсе иде.

Китап гаме—олы гамь. Ул халкыбызның уртак гаменә әйләнсен иде.

## Равил Фәйзуллин

# КИЛӘЧӘК ӨЧЕН ЭШЛӘРГӘ ТИЕШБЕЗ

Язучылык эшен язмыш дип кабул итеп, кырык елдан артык татар әдәби хәрәкәтенең үзәгендә кайнаган каләм иясе буларак, табигый, үткәннәргә таянып, бүгенге вәзгыять һәм киләчәк турында уй-фикерләрем күп. Кайберләрен үткән 2004 елда чыккан “Гыйбрәтләр алырлык үткән юл” дигән китабымда бәян иткән идем инде. Корылтай трибунасыннан әйтергә ниятләгән бу кыска чыгышым ике өлештән булыр: берсе—Кабул итү коллегиясе эше турында, икенчесе—“Казан утлары” журналы хакында.

Иҗади союзлар, ягъни берлекләр төзелгәннән бирле хәзергәчә кадәр яшәп килгән нигез-принцип: яшь буын әдипләрне тәрбияләп үстерү—язучылар оешмасының иң төп бурычларының берсе. Үткән гасырның 30 нчы елларыннан башлап бу принцип нык сакланды. Традиция бүген дә дәвам итә. Әмма хәзер—күбрәк инерция буенча. Сәбәпләре җитәрлек. Шуларның берсе—әлегәчә Россиядә иҗат оешмалары турында закон-канун булмавы. Без—иҗтимагый оешмалар статусында бүген. СССР вакытындагы кебек дәүләт структурасында ныклы материал базасы булмагач, иҗат оешмаларына “кем, кайда, ничек булдыра ала” ысулы белән эшләргә туры килә. Россиядә Язучылар союзы карамагындагы нәшриятлар, басмаханәләр, газета-журналлар бетте диярлек. Ни кадрлар сәясәтендә, ни нәшрият эшендә, ни тәрҗемә өлкәсендә үзәкләштерелгән тәртип-система юк. Әгәр язучылык хезмәте иҗтимагый фикернең бер мөһим өлеше, тәрбия чарасы икән, ягъни идеология икән—анда анархия булырга тиеш түгел. Мантыйк буенча, ил язучыларын берләштерергә тиешле Мәскәүнең үзендәге әдәби мохитне аңлау кыен: таркаулык, төрле мәсләктәге оешмалар, төркемнәр... Шуңа күрә, яшь һәм башлап язучыларны оешмага әгъза итеп кабул итү эшендә дә илкүләм уртак нормативлар юк (дөнья әдәбияты тарихы күзлегеннән караганда, андый кануни кагыйдәләр, әлбәттә, ясалма күренә). Безнең Коллегия корылтай сайлаган Идарә тарафыннан хупланган Устав кысаларында эш итте.

Өч ел эчендә 37 кешене Татарстан Язучылар оешмасына кабул иттек. Күпме? Бәлки, күбрәктер. Без эшкә каты таләпләр белән керешкән идек. Әмма заман һәр эшкә коррективалар кертә тора. Татар әдәбияты гомер-гомергә төрле төбәкләрдән чыккан каләм ияләре белән көчле булган. Беләсез, безгә Уралдан, Себердән, Урта Азиядән, Пенза, Астрахань якларыннан талантлар төркемләп килә торган заманнар үтте (Барып

кайткан кешеләр сөйлиләр: Такташ Сыркыдысында әдәби телдә юньләп сөйләшә белүче яшьләр бөтенләй юк ди, имеш). Шуна да халык язмышы мәнфәгатеннән чыгып эш итәргә, Татарстаннан читтә яшәүче каләмдәшләргә заманга хас ташламалар да ясарга туры килде. Корылтай делегатларына таратылган белешмәләр китабында әлеге кабул ителгәннәрнең исемлеген укып, аларның яшен һәм яшәү урыннарын белә аласыз. Теге яки бу кандидатураны тикшергәндә хокукый критерийлардан бигрәк, әхлакый-профессионал критерийлар өстенлек итте. Әйтик, әгъзалыкка кандидатның әдәби таланты, сәләте, ягъни профессионал әзерлеге бармы? Перспективалымы? Әдәбиятта яңа сүз әйтә аламы? Уртак милли идеягә хезмәт итәме? Иҗаты халкыбыз йөз тоткан сәясәт белән аваздашмы? Шәхес, гражданин буларак язучы-әдип исеменә лаекмы?

Гариза язучыларның күбесе өлкән яшьтәгеләр, фәнни исеме булган галимнәр, журналистлар... Яшьрәк дигәннәребезнең күпчелеге—кыз-кыркын. Дүрт кешенең гаризасын кире борырга туры килде, өч кешенең иҗатын яңа әсәрләре чыкканчыга кадәр кичектереп тордык. Коллегия составына абруйлы язучылар сайланган иде (Ә. Баян, Г. Зәйнашева, М. Хәбибуллин, В. Корчагин, М. Галиев, Н. Хисамов, Җ. Дәрзаман, Р. Зәйдулла, Г. Морат, Ш. Мостафин, Р. Фәйзуллин—рәис). Без вазифаларыбызга җитди карап, булдыра алган кадәр әдәбиятыбызның киләчәге өчен эшләргә тырыштык. “Таланты балкып торган фәлән яшь кешене нигә күрмәдегез, нигә оешмага кабул итмәдегез?” дип беркем әйтә алмас.

“Казан утлары” турында сүзем тагын да кыскарак булыр. Сезнең куллардагы белешмә китабында журналның соңгы өч елдагы эшчәнлеге турында шактый тулы мәгълүмат бар. Өстәвенә, ишетеп торасыз, тыңланган докладларда сүз, нигездә, безнең журналда басылган әсәрләр турында бара. Реаль факт хакыйкатьнең үзе инде ул. Чыннан да, “Казан утлары”сыз татар әдәби хәрәкәтен күз алдына китерү кыен. Читләрдән дә “Казан утлары”ның Россиядә иң абруйлы әдәби журналларның берсе икәнлеге турында еш ишетеп торабыз. Киләсе елның февралендә басмабызның 1000 нче саны дөнья күрәчәк. Без моны милли матбугатыбызның горурлык бәйрәме, әдәбиятыбыз бәйрәме итеп уздырырга ниятлибез. Безнең ниятебезне Республика җитәкчеләре хуплый, без моңа бик шат. Меңенче сан чыгу уңаеннан байтак конкрет эшләр планлаштырабыз: журналда чыккан иң яхшы әсәрләр антологиясен һәм фотоальбом чыгару, журналның тулы библиографиясен төзү, фәнни конференция үткәрү, милләттәшләребез күпләп яшәгән төбәкләрдә “Казан утлары” көннәре” дигән очрашулар оештыру h. б.

Адәм баласы алдында һәр заман үз проблемаларын тудырып тора. Бездә дә юк түгел алар. Шуларның берсе—журналның таралу-таратылу мәсьәләсе. Сер түгел, милли басмаларыбыз моннан егерме еллар элеккеге белән чагыштырганда күп мәртәбәләр кимеде һәм кимүен дәвам итә. Татарстаннан читтәге төбәкләрдә безнең матбугатка язылучылар ифрат дәрәҗәдә азайды. Сәбәпләре аңлашыла. Объектив дип әйтерлекләре дә бар. Шулай да, журналны тарату мөмкинлекләре, файдаланылмаган мөмкинлекләре бар дип исәплибез без. Әйтик, һәр мәктәп, һәр китапханә, һәр татар әдәбияты укытучысы язылган очракта гына да шактый түгәрәк сан килеп чыга. Кызганыч, моңа ирешә алган юк әле. Күп нәрсә җирле түрәләрнең үзаңыннан һәм мәсьәләне аңлавыннан тора. Фәкать югарыдан килгән фәрманны гына үтәргә өйрәнгән чиновниклар күп. Журналның иң күп өлеше Татарстанда тарала, аннан кала, табигый, Башкортстанда... Республиканың үзендә дә таралу рәвеше үтә чуар. Әйтик, Сабада, Балык Бистәсендә, Мамадышта 200-300 ләп таралса, Тау ягы районнарында—Кайбычта, Апаста—25-50. Бу хәл быел гына түгел, байтак еллардан килә. Нәтиҗә дә озак көттерми шул: әдәби журналлар таралмаган, укылмаган төбәкләрдән әдәбиятыбызга яшь алмаш та килми диярлек. Үзен татар дип исәпләгән (хәтта исәпләмәгән!) кеше өчен уйланырлык нәрсәләр җитәрлек. Традиция буенча журналны гамәлгә куючыларның берсе булып Татарстан Язучылар оешмасы санала. Әйе, соңгы елларда, чыннан да, санала гына шул. Асылда, журнал хөкүмәт тарафыннан (редакция керемнәре белән фәкать берничә генә сан чыгарып булыр иде) финанслана, редакция тарафыннан басмага әзерләнә. Реаль хәл шул. Без алга таба Язучылар берлеге җитәкчелегенең журнал файдасына актив эшчәнлеген күрергә теләр идек. Әлеге дә баягы журнал тиражын арттыруда, чын теләк булганда, Берлек байтак эшләр башкара алыр иде. Әдәби журналың булу язучы өчен зур бәхет ул. Синең бит яңа язган әсәреңне җиде-сигез мең данәдә көне-ае белән дигәндәй киң катлам укучыларга ирештерү

мөмкинлегең бар! Ә әсәреңне китап итеп чыгаруның, үзегез беләсез, юлы озын, чыккан очракта да кайчан укучысына барып ирешә әле...

Мин, шәхсән, безнең язучылар турында югары фикердә. Күбесен фидакяр затлар дип атар идем. Уртак ил байлыгын оятсызларча талау заманында, ярым-йорты тормыш алып барган хәлдә, кулга каләм алып, илһам табып, якты киләчәк турында язып кара әле! Димәк, иман безне ташламаган әле. Гомумән, язучыларыбызсыз милләтнең рухи үсешен күз алдына да китерү кыен.

P.S.: Сүзләр күп, вакыт аз. Вакыт димәктән, өч-дүрт елга бер җыела торган корылтайны ике көн уздырырга кирәктер. Беренче көнне докладлар тыңлап, кабаланмыйча фикер алышырга, проблемалар турында сөйләшергә; ә икенче көнне оештыру эшләре—сайлаулар, санаулар... Юкса инде ничәнче тапкыр съезд-корылтайдан өйләргә ярты төн узгач таралышабыз... Хәлебез экстремаль хәл дәрәҗәдә түгел ләбаса! 30 нчы елларда да, 50 нче елларда да, соңрак та язучылар үз җыеннарында берничә көн фикер алышырга җай тапканнар бит!

Соңгы Корылтайны алып баручыларның берсе буларак, җыелыш барышында тәфсиллерәк итеп сөйләргә әзерләнгән докладчыларга президиумнан "Вакытыгыз бетә!", "Регламентны саклыйк", "Тагын бер-ике минуттан тәмамлагыз!" кебек репликалар әйтергә мәҗбүр булынды (әлеге дә баягы шул каһәр регламент аркасында!) Хәзер исемә төшерәм дә, уңайсызлык кичерәм. "Без чыгарган бәет түгел, үпкәләмә Гайнетдин!" дигәндәй, бигайбә. Каләмдәшләргә исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телим.

**Айдар Хәлим**

## КӨРӘШТӘН ЧИТТӘ КАЛЫП...

...Рәсәй чынбарлыгы безне, кайчандыр горур, көрәшчел халыкны, көлкеле йорт куяны хәленә төшерде. Әгәр Татарстан хөкүмәте һәм парламенты 1990-99 елларда, күкрәк кага-кага, кыйнала-кыйнала мөстәкыйльлегебезне ныгыту буенча Указлар, карарлар кабул иткән булса, 2000—2005 елларда ул шулай ук күкрәген кага-кага шул мөстәкыйльлегебезне ныгыткан элеккеге Указларыбызны гамәлдән чыгару буенча яңа Указлар, карарлар кабул итеп утырды. Прокурор Кафил Әмиров образы колониаль тарихыбызда да сирәк күренеш. Аның үлемсез образын әдәбиятта калдыру—безнең бурыч. Путин вертикале Россия Федерациясенең милләтләр берлеге горизонталендә ныгыган булса да, безне кабер ягасына сузып салды... Без эндәшмәгәч, кара көчләр соңгы һөҗүмгә күчте. Элек "Сильные регионы—сильная Россия" дисәләр, бүген инде "Крупные регионы—сильная Россия" дип кенә җибәрәләр. Элек "Туган тел" дисәләр, хәзер безнең барлы-юклы мәктәпләребездә рус теленә "родной язык" статусы биреп, туган татар телен "региональный компонент"лыкка гына калдырып, гарьләнүнең иң түбән дәрәҗәсенә төшерделәр.

Рәсәй демократия юлыннан котырган шовинизм юлына борылып керде. Петр Беренче башлаган реформалар әле дә булса Рәсәй тамагында сөяк булып аркылы тора, чөнки гел басып алган, гел башкалар исәбенә яшәгән халык һәм аның гасаби җитәкчелеге белән демократик дәүләт төзү мөмкин түгел. Дөнья матбугаты язганча, бу җитәкчелек Рәсәйне милли мәсьәләдән "тәмам азат итү" хакына милләтләрне гамәлдән чыгару, мономилләтле-полициячел империя төзү эшенә кереште.

Шушы вәзгыятьтән чыгып караганда, бүгенге корылтайдагы хуш күңелле хисап доклады буш, мәгънәсез, купшы, аннан үлемтек одеколон сиптерелгән кәфенлек исе килә. Соңгы биш-алты ел эчендә Мәскәү Кремле Татарстан мөстәкыйльлеген юкка

чыгару өчен Татарстан Президентына, аның парламентына, хөкүмәтенә каршы көчле басым ясады, астыртын һәм ачык кампания алып барды. Мин, мәсәлән, Республика мәнфәгатьләрен яклап, бу басымга каршы шәхсән Путинның үзенә генә дә берничә дистә телеграмма һәм хат юлладым. Кызганычка каршы, Татарстан Язучылар берлеге җитәкчелеге Татарстан хөкүмәте алып барган бу авыр сәяси көрәштә катнашмады, язучыларны бу көрәшкә тупламады, купшы идарә утырышлары, юбилей кичәләрендә чәчкә тапшыру, "рәхмәт-рәхмәт" хатлары уку, тостлар әйтү белән мәшгуль булды. Ни үкенеч, соңгы алты елда берлек җитәкчелеге Татарстан суверенитетын яклау буенча бер генә белдерү ясамады, бер генә сәяси акция да үткәрмәде. Халык мәнфәгатьләре өчен көрәшергә тиешле язучылар оешмасы штабы, "Без сәяси оешма түгел", дип, халык мәнфәгатьләренең ничек, нинди юллар белән сатылуын читтән генә карап торды. Нәтиҗәдә Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары суверенитетны ныгытучылар һәм суверенитетны җимерүчеләр турында игътибарга лаек бер генә әсәр дә тудыра алмады. Шулай итеп, бүгенге заман әдәбиятындагы геройсызлык күренешен Язучылар берлеге үзе үк тәрбияли... Мин Язучылар берлеге җитәкчелегенең эшеннән кискен канәгать түгелмен...

Безгә хәзер килеп туган шартларда бу тармакларны ары таба саклап калу гына түгел, көннән-көн кәчәя барган кыргый базар, Госдума парталары артыннан шовинистик жириновщина котырган шартларда аларның эшен тагын да тирәнәйтү, камилләштерү турында уйларга кирәк. Болар булса—милләт булачак, болар булмаса—милләт булмаячак. Безгә нишләргә? Беренче. Рәсәй хөкүмәте милли мәгарифне буу һәм Рәсәйне милли проблемалардан арындыру өчен "единый государственный экзамен" дигән бик әшәке, мәкерле закон уйлап чыгарды. Әйтик, Татарстан мәктәбенең төрле милләт балалары татар сөтен-суын эчеп, татар ипиен ашап, татар һавасын сулап, татар җирен чүпләп укыйлар, тик аларны туендырган, киендергән татар халкының теле һәм әдәбияты буенча имтиханнар гына бирмиләр. Рәсәйнең яңа мәгариф министры бу хакта сөйләгәндә, "Без әле регионнарның фикерләрен көтәбез, әгәр аларда ЕГЭга каршылык көчле булса, без аны кабул да итмәбез" дигәнрәк фикер әйтте. Безнең Президент, безнең Премьер-Министр, безнең министр гына түгел, менә без, язучылар, милли мәктәбебезне саклап калу буенча теләкләребезне Рәсәй хөкүмәтенә җиткердекме? Безнең таләп бер: Татарстан кебек әйдәп барган республикада төп милләтнең туган теле һәм әдәбияты буенча имтихан ЕГЭ имтиханнары исемлегенә беренче булып кертелергә тиеш...

Рәсәйнең демократия юлыннан читкә борылуы булды, татарда һаман да шул бетмәс үләт кашынуы башланды: туган телдә укыту кирәкме? Имеш, аның "файдасы бармы?" Бу инде "Безгә кояш кирәкме?" дигән темага буш бәхәс кузгату була. Нишләп без моннан миллион ел элек ачылган аксиоманы гипотезага әйләндерәбез? "Балам урысча белми кала" дип укытуны бишектән үк русчага күчереп, сабыйларны яңадан татарчадан да, русчадан да надан калдыра, укыту урынына козгыннан чукыта башладык... Бөтен дөньяның халыкара документларында адәм баласында гражданлык шәхесен, патриотик тойгысын милли компонент—туган тел, туган мәдәнияттән башка тәрбияләү мөмкин түгел дип кырт кисеп әйтелә. Хәтта коточкыч саналган Сталин заманнарында, хәтта әллә кайдагы Хабаровски, Донбасстагы татар мәктәпләрендә дә татар баласы табигый рәвештә беренчедән дүртенчегә кадәр саф татар телендә укый, аннан соң гына рус телен өйрәнә башлый иде. Педагогикада шунысы билгеле: бала беренчедән дүртенче сыйныфларга кадәр туган телен никадәр камил белсә, бу шарт чит телне шул кадәр камил белү өчен юллар ача. Мин моны үземнән беләм. Безнең Мәгариф министрлыгы совет заманы спекулянтлары тарафыннан милләтләрне ассимиляцияләү өчен уйлап табылган "ата-ана теләге" дигән ясалма постулаттан котылырга тиеш... Әгәр без милли мәктәп дип аталган мәктәптә шушы шартны үти алмыйбыз икән, безгә туган телебездә китаплар чыгарып торуның да кирәге калмаячак. Татар җәмәгатьчелеге ярдәме белән Татарстан Мәгариф министрлыгы, Татарстан парламенты озын-озак сузмыйча, әллә кайчан эшләнергә тиешле бурычын үтәргә һәм Татарстан шартларында татар балаларын урта мәктәпнең беренче өч яки дүрт сыйныфында мәҗбүри рәвештә туган телдә укыту турындагы Законын кабул итәргә тиеш...

**Вахит Имамов**

## БЕЗ КЕМ ӨЧЕН ЯЗАБЫЗ?

Инде 20 ел буе демократия, сүз иреге дигәннәрен кичереп яшибез, авызыбызны томаламыйлар, сулышны иркен алабыз сыман тоела. Ни телисең—шул хакта яз, кайда телисең—шунда бар да китабыңны бастыр. Дөрес, күбесенчә яки үз кесәңнән, яки дус-туганнар аша тапкан акча хисабына. Бик тә елап һәм мүкәләп йөрсәң, китапны бастырып була-булуын. Ләкин аны кая илтәсең дә, ничек таратасың соң? Ул китапларны сату өчен сәүдә челтәре бармы да, безнең китапларны укучылар бармы?

Менә шушы хәлне ачыклар өчен дип мин фәкыйрегезгә республиканың берничә районын айкап чыгарга туры килде. Нәтиҗәдә шул беленде—Татарстан мәйданында хәзер китап сәүдәсе үлеп бара икән. 80–90 авылы булган дистәләгән районда бер генә китап кибете дә калмаган. Булган кибетләрне зур кесәле, йөнтәс куллы байлар алып бетергәннәр. Әйтик, 88 авылы булган Балык Бистәсендә 60 тан артык кибеткә шәхси кешеләр яисә оешмалар хуҗа. Билгеле ки, һәммәсенә табыш кирәк, алар аракы, сыра һәм башка төрле үтемле товар белән эш итеп кесә калынайтуны күпкә кулайрак саный һәм, сүз дә юк, алар безнең татар китабының язмышына төкереп кенә бирә.

Безнең китапларны мәгариф яки мәдәният системасы аша сатып алу буенча нәкъ шундый ук хәл. Аксубай, шул ук Балык Бистәсе, Кукмара, Мөслим, Зәй, Менделеевск, Минзәлә, Кайбыч, Чүпрәле, Әгерҗе, Ютазы районы хакимиятләрендәге мәгариф бүлекләренең авыл мәктәпләре өчен, мәдәният бүлекләренең авыл китапханәләре яки клублары өчен соңгы дүрт елда бер генә татар китабы сатып алганы юк. Алай гына да түгел, алдагы елга бюджет төзегән яки раслаган вакытта район депутатлары татар китапларын сатып алуны бюджет дигәненә бөтенләй дә кертеп азапланмый. Безнең Чаллы каласында да нәкъ шундый ук хәл һәм, һич шикләнмим, күршедәге Менделеевск, Алабуга, Зәй яки Минзәләдә дә шулайдыр ул. Чөнки соңгы 3-4 елда бюджет, ягъни шәһәр казнасы аша Чаллы мәктәпләре яки Чаллы китапханәләре өчен бер генә тиен дә акча бүлеп бирелмәгәнлеген мин төгәл беләм. Димәк, Татарстанның ким дигәндә ярты территориясенә татар китаплары ни кибетләр челтәре, ни җирле казна хисабына үтеп керми. Мәгариф министрлыгы бюджетына да авыл яки шәһәр мәктәпләре өчен матур әдәбият китаплары сатып алу, мәктәп китапханәләрендәге китап фондларын яңартып яки тулыландырып тору өчен бер тиен дә акча салынмаган. Димәк, без хәтта үзебезнең туган районнар, якташлар өчен дә тере килеш күмеп куела башлаган язучылар, шагыйрьләр булып чыгабыз лабаса!

Дөрес, безне: “Әнә, республиканың милли китапханәсе бюджетында яңа китаплар сатып алу өчен фондлар каралган бит”,—дип юатырга мөмкиннәр. Ләкин ул фондлар бик чикләнгән. Милли китапханә һәрбер язучы яки шагыйрьнең һәр китабын меңәр-меңәр данә итеп сатып ала алмый. Әгәр китапханә җитәкчеләре сез елап яки ялынып йөргән өчен сезнең кулыгыздан 200 яки 300 данә китап сатып ала икән, сүз дә юк, ул китаплар 2000 нән артык китапханәгә һичничек барып җитә алмый.

Мәсьәләгә тагын бер җәһәттән күз салыйк. Һичкемгә сер түгел, Татарстандагы татарларның ким дигәндә 50 проценты татар телен белми. Ә Татарстаннан читтә яшәүче татарларның туган телендә белем алу өчен бөтенләй мәктәбе юк. Шулай булгач, туган теленнән аерылган татарларыбыз бүгенге татар әдәбиятын бөтенләй дә белми. Туган теленнән аерылган булсалар да татар рухлы, татар җанлы итеп үстерү өчен татар китапларын рус теленә тәрҗемә итеп бастыру котылгысыз адым булып тора. Ләкин безнең бу өлкәдә дә җитди эшләр эшләп караган юк. Гариф Ахунов СССР Язучылар берлеге секретаре һәм СССР Югары Советы депутаты булган чакта аның тырышлыгы һәм аның танышлыгы белән йөздән артык татар китабы рус телендә дөнья күргән иде дә, Гариф абый властьтан китүгә үк бу эшчәнлек үлде. Соңгы 15-20 елда бер генә татар романының, повестының, поэмасының рус телендә басылып

чыкканы юк. Шуңа күрә без Чуашстанга, Удмуртиягә, Перьмга татар әдәбияты көннәре үткәрергә дип барган чакта шушы ут күршеләребез дә безнеңниндирәк язучылар икәнлекне аера алмадылар, ягъни без хәтта күршеләр белән дә бер-беребезнең кем икәнлегебезне белмичә яшибез. Мин кайсы да булса олы-дәү җитәкченең соңгы 20 елда кайсы да булса язучының китабын рус теленә тәрҗемә иттергәнен һәм шуның өчен акча бирүен белмим. Үзебезнең шәһәр башлыгы Илдар Халиков кына күркәм башлангыч күрсәтте һәм мин фәкыйрегезнең Казан каласы нигезләнүгә багышланган "Казан дастаны" романын тәрҗемә һәм нәшер иттерде. Аңа рәхмәт, һәм аның үрнәгенә иярүче җитәкчеләр яңадан табылырмы?

## Зөфәр Дәүләтов

# АДЫМНАРЫБЫЗ НЫК ӘЛЕ

Кырык ел элек барлыкка килгән Әлмәт язучылар оешмасы елъязмасында мондый юллар бар: "1955 елда әдәби түгәрәк эшли башлагач, Казаннан килгән өлкән әдипләребез: "Әгәр дә бу түгәрәккә йөрүчеләрдән берәрсе Язучылар союзына кабул ителсә, ул үзенең бурычын үтәде дип санар идек". Шушы еллар эчендә Әлмәт оешмасында 56 язучы әгъза булып торды. Алар барысы да диярлек әдәби түгәрәктә үсеп, канат чыгарып, чыныгып, Язучылар союзының әгъзалары булдылар. Димәк, бурыч 56 тапкыр арттырып үтәлгән дигән сүз.

Бүгенге көндә җиде административ районны үз эченә алган Әлмәт язучылар оешмасында 18 каләм иясе бар. Ике съезд арасында 3 каләмдәшебез берлеккә кабул ителде. Язучыларыбызның уртача яше 50 гә якын. Иң өлкән язучыбыз Әдип ага Маликовка 84 нче яшь, иң яшенә—38.

Бу чорда Әлмәт оешмасы язучыларының "Рухият" нәшриятында—15, Татарстан китап нәшриятында һәм "Матбугат йорты"нда 7 китабы дөнья күргән. Моннан тыш республиканың саллы журналларында басылган әсәрләр дә шактый. Минемчә, 42 нче яшенә атлаган Әлмәт оешмасы өчен бу бик тә табигый.

Нефть төбәге халкы талантлы. Укучы яратып укырдай әсәрләр тудырырга дип йөрибез. Тик утырган юк. Ә менә оешма картая. Яшьләрнең җитди әдәбиятка аз килүе безне борчый. Ләкин бу бит ил белән шулай.

Әйе, бездә татар әдәбиятының йөзек кашы саналырдай әдипләр бар. Күптән түгел генә өлкән язучыбыз Әдип Маликовның "Җуелмас хәтер" дигән шигырьләр җыентыгы табадан төште. Фронтовик шагыйрьнең бу китабы укучыларга нефтьчеләрдән Бөек Җиңүнең 60 еллыгы уңае белән зур бүләк дип кабул ителде.

Шулай да мин Мөслимдә яшәүче Ф. Садриевның "Бәхетсезләр бәхете" дигән романын бүлек язучылары иҗат иткәннәр арасында иң җитди әсәр дип бәяләр идем. Торгынлык чоры шартларындагы шәхес драматизмы бу романда шулкадәр тирән бирелгән ки, авторның психология остасы булуына, сурәтләү чараларының уңышлы һәм урынлы кулланылуына сокланырга гына кала. Минем Ф. Садриевны телгә алуым очраклы түгел. Шушы талантлы әдибебез, әгәр дә Казанның үзендә яшәсә һәм бераз әрсезрәк тә булса, язганнары да, үзе дә күптән тиешле бәясен алыр иде.

Каләмдәшләрем миңа корылтайда чыгыш ясауны йөкләгәндә, башкаладан читтәрәк яшәүче әдипләргә идарә җитәкчелеге тарафыннан игътибарның җитәрлек булмавын басым ясап әйтергә куштылар.

Игътибар җитмәү нәрсәдә чагыла соң? Әлбәттә, юбилейлар уздырганда Казаннан вәкилләр, идарә рәисе һәм аның урынбасарлары катнашмый дию гадел булмас иде. Мондый чараларның алар катнашында үтүе дәрәҗә өсти. Ләкин бит тормыш тантаналардан гына тормый. Игътибар көн дә кирәк.

Бүген республикада төрле премияләр һәм мактаулы исемнәр шактый. Ә шуларның

ник берсен 40 елдан артык тарихы булган һәм Татарстан язучыларының 6 процентын тәшкил иткән Әлмәт язучыларына бирмәскә? Әдәбият аксакалы, төбәкнең бердәнбер Тукай бүләге иясе, халык шагыйре Гамил Афзалның вафатына да тиздән ике ел тула бит! Бәлки бездә лаеклылар юктыр? Мин моның белән килешмәс идем. Соңгы өч елда 4 китап чыгарган шагыйрә К. Булатова алдында баш имәслекме? Тирән фәлсәфәгә ия шигырьләр авторы И. Гыйләҗев начар язамы? Кытай теледә 1 миллион тираж белән китабы чыккан А. Хәсәнов иҗаты хакында да җитди сүз алып барырга вакыт. Үзе шагыйрь, үзе тарихчы галим Д. Гарифуллин хезмәтләре тиешенчә бәяләнәме? Өлкән шагыйрәбез Э. Мөэминованың сәләтенә дә күз тимәсен! Мөслимдә тагын бер актив язучыбыз—Мөҗәһит Әхмәтҗанов бар. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрь, прозаик Н. Әхмәдиевнең республикада уздырылган "Ел китабы" конкурсында 2003 ел нәтиҗәләре буенча җиңүчеләр исемлегенә кертелүе шулай ук игътибарга лаек түгелмени? Соңгы елларда гына ул "Рухият" нәшриятында дүрттомлыгын чыгарды.

Күптән түгел генә язучылар сафына килеп кушылган язучы Әсгать Салах 2002, 2003, 2005 елларда "Казан утлары" журналында өч повесть бастырып, үзенчәлекле рекорд куйды. Аның "Соңгы вальс" дип аталганы Чернобыль фаҗигасенә багышлануы белән бигрәк тә әһәмиятле. Хәзерге прозада бу темага язылган бердәнбер әсәр ул.

Үзәктән читтә яшәүче язучыларның җанын иң әрнеткәне—оешмага тиешле финанс ярдәме булмау. Штаттагы ике кешегә бирелгән хезмәт хакы да дүрт мең сум гына. Телефон, почта, аренда һ. б. көндәлек чыгымнар өчен дә сметада акча каралмау—искиткеч зур гаделсезлек. Оешманы ничек кенә булса да саклап калу өчен миңа хәер сорашырга кала. Рәхмәт "Татнефть" җитәкчелегенә, Әлмәт хакимиятенә—ләкин бит көн саен сорап кергәнне берәү дә яратмый... Гарьләндерә дә...

Эшсезләр өчен пособие каралган, ә 18 язучыдан торган оешма язмыш иркенә ыргытылган. Җаваплы секретарь буларак, мин Казанга—ай саен уза торган идарә утырышларына да—үз акчама йөрим.

Съездда җитәкчеләр дә катнашуын искә алып, кабатлап әйтәм: болай ярамый! Акча булмагач, яшь талантлар белән җитдирәк эшләү мөмкинлеге дә үзеннән-үзе чикләнә. Яңа сайланасы идарә һәм аның рәисе моны истә тотсын: Әлмәт һәм Чаллы бүлекләренең тамырларына балта чапмаска иде. 60-70 нче елларда беренче чирканчык алып Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Гамил Афзаллар үстергән оешма бу!

Безнең төп эшебез—иҗат! Бүгенге тормышны, үзебезгә якын булган нефтьчеләр, игенчеләр тормышын тирәннән өйрәнеп яхшыдан-яхшы әсәрләр язу. Укучы бездән замандашлар турында мавыгып укырдай, киң масштаблы, вакыйга булырлык әсәрләр көтә. Ватанга мәхәббәтне лирик геройның тирән кичерешләре аша күрсәтеп бирергә, тормыш ямен, кадерен белергә өйрәтә торган әсәрләр тудырырга тиешбез! Әдәбиятыбызның Әмирханы булырга кирәк! Ләкин андый әсәрләр аз туа. Җан шуңа борчулы...

## Мансур Вәли-Барҗылы

Бу корылтаебыз резолюциясенә кертү өчен минем ике тәкъдимем бар.

Беренчесе. Ул республикабыз халкының, бигрәк тә яшь буынның, тормышына, киләчәк язмышына кагыла. Соңгы елларда без матбугат битләрендә дә, төрле җыелышларда да, җинаятьчелекнең, эчкечелекнең бик нык артуына зарланабыз. Моңа күпсанлы мисаллар китерәбез. Телевизор экраннары да җинаятьчелек, бандитизм күренешләре белән тулган. Ә нигә соң без республика халкын, бигрәк тә яшь буынны тәрбияләү эшен башлап җибәрмибез?! Бигрәк тә рухи һәм әхлакый тәрбияне? Моны бит капитализм шартларында яшәү белән генә аклап булмый. Чөнки капитализмның төп принциплары: ертлачлык, матди керем турында гына уйлау, рухилыкны санга сукмау—болар аерым шәхесне дә, тулаем җәмгыятьне дә, һәм барлык кешелек дөньясын да күп санлы конфликтларга илтә, ахыр чиктә тупикка китерә.

Ә нигә безгә үзебезнең республикада "Халыкны рухи-әхлакый тәрбияләү" программасын төземәскә һәм аны дәүләт күләмендәге мөһим эш итеп башлап җибәрмәскә?!

Әйдәгез, бу корылтайдан соң бик тиз арада без үзебезнең иҗат берлегебез исеменнән Татарстан Дәүләт Советына әнә шул хакта мөрәҗәгать белән чыгыйк.

Әгәр дә андый программа кабул ителсә, ул чагында республикабызның барлык рухи-интеллектуаль, иҗади көчләре системалы эшкә тартылыр иде. Шушы программаның бер состав өлеше буларак, китап тарату эше дә җайга салыначак. Китап хәзерге тормышта үз урынын табачак.

Икенче тәкъдим.

1970-1980 елларда безнең Язучылар берлегендә шундый бер әйбәт эш: зур күләмле әдәби әсәр язу өчен берничә әдипкә иҗат периоды бирү, ягъни берничә язучыны бер ел яшәрлек акча белән тәэмин итү бар иде. Ә хәзер исә язучыларыбыз иң җитди һәм зур күләмле әсәрләрен дәүләт эшеннән бушагач, кичләрен һәм төнлә генә, ягъни йокы хисабына язарга мәҗбүр. Нәтиҗәдә, иҗат ителгән әсәрләрнең фәлсәфи һәм сәнгати ягы мөмкин булган дәрәҗәдә үк югары килеп чыкмый. Бу хәлне төзәтү өчен хөкүмәт ярдәме белән безнең оешмабыз, мисал өчен 4-5 әдипкә бер ел яшәрлек (якынча һәркайсына 50 шәр мең чамасы диик) ярдәм итә алса, ягъни иҗат периодына пособие бирсә—моның нәтиҗәсе бик тиз арада сизелер иде. Ә инде икенче елны, шулай итеп, тагын 4-5 әдипкә бирәсең. Ел саен 4-5 әр әдипкә барысы 200-250 мең чамасы пособие биреп бару безнең нефть чыгаручы республика өчен әллә ни зур сумма түгел.

## "КАЗАН УТЛАРЫ" ЖУРНАЛЫ

2002-2005 ЕЛЛАРГА ХИСАП

"Казан утлары"—сиксән елдан артык дәвердә 991 санда чыгып, татар халкының төп әдәби-мәдәни журналы булып килде һәм бүгенге көндә дә халык тарихын, аның рух хәзинәсен чагылдыруда шул олы миссияне үтәп килә. Үзенең төп мәслягенә һәм укучыларына тугрылык саклап, ватандарлык һәм халыклар дуслыгы идеяләрен раслап, талантлы әдипләребезнең иң яхшы яңа әсәрләрен күп меңнәр белән исәпләнгән укучыларыбызга җиткереп бара. Соңгы өч елда журналда басылган әсәрләрнең күбесе шуңа дәлил. Кайберләрен искә төшереп үтик. Роман-повестьлардан—А. Гыйләҗев ("Кылдан нечкә, кылычтан үткен"), Ф. Садриев ("Бәхетсезләр бәхете"), М. Хәбибуллин ("Айбиби"), Р. Мирхәйдәров ("Һәрнәрсәгә—акчалата", "Карга короле"), Ф. Сафин ("Саташып аткан таң"), М. Маликова ("Өермә", "Мендем биек тауларга"), К. Кәримов ("Ак бүрек", "Сакау күке"), З. Зәйнуллин ("Гарасатлы юллар"), Т. Галиуллин ("Төнге юллар"), М. Әмирханов ("Тояк эзе", "Мөкәррәмә"), К. Миңлебаев ("Акыллы атын мактар"), С. Поварисов ("Оҗмахка бер адым"), Х. Камалов ("Үкезләр"), Р. Сибат ("Инабәт"), К. Латыйп ("Әдрән диңгез") һ. б. Шигърият бүлегендә бүгенге поэзиябезнең күренекле вәкилләре—Г. Афзал, И. Юзеев, Ф. Яруллин, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Р. Әхмәтҗанов, Ә. Баян, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Р. Миңнуллин, Л. Шагыйрьҗан, Р. Мингалим, З. Мансуров, Х. Әюп, Н. Гамбәр, Ф. Гыйззәтуллина, Р. Зәйдулла, М. Галиев, Г. Морат, Э. Шәрифуллина, Ш. Гаделша һәм башкаларның шигырь цикллары һәм поэмалары басылып чыкты. Драма әсәрләреннән Батулла ("Җимерелгән бәхет"), Зөлфәт Хәким ("Телсез күке"), Н. Фәттах ("Сармат кызы Сәринә"), Г. Зәйнашева ("Нәрсә булды безгә?"), Д. Салихов ("Мөгезле Мәүлихан"), Р. Мингалим ("Дүрт кешелек утыргыч") пьесалары дөнья күрде. Публицистикада Ф. Латыйфи, М. Зарипов, Н. Гариф, М. Абдуллин, М. Әхмәтҗановларның хезмәтләре чыкты. А. Хәлимнең "Яңа сагыш китабы", Ф. Гарипованың "Сан алудагы сырт санау" дип исемләнгән мәкаләләренең 2002 елдагы халык саны алу чорында басылып чыгуы аерым бер әһәмияткә ия булды.



Соңгы бу елларны тарихи юбилейлар еллары дип тә әйтеп буладыр. Әлбәттә, алар журнал битләрендә киң яктыртылды. Казанның мең еллыгына багышланган мәкаләләр (Ә. Мөхәммәди— "Казан шәһәренең барлыкка килүе һәм аның борынгы исемнәре", Р. Солтанов—"Ханлык чорында Болак аръягы Казаны", "Ханлык чорында Казан шәһәренең фортификациясе", Ф. Миңнегани— "Казан урамнары ни сөйли?"...); Казан университетының 200 еллыгы уңаеннан чыккан материаллар (С. Михайлова— "Россия халыкларының милли мирасы", "Казан университетының Идел буе һәм Урал төбәге халыкларының мәдәни һәм иҗтимагый тормышында тоткан урыны", Х. Миңнегулов—"Гыйлем-мәгърифәт мәркәзе"); "Казан утлары"ның 80 еллыгы уңаеннан (М. Шәймиев, Н. Мириханов, Ф. Яруллин, Ә. Фәтхетдинов, Ф. Сибагатуллин, И. Әхмәтҗанов, А. Арсланов, Р. Мостафин, Ш. Закиров һәм башкаларның котлаулары, теләк-фикерләре); Татарстан Язучылар берлегенең 70 еллыгына багышлап язылган хезмәтләр (Р. Фәйзуллин—"Гыйбрәтләр алырлык үткән юл", Л. Хәмидуллин— "СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге")... Шуларга өстәп, классик әдипләрнең һәм бүгенге исән язучыларның юбилейлары... Алар күп дистәләр белән исәпләнә.

Журнал әледән-әле әдәби тормышыбызның актуаль проблемаларына багышлап бәхәс-дискуссияләр үткәреп килә.

Соңгысы "Безнең заман герое" дип атала. 2004 елның башыннан башланган бу эшлекле сөйләшү әлегәчә дәвам итә. Фәкать сүз ирегe булганда гына мөмкин мондый бәхәс-дискуссиядә егермедән артык каләмдәшебез катнашты инде.

Моңарчы укучылар күңеленә хуш килгән күркәм традицияләрне дәвам итү белән бергә, яңа рубрикалар да ачылды: "Заман һәм шәхес", "Мөхәррир сүзе", "Тел дәрьясы тирәндер", "Хәтер", "Милләттәшләребез чит илләрдә", "Үткен мәсьәлә"... Шулай ук, бу өч ел эчендә "Татар хикәяләре хәзинәсеннән", "Әдәбиятлар дуслыгы— халыклар дуслыгы", "Дөнья әдәбиятыннан үрнәкләр" рубрикаларында байтак әсәрләр басылды. "Берлекнең яңа әгъзалары" дигәнендә, исеменнән үк күренгәнчә, Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителгән язучылар турында шактый ук тәфсилле мәгълүмат биреп барыла. "Яңа исемнәр" рубрикасында әдәбиятка яңа килгән, әмма әсәрләре белән хәзинәбезне баетырга өметләндергән яшь авторлар М. Кәбиров ("Сары йортлар сере"), Р. Габделхакова ("Сират күпере"), Л. Шәех (шигырьләр циклы) әсәрләре басылды.

Журнал, әхлакый яктан тәрбияви әһәмиятен истә тотып, дин тәгълимате турында әтрафлы хезмәтләр белән таныштыруны дәвам итеп килә. Үткән ел Коръән Кәримнең татарчасы (тәрҗемәче—Р. Батулла) басылып бетте. Р. Хәкимнең "Кайда безнең кыйбла?" дигән фәнни-публицистик хезмәте дөнья күрде. Гомумән, фән, мәгариф, сәясәт темаларын яктырткан мәкаләләр байтак булды бу елларда (М. Госманов, М. Мәхмүтов, Ә. Борһанов, Х. Миңнегулов, М. Зәкиев, И. Таһиров, И. Хәлиуллин һ. б.)

Журнал—әдәби хәрәкәтнең үзгә бер "диспетчерлык үзәге" ул. Ел әйләнәсендә редакциягә бихисап күп әсәрләр керә. Бер ел эчендә әсәрләре журналда дөнья күргән авторлар саны гына да ике йөзгә якын. Редакция хезмәткәрләренең авторлар белән бәйләнеше нык һәм нәтиҗәле. Шунсыз мөмкин дә түгел: авторлардан кергән материалларның күплеге, әдәби хәрәкәтне оештыру зарурлыгы шуны таләп итә. Редакторат теге яки бу мәсьәләгә багышланган оператив утырышларны, редколлегия җыеннарын даими уздырып килә. Шулай ук аерым мәшһүр шәхесләр белән очрашулар да еш булып тора.

Мәгълүм ки, соңгы елларда латин имлясы мәсьәләсе зур иҗтимагый-сәяси яңгыраш алды. Латин графикасының телебезгә табигый рәвештә кулай икәнен, заманында байтак әсәрләрнең шул имляда басылганын истә тотып, "Казан утлары" латин шрифтында шактый гына язу үрнәкләрен бастырды. Бу гамәл күпчелек укучыларда хуплау тапты.

Базар мөнәсәбәтләре заманында популяр басманың һәр юлы, һәр бите аерым бер бәһа тора. Журнал, үзенең матди мәнфәгатьләренә күпмедер хилафлык китереп булса да, исән язучыларыбызның (бүгенге вәзгыять-хаҗәт буенча ул урында калын кесәле хуҗалык җитәкчеләренең яки бай эшмәкәрләрнең сурәтләре тора алыр иде!) портретлары һәр сан саен чыгып килә. Мәктәпләрдә татар әдәбияты укытучылары өчен алар бик кирәкле кулланма булып санала.

Журналның иҗат коллективы зур түгел, нибары тугыз кеше. Әмма алар барысы да исемнәре киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш язучылар, һәммәсенең диярлек мак-

таулы исемнәре бар. Болар— Флүс Латыйфи, Рәдиф Гаташ, Наис Гамбәр, Рәфикъ Юныс, Камил Кәримов, Мансур Вәлиев, Марат Закир, Алмаз Гыймадиев. Күбесе берничә жанрда иркен иҗат итә ала. Журнал хезмәткәрләре төрле җәмәгать эшләрендә (редколлегияләр, комитетлар, жюрилар, конкурслар һ. б.) актив катнаша. Мисалдан, идарә әгъзалары Равил Фәйзуллин—Татарстан Язучылар берлеге каршындагы Кабул итү коллегиясе рәисе, Мансур Вәлиев—тәнкыйть остаханәсе җитәкчесе. Редакция хезмәткәрләре шулай ук төрле әдәби кичәләрдә, юбилей чараларында, очрашуларда актив катнашалар, халык белән даими аралашып торалар.

Моннан өч ел элек язучыларның XIV корылтаенда Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев "Казан утлары" турында мондый сүзләр әйткән иде: "Әдәби журналларыбыз тормыш сулышын ныграк тоеп, шул ук вакытта талымлырак эш итәргә тиешләр. Бу яктан "Казан утлары" үрнәк булып тора. Ул—әдәбиятта гына түгел, сәнгатьнең башка төрләрендә дә энциклопедия булырлык басма. Халкыбызның рухи байлыгын, иҗтимагый-сәяси, эстетик фикерен үстереп, фән-мәдәният тарихын барлап-теркәп, журнал сигез дистә ел буена зур эш алып бара". Бирелгән бу югары бәяне төшермәс өчен журнал коллективы хәл кадәри тырышып эшләп килә.

Киләсе елның февраль аенда журналның меңенче саны дөнья күрәчәк. Уртак рухи хәзинәбезнең меңенче томы дигән сүз бит ул! Әдәби җәмәгатьчелек өчен истәлекле зур вакыйга булыр дип ышанабыз.

## *Бер сорауга—бер җавап*

**Америка континентында яшәүче милләттәшебез Вил Мирзаянов кызу җәй уртасынданиләр майтарып йөри икән?**



Җәйнең кызу уртасында эшләр һич тә кимеми. Әле менә 600 биттән зур булган Маенхен-Хельфенның "Гуннар дөньясы" дигән китабын инглиз теленнән рус теленә тәрҗемә итеп, аның исемнәр индексын инде бетерәм дип торам. Гуннар турындагы иң төпле китап кайчан һәм ничек басылыр, анысы хәзергә билгесез. Июль башында "Идел-Пресс" нәшриятында Борис Ишболдин Әл-Бәкринең "Татар тарихыннан өзекләр" дигән китабы минем тәрҗемәдә рус телендә дөнья күрде. Монысы бик шатлыклы хәбәр. 1000 данәле тираж татар мәктәпләренә бушка таратылырга тиеш дигән ниятемне дустым Илдус Садыйков тормышка ашырып йөри. Французның зур тарихчысы Ренэ Гроссеның татар тарихы өчен бик тә әһәмиятле булган 700 битле, "Далалар империясе" дигән китабын тәрҗемә итә башладым. Бу китапны укымаган тарихчы яки татар интеллигенты үзен, минемчә, һич тә тулы белемле кеше итеп сизә алмыйдыр. Төрки халыкларның тарихы шушы хезмәттә аеруча нигезле итеп яктыртылган. Ә инде кереш сүзенең азагында тарихчы нәтиҗәсенең "Идарә итә торган расалар, империя төзүче милләтләр бик аз. Төрки-монголлар, римлылар кебек" дип бетерелүе үзе үк халкыбызга карата гимн сүзләре кебек яңгыраганы мине генә түгел, хәр татар җанлы беркемне дә дулкынландырмый калдырмас дип өмет итәм.

Вашингтонда урнашкан мәгълүм "Стратегик тикшеренүләр үзәге" дигән җирдә "Вызов" дигән китабымның инглиз телендәге вариантын нәшриятка әзерләү эшләре минем үземнең дә бераз көч түгүемне сораганга, шул эшләр белән дә мәшгульмен. Эш, бик кызу булмаса да, бара. Барган эшнең азагы булмый калмас дип ышанам.

Күңел ачу яклары бик күп булмаса да, Нью-Йорк каласында үткән сабантуйга барып кайттым гаиләм белән. Бик күңелле һәм дулкынландыргыч булды бу татар бәйрәме. 23 июльдә Мәскәү Зур Театрының "Спартак" балетын Нью-Йоркның "Метрополитен-опера" дигән театр бинасында карадык.

Июль уртасында Вашингтонда Ак Йорт алдында гаиләм һәм андагы берничә татар "Әсирлектәге милләтләр атнасы" уңае белән пикет оештырдык. Плакатларыбызда Америка Президентына үз халкыбызның хәлләрен белдереп, аны Американың Идел-Урал милләтләренә ярдәм итү турындагы вәгъдәләрен онытмаска чакырдык.

*Дискуссия: “Безнең заман герое”*

# КИЛӘЧӘККӘ КҮЗ ТӨБӘП

“Казан утлары” ачып җибәргән “Безнең заман герое” дискуссиясе татар әдәбияты үсеше белән кызыксынган кешеләрне бер тирәгә туплады, фикер алышырга мәҗбүр итте, чөнки әдәбият XXI гасырга атлаган чорда, аның үткәненә күз салып бүгенге казанышларын барлау, хәл-әхвәлен ачыклау көнүзәк мәсьәләләрнең берсенә әверелде. Дисскуссия шулай ук әдәби процесска карата каршылыклы бәяләр яшәп килүен дә, уй-фикер төрлелеге булуын да ачыклады.

Журнал битләрендә урын алган мәкаләләр белән танышканнан соң, “Кем ул безнең заман герое?” дигән сорауга җавап таба алмый гаҗиз калуыбыз күренә. Бу бәхәстә катнашкан һәр кеше замана героен үзенчә кабул итә, үз рухи кыйммәтләренә туры китереп шәрехли. Безнең заман герое турында сүз алып барганда, бәхәстә катнашучылар уңай герой мәсьәләсенә киңрәк тукталалар. Д. Заһидуллина *(Казан утлары, 2004, 10 сан)* татар әдәбиятында “герой югалу” тенденциясенең күзәтелүе турында сүз алып бара. Чыннан да, хәзерге әдәбиятта уңай геройны, үрнәк геройны аерып күрсәтү мөмкин түгел. Әдәбиятта субъектив катлам көчәя бара һәм алдынгы, уңай фикер еш кына автор образы аша җиткерелә, ә берничә сыйфатын калкытып куюаша сурәтләнгән геройлар *(Т. Галиуллин “Тәүбә”, “Әлмәк”, “Төнге юллар”, В. Имамов “Могикан”, З. Хөснияр “Терсәк сугышы” һ. б.)* уңай герой дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Бу урында Р. Сверигин *(Казан утлары, 2004, 11 сан)* фикере белән килешмичә мөмкин түгел: язучылар китап битләрендә күбрәк чынбарлыкны сурәтлиләр, җәмгыятьтәге бозыклыкны күрсәтәләр. Әлеге тип геройларны “безнең заман геройлары” дип атарга мөмкинлек бар, чөнки алар—бүгенге җәмгыять вәкилләре, чынбарлык кануннары белән яшәүчеләр, безнең заман сәхнәсендә төп рольләрне башкаручылар.

Без үз язмабызда заман героен татар әдәбиятында соңгы елларда мәйданга күтәрелгән геройлар арасыннан эзләргә булдык. Яңа тип геройлар дигәндә, без әдәбият дөньясында 1990 еллар ахырында пәйда булган һәм, бер яктан, тәнкыйть утына тотылган, икенче яктан, артык уңай бәяләнгән образларны күздә тотабыз. Алар арасында тормышны янадан корырга сәләтле, мәрхәмәтле, киң күнелле ир-егет образлары—Хәлим *(Г. Гыйльманов “Албастылар”)*, Зәбир *(З. Хәким “Гөнаһ”)*, Арслан *(Н. Гыйматдинова “Ак торна каргышы”)*; чынбарлыктан ерагайган, кешеләрдән читләшкән, әмма күңел сафлыгын югалтмыйча, очарга талпынучы Сәүбән *(Г. Гыйльманов “Оча торган кешеләр”)*, Сара *(Н. Гыйматдинова “Ак торна каргышы”)*, Ак йөз *(Ф. Бәйрәмова “Канатсыз акчарлаклар”)*, Сабира *(Ф. Бәйрәмова “Кем?”)*; мифологик аң төпкеленнән калыккан албастылар *(Г. Гыйльманов “Албастылар”)*, Алып *(Ф. Бәйрәмова “Алыплар илендә”)*, бичуралар *(М. Гыйлаҗев “Бичура”)* яшәп килә.

Хыялый, мистик әдәбият үзе дә, аның тарафдарлары да көннән-көн арта, бүгенге көн татар әдәбиятында шул юнәлештә эзләнүләр даирәсе киңәя бара, шуңа нисбәттән язучыларның мифологик образларны калкытып куюының, яңа геройның

мифология, хәтта мистика белән бәйле типларына мөрәҗәгать итүенең сәбәбен эзләү табигый. Гасырлар чиге—кешеләрнең дөньяга карашын үзгәртеп, яшәеш турындагы күзаллауларын янадан карап чыгарга мәҗбүр иткән кискен тетрәнүләр заманы. XX гасыр ахырында илдә барган үзгәрешләр кешеләр тормышына тирән тәэсир ясады: матди, иҗтимагый үзенчәлекләр кешеләрне капма-каршы ярларга аерып куйды; кешеләр кыйблаларын югалттылар, кыйммәтләр системасын янабаштан карап чыгарга мәҗбүр булдылар.

Күчмә чорда *(теоретик әдәбиятта кабул ителгән төшенчә)*, ягъни ике гасыр чигендә сәяси, мәдәни тормышта барган үзгәрешләр әдәбиятка да тәэсир итми калмады. Бу йогынты унай яктан да характерлана: әдәбиятта яналык жиле исә башлый, "универсаль дөнья картинасы үзгәрә, архетип һәм мифлар белән кызыксыну арта төшә, иҗат культы өстенлек ала"[1], сәнгатьтә аерым кеше шәхесен данлау күзәтелә. Игътибар итсәк, XX йөз башы да иҗтимагый һәм рухи тетрәнүләргә бай булып, татар әдәбиятын модернизм ярларына алып чыкты, анын үсешенә тирән тәэсир ясады.

Бүгенге көн татар әдәбиятында мифларга, постмодернистик алымнарга игътибар арту күнегелгән карашларнын, кабул ителгән кыйммәтләрнен хәзерге таләпләргә җавап бирмәвеннән килә булса кирәк. Хәзерге жан-рух кризисы язучыларны бүгенге көн сүз сәнгате бирә алмаган тотрыклылыкны милли аннын ерак төпкелләреннән, тәнречелек идеяләреннән эзләүгә этәрә. Төрки халыклар мифологиясенә мөрәҗәгать итү милләтнен аянычлы хәлен күрсәтүгә булыша, проблемаларны милли даирәгә күчерә, сюжет сызыгы, конкрет рамкаларыннан чыгып, универсаль дөнья сурәтен, яшәеш моделен тудыруга юнәлтелә, шул рәвешле язучылар дөньякүләм мәсьәләләрне калкытып куюга омтылалар. Әлеге күренеш бүгенге көн татар әдәбиятында мифологик карашларнын, образ-төшенчәләрнен, архетипларнын алгы планга чыгуына сәбәпче була, чөнки чынбарлыктан таба алмаган таянычны кеше коллектив һәм тарихи ан казанышларыннан, архетиплар арасыннан эзли.

Хәзерге татар прозасынын мифологик фикерләү белән тыгыз элемтәдә торуын бүгенге көн татар әдәбиятынын аерылгысыз үзенчәлеге дип кабул итәргә кирәктер. Реализм, романтизм кысаларына сыймаган әдәбиятта һәр авторнын үз Яшәеш моделе тудырылса да, аларны берләштерә торган бер образ, "яна татар прозасы"нын үзенчәлеге дип кабул ителә алырлык уртак сыйфат бар: ул—"оча торган", ягъни олы жанлы, изге кешеләр. Ф. Бәйрәмованын бер әсәреннән икенчесенә күчә килгән, Н. Гыйматдинова һәм Г. Гыйльманов иҗатында чагылып-чагылып киткән типажлар—Күк кешеләре. Жир кешеләренә бөтенләй охшамаган, очарга сәләтле адәми затлар—күк дөньясы белән нык бәйләнгән, саф күнелле, ләкин канатлары сынган, үз кыйблаларын югалткан, бәхетсез каһарманнар. Күктән төшкән кешеләр мәхәббәтне Иманнары дәрәҗәсенә күтәрсәләр дә, гомер буе ялгызлыкка дучар ителгәннәр, пар канатсыз калып, оча алмый жирдә тилпенүче изге жаннарга әверелгәннәр.

Г. Гыйльмановнын "Оча торган кешеләре" белән Ф. Бәйрәмованын "Канатсыз акчарлаклар" исемле әсәрләрендә тудырылган мифологик Яшәеш модельләре Күк белән Жир арасындагы каршылыкка нигезләнә. Г. Гыйльманов тәнречелектәге Күк һәм Жир төшенчәләрен Авыл, Туган нигез төшенчәсенә сыйдыра. Авыл галәме язучы иҗатында универсаль дөньяга әверелә. Татар авылы—Галәмнен чагылышы, хәтта тәнгәле; аны "язмыш орбитасы, яшәү божрасы" әйләндереп ала. Туган нигезен, имезеп үстергән Жир-Анасын оныткан кешене язучы түбән дөнья вәкиленә тинли, ана Жир һәм Күк куенында урын калдырмый, тормыш чылбырыннан чыгарып ташлый. "Кешене туган жире, туган нигезе, балачагы сагындырмый башлый икән, димәк, ана нидер булган, ул үзенен рухи орбитасыннан ычкынган, балачагыннан ук килгән гомер юлыннан читкә тайпылган, язмыш орбитасыннан төшеп калган, кыйбласын югалткан, Иблис коткысына бирелгән...". Әсәрдә авыл дөньясы күк белән жирне, яхшылык белән яманлыкны укмаштырган урынга әверелә.

---

[1] Переходные процессы в русской художественной культуре: Новое и Новейшее время. – М.: Наука, 2003. – С. 6

Ф. Бәйрәмова повестенда исә башкарак күренешкә тап булабыз. Язучы дөньяны нәкъ икегә—Жир һәм Күккә аерып куя. Жир дөньясы карангы, явыз көчләрнең туплану урыны булса, Күк—якты, изге дөнья итеп сурәтләнә. Ф. Бәйрәмованың жире тәмугка тин. Дингез белән уратылган утраудагы жүләрләр йорты жир кешеләренең яшәү рәвешен чагылдыра, түбән каттан өскә күтәрелү нәкъ безнең тормышның тәнгәл чагылышына әверелә, аның әдәби моделе буларак яши башлый. Г. Гыйльмановтан аермалы буларак жирне, утрауны уратып алган су божрасы кара язмышны, бәхетсезлекне анлата, кешене тирән чоңгылга бөтереп алып керә. "Алар (кешеләр) йөгерә башлыйлар. Ләкин яр бетми! Ярның очы-кырые юк. Шунда алар аңына коточкыч бер нәрсә барып житә—алар утрауда икән бит! Һәм бу яр, бу су мәнге йөгерсәләр дә, бетмәячәк. Монда эләккән кешегә бу утраудан чыгу юлы юк". Повестьта кешегә жирдә бәхетле булу мөмкинлеге калдырылмый, сәгадәт артыннан күккә очарга кирәк, ә сынган канатлар тәмуг өстеннән югарыга күтәрә алмыйлар.

"Оча торган кешеләр" дөньясында адәм заты, жирдән, авылдан, язмыш орбитасыннан читләшсә, "иясез язмышка", бәхетсез жанга әверелә, хәсрәт юлына кереп китә. Ф. Бәйрәмовада нәкъ киресе: кеше бары тик кара жирдән, "жүләрләр йорты"ннан ычкынгач кына бәхеткә тиенә, күк катында сөенечле тормышка ирешә. Әсәрләрдә бәхетле яшәешкә карата каршылыклы фикерләр әйтелүгә карамастан, һәр ике язучы сәгадәтле булу өчен пар канат кирәклеген раслый, бәхеткә ирешү юлында мәхәббәткә өстенлек биреп, сөю көченә ышана; әлеге идеягә нисбәтән әсәрләргә гадәти жир кешеләреннән аерылган, башка галәм затлары буларак кабул ителгән образлар кертелә.

Язучылар, дөньяны хәрәкәткә китерүче үзәк көч буларак, явыз кешеләр, кара рухлар һәм оча торган кешеләр, изге рухлар арасында барган көрәшне хәлиткеч дип саныйлар. "Оча торган кешеләр"дә Ак бабай сөйләгәнчә, "галәмнән төшкән кешеләр әрәмәлек буенда шәһәр төзи башлыйлар. Әмма жир кешеләренең явызлыгын белмиләр әле алар. Төзеп кенә бетерәләр, жирдәге кыргый затлар бу шәһәргә һөжүм итәләр, аны яндырып, пыр туздырып китәләр". Күк кешеләренең бәхетсезлеге шул вакыттан башлана: очу сәләтенә ия булу турыдан-туры мәхәббәткә бәйләп аңлатыла, әмма бәхетнең тулылыгына күк кешеләре белән кавышканда гына ирешергә мөмкин. Г. Гыйльманов "авылында" мәхәббәт әхлаклылык критериена әверелә, "кешенең әйбәтлеге ярата белүе белән билгеләнә, бәяләнә". Язучы фикеренчә, ярата белгән кеше начар кеше була алмый. Сәүбән дә ярата белә кебек: сөйгәненең һәр сүзеннән, ымыннан аңлый, әмма аның мәхәббәте кара гайбәт каршында көчсез, егетнең жир кешеләре арасыннан күтәрелерлек ихтыяры юк. Тормыш низаглары аны пар канатыннан мәхрүм итә, ә канатсыз кеше—бәхетсез, "иясез" кеше. Г. Гыйльманов мәхәббәтнең бар нәрсәдән өстен булуын раслый, сөюне кешенең Иманына әвереллерә. Бары тик батыр йөрәкле, пар канатлы кеше генә оча, яңа биеклекләргә ирешә ала, мәхәббәткә хыянәт кешене тирән упкынга этәрә.

Ф. Бәйрәмованың "Канатсыз акчарлаклар" повестенда да күк һәм жир тартышы үзәк конфликт буларак алына. "Без, күктән ингәннәр, кешеләргә ярдәм итә башладык. Безнең барлыкны сизенгән кешеләр безгә ышана, табына башладылар. Ләкин шундый вакытлар житте, кешеләр табигать белән бергә безне дә юк итә башладылар. Безнең күпләребез, кешеләргә тәмам ышанып, саклау чараларын да онытканнар иде—кешеләр аларны бик тиз тотып ашадылар! Шулай итеп, алар үзләренең Аллаларын, Иманнарын ашадылар",—дип сөйли күк кешесе. Язучы жирдә мәхәббәтен тапмаган, ярата белмәгән, жансыз кешеләргә генә урын калдыра, жирдә бары тик "гәүдәләр генә йөри, гәүдәләр генә", һәм бу—кешелекнең фажигасе, төзәтә алмаслык хатасы. Ярата белгән кешеләргә жир кешеләре арасында урын юк, алар бары тик Галәмдә, Жиһанда гына оча алалар. Ярату кешеләргә күккә күтәрелергә мөмкинлек бирә. "Ир-ат һәм Хатын-кыз! Табигатьнең мәнгелек могжизасы, Жиһанның иң зур ачышы, кешеләренең бер-берсенә бирә алырдай иң зур бәхете!", ә "жир кешеләре яшибез дип беләләр. Алар—канатсыз акчарлаклар. Күкләргә күтәрелү юлы алар өчен мәнге ябылган". Язучы галәмендә ярата белгән кеше генә

оча ала, яхшы тормышка ирешеп, башкаларга да бәхет бирә, ә пар канатсыз кешеләр—канатсыз акчарлаклар, язмыш божрасыннан төшеп калган иясез язмышлар.

Г. Гыйльманов һәм Ф. Бәйрәмова әсәрләрендә күк һәм жир кешеләренең конфликты нигездә гомер буе кеше күңелендә барган тартышуга кайтып кала. Һәр ике әсәрдә дә жир кешеләре һәм күк кешеләре кеше җанының ак һәм кара якларын гәүдәләндерәләр дигән тойгы кала. Язучылар мәңгелек төшенчәләрне мифологик фикерләү үзенчәлекләренә таянып, бик гади аңлатып бирә алганнар. Мифологик дөнья моделендә кеше күңелендәге изгелек оча торган кешеләр, ә явызлык жир кешеләре аша гәүдәләнә. Барлык Галәмне колачлаган, яшәү мәгънәсенә әверелгән тартышу нигездә кеше җанындагы Явызлык-Игелек көрәшенә кайтып кала, шунда гомумиләшә.

Ф. Бәйрәмованың "Кем?" әсәрендә дә сюжет сызыгына башкалардан аерылып торган Сабира образы килеп керә. Кечкенәдән үк бүтән балаларга охшамаган, очарга хыялланган кызны авыл кешеләре кабул итми. Кешеләр арасында адашып яшәгән Сабира тормыш иптәшенә зур өметләр баглый, әмма Идрис аны аңларга теләми, алтын читлеккә урнаштыра, очу хыялыннан мәхрүм итә. Тормышында фаҗигагә юлыккан, өметен югалткан кызның юлына язмыш Фазылны чыгарып куя, әмма күкләргә күтәргән илаһи мәхәббәткә яшәргә ирек бирмиләр, явыз Идрис—жир кешесе—гашыйкларны аера. Әсәргә кертелгән әкият катламы Сабираның тормышы белән тәңгәл килә. Сөйгәне белән күккә күтәрелгән канатлы кызны кешеләр таш белән атып үтерәләр. Сабира белән дә шул ук хәл кабатлана, жир кешеләре аның хыял һәм мәхәббәт канатларын сындыра, әмма шуна да карамастан ул рухи кыйбласын югалтмый, сыкранып булса да гомер буена мәхәббәтенә тугры кала.

Н. Гыйматдинова иҗатында да гадәти кешеләрдән аерылып торган хатын-кыз образлары *(Һашия "Каракош", Сара "Ак торна каргышы")* очрый. "Ак торна каргышы" повестеның сюжеты нигезенә музыка укытучысы Сараның авылдагы тормышы, Сара белән Арслан мөнәсәбәтләре салынган. Табигатьнең матурлыгын күңелләре белән тойган, рухи кыйблаларына турылыклы калган, саф күңелле унай геройлар—Сара һәм Арслан авыл кешеләренең наданлыгына, мәрхәмәтсезлегенә каршы куела. Сара белән бәйле рәвештә повестька канат образы кертелә. Канат әсәрдә тормышка яңадан кайту, кабат терелү, караңгылыктан котылу юлы буларак гомумиләшә. "Ярабби, әгәр канатлар үссә, мин бу ызбадан очып чыгар идем дә, зәңгәр кыңгыраулы аланга төшәр идем. Торна булыр идем мин, ап-ак торна…",—дип илерә Сара. Торна Сараның игезәгенә әверелә, ул кош үлгәннән соң Сара да юкка чыга, ә авыл коточкыч фаҗигагә юлыга. Кошларга мөнәсәбәт авыл халкы өчен рухи сынау итеп бирелә, шуңа карап кешенең күңел дөньясы, холык-фигыле, эше бәяләнә.

Язучылар "оча торган кешеләр" дип атаган шәхесләр асылда безнең арада яши кебек, әмма аларны гади "жир кешеләре" аңлап житкерми, башка дөнья әһелләре булуларын белүгә үзләреннән читләштерә киләләр. Ялгызлыкка дучар ителгән, саф күңелле, рухи бөтен, камил, мәхәббәткә дан жырлаучы геройлар гадәти түгеллекләре белән аерылып торалар. Очарга теләп тә оча алмаган язмышлар, фаҗигагә юлыккан гомерләр, җәмгыятьчелек тарафыннан авыр кабул ителгән кешеләр татар әдәбиятына килеп кереп, архетип дәрәҗәсенә күтәрелсәләр дә, безнең заман геройлары буларак кабул ителми. Дөрес, алар—бүгенге әдәбиятның төп каһарманнары, әмма тормышта алар әле юк, алар килер өчен жирлек тә әзер түгел әле. Әдәбият тормыш-яшәешнең һәр үзгәрешен алдан сизүчән. "Оча торган кешеләр"нең бүгенге әдәбият мәйданында киң таралуы да әдәбиятның күрәзәчелегенә бәйле булса кирәк.

Яңа тип геройларның икенче төре—ир-егет образлары—татар әдәбиятында мифологик күзаллаулар белән бәйле рәвештә мәдәни каһарманнарга барып тоташа. Мәдәни герой *(культурный герой)*—борынгы мифологиядә иң мөһим әйберләрне табучы, кешеләрне беренче башлап төрле һөнәрләргә өйрәтүче, галәмне тәртипкә китерүче ир-егет. Г. Гыйльмановның "Албастылар" романында мифологик геройга тиңләштерерлек Хәлим образы бар. Хәлим—Табигать белән Кешелек дөньясын

үзара якынлаштырып торучы образ. "Житез-өлгер атлавына, нык адымнарына карап, аның бер сугуда бүрәнә өзәрдәй әзмәвер егет икәнен чамаларга мөмкин. Йөзе кояшта янган. Карашы туры, тирән... Ә күзләре, күзләре—күк төсендә, ачык зәңгәр! Халыкта мондый күзләрне изгелеккә, илаһилыкка юрыйлар. Йөз-битенә кунган сакал-мыек төкләренә караганда, ул егерме яшьләр чамасында булыр". Төскә-биткә чибәр Хәлимнең берничә еллык гомерен колачлаган әсәр дә асылда аның олыгаю, өлгерү юлы буларак кабул ителә. Урман юлына ваемсыз бер егет булып кереп киткән Хәлим, нәтиҗәдә, Акны Карадан аерырлык, барыр юлын анык белгән кешегә әверелә. Иң элек явызлыкка явызлык белән җавап бирергә теләгән, авырып яткан әбиләрне *(албасты карчыклар)* "тамчы да кызганмыйм" диган Хәлим *(әнисен ничә кат рәнҗеткән, ваемсыз кыланган Хәлим)*, ниһаять, урман юлында юлыккан югалту-табышларыннан соң, тормыш хакыйкатен аңлый: әбиләр (албастылар) язмышында кешеләрнең юылмас гаебе булуын таный, урман белән бәхилләшеп, гаиләсе янәшәсендә тыныч-тату яшәүгә ирешә. Урман дөньясында бик күп сынауларга дучар булган егет авылга күңеле утырган, акылы тирәнәйгән, ипле-саллы фикер йөртерлек ир-егет булып, кире китмәскә кайта. Урман дөньясы Хәлимне, әйтерсең лә, тормышка өр-яңадан аяк бастыра, аның күңел дөньясын баета, рухын ныгыта. Автор юлчы карт авызыннан егеткә соңгы сүзләрен әйтә: "Юк, син үлмисең. Син әле тудың гына. Яши генә башладың".

Хәлимнең урман белән авыл арасында үткән юлы үз күңелендәге албастыларны җиңү буларак аңлашыла һәм борынгы чорларда киң таралыш тапкан *инициация* йоласы белән тыгыз бәйләнә. Балалар тиешле яшькә җиткәч, аларны ыруга тулы хокуклы әгъза итеп алу өчен, баланың физик һәм рухи мөмкинлекләрен ачыклау максатыннан үткәрелгән йоланың башкарылу урыны һәрвакыт урманда булган. Хәлим дә, нәкъ борынгы йоладагыча, урман йортында сынаулар үтә, тормыш хакыйкате белән таныша, мәрхәмәтле, сабыр булырга өйрәнә, күңелендәге албастыны "агарта". Шул рәвешле ул үз дөньясын бөтенләштерә, күңел хөрлегенә ирешә, әмма зур дөньяны—авыл галәмен—тәртипкә кертә алмый, шуна күрә дә ул көчсез герой буларак кабул ителә, аның дөньяны үзгәртә алырлыгы ышандырмый.

Бүгенге көн татар әдәбиятында мифологик катламга зур урын бирелә. Мифологик күзаллаулар белән бергә әсәр кысасына мифологик образлар кертелә. Мифологик образ төп геройга яшәү хакыйкатен таныту, автор позициясен ачыклау өчен хезмәт итә. Ф. Бәйрәмованың "Алыплар илендә" повестенда хыялый образлар—алыплар—реаль дөньяда сурәтләнәләр. Әсәрдә Алып өч юнәлештә үзгәрә: дини, мифологик, әдәби яктан. Мифологик катлам Алыплар турындагы мифологик сөйләкләр аша ачыла; дини аспектта алыплар Коръән мотивлары белән бәйле рәвеше ачыклана, иманга, дингә килү идеясе мифологик образ аша тормышка ашырыла; әдәби юнәлештә Алып мифологемасы әсәрнең идеясен, ягъни, Аллаһы Тәгалә кануннары буенча, игелек кылып яшәгәндә генә бәхетле тыныч тормышка ирешү мөмкинлеген күрсәтү өчен кертелә.

Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, бүгенге татар прозасында яна тип геройларны очратырга мөмкин. Алар гадәти яшәештән читләшүләре, башкаларга охшамаулары белән аерылалар, рухи ныклыклары, илаһи мәхәббәткә сәләтле булулары, күңелләренең хөрлеге белән игътибарны җәлеп итәләр. Аңлашыла ки: безнең болгавыр заманда, рухи кыйммәтләр җимерелгәндә, әлеге геройларның тормышта булуы шик уята, әмма әдәбиятта инде алар бар, алар килеп ята, бу исә үз чиратында әдәбиятның үзгәрешләрне алдан сиземләвенә бәйле. Әлбәттә, бер мәкалә кысаларында әдәбиятның барлык катламнарына, агымнарына бәя бирү мөмкин эш түгел. Шулай да, күзәтелгән материал бүгенге көн әдәбиятында барлыкка килүче яна тенденцияне билгеләргә мөмкинлек бирә һәм "киләчәк" заман геройларының "бүген" тууы хакында сөйли.

**Ләйлә ДӘҮЛӘТШИНА**

**Зиннур Мансуров**

# ЧИЧӘННӘР КАЙТАВАЗЫН КЕМНӘР КӨЧӘЙТӘ

Күктән иңгән кебек тоелучы талант ияләре дә гадәти үсеш баскычы буйлап күтәрелергә мәҗбүр. Дәвамчанлык күренешенә бәйле мондый зарурият, әлбәттә, теләсә кайсы сәнгать төренә кагыла. Шул исәптән шигърияткә дә. Шуна күрә, элгәрләре тәэсиренә бирелмәгән шагыйрь чынлыкта бөтенләй була алмыйдыр. Ә йогынты көче зурайган саен, шигърият үзе дә олпатлана бара. Бу җәһәттән безгә шөкерана кылырга кирәк: алыс гасырлардан ук килгән затлы әдәбиятыбызның кабатланмас мирасханәсе яңь-яшь дәвамчылар үрнәк алырлык язу рәвешләренә аеруча бай.

Әле чагыштырмача яшьрәк буын вәкилләреннән саналган Газинур Моратның иҗатын тулаем күзаллаганнан соң, мин аерым күренекле шагыйрьләребез барлыкка китергән тел-өслүп мәктәпләрен берәм-берәм хәтер аша үткәрдем. Төрлелеккә исең китәрлек! Нәкъ менә шундый яхшы нигездәге күпьяклылык шигъриятебезнең гомуми культура дәрәҗәсен билгели дә инде. Табигый ки, алма агачыннан ерак төшмәгән кебек, Газинур да традицияләребез җирлегендә калган. Әмма, теге яки бу йогынтыга бирелгән очракта да, ул остазлары алдында таләпчән шәкертлек холкын күрсәтә алган. Һәрхәлдә, минем үземә шулай тоела.

Чын шигърияткә тугры хезмәт итүнең мәҗбүри үтәлергә тиешле шартлары бар. Шуларның берсе, әлбәттә, яңалыкка омтылу. Гәрчә беренче карашка гади булып күренсә дә, бу фарызлык әле үзе дә байтак таләпләр куя. Әмма иҗатта яңалыкка ирешү, барыбер, үз сүзеңне әйтүгә, бихисап кайтавазлар илендә үз тавышыңны яңгыратуга кайтып калады. Яхшы хәтерлим, сиксәненче еллар башында әдәбият мәйданына ныклап аяк баскан Газинур Морат кулга шагыйрьлек каләмен алу җаваплылыгын тирәнтен аңлар дәрәҗәдә әзерлекле иде. Иҗат яшьләрендә сирәк очрый торган мондый өлгергәнлек аның беренче җыентыгында да шактый ачык тоемлана *("Җир хәтере", Татарстан китап нәшрияты, 1985).* Шигырьне ритмик сүз тезмәсе итеп кенә аңлаучы беркатлылар бирегә үзләренең ялгыш күзаллавын акларлык мисаллар таба алмастыр. Нык кул белән язылган әсәрләрдән үзенчәлекле шагыйранә рух бөркелеп тора. Киң фикри офыкларны колачлаган, тирәнлек түренә юнәлтелгән рух... Менә шундый рух иҗатчыга тормыш күренешләрен эчтән яктыртып күрсәтергә, хисапсыз яшәеш хикмәтләренең асыл үзәгенә үтеп керергә ярдәм итә. Тылсым көченә ия шушы рух белән ул җисем табигатендәге матурлыкны эзләп таба. (Матурлыкны үзе уйлап чыгармый). Шагыйрьнең дөнья белән мөнәсәбәте исә үзара ышанулы ихласлык нигезенә корылган: "Җиһандагы һәрбер җисем—җанлымы ул, әллә җансызмы—кызып сөйли миңа эч серләрен, шатлыкларын, дәгъва-таләпләрен...".

Беркадәр яшьләрчә хиссият белән белдерелсә дә, бу сүзләрдә шагыйрьнең холык-фигыле дә чалымлана. Чыннан да, Газинур Моратның шигырьләре шәхси уй-хисләрне белдергән монологлар кимәлендә түгел, киресенчә, җанлы әңгәмәдәш белән ихлас ачылып сөйләшү рәвешендә кабул ителә. "Аңлашырбыз гүзәллек һәм язмышлар теле аша" кебек искәртүдә исә сөйләшүнең шактый катлаулы темалар турында баруына ишарә ясала. Шигырьләр бер-берсен тулыландыра. Иҗат тәҗрибәсе отыры баеган саен шигъри характер даимилек ала бара. Шул ук вакытта шагыйрь элгәрләр рухына тугрылыгын, уй-гамьнәренең житдилеген дә үзенчә тикшергәләп куя кебек:

*Чәчән бабайларның кайтавазы*
*Яңгырыймы бүген безнең җанда?..*
("Җир хәтере").

Әдәбият белеме классиклары бердәм рәвештә искәрткәнчә, фикер ягыннан үсеш кичермәүче шагыйрьнең иҗаты тулаем зур әһәмияткә ия була алмый. Дөрестән дә, әгәр каләм әһеле образлар белән эш итә икән, ул шушы образлар аша нинди фикер үткәрергә тиеш. Элек-электән халык мәхәббәтен казанган шагыйрьне тикмәгә генә акыл иясенә тиңләмәгәннәрдер. Вәләкин мондый биеклеккә күтәрелү өчен гаять мөһим шартларны үтәргә кирәк: бер үк вакытта тирән фикер йөртү, һәрчак ташырга торган хисләрең белән оста идарә итү һәм шуларны үз шигырендә мөкәммәл дәрәҗәдә гәүдәләндерү, ягъни бердәй югарылыктагы акыл, күңел һәм зәвыкка ия булу. Асылда һәрбер иҗатның сәнгатьчә камиллек дәрәҗәсен менә шундый гармония билгели дә инде. Аерым башлангычка чама белән өстенлек бирү исә соңгы исәптә язу рәвешләрен яхшы төрлелеккә китерәдер.

Әсәрләренең табигатеннән күренгәнчә, шигъри иҗатның мондый серләрен Газинур Морат әчке сиземләү белән аңлый. Хәер, акыл, күңел һәм зәвык берлегенә ирешү аның талантына ук салынгандыр кебек тоела. Өстәвенә, житмешенче еллар көндәлек матбугатында барган кайнар бәхәсләр дә әдәбиятка килергә карар кылган егеткә йогынты ясамыйча калмагандыр. Хәтерлисездер, шигъри фикер белән хискә карата төрле карашлар булу каләм ияләрен үзеннән-үзе зур сөйләшүгә тартып кертте. Дөресен әйткәндә, мондый бәхәс өчен җирлек тә бар иде. Эчтәлек һәм шәкел мөмкинлекләрен киңәйтү юнәлешендәге эзләнүләрнең көчәюе, аерым алганда, фикергә беркадәр микъдарда өстенлек бирелгән шигырьләрнең күбәюенә китерде. Ә уйның хистән ераклашуы шигърият билгесе була алмый... Ерак чорлар үрнәге—әле бер хәл. Ә замандаш шагыйрьләр йогынтысы чагыштырмача көчлерәк булучан. Фикер ягына ныграк басым ясалган әсәрләр, әлбәттә, Газинур Моратның башлангыч иҗатында да очраштыра. Әнә бит, кайбер очракта ул үзе дә икеләнеп калган: "Акылгамы әллә күбрәк Биреп куйдым вәкаләт?.." Үзеннән-үзе "акыллылык"ка авышучан ирекле шигырьдә дә көчен сынап карый яшь шагыйрь. Әмма аның мондый шәкелгә күңеле никтер ятып бетмәгән—беренче китабында урын алган "ак шигырь"ләр биш-алтыдан артмый. Аннан соң чыгып килгән яңа җыентыкларында да мондый тәҗрибә үрнәкләре күзгә бәрелеп тормый. Үзенең шагыйрьлек вөҗүде өчен ул гадәти өслүпне кулайрак күрә. Серле шигъриятнең табигый асылына тәңгәлрәк килгән, гасырлар буена камилләшкән, бинихая мөмкинлеге булган классик алымны сайлый. Әмма шигъри сүзнең ирекле яшәешенә, каләменең хөрлегенә, барыбер, тугры кала.

Иҗатка интеллектуаль әзерлек белән килгән каләм иясе үзеннән өлкәнрәк шагыйрьләрнең язганына таләпчәнрәк карарга тиештер. Сер түгел, әдәби хәрәкәтне җанландырып җибәргән көчле буынның да уңышлары артында тырпаеп торган җитешсезлекләре була. Минемчә, Газинур Морат йогынтылы элгәрләренең әнә шундый "зәгыйфь яклары"н вакытында күрә алды һәм, аларның ялгышларын мөмкин кадәр кабатламаска омтылган хәлдә, үзенчә язу рәвешен булдырды. Шагыйрьнең лирасы шактый нәзакатьле. Моның сере нидә? Бу хакта минем озак уйланганым бар. Фаразлавымча, әлеге дә баягы "фикер, хис һәм зәвык" формуласындагы гармонияне саклап, ул күпләргә җитенкерәмәгән тел камиллегенә ныграк игътибар бирәдер кебек тоела. Үзенең шагыйрьлек холкын билгеләүче төп үзенчәлекләрдән саналган бу хасиятне Газинур Морат "Каударланма, каләм..." исемле шигырендә дә сиздереп куя.

*Дөньяныкы дөньялыкта кала,*
*Каударланма, каләм, кабаланма;*
*Кадерен бел Сүзнең...*
*Болай да бит*
*Гомеркәйләр—тоташ каралама.*

Кызганыч, язганнарын югары сәнгать таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәгә житкермичә, ягъни каралама хәлендә укучыларга тәкъдим итүчеләр хәттин ашкан. Бу заманда бигрәк тә... Ә бит күпме генә бәхәс кылсак та, һәрбер каләм әһеленең иҗаты, ахыр чиктә, шәхси стиль белән билгеләнә. Ә стиль үзе барыннан да элек телгә барып тоташа. Һәм әдәби иҗат техникасы да, нигездә, тел өйрәнүгә кайтып кала. Бездә "тел-өслүп"нең парлы сүз рәвешендә язылуы да нәкъ менә шушы хакыйкатьне раслый булса кирәк. "Шагыйрь бул син, әйдә, шагыйрь бул син, Гөл-

чәчәктән сүзләр үрсәнә", дип яшьли үз-үзенә эндәшкән Газинур Морат, әлбәттә, кирәкле сүзнең кирәкле урында торуыннан гына яхшы стиль барлыкка килүенә беренче шигырьләрен язган чакта ук төшенгәндер. Бүген аның чын мәгънәсендә тел остасы булуын яшьтәшләре белән бергә өлкән каләмдәшләре дә таный. Шагыйрьнең стилистлык сәләте күптөрле мәкаләләрендә дә, чәчмә белән язылган юмор-сатира әсәрләрендә дә, шулай ук мөхәррирлек эшчәнлегендә дә ачык күренә... Без инде беләбез, турыдан-туры сүз белән эш итүчеләргә, бигрәк тә шагыйрьләргә, барысыннан да зуррак бурыч йөкләнгән: телне яшәтүнең иң югары формасы булган сәнгатькә үзеннән бөтен осталыгынны багышлап тугры хезмәт итү. Ә Газинур Моратка килгәндә, безгә бик кирәкле мөкатдәс бурыч, минемчә, аның шагыйрьлек тәкъдиренә үк язып куелган.

Нәкъ менә күп катмарлы тел җәһәтеннән чыгып караганда, шагыйрьнең стиле кайсы яклары белән аерылып тора соң? Беренче чиратта аның шактый ачык, ягъни аңлаешлы булуы күзгә ташлана. "Иң яхшы тәртиптәге иң яхшы сүзләр..." Аеруча әйбәт шигырьләрне укыган чакта менә шушы билгеләмә хәтергә килә. Сизелә ки, Газинур Морат әдәби телебезнең чиксез зур байлыгыннан оста файдалана, нигәдер онытыла төшкән аңлаешлы матур сүзләребезне дә уңышлы куллана. Әйтик, "вөҗүд", "ырыс", "иләт", "тияк", "батман" кебек сүзләр шигырь тукымасында бөтенләй яңа яктан ачылып китә. Аның "сынчыбагар" (натурщик) неологизмын уйлап чыгаруы да тел хәзинәбезне баету теләгеннән киләдер дип уйлыйм. Шагыйрь аерым сүзбизәкләргә басым ясаган чакта сүз һәм мәгънә гармониясенә ирешергә омтыла. Моның өчен әүвәл төгәл сүзләр сайлый. Заманында татар әдәбиятына остазлык кылган Максим Горький үзенең бер чыгышында хаклы рәвештә искәртеп үткәнчә, телнең чын мәгънәсендәге матурлыгы сүзләрнең төгәл, ачык, янгыравык булуы белән тудырыла. Ә сүзнең төгәллеге стиль яисә югары зәвык таләбе генә түгел, иң беренче чиратта мәгънә таләбеннән килеп чыга торган зарурият ул. Сүзләрнең төгәллеге исә, табигый рәвештә, тыгыз кыскалыкка китерә. Гомумән, фикри-хисси тыгызлыктан башка сәнгатьлелек була алмыйдыр. Әгәр тирәнлеге чамалы икән, шигырь дә озынга сузыла. Иҗатында тыгызлык принцибына тугры булуын Газинур Морат үзе дә яшерми:

*Озын сүзнең кыскасы шул*
*(Хаклыгына юк шигем):*
*Кысалар кысылган саен*
*Кыскара бара шигырь...*

("Кыска шигырь турында").

Шигъри әсәрләрнең һәрбер төрендә дә шагыйрь азсүзлелекне кулайрак күрә. Аның балладаларына да җыйнаклык хас. Хәтта асылы буенча киң фикри офыкларны колачларга чакырган поэма жанрында да Газинур Морат эчтәлекне концентрацияләү юлы белән мөмкин кадәр кыскалыкка ирешә. Мәсәлән, төрле елларда язылган "Лонг-Кеш" (1981), "Җир хәтере" (1982), "Түбә" (1986), "Атом- кирмән" (1988), "Ачлык" (1991) исемле поэмаларда да шагыйрьнең тотнаклы тел-өслүбе үзенә нигез итеп алган кагыйдәләргә, барыбер, тугры булып кала. Тыгызлыкка ирешүнең, сүз дә юк, серләре байтактыр. Бу уңайдан игътибар иткәнем бар: Газинур Морат кайвакыт фигыльләрдән сирәгрәк файдалана, эпитетлар тезеп китү белән дә мавыкмый; ул исемнәрне яратарак төшә, предмет яки күренешнең исеме аның өчен мөһимрәк санала. Ә шигърияттә мондый алым кечерәк формаларны таләп итә.

*Горурлыгым. Мескенлегем.*
*Таянычым. Абынуым.*
*Тугрылыгым. Хыянәтем.*
*Ихтыярым. Табынуым...*

("Син").

Соңгы елларда Газинур Морат үтемле кыска шигырьнең дә чын остасына әверелде, җыйнаклыкка ятышып торган тел-өслүбен туктаусыз камилләштереп, безнең шигърияттә элек-электән яшәп килүче мондый форманың мөмкинлекләрен тагын да киңәйтте. Аның язганнары һәрбер гамьле күңелне дулкынландыра алырлык яңа

хакыйкати катламнарны ачуы белән генә түгел, сүзне илаһият бүләге рәвешендә кабул иткән шагыйрьнең үзенчәлекле шигъри синтаксисы ягыннан да аерылып тора. Һәммә сүзнең үз аһәңе, үз авырлыгы, үз тәме, үз йөкләнеше булуын сизәсең. Гомумән, кече шигъри кишәрлектәге һәрбер сүз бар яктан да үтәли күренүчән.

Менә шундый чакта инде мәгълүм мәкалебез искә төшә: сүз эчендә энже бар... Ә Газинур Моратның берничә юллы шигырьләрендә энжесе күренеп торган сүзләр аеруча күп. Әлбәттә, мондый форманы кыскалык белән чикләү аның шартлы аталышыннан гына киләдер. Гәрчә хикмәтле дүртьюллыкларда сүзләр тәгаен санаулы булса да, аларның тирәнлеген үлчәрлек бернинди берәмлек тә юктыр. Сүз сөйләүдә аңа кыска булырга боерылганын шагыйрь "Автопортрет"ында үзе дә сиздереп куя: "Минем хакта хак булганны Сөйләмәсеннәр бозып; Мин—мәзәк шикелле кыска, Әкият кебек озын...".

Әгәр Газинур Морат үз иҗатында азмы-күпме һөнәри осталыкка ирешкән икән, әйе, ул шагыйрьнең тел-өслүп кебек әһәмиятле мәсьәләгә таләпчән мөнәсәбәттә торуыннан да килә. Буыннар арасындагы дәвамчанлык кабатланудан гына тормый. Белгәнебезчә, алтмышынчы еллар башында әдәбиятка яшен уйнатып килгән Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Рәдиф Гаташлар буыны, һичшиксез, гадәти бертөрлелектән күпмедер тынчуланып калган шигъриятебезне тел-өслүп һәм эчтәлек-шәкел ягыннан яшьләрчә кайнарлык белән беркадәр сафландырып җибәрүгә ирештеләр. Мондый фактны инде кире кагып булмый. Әмма шунысын да танырга кирәк: аларның аеруча ирекле шигырь өлкәсендәге кайбер эзләнүләре модага иярүчән графоманнарның артуына да сәбәпче булды. Классик шигырь үрнәгенең асыл үзәген ватып-җимерүләргә гаммәви "шигырь язу бумы" килеп ялганды. Хәтта профессиональ иҗат оешмасында торган каләм ияләре дә гап-гади поэтика кануннарына карата талымсызлык күрсәтә башлады. Ритмга игътибар кимеде. Алама рифмаларның үрчүе тезмәнең тәмен җибәрде. Шигырьнең әүвәлге юлларын бер үлчәмдә башлап, аннары икенче төрле иҗек санына күчеп, өченче үлчәмдә төгәлләү гадәти күренешкә әйләнде. Абруйлы басмаларда дөнья күргән байтак шигъри әсәрләр тәҗрибәле мөхәррирнең баштанаяк камиллек дәрәҗәсенә җиткерүенә мохтаҗ иде. Сүз сәнгатенең иң мәһабәт формасы булган шигырьне күрәләтә ниндидер коры карикатурага авыштыра баручылар бермә-бер ишәйде. Кыскасы, шигърият бакчасы пычранды. Бүгенге көндә "шигърият экологиясе" мәсьәләсе бөтен җитдилеге белән көн тәртибенә басты. Менә шундый шартларда яшьрәк буын шагыйре Газинур Моратның үзен чолгап алган әдәби мохиткә тәнкыйди күзлектән каравы, камиллеккә ирешкән тел-өслүбенә һәрвакыт тугры калып, татар шигърияте чисталыгы сагында торуы аның тигез агышлы тирән иҗатына янә бер әһәмиятле кыйммәт өсти.

Чыннан да, фикри сайлыкта утыручы шагыйрьләрнең иҗаты зур әһәмияткә дәгъва кыла алмый. Әгәр Газинур Морат үзенең шигъриятендә ниндидер дәрәҗәдәге фикер иясе булуга ирешкән икән, аның әлеге казанышында "сүз төгәллеге—тел—стиль—мәгънә" кагыйдәсеннән читләшмәве дә чагылыш таба. Шагыйрь әсәрләре аша үткәрелгән образлы фикер күпчелек очракта милләт гаменә килеп тоташа. Аллаһ тарафыннан ирекле итеп яралтылган газиз кавеменең хәләл хакын даулау уе аның сабыр даимилеге белән аерылып торган шагыйрьлек холкына ук салынган кебек. Йөрәк типкән саен сулкылдап алган әлеге мөкатдәс гамь Газинур Моратның шигъри басмаларында гына түгел, "Җәяүле кошлар" исемле мәкаләләр җыентыгында да *(Татарстан китап нәшрияты, 2002)*, хәтта балаларга атап чыгарылган китапларында да *("Әкияткә ышанмаучы малай", "Мәгариф" нәшрияты, 2003)* һ.б. әледән-әле саркып чыга. Милләт турында борчылуын белдерү өчен, һичшиксез, шагыйрь акыл-рух культурасы ягыннан шактый әзерлекле. Безнең әдәбиятта уңышка ирешергә теләгән шагыйрь күпмедер дәрәҗәдә тарихчы да булырга тиеш. Бу җәһәттән Газинур Морат, Ркаил Зәйдуллалар буыны, шөкер, халкыбызның үткәнен кайбер элгәрләренә караганда яхшырак белә. Шуңадыр алар милли тематикада үзләрен вәкаләтле итеп сизәләр.

*Җирдә һәркем, халкым, диеп,*
*Тиеш ләса бер яныр*га!..
("Ничәнче төн тынгы бирми...").

"Халкым" төшенчәсе шагыйрь Газинур Морат өчен төчелек төсмерендәге риторик сүз генә түгелдер. Дөрес, яхшатланып лаф орырга яратучы монафикъ затлар инде әлеге кыйммәтнен дә желеген суырып баралар. Ә менә Газинур—теле белән әйткәнне ине белән күтәрергә һәрчак әзер. Бер генә мисал... Соңгы сулышын алып яткан СССР империясе үзенең гаргарәсенә якынлашкан чакта, 1991 елның гыйнварында, Газинур Моратка Ригада ижат сәфәрендә булып кайтырга туры килде. Латыш халкының ирекен танклар ярдәмендә сытарга омтылу фажигасен безнең татар шагыйренә шаһит буларак күзәтергә язган икән. (Шушы канлы вакыйгалар тәэсирендә ул шигырьләр бәйләме дә язып кайтты). Илдәге сәяси вәзгыятьнең отыры киеренкеләнгән чагы. Шул исәптән Татарстанда да ижтимагый жанлану сизелә. Халык тулы мәйданнарда "Азатлык!" шигаре монарчы ишетелмәгәнчә көчле янгыраш ала. Дәүләт суверенитеты турындагы Декларацияне халык хуплавы белән ныгыту максатыннан, республикабызның рәсми-милли даирәсе кичекмәстән референдум оештыру хәстәрен күрә башлый. Мәскәү басымы көчәя. Житмәсә әле тиздән Русия президентын сайлау да үткәреләчәк. Мөстәкыйльлек юлыннан киткән Татарстан өчен мондый гамәлдә катнашу әзлеклелек кысасына сыямы? Юк, әлбәттә. Моның шулай икәненә тирәнтен инанган милләтпәрвәрләр төркеме, Ирек мәйданында чатырлар корып, 1991 елның маенда сәяси ачлык игълан итте. Мондый тәвәккәл адымга барган гаярьләр арасында шагыйрь Газинур Морат та бар иде. Ачлык тотунын да ярдәме тигәндер: Татарстанда Русия президентын сайлау ахыр чиктә барып чыкмады.



*Газинур Морат Ирек мәйданында чыгыш ясый. 1991 ел, 27 май.*

*Алып буйлы халык идек, юкса,*
*Яралган соң нинди каннан без?*
*Илсез калмас, телсез калмас өчен,*
*Ачлык тотар көнгә калганбыз...*

("Ачлык").

Әле сиксәненче еллар башында ук "Үзгәрешләр көтәм, үзгәрешләр", дип белдергән Газинур Моратның сәяси таләпләр белән игълан ителгән ачлыкка кушылуын да, бездә монарчы гайре табигый булып саналган шушы четерекле теманы жан-тән аша үткәреп күләмле әсәр язуын да мантыйкый яктан аңларга мөмкин. Поэманың фикри йөкләнеше нинди дер максат белән ризык-тәгамнән баш тарту хәлләренә генә корылмаган, шагыйрь ачлык төшенчәсенә гүяки зурайткыч пыяла аша карап, гомумиләштерүләр ясарга омтылган. Француз язучысы Альбер Камюның эпиграф рәвешендә бирелгән сүзләре дә әсәрнең идея юнәлешен алдан ук ачыклап куя шикелле: "Ирек хакына шаһит китү генә мәгънәгә ия була. Тик шул чагында гына кеше үзенең бөтенләй үк үлмәячәгенә ышана...".

Һәр аерым тема зур метафорага нигезләнсә, галәттә, ижатчы алдында тирән катламнар ачылып китә. Бу яктан "Ачлык" поэмасы да нәкъ менә шундый үзенчәлеккә ия. Эпик колачлы шигъри гомумиләштерүләрдә кайчандыр болгар бабаларыбызның урыс халкын ач үлемнән саклап калуы да, гасырлар буе кытлык-мохтажлыкта яшәгән илнең инде ачлыкка күнегеп бетүе дә, шулай ук ирланд егетләренең Лонг-Кеш төрмәсендә сәяси ачлык тотудан һәлак булуы да искәртеп үтелә. Юксыллыктан интегүче адәмнәрнең берсен-берсе ашауга кадәр барып житүләре исә шул заманнарның жинаятьчел хакимияте турында катгый нәтижәләр ясауга китерә:

"Ачлык-патша хужа тәхеткә...". Әсәрдә ачлык темасы, әйе, төрле яклап ачыла. Мең еллар ураза тоткан кавемнең ачлыкны жинелрәк кичерүен икърар иткәндәй, шагыйрь иман юлыннан тайпылмыйча баруның әжерле булуына да ишарә ясый.

Поэмада татар башын татар ашау яки ана телен табада кыздыру кебек кинаяле гыйбарәләр дә төп шигъри метафораның кинлеккә һәм тирәнлеккә тармакланып китүе өчен астарлы фикри җирлек вазифасын үтәгән. Ә менә җирдә барысын да ашап киләчәк куркыныч Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ образын автор хисап көнен күздә тоткан кисәтү рәвешендә искә алгандыр кебек... Менә шулай үткәннәр аша киләчәккә караш ташлаган шагыйрь газиз халкының әлегә бүгенгесе өчен жаны-тәне белән борчыла: чөнки, күпме сынау кичкән татар хәләл бәхетенә һаман ач килеш кала бирә.

Күренә ки, шагыйрь Газинур Моратның күпкырлы иҗатында милләт гаменә һәрдаим өстенлек бирелә. Гомумән, аның хәтта шәхес буларак фикер йөртүе үк шушы бөек уй-хис белән ашланган кук тоела: әдәби иҗатта да, иҗтимагый эшчәнлектә дә, көндәлек яшәештә дә... Бу яктан шагыйрь милләт җанлы зур шигъриятебезнең лаеклы варисы кыяфәтендә күз алдына килеп баса. Үтә сентименталь кебек күренгән мәхәббәт шигырьләрендә дә Газинур "сөюен йөрәккә күмгән" мәхзун булып кала. Үзенең мөкәммәл стилен барлыкка китергәндә дә ул милләт мәнфәгатен алга сөргәндер төсле: инде әйтелгәнчә, газиз халкына хезмәт итүче әдипнең язу рәвешендә ана телен саклау җаваплылыгы да истә тотылырга тиеш.

Кайбер нәтиҗәләр ясап әйткәндә, һәрдаим камиллеккә омтылып иҗат итүендә дә аның чын талантларга хас сыйфаты чагыла. Шагыйрь төрле жанрларда бердәй осталык күрсәтә. Һәрбер шигъри әсәре тематика, шәкел-үлчәм, мелодика җәһәтеннән аерылып тора. Каләм әһеленең предметны белүе, гадәттә, төзүче материалының ныклыгына тиңләнә. Бу уңайдан Газинур Моратның теманы тирәнтен өйрәнеп язуы аның күздән кичерелгән "Ачлык" исемле поэмасында күренде инде.

Кайбер көнүзәк мәсьәләләр көннең үзедәй—үлчән. Шагыйрь андый узгынчы вак-төяк темалар белән алай артык мавыкмый, алынган очракта да аларның иртәгәсе көнгә караган мәгънәсен табуга ирешә... Кыскасы, Газинур Морат элгәрләреннән өйрәнә алырдайны яхшы итеп үзләштергән һәм әдәбиятыбызда үзенчәлекле урынын таба алган шагыйрь булып күзаллана. Хәер, остазларының зарури йогынтысын ул үзе дә таный, шуның өчен аларга рәхмәтле икәнен дә сиздерә:

*Алардан без гаять тә*
*Күпне алабыз.*
*Үзебезне тапкач кына*
*Үзебез булып калабыз.*
("Үз-үзенә...").

...Миңа бервакыт Башкортстанның халык шагыйре Нажар Нәҗминең Газинур Моратка язган хатын укырга туры килде. Чит хатлар белән кызыксыну гадәтем юк-югын, әмма монысында минем исем дә телгә алынган иде... Каләмдәшем хакындагы бәяләмә сүзләре игътибарымны аеруча җәлеп итте. "Хөрмәтле Газинур энем,—дип башлана 1999 елның 15 гыйнварында язылган әлеге хат.—Мин синең "Жир хәтере" исемле китабыңны укыгач та, синең хакта язарга "телем кычытып" тора иде. Менә хәзер "Түбә"не укыгач, тешемне "кайрап" куйдым. Яшьрәк чакта андый эшләр тиз эшләнә иде, хәзер энергия житенкерәми. Китабың уйландыра, талантың һәр шигырьдән чәчрәп тора. Менә шуларны әйтеп бирергә көч җитәрме икән, дип уйланып торам...".

Яшьрәк буын татар шагыйрьләренә карата аеруча хәерхаһлык күрсәтеп яшәгән аксакалыбыз, кызганыч, ихласлык белән белдергән әлеге теләген тормышка ашыра алмыйча китеп барды. Гомеренең соңгы елларында ул чир-сырхау эзәрлекләвеннән арынмады. Кызык, таланты һәр шигыреннән чәчрәп торган яшь каләмдәше турында әдәбиятта ат уйнаткан олуг шагыйрь ничек язар иде?! Хәзер инде аның әйтеп бирергә теләгән сүзләрен безнең колакларга фәрештәләре дә пышылдап җиткерә алмас. Әмма шулай да күңел сизенә, безнең күпчелек фикерләребез авыздаш булыр иде: Газинур Морат—һичшиксез, элгәрләре кайтавазын көчәйтүче талантлы шагыйрьләребезнең берсе.

*Таҗи Гыйззәтнең тууына 110 ел*

**Казбек Гыйззәтов,**
**философия фәннәре докторы**

# ХАЛЫК ТОРМЫШЫН ЯЗДЫ

Татар совет әдәбияты классигы, артист һәм режиссер, оста оештыручы, күренекле җәмәгать эшлеклесе Таҗи Гыйззәт 1895 елда Баржы-Умга авылында *(хәзерге Әгерҗе районы)* жирсез крестьян гаиләсендә туа.



Таҗи Гыйззәтнең атасы Кәлимулла, 14 яшеннән алып, солдатка киткәнче, татар, рус, удмурт байларына батрак хезмәтендә йөри. 1893 елда урта хәлле крестьян кызы Фатыйха белән никахлаша. 1895 елдан алып 6 ел солдатта хезмәт итә. Аннан кайткач 4-5 ел заводта эшли. Шулай чит җирләрдә русча укырга-язарга өйрәнә.

Авылга кайту Кәлимуллага шатлык китерми, ана "килмешәк" дип җир бирмиләр, күп балалы гаилә ачлы-туклы яшәргә дучар ителә. Кәлимулла, характеры белән кайнар кеше буларак, байлар белән ярлылар арасындагы төрле конфликтларда катнаша (рус телен белүе аңа җәберләнгән, кагылган кешеләр исеменнән "прошение"лар язарга мөмкинлек бирә, аны тылмач итеп тә чакыралар). Ләкин үзен, бояр урманын кисүдә гаепләп, төрмәгә утырталар. Таҗи Гыйззәт гаиләдә иң олы бала булганлыктан, тормышның төп авырлыгы аның җилкәсенә төшә.

Таҗи Гыйззәт "Тәрҗемәи хәлем" дигән язмасында бала чагын искә төшереп түбәндәгеләрне язган: "Баржы-Умга авылында урак урмаган, җир сөрмәгән, ашлык сукмаган, урман кисмәгән, йөз суларым түгеп, ярдәм сорашмаган йортлар бик сирәк булгандыр. Шунын өстенә, Бишер, Усау исемле рус авылларына да барып эшләргә туры килә иде. Ләкин без һаман ач, ялангач идек" *(Гыйззәтов К. Таҗи Гыйззәт.—Казан, 2000.—10 б.)*.

Таҗи мәктәп яшендә җәйләрен байларга эшли, кышларын мәдрәсәдә кизү, мич ягучы, җыештыручы булып хезмәт итә. Шул ук дәвердә мәдрәсәдә аз-маз белем алуга да ирешә. Буби мәдрәсәсен тәмамлаган Габдулла Маннапов исемле укытучы балаларны рус теленә дә өйрәтә. Таҗи, укуга сәләтле малай булганлыктан, укытучы аңа кечерәк сыйныфларда дәрес алып баруны тапшыра. Ләкин Таҗи мәдрәсәдә укуын дәвам иттерә алмый, эш эзләп читкә чыгып китәргә мәҗбүр була. "Бераз үсеп алгач, 1911 елдан башлап, Гөлширмә, Бондюг, Иж, Воткинск заводларында эшкә йөри башладым",—дип яза Т. Гыйззәт. "Ул заводларда грузчик, җир казу, утын кисү, таш вату кебек иң авыр эшләрне тиеннәр бәрабәренә эшләргә туры килде. Ике-өч ел шулай ярым батрак, ярым сезон эшчесе булып, шәһәр белән авыл арасында йөргәннән соң, 1913 елны Иж заводына эшкә кереп, бер тоташтан алты ел шул заводта эшләдем",—дип искә ала ул яшьлек елларын *(Таҗи Гыйззәт // Татар совет әдәбияты тарихы. Очерклар.—Казан, 1960.—704-705 б.)*.

Таҗи Гыйззәт Октябрь революциясен шатланып каршы ала. Ул сәяси эшләргә

тартыла, укый-яза белмәгән эшчеләрне газета мәгълүматлары белән таныштыруны үз өстенә ала. Октябрь революциясе биргән шартларда заводта драмтүгәрәктә дә катнаша башлый.

1919-1920 елларда ул—Кызыл Армия сафында. Анда үзе яратып өлгергән "театр уйнау" эшен дәвам иттереп, драмтүгәрәк оештыра. Аның бу сәләтен күреп, Самарада Идел аръягы хәрби округының Политуправлениесе тарафыннан оештырылган драма студиясенә укырга җибәрәләр. Студияне тәмамлаганнан соң труппа составында Оренбургка китә. Ләкин труппа озак яшәми. Ул таралганнан соң, Урта Азиядә мәгариф органнарында хезмәт итеп ала. 1922 елны ул Казанда Татар дәүләт театрында артист булып эшли башлый. 1923-1925 елларда Ульяновск шәһәрендә, 1925-1928 елларда Алабугада төрле клуб оешмаларында эшли. Анда яшьләрдән театр труппасын төзи, спектакльләр куя, үзе баш рольләрне башкара. 1928 елда Мәскәү татар театрында эшли башлый. Ул таркалганнан соң 1929 елны янадан Казанга кайта, Татар дәүләт академия театрына эшкә керә. Т. Гыйззәт 1950 елга хәтле—артист. Шушы театр сәхнәсендә ул бернична дистә роль башкара. Шулар арасында—көнбатыш илләр драматургларының әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә: Монтано ("Отелло"), "Роллер" ("Юлбасарлар") h. б., рус классикасы буенча куелган спектакльләрдә: Клещ ("Тормыш төбендә"), Почтмейстер ("Ревизор"), Синцов ("Дошманнар"), Доктор ("Варварлар") h. б., татар спектакльләрендә: Закир ("Бәхетсез егет"), Кузнецов ("Томан арты"), Хәлил ("Галиябану"), Булат ("Наемщик"), Суфый ("Ил"), Орлов ("Чаткылар") Әхтәри һәм Земский начальник Твардовский ("Ташкыннар"), Шәйхезаман ("Кыю кызлар"), Әхтәмҗан ("Бишбүләк"), Ярул ("Мактаулы заман"), колхоз председателе Шәйхетдинов ("Фамилиясез тимерче") h. б. образлары тамашачы күңелендә аеруча истә калалар.

Бу елларда Т. Гыйззәт күренекле драматург буларак танылa. 30-40 елларда аның әсәрләре Татар академия театры репертуарында төп урынны били.

Таҗи Гыйззәт—37 драма әсәренең авторы, Язучылар союзы әгъзасы, театрның худсовет әгъзасы, Союзда драма секциясе житәкчесе, күп еллар дәвамында "Совет әдәбияты" журналының редколлегия әгъзасы. Ике тапкыр орден белән бүләкләнә. 1939 елда ТАССРның, 1940 елда "РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе" исемнәрен ала. 1942—1949 елларда Татар совет Язучылары союзының житәкчесе итеп сайлана, киң планда җәмәгать эшлеклесе булып танылa.

Таҗи Гыйззәтнең нәфасәти карашлары гади һәм тотрыклы. Аныңча, гүзәллек белән ямьсезлек башлыча чынбарлыкның үзендә. Таҗи Гыйззәт тормышның матур якларына сөенә, яман яклары аны борчый, һәм ул әлеге кичерешләрне әсәрләрендә дә чагылдыра. Сәнгатьнең асылы, аның карашынча, чынбарлыкның образлы шәкелдә чагылышы, ә сәнгатьнең төп вазифасы—халыкка, аның мәнфәгатьләренә хезмәт итү. "Минем уйларым һәм хисләрем—халык белән",—дигән ул үзенең бер язмасында.

Таҗи Гыйззәт—сәнгатьнең халыкчанлык принцибын киң планда чагылдырган әдип. Ә халыкчанлык нинди принципларны күздә тота соң?

Таҗи Гыйззәт карашы буенча, язучы иҗатының төп предметы итеп үз халкының тормышын алырга тиеш. Аның фикеренчә, язучы, гомумән сәнгатьче, әсәрнең образлары һәм аның сюжеты өчен гел башка ("әллә кайда, әллә кайчан" булган) илләрне, аларда катнашкан геройларны сайлый икән, ул инде үз халкының тормышыннан читкә тайпылган дигән сүз. Аны үзе яши торган илдәге катлаулы каршылыклар кызыксындырмый, яисә ул аларны күрми, күргән тәкъдирдә аларны сурәтләүдән кача булып чыга...

Т. Гыйззәт бу карашны үз тәҗрибәсеннән чыгып белдерә. Ул 20 нче еллар башында "Каһәрле мөһер" исемле трагедия язган була. Әсәр—тарихи шәхес Бабур хан *(XV—XVI гасыр)* тормышыннан алып иҗат ителгән. Кыскача гына әйткәндә, сюжет түбәндәге вакыйгалардан тора. Бабур хан бишектәге улының кулына мөһер басып, аны калдырып Фирганәдән (шәйбаниләр кысрыклавы нәтиҗәсендә) качарга мәҗбүр була. Күп еллар уза. Бабур Һиндстан жирендә дә хан дәрәҗәсенә ирешә. Бервакыт аңа: "Синең кызың читтән килгән егет белән гыйшык тотыша",—дигән хәбәр житкерәләр. Бабур хан, ачуга килеп, әлеге егетне тотып башын кисәргә боерык бирә. Боерыкның үтәлгәнен белү өчен хан егетнең гәүдәсен күрергә килә һәм шунда үзе калдырган мөһир буенча җәза алган яшь егетнең үз улы икәнлеген төшенә.

Әлеге хәл Бабур хан өчен коточкыч трагедия була, әлбәттә...

Бу әсәр 20 нче еллар башында Сембер шәһәрендә языла, һәм аның даны әллә кайларга барып житә. Трагедияне күп шәһәрләрдә сәхнәгә куялар, бар жирдә дә ул зур уңыш белән бара. Ләкин әсәрнең кульъязмасы югала. Тажи Гыйззәт күп еллар узгач, үзенең мемуарларында түбәндәгене яза: "Шуннан соң бу әсәрне мин үзем бер жирдә дә куймадым һәм уйнамадым. Хәтта ул минем үземдә саклана да алмады. Бүгенге көнне үземдә караламасы да юк. Әллә инде Мәскәү татар театрында калды, әллә Академия театрында югалды—исемдә түгел. Бу инде ул еллардагы ханнар, пәйгамбәрләр, әүлияләр тормышыннан сәхнә әсәре язу чиренә ияреп эшләнгәндер. Бу теманы мин яңадан кабатламадым һәм яхшы иттем" *(Тажи Гыйззәт. Әсәрләр. Дүрт томда. 4 нче том.—Казан, 1978.—259 б.).*

Тажи Гыйззәтне бу югалту ижат принциплары турында уйлануга этәргән. Шуннан башлап ул теге яки бу язучының үз ижатын бары тик "әллә кайчан, әллә кайда" булган вакыйгаларга нигезләвен тәнкыйть күзлегеннән бәяли торган булган. Ә Тажи Гыйззәтнең үз әсәрләрендә—татар халкының тормышы, шушы тормышның катлаулы каршылыклары сурәтләнгән. "Наемщик", "Ялкын", "Ташкыннар", "Чаткылар", "Мактаулы заман", "Алсу таң"—гомумән, барлык әсәрләрендә халык массасы, аның мәнфәгатьләре, аның яхшырак тормыш өчен көрәше үзәккә куелган.

Сәнгать әсәренең халыкчанлыгы өчен тагын бер таләп—халык тормышын белеп эш итү. Югыйсә, кайбер язучылар халык тормышын чагылдырам дип әйтеп, аның турында алдан уйланган стереотиплы схема, газета материалларыннан чүпләнгән фактлар белән генә чикләнәләр, ә халык катламының бүгенге көндә нинди проблемалар белән яшәгәнен белмиләр дә. Бу яктан Т. Гыйззәтнең бер белдерүе кызыклы. Узган гасырның 30 нчы елларында авылда күмәк хужалыклар төзелә башлый, авыл тормышына күп төрле яңалыклар килә, бигрәк тә ул крестьян психологиясендә чагылыш таба. Ләкин ничек?.. Моның өчен язучыга газета мәкаләләре белән таныш булу гына житми. Үзгәрә башлаган авылның үзендә яшәп карау, аның кешеләре белән тыгыз аралашу тәжрибәсе булуы кирәк.

Тажи Гыйззәт үзенең "Колхоз—минем ижат мәктәбем" дигән мәкаләсендә түбәндәгене яза: "Быел мина ТДАТның колхозларга чыгарылган труппасы белән 8 районда, 60 авылда булырга туры килде. Без—язучылар, артистлар—шәһәрдә торып, газета аша пьесалар язып һәм сукыр көенчә авыл типларын уйный идек. Авылдагы тормышны, социаль үзгәрешне, элекке аерым хужалык, хосусый милекчелек крестьяныннан яңа кешеләр туып килгәнен күз белән күрми идек" *(Т. Гыйззәт. Колхоз минем ижат мәктәбем // Совет әдәбияты.—1933.—N 8-9).*

Тажи Гыйззәт жәйге ял вакытларын күбесенчә республика авылларында уздыра, крестьян тормышын ныклап өйрәнә. Язучы авылдагы күренешләрне, яңа кешеләрне, аларның уй-фикерләрен жентекләп өйрәнеп, мона хәтле колхоз темасына язылган башка әсәрләрдән шактый үзгә булган "Мактаулы заман" *(1935)* әсәрен ижат итә. Бу әсәргә колхозчылар тарафыннан белдерелгән бәяләр драматургның үзе билгеләгән югары таләпләргә жавап биргәнлеген күрсәтә.

Сәнгатьтә халыкчанлык принцибы язучының, гомумән сәнгатьнең, халык массасына аңлаешлы тел белән ижат итүен күздә тота. "Тел" дигәндә бу сүзнең киң мәгънәдә алынуы күздә тотыла. Мәсәлән, музыка теле, сурәтле сәнгать теле, сәхнә теле һ. б. Әдәбиятта да ул фәкать кешеләрнең сөйләшү теленә генә кайтып калмый. Матур әдәбият теле ул—гомумән чагылдыру чаралары да (чагыштырулар, метафоралар, символлар һ. б.). Шулай да "әдәби тел" дигән нәрсә бар. Язучының теле киң укучыга таныш булу гына түгел, ул аңа нәфасәти ләззәт бирә алырлык та булырга тиеш. Моның өчен язучыга үз халкының телен бик әйбәт белү кирәк. Язучының лексикасы бай булуы, фонетик, морфологик кагыйдәләрнең даими рәвештә үтәлә баруы, жөмлә төзелешенең (синтаксисның) ыспайлыгы һ. б. жиренә житкерелгән булырга тиеш. Шуның өстенә, персонажларның теле—газет теле түгел, һәр геройның "үз теле" булырга тиеш, чөнки һәр конкрет затның телендә аның характеры чагыла.

Тажи Гыйззәт телгә карата куелган таләпләрен үзенең әсәрләрендә тормышка ашыра. Ә бу мәсьәләдә үзенең нәфасәти карашларын ул теоретик девиз рәвешендә белдергән: "Без, язучылар, халыкны матур итеп сөйләргә өйрәтергә тиешбез" *(Гыйззәтов К. Тажи Гыйззәт.—Казан, 2000.—4 б.).*

Т. Гыйззәт сәнгатьтә халыкчанлык принцибын милли үзенчәлек, милли характер күренешләре белән дә тыгыз бәйләп гамәл иткән язучы. Бу күренешләргә Таҗи Гыйззәтнең нәфасәти карашлары түбәндәге сүзләр аша әйтелгән: "Драматургиядә милли аерымлыкларны кайбер тәнкыйтьчеләребез "натурализм" дип бәялиләр. Бер милләтнең хосусый аерымлыкларын күрсәтү шул халыкның фәкать тормышта булган гореф-гадәтләрен, дөньяга карашларын... чагылдырганда гына мөмкин...

Галиәсгар абыйның самодур картлары, комсыз байлары үзләренең начар яклары белән фәкать татар феодализмының калдык экспонатлары булып күз алдына басалар. Шулай ук Шәриф Камалның йомшак табигатьле, керсез күңелле татар хезмәт ияләре... (халыкның) иң яхшы сыйфатларын, милли гореф-гадәтләрен, милли характерын үзләрендә чагылдырулары белән безгә якыннар. Син аларны немец итеп, яисә англичан итеп тә үзгәртә алмыйсың. Чөнки алар гомумкешелек идеалларын чагылдырган татар халкының милли геройлары..." *(Гыйззәт Т. Милли аерымлыклар турында // Социалистик Татарстан.—1975.—14 сентябрь).*

Нәфасәтлек, бер яктан караганда, объективлыкка ия булса (әйтик, табигатьнең гүзәллеге, яшь кызның чибәрлеге һ. б.), икенче яктан, аңа субъектив фактор хас (әйтик, төрле халыклар, төрле сыйныфлар вәкилләре чынбарлыкның объектив сыйфатларын бәйләүдә төрле караштa булулары мөмкин). Субъектив фактор традицияләр һәм новаторлык мөнәсәбәте яссылыгында да күренә.

Милли традицияләргә ихтирам, аларны дәвам иттерү һәм (шул ук вакытта) яңа, объектив таләпләрне искә алып үстерү, ягъни новатор булу—бу сәнгать өлкәсендәге диалектик каршылыкларның берседер. Таҗи Гыйззәт әлеге каршылыкның зарурлыгын әйбәт тоя һәм тирәнтен аңлый торган булган. Мәсәлән, Галиәсгар Камалга (үлүенә 5 ел тулу уңае белән), Шәриф Камалга (үлүе мөнәсәбәтендә), шулай ук Кәрим Тинчуринга багышланган мәкаләләрендә һәм истәлекләрендә ул аларның иҗади казанышлары алдында баш ия. Бигрәк тә ул үзенең турыдан-туры укытучысы Кәрим Тинчурин традицияләренә үз иҗатының якынлыгы хакында әйтә: "Миңа Тинчурин школасы белән барасың, Тинчурин алымнарын кулланасың, диләр. Кәрим ага минем артистлык ягыннан гына түгел, драматург ягыннан да остазым,—ди Т. Гыйззәт.—Мин башка драматургларга да аңардан өйрәнергә, аның яхшы якларын кулланырга киңәш бирер идем. Ул—тел остасы, образлы җөмләләр мастеры һәм театрны бик нык белә торган язучы" *(Гыйззәт Т. Бәхетле, шатлыклы чынбарлыгыбызны дөрес чагылдырыйк // Совет әдәбияты.—1936.—N 4).*

Ләкин Т. Гыйззәт К. Тинчурин иҗатына, ягъни татар театры өлкәсендә үзенә хәтле традицияләргә, сукыр рәвештә иярүче булмаганлыгын күрсәтә. Югарыда китерелгән чыгышында К. Тинчурин әсәрләренә хас кайбер кимчелекләрне дә атый: "...аның әсәрләрендә,—ди ул—байтак вакытта сюжет ярлылыгы, вакыйгаларның куе булмавы да күренә. Мондый вакытта ул шушы кимчелекләрен матур сүзләр, кызыклы эпизодлар белән шомартып, тамашачыны ялыктырмый тотып тора" *(шунда ук).*

Ләкин эш анда гына да түгел. Таҗи Гыйззәт кайбер язучылар тарафыннан халыкның этнографик үзенчәлекләрен күрсәтү белән мавыгып, аның социаль омтылышларын ачмый калдырулары хакында әйтә. "...Кайбер язучылар авыл тормышыннан алып язылган драма әсәрләрендә кыз белән егет арасындагы мәхәббәтне төп тема итеп алалар да шул чорның политик, экономик шартларын томалап калдыралар... Авыл яшьләрен сыйнфый көрәштән читтә торучы, бөтен гомерләрен җырлап-биеп үткәрүче аңсыз, надан яшьләр итеп күрсәтәләр.

...Икенчедән, безнең татар артистлары... авторларның ялгышларын тагын да күпертеп уйнап килделәр... Мин бу ике принципиаль мәсьәләдә җавап бирү нигезендә "Яшь йөрәкләр" *(Ф. Бурнаш пьесасы—К. Г.)* күрсәтә алам. Шулай ук... кайбер башка әсәрләрдә дә крестьян балалары баштан ахырына хәтле уен-көлке, кызлар белән күңел ачучы, үз тормышларыннан риза булган, шат, төрле кызыклар эшләп йөрүче яшьләр итеп күрсәтелә. Ул гына да түгел, аларның сугышка китү һәм башка моментлары да комедия рәвешендә бирелә". *(Гыйззәт Т. "Ташкыннар" әсәре турында. Таҗи Гыйззәт. Әсәрләр. Дүрт томда. 4 нче том. 230 б.).*

Таҗи Гыйззәт кайбер татар язучыларының этнографик моментлар белән чиктән тыш мавыгу тенденциясенә социаль мотивларны каршы куя. "Ташкыннар" әсәрендә,—ди ул,—хезмәт халкының узганда булган кара көне, шул авырлыкларга чыдаша алмыйча, үз кулы белән сугышып алган Бөек Октябрь революциясе уңышы күрсәтелә. Минем

хезмәтем... үткәндә булган авыр тормышыбызны дөрес һәм чынбарлыкны тулысы белән художество образлары аша бирә белүемдә..." *(шунда ук).*

Тажи Гыйззәт иҗаты үзенчәлеген һәм аның татар драматургиясендә электән килгән традицияләрне дәвам иттерүе белән бергә новаторлыгын Азат Әхмәдуллин түбәндәге сүзләр белән анлата: "Т. Гыйззәт татар сәхнәсендә М. Фәйзи һәм Ф. Бурнаш иҗатларыннан башланган крестьян образларын яңа югарылыкка күтәрде. Бигрәк тә ике яссылыкта. 1) Крестьянның сыйнфый иҗтимагый азатлыкка омтылышын сурәтләүдә, крестьянның авыр тормышын күрсәтүдә. 2) Болар һәр икесе крестьянны—безне ашатучы, киендерүчене зурлау белән сугарылды, авылның гореф-гадәтен, этнографиясен оста гәүдәләндерү белән баетылды" *(Әхмәдуллин А. Тажи Гыйззәт куркак булмаган // Мәгариф.—1995).*

...Бөтендөнья сәнгате үзенең тарихи үсешендә төрле иҗади методларны куллануга ирешә. Конкрет чынбарлыкның асылын, аның типик хасиятләрен җыелмалы рәвештә чагылдыру ягын алганда, иң югары баскычны реализм методы биләп тора. Реализм методы нигезендә иҗат ителгән әсәрләр сәнгатьтә реализм юнәлешен тәшкил итәләр. "Реализм"—димәк, чынбарлыктагыча: гүзәлне—гүзәл рәвешендә *(аны гарипләтмичә, деформацияләүгә бирмичә),* иләмсезне—иләмсез рәвешендә сурәтләү, дигән сүз.

Реализм Борынгы Греция сәнгатьчеләренә дә таныш метод булган һәм ана тәнгәл атама да бар: "антик реализм". Реализм методы җирлегендә барлыкка килгән сәнгати юнәлешнең чәчәк атуы исә XIX гасырга туры килә. Ләкин бу чор реализмын да икегә аерып карау күзәтелә: көнкүреш реализмы (бытовой реализм) һәм социаль юнәлдерешле реализм (социально направленный реализм). Соңгысын социалистик реализм белән бутарга ярамый.

Татар драматургларының чынбарлыкны сурәтләүдә этнографик детальләр белән мавыгуларын, күрәсен, көнкүреш реализмы кысаларында карап була. Тажи Гыйззәт исә, шушы реализм алымнары белән чикләнмичә (аны тәнкыйть итеп) социаль юнәлдерешле реализм принципларын яклап чыга.

Аңлашыла ки, шушы принципларны тәнкыйть күзлегеннән бәяләгәндә язучы үзе ниндидер башка критерийлар белән эш итәргә омтыла. Һәм шушы яңа критерийлар, әйтергә мөмкин, язучының нәфасәти программасын билгели дә, аның иҗат процессы белән житәкчелек итә. Ул язучының башта фәлән төрле итеп (өстәнрәк, тирәнгә кермичә) уйланылган темага, образларга, коллизияләргә төрле "төзәтмәләр" кертергә, аларны шактый үзгәртүдә роль уйнарга мөмкин. Т. Гыйззәтнең кайбер әсәрләре өстендә кат-кат эшләвен, аларны конкрет тарихи чорның социаль-икътисади элементлары белән сугара баруын реализм методы кушуы буенча эшләү нәтиҗәсе дип карарга кирәк.

Ф. Энгельс: "Мин Бальзакның "Кешеләр комедиясе"н укып, хәтта икътисади детальләр ягыннан да шушы чорның барлык икътисадчылары, тарихчылары, статистлары язганга караганда күбрәк белүгә ирештем",—дигән *(Әсәрләр., Т. XXVII.—29 б.).* Бу—сәнгатьтә аналитик алым, реалистик метод гамәлендә кулланыла. Чын реализм әсәре башка методлар белән иҗат ителгән әсәрләрдән нәкъ шуның белән аерылып тора да: ул художество чаралары белән конкрет илнең, конкрет халыкның, конкрет чорда булган хасиятләрен нәкъ чынбарлыкның үзендәгечә, конкрет рәвештә ачып сала. Тажи Гыйззәт югарыда аталган әсәрләре өстендә кат-кат эшләгәндә шушы әсәрләрнең геройлары хәрәкәт иткән чорларның конкрет шартларын, аерым кешеләр һәм социаль төркемнәр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачуга басым ясый. Мәсәлән, "Чаткылар"да, "Талир тәңкә"дәгечә яратышу гына түгел, бәлки күп төрле социаль-сәяси проблемалар бар.

Авыл халкы белән Сабир Ишбулдин арасындагы конфликт та абстракт (берәүләре—"ярлы", икенчеләре—"бай") рәвештә генә түгел. Каршылык—заманча конкрет. Сабир бай, Столыпин реформасы ачкан мөмкинлекләрдән файдаланып, община җиренең иң яхшы өлешен үзенә умырып ала. Аннары крестьян халкын—кайсын алдап, кайберсен куркытып, юмалап, кайсысының кайчандыр алып торган бурычын түли алмавыннан файдаланып—юк бәягә генә иманаларын үзләштерә. Шулай итеп, әсәрдә тимерче Гаязның юлына төшкән көндәше—традицион сюжетлардагы кебек абстракт "бай малае" гына түгел, ул конкрет тарихи чынбарлыкның конкрет социаль-сәяси сыйфатларына ия булган конкрет "бай малае", конкрет фигура.

Бу—реализм. Шушы метод турында сүз йөрткәндә аны ялгыш аңлату да еш кына очрый. Янәсе, реализм ул чынбарлыкны "дөрес чагылдыру" методы ("Правдивое, объективное отражение действительности"). Болай әйтү фәнни яктан тәгәл түгел. Әгәр дә без реализмның асылын "дөрес, объектив чагылдыру" дип бәялибез икән, ул вакытта башка методлар (әйтик, классицизм яисә романтизм) "дөрес, объектив чагылдырмый" дигән нәтиҗәгә урын калдырабыз. Чынлыкта исә реализм ул чынбарлыкны аналитик алым белән чагылдыру. Классицизмда, шулай ук романтизмда да ул бик аз күзәтелә. Фонвизинның "Җитлекмәгән егет" ("Недоросль") пьесасында һәр персонаж ниндидер идея тупламасы буларак сурәтләнә. Шушы персонажларның исемнәре генә дә аларның төп сыйфатын ача: Правдин, Софья, Милон, Скотинина, Вральман һ. б. Бередә персонажларның психологик кичерешләренә, шулай ук аларны чолгап алган икътисади детальләргә (аналитикага) әллә ни урын бирелмәгән. М. Горькийның "Давыл хәбәрчесе", шулай ук Һ. Такташның "Җир уллары" әсәрендә дә—шул ук хәл: аналитик алымга урын калмаган. Әгәр дә реалистик әсәрләрдә дөреслек бар икән, ул башлыча, нәкъ аналитик алымның нәтиҗәсе дип каралырга тиеш. Аналитик алым, Энгельс әйткәнчә, әсәрне икътисади (һәм, әлбәттә, башка әһәмиятле) детальләргә бай итә дә.

Тасвирлана торган предметны аналитик алым белән конкрет (мөһим) детальләр аша бирү өчен, әлбәттә, күпне белергә дә кирәк. Таҗи Гыйззәт үзенең язмаларында нәкъ шуны игълан итә: "Ташкыннар" әсәре өстендә елга якын эшләргә туры килде. Чөнки авылның ярлы-батрак, урта хәлле крестьяннарының империалистик сугыш, февраль буржуаз-демократик революциясе аша Бөек Октябрь социалистик революциясенә килүләрен художество образлары белән бирү өчен күп укырга, шул заманны бик нык өйрәнергә... туры килде" *(Т. Гыйззәт. Әсәрләр. 4 томда. 4 нче том.—Казан, 1978.—231 б.).*

Шулай, Таҗи Гыйззәтнең нәфасәти принциплары сәнгать өлкәсендә реализм һәм аның конкрет чагылышы социалистик реализм юнәлешенә туры килә. Моның хакында күренекле театр белгече З. Кедрина язып чыккан иде. Ул "Ташкыннар" әсәре турында сүз алып барганда, бигрәк тә андагы күренешләрнең ышандыру сыйфатына басым ясый: "Укучы алдында,—ди ул,—татар авылының революциягә кадәрге тормышы шул хәтле ачык бирелә ки, әйтерсең лә әсәрне укучы гомер буе Биктимер гаиләсендә торган, аның дус-ишләре белән аралашкан, аның дошманнары белән көрәш алып барган" *(Кедрина З. Родня и враги Хамзабая // Октябрь.—1939.—N 10-11.—С. 324-325).*

Таҗи Гыйззәт 40 ка якын драма әсәре, күпсанлы рецензияләр, мәкальләр авторы буларак нинди нәфасәти идеалларга баш игән соң?

Башлыча шуны әйтергә кирәк, Таҗи Гыйззәт драматургиясен хаклы рәвештә уңай геройлар драматургиясе дип саныйлар *(кара: История татарской советской литературы. М., 1965.—488 б.).* Шулай, аның төп нәфасәти идеалын социаль кыйбласына тугрылыклы көрәш тәшкил итә. Аның әйдәп баручы персонажлары—гадәттә, алдынгы идеяле, халык мәнфәгате өчен көрәшүчеләр. Алар—көчле ихтыярлы, физик яктан куәтле, арыслан йөрәкле, хәтта "баш китәрлек" эшләр эшләп ташларга сәләтле кешеләр. Шундыйлардан: "Наемщик"та—Батыржан, "Ялкын"да—Каһарман (боларның исемнәре генә ни тора бит!), "Чаткылар"да—Рамай, "Мактаулы заман"да—котырган үгезне буйсындыручы бригадир Ногман, "Ташкыннар"да—Биктимер, Нургали, "Таймасовлар"да—Марат һ. б.

Таҗи Гыйззәт ир кешенең көчле холкына соклана. Аның уңай геройлары яшь коймый, сыкранмый. Мәсәлән "Ташкыннар"да Биктимер карт өстенә берничә сәгать дәвамында гына, берсе артыннан берсе—дөнья хәтле кайгы-хәсрәт килә. Ләкин автор Биктимерне сәхнәдә мескен рәвешендә күрергә теләми. Башкорт театры режиссеры Имашевка язган хатында ул, Биктимер ролен башкарганда аеруча сак булырга, образның героик пафосын югалтмаска, бу рольгә театрның иң көчле артистын куярга киңәш бирә.

Ә хатын-кызларда ул акыл, сабырлык, мөлаемлык сыйфатларын күрергә тели. Ләкин аның хатын-кыз персонажлары йомыкый түгелләр, алар—алдынгы принциплар өчен көрәшчеләр, кыю йөрәкле, тәвәккәл кешеләр. Гөлйөзем ("Наемщик"), Маһи ("Чаткылар"), Гөлчирә ("Ташкыннар"), Фәрхиназ ("Ялкын"), Бибкәй ("Кыю кызлар"), Гөләндәм ("Чын мәхәббәт"), Халидә ("Алсу таң") кебек

хатын-кызлар үзләренең батырлыклары, тәвәккәл эшләре белән арысландай егетләрдән һич тә ким түгел.

Тажи Гыйззәтнең тагын бер нәфасәти идеалы—ул фидакарь хезмәт кешесе. Бу идеал Тажи Гыйззәтнең күп кенә әсәрләрендә, бигрәк тә илебезнең совет чорын чагылдырган әсәрләрендә, алардагы геройлар эшендә үзен тапкан. Тажи Гыйззәт кешеләрнең иҗтимагый хезмәткә фидакарьлек белән карауларын конкрет социаль-икътисади шартлар белән бәйләп сурәтләргә омтыла. Һәм бу алым нигездә үзен аклый торган булган дип әйтәсе килә. Әлеге фикерне тамашачыларның "Мактаулы заман" спектакленә биргән бәясе житәрлек дәрәҗәдә исбатлый булса кирәк. Биредә матбугатта булган бер өзекне китерү урынлы тоела:

"Кичә, 26 нчы мартта, Арча районынын барлык колхозчыларыннан иң алдынгы социалистик игенчелек стахановчылары, ударникларыннан, укытучыларыннан 900 кеше, коллектив рәвештә, Тажи Гыйззәт иптәшнең "Мактаулы заман" пьесасын карарга Татар дәүләт академия театрына килделәр. Театрга килүче колхозчыларны татар совет язучылары, Татар дәүләт академия артистлары, "Кызыл Татарстан" вәкилләре һ. б. каршыладылар.

Арча поезды Казанга килгәннән соң митинг булды... Митингтан сон алар, сафка тезелеп, Казан урамнарыннан оркестр белән Татар дәүләт академия театрына килделәр... "Мактаулы заман"ны колхозчылар зур кызыксыну белән карадылар..."

"Кызыл Татарстан" газетасы битләрендә спектакльны караган колхозчыларның фикерләре дә басылган булган.

*"Тажи Гыйззәт иптәшнең "Мактаулы заман" исемле пьесасы мина бик ошады. Татар дәүләт академия театры шундый спектакльләр хәзерләп авылларга да чыксын иде. Моны колхозчылар бик яраттылар. Авылга кайткач бу спектакль турында башка иптәшләргә дә сөйләрмен."*

*Колхозчы Гарәфи Гафуров.*

*"Мактаулы заман" бик файдалы театр икән. Без картларны да дәртләндереп җибәрде... Колхозга кайткач, мин бу турыда колхозчыларга да сөйлим. Язгы чәчү эшендә дә тырышып эшләргә сүз бирәм."*

*Колхоз члены Хөснетдин Гәрәфетдинов.*

*("Кызыл Татарстан".—1936.—27 март).*

Күренә ки, колхозчыларның "Мактаулы заман" спектаклен каравы зур вакыйгага әверелгән. Моның сәбәбе шунда ки, әсәрдәге геройларның хезмәткә булган мөнәсәбәте колхозчы-тамашачыны шундый ук тырыш эшкә дәртләндергән булган. Менә нинди көчкә ия ул чын сәнгать әсәре!

Тажи Гыйззәтнең нәфасәти идеалы Ватаныбызны төрле дошманнардан саклауда батырлык күрсәткән патриотик хисләр белән янучы героик образларда аеруча гәүдәләнеш тапкан.

Бу планда бигрәк тә "Таймасовлар" әсәрендә карт эшче Таһир Таймасов, "Изге аманәттә" Донбасс шахтеры Гыйният гаиләләре, "Чын мәхәббәт"тә Дәуран белән Гөләндәм образлары характерлы.

Тажи Гыйззәт персонажларның эшчәнлеген конкрет тарихи шартлар белән бәйле булуына зур игътибар биреп иҗат иткән язучы. Аның әсәрләрендәге вакыйгалар илебез, халкыбыз кичергән конкрет тарихи чор шартларында бара. XIX гасырның 60 нчы елларыннан алып, үзе үлгәнче—XX гасырның 50 нче елларына хәтле, 90 еллык тарихи чор колачлана. "Наемщик"та крестьяннарның 1861 елгы патша Манифестына каршы күтәрелеше, "Ялкын"да 1878 елдагы тарихи вакыйгалар, "Чаткылар"да—крестьяннарның 1907-1910 нчы Столыпин реакциясе елларындагы хәле, "Ташкыннар"да—дәһшәтле һәм катлаулы 1914-1917 еллар, "Бишбүләк"тә—гражданнар сугышы еллары. Аннан инде—совет заманы...

Тажи Гыйззәт үз халкының, бигрәк тә татар крестьянынын, совет чорындагы уңышлары белән бергә, аның газабын, чишелә алмаслык каршылыкларын да сурәтли. Бу яктан караганда аның үзенә күп михнәтләр китергән (һәм сәхнәдә куелмый калган) "Алсу тан" драмасы характерлы. Ә дөньядан китү сәбәпле тәмамланмый калган "Туктаровлар язмышы" дип аталган драмасы ана, гомумән, зур "проблемалар" тудырырга тиеш иде, чөнки ул заманда андый әсәрнең басылуы да, куелуы да бик шөбһәле булды (драманың төп герое итеп "йодрык" белән генә эш итүче райком секретаре алына). Автор чынбарлыкның каршылыклардан торганлыгына инанып,

әсәрләрен дә каршылыкларга, кискен көрәшкә нигезләнеп иҗат итә. Алар, аның фикеренчә, сәнгатьнең төп эчтәлеге булып каралырга тиеш. Шунлыктан сәнгать белгечләре (дөресрәге, сәнгать өлкәсендә идарә иткән чиновниклар) арасында барлыкка килгән "конфликтсызлык теориясенә" ул кискен рәвештә каршы чыгучылардан була.

Таҗи Гыйззәтнең барлык әсәрләренең эчтәлеге көрәш коллизиясеннән гыйбарәт. Бигрәк тә татар халкының Октябрь революциясенә кадәрге тормышын чагылдырган әсәрләрендә урын таба ул хәл. Мисал өчен "Чаткылар"ны, "Ташкыннар"ны, "Ялкын"ны, "Бишбүләк"не һәм башка әсәрләрен алырга була.

Ә нишләп соң сәнгать әсәрендә каршы көчләрнең көрәшен чагылдыру шул хәтле мөһим? Моның сәбәбе ачык. Хезмәт ияләре үзләренең мәнфәгатьләренә бары тик кискен, аяусыз көрәш аркылы гына ирешә алалар.

Бу караш беренчедән, чынбарлыкның мантыйгын чагылдыра торган булса (көрәш—диалектиканың төп кануны), икенчедән, көрәш—изелгән хезмәт ияләренең, ягъни халыкның, изге максатларына ирешүе өчен бердәнбер чара ул.

Димәк, сәнгать әсәрләрендә көрәшне чагылдыру, аны үзәк коллизия итү сәнгатьнең шул ук халыкчанлык принцибын чагылдыра, дигән сүз.

Таҗи Гыйззәт, диалектика кануннарын истә тотып, каршылыкларның социалистик җәмгыятьтә дә хәрәкәт иткәнлеген онытмаган. Узган гасырның 40 нчы елларында сәнгать өлкәсендә конфликтсызлык теориясе барлыкка килеп, язучыларның иҗади эшенә зур комачаулык ясый башлаган иде. Т. Гыйззәт үзенең радиода ясаган бер чыгышында әлеге теория тарафдарларын тәнкыйтьләп болай дигән: "...Татарстан шартларында... конфликтсызлык теориясенең... яшәп килүен күрергә туры килә. Әлеге теориянең колы булучы тәнкыйтьчеләр, әдәбият, сәнгать өлкәсендә эшләүче иптәшләр: "бу—тормыштагыча түгел", "бу—характерлы түгел", "бу—типик түгел" дигән терминнар күзлегеннән чыгып, драма әсәрләрен тәнкыйть итеп килделәр. Күп вакытта аларның язмышларын да кире якка хәл кылдылар.

Шуның нәтиҗәсендә конфликтсыз, көрәшсез, фәкать унай якларны гына чагылдыра торган кызыксыз, коры риторикадан торган әсәрләр тудылар...

Сәнгатьтән, әдәбияттан тормыштагы яхшы яклары гына күрсәтүне таләп итү—табигатьтә, җәмгыятьтә булган каршылыкны, яңалык белән искелек арасындагы көрәшне инкяр итүгә кайтып кала" *(Гыйззәтов К. Таҗи Гыйззәт. Фикерләр. Истәлекләр. Хатлар. Бәхәсләр.—Казан, 2000.—Б. 114-115).*

Т. Гыйззәт киң диапазонлы язучы булган. Аның иҗади мирасында драматургиянең һәр жанры (драма, комедия, трагедия) үзенең гәүдәләнешен таба алган.

Таҗи Гыйззәтнең нәфасәти карашларын чагылдыруда музыка да зур роль уйнап килә. Татарда музыкаль драма Мирхәйдәр Фәйзинең "Галиябану"ыннан башланып, мөстәкыйль жанр рәвешендә 20 нче елларда Тинчурин һәм Бурнаш тарафыннан нык үстерелә. Ә татар музыкаль драмасының иң югары ноктасы "Наемщик" дип таныла, чөнки бу драмадагы образлар, сюжет коллизияләре композиторга үзенең талантын ачу өчен киң мөмкинлекләр бирә. Салих ага Сәйдәшевнең шушы хакыйкатьне тануы очраклы түгел, әлбәттә.

Җ. Фәйзи татар сәнгатендә дә музыкаль драма жанрының урыны, С. Сәйдәшевнең аеруча зур роле хакында сүз алып барганда түбәндәгене белдерә: "Наемщик"—Салих Сәйдәшевне ... мәңгеләштергән әсәр! Увертюрасыннан башлап ахыргача "Наемщик" та Сәйдәш күнеленең бөтен кыллары моңлана, дәртле йөрәк тибеше ишетелә, композиторлык таланты бөтен көченә янгырый. Әйтерсең лә халык көйләре чылбыры белән бәйләнеп куелган юрга, иске алымнар традициясе баганасыннан ычкына да, сөрелмәгән җирдән яңа юл салып чапкан. Рәхмәт Таҗи Гыйззәткә! Ул аны бу бәйдән ычкындырган" *(Фәйзи Җ. Халык җәүһәрләре. Күңелем кыллары.—Казан, 1987.—281-282 б.).*

Таҗи Гыйззәтнең башка драма әсәрләрендә дә ("Бишбүләк", "Ташкыннар", "Изге әманәт", "Чаткылар", "Чын мәхәббәт", "Алсу тан" һ. б.) музыкага билгеле урын бирелә. Ләкин бу юнәлештә аның шул ук күренекле композиторыбыз Җәүдәт Фәйзи белән берлектә (либретто авторы рәвешендә) иҗат иткән "Башмагым" әсәре татар сәхнә сәнгатендә аерым урын алып тора. Бу—татар милли сәнгатендә беренче музыкаль комедия иде.

Таҗи Гыйззәт драма әсәрләрендә музыканың ролен таныса да, аны һәр әсәргә

көчләп кертүне тәнкыйтьчел бәяли иде. Эш шунда ки, кайбер язучылар җыр-бию элементларын әсәрнең эчтәлек ягыннан буш, йомшак булуын аклау өчен генә кертәләр. Бу—татар театры сәхнәсендә күптәннән килә торган тенденция. Һәм ул тамашачыны интеллектуаль яктан тәрбияләүдә киртә булып тора. Чөнки халкыбызның аерым катлавы нәфасәти яктан түбән фикерли әле. Аларга театр залында күңел ачу да җитә. Артистларның кирәкме, кирәкмиме, җырлап, биеп алулары әлеге таләпләргә җавап бирә ала, әлбәттә. Ләкин театр сәнгатенең бурычлары шуна гына кайтып каламы соң?

Гомумән тамашачының нәфасәти зәвыкларын тәрбияләү җитди һәм читен проблема. Таҗи Гыйззәт моннан күп дистә еллар элек "Театр өч элементтан: драматургия, артист, тамашачыдан тора", дип язган иде *(кара: Кызыл Татарстан.—1939.—6 апрель).* Бу караш бүгенге көндә дә үзенең көчен саклый. Чөнки, ни дәрәҗәдә театр тамашачы зәвыгына йогынты ясый торган булса, шул кадәр тамашачы да театрга һәм драматургларга үзенең йогынтысын ясый тора.

Таҗи Гыйззәт бай тормыш юлы узган язучы. Аның сәнгать өлкәсендәге юлы сикәлтәле булса да, бормалы түгел иде. Ул, яшьтән авыр һәм катлаулы тормыш кичергән шәхес буларак, дөньяга карашына, үзенең социаль һәм сәяси программасына хыянәт итмәде. Халкыбызның атаклы композиторы Нәҗип Җиһанов әйтүе буенча, Т. Гыйззәт татар совет драматургиясе һәм театр сәнгатенә зур өлеш керткән шәхес булды. "Ләкин мин аның турында әдәбиятта җинел тормыш кичерде, дип әйтә алмас идем. Чын талант сынауларда, көрәштә ачыла",—дип язган иде олы композиторыбыз *(Гыйззәтов К. Таҗи Гыйззәт.—Казан, 2000.—223 б.).*

Таҗи Гыйззәт әсәрләре аның замандашларына гына түгел, соңрак яшәгән буын вәкилләренә дә зур тәрбияви йогынты ясап килде. Кеше күңелләрен эретеп җибәрә торган әсәрләре белән танылган һәм дөньядан иртәрәк киткән язучыбыз М. Мәһдиев үзенең авылда малай чагында Таҗи Гыйззәт әсәрләре буенча куелган спектакльләрдән алган тәэсирләре белән уртаклаша. "Ул кышны (Ватан сугышы алдыннан) авыл "Наемщик" белән генә яшәде. Авылда ул спектакльдән ике җыр, бер мәзәк калды. Җырлар: "Сау бул инде, минем туып-үскән илем..." һәм "Егет күңеле җилкенә..." Мәзәк: Иманкол мулланың ярлы крестьянга шәригатьне яшел тышлы һәм кызыл тышлы китап буенча аңлатуы..."

Тагын бер истәлек. Бусы—"Ташкыннар" драмасы турында.

"Ташкыннар", гомумән, бик тормышчан әсәр, ул—безнең халыкның тәрҗемәи хәле...". М. Мәһдиев авылында бу әсәр буенча да спектакль куела. Беренче пәрдәнең финалында Әхтәри староста туй мәҗлесенә килеп керә: "Патша хәзрәтләренең указы бар. Герман белән сугыш башланган!" дип бөтен залның йөрәген тетрәтте.

Дүрт ай узгач, безнең авылга телефонлы Сикертән авылыннан чапкын килде: "Совет хөкүмәтенең белдерүе бар: фашистик Германия безгә сугыш башлаган!"

Әхтәри, Басари, Нургали, Мирвәли, Мирхәйдәр, Биктимерне уйнаган егетләр шул ике-өч көн эчендә җырлап авылдан чыгып киттеләр...

Безнең күңелләрдә "Ташкыннар" драмасы ил, халык язмышының якты да аянычлы да, гыйбрәтле дә тарихы булып сакланып калды!" *(Гыйззәтов К. Таҗи Гыйззәт. Фикерләр. Истәлекләр. Хатлар. Бәяләр.—Казан, 2000.—287, 291 б.).*

Танылган татар язучысы һәм кыю йөрәкле җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлим: "Шигърияттә безне—Тукай, музыкада—Сәйдәшев, сәхнәдән безне Галиәсгар Камал һәм Таҗи Гыйззәт тәрбияләде",—дип язган иде *(кара: Аргамак.—1995.—N 9.—... б.).*

Гомумән, Таҗи Гыйззәт калдырган иҗади мирас күпләрне игелекле принципларда тәрбияләүдә мөһим роль уйнады, аның бу өлкәдәге әһәмияте кимемәячәк. Таҗи Гыйззәтнең нәфасәти карашлары татар сәнгатенең реалистик юнәлешендә, чын милли традицияләр нигезендә үсү юлында алга таба да мөһим роль уйнаячак дип ышанабыз.

Гәп Фән

Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***МИСАЛ***— **1**. Үрнәк, өлгә. **2**. Кебек, шикелле, төсле; охшаш. // *Гөнаһтан тәүбә итүче кеше гөнаһсыз кеше мисалында булыр.* **3**. Хисап дәресләрендә санлы мәсьәлә. Соңгысы русча санлы мәсьәлә мәгънәсендәге *пример* сүзенең калькасы булып, рус сүзе, үз чиратында, латинча *примус* сүзенә барып тоташа. *Прима, премьер* сүзләре дә шушы тамырдан. (Борынгы грек математиклары саннарны гади тапкырлашучыларга таркатып "уйнарга" яратканнар. Инде таркатып булмый торган гади саннар латинча *примус нумерус* дип атала (гарәпчәдә-*гадәде аслый*). Тора-бара шушы примус сүзе, мәгънәви үзгәрешләр кичереп, рус телендә *пример* (мәсьәлә, проблема) сүзенә әйләнеп калган.) Исмәгыйль Гаспринскийның 1897 елда басылып чыккан башлангыч арифметика китабы "Эсап вә мисаль" дип атала. Ихтимал, санлы мәсьәлә мәгънәсендәге "пример" сүзенең татарчага калькасы беренче тапкыр шушы дәреслектә кулланылгандыр.

Күплек саны шәкеле — *әмсаль*.

***МИСВӘК*** *г.* — Теш чистарткыч. Очы йомшатып чукланган таякчык, шырпы. *Тасвик (тәһарәте)* вакытында кулланыла. Карл Фукс Казан татарларының Бохарадан алып кайткан әче тәмле кыска агач таякчык белән тешләрен, аңкауларын ышкуы турында яза (XIX гасырның беренче яртысы). Ул аны *мисвәт-агач* дип атый.

Мисыр хәлифәсендә Пәйгамбәрнең таягы, мисвәге, башмагы, чәч һәм сакал бөртекләре әманәт булып сакланган. Төрекләр, сугышта гарәпләрне җиңгәч, ганимәт маллары белән бергә, бу ядкярләрне дә Истанбулга алып кайталар һәм, көмеш сандыкларга салып, Солтан мәчетенең хәзинәләр бүлегенә куялар.

***МИШӘР КАРАВЫЛЛАРЫ*** *тар.* — Элек Пенза губернасы җирләрендә йомышлы мишәрләр һәм украинлылар тарафыннан саклана торган ныгытмалар тезмәсе (линиясе), засекалар. Бу линияләр Мәскәү хакимиятләре тарафыннан илнең көньяк-көнчыгыш чикләрендә Кырым татарларыннан һәм нугайлардан саклану өчен, шулай ук башкорт, кыргыз, калмык яуларына һәм барымтасына каршы урман егып төзелгән.

***МИШӘРӘК*** *тар.* — Йомышлы мишәрләр (мәс., Златоуст татарлары арасында). Рус телендә — *мещеряк.*

***МОВӘЛЛӘД*** *г.* — Урта гасырларда Испаниядә Ислам динен кабул иткән җирле халык (иберийлар, шулай ук вестготлар) белән гарәпләрдән барлыкка килгән мөселманнар. Европа телләрендәге (шулай ук рус телендәге) *мулат* сүзе шушы "мовәлләд" сүзеннән килеп чыккан.

***МОНАФИКЪ, МОНАФЫЙК*** *г.* — Ике йөзле, эчкерле кеше. // *"Монафыйк — Ислам диненең бер ишегеннән кереп тә, икенче ишегеннән чыгып китүче."*

*Монафикълар камап һәр дүрт ягымны, Күрәлмим мин кояшым һәм аемны.* Тукай.

*Монафикун* ("монафикъ"ның күплек саны шәкеле) — Йасриб (Мәдинә) шәһәре халкының Исламны кабул итеп Мөхәммәдне пәйгамбәр дип таныганнан соң, аның йогынтысы үсүдән куркып, аңа каршы мәкерле эш алып барган өлеше. Коръәндә аларга ләгънәтләр яудырыла.

Хатын-кыз җенесеннән булса — *монафика.*

---

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2004 елның 1нче санында.*

***МОРЖА*** – Р.Әхмәтьянов бу сүзнең көнбатыш төркиләре өчен уртак булуын (*мурҗа, мури*-моржа; мичтәге төтен юлы) искәртеп, аны фарсы телендәге *мурича* "моржа, төтен юлы, төрле торбалар" сүзенә илтеп тоташтыра. "Татар теленең диалектологик сүзлеге"ннән (1969, 1993) "мурҗа" һәм "мөрҗә" сүзләре русча *мурья* сүзеннән алынган булып аңлашыла. Чыннан да рус диалектында мондый сүз бар (булган), мәс., В.Дальнең "Толковый словарь живого великорусского языка" сүзлегендә аның "труба" мәгънәсе *каз.* (ягъни Казан ягы) искәрмәсе белән теркәлгән. Шуңа күрә *мурья* сүзе рус теленә татар теленнән килеп кергән дип фараз итү нигезле сыман. В.Даль бу сүзнең мәгънәсен аңлатканда "алебастр чыгару өчен шахта" дип тә өсти. Бездә Югары Ослан якларында, Печищи авылы тирәсендә акташ чыгару, известь (кирәч) һәм алебастр яндыру бик күптәннән килә һәм Печищи атамасы да тау битләвендәге мәгарә-мич атамасыннан алынган (русча *пещера* сүзе белән чагыштырыгыз). Ихтимал, анда татарлар русларга кадәр үк төзелеш ташы чыгару һәм кирәч яндыру белән шөгыльләнгәннәрдер, ә таш чыгару һәм яндыру базлары "моржа" дип аталгандыр. Ул чагында русча "Печищи" атамасының татарчадан калька гына булып чыгу ихтималы бар.

"Татар теленең диалектологик сүзлеге"ндә (1993) "мөрҗә" сүзе "хуҗалык" мәгънәсендә дә ия дип күрсәтелә һәм "Мөрҗә акчасы җыйлар ыйы, кырык, илле тин, бай кешенең ике-өч мөрҗәсе була торган ыйы" дигән мисал-иллюстрация китерелә. Монда "төтен хәреҗе" турында сүз бара дип уйларга кирәк, ә ул моржа исәбеннән алынган (хуҗалыкта, ихатада берничә моржа булырга да мөмкин).

// *Кече моржа* – мичтәге учак төтене юлы, ул төп моржага тоташа.

***МОРЗА*** – Мирза. Казан ханлыгында морзалар яки мирзалар дип бәкләрнең (кенәзләрнең) кече угылларын (әмирзадәләрне) атап йөрткәннәр, ә бәк титулы өлкән угылга күчкән. Шулай итеп, мирзалар аксөяк катлауның өченче дәрәҗәсен тәшкил иткәннәр. Аларны Англиядәге *эсквайрлар* белән чагыштырырга була. Болгар чорында морзалар булмаган әле. Морзалар, мәсәлән, чуашларда да булган һәм христианлаштыру сәясәте вакытында аларга да татар морзалары кичергән хәлләрне кичерергә туры килгән.

***МОСАУВИР*** *г.* – **1.** Рәссам, сурәт ясаучы, сурәт төшерүче; фотограф. Г.Тукай бер шигырендә Гаяз Исхакыйны "мосаувир" дип олылый. **2.** Аллаһының күркәм исемнәреннән берсе. Бу очракта төрле чыганакларда *(әл-)Мусаувир* һәм *Мусаувир* язылышлары да очрый һәм – *Сурәт бирүче, Бөтен нәрсәгә шәкел бирүче* дип тәрҗемә ителә. Ихтимал, иң кулае *Сынландыручы* сүзе булыр иде.

"Шәрык алынмалары сүзлеге"ндә *мосаүир* язылышы да тәкъдим ителгән.

***МОСТАФА*** *г.* – Сайлап алынган, сайланмыш мәгънәсендә. Мөхәммәд Пәйгамбәрнең эпитеты. Кеше исеме булып та йөри. // *Бу дөньядин күп үтде әнбийә һәм әүлийа, барчасының рәһбәри Мөхәммәд Мостафа.* Кол Шәриф.

***МОТЛАК*** *г.* – Абсолют; чикләнмәгән; бәйсез; шартсыз. // *Мотлак бушка* – гел бушка, бөтенләй бушка. *Хәзер бәхәсләре "шәйә мотлак" илә "мотлакы шәй" арасындагы фәрыкның исбатында икәнен сүзләреннән аңладым* – Хәзер бәхәсләре әйбернең чикләнмәгән булуы белән чикләнмәгән әйбер арасындагы аерма икәнен сүзләреннән аңладым. Фатих Әмири.

***МОТЫЙГЫ*** *г.* – Буйсыну. // *Кешенең ихтыярын үзеннән алып һәр эштә гипнотизмә хуҗасына мотыйгы кыла торган бер куәттер.* Г.Исхакый.

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Гариф Ахуновның тууына 80 ел*

# ХӘЗИНӘ ТАПКАН ӘДИП

Егерменче гасырның илленче еллары уртасыннан ил тормышында башланган иҗтимагый-рухи җанлану шартларында халык язмышы, үз буыннарының уйомтылышлары хакында тирәннән борчылып яшәгән бер төркем әдипләр зур әдәби мирас калдырып, гасыр ахырында бер-бер артлы якты дөньядан китеп тә бардылар...



Иҗади эшчәнлекләре үзең уйлаганны кәгазьгә төшерергә ярамаган заманага туры килде аларның. Шуна да карамастан, бу чор әдәбият тарихы үсешендә иң бай чор булуы белән аерылып тора. Язучыларыбызның үз халкы тарихын, аның яшәү үзенчәлекләрен, чор проблемаларын реаль төсмерләрдә чагылдырып язган әсәрләре укучы күнелендә ныклы урын алды.

Үткән гасырның туксанынчы елларында исә башлаган иркенлек җилләре совет чорында иҗат ителгән ул әсәрләргә нык килеп кагылды. Кайберәүләр укучы яратып кабул иткән әсәрләрне хурлый башлады. Бөтен гомерен әдәби иҗат эшенә багышлаган, үз халкына сүз сәнгате ярдәмендә тормыш дөреслеген аңлатырга тырышкан, укучы яратып кабул иткән әсәрләр тудырган әдипләребезнең байтагы бу урынсыз хурлауларны ишетеп, рәнҗеп киттеләр кебек тоела күнелгә.

Инде хәзер тетрәнүләр артта калып бара. Бай мирасыбыз турында акыл белән, ашыкмыйча, уйлабрак фикер йөртергә вакыттыр.

Иҗади эшчәнлеге совет чорына туры килгән, әдәби тәнкыйтьтән төрлесен ишеткән язучыларыбызның берсе—Гариф Ахунҗан улы Ахунов. Илленче еллар уртасында татар әдәбиятына килгән буынның күренекле вәкилләреннән булган Гариф Ахуновка быел сиксән яшь тулыр иде.

Балачагы сугыш елларына эләккән Гариф Ахуновка тормышның төрле авырлыкларын, борылышларын күрергә туры килә. Яшьли әтисез калу, гаиләдә итәк тулы баланы бер үзе караган әнисенә ярдәм итү теләге белән вакытлы-вакытсыз укуын ташлап торырга мәҗбүр булу, башка яшьтәшләре белән бергә колхоздагы авыр эшне төпкә җигелеп тарту... Аннан соң Арча педагогия училищесын, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлау...

Бәхетле кеше була Гариф Ахунов! Булдыклы, тырыш егетнең беренче язмаларын Гази Кашшаф, Хәсән Хәйри, Хатип Госман, Мөхәммәт Гайнуллин, Латыйф Җәләй кебек күренекле тәнкыйтьчеләр укыйлар. Егеттәге иҗади сәләтне күреп, аны "Совет әдәбияты" журналына эшкә чакыралар. Арча педучилищесында укыганда ук "тере язучыны күрү теләге белән яшәгән" Гариф Ахунов һәркөнне диярлек Гомәр Бәширов, Ибраһим Гази, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур кебек язучыларны очрата, сугыштан соң язылган әсәрләр турында фикер алышуларда катнаша. Тынгысыз күнелле, эзләнүчән шәхес буларак ул 1957 елда Әлмәткә нефть чыгаручылар тормышын өйрәнергә китеп бара, анда Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеген оештыра, аның җитәкчесе була... Аннан сон—Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы секретаре, озак еллар буе берлек рәисе, "Казан утлары" журналының редакторы... Болардан тыш, ул—ике мәртәбә СССР Верховный Советы депутаты, XXV съезд делегаты... Сонрак "Әлмәт шәһәренең мактаулы нефтьчесе", "РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре" исемнәренә, "Татарстанның халык язучысы" исеменә, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясенә, Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премиягә лаек булды.

Гариф Ахунов үткән тормыш һәм хезмәт юлы—сокланырлык бай, күпкырлы. Ул үзен күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе итеп танытты. Мондый дәрәҗәгә ул исkиткеч тырыш, эшчән, гадел булуы, кешелек сыйфатлары аркасында ирешә. Әдип белән үткән яшьлек гомерен искә алып, хатыны Шаһидә ханым болай ди: "Ул кешеләр

өчен яшәде. Исемдә, берәр кешенең йә фатир алу, йә санаторий-мазарга путевка алу мәсьәләсе буенча йомышы төшсә, ул бу эшне башкарып чыкмый тынычланмый иде. Эштән кайтып кергәндә, йөзенә карап, аның бу мәсьәлә буенча эше унган-унмаганны чамалый идем. Эш унса—елмаеп кайтып керә, унмаса—йөзе караңгы була".

Гариф Ахуновның иҗаты мәктәптә һәм Арча педагогия училищесында укыганда ук башланса да, "Галләм сорау бирә" дип аталган хикәясе 1951 елда гына укучыга барып ирешә. Сугыштан соңгы авылның язмышы турында тирән борчылу, аның үсеш юллары турында уйлану, авылда яшәүчеләрне җәмгыятьнең тулы хокуклы кешеләре итеп күрергә теләү аша автор үзенең бу хикәясендә геройларның эчке дөньяларын үсеш-үзгәрештә бирүгә ирешә. Әсәрдә колхоз рәисе Бикбулатов яшьләрнең алдынгы фикерләренә каршы килеп, искечә генә эш итмәкче була. Ләкин Г. Ахунов үзенең бу героен начар итеп калдырырга теләми, вакыйгалар барышында автор аны тискәре сыйфатларыннан арындыра. "Юллар чатында" хикәясендә дә Зәлифә исемле хатын гомер буе башкалар исәбенә яши, ләкин әсәр ахырында ул да унай якка үзгәреп китә. Әнә шулай итеп яшь автор үзе уйлап чыгарган геройларны җиңел генә дөрес юлларга алып керү теләге белән яши. Әмма тормыш авыр да, катлаулы да. Бу хакыйкатьне аңлау Г. Ахуновка еллар узгач, тормыш тәҗрибәсе аша килә.

Яшь язучының әдәби осталыгы үсә баруы аның "Яшьлек яме" (1955) дигән повестында күренә. Башлангыч чор иҗатына караган кайбер әсәрләрендәге кебек монда да бала һәм үсмер чаклары авыр сугыш елларына туры килгән, белемгә, яшәүгә сусаган, якын һәм ерак киләчәккә зур ышаныч, өмет белән караган бай романтик хыяллы яшьләрне күрсәтә автор. Миллионнарның яшь гомерләрен алып киткән сугыш афәтеннән соң килгән дәртле һәм хыялый буынның уй-кичерешләрен автор ниндидер бер күнел жылылыгы белән сурәтли. Илленче еллар яшьләренең киеренке, кайсыдыр яклары белән каршылыклы хис-тойгыларын Г. Ахунов үзенә таныш, якын булган студентлар тормышына нигезләнеп яктырта.

Әсәр геройлары—югары уку йорты студентлары Таһир, Гөлнур, Айратлар яшәү мәгънәсен эзлиләр, тормышта үз урыннарын төрлечә табарга омтылалар. Студент геройларның хезмәткә, бер-берсенә мөнәсәбәтләре аша характерлары формалаша, аларның әхлак йөзе, кешелек дәрәҗәсе бәяләнә. Автор Айрат һәм Мәрфуга образлары аша, намуслы хезмәттән читләшкән кеше әкренләп физик яктан гына түгел, рухи яктан да зәгыйфьләнә бара, дигән фикерне үткәрә. Тумыштан сәләтле һәм чибәр булган бу кешеләр хәтта үзләрендәге унай сыйфатларны да төрле хәйләле һәм мәкерле планнарын тормышка ашыру өчен кулланалар һәм шуның белән үзләрен коллективка каршы куялар. Аларның шундый булып үсүләренә Г. Ахунов беренче чиратта гаиләне гаепли. Мәсәлән, "авыл малайлары мәтәлә-кадала кул арбасы белән урманнан печән ташыганда, үзем исән чагында сабыйлыкның рәхәтен татып калсын" дип Айратның әнисе аны "кара" эшкә якын да җибәрми. Гаиләдә дөрес тәрбия күрмәгән Мәрфуга белән Айратны соңыннан коллектив кына үзгәртә алмый инде! "Бала тәрбияләүдә иң беренче һәм иң хәлиткеч бурыч гаиләгә, аеруча ана өстенә төшә" дигән фикер үткәрелә әсәрдә. Совет педагогикасы яшь буынны тәрбияләү бурычын тулысынча коллективка—балалар бакчасы, мәктәп, эш урынындагы төрле җәмәгать оешмаларына—тапшырган бер заманда яшь авторның мондый урынлы фикер уздыруы бик әһәмиятле иде. Һәм бүгенге яшәеш тә бу карашның дөреслеген раслады.

Татарстан җирләрендә нефть табылу Россия икътисады үсешенә нык этәргеч ясый. Җөмһүриятебездәге бетмәс-төкәнмәс "кара алтын" Россиягә генә түгел, башка социалистик илләргә дә күпләп җибәрелә башлый. Татарстан нефте алга киткән капиталистик илләр алдында Россиянең дәрәҗәсен шактый ныгыта. Әлмәт җирләрендә күпләп нефть табылу, үз чиратында, яна шәһәр, яна эш урыннары тууга да сәбәп була. "Кара алтын"ны җир өстенә күтәрү өчен бу якларга төрле төбәкләрдән эшче көчләр килә башлый.

Илленче еллар башыннан алып әдәбиятта да нефтьчеләр тормышы белән кызыксыну көчәя. Республикада нык күтәрелеп киткән нефть промышленносте һәм бу өлкәдә эшләүче кешеләр әдәбиятның төрле жанрларында зур урын ала.

Шагыйрь Зәки Нури әйткәнчә: "Ишек шакучы гына булып түгел, ә әдәби бүлмәгә үтеп кереп, һәм шунда үзенең эш өсталләрен куеп, чынлап торып эшли башлаган" Г. Ахунов та, нефть якларындагы тормыш һәм хезмәт кешеләре белән якыннан танышу, бу яналык алып килгән үзгәрешне әдәби иҗатта яктырту өчен 1957 елда

гаиләсе белән Әлмәткә күчеп китә һәм анда 1968 елга кадәр яши. Яна тормыш белән кайнаган районнар аңа "серле дөнья" булып тоела. "Әнә шул серләрне ачасы, тойгыларны кәгазьгә төшерәсе" килгән язучы бер-бер артлы очерк, хикәяләр һәм "Җир куенында" дигән бер пьеса да яза.

Эшчеләр сыйныфының яна катламы—җир астыннан кара алтын чыгаручы нефтьчеләр—тормышына, хезмәтенә бәйле рәвештә туган яңалык-үзгәрешләрне, авыл белән шәһәр арасында туган каршылыкны реалистик планда күрсәтеп язган һәм алтмышынчы еллар татар прозасында иң уңышлы саналган әсәрләрнең берсе Г. Ахуновның "Хәзинә" (1957—1961) романы була.

Алтмышынчы-җитмешенче елларда киң колач җәйгән илне индустрияләштерү процессы, шул исәптән Татарстанда нефть табылу, берьяктан, авылдан бик күп крестьяннарны эшчегә әйләндерү, икенче яктан, чәчүлек җирләрен, болынтугайларны, авылларны юкка чыгару исәбенә алып барылды. Хезмәт һәм бу хезмәтне башкаручыларга дан җырлау Г. Ахунов иҗатында төп тема булып калса да, әдип яшәешкә күп югалтулар китергән әнә шул үзгәрешләрне романда чагылдырмый кала алмаган. Авыл һәм аның кешеләренең тормышын нефтькә мөнәсәбәт аша чагылдырган бу әсәрдә язучы рухи байлык һәм физик байлыкның бердәмлеге, мәхәббәт, бәхет, кеше һәм табигать бердәмлеге, буыннар бәйләнеше өзелү, авыл һәм шәһәр, крестьяннар һәм эшчеләр арасындагы аерма кебек әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрә, аларны иҗтимагый-социаль җирлектә аңлатырга омтыла. "Намуслы хезмәт, рухи һәм физик байлыклар бердәмлеге, бөтенкешелек кыйммәтләре аша гына бәхеткә ирешеп була" дигән идея үткәрелә романда.

Әсәр үзәгендә тормышка карашлары, холык-фигыльләре белән бер-берсеннән аерылып торган ике гаилә: Шәвәли карт һәм Лотфулла Дияровлар гаиләсе куела. Нефтьнең крестьян психологиясенә тәэсирен тирәнрәк күрсәтү максатыннан автор киң планда Шәвәли карт гаиләсен тасвирлый. Шәвәли карт кайчандыр мәэзин кызы Мәгыйшәгә өйләнеп гаилә кора, хатынының явызлыгы аркасында, ата-ана нигезен ташлап башка чыгарга мәҗбүр була. Үз көче белән йорт төзи, нигез кора. Гомер буе бәхет эзләп, "көч куйдым, ташның авырын күтәрдем, әмма ләкин хәзинәне таба алмадым",—ди ул соңыннан. Байлыкны бары тик үз көче белән генә табарга өйрәнгән Шәвәли чын крестьяннарга хас булган: эшчәнлек, физик ныклык, булганның кадерен белү, саранлык, авырлыкларга тешеңне кысып түзә белү кебек бик күп сыйфатларны үзенә җыйган.

Олыгайган көнендә Шәвәли карт өчен иң зур хәзинә—үз йорты, үз нигезе булу. Ләкин балалары ата нигезен үз итмиләр, төрлесе-төрле җирдә сибелеп яшиләр. Кайчандыр Кәлимәттә иң күренекле, иң нык нигезләрдән саналган Шәвәлиләр йорты инде тузып-искереп бара. Мона атаның эче поша, күңеле әрни. "Бер-бер артлы йортны ташлап чыккан балалары өчен, көн саен туза, җимерелә барган хуҗалыгы өчен борчылу, кайры корты кебек йөрәген кимерә", ди автор, геройның эчке халәтен тасвирлап. Шуның өстенә нефтькә бәйле килеп кергән үзгәреш-яңалыклар картның күңел тынычлыгын ала. "Авылны бетерәләр инде, бетерергә тотынгач, бер эш тә эшләр хәлең юк..." дип уфтанган геройны, гомере буе барлык авыл крестьяннары өчен дә бердәнбер яшәү чыганагы булган йорт яны хуҗалыгының язмышы борчый. Шуна күрә үзенең яшәү чыганагын бары тик нефтьтә генә күргән, тормышны берьяклырак аңлаган Арсланның "бакчаң өчен акча бирерләр" дигән сүзләре кендеге җиргә береккән крестьянны һич тә юата алмый.

Яңалык басымы астында кайчандыр "бер кычкырып җибәрсә, тавышы өч чакрымдагы Торналы авылына ишетелә торган", әкият батырлары төсле гайрәтле булган Шәвәли карт ничектер мескен булып, киләчәге беткән авыл тормышының соңгы вәкиле булып кала. Автор үз героеның аянычлы хәлен икенче бер герой Лотфулла Дияровка мөнәсәбәттә тагын да тирәнрәк ачуга ирешә. Баштарак нигезен, ата-баба йортын ташлап киткән Лотфулла Дияровка, тормыш итә белми торган кеше итеп караган Шәвәли карт күршесенең көн саен иртән бер үк вакытта "шыгырдап торган каты кожаннан һәм таза күн итекләрдән эшкә барырга чыгуын, читән янына басып, көнләшүгә якын бер хис белән" озатып кала башлый. Шулай итеп герой тирән психологик кичерешләрдә бирелә.

Теләсә нинди юллар белән бары тик җир астыннан нефть чыгаруны гына алгы планга куйган Лотфулла Дияровлар, Арсланнарга Шәвәли картны, шәһәр булып килә

торган Кәлимәткә авыл булып калган Кәлимәтне каршы куеп, чагыштырып сурәтләү ярдәмендә әдип бүгенге көндә яшәеш өчен чын-чынлап борчу тудырган мәсьәләне: илленче еллардан башлап авылларны, крестьян хуҗалыкларын, чәчүгә файдалы җирләрне бетерү нинди юллар белән алып барылуын күрсәтүне максат итеп куя.

Нефтьнең, бер яктан—зур хәзинә, икенче яктан, табигатькә килгән куркыныч икәнлеген башка образлар белән танышканда да аңларга мөмкин. Мәсәлән, шуларның берсе—беренче карашка хәзинәгә бернинди мөнәсәбәте юк сыман тоелган—Йөзләкәй карчык. Йөзләкәй карчык—җир өстендә иң зур хәзинә хуҗасы. Иске Кәлимәт авылында Көбәшләр нигезендә яшәгән кешеләрнең иң борынгысы—йөзьяшәр карчык "татар авылларында сирәк очрый торган озын гомерле һәм хәсрәт-кайгыны батыр күтәрә алган чыдам кешеләрнең берсе" җир өстендә үзе кебек үк сау-сәламәт, физик һәм рухи яктан нык булган, тормышның авыр йөген тартып барырдай таза нәсел калдыра. Йөзләкәй карчык тазалыкны табигатьтән алган. Кәлимәтнең саф һавасын сулап үскән, борынгы чишмәләрнең чиста суын эчеп, шул суда юынып, аның шифасын алган, гомере буе яшел чирәмгә яланаяк басып йөреп, җирнең җылысын тойган Йөзләкәй карчыкның табигатькә якынлыгы, байлык, шөһрәт артыннан куучы, җирне, суны, һаваны пычратучы бүгенге кешегә, бу кешенең табигатькә карата кылган вәхшилегенә каршы куела. "Дөрес булса, җир астыннан май тапканнар, ди... Үлмәсән әллә ниләр ишетерсең әле. Һәмәкәй төшне тишеп, җир мае суыртасылар, ди... Чишмә суларын былчыратып, үләннәрне корытып бетермәсәләр ярарые". Бер уйлаганда, ашын ашаган, яшен яшәгән әби табигатьтән аласын алган, бирәсен биргән кебек, ул тыныч кына үлем турында уйлар иде, ләкин бөтенхалык язмышын, милләт рухын үзендә туплаган карчыкны яшәешнең киләчәге, табигатьнең чисталыгы борчый.

Озын тормыш юлы үтеп, зур тәҗрибә туплаган, халыкның акылын үзендә сеңдергән, җир өстендә яшәеш дәвам итсен өчен таза-сау балалар үстереп биргән Йөзләкәй әби, кешелекне борчый торган мәсьәләләр турында уйланулары, борчылулары белән Әмирхан Еникиның "Әйтелмәгән васыять" исемле хикәясендәге Акъәбигә охшаш.

Җыеп кына әйткәндә, күренекле әдип Г. Ахунов үзенең "Хәзинә" романында "производство" темасын яктыртып, чор проблемаларын социаль-әхлакый яссылыкта бирә алды. "Хәзинә"нең дәвамы булган "Хуҗалар" романында элеккеге хезмәт энтузиазмы сүрелә төшкән. Нефтьне бары тик байлык чыганагы гына дип караган геройлар инде бәхетнең алай тиз генә килмәвенә төшенгәннәр. Беренче китапта үзләрен чын хуҗалар итеп хис иткән геройларның сөйләмендә үзләре тудырган хезмәткә һәм өстәге хакимият әһелләренә карата ризасызлык билгеләре чагыла. Гади бораулаучыдан трест управляющие булып җиткән Арслан һәм башка җитәкчеләр дә көндәлек эш мәшәкатьләре яссылыгында төрле каршылыклар белән очрашалар, шуңа күрә бу көчле геройлар күбрәк кыенлык-авырлыклардан зарлануылары белән күңелгә кереп кала. Инде барлык геройларга да бәхет китерергә тиеш булган байлык—нефть тә табылган, ләкин шул байлыкны табучы хуҗалар нишләптер үзләрен "чын хуҗалар", бәхетле кешеләр итеп хис итмиләр. Парторг Таҗиның: "Кеше просто арыган: ун ел сугышта инде—ирешкәне вак-төяк. Борчылмаска, канатсыз яшәргә өйрәттеләр безне" дигән сүзләре чор проблемаларын тагын да ачыграк аңларга ярдәм итә. Эшчеләргә торак урыннары җитмәү, хезмәт хакының түбән булуы, балалар бакчалары, санаторияләр, ял итү урыннары булмау, шуңа бәйле геройларның үз сүзләре белән әйткәндә "текучесть кадров", производствода бик еш булган аварияләр аркасында кешеләрнең гарипләнеп калулары, йә булмаса үлемнәре... Мәсәлән, Арслан белән Мөнәвәрә ятим балалар белән тол кала, Кәрим белән Сәгыйдә кара җир астына кереп ята, Николай Кожановны яраткан эшеннән китәргә мәҗбүр итәләр... Монардан тыш табигать байлыгы—газның юкка янып, берьяктан, һаваны пычратуы, икенче яктан, бу байлыкның әрәм-шәрәм булуы, һәм менә инде ничә еллар хөкүмәтнең бу эш буенча бернинди дә чара күрмәве—болар бар да җәмгыятьнең авыру якларын күрсәтә торган факторлар. Рухи һәм физик байлыкларны бергә куша алмаган, гомумяшәеш кыйммәтләренең кадерен белмәгән кеше беркайчан да бәхетле булмый. Ләкин яшәеш болай дәвам итә алмый. Кеше кайчан да булса, табигать алдында үз гаебен аңлап, дөрес карар кылырга тиеш. Моңа инанган әдип "җирнең чын хуҗалары кемнәр булырга тиеш?" дигән сорауга унай җавап бирергә омтыла, шул максаттан романга бер төркем яшь геройларны—Габделхәй, Саша, Тансыкларны кертә.

"Көбәшләр нәселенә хас булган кунадай киң арка-жилкә күзенә чалынды. Тәбәнәк базык гәүдә, аякны аера төшеп жиргә нык басып тора иде", дип сурәтли автор Габделхәйнең туган җирендә тәпләнеп каласына ишарәләп. Җирнең чын хуҗалары ата-ана нигезен үз иткән, җирдәге барлык байлыкларның кадерен белеп, аны тиешенчә файдаланган, үзен табигатьнең бер кисәге итеп тойган кешеләр булырга тиеш. Тормышта кешеләрдән дә, "кара алтын"—нефтьтән дә—зуррак хәзинә бар: ул—табигать. Романның һәр ике кисәгеннән дә әнә шундый фикерләр аңлашыла.

XX йөз башында ил тормышындагы зур тетрәнүләр—сәясәт, икътисад өлкәсендәге тамырдан үзгәрешләр барлык халыкларның да яшәешенә шактый авырлыклар алып килә. Дистә елларга сузылган сыйнфый көрәш, ачлык, юклык күпләрне яшәү рәвешләрен үзгәртергә мәҗбүр итте. Һәр кешенең тормышта үз бәхетен табарга омтылуы—ул гадәти күренеш. Гасыр башында яңа тормыш басымы астында бәхет эстәп, туену-сыену урыны эзләп, чит-ят җирләргә чыгып китүчеләрнең саны шактый була.

Киләчәккә өмет-ышаныч белән караган, бәхетле көннәрне якынайту өчен теләсә нинди корбаннарга барырга әзер булган геройлар тормышын гәүдәләндереп, Гариф Ахунов үзенең "Чикләвек төше" һәм "Ардуан батыр" исемле повестьларын яза. Бу ике әсәр дә әдипнең әдәби-тарихи эзләнүләре нәтиҗәсендә туа.

Татар эшчеләре арасында беренче булып Ленин ордены белән бүләкләнгән, СССР Үзәк Башкарма Комитеты әгъзасы итеп сайланган, Березники шәһәрендә үзе үлгәч һәйкәл куелган, аның исемендә премия кертелгән Мирсәет Ардуановның якты истәлеген әдәбиятта мәңгеләштерү, бер яктан, бүгенге укучыга беренче бишьеллык төзелешләрен күз алдына китерергә мөмкинлек бирсә, икенчедән, татар халкының каһарман улларын, аларның көчле рухларын тасвирлап, үткән буын белән горурлану хисе тәрбияли. Г. Ахунов үзенең бу повестьларында документаль фактларга таяна, реаль прототиплары булган геройларны әсәр үзәгенә куеп, халык өчен авыр һәм киеренке заманнарны чагылдырды.

Күптәннән тарихи-революцион темага зур күләмле әсәр язу теләге белән янган Г. Ахунов 1978 елда, ниһаять, гаять киң тормыш материалын катлаулы, аянычлы, кызыклы язмышлы геройлары аша гәүдәләндерү өчен "Идел кызы" романына тотына.

Әдип язып калдырган истәлекләрдән аңлашылганча, бу романны язу теләге аңарда бик күптәннән—1960 елларда ук туа. "Мин "Идел кызы"н 1962 елда ук яза башладым, дөресрәге, әсәрнең төп фикерен "амбар кенәгәсе"нә язып куйган идем, башта ул "Авыл малае" дип атала иде, аннан соң "Авыл кызы" булды. Аның өченче исеме—"Юлдаш", иң ахырдан "Идел кызы" итеп үзгәрттем", ди әдип. Үзе күргән, үзе ишеткән ике зур вакыйга Г. Ахуновның күңелен туктаусыз гасабиландырып тора. Берсе—язучының хатыны Шаһидә ханымның әтисе Габдрахман абзыйның аянычлы язмышы, икенчесе—Бауман урамыннан кычкырып елап баручы чал чәчле, яланбаш бер абзый сөйләгән гыйбрәтле хәл. Бу кешеләрнең һәр икесе дә "социалистик система" корбаннары. Мулла булып гомере буе ярлы халыкка аң-белем тараткан Габдрахман абзый, инкыйлаб нәтиҗәсендә властька килгән яңа хуҗаларның басымына, кыерсыту-җәберләүләренә түзә алмыйча, үз-үзенә кул сала. Шәхес культы корбаны—урамда очраган абзый да, юкка гаепләнеп, егерме ел төрмәләрдә бик күп газаплар кичергән, ниһаять акланып, исән-сау кайту бәхетенә ирешкән, ә бүген аны яңадан партия әгъзасы итеп таныганнар, абзый шуңа елый икән. Димәк, әсәр материалын язучыга тормыш үзе бирә.

"Ул—минем рухи ихтыяҗым. Мин аңа 25 ел буе әзерләндем. Тау чаклы материал җыйдым. Күңелемне беркеттем. Ул минем язучылык эшемә, осталыгыма имтихан булачак. Ул—минем халкым турында әйткән сүзем. "Идел кызы"н бүтән һичкем түгел, мин генә яза алачакмын!"—дип билгеләп үтә әдип бу романның язылу тарихы турында.

"Идел кызы" романында вакыйгалар—киң, катлаулы, каршылыклы. XX йөз башы—Россиянең иҗтимагый, сәяси, икътисадый тормышына зур тетрәнүләр алып килгән чор. Шуңа бәйле рәвештә әсәрдә алынган вакыйгалар да киң планда һәм әле бер, әле икенче җирдә яктыртыла. Язучы үзенең геройларын әле Россиянең үзәге Мәскәүгә, әле Алабуга җирләренә, Әгерҗе якларына, Зартугай кебек авылларга күчерә.

"Идел кызы" романының беренче китабында төп фигура булып торган Габбас мулла үзендә күп каршылыклар туплаган кеше. Ул үзеннән егерме яшькә олы Шәмсениса абыстайга йортка керә, шулай итеп социаль асылыннан читкә китә.

Ләкин өстен сыйныф вәкилләре арасында да үз кеше булып житә алмый. Хәерчесе дә, (мәсәлән, бөкере Гафият), бае да (Габделхәлим бай) жае чыккан саен анын сыйнфый чыгышын исенә төшереп торалар. Шунын өстенә крестьян хезмәте, жир эше аны гел үзенә тартып тора. Күнел тынычлыгы эзләп, тук тормыштан баш тартып, ул янәдән крестьянча яшәп карый. Ләкин Габбас мулланы чолгап алган рухи бушлыкны, ялгызлыкны берни дә тутыра алмый.

Ахырдан затлы нәселле Шәмсениса абыстай аны ташлап китә. Яраткан кызы Нурия әтисеннән бөтенләй баш тарта, өеннән үк куып чыгара. Нажия Уразаевалар төзегән яна тормышнын законсызлыгын, кеше шәхесеннән ничек көлүен, кеше хокукын бозып, аны ничек изүен күргән, үзендә тойган Габбас мулла, әлбәттә, бу тормышка йөз белән борыла алмый. Тәминдар Тураев, Сөләйман хәзрәт, штабс-капитан Динислам Бохараевлар сайлаган юлнын да киләчәге юк икәнлеген төшенгән Габбас мулла аларга да иярми, үз авылында яшәүне артыграк саный. Шулай итеп, нинди генә ижтимагый-социаль шартларга эләксә дә, герой аны кабул итә алмый, һәм, киресенчә, чолгап алган тирәлек өчен дә ул артык, кирәкмәгән кешегә әйләнә.

Билгеле булганча, экзистенциаль әсәрләрдә кеше язмышынын ин әһәмиятле моментларын гына алып сурәтләү таләп ителә. "Идел кызы" романында әдип нигездә Габбас мулла тормышында хәлиткеч роль уйнарга тиеш булган вакыйгаларны тасвирлауга игътибар бирә.

Әсәр Габбас мулланын тормышын кискен рәвештә унай якка борып жибәрергә тиешле булган шатлыклы вакыйганы сурәтләү белән башланып китә. Ул күптәннән бала көтә. Шәмсениса абыстай белән Габбас мулланын балалары юк. Ике арадагы зур бушлыкны һәм яшь аермасын яна туган бала тутырыр төсле. Һәм, ниһаять, кышкы көннәрнен берсендә, буранлы төндә, Габбас мулла кызы Нурия дөньяга килә. Ләкин әсәр башында бу вакыйганы хикәяләү үтә дә монсулык белән сугарыла. Табигатьнен ямьсез булуы Габбас мулланын жанын тетрәтә.

"Бу төнне Габбас мулла йокы күрмәде.

Танга ерак иде әле.

Тышта буран үкерә. Инде өченче көн туктаусыз котырынган жил-бураннын, әле йорт нигезенә үк житеп, ач бүреләр көтүе сыман, куркыныч авазлар белән улавы, әле бөтенләй ерагаеп, кайлардандыр әйләнеп кайтуы бозлы тәрәзә пыяласына, урам карангылыгына төбәлеп утырган Габбас мулланын жанын тетрәтә иде".

Котырган жил-буран геройнын болай да тыныч булмаган жанын тагын да ныграк борчый, аянычлырак итә. Әйтерсен лә, табигать анын бүгенге рухына гына туры килеп калмый, ә киләчәк язмышына да ишарә ясый. Шулай итеп, дөньяга яна кеше туу, яшәү чыганагы башлану Габбас мулла өчен сызлану чыганагына әверелә. Шушы сызлану йомгагын геройнын ялгызлыгы тәшкил итә. Әдәбиятта экзистенциализм фәлсәфәсен үткәрүче чара булып та ялгызлык тора. "Юлдаш юк Габбас муллага", ди автор. Ин кирәк вакытта, ин зур теләге, гомере тормышка ашам дип торганда Габбас мулла ялгыз. Һәм әсәр башындагы шул ялгызлык, сонрак, янында ике хатыны, балалары булып, гаиләсе ишләнсә дә, авыл халкы үз итсә дә, ахырга кадәр дәвам итә. Мулла хатыны, затлы нәселле Шәмсениса абыстай аны анламый, чөнки ике арада— байлык, нәсел, яшь тигезсезлеге. Яшь хатын Хәнифә дә анлый алмый, чөнки арада— рухи аерма. Кызы Нурия дә аны анламаска мәжбүр, чөнки социаль шартлар шулай таләп итә. Мәгълүм сәбәпләр аркасында баеннан да, ярлысыннан да читләшкән Габбас мулланы авыл халкы да үз күреп, ахыргача анлап кабул итә алмый. "Бәхетсез кеше булды ул Габбас. Үзенә дә юк, кешегә дә" диләр, ул үз гомерен үлем белән чикләгәч.

Уттан зыян күргән кешеләргә йорт салыр өчен авыл Советы урманнан диләнкә бүлеп биреп, бер Габбас мулланы гына өлештән калдыргач, "...авылнын диндар картлары аны, кызын Пәнжәрдә рус мәктәбендә укытканы өчен, кәфер дип, кызыл мулла дип күзен ачырмасалар, инде бәлагә тарыгач, авыл Советы башлыклары да анын хәленә кермәде, аны буржуй сыйныфына яздылар", ди автор.

Шулай итеп, герой иске тормышта да, янасында да—ялгыз. Анын гомере бетү, вакытсыз юкка чыгу минутлары якыная...

Әсәрдә Габбас муллага бәйле бик күп уй-фикерләр бар. Милли мәсьәләләрне хәл итүдә, мәсәлән, Габбас мулланын үз акылы. Ул янача укыту ярдәмендә "йоклаган" милләтне коткарып калырга, уятырга мөмкин дип фикер йөртә. Дөрес юнәлеш белән

барганда, аның киләчәге матур булыр дип уйлый. Габбас мулла болай ди: "Хөррият заманасы килә, татарның да күзе ачылырга тиештер бит инде... Пароход хуҗалары Стахиевлар гына булырга дигәнмени? ...Урыс авылларында күпме чиркәү бар, күпме вак чиркәү кырларда утыра... Имеш, мөгаллим булмаса, Таминдар бай мәктәп салдырмый. Салдырмаса, үзенә начар, ул тотасы пароходларны, ул ачасы заводларны кем эшләтер? Сөләйман хәзрәт тал чыбыгы ашаткан мокыт шәкертләрме? Туры Тукай чыкты дөньяга, китапларны кара, Казан басмаларын". Романда милли мәсьәләләргә бәйләп, кызыклы гына нәтиҗәләр дә ясала. Габбас карт муллаларны өч төркемгә бүлә: "Беренче төркем—шымчы муллалар. Боларның указлары була, болар жандармерия идарәсендә хисапта торалар, болар авыл халкы арасында барган барлык хәлләрне охранкага җиткереп торалар. Болар Алланың барлыгына һәм берлегенә ышанмыйлар, болар өчен кеше җанын кыю берни тормый..." Икенче төркем муллаларга ул шагыйрьләрне кертә. Һәм алар "гасыр саен булганнар: Габделҗаббар Кандалый, Утыз Имәни, Мәрҗани... Боларның укымышы зур. Болар кеше җанының матурлыгына ышаналар, болар халыклары алга китсен, аңы үссен дип гомер буе тырышалар". Өченче төркемгә керүче муллаларны иң зур эш эшләүчеләр дип саный Габбас мулла. "Гомер буе балалар укытканнар, кара халыкны агартырга тырышып яшәгәннәр. Аларга казна акча түләми, алар патша хәзрәтләренең дә сөекле балалары түгел, мәгърифәткә булган ихтирам, башкаларга да дөньяны таныту хисе аларны алга әйдәгән". Бу төркемгә герой үзен дә кертә. Шул рәвешле, гыйлем юлында төрле катлам муллаларның образларын тудырып, герой милләтнең киләчәге, язмышы кемнәр кулында булырга тиешлеге мәсьәләсен ачыклый һәм аны яшәеш, гомумкешелек проблемаларына китереп тоташтыра.

Милләт язмышы турындагы хакыйкатьне аңлау баскычына күтәрелгән Габбас мулланың бу өмете дә акланмый. Чөнки укымышлы муллалар патша ялчылары тарафыннан эзәрлекләнә, ә алдынгы фикерле Давыт мулланың "язганнары кайчан да булса халык кулына тапшырылыр микән? Әллә ул түккән көч, җанын сарыф итеп җырлаган тойгылар мәңгегә тарих диварлары астында күмелеп калырмы?" дип борчыла герой. Ә Габбас мулланың үз шәкертләре исә, зур урыннарда утырып, "азатлык бирдек дип, күкрәк кагалар". Кайчандыр үзләрен укыткан Габбас мулла кебекләргә "мулла-мунтагай" дип кычкырып, өсләренә кемнәрнедер өстереп җибәрәләр. Нәтиҗәдә гомер буе кешеләргә хезмәт иткән Габбас мулла артык, кирәксез кешегә әверелә. Һәм аның мондый халәте җәмгыятьтә шәхеснең үзен азат тоймавы белән аңлатыла.

Әсәрдә шәхес өчен бик тә кирәкле кыйммәтләр: гыйлем, дин, фәннең әһәмияте турында фикер йөртелә, ләкин кешелеклелек мөнәсәбәтләре барыннан да өскә куела. Бу мөнәсәбәтнең гадел булмавы эчке һәм тышкы каршылыкларны тудыра.

Романның икенче китабында Нурия Уразаеваның сугышка кадәрге һәм сугыштан соңгы тормышын сурәтләүгә киң тукталынса да, укучыны күбрәк шәхес культы корбаннары булган Солтан белән Чишмәбай язмышлары кызыксындыра. Тамыры сәяси, әхлакый, интеллектуаль явызлыкка барып тоташкан система гасыр башында Габбас мулла кебек акыл ияләрен юкка чыгарса, тора-бара үзен тудыручылардан да котылу юлларын эзли. Авыру җәмгыять Солтан, Чишмәбай кебек намуслы, булдыклы кешеләргә ялган яла яктырып, аларның тормышын явыз, имансыз үтерүчеләр кулына тапшыра. Нәтиҗәдә бу геройлар "халык дошманы" исеме алып, аяныч язмыш белән гомерләрен тәгәллиләр.

Г. Ахунов—әдәбиятның төрле жанрларына мөрәҗәгать иткән язучы. Төрле елларда язылган "Утлар яна учакта" (1965), "Ардуан батыр" (1980), "Чулпы җыры" (1959), "Икәүдән икәү" (1981) пьесаларында автор хезмәткә мөнәсәбәтләре аша геройларының рухи-әхлакый йөзләрен ача.

Г. Ахунов күпсанлы мәкаләләр, очерклар, документаль язмалар авторы да. Язучының "Йолдызлар калка" китабы бүгенге укучыга үткән гасырның икенче яртысында иҗат иткән әдипләрнең, галимнәрнең, авторның үзенең кызыклы һәм гыйбрәтле тормыш юлын, күпкырлы эшчәнлеген тасвирлап бирүе белән әһәмиятле.

Җыеп кына әйткәндә, хәзинәләрне җир куенынннан табып алу бик җиңел булмаган кебек, Гариф Ахунов иҗатының серләренә төшенеп бетү дә гади эш түгел. Әмма шунысы хак: ул чын мәгънәсендә хәзинә тапкан әдип булды.

**Әлфинур НӘҖИПОВА**

## «Татар энциклопедиясе» битләреннән

# Ә

**ӘБЕЛХАН** Хәлил (тулы исеме Әбелханов Хәлиулла Габделвәли улы) (1887, элекке Шыгырдан а., Сембер губернасы, хәзерге Чуаш Респ-касы Батыр р-ны, – 6.1.1919, Казан), язучы, журналист, педагог. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен, 1909 елда Татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. 1910–12 елларда хәзерге Башкортстан Респ-касының Кыйгы р-ны Идрис авылы рус-татар мәктәбендә, 1912–14 тә Казан губернасы Тәтеш өязенең Ындырчы авылында балалар укыта. 1912 елдан алып "Шура", "Мәктәп", "Мәгариф" ж-лларында, "Йолдыз", "Кояш", "Корылтай" г-таларында актив языша. Мәктәп-мәдрәсәләрдә җәдитчә укыту ысулын пропагандалаучы. "Ак юл" ж-лында хайваннарга, җәнлекләргә багышланган хикәяләрен бастыра (соңыннан алар класстан тыш уку әсбабы буларак аерым җыентык булып басылалар). Җәдитчелек хәрәкәтенең аерым җитешсез якларын тәнкыйтьләгән "Ысулы җәдиткә каршы беренче адым" (1911) исемле китап авторы. 1917 елдан соң Казан губернасының мәгариф оешмаларында эшли.

*Әд.*: Хәлил Әбүлхановның вафаты (некролог) // Эш. 1919, гыйнв.

Автор: *Ф.И.Ибраһимова.*

Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ӘБӘЛХӘЕР** (тәхәллүс булуы да ихтимал) (19 йөзнең 2 нче яртысы), шагыйрь. Тормышы һәм иҗаты аз өйрәнелгән. "Һаза китабе мәснәви" (Казан, 1882) исемле шигырьләр (мәснәвиләр) җыентыгы авторы. Ике тезмә әсәре, Акмулла шигырьләре белән берлектә, Троицк шәһәре имамы һәм мөдәррисе Мөхәммәдшәриф Шиһабетдин угылы әл-Карасуви 1872 елда күчереп язган кулъязма җыентыкка урнаштырылган (табылуы 1981 дә). Мәснәви калыбында язылган 104 юллы беренче тезмә: "Керүбән ялгызым ошбу базарә..." – дип, икенчесе (икеюллык шигырь): "Аh, бу юлның озакыннан..." – дип башлана. Ә.нең шигырьләре ватандарлык һәм иҗтимагый уй-фикерләр белән сугарылган, шигъри алымнарында һәм бигрәк тә образлар, характерлар бирелешендә Акмулла һәм Һибәтулла Салихов шигырьләренең көчле тәэсире сизелә.

Әсәрләре: Һаза китабе мәснәви. К., 1882.

*Әд.*: Госманов М.Г. Акмулла мирасын өйрәнүгә яңа материаллар // Поэт-просветитель Акмулла. К., 1983; Татар әдәбияты тарихы. 2 *т.* – К., 1985.

*Р.Ә.Әхмәтов.*

**ӘБЛИЕВ** Мөхәммәт Шәриф улы (15.7.1900, хәзерге Кама Тамагы р-ны Даныш а. – 1941), прозаик, драматург. 1922 елдан Кызыл Армия сафларында. 1926 да Казанда татар-башкорт хәрби мәктәбен, 1928 да Мәскәүдә хәрби-сәяси курсларны тәмамлый. 1932 гә кадәр политрук, соңыннан Урта Азиядә рота командиры. 1936 елда Ленинград Хәрби-сәяси академиясен тәмамлагач, Казандагы укчы полкта инструктор, соңыннан хәрби комиссар. 1939–40 та совет.- фин сугышында катнаша. Укчы дивизиянең сәяси бүлеге җитәкчесе сыйфатында Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән фронтның алгы сызыгында сугыша, күп тә үтми, һәлак була. Беренче әсәрләре 1920 еллар башында басылып чыга. Ә. "Минем дустым сугышта" (1922), хикәя, "Итекче кызы" (1928), "Ком улы" (1922–29) повестьлары һәм хикәяләре, "Ике туй" (1923–25), "Лейтенант" (1936–40) пьесалары авторы. Ә.не драматург буларак танытхан әсәр – "Шәмсекамәр" (1929–36) драмасы (Татар академия театрында 1938 елда, кабат 1998 елда куела, Татарстанның башка театрларында да уйнала). Пьесада революциягә кадәрге татар авылы тормышы, татар хатынының фаҗигале язмышы тасвирлана.

*Әд.*: Гиниятуллина А.К. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справочник. К., 1970; Даутов Р.Н., Нурул-

лина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**ӘГЪЛӘМЕВ** (Әгъләметдинев) Мөдәррис Зөфәр улы (13.10.1946, Зәй р-ны Биш Субашы а.), шагыйрь. Казан ун-тында укый. 1968-73 елларда Тукай р-ны Яңа Гәрдәле урта мәктәбендә укыта. 1974 тә язучы-профессионал сыйфатында әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә. 1959 елдан бирле матбугатта әсәрләре даими басылып килә. "Кыңгырау" (1970), "Учак урыннары" (1973), "Исәнме, йөрәк!" (1978), "Киләчәккә кайту" (1987), "Мин әйттем..." (1991), "Иман тәрәз шакый" (1996), балалар өчен "Без, без, без идек" (1980) исемле шигъри китаплар авторы. Ә. поэзиясе өчен нечкә лирика белән кискен публицистик рухның үрелеше, уйлар ташкыны, лирик герой кичерешләренең тирәнлеге хас. Иҗатындагы төп мотивлар — туган җиргә мәхәббәт, аның үткәне, кешенең эчке дөньясы белән тирән кызыксыну. Аның поэзиясендә — музыкальлек, классик поэзия һәм халык иҗаты традицияләре җирлегендә табигыйлек, үзгә бер моң бар. Шагыйрьнең индивидуальлеге бигрәк тә кыска шигырьләрендә ачык күренә. Кечкенә генә поэтик деталь аша ул туган ил, халык язмышы, аның үткәне һәм киләчәге турында фәлсәфи гомумиләштерүләр ясарга омтыла. Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы да үзенчәлекле табышлары, хисләренең сафлыгы, нәзакәтлеге белән аерылып тора. Форма ягыннан Ә. шигырьләре төгәл ритмикалы, шома, йөгерек телле. Аларда афоризм булып яңгырарлык тирән мәгънәле, тапкыр гыйбарәләр күп. Ә. сюжетка корылган озын шигырьләр, балладалар һәм поэмалар язу юнәлешендә дә уңышлы эшли. "Сугышлыда сугыш беткән көн" (1972), "Заман язган язмыш" (1987) балладалары, "Тукайдан хатлар" (1972-85), "Акмулла арбасы" (1981) поэмалары шундыйлардан. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1992).

Әсәр.: Кан тамырын кистем. К., 2001.

Әд.: Хәким С. Хәерле сәгатьтә! //Социалистик Татарстан. 1968, 17 нояб.; Галиуллин Т. Йөгер, каләм! //Шагыйрьләр һәм шигырьләр. К., 1985; Фәйзуллин Р. Туңма, туган! //Мәдәни җомга. 1996. 22 нояб.

*Р.Н. Даутов.*

**ӘДҺӘМЕВА** Сәрвәр Сабир кызы (5.4.1901, Оренбург губ. Троицк ш. — 10.11.1979, Казан), язучы, тәрҗемәче. 1920-23 елларда Томск, 1929-31 дә Казан ун-тларында укый. 1925 елда аның балалар сәхнәсе өчен язылган беренче пьесасы басылып чыга. Соңрак яшь геройларның үзара дуслыгын, кыюлыгын, тапкырлыгын сурәтләгән "Дуслар" (1948, русчага тәрҗемәсе "Друзья", 1959), "Минем апалар" (1953), "Тубалбаш" (1958) исемле хикәя җыентыклары дөнья күрә. 1979 елда "Тормыш сынавы" дигән истәлекләр китабын тәмамлый. Ә. иҗатында әдәби тәрҗемә эше зур урын алып тора. Аның тәрҗемәсендә М.Горькийның 6 томда "Сайланма әсәрләр"е (1947-53), А.С.Пушкинның "Мәрхүм Иван Петрович Белкин хикәяләре" (1936), Л.Н.Толстойның "Алпавыт иртәсе" (1935), "Кавказ әсире" (1947), Д.Дефоның "Робинзон Крузо" (1936), В.Василевскаяның "Салават күпере" (1944), М.Ауэзовның "Абай" һ.б. әсәрләр татар укучысына барып ирешә. Ә. 1938 елда нахакка гаепләнә; 1940 елда аклана.

Әсәр.: Хикәяләр, истәлекләр. К., 1971; СИБЛАГтан хатлар //Әдәби мирас. К., 1996.

Әд.: Гиниятуллина А.К. Писатели Советского Татарстана:Биобиблиогр. справочник. К., 1970; Әхмәт А. Язучы һәм тәрҗемәче //Совет әдәбияты. 1951. №4; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986.

*Ф.Г. Галимуллин.*

**ӘЙДИ** (Әйделдинев) Тәуфикъ Рамазан улы (1.5.1941, Мәскәү өлкәсе Шатура р-ны Туголесский Бор пос. — 2.4.2001, Казан, Биектау р-ны Әлдермеш а.нда күмелгән), язучы, ТССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). 1973 елда Казан ун-тын, 1985 тә Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршында Югары әдәби курслар тәмамлый. 1985-97 елларда "Казан утлары", 1997-98 дә "Татарстан" ж-лларында баш мөхәррир урынбасары. 1998 дән "Аваз" хосусый нәшрияты директоры. 1967 елда матбугатта басыла башлый. "Яңа уен" (1988), "Дачада" (2000) исемле хикәя җыентыклары, "Бөҗра" (1978) детектив повесте, "Елан угы" (1991), "Иблискә ришвәт" (2000) маҗаралы романнары, татарлар һәм кардәш халыкларның тормышы, әдәби-мәдәни бәйләнешләрена караган "Исәнме, Гагаузстан"

(1991), "Йөртә безне язмышлар" (1992), "Дунай буендагы кардәшләр" (1994) документаль повестьлары билгеле. "Кайда да кадерле" (1984), "Безгә ни булды?" (1991) җыентыкларындагы эссе һәм публицистик мәкаләләре татар халкының күренекле вәкилләренә, татарларның милли проблемаларына һәм үзаңы үсешенә багышланган. Болгария, Германия, Кипр, Румыния илләренә сәяхәт кылганда туган кичерешләре "Оҗмах утравы" (1999), "Кардәшләр кочагында" (2000) юльязмаларында тупланган. Кайбер төрки телле әдәбиятларның вәкилләре С.Морәтбәков, А.Сатаев, Ә.Мохтар, У.Һашимов әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итте.

Әд.: Ахунов Г. Мәгълүматлар дөньясы яки Безгә ни булды? //Ватаным Татарстан. 1992.29 май; Дәүләт Н. Халыкларны якынайта//Шәһри Казан. 1995. 4 апр.; Әхмәтҗанов М. Иблискә ришвәт//Ватаным Татарстан. 2000. 17 май.

**ӘМИНЕВ** Әхтәм Әмин улы (1918, хәзерге Башкортстан Респ-касы, Миякә р-ны Әнәч а. – 1942), шагыйрь. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1941). Шигырьләре "Яшь сталинчы", "Яшь ленинчы" г-таларында, "Пионер каләме" ж-лында, "Туган ил" (1938), "Очкыннар" (1940), "Алар сафта" (1961) җыентыкларында басыла. 1941 елда сугышка китә, 1942 елда Калуга өлкәсенең Сухиничи, Мещовск ш. янында барган сугышларда каты яралана, шул ярадан вафат була.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары. К., 1986.

**ӘМИНЕВ** Юныс Шәрип улы (1.12.1921, Әгерҗе кантоны Салагыш а. – 3.12.1982, Әлмәт ш.), драматург, ТАССР-ның атказ. сәнгать эшлеклесе (1981). Бөек Ватан сугышында катнаша, медальләр белән бүләкләнә. Армиядән демобилизацияләнгәннән соң, Әгерҗе р-ны мәктәпләрендә укытучы булып эшли. Алабуга педагогия ин-тын (1953) һәм М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1961) тәмамлый. Әсәрләре 1950 еллар башында басыла башлый. Ә.нең "Язылмаган законнар" (1956) драмасы киң танылды. Минзәлә татар драма театры коллективы бу спектакль белән 1957 елда Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре декадасында катнашты. Аның "Гөлчәчәк" (1956), "Тамырлар" (1961), "Сатучылар" (1961), "Уҗым бозавы" (1966), "Минем җинаятем" (1968) пьесалары авыл хезмәтчәннәре һәм интеллигенциясенең мораль-әхлак проблемаларына багышланган. "Кан кардәшләр" (1972), "Очрашырбыз, Гөлсылу!" (1980) драмаларында, "Сафура буранналары" (1975) комедиясендә, "Кондырлы кодачасы" (1981) трагикомедиясендә шәһәр тормышы, нефтьчеләр көнкүреше бәян ителә. Ә. нең геройлары хезмәт сөючән, самими, халык традицияләрен дәвам итүчеләр. Аның күпчелек пьесалары Минзәлә, Казан, Әлмәт, шулай ук Башкортостанның Салават, Сибай халык театрлары сәхнәләрендә уйналды.

Әсәр.: Гөлҗәннәтнең җәннәте. Пьесалар. К., 1973; Драмалар, комедияләр. К., 1981; Очрашырбыз, Гөлсылу! Сәхнә әсәрләре. К., 1984.

Әд.: Гыйләҗев А. Ак нур белән // Казан утлары. 1971. №12; Әхмәдуллин А. Кешелекле иҗат//Дөреслеккә ирешү юлында. К., 1993.

*А.Г.Әхмәдуллин*

*Дәвамы киләсе саннарда*

## *«Казан утлары» архивыннан*

**Татарстанның халык язучысы Гариф Гарифҗан улы Ахунов (1925 — 2000) татар әдәбияты һәм шул исәптән "Казан утлары" тарихында якты эз калдырган шәхес. Редакция архивында аның байтак фоторәсемнәре бар. Без бу сәхифәдә Гариф аганың күмәклектә төшкән берничә фото-рәсемен сайладык. Чөнки ул һәрвакыт хезмәт кешеләре, каләмдәшләре арасында булды, әдәби хәрәкәтнең үзәгендә торып яшәде һәм иҗат итте.**



*"Казан утлары" журналының редколлегия әгъзалары. Беренче рәттә, сулдан уңга: Шәйхи Маннур, Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов, Ләбибә Ихсанова, Әмирхан Еники; икенче рәттә: Рәфикъ Нафиков, Атилла Расих, Шәүкәт Галиев, Рафаэль Мостафин, Гали Халит. Үткән гасырның 70 нче еллары.*



*Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыштан соң төшерелгән фоторәсем. Сулдан уңга: Фатыйх Хөсни, Сергей Викулов, Гариф Ахунов, Зәки Нури, Кайсын Кулиев, Сибгат Хәким, Җәмил Мостафин, Гази Кашшаф. 1971 нче ел.*



*Коми АССРда үткәрелгән Совет әдәбияты көннәре истәлеге. Уртада — Гариф Ахунов, белорус язучысы Микола Аврамчик, адыгей шагыйре Исхак Машбаш. 1974 нче ел.*



*"Кемнәр бар да, кемнәр юк..." Бер төркем язучылар Балтач районының атаклы Кара күл яры буенда. Бу рәсемдә Татарстанның халык язучысы, халык шагыйре исеменә лаек булган алты кеше бар. Шуларның дүртесе бакый дөньяга күчкән. Уртада — Гариф Ахунов. 1994 нче ел.*

*Берлекнең яңа әгъзалары*

## Хөсәен Вәлиәхмәтов



Вәлиәхмәтов Хөсәен Хәсән улы 1950 елның 22 декабрендә Әлмәт шәһәрендә туган. 1956 елда Вәлиәхмәтовләр гаиләсе Аксубай районының Иске Кыязлы авылына күчеп кайта, Хөсәен шунда урта мәктәпне тәмамлый. Беренче шигырьләрен, мәкаләләрен район газетасы, "Яшь ленинчы" газетасы, "Ялкын" журналы битләрендә бастыра. Ул чор турында Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Галиев болай язды: "Өлкән әдипләребез туган телебезнең киләчәген кайгыртып яшәделәр. 1965 елда "Яшь ленинчы" газетасы үткәргән конкурста Нәкый ага Исәнбәт, Хәсән ага Туфан, өчәү жюрида булдык. Йомгаклары турында газетада язып чыккан идем. Бер сәләтле укучының язганнары турында: "Шигырьләрен укып куандым. Көлке законнарын тоеп, чама хисен белеп язылган алар", дигән идем мәкаләмдә. Аксубай районы Иске Кыязлы мәктәбенең VII класс укучысы Хөсәен Вәлиәхмәтов иде ул. Әйе, хәзер инде танылган журналист, "Мәгърифәт" газетасының баш мөхәррире, республикабызның атказанган мәдәният хезмәткәре, психология фәннәре кандидаты, шул өлкәдә эшләүче галим-мөгаллим, кеше психологиясен тирәнтен ача торган әсәрләр язучы каләмдәшебез".

1968—1973 елларда Хөсәен Вәлиәхмәтов Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укый. 1989—1991 елларда Ленинград политология институтын тәмамлап, икенче югары белем ала.

Хезмәт юлын 1973 елда "Татарстан яшьләре" газетасының әдәби хезмәткәре булып эшләүдән башлый. Бу редакциядә ул 1985 елга кадәр эшли, аннан 1 ел Татарстан телевидение һәм радио программалары редакторы, ә 1986 елдан 1989 елга кадәр "Социалистик Татарстан" *(хәзерге "Ватаным Татарстан")* газетасында хезмәт итә.

Ленинградта укыганда да Х. Вәлиәхмәтов әдәби әсәрләр һәм публицистик язмалар иҗат итә. 1989 елда Татарстан китап нәшриятында аның "Камышлы күл сагышы" дигән детектив язмалар җыентыгы 30 мең данәле тираж белән нәшер ителә.

Политология институтын кызыл диплом белән тәмамлаган белгеч "Ватаным Татарстан" газетасына бүлек мөдире булып кайта. 1992 елдан республикабызда яңа оештырылган Матбугат һәм мәгълүмат министрлыгына эшкә күчерелә. Анда эшләгән дәвердә, чит илләрдә дә таралырлык итеп, рус һәм инглиз телләрендә чыга торган "Бизнес в Татарстане" журналын оештыра һәм аның беренче мөхәррире була. Бу хезмәтләре өчен аңа 1997 елда "Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре" дигән мактаулы исем бирелә.

1998 елдан Х. Вәлиәхмәтов "Мәгърифәт" газетасын җитәкли. Бер үк вакытта фән һәм иҗат эше белән дә актив шөгыльләнә. Бүгенге көнгә авторның төрле басмаларда һәм җыентыкларда дөнья күргән шигырь цикллары, әхлак тәрбиясе проблемаларына караган монографиясе, "Юлда чыныккан уллар" дигән документаль повесте *("Мәгариф", 2003 ел)*, "И, гомер!" дигән романы *(беренче кисәге "Мирас" журналында, 2000—2002 елларда басылды)* һәм башка әдәби әсәрләре бар.

"Хөсәеннең кайбер проза әсәрләрен укыгач, безнең прозаиклар арасына шактый саллы сурәтләү чараларына сәләтле әдип килә дип кинәнеп куйдым", — дип яза күренекле язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин үзенең тәкъдимнамәсендә. Яшь автор турында байтак олпат язучыларыбыз да шундый фикердә.

2005 елның 24 маенда Кабул итү комиссиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә язучылар: Шәүкәт Галиев, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Мәхмүт Әхмәтҗанов), Язучылар берлеге идарәсе Вәлиәхмәтов Хөсәен Хәсән улын Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## КҮПТӘН КӨТЕЛГӘН БӘЙРӘМ

Бөек композитор Салих Сәйдәшевкә һәйкәл кую мәсьәләсе җәмәгатьчелек тарафыннан моннан ярты гасыр элек үк күтәрелгән иде. Ниһаять, ул көн килде: 12 август көнне Казанның үзәгендә — Болак суы белән Кабан күле тоташкан җирдә Салих Сәйдәшевкә һәйкәл куелды. Һәйкәл шул ук көнне ачылган Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты каршындагы мәйданга урнаштырылды. Ике зур вакыйга унаеннан оештырылган тантананы кереш сүз белән Татарстан Премьер-министр урынбасары — культура министры Зилә Вәлиева ачып җибәрде. Төп чыгышны Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев ясады. Элеккеге педагогия институты нигезендә яңа ачылган университетның асылы һәм киләчәге хакында сөйләгәннән соң ул, композиторга куелган һәйкәл турында болай диде: "Салих Сәйдәшевкә һәйкәл кую уе ярты гасыр буе куертылып торган икән, димәк, ул безнең яныбызда, димәк, ул чыннан да бөек шәхес. Татар профессиональ музыкасына нигез салган, аны дөнья дәрәҗәсенә чыгарган Салих Сәйдәшев, ниһаять, республикада тиешле бәясен алды. Тукай белән Сәйдәш безнең кем икәнлегебезне, йөзебезне күрсәтеп тора, Алла боерса, гомергә шулай булачак".

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты һәм С. Сәйдәшевкә һәйкәл ачылу тантанасында Татарстанның халык шагыйре, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, "Татэнерго" берләшмәсенең генераль директоры Илшат Фәрдиев, ТДГПУ ректоры Җәмил Нигъмәтов, Татарстан югары уку йортларының ректорлар советы рәисе, КДУ ректоры Мәгъзүм Салахов чыгыш ясадылар.

Салих Сәйдәшевкә куелган һәйкәлнең авторлары — архитектор Мәхмүт Гасыймов һәм Герман Бакулин.

## УРАМНАРГА ЯҢА ИСЕМНӘР

Казан хакимияте башлыгы Камил Исхаков 16 июль көнне 1000 еллык шәһәрнең кайбер урам һәм тыкрыкларының исемнәрен үзгәртү турындагы карарга кул куйды. Шулай итеп, Калинин урамының бер өлеше (Вишневский урамыннан Иптәшлек урамына кадәр) Әмирхан Еники урамы, Володарский урамы танылган татар язучысы, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, журналист һәм публицист Гаяз Исхакый, ә Сакко һәм Ванцетти урамнары Татарстан Республикасы гимны авторы, композитор Рөстәм Яхин исемен йөртәчәк. Шулай ук Вахитов районындагы Мәктәп һәм Тукай тыкрыклары яңа исем ала. Беренчесенә иске исеме — Катанов тыкрыгы кайтарыла, ә икенчесе Казан дәүләт университетының танылган профессоры, тарихчы Худяков исемен алып, Михаил Худяков урамы дип аталачак. Ухтомский урамы исеме киләчәктә сәясәт эшлеклесе һәм Кытай мөселманнары җәмгыяте рәисе хөрмәтенә Борһан Шаһиди урамы дип йөртеләчәк.

Совет районындагы Революция урамының да исеме үзгәрә. Ул хәзер татар әдәбияты классигы хөрмәтенә Нәкый Исәнбәт урамы дип атала.

## КАЗАННЫҢ ШӘРӘФЛЕ ГРАЖДАННАРЫ

Казанның 1000 еллык юбилее алдыннан халык депутатларының Казан Советы карары нигезендә унөч кешегә: СССРның халык артисты Азат Аббасовка, ятим балаларны үз канаты астына алган Әсгат Галимҗановка, милиция майоры, тренер Наилә Гыйләҗевага, Совет районының элеккеге хакимият башлыгы Альберт Камалиевка, "Казан вертолет заводы" генераль директоры Александр Лаврентьевка, Социалистик Хезмәт Герое Илдус Мостюковка, Ветераннар советы рәисе Надежда Тимашовага, галим-тарихчы Миркасыйм Госмановка, академик Александр Фурсенкога, Россия сәнгать академиясе әгъзасы Харис Якуповка, Россиянең беренче Президенты Борис Ельцинга һәм бүгенге РФ Президенты Владимир Путинга, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевкә "Казанның мактаулы гражданины" дигән дәрәҗәле исем бирелде. Алар арасында журналыбызның редколлегия әгъзасы Миркасыйм Госмановның (Усманов) да булуы безнең өчен аеруча куаныч. Карар-

да болай диелгән: "Миркасыйм Габделхак улы Усманов —тарих галиме, язучы, ТР Фәннәр академиясе академигы, Казан дәүләт университеты профессоры, ТР Милли китапханәсенең фәнни киңәшчесе—фәнне үстерүгә керткән зур хезмәте һәм Россия халыкларының тарихын өйрәнү проблемаларын тикшеренүе, иҗтимагый эшчәнлеге өчен.

## ТӨРКИ ХАЛЫКЛАРГАҺӘЙКӘЛ

Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев җитәкчелегендәге Татарстан парламенты делегациясе Алтай Республикасында булып кайтты. Әлеге сәфәрнең максаты — бирелә төрки халыкларга багышланган һәйкәл куюга бәйле мәсьәләләрне тикшерү иде.

Сәфәр узган ел Татарстан һәм Алтай республикаларының югары вәкиллекле органнары арасында кул куелган парламентара хезмәттәшлекне үстерү турындагы килешү кысаларында оештырылды. Татарстан делегациясе составында Татарстан Президентының сәяси мәсьәләләр буенча киңәшчесе Рафаил Хәкимов, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, Дәүләт Советы депутаты Ринат Закиров, Архитекторлар берлеге рәисе, Кол Шәриф мәчете проекты авторларыннан берсе Искәндәр Сәйфуллин һ. б. бар иде.

Р. Вәлиев әйтүенчә, делегация әгъзалары визит барышында Алтай парламенты вәкилләре, республика җитәкчелеге белән очрашып, булачак һәйкәлнең проекты, аның урыны турында фикер алышкан. Моннан тыш, алар Алтай Республикасының кайбер районнарында булып, төрки халыкларның тарихи урыннарын караган. Һәйкәлгә исә "Алтай — төрки халыклар бишеге" дигән исем бирү күздә тотыла икән.

Делегация Барнаулда Алтай татарларының милли-мәдәни мохтәрияте активистлары белән дә очрашкан.

## ИСХАКЫЙНЫ ЯД ИТЕП

Гаяз Исхакыйның туган авылы Яуширмәдә быел да әдәбият-сәнгать җыены булып узды. "Исхакый укулары" дигән исемдә уза торган бу җыенның оештыручылары — Татарстан мәдәният министрлыгы, Камал театры һәм Татарстан Язучылар берлеге. Инде өченче тапкыр уздырыла торган бу бәйрәмнең инициаторы һәм оештыручысы, әлбәттә, Камал театры. Театр директоры Шамил Закиров һәм аның ярдәмчеләре, гадәттәгечә, бу җыенның төп мәшәкатьләрен үз өстенә алдылар. Бәйрәмнең программасы бик бай иде. Тантанада күренекле җырчылар, сүз осталары, татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле вәкилләре катнашты. Бөек шәхесне яд итәргә байтак язучылар һәм галимнәр дә килгән иде: Туфан Миңнуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Зәки Зәйнуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Хатыйп Миңнуллин, Факил Сафин, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Флера Тарханова... Яуширмә әдәбият йортында җыелган халыкка Гаяз Исхакыйның "Зөләйха" трагедиясе буенча эшләнгән фильм да күрсәтелде.

## ЭНЦИКЛОПЕДИЯНЕҢ 2 ТОМЫ

Татар энциклопедиясенең 2 нче томы басылып чыкты. Анда татар халкының һәм Татарстанның борынгы заманнан алып безнең көннәргә кадәрге тарихын һәм яшәешен яктырткан 3150 мәкалә һәм 1200 иллюстрация урнаштырылган. Бу томда Г — Й хәрефләренә туры килгән мәкаләләр урын алган. Бирелә бай фактик материаллардан тыш матур-матур иллюстрацияләр, карталар да бирелгән. Аларны әзерләүдә 413 кеше катнашкан. Тиздән Татар энциклопедиясенең татар телендәге тулыландырылган басмасын чыгару да күздә тотыла, аның 1 томын 2006 елның беренче кварталында бастыру планлаштырыла.

Татар энциклопедиясе барлыгы 6 томнан торачак.

## "МӘДӘНИ ҖОМГА"ГА — 10 ЯШЬ

"Мәдәни Җомга" газетасы чыга башлауга 10 ел тулды. Шушы унай белән газетаның махсус саны чыкты.

Газетаның баш мөхәррире Зиннур Мансуров "Мәдәниятле халык булып калыйк" дигән мәкаләсендә коллективның башкарган эшчәнлегенә анализ ясый.

Коллективны юбилее белән Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, мөфти Госман хәзрәт Исхакый, армия генералы Мәхмүт Гәрәев, мәгариф һәм фән министры Рәис Шәйхелисламов, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Илфак Ибраһимов, Премьер-министр урынбасары — авыл хуҗалыгы һәм азыктөлек министры Марат Әхмәтов, прокурор Кафил Әмиров, Казан шәһәр хакимияте башлыгы урынбасары Әлфия Тутаева һәм башкалар котлый.

Бу котлауларга "Казан утлары" журналы редакциясе хезмәткәрләре дә кушыла. "Мәдәни Җомга"га яңа иҗади уңышлар телибез.

## КАЗАН СУРӘТЛӘРЕ ТӨРКИЯДӘ

Башкалабызның тугандаш шәһәре Анталиядә "Фотоларда — меңьеллык Казан" дип исемләнгән фотокүргәзмә ачылды. Әлеге чараны Татарстанның Төркиядәге вәкаләтле вәкиллеге Анталия шәһәре ха-

кимияте белән берлектә оештырган. Башкаланың меңьеллыгы уңаеннан оештырылган бу күргәзмәгә Анталиядәге дипломатик вәкилләр, эре сәнәгать һәм сәүдә ширкәтләре, танылган туризм оешмалары чакырылган.

Әлеге чараның ачылу тантанасында чыгыш ясаган Анталия губернаторының урынбасары Бәкир Сыткы Ханлыоглу тугандашлык килешүе ике ил һәм ике халык арасындагы дуслыкны тагын да ныгытачагын, бу күргәзмәнең исә әнә шул юлдагы бер адым булуын белдерде. Казан шәһәре хакиме урынбасары Фәрит Ишмаков исә фотолардагы биналарның күбесен төрек ширкәтләренең төзүен билгеләп узды.

### ИГЪТИБАР: КОНКУРС!

"Идел" яшьләр үзәге һәм Татарстан Язучылар берлеге "Иделем акчарлагы" конкурсы игълан итә. Быелгы конкурс шәһәребез юбилее уңаеннан "И Казан! Нурлы Казан! Моңлы Казан!" дигән темага багышлана.

Иҗат әсәрләре проза, поэзия һәм драма жанрлары буенча кабул ителә. Шуның да искәртергә кирәк: быелгы бәйгедә проза һәм драма әсәре язучыларга аерым игътибар ителәчәк. Казан темасыннан тыш, яшьләр тормышын чагылдырган әсәрләргә дә өстенлек бирелә.

Төп таләпләр: бәйгегә тәкъдим ителгән әдәби әсәрләр татар телендә һәм компьютерда басылган булырга тиеш. Катнашучыларның яше 14 тән 30 гача чикләнә. Конкурста Татарстан Республикасында гына түгел, чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез дә катнаша ала. Иҗат әсәрләре белән хат юллаганда, конкурсантка үзе турында кыскача белешмә, төгәл адрес һәм хәбәрләшү өчен телефон номерын күрсәтү мөһим. Әсәрләрне "Идел" яшьләр үзәге, 420107, Казан шәһәре, Санкт-Петербург (элекке Свердлов) урамы, 12 нче йорт адресы буенча җибәрә аласыз. Хәбәрләшү өчен телефон: (8432) 78-98-63 яисә e-mail: mc-idel@yandex.ru.

### ДЕРЖАВИН РУХЫНА БАГЫШЛАНА

Лаешта мәшһүр шагыйрь, дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинны искә алдылар. Иң элек аның тормыш юлына, иҗатына багышланган чыгышлар булды. Аннары Державин исемендәге бүләкнең быелгы лауреаты, Чаллы шагыйре Николай Алешковка әлеге олы бүләкне тапшыру тантанасы узды.

Бәйрәм тантанасы Казанда, Е. Боратынский музеенда дәвам итте. Шагыйрә Наилә Ахунова җитәкчелегендәге "Ак карга" иҗат берләшмәсе яшь шагыйрьләр һәм шагыйрәләр арасында үткәргән "Державин бүгенге шигърият контекстында" дигән темага докладлар бәйгесенә йомгак ясалды. Державин шигырьләрен аһәнле итеп укучылар арасында да җиңүчеләр билгеләнде. Җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр, китаплар тапшырылды.

Кичен исә Горький урамындагы Лядов бакчасында, Державин һәйкәле янында язучы Владимир Корчагин, шагыйрьләр Ренат Харис, Валерий Тургай (Чуашстан), Фаил Сафин, Николай Алешков, Роза Кожевникова, Сергей Малышев, Илсөяр Иксанова, Альбина Әпсәләмова, Михаил Тузов, Качалов исемендәге театр артистлары, халык җыр, музыка коллективлары катнашында театрлаштырылган әдәби-музыкаль кичә булып узды.

Тамашаны шагыйрә Лилия Газизова һәм Качалов театры артисты Михаил Галицкий алып барды.

### ХӘТЕР

Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылында (элеккеге Кызыл Йолдыз районы үзәге) күренекле дин эшлеклесе, философ Идрис Зөлмөхәммәт улы Хафизның (халык телендә аны Хәлфә бабай дип йөртәләр) 355 еллыгына багышланган фәнни-гамәли конференция уздырылды. Анын эшендә күренекле галимнәр, язучылар, музей хезмәткәрләре катнашты.

Шул ук көнне Котлы Бөкәш урта мәктәбе бинасында туган як музее ачылды. Көннең икенче яртысында тирә-як авыллардан җыелган халык һәм килгән кунаклар Борынгы Чаллы шәһәре урынында булдылар. Хәзер тыюлык саналган бу җирдә унбиш метр биеклектәге манаралы капка төзелә башлаган. "Алтын капка" дип аталачак бу корылма быел Хәтер көненә кадәр төзелеп бетәргә тиеш. Киләр буын өчен бик тә әһәмиятле булган бу чараларда Балык Бистәсе районы хакимияте башлыгы Равил Хәйруллин, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, Татарстан мәдәният министры урынбасары Рафаэль Вәлиев, Татарстан Милли музее директоры Геннадий Муханов, тарих фәннәре докторы, археолог Фаяз Хуҗин, тарихчы әдип Нурулла Гариф, Котлы Бөкәш музееның төп оештыручысы Кәримулла Ахуновлар катнаштылар һәм чыгыш ясадылар. Тантанада шулай ук бу төбәктән чыккан дистәдән артык әдәбият-сәнгать вәкилләре дә катнашты.

### КАЛӘМДӘШЕБЕЗНЕ КОТЛАУ

Татарстан Язучылар берлегендә Уфада яшәүче күренекле галим һәм язучы, Галимҗан Ибраһимов турында трилогия иҗат иткән Суфиян ага Поварисов белән очрашу булды. Әдәби мәҗлесне Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, шагыйрь Илфак Ибраһимов ачып җибәрде. Ул Су-

фиян аганың әдәбият һәм фән өлкәсендәге хезмәтләренә югары бәя бирде.

Аннары Татарстан Дәүләт Советы Президиумы әгъзасы, Татарстанның халык шагыйре Роберт Миннуллин сүз алды. Күптән түгел С. Поварисов Президент М. Шәймиев Указы нигезендә "Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе" дигән мактаулы исемгә лаек булган иде. Р. Миннуллин ана шунын дипломын һәм күкрәк билгесен тапшырды. "Казан утлары" журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров һ. б. ил агасын мактаулы исемгә лаек булуы белән тәбрикләделәр.

## БӘЙРӘМГӘ РӘССАМ БҮЛӘГЕ

Президент Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә Татарстанның халык рәссамы Рәшит Имашевны кабул итте.

Республика җитәкчесе белән сөйләшү барышында танылган рәссам Казан Кремлендә элеккеге юнкерлар училищесы бинасында урнашачак рәсем сәнгате галереясенә үзенең берничә картинасын тапшырды.

Президент Казанның 1000 еллык юбилее уңаеннан тапшырган бүләге өчен рәссамга рәхмәт әйтте һәм Казан Кремлендә ачылачак картиналар галереясе сәнгать сөючеләрне һәрчак үзенә тартып торыр дигән ышаныч белдерде.

## "МӘГАРИФ" НӘШРИЯТЫНДА

***

Күренекле драматург Туфан Миннуллинның "Әлдермештән Әлмәндәр"е татар, инглиз һәм рус телләрендә дөньяга чыкты. Әлеге китап мона кадәр "Мәгариф" нәшриятында инглиз телендә басылып чыккан һәм чит илләргә таралган "Tatar literature today" ("Бүгенге татар әдәбияты"), "History of the Tatars" ("Татар тарихы"), "Tatar folk tales" ("Татар әкиятләре") һ. б. сафында үз урынын алды.

***

"ДИ ЭМ БИ" нәшрияты белән "Мәгариф" нәшрияты хезмәттәшлегендә татар телендә Татарстан Республикасының географик һәм социаль-икътисади карталары басылып чыкты. Атамаларның язылышы "Татарстан Республикасының административ-территориаль бүленеше" дигән белешмәлеккә һәм "Татар энциклопедия сүзлеге"нә нигезләнеп бирелде.

## ЭЛЕМТӘЛӘР НЫГЫЙ

Казаныбыз юбилее алдыннан башкалабызга Чуашстан Профессональ язучылар берлеге идарәсе рәисе Валерий Тургай җитәкчелегендәге Чуашстан Республикасы делегациясе килде.

Делегация составында Чуашстан Дәүләт Советы депутаты Леонид Григорьев, медицина фәннәре докторы Николай Григорьев, язучылар Иосиф Дмитриев, Светлана Азаматова һ. б. бар иде. Башкалабызның истәлекле урыннары белән танышканнан соң, кунакларны Казан шәһәре хакимияте башлыгы урынбасары Әлфия Тутаева кабул итте. Алар шулай ук Болгарга да сәфәр кылды.

## ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ...

Татар халкы бай әдәби мирас калдырган шәхесләрен һәрвакыт хөрмәт белән искә ала. Әле күптән түгел генә Арча районы Казанбаш мәктәбе укучылары Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гариф Ахунов истәлегенә багышланган кичә уздырды. Анда язучының хатыны Шаһидә Максудова, кызы Наилә Ахунова, язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин, Галимҗан Гыйльманов, әдәбият һәм сәнгать музее директоры Ринат Фазлыәхмәтов, район хакимияте башлыгы урынбасары Надия Мифтахетдинова да катнашты.

Укучылар Шаһидә ханымның Гариф Ахунов турындагы истәлекләрен яратып тыңлады. Соныннан кунаклар һәм укучылар язучының каберенә чәчәкләр салды.

## ПРЕЗИДЕНТНЫҢ РӘХМӘТ ХАТЫ

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләре хакына күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм татар милли әдәбиятын үстерүгә лаеклы өлеш керткән өчен язучы **Маликова Мәдинә Габделхак кызы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Әбиләр чуагы. **Р. Гомәров** эше.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Заһид Мәхмүди**.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Ркаил Зәйдулла. **Мәгарә**: Шигырьләр, поэмалар.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.—351 б. Тиражы—2000 данә.




Биш бүлектән торган бу китапны Ркаил Зәйдулланың сайланма шигырьләр китабы дип атарга була. Аңа шагыйрьнең үткән гасырның 80 нче елларыннан башлап бүгенгәчә язылган шигырьләре тупланган. Соңгы елларда прозаик һәм драматург буларак танылып барган әдип бу китабы белән үзенең зур шагыйрь икәнен дә раслый.

"Ркаил Зәйдулланың яңа җыентыгы шигърият сөючеләрне битараф калдырмас. Күзендә Татар моңы булган һәркемгә дә юллана әлеге шигырьләр. Газиз халкыбызның язмышы хакында уйланулардан тыш, биредә—ихлас мәхәббәт хисләре, хушлашу сагышы һәм киләсе көнгә өмет..." диелә китапның аңлатма-аннотациясендә.

Китап ахырында каләмдәшләренең Ркаил Зәйдулла иҗаты турында фикерләре цитата рәвешендә урын алган.

Китапның мөхәррире—Р. Корбанов, рәссамы—Н. Воропаева.

Газинур Морат. **Төнге әверелеш**: Шигырьләр, поэмалар.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.—399 б. Тиражы—2000 данә.




Газинут Морат—талантлы шагыйрь һәм публицист. Моңа кадәр дә һәр ике сыйфатта аның китаплары чыккан иде инде (2002 елда "Җәяүле кошлар" исемле публицистик әсәрләр һәм мәкаләләр китабы чыкты).

"Төнге әверелеш"—Г. Морат шигъриятенең тулырак басмасы; китапка шагыйрьнең төрле елларда язылган иң яхшы әсәрләре тупланган. Китап, нигездә, шигырьләрдән торса да, анда шулай ук шагыйрьнең мәгълүм поэмалары ("Ачлык", "Вакыт машинасы", "Лонч-Кеш", "Түбә", "Атом-кирмән") да урын алган.

Китапның ахырында Газинур Моратның иҗаты турында күренекле шагыйрь һәм мөхәррир Зиннур Мансуровның "Чичәннәр кайтавазын кемнәр көчәйтә?" дигән мәкаләсе бирелгән. Анда бер урында болай диелгән: "Газинур Моратның күпкырлы иҗатында милләт гаменә һәрдаим өстенлек бирелә. Гомумән, аның хәтта шәхес буларак фикер йөртүе дә шушы бөек уй-хис белән ашланган күк тоела: әдәби иҗатта да, иҗтимагый эшчәнлектә дә, көндәлек яшәештә дә..."

Китапның мөхәррире—Р. Корбанов, рәссамы—Р. Хәсәншин.

Индекс 73210



Заһид Мәхмүди

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)